ISSN 0[illegible]-[illegible]189

# Казан утлары

1. 1992



*Авторлар игътибарына*

Редакция кулъязмаларны рецензияләми, әсәрне журналда бастыру-бастырмау турында гына авторга хәбәр итә.

Кулъязмалар, автор тарафыннан почта чыгымнары алдан түләнгән очракта, кире җибәрелә.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**1**

**(831)**

**1992**

КАЗАН

## *Бу санда*

### ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ә. Рәшит. Колшәриф. *Поэма* ........ 3
Р. Кәрами. Каргышлы юллар. *Роман* ........ 17
З. Мансуров. Соңгы сәхнәгә бару. *Шигырьләр* ........ 83
Г. Рәхим. Җәгүр дәдәй дәмәкләре ........ 89

### ПУБЛИЦИСТИКА

М. Юныс. Шәфкать кыйбласы ........ 115
Ф. Әхмәтова. Камиллеккә омтылу ........ 123
Р. Сибгат. Башкортстан татарлары һәм аларның теле ........ 129

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. Хәсәнов. Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер методологик мәсьәләләре ........ 141
Н. Нәжми. Гомернең дәвамы ........ 147
Р. Вәлиев, М. Мәһдиев. Болганчык еллар авазы ........ 153

### ТАРИХ ДӨНЬЯСЫНДА

Яшерен васыять *(Керәш сүз белән)* ........ 166

### СӘНГАТЬ

И. Илялова. Үзебезнеке, халыкныкы! ........ 169

### КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. Әмирхан. Борынгы тамырлар эзеннән ........ 174

### МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Р. Мөхәммәтҗанов. Ел фасылларына бәйле йолалар һәм җырлар ........ 177
Котлыйбыз ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 187
Китаплар дөньясында ........ 190
Тышлыктагы сурәтләр ........ 192

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**

**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**

**Тәлгат Галиуллин**

**Аяз Гыйләҗев**

**Салих Маннапов**

**Зиннур Мансуров**

**Рөстәм Мингалимов**

**Фәрвәз Миңнуллин**

**Минтаһир Минһаҗев**

**Мөхәммәт Мәһдиев**

**Ринат Мөхәммәдиев**

**Рашат Низамиев**

***(баш мөхәррир урынбасары)***

**Индус Таһиров**

**Марс Шабаев**

***(җаваплы сәркатип)***

**Тәуфикъ Әйди**

**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары —
53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият,
очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа Р. КАРАМИ «Проклятые дороги», короткие рассказы Г. РАХИМА из жизни крещенных татар; поэма А. РАШИТА «Кулшариф», новые стихи З. МАНСУРОВА.

«Публицистика»: М. ЮНУСОВ. «Путь к милосердию»; Ф. АХМЕТОВА. «Постижение совершенства»; Р. СИБАГАТ. «Татары, живущие в Башкортстане и их язык».

«Литературная критика»: М. ХАСАНОВ. «Некоторые методологические проблемы изучения истории татарской литературы»; Н. НАДЖМИ. «Продолжение жизни»; Р. ВАЛИЕВ, М. МАГДЕЕВ. «Голоса смутных времен».

«Страница истории»: «Секретное завещание Петра I».

«Искусство»: статья И. ИЛЯЛОВОЙ о творчестве актера Халима Залялова.

«Книжное обозрение»: Р. АМИРХАНОВ рецензирует книгу Г. ДАВЛЕТШИНА «Духовная культура Волжских булгар».

«К истории культуры»: Р. МУХАМЕТЗЯНОВ. «Обычаи и песни, связанные с временами года».

«В мире книг».

Поздравляем юбиляра.

Дневник общественно-политической жизни.

На наших обложках: картина Н. Лотфуллина «Философ»; портрет известного писателя и литературного критика Р. МУСТАФИНА.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Шамил Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Г. Хөснетдинова.

Производствога бирелде 15.11.1991 ел. Басарга кул куелды 14.01.1992 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 38515. Заказ И-536. Бәясе 1 сум 80 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1992 ел.

# Әхмәт Рәшит

## Колшәриф

поэма

### I. Баш сүз

Бисмиллаһи рахман ирахим, дип,
Башлыйк әле сүзне, туганнар!
Шул сүз белән эшкә керешкәннәр
Безгә кадәр җирдә булганнар.

Ә без әллә өлгермәбез, дидек —
Чаптык — вакыт аз күк тоелды,
Заман белән заман аймылышты —
Бик күп нәрсә... җиргә коелды.

Чәчәк чәчсәк, билчән үсеп чыкты,
Дөнья куыйк, дидек, иң элек.
Кудык, кудык, әмма тоталмадык,
Ә күңелдән качты изгелек.

Алланы бар һәм бер диеп белгән
Бабалардан гыйбрәт аласы.
Кем булсаң да, халкың үткәненнән
Йөз чөермә, заман баласы.

Калдырып тор юк-бар мәшәкатең,
Тыңлап кара чорлар тавышын;
Урап кайтыйк, әйдә, борынгыдан —
Заман белән заман кавышсын.

### II. Кичке азан

Фал китабын ачты —
«Хак тәгалә
Тәкъдирләргә нәрсә язган соң?
Кемне данлап яшәр шәһре Казан?
Кайсы якка агар Казансу?

---

Әхмәт РӘШИТ (1936) — *шагыйрь, публицист әдип, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән унга якын китап («Хатирә», «Сәяхәтнамә» «Киек каз юлы») авторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Икенде дә житкән...
Ага гомер...
Ага...
Ага...
Яшәү — фанилык...

Фанилык та...
Әмма сабыйларга
Әйтер сүзең әйтеп кал элек.
Ишетсеннәр...
Көч-куәткә каршы
Көч-куәтләр куеп базганчы...»

Шундый уйлар белән,
Акрын гына
Манарага менде азанчы.
Манарага менде
Озак итеп
Карап торды шәһре Казанны.
Йөрәкләргә салып ниндидер шом
Бер моң булып чыкты азаны.

Күзе яшьле иде карт мәзиннең,
Тыныч түгел иде күңеле;
Тирә-юньне камап алган чиру
Тагын мәкер кора түгелме?

Иртәгәме... бәлки бүген үктер...
Барыбер дә алыш буласы;
Изге яуда мөэмин-мөселманның
Хозыр-Ильяс булсын юлдашы.

Дүрт кыйтгага очты изге аваз —
«Аллаһе әкбәр!» дигән дүрт нида.
Әһле ислам дошман ниятеннән
Белми иде әле берни дә.

Килде халык шулай көндәгечә,
Намазга дип, җәмигъ мәчеткә...
Озак итеп вәгазь сөйләнелде,
Таралмыйча гына ят-читкә.

Телгә керде пәйгамбәрле чорлар,
Ходай телдә булды һәрдаим.
...Икенде дә тәмам.
Әмма һәркем
Таралмыйча торды бер кавым.

Миләр түнгән.
Михраб диварында
Күзгә чәнчеп керә һәр хәреф.
«Ни өчендер күнегелгән төштә
Күренмәде бүген... Колшәриф.

Афәтләрдән илне саклар өчен
Берәр чара бәлки күрәдер?
Бу низаглы чорда ул Казанда
Ышанырдай кеше...
Бердәнбер...»

Сабыр гына аннан кузгалдылар...
Бергә иде яхшы-яман да.
Һәркем эчтән ләгънәт укып кайтты
Афәт алып килгән заманга.
Көндәгечә өмет нуры сирпеп
Мөэминнәрнең яше-картына
Кызыл кояш кабат кереп качты
Ослан тауларының артына...

## III. Гөнаһларын кая куярсың...

Намазга дип тәһарәтен алгач,
Җыенганда җәмигъ мәчеткә,
Колшәрифкә мәктүб тоттырдылар,
Шыпырт кына ымлап бер читкә.

Кем икәнен сәет танымады...
Тик аңлады: мөһим эш белән...
Яшереп кенә бирә торган булгач,
Китергәндер кирәк кешедән...

Килгән адәм ничек пәйда булса,
Шулай юкка чыгып эреде;
Бу хәл бүлмә эңгерендә калган
Сәет өчен хәтта сер иде.

Ул мәктүпне ачты кабаланып...
Якынрак килде яктыга...
Язу... таныш иде... кинәт аның
Күзләреннән яшьләр актылар.

«И Колшәриф!..» — дигән иде анда,—
«Мин бит аккош идем — ил-йортта;
Хәзер исә ятлар тозагында
Көне-төне канлы яшь йотам».

Тыныч кына укып булмый иде
Кинаяле, утлы сүзләрне...
Бу кадәрле каргыш тулы язу,
Их, күрмәсен иде күзләре.

«Бәкләр сүзе сүздер, дидеңме син —
Шатлансыннар — сүнә кояшым...
Мин читлектә яралы кош бүген —
Гөнаһларын кая куярсың?!

Шаһгалигә хатын итмәкчеләр —
Үкереп-үкереп яшьләр коярсың.
Карт каргага аккош тиң булырмы —
Гөнаһларын кая куярсың?!

Сабыемны поплар чукындырды —
Кяфергәме ләхет уярсың...
Хак динебез мәсхәрәгә калды —
Гөнаһларын кая куярсың?!

Син мөнәҗәт яздың «Аллаһу» дип,
Һәр гамәлең саен «һу» дидең —
И Колшәриф, синең сүзләреңне
Изге диеп йөргән мин идем.

Инде китап сүзе сөйли-сөйли,
Яннарыңа кемнәр җыярсың?!
Җыен чыпчык — тәхет тирәсендә —
Гөнаһларын кая куярсың?!

И Колшәриф, антлар эчтең миңа —
Ант бозарга ничек кыярсың?
Барасы бар алла каршысына —
Гөнаһларын кая куярсың?!

Бабам кулы таҗ кидергән колның
Турунына башлар иярсең;
Ил-йортыбыз пыран-заран килә —
Гөнаһларын кая куярсың?!

И Колшәриф!..»
Мәктүб озын иде...
Сикереште сүзләр...
Уйнады...
Ике күзен яшьле пәрдә каплап,
Зарый-зарый йөрәк елады.

Ул сыгылып төште...
Хәле китте...—
Гомер буе юкса нык иде.
Әллә нинди хәлләр булганда да,
Йомшарганы болай юк иде.

Телде, телде, телде җанны өч сүз,
Гел-гел телеп торыр — тоярсың:
«Гөнаһларын кая куярсың...»
«Гөнаһларын кая куярсың...»

Гомере буе Хак юлында йөреп,
Һәр гамәлен Хакка багышлап,
Карт көнендә шулай гөнаһ җыеп,
Калдымыни ялгыз, байгыштай?!

«Кем уйлаган болай булыр диеп,
Изгелектә иде нияте.
Мәскәү илчесе бит вәгъдә бирде,
Аңа каршы кем соң ни әйтте?!

Саклап калыр өчен ил тәхетен
Корбан иткән идек аккошны;
Ходай язган, диде, үзе күнде —
Ала хәзер болай ник һушны.

Ялгыштыңмыни соң, и Колшәриф,
Сизмәдеңме хәйлә-мәкерне,
Алдандыңмыни соң карт көнеңдә,
Аермыйча туры-кәкрене.

Карчыгамы тәхет биләгән зат,
Каракошка бер җим булмасмы?

Бездән битәр күбрәк тыңламасмы
Мәскәүләрдән килгән тылмачны?

Мин бит алла түгел, алла колы,
Кайдан барын белеп бетерим!
Казан иле исән калсын өчен
Тагын нинди корбан китерим?!»

Хәлсезләнеп чүкте намазлыкка,
Шөкер итеп алла барлыкка,
Елый-елый тәкърарлады бары:
«Ярлыкагыл, ходам, ярлыка».

## IV. Төш юрау

Йокылары качкан Колшәрифнең...
Кояш чыгып килгән чак иде.
Хан катына чакырып кичекмәстән
Йомышчы карт ишек шакыды.

Йәдгәрне дә, димәк, йокы алмый,
Димәк, ул да тирән борчуда.
Карчыга ук булмаса да...
Барыбер
Канда булган ярсу бер чыга.

Кол булалмый хаким булып туган —
Буйсыну һәм куну юк аңа!
Хаким булып яшәү бик җиңел дә,
Бик авыр да икән дөньяда.

Керде... күрде... зурлап сәлам бирде...
— Ни боерың,— диде,— баш өсте!
Йәдгәр эндәшмәде. Ишарәләп
Утырырга кушты.

Озак дәшми торгач сүз башлады:
— Мин төш күрдем, сәет...
Юрарсың...
Әйткән фалың мине сөендерсә,
Ни теләсәң, шуны сорарсың.

— Баш өсте!..— дип кабатлады сәет,—
Тик әйтмәмен фалның киресен...
Сөендерсә, сөендермәсә дә,
Мин сөйләрмен... фәкать дөресен.

— Йә, хуп!.. Кыю сүзең ошый миңа...
Мин дә сөймим башлар игәнне...
Ханнар тирәсендә йөри-йөри
Онытмагансың курку дигәнне.

— Куркам диеп...
Шушы яшькә җиткәч,
Калтырап ук инде төшимме?
Хак хакыйкать салган иманыма...
Я, Йәдгәрхан, сөйлә төшеңне.

— Без бостанда, имеш, утырабыз...
Кәнизәкләр бии...
Җыр да моң...
Мин дә, уйга чумып, озак кына
Сорнай авазларын тыңладым.

Син кунаклар белән гөр-гөр, имеш,
Җыру әйтеп, кыйсса сөйлисең...
«Хөбби Хуҗа» дисең...
Күңелләр хуш!..
Алда нигъмәт — нәрсә телисең...

Кинәт кенә шунда әллә кайдан
Яңгырады аккош тавышы —
Җан ачысы белән өзгәләнә...
Әй кычкыра — шундый сагышлы.

Мәҗлеснең дә кинәт яме китте,
Пәйда булды кинәт бер читлек;
Имеш, аккош шунда бәргәләнә,
Коткарырга, дибез, тик ничек.

Мин ачарга куштым ул читлекне...
Син ачтың да...
Аннан «Кар!» да «Кар!»,
Көтү-көтү булып,
Өерелеп
Очып чыкты бары каргалар.

Урап алар мәчет манарасын
Кунмакчылар айның очына.
Без аптырап, хәйран калып тордык...
Мин уянып киттем шушында.

...Ни әйтергә белми торды сәет.
— Йә, Колшәриф, юра, юш килсен.
Ил капкасын дошман какмасын... һәм
Кунак булып илгә дус килсен.

Урамакчы иде бик ерактан,
Ләкин сәет читкә бормады,
— Бик хикмәтле икән төшең, — диде, —
Ханнар гына күрә торганы.

Төшеңдә ни булса — өнеңдә шул...
Өнеңдә ни? —
Идел аръягы...
Карга көтүе күк чиру баскан...
Хәвефләнер ниең бар тагын?

— Яу чыгыйк дип әйтми торгансың бит?..
— Юк, юк, ханым, алла сакласын...
— Килгән чиру бер көн кире китәр,
Капкаларын гына какма син.

Алар тимәсәләр, без тимәбез,
Кирәк түгел безгә җиһаның...
— Ходай сакланганны саклармын, ди,
Гафил булмыйк, димен, и ханым.

— Сүз куешкан, вәгъдә-иман, диеп,
Иван белән куллар бирешкән.
Башка кайгың юкмы — котылып тор
Сугыш атлы кыен ул эштән...

Син әйт, менә, аккош турысында...
Анысы... Сөембикәме, синеңчә?..
..Күзгә бәреп сорау бирде Йәдгәр —
Ул дигәнчә булыр — ни дисә?!

Ни әйтергә аптырады сәет —
Әйталмады, юк, дип, дөрес, дип...
Гел дөресен генә сөйләп булмый,
Хакимнәрдә бүтән дөреслек.
Әйтте сәет, күзгә туры карап:
— Анысы безнең шанлы дәүләтебез,
Җиңә алмас аны беркем, — дип, —
Читлектәге кебек бәргәләнә —
Җитми бүген аңа иркенлек.

Кояш чыгышымы, баешымы —
Ят чирүләр баскан бар җире;
Чукымакчы безнең шул аккошны
Төшеңдәге карга өере.

— Йә, хуп...
Никтер миңа соңгы вакыт
Әллә нинди юньсез төш керә...
Ярар...
Эшеңдә бул...
Моннан ары
Сөембикәне искә төшермә!..

Авыр уйлар уйлап китте сәет —
Уйламаслык җирдән уйларсың!
Ә колакта өч сүз чыңлап торды:
— Гөнаһларын кая куярсың?..
Гөнаһларын кая куярсың?..
Гөнаһларын кая куярсың?..

## V. Фетнә

Иртән, намаз беткәч, Аңбилде би
Серле генә итеп ым какты;
Әйтер сүзе бардыр Колшәрифкә...
Ярар, тыңлар, әле бар вакыты.

Халык кайсы кая таралышкач...
Юк-бар йомыш табып Аңбилде
Бөтерелде михраб тирәсендә,
Аннан Ходайколны апкилде.

— Сәет, сиңа бик зур сүзебез бар...
Бик мөһим сүз синең өчен дә...
Атлый-атлый бәлки сөйләшербез,
Яхшы түгел... мәчет эчендә.

Кузгалдылар тотып таякларын,
Әкрен генә корып әңгәмә.
Тәкъва картлар, дияр иде берәү,
Читтән карап торса әгәр дә...

Аңбилде би әйтте:
— Гаҗәпләнмә,
Фетнәләр дип уйлап, аптырап,
Иркенләп бер сөйләшеп тә булмый —
Һәммә җирдә йөз күз, мең колак.
Безне борчый Идел аръягында
Тыз-быз килгән урыс чиреүе...
Зөя буенда бит тиккә түгел
Аның кальга корып йөрүе.

Берәр чара күрик мәллә, сәет,
Йөреп булмый болай исәреп.
Йоклап калсак, ходай ярлыкамас...
— Ә хан?..— диде кинәт Колшәриф...
— Ни уйлавын ханның белеп булмый...
Ул бүген хан безгә, ә аннан...
Кыскасы, шул... диван хәл итсен дә...
Ул чагында курка кем ханнан?..

— Бу бит фетнә!
Ходай каршысында
Нәрсә диеп җавап бирербез?!
...Ходайкол да усал итеп әйтте:
— Соң алайса шулай черербез.
Таш капчыкта күпме яшәп була —
Ни икмәгең җитми, ни суың...
Урыс кешеләре җыеп алды
Тау ягының бөтен басуын...
Белә сәет, белә:
Туган йорты,
Газиз җире шушы төбәктә.
Һич кайтара алмый карышын да,
Ходайга мең теләк теләп тә.
Ләкин ничек?
Нинди тылсым белән?..
Йөз илле мең чиру — Зөядә.
Биш мәртәбә азрак көчең белән
Сугышырга чыгам, димә дә!

— Юк, җәмәгать!—
Колшәрифнең сүзе
Әмер сыман кискен, нык иде.
— Япан кырга чыгып кара-каршы
Сугышыр көч бездә юк инде.

— Соң, алайса нәрсә итәбез соң?—
Ходайколны сүзе сәетнең
Тәмам мингерәтте.
Әйтерсең, ул
Сәбәпчесе иде гаепнең.

Ә Колшәриф әйтте, бераз баргач:
— Көч-коралсыз гына туктасын...

Күндерергә кирәк яшь Иванны...
Безгә каршы сугыш чыкмасын.
Мин бит беләм аны...
Шактый куркак...
Һәр кешесен шикле дип карый...
Артында бит аның котыртучы
Кара шәүлә генә — Макарий.

Кара мәче җибәрергә иде
Җайлап кына ике арага...
Сугыш кына булмый калсын берүк...
Ярап торыр нинди чара да.

Йәдгәр ханга әләк җитмәс борын
(Казан аны барыбер ят саный!)
Син, Аңбилде, князь Петрны күр,
Ә мин капшап карыйм... патшаны.

...Таралдылар берни булмаган күк...
Яна иде эчтә зәһәр ут...
Ни кылырга мөмкин — мәгълүм иде,
Тик исәптә иде һәр минут.

## VI. Сарай сере

Серледән дә серле нәрсә серле?
Колшәрифнең инде нык уе;
Бу — теге чак мәктүб биргән затның
Пәйда булып юкка чыгуы.

Уйлап-уйлап очына чыгалмады —
Кергән, ләкин беркем күрмәгән...
Ваемсыз җан, ул бит җыру язып,
Намаз укып кына йөрмәгән.

Ул Тутыйны дәште уйлый торгач,
Тутый — ятим мари малае;
Элегрәк, Мәскәү явыннан соң
Улы иткән иде ул аны.

Диварларны Тутый капшап чыкты,
Һәр ярыгын бакты идәннең,
Түшәм исә тоташ актан иде —
Һич юк иде ул сер дигәнең.
Күчерделәр китап киштәсен дә,
Карадылар ятак астын да...
Әллә ниләр вәгъдә итте сәет,
Башың җитеп серне ач кына.

Тирләп чыкты малай: ышанычны
Булмас микәнни соң, һәй, аклап?
Почмакта тик калды иңе, буе,
Бисклеге тигез таш шакмак.
Ул нәрсәгә монда кирәккәндер:
Утырырга — биек, ятсаң — тар...
Тартып карадылар — кымшанмады...
Төшенделәр ләкин: нидер бар.

Аударам дип, Тутый үзенә таба
Тарткан иде — бик тиз биреште.
Аста исә кара чокыр иде,
Тап-тар чокыр, кеше керешле.

Хикмәт менә нидә булган икән?!
Яшерен юл, димәк...
Тик кая?
Ул арада Тутый аска чумды —
Һәй бу малай!
Җендер — бик чая.
Үз баласы аның булмады шул —
Йөкле чакта үлде хатыны...
Инде менә карый ятимнәрне...
Ялгыз иргә бала ятмыни?!

Савап булыр ходай каршысында,
Сабыйларның кибәр күз яше...
Аерма юк — читме, үзме? — бала...
Мөселман дип тигез сөясең.
...Никтер озаклады...
Колшәрифне
Борчу биләп алды.
Ул, көтеп
Көтек булгач, идән чокырыннан
Килеп чыкты Тутый ялт итеп.

— Әти, әти, — диде, — була анда
Иелмичә генә барып та...
Мин йөгердем әле...
Барган юлым
Килеп чыкты куе таллыкка.
— Булдыргансың, бәбкәм...
Таллык, димсең?
Син бел дә бу юлны, мин белим...
Шундый чая улым була торып,
Ятларга мин ничек җиңелим?!

Иртәгә без икәү таң алдыннан
Качып кына чыгып китәрбез.
Сизми калыр, димәк, һичкем безне —
Бар саклардан шома үтәрбез.

Туган җиргә, бәбкәм, сугыш яный —
Корал тота кече-олыбыз,
Газават дип илне күтәргәндә
Бергә булсын иде юлыбыз.

## VII. Көтелмәгән очрашу

Мәскәүләргә сәет таныш иде.
Ул, карамый акка-карага,
Илче булып байтак киләп сарды
Казан белән ике арада.

Төрле чаклар булды
Мәскәү аны

(Илчедә соң юкса ни гаеп?)
Каршылады кайчак чырай сытып,
Каршылады кайчак елмаеп —

Иелгән баш — кылыч кисмәс, диеп,
(Бусы соңгы чара бит инде!),
Ул, Айшәдә аркадашлар табып,
Төнлә белән кичте Иделне.

Шома үтте патша станын да —
Элеккеге ярлык ярады,—
Тик, сарайга җиттем, дигәч кенә
Уйланылган уйлар таралды.

Кем көткән бит?..
(Юкса сарайда да
Патша уянмаган чак әле!)
Гөнаһ шомлыгына каршы, аннан
Килеп чыкты кинәт... Шаһгали.
— Ә, синмени, сәет?..
Йә, ни йомыш?
Син килгәнсең икән, кем дисәм...
Сине әле асмадылармыни?..
Ничәмә хан үлде...
Син исән...

— Сәлам бирү кирәк... мөселманга...—
Ахры дәшми калып булмады.—
Юкка мине болай битәрләвең,
Мин бит сиңа зыян кылмадым.

— Сез барчагыз җәнҗал куптаручы,
Барчагызны асып куясы...
Астын-өскә китерәбез әле,
Чөнки Казан — елан оясы.

Син ишекне, сәет, ялгышкансың —
Дөньяви эш синнән торырмы?
Изге атакайга — Макарийга
Мөрәҗәгать итсәң — урынлы.

— Иван мине сабый чактан белә...
Әтисе дә белде... элек тә...
— Буш түгел шул
Патша хәзрәтләре...
Казан кызы белән ял итә...
Хи-хи-хи-хи!

Ул борылып кире кереп китте...
Кашып калды сәет җилкәне;
Түбәнчелек белән баш ияргә
Шуңа туры килер микәнни?!

Юк, юк, булмый...
Булмый булгач, булмый —
Шул гөберле бака кабаттан
Утырсынмы Казан тәхетенә?..
Мин түгелме ил дип җан аткан?..
Өйгә, өйгә... өйгә...

Казаныма!
Һәрбер сүзем уктай атылсын.
Һәр таш ядрә булсын, һәр йорт — кальга,
Дошман безне, әйдә, татысын.

Илен, телен, динен сатучылар
Моннан соң да булыр... табылыр.
Тик барсына халык исеменнән
«Хаин» дигән исем тагылыр.

Агач янса, исән орлык кала,
Ашлы туфрак кала, җил кала.
Җил-давылга баш имәслек булып
Җаннан газиз туган ил кала.

## VIII. Соңгы дога

Һәм башланды.
Күзгә аяз көнне
Мәхшәр купты һәммә җирдә дә;
Икеләнеп торгач алай-болай,
Салды бугай тарих җирәбә.

Дер селкетте нидер бөтен җирне.
Курку алды бала-чаганы.
Керер тишек тапмый чапты алар —
Мыштым булды шугы-шаяны.

Әбиләрнең «Урыс килә!» дигән
Куркытуы ахры рас килде:
«Урыс, урыс, усырак» дип үртәп,
Хәзер менә аннан кач инде!

Ә олылар кулга корал алды
Олыларның эше — куркыныч.
Ил хәтле ил хәле мөшкел чакта
Ятар икән өйдә кем тыныч?!

Күрше белән күрше әрләшкәндә
Ярты сүздә калды туктапып;
Чапты алар дошман каршысына
Бер-берсеннән җәя-ук алып.
Бистәләрдән шәһәр үрләренә
Ябырылды ирләр, егетләр...
Һәркайсында теләк бер булганга,
Кирәкмәде гозер-үгетләр.

Яуды аска уклар...
Атылды таш...
Акты су һәм кайнар сумала...
Изге җир бу!
Анда ансат кына
Бил бирер зат әле тумаган!

Бөтен яктан чебен өере күк
Ябырылган чиру ни санда?

Килә, килә, килә тора чирү,
Үлә, үлә, үлә торса да...

Кыза, кыза, кыза һаман сугыш,
Арта һаман, арта корбаннар.
Соңгы кәчкә инде селтәнәләр
Капкаларда кизү торганнар.

Тышкы яктан җанлы ташкын килә —
Мөмкин түгел кырып бетерү...
Ут ялмады менә коймаларны,
Менә утте алар күперне.

Һәм тетрәнде кинәт алгы сафлар —
Акрын-акрын артка чигенде.
Ә кайда соң, кайда өстәмә көч,
Килеп җитми һаман ник инде?

Казаннарда сафлар сирәгәйгәч,
Карышыр көч беткәч аларга,
Мәскәүләр (шул иске гадәт инде)
Бәреп керде өйләр таларга...

Кырып юлда торган бар җанлыны,
Тарткалашып алар үзара,
Талаганын илтеп яшерде дә,
Кабат килде байлык эзләргә.
Кинәт аваз салды бер әзмәвер:
— Секут...
— Секут...
— Беги... басурман.
Бар табышны ташлап йөгерделәр,
Әрәм итте талап яшергән.

Башлыклары тотып тукмамаса,
Чабасылар иде, һәй, ерак!
...Бераз тынып торган сугыш кинәт
Дөрләп китте тагы да көчлерәк.
Ә Колшәриф — алтмыш тутырган карт,
Бетмәс икән көч бу җанда да.
Кяферләрне Гали ничек кырса,
Шундый гайрәт бүген анда да.

Телдә — Коръән сүзе...
Кулда — кылыч.
Менә кем ул илдә карчыга!
Ак фәрештә сыман ак киемнән,
Кайда кысен — шунда ашыга.

Як-ягында якын шәкертләре,
Кайсы нәрсә кулга күтәргән;
Ант иткәннәр алар йә җиңәргә,
Йә, ил өчен шәһит китәргә.

Кыза сугыш... Ава газиз җаннар...
Ага каннар... арта корбаннар.
Ә Мәскәүләр инде өер-өер
Кальгага да кереп тулганнар.

Үлем бии һәрбер карыш җирдә —
Газраилгә бүген тантана.
Ничә җанын алдың мөселманның,
Кяфернекен ничә — бар, сана.
Мондый сугыш, миһербансыз сугыш
Мең елга бер була торгандыр.
Кими көче, кими Казаннарның —
Сәгатьләре суга торгандыр.

Куллар талган...
Баш-күз тәмам тонган...
Соңгы ыргу... Соңгы селтәнү.
Кинәт кемдер арттан, искәртмәстән,
Гөрзи белән орды җилкәне.

Ә Колшәриф...
Борылып бакса артка:
Үз шәкерте тора...
Һәм сәет:
«Бәддога!..» дип кенә әйтә алды,
Барып төште җиргә чөнкәеп.
Якындагы урыс укчылары,
Гаҗәпсенеп башта бу эшкә,
Колшәрифне өскә күтәрделәр,
Як-ягыннан алып кылычка.

Күз күрер җир тоташ үлек иде —
Димәк, көчләр инде калмады...
Бу вәхшәтне күзе генә күрде,
Теле белән әйтә алмады.

Канга тәмам гарык булган дөнья
Ишетмәде аннан бер «Аһ!» та.
Тик, гөнаһлы җирдән аерылып,
Җаны тыныч...
Очты оҗмахка.

Бик битараф кына нурын сирпеп
Үлгәннәрнең яше-картына,
Кызыл кояш кереп бара иде
Ослан тауларының артына.

И Раббем! Хак динебезне, күркәм гореф-гадәтләребезне иң авыр заманнарда мыскыл-мәсхәрәдән аралаган Колшәриф сәет кебек олуг имамнарыбызны, кяферләрдән тән вә җан газаплары татып дөнья куйган соңгы ханнарыбызны изгеләр рәтендә исәплә!

И Раббем! Шанлы пайтәхетебезне, газиз җиребезне саклап шәһит киткән барча мөэмин-мөселманнарның урыннары мәңгегә җәннәттә булсын!

И Раббем! Хыянәтләре аркасында үз халкының бәддогасына дучар булган Шаһгали һәм башка хаин бәндәләрне мәңгегә тәмуг кисәве яса!

И Раббем! Изге пайтәхетебезне уртак дошманнан саклап һәлак булган башка өммәт, бүтән дин кешеләренең гөнаһларын ярлыка!

И Раббем! Изге динебезне, телебезне-моңыбызны, ата-баба гадәтйолаларын дәвам итү өчен һәммәбезгә иман вә куәт бир!

Амин!

## Рәфкать Кәрами

# КАРГЫШЛЫ ЮЛЛАР

РОМАН

*Репрессия елларында хаксызга рәнҗетелгән гөнаһсыз җаннар истәлегенә багышлыйм.*

Автор.

## I

Шомлы мең тугыз йөз утыз җиденче елның декабре, якшәмбе көн иде.

Ял көне икәнен белеп, адәм балаларына куаныч алып килергә теләгәндәй, кояш та иртәрәк чыкты, нурларын да саранланмыйча мул сипте. Нурлар иң әүвәл сай гына елга буена урнашкан өч урамлы авылның чор шаукымына эләкмичә калган мәчет манарасының саргылт аена, аннары байлардан калган ике-өч кенә бөртек алты почмаклы нарат йортларның калай түбәләренә, анда-санда күренгән биек тупыл агачларына төште.

Ир-атлар, тәмле йокыларыннан уянып, теләр-теләмәс кенә сәкедән аякларын салындырдылар. Идәндә кайсы-кая яткан сарык, кәҗә бәрәннәренә һәм аларның «шомырт»ларына басмаска тырышып, аралыктагы агач чөйдән бишмәт-туннарын иңнәренә салып, мал-туар карап керделәр. Уңган киленнәр коймак-кабартма пешерү өчен таба чыжлата, әби-әниләр балалары торуга солы катламасы, күкәй күмәче, җылы шишара өлгертү өчен мич ягу хәстәренә керештеләр. Җыйнак авыл өйләреннән морҗаларыннан тирес кирпеченең, арыш саламының сыек төтеннәре күтәрелә башлады.

Кыскасы, авыл әкренләп уянды: эт өргән, сыер мөгрәгән, сарык бәэлдәгән тавышлар ишетелде, ишегалдында казлар каңгылдады, әтәч-тавык та үз авазын салды, иртәнге тынлыкны ярып, олтанлы киез астында кар шыгырдады.

Авылның югары очындагы салам түбәле кечкенә усак өйнең хуҗасы Мотаһир да уянды. Аның дүрт тәрәзәле, такта өйалдылы йорты, сыер белән ике сарыгын ябарлык кына абзар-курасы һәм бәрәңге бакчасының бирге башына чыгарып салган кара мунчасы бар. Заманы өчен болар куркып-өркеп яшәрлек мал-мөлкәт түгел. Хәер, моннан дүрт ел элек өйләнеп, башка чы-

---

Рәфкать КӘРАМИ (1942) — *прозаик, «Дүрт кешелек каюта», «Очар кошлар белән янәшә» (трилогия), «Сагышлы кояш» һ. б. китаплар авторы. Драма әсәрләре дә яза. Татарстан ССРның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

гып, үзенә йорт-җир тергезгән кешегә болардан да олы куаныч юк иде әле. Шуңа күрә аларның — яшь ир белән хатынның, һәр көне — шатлык, бер-беренә карашы — бәхет, киләчәкләре өмет иде.

Уртага яткан оч яшьлек Әгъдәсне уятмаска тырышып, Мотаһир шыпырт кына хатынына дәште:

— Мөсәмирә, торасыңмы әле?

Хатыны уяу икән. Ак яулык бәйләгән башын чак кына калкытып иренә яратып карады.

— Торыйммы соң?

Мотаһир да аз гына калкынды. Урам яктагы ике кечкенә тәрәзәдән төшкән кояш яктысы бөтен өйне тутырган иде. Ул хатынының сызылып киткән кара кашларына, чак кына киңәя төшкән килешле матур борынына, алсу битләренә һәм күзгә ташланып торган кабарынкы иреннәренә иркәләп карады.

— Хәлең ничек?

— Әйбәт,— диде Мөсәмирә һәм улы аркылы иренә кулын сузды.

Ул башта иренең таза беләгеннән тотты, аны сыйпый-сыйпый учына, бармакларына кулын тидерде. Якын итеп, үз итеп аның кыска, ләкин көчле бармакларын бергә җыярга тырышты һәм, ниһаять, аларны кысып тотып, әкрен генә үзенә таба тартты.

Мотаһир, сүзсез дә аңлап, хатынының юка эчке күлмәк аша эссе бөркеп торган кайнар тәненә кулын тидерде, түгәрәк корсагына учын куеп, тын калды. Бу мәлдә аларның икесен дә әйтеп бетергесез шатлык, горурлык биләп алган, уртак мәхәббәт җимеше, уртак бәхетләре дә уянган, әледән-әле үзенең дөньяда барлыгын белдереп, тибенеп куя. Ир белән хатын тын алырга да куркып, һәркайсы үзалдына елмаеп, чиксез рәхәт минутлар кичерә иде...

Мөсәмирә, ана булу шатлыгы өстенә, үзенең акыллы, эшчән иргә тап булуына сөенә, Мотаһир аны үзен якын иткәне өчен, әллә ни җиһазы булмаган бәләкәй генә өйне дә кунак йортыдай пөхтә тота белгәне өчен һәм аңа икенче бәби бүләк итәргә җыенганы өчен сөекле хатыны итеп ярата иде.

Мөсәмирә дә иренә назлап карый. Аның куе коңгырт чәчләрен сыйпыйсы, биек, калку маңгаена кулын тидерәсе, кайнар иреннәренең тәмен тоясы килә. Әмма борын-борыннан килгән тыйнаклык-тартыну аны бу теләгеннән тыелып торырга мәҗбүр итә. Иренә булган сөю хисләренең йөрәктән ургылып чыккан ташкынына түзә алмагач, Мөсәмирә аны улына күчерә. Аның башына, маңгаена кулын куеп тора, иңбашын сыйпый. Малаенда иренең йөз чалымнарын күрә. Бу халәт Мотаһирга да бик-бик аңлашыла: ул да малаена кагылып куя, ә үзе хатынына карый. Алар күз сирпеп алудан ук бер-берененең ни әйтергә теләгәнен, уйлаганын аңлыйлар төсле. Бәхетле елмаю иреннәрендә, күзләрендә чагыла, бөтен барлыкларын биләп ала. Андый вакытларда Мөсәмирә ирексездән илаһи көчкә ялвара: «И ходаем, безнең бәхетебезне күпсенмә! Шушы сабыебыз, буласылары хакына иминлек-тазалык, йортыбызга бәрәкәт бир...»

Әти-әнисе биргән үгет-нәсихәт, иренә тугрылык, бала үстерү вазифасы, гаилә җылылыгын саклау — болар бер генә минутка да аның уеннан китми.

Икесе дә бер үк төрле хисләр кичереп, татлы уйларга бирелеп, туачак көннең аларга бары бәхет-сәгадәт, шатлык-куаныч кына алып килеренә чын күңелдән инанып, алар беркавым дәшми яттылар. Бүген — ял. Бәлки, әти-әниләренә кунакка барып кайтырлар, белмәссең, үзләренең килеп чыгуы да ихтимал. Шуңа күрә мунча ягарга кирәк булыр...

Шушы татлы уй-хыяллар диңгезенә чумып, үзен бәхетле тоеп яткан Мөсәмирә кинәт сискәнеп куйды: бүген күргән төше исенә төште. Әйе, ул аны Мотаһирга сөйләмәде бит әле. Әллә юк-бар белән иренең башын катырмаска, кәефен кырмаскамы? Әнисенә әйтеп карар. Әнисе төш юрарга оста бит. Әллә ашыкмаскамы? Сабыр итәр, могаен, аңа да әйтмәс. Чонки

Мөсәмирә үзе бу төшне хәерлегә юрый алмады. Әйе, ни генә булмасын, бүгенге матур иртәгә, алсу-зәңгәр күк йөзенең ерак читендә пәйда булган бер тотам кара болыт кисәге кебек, әлеге төш килеп кысылды. Мөсәмирә үзләренең бозавын чит көтүгә илтеп кушты, имеш...

Кичкә таба көннең сөмсере коелды. Мотаһирлар мунчага кереп киткәндә сирәк кенә кар төшә башласа, чыкканда — ап-ак күбәләкләр бөтен тирәлектә кайнашалар иде инде. Мөсәмирәгә бөтен җир акка чумган төсле тоелды. Бары күршеләренең кое сиртмәсенә кунган кара карга гына нинди-дер ятышсыз, яман нәрсә кебек кукыраеп утыра иде.

Алдан Мөсәмирә, аның артыннан улы Әгъдәсне күтәргән Мотаһир керде. Ишек катында киез итекләрен салып, йон оекбаштан гына калып, салкын идәнгә бастылар. Әгъдәс тә әтисе кулыннан шуып төште, идән уртасында чәптереп торган бәрәнгә кагылып, йөгереп сәкегә үрмәләде. Мотаһир кучкардан шырпы кабы алып, тәбәнәк матчага эленгән җиделе лампаны кабызды.

Мөсәмирә, бәрән юешләгән идәнне сөртеп алгач:

— Мин берәр нәрсә әмәллим әле,— дип, учак тирәсендә чуала башлады. Самавырга су, күмер салып, чыра телеп яндырды да, кече морҗа тимерен тартты. Самавыр торбасының кәкре башын морҗа тишегенә тыкты.

Шулчак, аларның кайтып керүен көтеп кенә торгандай, такта өйалдында яңгырап, аяк тавышлары ишетелде. Мотаһир, тавышка колак салып: «Күршекуләнме, туган-тумачамы... Алай дисәң, күн итекле бугай. Ят кешеләрме соң?» — дип уйлап та бетермәде, чыпта белән тышланган ишек кинәт ачылды. Әгъдәс сискәнеп китте. Ишек катында бер-бер артлы ике милиционер пәйда булды.

Мотаһир: «Бу ни хәл!» — дип сәкедән күтәрелде. Улы исә өеп куелган түшәк-ястыкка табарак, әтисе артына елышты.

Кара шинельле, киң каешлы милиционерларның берсе шактый озын гәүдәле иде. Аның кызыл йолдызлы кара бүреге чак кына түшәмгә тимәде. Икенчесе гәүдәгә кайтыш, әмма төп кебек таза. Аныса керә-керешкә үк күн итекләрен аерып, хуҗа кебегрәк басты. Бил каешын рәтләгән арада янтыгындагы наган кобурасына да кул тидереп алды.

Исәнме-саумы юк, тәбәнәк гәүдәлесе, калын каш астындагы чепи күзләрен өй эчендә ялт-йолт йөртеп чыкты да, чиртсәң чәчрәп кан чыгардай таза кызгылт йөзен Мотаһирга таба борды. Туры карап, яңгыравык тавышына катылык өстәргә тырышып, сорау бирде:

— Фамилиягез ничек?

Юка такта һәм кызгылт-чуар чаршау белән генә бүленгән кече яктан Мөсәмирәнең куркудан агарып чыккан йөзе күренде. «Әстәгъфирулла!» — дип кенә әйтә алды ул әле ирenә, әле кергән кешеләргә карап. Аннан, кулындагы пычагын һәм әрчи башлаган бәрәңгесен алъяпкыч астына тыгып, ни кылырга белмичә тораташтай катты.

Мотаһир тынычлыгын җуймаска һәм каушаганын сиздермәскә тырышып:

— Фарукшин,— диде.

Истә-оста юкта килеп кергән бу милиционерларның сугылуын ул әле нәрсәгә юрарга да белмәде. Шуңа күрә тәрәзә каршындагы өстәл янынnан артсыз ике урындыкны, уртадагы тишекләренә бармак тыгып, ишек катынарак күзгатып куйды.

— Утырыгыз.

Аның бу тәкъдиме җавапсыз калды. Озын милиционер дәшмәде. Бары карсак гәүдәлесе генә сөйләшә иде.

— Әле кайда идегез?

— Мунчада.

«Димәк, алар бая, без мунчада чакта ук килгән булганнар. Әйтәм җирле эт өргән сыман иде,— дип куйды Мотаһир үз-үзенә.— Ни йомышлары төште икән?» Ул, авыл фельдшеры буларак, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында үзенә кеше керүгә күнеккән иде инде.

Милиционерлар бер-беренә карашып алдылар. Тәбәнәк гәүдәлесе, уң кулының баш бармагын бил каешына кыстырып, баягыдан да зәһәррәк тавыш белән:

— Сез кулга алынасыз!— диде.

Мөсәмирә еларга җитешеп иренә карады. Ул:

— Атасы...— дип нидер әйтергә теләде.

Ләкин тавышы киселде, авызыннан бүтән сүз чыкмады. Кече якка керде, кулындагы әйберләрне калдырып, авызына ак яулык читен тидереп, янә чаршау алдында пәйда булды.

Бу минутларда бары өч яшьлек Әгъдәс кенә тыныч иде. Ул хәзер, сәкедә утырган җиреннән, өйгә килеп кергән ят абыйларны күзәтте. Малайга аларның елык-елык килеп торган аеллы күн каешлары да, бүрекләрендәге матур йолдыз да, янтыкларындагы кара кобуралары — барысы да кызык һәм мавыктыргыч иде.

Мөсәмирә шыпырт кына малаен үз янына чакырды, яшенле яңгыр алдыннан бәбкәсен канат астына яшергән ана каз кебек, аны ник бүлтәеп торган корсагы белән каплап, саклап калырга теләде. Бары шуннан соң гына малай эзләүсез-сораусыз басып кергән йолдызлы бүрек кигән абыйларның яхшы ният белән кермәгәннәрен бераз аңышты булса кирәк. Ул аларга хәйран калып түгел, ә тәкъдим ителгән урындыкларга утырмыйча һаман ишек катында басып торуларына, күн итек табаны астында инде кар җеби башлавына, әмма моңарга ни әтисенең, ни әнисенең сүз әйтмәвенә аптырабрак һәм бераз шикләнеп-шүрләбрәк карап тора башлады. Ишек тупсасына менеп, чыгаруларын сорап бер-ике мәртәбә аваз салган песигә дә әти-әнисенең игътибар итмәве гаҗәп иде. Малай аны бүтән чактагы кебек үзе чыгарып җибәрергә дә батырчылык итмәде.

Моңарчы дәшмәгән озын милиционер телгә килде.

— Безгә өегезне тентергә кирәк, рөхсәттер бит?— диде ул һәм, үрелеп ишекне ачты да, песине чыгарып җибәрде.

Сафта басып торгандай, гәүдәсен катырып тоткан, зиһене томаланган Мотаһир әле һаман аптыраулы хәленнән чыга алмый иде. Ни әйтергә белмәде. Бары, түгәрәк иңбашларын чак кына сикертеп, кыяр-кыймас кулларын кыймылдатып, зәгыйфь тавыш белән:

— Санкциягез булса, эзләгез,— диде.— Нәрсә эзлисез?

Тәбәнәк гәүдәле бер адым алга атлап, Мотаһир каршына килеп басты. Бил каешыннан баш бармагын чыгарып, уң кулын югары күтәреп, ике бармагын җыеп, аны наганга охшатты да йорт хуҗасына төбәгән сыман итте:

— Наган!

Күрәсең, милиционер, бу сүзнең тәэсире көчле булачагын һәм шуннан ләззәт алачагын тоеп, рәхәт бер көтү белән аның күзенә текәлгән иде. Ләкин киресенчә килеп чыкты.

— Күргән нәрсәм түгел,— диде Мотаһир җиңел сулап, хәтта аның ирен читләрендә чак кына елмаю галәмәте дә чагылды.— Мин аны армиядә дә күрмәдем.

Үзләре хезмәттә булгач һәм һәрдаим наган асып йөргәч, милиционер өчен бу гайре табигый кебек яңгырады.

— Ничек?— дип аптырабрак калды ул.— Кем булып хезмәт иттең?

— Санинструктор.

Тәбәнәк гәүдәле артына борылып, ишек катындагы иптәшенә карады. Тегесенең йөзендә икеләнү иде. Үзе дә сизмәстән, башын һәм сул иңен селкетеп алды шикелле. Шулай да бу чарасызлык шундук юкка чыкты, бер генә мизгелгә дә хезмәт вазифасын үтәүне онытмаска тиеш икәнне һәм, тапшырылган эшне җиренә җиткереп башкармасалар, үзләренең үк кыен ашыйсыларын алар бик яхшы аңлый иде, күрәсең. Әз генә йомшаклык күрсәткән хезмәттәшләренең нинди язмышка дучар булулары да күз алдында. Әйе, мондый эштә кеше җәлләп шөһрәт казанып булмый. Шунлыктан, бернинди икеләнүсез, оятларына көч китермичә, үзләрен хак санап алар тентүгә керештеләр.

Озын буйлысы ишек катындагы чөйгә, анда эленгән тун, бишмәт, бүрекләргә күз йөртеп чыкты, идәндәге лаканга карап алды, аралыкка башын тыкты. Анда почмакка бәйләп куелган бозаудан, стенага асып куелган ике-өч бәйләм башлы суганнан гайре әйбер күрмәгәч, мич башын да онытмады, идәндәге тас белән комганны да шәйләде. Матча кашагаларына кагылып үтте, кучкарны күзеннән кичерде. Ахры, нияте чаршау артында да иснәнү иде. Шулай да, бик батыр кыяфәтле тоелса да, нәфрәте йөзенә чыккан яшь хатынны — ачудан кабарынкы аскы иренен тешләгән ананы һәм аның корсак астына ук диярлек кереп поскан, куркудан күзләре зур ачылган малайны күреп, ул кече якка керергә базмады. Әллә инде хатын-кыз почмагы дип тә гарьләнде. Аның карашы югарыдан, бүлмә тактасына беркетелгән киштәдәге әйберләрдән — шакмаклы ашъяулыкка төрелгән түгәрәк ипидән һәм башка вак-төяктән шуып үтте.

Тәбәнәк гәүдәле милиционер, сул кулындагы пирчәткәләрен өстәлгә ташлап, тентүне уң як стенага беркетеп эшләнгән киштәдән, дөресрәге, андагы китаплардан башлаган иде.

Монысы Мотаһирны бераз гаҗәпләндерде. Фәкать соңыннан гына ул аларга ни кирәген аңлады.

Киштәдә күзгә ташланырдай әйбер — ике томлык «Медицинский справочник». Милиционер китапларны берәм-берәм киштәдән алды, өстәлгә куйды һәм бик дикъкать белән карый башлады. Ул аларның битләрен актара иде. Китап эчендә наган яшерелгән дип уйлый микәнни?! Ахыргача актарып чыккач, көрән тышлыгыннан әләктереп, селкетеп тә карады. Икенче том белән дә шулай кыланды. Ә үзе әледән-әле киштәгә карап ала иде. Ниһаять, ул янә югары үрелде. Анда калын гына гомуми дәфтәр бар иде. Аңарда Мотаһирның 1934 елдан бирле җыеп килгән язмалары. Болар медицина хезмәткәренең авырулар тарихын тасвирлавы яисә күзәтүләре дә, табигать күренешләре яки сынамышлары да, гашыйк егет һәм кызның көндәлек дәфтәре дә түгел, ә ревкомиссия мәгълүматлары иде. Эш шунда: Мотаһирны, гәрчә колхозда эшләмәсә дә, 1934 елда ревкомиссиягә әгъза итеп сайладылар. Ә комиссиянең беренче утырышында аны председатель иттеләр. Елның-елында үткәрелгән тикшерү-барлау мәгълүматларының акка күчерелгәне, утырыш беркетмәләре колхоз идарәсендә сакланса, караламасы — өендә, нәкъ шул киштәдә, гомуми дәфтәргә теркәлгән иде. Хәзер шулай барысы да милиционерның кәкрәебрәк торган таза бармакларына килеп эләккән. Ул хәтта бүреген дә өстәлгә салып ташлады. Күрәсең, теләгенә ирешкәч, бер төрле дулкынлану кичерүдән эсселәп киткәндер. Аның тарак күрмәгән чәчләре юешләнеп укмашкан иде. Ул бу кара тышлы дәфтәрне «Медицинский справочник»тан аерып, пирчәткәсе өстенә куйды һәм Мотаһирның үзенә текәлгән күз карашын тоюдан, үзенең хис-тойгыларын яшерә алмавына ачуы килеп, мөмкин кадәр тупасрак булырга тырышып, әмер бирде:

— Сандыгыңны ач!

Сандык бикле түгел иде. Мотаһир ян стена буендагы калай бизәкле яшел сандыкның капкачын күтәрде. Аңа терәлеп торган бәрәнне читкәрәк этәрде.

Әгъдәс әнисенең кулыннан ычкынды да йөгереп килеп:

— Сандыкта ике пар ботинка бар: берсе — әткәйнеке, берсе — әнкәйнеке.

— Улым, кил монда, — диде Мотаһир йомшак кына.

Малай карышмады. Әтисенә сыенды. Такыр башына учын куеп, аны тынычландыргач, бәлки киресенчәдер, — үзе тынычлангач, — Мотаһир улын әнисе кулына тапшырды. Анысы иелеп, малаена нидер пышылдаганда түшендәге саргылт муенсасы Әгъдәснең баш түбәсенә тиеп китте. Ул әнисенең кулын терсәктән түбән әләктерде, көмеш беләзеген капшап, шуңа тотынды. Дөньяда беренче кат гаделсезлек белән очрашкан сабый җаны үзенә яклаучы, таяныч эзләде.

Ә тегеләр үз эшләрен дәвам итәләр иде. Сәкедәге кабартылган түшәк-ястык та, сырган юрган да, ак киез һәм шакмаклы палас та аларның

кулыннан үтте. Сәке астына да үрелеп карадылар. Гаҗәп: базны ачтырмадылар.

Ике ак бәрән, чит кешеләрнең ни өчен кергәнен һәм ни эзләвен белмичә, аңгыра башларын кыңгыр салып, бу хикмәтне тамаша кылып тордылар. Хәер, бу афәтле елларда сарык бәрәннәренең генә түгел, бик күп адәм балаларының мие түнгән һәм алар карусыз маллар хәленә ,китереп җиткерелгәннәр иде.

Милиционер «Медицинский справочник»ларны Мотаһирга таба этәрде, ә кара тышлы дәфтәрне үзенәрәк, өстәл читенәрәк елыштырды. Мотаһир түзмәде, аның ниятен чамалап:

— Сез моны алмагыз,— диде.— Анда дүрт еллык ревкомиссия тикшерүләре. Кирәк ул миңа.

— Кемгә нәрсә кирәген бүтән җирдә ачыкларбыз.

Карсак милиционер, таза муенын кысып торган шинель каптырмаларын ычкындырып, куен кесәсеннән кәгазь бите чыгарды.

— Ручка белән карагыз бармы?— дип сорады ул дорфа гына.

— Бар.

Йорт хуҗасы киштәдән кара савыты белән ручка алып бирде.

Милиционер ручканы сул кулына тотты, каләмен җентекләп карады, савытка манды һәм, калын дәфтәрне ачып, аның бер битенә сызып карады. Бары шуннан соң гына сул кулы белән акт язарга кереште.

— Фамилияң? Исемең?

— Фарукшин Мотаһир...

Язу белән мавыгып, милиционер Мотаһирның фамилиясен искәрми дә калды бугай, язуында булды. Ул хәрефләрне нык авыштырып, бик зур тырышлык белән язды, тирләп чыкты, кесәсеннән керләнеп беткән чигүле кульяулыгы чыгарып, маңгаен сөртте.

Язып бетергәч, милиционер актны башта үзе укып чыкты, аннан өстәл янында басып торган Мотаһирга таба этәрде.

— Мә, актка кул куй.

Мотаһир кәгазьгә күз йөртеп чыкты да имзасын салды.

Мөсәмирә иренең кәгазьне бик тиз укуына да, шундук кул куюына да башта сәерсенеп, аннары гасабиланып карап торды. Ләкин, иренә тел тибрәтеп каршы сүз әйтергә күнекмәгәнлектән, дәшмәде. Хәлбуки, аның ул кәгазьдә ни-нәрсә язылуын беләсе һәм үзенең дә укыйсы бик килә иде. Ул улының башыннан өзлексез сыйпап торды һәм эзләүсез-сораусыз басып кергән бу бәндәләрнең кыланышын бер дә хәерлегә юрамады. Бу арада авылдан кайберәүләрне алгаладылар. Ләкин аларның берсе — мулла, икенчесе... Аның уйлары бүленде, чөнки милиционерның җанны өшетә торган әмере ишетелде:

— Киенегез!

Мөсәмирә аптырап китте. Ирексездән:

— Мотаһир, чәй өлгерде бит!— дигән аваз чыгарды.

Бу сүзләргә аның гаделсезлеккә каршы килергә омтылуы да, ялваруы да, өмете дә, тегеләрне миһербанлы булырга чакыруы да һәм, ниһаять, бәлки әле бу хатаны төзәтә алу ихтималы барлыгы да сыйган иде. Чөнки беркем дә аштан олы була алмый. Юк, болар... олы икән. Колак салмадылар. Әнә бит, өстәл артындагысы чепи күзенең агы белән, кашын җыерып карады. Артсыз урындыкны ишек катынарак тартып утырган яшьрәге шулай да әйтүне кирәк тапты:

— Хәзер кайтыр. Авыл советына гына бара ул.

Анысы бүреген дә салмаган, аякларына да карап-карап ала, чөнки күн итек табанына ябышкан карның соңгы кисәкләре эреп, сап-сары идәндә су табы хасил иткән иде.

Мотаһир өстенә пинжәген, аягына киез итек киеп, ишек катындагы чөйгә үрелгәнче, Мөсәмирә тизрәк үзе барып, аңа бишмәтен һәм үзе бәйләп биргән йон шарфын тоттырды, чүпрәк түбәле бүрек тә салмак кына үз урынына менеп кунаклады, тышына киндер салган

йон бияләй дә кучкардан, теләр-теләмәс кенә, йорт хуҗасының кулына күчте.

Өч яшьлек малай, әле әнисенә, әле әтисенә, әле милиционерларга карап, ни диярга дә белмәде. «Хәзер кайтыр. Авыл советына гына бара ул».— дигән сүзләр аның сабый аңына барып иреште ирешүен һәм күңелен бераз тынычландырды. Ләкин шул мәлдә, инде әтисе чыгып китәм дигәндә генә, өстәл янынан торып, дәфтәрне куенына кыстырган һәм каешын-наганын төзәтеп-җайлап торган юан милиционер өстәп әйтте:

— Бер күлмәк ашарыңа ал,— диде.

Монысын ничек аңларга да белмәде малай. Әнисе белән әтисе дә бу сүзгә аптырый калдылар. «Бәй, мин анда кунып калам микәнни? Саклыйлар микәнни?»— дигән уй йөрәген телеп китте. Шулай да авыл советы ерак җир түгел, иртәгә дә кайтырга була иде. Ә менә бөтенләй районга ук озатылу ихтималы — анысы Мотаһирның башына да кермәде.

Мөсәмирә, авыры барын оныткандай, җәһәт кенә бәләкәй якка чыкты, бер түтәрәм ипи һәм кисәге белән салкын ат ите төреп, иренең каршына килде.

— Мотаһир...

Ир хатынының зур ачылган күзләренә карап:

— Ярар, көяләнмә,— диде.— Озак тормам.

— Шулай гына булсын инде, ходаем...

Мөсәмирә төргәкне иренең кесәсенә тыкты.

Мотаһир улының җилкәсенә кагылды:

— Чыгып йөрмә, яме, улым, мунчадан соң салкын тидерерсең.

— Ярар, әткәй,— диде малай башын күтәреп, күзләрен тутырып атасына карады.

Аның мөлдерәмә карашы еллар буе күз алдыннан китмәячәген Мотаһир белми иде әле. Үксезлекнең никадәр авыр булачагын нарасый да белми. Кабат очрашканда берсенең үсмергә әйләнеп, икенчесенең йончып-талкынып картлар кыяфәтенә керәчәген ата белән ул күз алдына да китермиләр иде әле.

Хатыны өзгәләнеп, малае аптырап-моңаеп, өйдә калдылар. Чөнки милиционерларның берсе — алдан, икенчесе Мотаһир артыннан чыкты. Шулай да җил капканы Мотаһир үзе япты, бавын үзе эләктерде.

## II

Алар урам уртасыннан — милиционерлар чана юлына басарга тырышып, Мотаһир ат эзеннән атлап — түбән очка, авыл советына таба төшеп киттеләр.

Авыл тын. Тәрәзәләрдә саргылт-тонык ут яктысы күренә. Бик сирәк өйләрдә, урам якта өч тәрәзәсе булган биек йортларда гына уңлы лампа яна, күбесендә җиделе яки сукыр лампа, шешәгә тыгылган филтә янсә чыра гына, шуңлыктан аларның яктысы урамга төшми диярлек. Ләкин караңгы да түгел, ак кар аяк астында шыгырдап, сыкрап кала. Ай да күренми, кайдалыгын шәйләп була булуын, әмма үзен болыт каплаган.

И газиз ай, күрмә, күрмә бу мескен бәндәнең өеннән аерылу сәгатьләрен! Син болай да бик күпләрнең туган җирен калдырып китүенә шаһит булгансыңдыр инде. Син аны, бер гаебе булмаган гөнаһсыз җанны, әле күп мәртәбәләр күрерсең...

Кешеләр очрый, исәнләшеп китә. Мотаһир да аларның сәламен ала. Ләкин теләр-теләмәс кенә, читенсенеп кенә — ул сак астында бара бит. Кемнең бу хәлендә кешегә күренәсе килсен?! Кешегә түгел, күрше этенә дә күренәсең килмәс. Әнә бит алар да бу кара киемле, каеш-наганлы адәмнәргә читтән генә, шикләнеп кенә өреп алалар һәм, нидер сизенгәндәй, койрыкларын кысып, капка астына шылу ягын карыйлар.

Авыл советы куылган байларның йортларын күчереп, кушып салынган зур бинада иде. Кара-каршы ике йортны урам буйлап салып, коридор белән тоташтырганнар. Бер өйдә авыл советы урнашкан, икенчесендә — колхоз идарәсе. Аның каршында, урам якта, ике баганага аркылы агач сузылган. Бу — ат бәйләү урыны. Аңа карагач, Мотаһирның эчендә нидер өзелеп төшкәндәй булды: җигүле ат тора — идарә айгыры. Кошовка янында өстенә толып кигән ат караучы таптана.

— Исәнме, Ихсан абзый.

Ул, Мотаһирга карамаска тырышса да, аның кычкырып биргән сәламен алды. Ихсан абзый идарә атларын карый һәм, районнан кеше алып киләсе яки илтәсе булса, гадәттә, аны йөртәләр иде.

Авыл советында бер малай — кизү утыра.

— Нихәл, үскәнем.

— Исәнме, Мотаһир абый.

Ул, шикләнебрәк, берәм-берәм милиционерларга карады, түрдәге өстәл артыннан сикереп торды да мич буендагы эскәмиягә барып утырды.

Таза милиционер керә-керешкә нечкә тимер чыбык белән матчадагы кадакка эленгән җиделе лампаның филтәсен чыгарды. Болай да куыгы корымлы иде, сөреме тагын да катырак булып, сузылып өскә үрләде. Ләкин милиционер аңа игътибар итеп тормады, түргә узып, сул як стенадагы кара телефонны әйләндерә башлады.

Озын милиционер, бүлмәдәге артлы урындыкларның берсен алып, ишек катынарак барып утырды, тәмәке көйрәтеп җибәрде. Ул Мотаһирга:

— Әнә, теге өстәл янына утырыгыз,— дип, дежур малай торып киткәненә түгел, ә икенче өстәлгә күрсәтте.

Ул өстәл — рәиснеке. Аның янында кара төстәге калын тимер сандыксейф һәм байлардан талап алынган бер саргылт шкаф та бар. Болар тар такта белән әйләндереп алынган, аерым ишек-капкалы. Рәшәткә белән ишек-капка бил тиңентен генә. Шулай да Мотаһир үзен читлеккә ябылгандай хис итте. Һәм, өстәл артына барып утыргач, тәне чымырдап куйды.

Түр стенадагы, ике тәрәзә арасындагы рамнан даһи юлбашчы карый һәм, үзенең егетләреннән канәгать булып, аларның һәр хәрәкәтен хуплап, калын кара мыегын селкетә кебек иде.

Таза милиционерның тавышы бөтен авыл советын яңгырата.

— Але! Але!.. Районмы?... Але, НКВД?.. Кая соң болар, чәнчелеп киткерләре... Але, дим! Анаңны...

Озын милиционер торып басты. Мотаһирга карап алды. Иптәше янына килеп:

— Кая, бир әле үземә,— диде.

Теге теләр-теләмәс кенә читкәрәк китте, лач итеп идәнгә төкерде. Кесәсеннән папирос кабы чыгарып юантык бармаклары белән, папирос эләктерде дә, лампаны тимер чыбыктан ычкындырып, куыгын авызына якын китерде, көйрәтеп җибәрде.

Озын буйлы милиционер телефон боргычлый, икесе дә пыш-пыш тарталар — зәңгәр төтен бүлмәгә тарала, кулдан язылган өндәмә-лозунгларны, сайлау уңае белән чыгарылган һәм кубарып атарга онытылган плакатларны капларга азаплана.

Бераздан карсак буйлы өметен өзеп:

— Юкмы? — дип сорады.

— Юк.

— Ярар, болай гына алып китик.

Мотаһир корт чаккандай сикереп торды. Бермәлгә теле бәйләнде. Аннан кисәк кенә сорады:

— Мине кая алып китмәкче буласыз?

— Районга,— диде базык гәүдәле милиционер.

— Ни өчен?

Мотаһир, капкалы бүлем артыннан чыгып, болар янына килде. Озыны аны юатырга тырышкандай әйтте:

— Бер көн кунарсың да, хәл итәрсең, кайтырсың.

Күрәсең, бу билгесезлек милиционерларның үзләрен дә туйдыра башлаган иде, бу юлы алар Мотаһирга артык каты бәрелмәделәр.

Мотаһир ишек катынарак атлады да, малай белән тигезләнгәч, иелеп, колагына пышылдады.

— Мөсәмирә апаңа әйт: мине районга алып киттеләр.

Малай, ярар дигәнне аңлатып, ым какты.

Тагын аллы-артлы саклап, Мотаһирны урамга алып чыктылар, кошовка янына китерделәр. Таза милиционер хезмәттәшенә:

— Мин киттем,— диде.— Кунарга кая барасын беләсең.

— Беләм.

— Хатыныңа кереп әйтимме соң? Ә?

Моның мыскыллы көлеп әйткән сүзенә каршы тегесе тизрәк:

— Әйтермен мин сиңа!— диде.

— Йә, ярар, курыкма.

Тик торып ялыккан айгыр, чана борылуга, юыртып, урам буйлап алып та китте.

Бу вакытта, ерактагы капка төбендә, бер кешенең төлке якага башын яшереп, сәгатьләр буе әлеге атны күзәтеп торуын һәм, ниһаять, аның район юлына чыгуын күргәч, сөенеп өенә кереп китүен, кара айгыр белмәде.

Айгыр бая Мотаһир килгән юлдан бара иде. Ләкин бераздан ат уңга борылды һәм як-ягында тал агачлары үскән инеш аркылы салынган күпер аша чыкты. Ә сулда, ике урам арасында, үзенә аерым ихата булып, Мотаһирның әти-әнисе яши — бу аның туган йорты иде.

Мотаһир, хафаланып, янында утырган милиционерга таба борылды:

— Иптәш милиционер, монда минем әтиләр яши. Төшеп әйтим әле.

Мотаһир шулай диюгә, кучер атын тыя башлады.

— Юк, төшмисең,— диде милиционер төксе генә һәм кучерга дәште:— Куала!

Юл үргә табарак булса да, дилбегә какканны тоеп, айгыр янә юыртып китте һәм тыкрыктан урамга килеп чыкты. Ул, район юлын әйбәт белгәнлектән, сулга борылды, урам буйлап бераз баргач, уңга каерды.

— Сезнең әти-әниегез бармы?— дип сорады Мотаһир, милиционерга таба башын бора төшеп.

— Нишләп булмасын?! Әллә мине җилдән туган дип беләсеңме?

«Акыллыга — ишарәт, акылсызга бишәр әйт,— дип уйлады Мотаһир башын чайкап.— Моңа төшендереп торуның мәгънәсе булмас. Туң баш».

Ямчы да дәшмәде. Чөнки ул бу юлдан беренче тапкыр гына бармый, кеше күзеннән яшереп, кичкырын яисә төнлә күпләрне районга илткәләгәне бар. Бу озатулар аның җанын телгәләсә дә, бәгырен ашаса да — ул берни кыла алмый, бәхетсез авылдашларына берни белән дә ярдәм итә, хәлләрен җиңеләйтә алмый. Чөнки артык тел озайта башласа, бер баруында үзенең дә ике катлы йортта «куна калуы» ихтимал. Ул торымнан-торымга авыр көрсенеп куя да, әпә кешедәй дәшми баруны өнәп бетермәгәндәй:

— На, малкай, атла җәтрәк,— дип куя.

Ә малкай нишләсен, ул — мескен, телсез. Ә кешенең теле бар. Ләкин малкай кешеләрне дә телсез итә торган урыннар, хәлләр барын башына да китереп карамый. Хәер, бу нәрсә аны артык борчымый да. Ул теркелдәвен белә. Аның әле әйләнеп кайтасы да бар. Әнә, караңгы тагын да куера төште, кар ява башлады. Зират агачларын да чак-чак кына шәйләп бара ул. Ләкин юлны саташтырмый: уңга борыласың, аннан тау төшәсең, таш күперне үтәсең дә тау менәсең...

Мотаһир дәшми. Уйларына чумып бара. Ярты авыл суга йөри торган (аның тәмле суын чәйгә генә тоталар) чишмә дә, кечкенә чакта малайлар белән уйнаган, үсә төшкәч, кызлар янына кичке уенга чыккан, исле үләннәре борыннарны ярып керә торган ындыр арты болыны да артка чугә. Кар астыннан да аның хуш исе аңкый кебек. Зират та... «Сандугачлар басып сайрый зиратның киртәсенә, быел еллар бик ямансу, әллә без китәсенә?!»

Каян башына килде әле бу җыр? Каян булсын — яшьлегеннән. Әйе, армиягә киткәндә «никрутлар» шулай җырлый иде. Мотаһир да яшьтәшләре белән, кыңгыраулы-шөлдерле атларда, шушы җырны сузып, сирәк киртә белән тотылган зират яныннан районга таба юл тотты бит. Тальян моңнары өч ел буе колагында чыңлап торды. Әле дә булса колагында... Бер-берсен кочаклап арбага баскан егетләрнең авылга карап-карап алулары, вагъдә бүләге — чигүле кулъяулыклар болгый-болгый, яшьле күзләрен сөртә-сөртә соңгы тапкыр газиз туган авылга өзелеп караулары, озата килүчеләрнең шушы зират буенда изге теләкләр теләп калулары — барысы да истә, хәтердә. Ләкин ул чагында алар Кызыл Армия сафларына китә иде, илне сакларга һәм... әйләнеп кайтырга. Аларны көпә-көндез бөтен авыл озатып калган иде. Ә хәзер... «Тукта, нишләп мин үз-үземә җеназа укыйм әле? Мин бит җинаятьче түгел: җан кыймаган, кеше малын таламаган, кусәк күтәреп олы юлга да чыкмаган. Иртәгә үк әйләнеп кайтырмын, алла боерса. Шулай бит, иптәш Фарукшин?»

Гасабилы уйлардан арынырга, эч пошуын басарга теләгәндәй, үз-үзен җанландырып, дәртләндереп, ул үз-үзенә әнә шулай фамилиясе белән дәшкәндәй итте. Ләкин Мотаһир үзенең хәзер Фарукшин түгел, ә Нәбиуллинга әйләнүен һәм шул фамилия белән йөриячәген белми иде әле. Беркатлылыгы белән, ул тентергә килүчеләрдән прокурор санкциясен сорамады, тегеләр — күрсәтмәде. Ә андагы фамилия Нәбиуллин иде бит.

Аның кырыс юлдашын исә башка нәрсә борчый: ишеп кар ява, рәтлебашлы юл да юк, ә чираттагы берәүне исән-имин илтеп җиткерергә кирәк. Шулай булса да, аның кәефе күтәренке — буш кул белән кайтмыйлар. Юкса, алай да булуы ихтимал иде. Әш шунда ки, көндез алар Түгәрәк Күлдән биш чакрымлы Баллы Күл авылына бардылар. Әмма алып китәсе Нәбиуллин атлы кешене таба алмадылар.

— Кичәгенәк каядыр җыенып, чыгып китте,— дип чатнап торды хатыны.

Ничек кенә кысып карамасыннар, хатын һаман шул сүзен такылдады.

— Җыенып китте, кая икәнен миңа әйтмәде.

Күрмәгән-белмәгән, мең бәладан котылган.

— Җир йотмагандыр бит аны? Икенче тапкыр кулдан ычкына,— дип авыл советында тавыш күтәрүнең дә файдасы тимәде.

Тегенең кайдалыгын ни авыл советы рәисе, ни колхоз җитәкчесе тәгаен генә әйтә алмадылар.

— Гаеп бездә, иптәшләр, карап җиткермәгәнбез,— дип акландылар алар.

Шулай итеп, милиционерлар коры кул белән кайтып киттеләр.

Юлда туңып-күшегеп, караңгы чырай белән кайтканда, берсенең исенә төште: Түгәрәк Күлдә чыбык очы туганнары бар бит. Һәм алар Тавис Тархановларга сугылдылар. Исәпләре — җылынып кына чыгу иде.

Ләкин анда сүз иярә сүз китте. Бер стакан ачы бал җибәргәч:

— Эх, тагын кулдан ычкынды бит!— дип әйтеп салганын сизми дә калды таза милиционер.

— Кем?— дип сорады боларның тикмәгә генә йөрмәүләрен сизенгән Тавис Тарханов, шыпырт кына.

— Баллы Күлнең Нәбиуллин Мотаһир атлы бәндә.

— Сез аны алырга бардыгызмыни?

— Әйе. Бик елгыр кеше, ахры.

— Алай икән,— диде Тавис Тарханов һәм өстәлгә ризык чыгарган хатынына кырыс кына дәште:— Бар, чыгып тор әле. Алай икән... Нәбиуллин Мотаһир дисезме?

— Әйе,— дип озын гәүдәле милиционер аңа җавап кайтарды, чөнки тегесе ашау белән мәшгуль иде.— Ике рәт бардык, икесендә дә тоталмадык. Тагын буш кул белән кайтабыз. Тагын үзебезгә эләгә инде...

— Алай икән,— диде Тавис Тарханов, янә уйга талып.— Әгәр нитсәк... Бездә дә бер кеше бар... Тужы Мотаһир атлы. Фамилиясе Фарукшин йөри йөрүен, ә бабасы — Нәбиулла...

— Ә?! Алай ярамас бит...

— Нигә ярамасын икән,— диде Тавис Тарханов боларның икеләнә калуларын күреп.— Кеше урынына кеше булгач... Рәхмәт кенә әйтерләр...

— Һы,— дип тамак кырып куйды таза милиционер.— Шәп фикер бу! Ниндирәк адәм соң ул?

— Эт!— диде Тавис Тарханов идәнгә төкереп.— Ревкомиссия персидателе. Әллә кайчан олактырасы нәрсә.

— Да-а...

— Әйе. Тәмамысы җелеккә төште. Гарык.

— Анысы шулай да,— диде милиционер иптәшенә карап.— Тик безнең кулда аңа санкция юк шул.

— Аптырамагыз. Аның да бабасы Нәбиулла дидем бит. Исеме дә туры килә. Ә безнең аңа дигән бөтен кәгазьләр әзер. Иртәгә районга илтәсе ием.

— Шыпырт сөйләш.

— Минем өйдән сүз чыкмый. Шым бул,— диде Тавис Тарханов һәм сорап куйды:— Тагын җылынасызмы?

— Тукта, башта уйлашып бетерик...

— Ярар соң,— диде хуҗа килешеп.— Бу атны җибәрегез, идарә айгырын җиктерәм...

Менә шулай итеп, Мотаһир әлеге чанада бара.

«Безгә нәрсә? Безнең эш — кешесен китереп җиткерү. Калган ягын башкалар карасын»,— дип фикер йөртте кошовкада Мотаһир белән янәшә утырган милиционер.

## III

Шактый ара үтсә дә, идарә айгыры район үзәгенә әүвәлгечә чаптырып-юыртып килеп керде, бәхетенә каршы, юлның соңгы чакрымнары гел түбән таба иде. Биек такта күперне чыккач, ул уңга таба борылды һәм бераздан ике катлы йорт каршында туктады. Атның башы таза имән баганалы урыс капкага терәлде. Мотаһирның да күңеле, әлеге юл кебек, отыры төшенкеләнә барды һәм ул да кисәк кенә үзен таш диварга килеп бәрелгәндәй хис итте.

— Килеп җиттек,— диде милиционер, һәм, авыр гәүдәле булса да, җәһәт кенә кошовкадан сикереп төште.

Мотаһир да әйткәнне көтеп тормады. Ямчы да кузладан тиз генә шуып төште. Ләкин алар аяк язып, сүз алышырга да өлгермәделәр, дорфа тавыш кичке тынлыкны ярды:

— Әйдә!

Мотаһир өтәләнеп:

— Ихсан абзый, исән-имин кайтып җит,— диде.

— Амин берүк. Сихәт йөр, апай, үзең дә. Ходай сабырлык бирсен.

Бәләкәй капканы ачып, милиционер Мотаһирны эчкә үткәрде. Ике катлы бинаның асты таш, өсте агачтан гыйбәрәт булып, анда вакытлыча ябылганнарны тоту өчен төрмә дә, милиция бүлеге дә урнашкан иде.

Алар текә агач баскычтан менгәндә басмалар сыкрап-сыктап калды. Күрәсең, монда эләккән дисталәгән-йөзләгән кешенең һәркайсын шулай елап-сыктап озаталардыр. Чагыштырмача якты, бәләкәй генә бүлмәгә килеп керделәр. Каршыда ишек һәм тагын бер бүлмә икән: шундук иңенә шинель салган дежур милиционер чыкты.

— Менә, сиңа бер контр алып килдем,— диде Мотаһирны озата баручы.

Өстенә петлицалы яшел гимнастерка кигән, биленә каеш буган, яланбаш дежурный күтәрелеп карады.

— Мин беләм моны.

Мотаһир аның шулай диюенә һич тә шаккатмады. Медицина хезмәткәре буларак, еш кына районга йомышы төшә бит, тегенең күзенә чалынгандыр, аннары, дежур милиционерның алар авылына да килгәне бар сыман. Һәрхәлдә, аның какча йөзе Мотаһирга таныш иде. Иңендәге шинелен

җилкәсен сикертеп төзәтеп куйды да, дежурный үзенең хезмәттәшенә дәште.

— Туңдыңмы?

— Бар әзрәк.

— Җылынасыңмы?

— Шым...

— Юк ла, уйнап кына әйттем. Әнә мич җылы дим.

Тын беленеп торган салкынча бүлмәдә милиционерлар озак юанмадылар. Мотаһирның чалбар каешын салдырып алдылар да чыгарга җыендылар.

— Тышка чыгасың килсә, менә бер чүлмәк,— диде дежурный һәм өстәл тартмасыннан бармак буе ачкыч алып, утны сүндереп, иптәше артыннан чыгып та китте.

Мотаһирны өстеннән йозаклап куйдылар. Ул башта аптырап, аннары кызыксынып, бүлмәгә күз салды, рәшәткәле тәрәзәгә карап алды. Урамнан бүлмәгә саран гына якты төшә иде.

«Алай»,— дип куйды Мотаһир. Мие томаланган, башы эшләми. Әле үз хәлен ныклап ачыкламаган килеш, ул катып калды: ни утырырга, ни ятарга белмәде. Хәер, караватише нәрсә монда юк та. Баш астына бияләен куеп, идәнгә ятты. Ләкин йокы алмый иде. Ничек болай килеп чыкты соң әле бу? «Контр» дидеме? Контр дип әйтерлек ни кылганы бар аның? Ил-көнгә ни хафа салды? Юк. Ул, укый-яза белүче кеше буларак, армия сафларында да хезмәт итеп кайтканлыктан һәм, даими рәвештә гәзитләр караштырып барганга күрә, илдәге хәлне чагыштырмача яхшы белә иде. «Уңнар» һәм «сул-лар» дигән атамалар, Троцкий исеме, МТСларда политбүлекләр кертелү һәм бетерелү, Кировның үтерелүе, узган ел яңа Конституция кабул ителүе, һәр кешегә тигез сайлау ирегe, илдә башлангыч мәҗбүри белем бирүне кертү — болар барысы да соңгы елларда булып узган вакыйгалар. Билгеле, террорчы, корткыч, диверсант, шпионаж, троцкийчы-немец-япон шпионы кебек сүзләр дә аңа таныш иде. Ләкин үзенә кайчан да булса «контр» исеме тагарлар дип ул юрамалый гына да башына китермәде. Кем ул? Гап-гади сала кешесе, иң түбән медперсонал. Ул бит шөһрәтле дәүләт-партия эшлеклесе дә, зур чиннарга ирешкән хәрби башлык та, танылган әдәбият-сәнгать вәкиле дә, ачышлар ясаган галим-голәмә дә түгел. Аның эше — иген игү, сырхауларны савыктыру, бала үстерү. Илгә ни зыяны тигәне бар аның? Киресенчә, һәр эшен, хезмәтен җиренә җиткереп башкарырга тырыша, эчми, тартмый, уйнаш итми. Үз хатыныннан башка кыз-кыркынның кулын да тотып караганы (медпунктка чирләп килүчеләрнең пульсын тикшерүне исәпләмәгәндә) юк. Ничек шулай мәсхәрәгә калып, юньләп себерелмәгән-юылмаган идәндә, шәһәр вокзалларындагы хәерче-сукбайлар кебек, аунап ятарга дучар ителде соң ул? «Әле генә мунчадан чыккан килеш эт шикелле бөгәрләнеп идәндә ятам. Ни өчен? Кем аркасында? Советка, колхозга каршы авыз күтәреп бер сүз әйттемме? Юк. Юк ич. Хәл-хәленчә эшләдем, булыштым түгелме?»

Кылт итеп исенә төште Мотаһирның: җәй көне кисәткәннәр иде бит аны. Әйе, яшьтәше Зәһлүл әйтте бит. Ә Мотаһир... аңа ышанып та җитмәде, язмышта ни язса, шул булыр дигән сыманрак карады. Эх...

Мотаһирның карашы түшәм такталарына барып төртелә. Уйлары чияләнгән, очына чыгарлык кына түгел. Иртәгә ни язган... Өендә ни уйлыйлар икән инде? Хатынының да күзенә йокы керми булыр... Әгъдәсе... Ул, билгеле, балалыгы белән аңлап-төшенеп җитми. Әнисенең куенында мышнапмы мышный торгандыр. Ә хатыны? Ул ни уйлар? Әти-әнисе бүген булмаса иртәгә бу хәлне беләчәк. Әйтми торсалар, әйбәтрәк булыр иде. Иртәгә үк кайтып җитәр бит, шәт. Ә җибәрерләрме? Монда бер килеп эләксәң... Мотаһирның башы тубал кебек булды: мең төрле уй, чыдасын гына...

Якында гына әтәч кычкырды, аңа ачу итеп микән, бер эт ялкау гына өреп куйды, милиция ишегалдындамы — ат кешнәде. Дөп-дөп килеп, электр станциясе эшләгәне ишетелә. Тормыш, гадәти тормыш дәвам итә:

кемнәрнеңдер сыеры бозаулый, сарыгы бәрәнлидер, шифаханәләрдә дежур табиплар, шәфкать туташлары йокысыз төн үткәрәдер...

Акрын гына төн сизерәп, таң атканда баягы кизү керде. Ут кабызды.

— Тордыңмы? Әйдә...— диде ул ачкычын өстәл тартмасына ташлап һәм Мотаһирны аска алып төшеп китте. Буе биш-алты, иңе дүрт-биш адым булган бер бүлмәгә кертте. Ул, ишек катында торып, керосин салынган калай банканың филтәсенә ут кабызды.

— Менә сезгә тагын бер «кунак».

Аңа җавап кайтаручы булмады. Гәрчә монда егерме-утызлап кеше бар иде. Ишек янында параша-лакан тора. Кайберәүләр гәп куерта, берише үз-алдына уйланып утыра. Һәрхәлдә, алты-җиде кеше уяу иде. Төрле кыяфәттәге, төрле киемдәге кешеләрне — яшен-картын дигәндәй, шушы кысан, тынчу бүлмәгә дыңгычлап тутырганнар да, өсләреннән биклап куйганнар. Мотаһир кергәч тә ишек ябылды һәм аңа шалтырап йозак эленде.

Яңа тоткын керүгә, йокымсырап утырганнар да башларын калкытып, җентекләп аңа карап тора башладылар, башта — шикләнебрәк, аннары — жәлләп, соңга таба — теләктәшлек белдереп.

Мотаһирның күзенә аларның кайры һәм камалы туннары, кыска бишмәтләре, чикмәннәре, солдат бушлаты һәм шинельләре, куян яисә бәрән бүрекләре генә түгел, күбесенең күптән кырынмаган кара төкле йөзләре дә ачык күренде. Аларда сагыш, кайгы-хәсрәт, үч-ачу, курку-каушау да ачык чагыла иде.

Шулвакыт арадан берсе Мотаһирны танып алды:

— Бәттәч, Фарукшин, син ничек монда?

Түгәрәк кара сакаллы бу адәмне Мотаһир да таныды: Асылмәрдән. Күрше авылдан — Юкәленең колхоз бригадиры. Алар ике куллап күрештеләр. Абзый үз тирәсендә утырганнарга Мотаһирның кайсы авылдан, кем икәнен бер-ике сүз белән генә аңлатып бирде.

Таныш кешесен очраткач, Мотаһирга ничектер җиңелрәк булып китте. Ул, кайсыдыр кысылып, үз янында урын биргәч, идәнгә чүгәләде һәм сораштыра башлады.

— Син кайсы авыл? Сез...

— Болгар, Коры Елга, Таллык, Җиләкле Алан,— дигән авазлар ишетелде.

— Безнең авыллар юкмы?

Тегеләр белмәделәр. Такыр башлы, җирән мыеклы бер абзый алар өчен әйтте.

— Юк,— диде ул.— Элегрәк булдылар. Озаттылар аларны.— Ул Мотаһирның йөзенә туры, сынап карап, тавышын тагы да йомшата төште:— Олан, сине сорау алырга дәшерләр. Саграк бул, күп сөйләмә. Тел сөйләр дә үтәр, каләм аны язып саклар. Монда хәлләр хәтәр, бик хәтәр...

— Береженого — бог бережет, а небереженого — конвой стережет. Понял?— диде көрәк сакаллы рус кешесе.

Мотаһир, аңлаганын белдереп, сүзсез генә баш какты. Ач, йончыган кешеләрне күреп, аның йөрәге әрнеде, ни-нәрсә белән дә хәлләрен җиңеләйтә алмавына гаҗизләнде. Шунда ул кесәсенә Мөсәмирә тыккан ризык барын исенә төшерде. Аны мондагыларның барысына да әз-әзләп өләшеп чыкты. Тагын әңгәмә җанланды.

Күпме вакыт үткәндер, Мотаһир тәгаен әйтә алмас иде, шулай да инде тәмам яктырып, сигезләр тирәсе булганда аны дәштеләр. Камерага кергән милиционер коры гына:

— Фарукшин, киен!— диде.

Мотаһир торып басты. Аның бар булган киеме өстендә иде. Моны күреп, милиционер:

— Әйдә, чык!— диде.

Ишек төбендә икенчесе тора икән. Анысы да усал кылана.

— Кулыңны артка куй!

Урамга чыгу белән тагын фәрман яңгырады:

— Уңга карама, сулга карама! Атла, әйдә!

Сасы камерадан соң салкынча саф һаваны күкрәк тутырып сулый-сулый атлап китте ул. Ләкин бераздан, аллы-артлы ике милиционер арасында булган хәлендә урам уртасыннан барганда, Мотаһир бик гарьләнде, үзен җайсыз хис итте. Район үзәге, гадәттә, төрле учреждение, оешмалар белән тулган була. Хезмәткәрләрнең күбесе эшкә барган вакыт. Ә син сак астында, бөтен халыкның күз карашын тоеп, аяк атламаган җиргә мәҗбүри барасың,ояты ни тора! Таныш-белеш очраса, нишләрсең? Алар ни уйлар? Өргән этнең авызына сөяк тыгып булмаган кебек, һәрберсенә, минем гаебем юк, бары нәрсәнедер ачыкларга гына алып баралар, дип акланып булмый ич...

## IV

Военкомат янына җитәрәк, сары таштан салынган бер бинага таба борылдылар. Милиционерларның берсе алга китте, икенчесе артта калды, Мотаһирны уздырды. Берсе, бина эченә керүгә үк, уң кул яктан икенче ишекне ачып, Мотаһирга әмер бирде:

— Кер!

Зур гына бүлмә, артык җиһазлы түгел. Уң якта шкаф, икенче якта китап киштәсе — кырып эшләнгән агачтан ясалган. Каршыда кызыл постау белән ябылган өстәл, анда телефон — трубкасы тартма өстендә торган шикелле, кара савыты белән ручка, кәгазьләр, шунда ук пресс-папье, ягъни, киптергеч. Стенада — Дзержинский сурәте.

Өстәл артында яшь кенә бер егет утыра — НКВД кешесе булса кирәк.

— Фамилияң?

Челт иттереп яңагына китереп суккан кебек булды бу. «Исәнме-саумы юк, урын тәкъдим итү юк, менә сиңа мә»,— дип уйлап кына өлгерде Мотаһир, әлеге сорау янә маңгайга килеп чәпелде:

— Фамилияң?

— Фарукшин.

— Исемең?

— Мотаһир.

— Семьяң?

— Хатын...

— Балаң бармы?

— Бар. Малай...

— Житте. Син миңа турысын әйт: синең атаң кулак булганмы? Син совет хөкүмәтенә каршы барасың икән. Заем кампаниясенә каршы килгәнсең...

Мотаһир да сорау алучының үзе кебек ашыгып җавап кайтарырга теләде. Гүя шушы мизгелдә үк җавап бирүе аның алдагы язмышын хәл итә. Бер үк вакытта, җавабы каршы әйтү шикелле түгел, ә искәртү рәвешендәрәк, сабагын белмәгән баланың ялгышын мөгаллим төзәткән сыманрак тоелды.

— Иптәш, сез дөрес әйтмисез. Минем эти — урта хәлле крестьян. Нәселдә беребезнең бер советка каршы барганы юк. Мин бер айлык хезмәт хакыма — туксан тәңкәгә үзем заемга язылдым...

Бу яктан эш барып чыкмаса, икенче яктан чәпәргә тегенең соравы әзер иде, ахрысы. Ул, Мотаһир сүзен әйтеп бетерер-бетермәс, торып басты:

— Син колхозны таркатырга йөрисең, кешеләрне эшкә чыкмаска өндисең икән. Килсәгез дә — эшләмәгез, дисең икән.

Яшь, чибәр, чип-чиста йөзле, кызлар кебек зифа сынлы, пөхтә киемле бу егетнең бәгыре таш икәнен Мотаһир бик тиз шәйләп алды. Әмма моны аңлау аның тез буынын калтыратмады, киресенчә, күңеленә хөрлек, көч өстәде. Еш кырынудан зәңгәрләнеп торган, бет таеп төшәрлек шома яңакларына, кинчә иягенә генә түгел, егетнең карап торышка матур коңгырт күзләренә дә ул туры карады.

— Бу — ялган,— диде ул катгый тавыш белән.— 1931 елда ук оешкан колхозны ничек итеп утыз җиденче елны таркатасың? Аннан... без, «колхозың алда булса, авызың балда булыр»,— дип тырыштык...

— Сезнең кебек мәкерле, үчле кешеләр бөтенесен эшли ала.

— Миндә андый теләкнең булганы да юк. Минем колхозга бернинди ачуым юк. Мин бит үзем шунда эшләгән кеше. Колхоз бассын, тернәкләнсен, дип тырышып йөргән кеше.

— Шулаймы?— дип сорады, мыскыллы елмаеп, яшь тикшерүче.

Ул торып басты. Аның өстендә коңгырт төстәге, герб төшерелгән җиз төймәле гимнастерка, шундый ук җиз төймәле ике түш кесәсе дә бар. Гимнастерка якасында читләре кара белән тотылган, өч кубиклы алсу петлицалар. Зәңгәр галифе чалбары кабарып тора, ялтыратып чистартылган күн итекләре шыгыр-шыгыр килә. Билдә аеллы киң каеш, сул иңнән билгә тар каеш төшкән, уң янтыгында кобуралы наган. Кап-кара чәчле бу кешенең киеменнән дә, үзеннән дә чисталык, пөхтәлек бөркелеп-сизелеп тора. Беренче карашка ул үзе дә бик итагатьле кеше сыман. Ул, йөренеп алгач, янә өстәл янына килде.

Күндәм һәм йомыкый сыманрак күренгән авыл адәменең үз-үзен тотышы анда кызыксыну уятты булса кирәк. «Юаштан юан чыгар диләр, карап карыйк алайса»,— дип уйлады ул өстәлдә бармакларын биетеп, һәрхәлдә, чыгырыннан чыкмаган иде әле.

Моны шәйләп, Мотаһир ашыгып, сүзен сүзгә тезеп, хикәяләвен дәвам итте:

— 1932 елны мин өч ай шушында, районда РКШда укып, өлкән машинист таныклыгы алдым. Колхозга кирәкле белгеч булып кайттым.

— Кемнәр белән укыдыгыз?

— Авылдан икәү. Башка авыллар да бар иде. Фамилияләре...

— Анысы не важно.

— Менә шул, иптәш, колхозга кайтып, кешеләрне чәчкечләр белән эшләргә, ягъни күпме симәнә салырга икәнен өйрәттек. Бездә агроном юк бит. Чәчкеч, урак машиналары көйләргә Юкәле авылына да чакырдылар. Анда да укытып йөрдем. Ышанмасагыз, Асылмәрдән абзыйдан сорагыз. Ул ябылуда ята. РКШ директорры Мәхмүтов Кәбир иде. Әле белә дә торгансыздыр?

Егет Мотаһир яныннан китеп, урынына утырган гына иде, тезгененең кулдан ычкына баруын шәйләп, көчсезлегенә гарьләнеп, чәчрәп сикереп торды. Ярсудан тавышы яшелле-зәңгәрле булып чыкты.

— Мәхмүтовны беләбезме, юкмы — анысы синең эш түгел! Чүбек чәйнәп май чыкмый. Ишеттеңме?! Син, сүз боткасы ясап, безнең башны буташтырма, яме! Элекке заслугаларың белән мактанма. Әнә, революция ясашкан, гражданнар сугышында йөргәннәр дә, әллә нинди зур маршал-генераллар да халык дошманы булып чыкты. Син бит грамотный: укыганың, ишеткәнең бардыр?

— Бар.

— Шулай булгач?!

— Соң...

— Соң түгел! Халык дошманнарын фаш итәргә беркайчан да соң түгел! Аңладыңмы? Шулай булгач, турысын әйт, үзеңә җиңелгә килер — әйтәсеңме, юкмы?

Мотаһир чын мәгънәсендә аптырап, гаҗизләнеп, сорау алучының йөзенә текәлде. Чөнки теге тагын Мотаһир каршында тора иде.

— Нәрсәне?

Егет чәрелдәп кычкырып җибәрде:

— Әнәннен...

Ул дагалы күн итеген идәнгә бәрә-бәрә, катлы-катлы итеп сүгенергә керешә. Кыйшайган авызыннан төкрек чәчрәп-чәчрәп чыга, борын тишекләре бер киңәеп, бер тараеп, янак сөякләре кыеш-мыеш килеп бетә, йодрыклангган куллары Мотаһирга төртелә язып кала, кашлары маңгаена менә, үзе

кибәк ашаган сыердай мышный, гыжлый. Бая матур күренгән яшь чырае, отыры нурын югалтып, җыерчыкланып, картайганнан-картая һәм косасыны китерер дәрәҗәдә нәфрәт тудыра. Берәү булса, бу галәмәткә түзеп тора алмас: йә аңа сугып җибәрер, йә йөзен читкә алыр иде. Ләкин Мотаһир боларның берсен дә эшләмәде, чөнки хәл тагын да кискенләшүдән, үзенә кыен килүдән гайре һичнәрсә барып чыкмасын белә. Ул берни дә кыра алмый: аны монда китергән милиционерлар ишек артында гына, тикшерүченең үзенең дә наганы әзер, атып үтерергә дә күп сорамас. Аннары, Мотаһир гаеп өстендә тотылган кеше түгел, аны өеннән, хатыны, баласы янынннан, алдап-йолдап алып чыгып киттеләр. Гаеп ташлаулары да кыек атып туры тидерергә тырышу гына. Димәк, чыдарга, ничек кенә авыр булса да түзәргә, тешне кысып, бөтен ачуын йотып котәргә. Басылыр, сүрелер бу адәм, йә булмаса, күркә кебек кабарына торгач, шартлар...

Төкәне бетеп, тәмам хәлсезләнеп төшкәч, тикшерүче соңгы көчен җыеп акырды:

— Куй кулыңны артка таба! Стенага борыл!

Мотаһир берсүзсез буйсынды. Күн итек шыгырдавыннан тегенең чыгып киткәнен чамалады. Ләкин шундук аяк тавышы янә ишетелде, түргә узды. Өстәл янындагы урындык сыкрап куйды. Мотаһир кырын күз белән генә карап, керүченең икенче кеше икәнен күрде. Бусы да милиция киеменнән, тик гадирәк. «Дежурный бугай»,— дип уйлады Мотаһир һәм әкрен генә, ни булса шул булыр дип, кулларын төшерде, борылды. Теге дәшмәде. Ниндидер журналмы, кенәгәме актара башлады. Шул рәвешле бер сәгать чамасы узды.

Кинәт ишек ачылды һәм баягы бәндә кергән уңайга ук:

— Сөйләштегезме?— дип сорады.

— Юк,— диде өстәл артындагы журналын ташламыйча.— Мин аннан берни дә сорамадым.

— Сорамасаң, мин әйттерермен,— диде тикшерүче һаваланып һәм Мотаһир янына ук килде.— Кая куйдың наганыңны? Кулак! Халык дошманы! Колхозны таркатучы...

Тагын шул нурсыз чырай, тәмәкедән саргайган тешләр ыржаеп каршыда тора, җитмәсә, әле генә пыскытып кергәнме — авызыннан тәмәке исе аңкый, чыдасаң — чыда, чыдамасаң — юк. «Түз,— ди Мотаһир үз-үзенә.— Сине дүрт күз белән зарыгып көтүче balаң, хатының хакына түз! Намаз артларында балаларына тәүфикъ теләгән атаң-анаң хакына түз! Намуслы исемең, авыл халкы арасында яулап өлгергән абруең хакына түз! Тешең сынса сынсын, сабырың сынмасын!» һәм Мотаһир тагын сабыр итте. Күпме кабахәт сүгенү сүзе ишетсә дә, күпме хаксызга тагылган пычрак исемнәр күтәрсә дә — барысына да түзде. Ә теге отыры чыгырыннан чыга, бәйдәге эт кебек котырына, өрә, ыргыла — әмма тешли алмый. Аның пырдымсызлануына дежурный да чыдамады — чыгып китте. Ә ул — һаман пычрак атуында. Ниһаять, аргач, хәлсезләнеп куллары салынып төшкәч, сулышына буылып, ул дыңк итеп өстәл артына чөңкәйде.

— Кил монда.

Мотаһир ике адым атлады да туктады. Тагын боерулы тавыш бүлмәне яңгыратты. Тәрәзәләр зыңлап куйды.

— Кул куй!

— Юк, куймыйм.

— Алланы...

Тагын сүгенү, җикеренү, янау, өркетү... Тагын сүгенү...

«Йә хода, шул тикле җирәнгеч сүзләрне каян, кемнәрдән өйрәнде икән бу?— дип уйлады Мотаһир хәйран калып.— Утыз бер ел яшәп, күпме җирләр гизеп, чит-ят кешеләр күреп, бу хәтлене ишеткәне юк иде. Бу — адәм затыннан микән соң? Әллә...»

— Борыл стенага! Кыймылдама!

Мотаһир стена каршына килеп басуга, тикшерүче чыгып китте. Баягы дежурный керде. Мотаһир тагын бүлмәгә таба борылды. Искәрмәстән ят бер кеше керде. Ул да, баягы тикшерүче сыман, хәрби киемнән, әмма моның

петлицасында дүрт кубик иде. Монысының да чыраенда иман нуры юклыгын Мотаһир шундук аңлап алды. Чөнки бу да, баягы тикшерүче кебек, эшне коры тотмакчы.

— Әйттеме?

— Юк,— диде тәрәзә каршында утырган дежурный.

Теге Мотаһирның каршына ук килеп:

— Әйттерербез әле без синә,— диде һәм бер генә мәлгә сынап карады да, өстәл артына барып утырды. Саплы наганын чыгарып салды.— Менә моны күрәсеңме?

— Күрәм,— диде Мотаһир куңдәм генә.

— Ну?! Әйтәсеңме, юкмы? Нишләп син колхозны таркатырга йөрисең?

Мотаһир гарьләнеп:

— Мин үз теләгем белән колхозга язылдым,— диде.— Җан көчемне биреп эшләдем. Беренче трактор кайткач, сабый баладай шатландым, күмәк хуҗалыкның файдасын...

Тикшерүче аны кырт кисте:

— Нишләп кешеләрне заемга язылмаска котыртасың? Анаңны фәләнфәсмәтән... Кулак! Контр!

— Мин кулак та, контр да түгел!

— Молчать!— дип өстәлгә йодрыгы белән китереп орды тикшерүче. Наган сикереп куйды.— Кем соң кулак? Минмени?

— Мин алай димәдем.

— Йә-а-к, синең тел төбең шуңа бара! Нәрсә, ирektән туйдыңмыни?! Әйт, кайда наганың? Шушындыймы? Әллә бүтәнме? Ничә патронын бар? Әйт, нишләп син совет хөкүмәтенә каршы барасың?

Мотаһирның тамагы кибә, ачлыктан күз аллары караңгылана, өзлексез өстенә акыру-бакырудан башы шаулый. Алай да ул үзен тыныч тотарга тырыша иде.

— Иптәш, нишләп мин хөкүмәткә каршы барыйм ди. Әнә, уникесендә, Верховный Советка сайлауларда иң беренчеләрдән тавыш бирдем, хатыным белән парлап бардык.

— Молчать! Саботажник! Мин сиңа күрмәгәнеңне күрсәтермен, эттән туган нәрсә.

Монысы инде артыкка китте. Бернинди киртәгә сыймый иде. Мотаһир ачулы карашын тикшерүченең тук-көр йөзенә төбәде.

— Сезнең мине мыскылларга хакыгыз юк. Минем әти авылда могтәбәр кеше. Без тугыз бала үстек. Эт дип...

Иманеч йөзе кыйшаеп китте тегенең. Чөнки ул да юаш кыяфәтле Мотаһирдан бу кадәресен — кыюлык — көтмәгән иде, ахрысы.

— Молча-ать! Контр! Халык дошманы! Куй кулыңны!

Мотаһирның җавабы катгый иде.

— Юк, куймыйм.

— Ярар, карарбыз,— диде тикшерүче һәм милиционерга дәште:— Алып кит.

...Тагын урам буйлап, рисвай булып, бөтен кеше алдында хурлыклы рәвештә ике милиционер арасында кайту.

...Камера. Ишек төбенә күз төшү белән косасыны китерә торган параша. Җитмәсә, нәкъ Мотаһир кергән вакытта икәү чаршау тотып, берәүне тышка чыгаралар иде.

Урамнан, саф, салкынча кышкы һавадан кергәч, мондагы бозык һава борынга бәреп керә, бугазга килеп тыгыла, тынга каплана. Тик... барыр урын, зарланыр кеше юк. Бөтен мохитең шушы сасы камера һәм анда ябылып ятучылар белән чикләнгән.

Хәл-әхвәл сораштыру, кайгы-борчуны уртаклашу, тагын кемнәрнеңдер йончып-елап (күбесе кыйналган була) сорау алудан кайтулары — болар көне буе дәвам итте. Мотаһир инде чирканчык алган, аннары, ул азмы-күпме дөнья күргән, медицина хезмәткәре буларак кеше күңеленә дә керә белә — болар аны бермә-бер үстереп җибәрде.

Гомерендә беренче яисә икенче мәртәбә генә район үзәген күргән авыл агайларына аның үгет-нәсихәте дә кайчак ярап куя. Даруга һәм скальпельга тотынганчы, иң беренче дәва — сүз икәнен Мотаһир исеннән чыгармый иде. Хәер, аның кебекләр, дөнья күргәннәр дә юк түгел иде монда. Алар белән сөйләшү — тиңнәрчә.

— Кул куйдыңмы?

— Юк.

— Мин дә куймадым.

Ә өченче бирәү боларга үз дәлилен китерә.

— Мин дә куймаган идем куюын. Кабат баргач, куймыйча булмас инде. Узган атнада берәүне кыйнап үтергәннәр. Чүккән дөягә сукмаслар әле, бәлкем җиңелгә туры килер.

Аңа Мотаһирның тиңе җавап бирә.

— Килер, көт. Таш капчыкка ябып куярлар, сөякләрең генә шыгырдар...

Ә теге һаман үз кишәрлеген сукалый:

— Аларга минем ни начарлыгым тигән? Нишләп алай итсеннәр икән. Кеше таламаган, әйбер урламаган...

— Эт яхшыга да өрә, яманга да өрә. Рас алар кулына килеп каптың, ычкынам димә инде син. Бетте башың... Кул куйсаң, үзеңә-үзең хөкем карары чыгарасың...

Мескен баш хәзер үк иелә, яшьле күзләр томалана, ун-уникe яшьтән сабан сөргән, сука башы тоткан, гомер буе чалгы-сәнәк төшмәгән куллар ирексездән дерелди, ни-нәрсәгә орынырга белми, җәлпәк борын йомшый...

— Җелеккә төшәләр бит, агай.

Андыйларга Мотаһир җылы сүзен — җан азыгын җәлләми. Үз хәлен дә онытып, мескеннәрне юата.

— Ярар, алай җебеп төшмә әле, туган... Болытлы көннең бер аязы да булыр.

Әмма алар гына түгел, ул да үзен кыерсытылган, күп нәрсәдән мәхрүм ителгәндәй тоя. Һәм чыны да шулай. Көндез бирелгән бер бадьян аш күптән онытылган, өч йөз грамм ипидән җилләр искән. Ә ашыйсы, аннан да битәр өздереп эчәсе килә. Чәй түгел, салкын су да юк. Тоткыннарның битенә атналар буе тамчы да су тимәгән.

Тагын йокысыз төн. Уйга чумган баш. «Мөсәмирәнең хәле ничек икән инде? Борчылып, авырына зыян килмәсә ярар иде. Өс-башына җылы киенеп йөри микән? Тирләгән килеш, ялан-өс урамга да чыгып китә торган гадәте бар. Иске итегенә олтан салып өлгерә алмадым. Тишелеп чыкмас микән? Ичмаса, авылдан килүче дә юк. Бәлки иртәгә килерләр? Килерләр, түзеп ятмаслар».

Ләкин иртән аңа кабат тикшерүчеләрне генә күрү насыйп икән.

Өч көн буе аны сорау алып интектерделәр. Алып киткәләр дә җәфалыйлар. Чиратлашып керәләр. Берсе ялыкса, икенчесе әзер тора. Ничек тә бөгү ниятләре. Янау, сүгенү, кыйнау, тагын янау, тагын сүгенү... Андый чакларда Мотаһир уйлап куя: «Бу бәндәне дә газиз анасы интегеп тапкандыр инде. Улым дип иркәләгәндер, инсафлы булсын, теле балдай, йөзе айдай булсын, дип теләкләр теләгәндер. И ана, ярый әле ишетмисең малаеңның авызыннан чыккан бу җирәнгеч сүзләрне, югыйсә, йөрәгең ярылып үләр идең...» Сүз белән җәфалаулары гына җитмәгән, тозлы балык ашатып, су бирмәү, утыртмыйча, сәгатьләр буена стенага терәп кую... Тезгә сугу... Резин белән арканы яру... Бу хәлгә тимер дә чыдамас...

Һәм Мотаһирның да тәкате төкәнде. Мәгънәсез сораулардан гарык булгач, ул, сабыры бетеп:

— Мин болай итеп басып тора алмыйм, — диде. — Хет урындык бирегез... Аяклар гөбе кебек шеште бит инде...

— Торырсың! — дип аның сүзен бүлде яшь тикшерүче. — ...нә үтми әле синең.

Мотаһирның ачуы кабарганнан-кабара барып, чүлмәге ташыган, сабыр канатлары сынды. «Күпме түзәргә була бу гаделсезлеккә?!»

— Китерегез миңа прокурорны, врачны. Минем аякларым авырта. Үләсе генә калды... Йә атыгыз...

— Пуля әрәм итәбез ди.— Тикшерүче беренче мәртәбә тантана итә, ләззәт ала.— Үлмәссең дә, исән дә калмассың. Макар да көтү көтмәгән җирләргә барып чыксаң...

Каһкаһәле көлү Мотаһирның ачуын гына чыгара.

— Ничә көн инде юынган юк. Без бит хайван түгел. Бер район, бер җир кешеләре ләбаса. Без үстергән икмәктән ризык җыясыз түгелме? Бу кадәрле мыскыл итәргә...

— Сайра,— диде тикшерүче һәм кулларын күкрәге турысына кушырып куйды.

— Мин, медицина хезмәткәре буларак, чисталык...

— Төкерәм мин синең медицина кагыйдәләреңә һәм... үзеңә! Әйт, коткы тараттыңмы?

— Юк.

— Әйт, контр калдыгы!

— Мин контр түгел!— диде стенага каратып куелган Мотаһир һәм кулын ычкындырды.

— Ә, син әле мондагы тәртипләрне белмисеңмени?! Күтәр кулыңны!

Ләкин Мотаһир да үҗәтләнә башлады.

— Кул түгел, аяклар да тотмый инде хәзер.

Һәм ул идәнгә чүгәләде.

Тикшерүче очынып килде дә аңа күн итеге белән тибеп җибәрде. Мотаһир һаман тормагач, ярсып-ярсып аны типкәләргә керешге:

— Тор, сволочь! Тор!..

Тагын сорау алу, тагын мыскыл итү, җәберләү... Ахырда, үз дигәненә ирешә алмагач, тикшерүче, парикмахер чакыртып, Мотаһирның әле юньләп җитмәгән дә чәчен кырдыртты һәм ни утыра, ни ята алмый торган бәләкәй җиргә кертеп япты. Кеше сыярлык кына иде ул бастырып куелган сандык шикелле тар бүлмә. Мотаһирны төрткәләп кертү белән тыштан йозаклап та куйдылар һәм шул минутта ук аның башына тып итеп салкын су тамды. Мотаһир башын бер читкә алмакчы, күтәрелеп карамакчы булды. Ләкин кеше җәзаларга көйләнгән бу җайланманың өске өлеше тагын да кысанрак булып чыкты. Әле генә үткен пәке белән кырылган шәрә башка тып-тып боз кебек салкын су тама башлады...

## V

Бишенче көнне, таң белән, унҗиде кешене Чаллыга озаттылар. Алдан бер ат белән олаучы, аның артыннан наганлы сакчы, икешәрләп тезелгән тоткыннар һәм янә өч сакчы бара. Каршы килгән атлы, җәяүле — һәммәсе юл читенә чыгып, көтеп торырга, юл сабарга мәҗбүр. Чөнки алдагы сакчының әмере шундый. Ул вакыт-вакыт артына да карап ала, ниндидер команда биргәли. Арттагы сакчылар исә, тизлекне киметмәскә тырышып, әкрен кыймылдаганнарга боералар:

— Җәтрәк!

— Калма!

— Куып җит!

Ике-өч чакрым узып, уң якта боегып калучы биек тауларга карагач, Мотаһир йөрәге ярсып тибә башлады, башына кан йөгерде. Бердән, иленнән аерылу турындагы шик-шөбһәләр чынга әверелсә, икенчедән, кар каплаган зәңгәр таулар артында аның туган авылы кала бит. Әйе, ул алга бер адым атлаган саен — ерагая. Кала, кала туган илләр! Анда Мотаһирның гаиләсе: хатыны, малае... Анда газиз ата-анасы... Алар ни хәлдә икән? Килүче, хәл белүче һәм алар турында ни дә булса җылы сүз әйтүче булмады. Моны нинәрсәгә юрарга? Ничек аңларга? Ничек итеп аңлатырга? Әллә инде килеп тә

кертмәделәр, очраштырмадылар микән? Әллә ул хәзер туганнары белән күрешүдән дә мәхрүм ителгәнме? Юк, башына сыймый, гакылына барып җитми болар Мотаһирның. Уйлар, уйлар... Алар — барысы юл кебек очсызкырыйсыз.

Басудан барганда иркенлек кичереп, уйлар диңгезендә йөзсә, авыллар аша үткәндә Мотаһир кысанлык сизә, оялу катыш читенсенү хисе бәгырен телгәли. Капка төпләрендә сөйләшеп торучы, кар көрәүче яки колоннаны үткәзеп урам уртасында басып торучы ир-ат, хатын-кыз аларга нәфрәт белән, бала-чага исә куркып-шикләнеп карый шикелле. Гаҗәп түгел, алар бит — «халык дошманы». Ләкин үзенең дошман вә җинаятьче булуына, сак астында «өтәрмәнгә» куылуына Мотаһир һич кенә дә ияләшә, бүгенге язмыш белән килешә алмый. Шулай да ул кешеләрнең йөзенә күтәрелеп карарга җөрьәт итми, хурлык тамгасы, авыр капчык булып, гәүдәсен баса. Ул гына түгел, аның кешелеген изә, сыта.

Авылдан чыгып, шактый баргач, арттан аларны җигүле ат куып җитте. Шөлдерләрен чылтыратып, җан-фәрманга чаптырып килгән ат колоннага житәр-җитмәс шып туктады. Аягүрә басып килгән ир шундук артлы чанадан сикереп төште. Үрелеп, шакмаклы ашъяулыкка төргән зур табак алды. Ул кыска туннан, изүе ачык, башындагы күн бүреген кыңгыр салган, калын, карлыккан тавыш белән эндәште:

— Иптәш милиционер, агайне, карале...

Сакчылар аны ерактан ук күреп-ишетеп борылганнар һәм туктап-көтеп торалар иде. Берсе, йөзенә канәгатьсезлек билгесе чыгарып, тегеңә таба атлады.

— Ни бар?

Икенчесе, авызлыгын чәйнәп, борын тишекләреннән пар бөркеп, алгы аягы белән тибенеп торган ат ягына күз салды. Анда шикләнерлек әйбер-кара юк иде шикелле. Ул да карашын ат хуҗасына күчерде.

— Агайне,— диде теге чая адәм,— мин тәрәзәдән сезнең колоннада бер танышымны күреп калдым.

— Шуннан?— диде сакчы төксе генә һәм, бу нинди бәндә икән, берәр этлек эшләргә җыенмыймы дигәндәй, аңа чәнчеп карады.

— Солдатта бергә булган идек.

Аларның сүзен арттагы тоткыннар да ишеткәнлектән, сафтагылар барысы да диярлек, ярым борылып, бу тамашаны күзәтәләр һәм шул ук вакытта әкрен генә юлларын да дәвам итәләр иде. Уртадан бер ир, полкташын танып, кул болгады, артка кала башлады. Ләкин сакчылар аңа кул изәделәр, янәсе, юлыңда бул. Ә берсе, мыскыллы елмаеп, ат хуҗасына дәште.

— Дустың янына сафка басасың килмидер бит? А-ну, марш моннан...

— Сабыр,— дип өлкән конвойчы аны туктатты һәм тегеннән сорады.— Әйтер сүзең бармыни?

— Менә служакка әзрәк күчтәнәч алмассызмы?— дип чая адәм төенчеген сул кулына тотты да, уңы белән чалбар кесәсеннән бер шешә чыгарды.— Кичә кызымны кияүгә бирдем, шатлыгымны сез дә бүлешегез.

— Кхым,— дип тамак кырып алды милиционер һәм, ярым борылып басты да, шешәне җалт кенә шинель кесәсенә шудырды.— Кая, бир күчтәнәчеңне, тапшырырмын.

— Рәхмәт.

— Бик авыр түгелме соң бу?

— Алар күбәү бит.

— Ярамаган әйбер юкмы?

— Юк, юк, бала-чагамыни, аны гына... Чишеп күрсәтимме?

— Кирәкми.

— Сез кая, Чаллыгамы?

Мыскыллы елмаеп торган сакчы тагын зәһәрлеген күрсәтте.

— Күп белсәң, тиз картаерсың, абзый кеше. Тәртәңне бор. Кру-гом! Хуш.

— Ярый, ярый,— дип теге адәм чанасына таба атлады.

Сакчылар кыр казлары кебек тезелешеп баручы тоткыннар артыннан ашыктылар. Бераздан тегенең әманәте чанага илтеп куелды.

Тагын бер авыл артта калды. Өлкәнрәкләрдән берсенең бик интегеп баруын күргәч, Мотаһир түзмәде, туктап, сакчылар белән тигезләште. Берсе:

— Нәрсә, йомышың бармы әллә?—дип сорады.

— Әйе.

— Әнә, читкәрәк чык та агыз.

— Юк, икенче нәрсә белән...

— Ну бар, утыр алайса. Нәрсә баш катырасың.

— Юк, иптәш, минем башка үтенеч: әнә бер абзый тәмам хәлсезләнгән, атка утыртасы иде.

— Туганыңмыни?

— Юк.

— Алайса, нигә кушмаганга куштанланасың?

— Мин...

— Күрәм син икәнне. Марш, стройга!

...Галәмәт биек тау. Юл — түбән. Ирексездән йөгерәсе килә. Чөнки тау текә, әйтерсең, сине кемдер арттан этеп бара...

Ләкин ач, хәлсез юлаучылар гел түбән таба гына атламыйлар. Юлның тигезе дә, үргә табасы да туры килә. Ат та ялыкты, тоткыннар гына түгел, сакчылар да сизелерлек арыдылар.

Мотаһир да, гәрчә элек җәяү йөрүнең әллә ни авырлыгын күрмәсә дә, нык йончыды, җеп өзәрлек тә хәле калмады. Ул, башын түбән иеп, бара да бара. Вакыт-вакыт аңа алдагы иптәшләренең олтанлы итек кунычлары, тун һәм бишмәт чабулары, ат тоягы чокыры, чана табанының шома эзе, шыкраеп каткан тизәкләр, коелган салам яки печән учмалары гына күренә. Әйтерсең лә, дөньяда башка берни дә юк: мул яктыртучы кояш та, аның нурларында коенучы тал-тирәкләр дә, күзне чагылдыручы ак кар да, таулар-үзәннәр һәм еракгагы күгелҗем зәңгәр урманнар да, әйләнә-тирәдәге таныш авыллар да, юлда сирәк-мирәк очраштырган атлы яки җәяүлеләр дә юк сыман. Мотаһирның кисәк-кисәк башы әйләнә, күз аллары элҗе-мөлҗе булып, караңгыланып хәле китә, үтереп эчәсе килә, тәне кызыша, бүрек астыннан, аркасыннан ачытып, тир тамчылары агып төшкәне аермачык сизелә...

Ярты юл үткәч, бер авылда сәгатькә якын ял иткәннән соң, аңа әзрәк хәл керде. Коры-сары белән тамак ялгадылар. Теге мәрхәмәтле кыю адәм калдырып киткән ризык-нигъмәттән авыз итү аларга тәтемәде. Ул нигъмәтләр конвойчылар табынында эреде.

Челнинка елгасы буенда калкып торган ике катлы таш бинага якынлаштылар. Каршыда тәресез калган дәү гөмбәзле таш чиркәү, янәшәдә «Металлист» әртиле Мотаһирга таныш җирләр. Бередә, йозаклар, элмәкләр, атлама ише вак-төяк тимер-томыр әйберләр ясый торган әртилдә, аларның ерак туганы эшли. Чаллыга килгән чакларында аның янына кергәләгәне бар иде.

Шәһәр урамнары тыныч диярлек, анда-санда атлы, җәяүлеләр күренгәли, шалтыр-шолтыр калтырап бер машина узып китте. Өйләрдә тонык кына утлар яна.

Аларны зур таш йортка урнашкан милиция идарәсенең аскы катындагы бер бүлмәгә кертеп ялтылар.

Икенче көнне тоткыннар, милиция идарәсеннән чыгып, халык телендә «ресторан» дип аталса да, чынында исә гап-гади бер ашханә булган зур йорт янышнан, борыннарны ярып кергән тәмле аш исенә иреннәрен ялый-ялый, Кама ярына чыктылар, бер генә яклы урамга борылдылар. Монда паром, арырак агач заводы бар. Башка чыгып, өй салганда Мотаһир ул заводтан такта да алып киткән иде.

Бөтенесе таныш җирләр һәм, менә шуларны калдырып, ул китеп бара. Юк, китми. Ул үзенең туган җирен беркайчан да ташлап китмәс иде. Армия хезмәтен тутыргач, кайбер солдатлар кебек читтә калмады, көне-сәгате белән үз авылына кайтты. Илен-йортын сагынып кайтты... Ә хәзер китә. Юк,

китми. Аны сак астында алып китәләр, мәҗбүри рәвештә туган туфрагыннан аералар...

Су буенда каплап куйган көймәләр язны көтә, аркылы-торкылы яткан агачлар күренә. Бер «полуторка» машинасы һәм ике-өч атлы паром көтеп тора. Ә паром үзе су уртасында икән әле. Бирегә таба аны бәләкәй катер сөйри. Җәйнең җәй буе эштән башы чыкмаган иске катер яньчелгән-бәрелгән, тәмам калтырчага әйләнгән, ә шулай да җан көченә тырмаша. Гадәттә, елның бу вакытында су каткан була. Ә быел әле ул юка гына һәм, бозны ватып, паром йөри.

Паром яр буена килеп туктауга аннан кешеләр, атлылар төште һәм мондагылар керә дә башлады. Купты ыгы-зыгы: тегесе ашыга, монысы кабалана. Паромчы, өстенә бушлатсыман манчистр бишмәт, башына, колакчыннарын төшереп бүрек кигән агай, карлыккан тавыш белән фәрман биреп тора, олы күн бияләйле кулларын бутый.

— Әйдә, монда куй! Әй, син кая ашыгасың? Сиңа әйтәм түгелме...

Иң әүвәл «полуторка» кузгалды. Машина басмадан керүгә, паром селкенеп-чайкалып куйды һәм яртылаш чүкте. Аннан атларны керттеләр. Толыплы, чикмәнле авыл агайлары чаналарын бер-беренә терәбрәк, тартып-этеп куйдылар. Бары шуннан соң гына тоткыннарга чират җитте. Алар койрыкка, бер почмакка укмашып кереп бастылар. Бер-бер артлы боерык яңгырады:

— Не стоять! Садись! Не двигаться!

Тоткыннар чүгәләде. Өч-дүрт җәяүле дә паромның икенче почмагында үзенә урын тапты.

Алар керә башлауга, конвой башлыгы:

— Читкә кит! Якын килмә!— дип кисәтә торды.

Басманы паромга алу белән кечкенә катер тагын үз эшенә керешге: артында быгыр-быгыр суны кайната-күбекләндерә башлады. Әкренләп бу як яр ерагая, тегесе якынлаша иде.

Алда Мотаһирны ни көтә? Тәкъдирендә ни язган? Язмыш аңа үзенең нинди сират күперләрен әзерләгән? Моны ул белми. Паромдагы тоткыннардан моны беркем дә белми...

...Көн җылы. Үзе җилсез. Аз гына кар сибәли башлады. Эре кар бөртекләре юка боз белән капланган Кама өстендә дә, буксирга тагылган паромга һәм анда бер почмакта басып торучы тоткыннар өстенә дә — һәрнәрсәгә бертигез яталар. Әйе, кар аларның барысын да тигез күрә, язмыш кына аралый.

Мотаһир өсте чираган суга карап бара. Кая алып баралар, соң аны? Билгесез. Әнә бер адашкан акчарлак килеп чыкты. Паром артында хасил булган карасу эздә балык күзли. «Их, булсаң иде шушы акчарлак... Китсән иде каерылып очып... Һич югы, балык буласы иде... Һәрхәлдә, алар — ирекле. Ә мин?»

— Идел тотмаган икән әле.

— Быел соңлаган.

— Безне көткәндер...

Колак төбендә генә юлдашларының басынкы авазы. Ул да сүзгә кушыла. Ләкин болар барысы да аптыраганнан, гелән генә уйларыңа бәйләнеп яшәмәс өчен, әз-мәз эчне бушату өчен генә...

Ярга килеп туктауга, иң алдан тоткыннарны төшерделәр. Алар җиргә аяк басканнан соң, җәяүлеләр, машина һәм атлылар да киң басмадан ярга чыктылар. Тоткыннар, сафка тезелеп, сак астында, Алабугага юнәлделәр. Аларны озата килүче олау бүген юк иде инде.

Ниһаять, алда күпсанлы чиркәүләре белән борынгы шәһәр күренде.

Эчендәге Воскресенская Богородица чиркәве булган хатын-кызлар монастыре, озын манаралы, җыйнак кына таш мәчет һәм сукыр татар балалары өчен революциягә хәтле үк төзелгән училище янынннан үттеләр. Алда, бер катлы агач өйләр өстендә мәһабәт бина — өч катлы зур таш йорт калкып тора иде.

Кемдер:

— Әнә шул инде,— диде.

Бу йорт катына якынлашкан саен Мотаһирның гаҗәпләнү-кызыксынуы курку-каушау белән алышынды. Чөнки ерактан бина үзенең озынча, өсте ярым түгәрәк тар тәрәзәләре, бизәкле-челтәрле зур капкасы белән күңелне җәлеп итсә, өч метрлы такта коймасы, почмаклардагы каланчалары һәм андагы кораллы солдатлары белән йөрәктә шом уятты. Җансыз, шыксыз-салкын буяуы һәм койма өстеннән үткәрелгән рәт-рәт чәнечкеле тимер чыбыгы — ирексездән сине сагаерга мәҗбүр итә, йөрәк ешрак тибә. Боларны күрүгә тоткын юашланып кала.

Йорт, чыннан да, мәшһүр икән. Кайчандыр, унтугызынчы гасыр урталарында, бөек рәссам Шишкинның атасы подряд алып төзеткән, диләр.

Халык телендә «коры төрмә» (чөнки камералар калорифер ярдәмендә, ягъни җылы һава өрдереп җылытыла) дип аталган төрмә замогы иде бу. Риваятьләргә караганда, этап белән Себергә куылган кешеләрне (ә элек Себер тракты Алабуга аша үткән) шушында төн кундырып чыгарганнар. Замок эчендәге Александр Невский чиркәвендә тоткыннар гыйбадәт кылганнар...

Менә чын төрмә нинди була икән! Аның калын таш стеналарыннан тирә-юньгә җан өшеткеч салкынлык, кырыслык тарала. Төрмә тирәсендә шомлы тынлык: олы кешеләр түгел, бала-чага да юк. Күпләр бу каһәрле бинаны әйләнеп үтәргә тырыша.

Мотаһир бу бинага якын килгән саен үзен кичерәя баргандай тойды. Гүя ки, иләмсез бу бина үз тоткыннарын кабып йотар өчен ачу белән кабарына бара иде.

## VI

...Хәлсезләнгән аяклар ял сорый. Ләкин ял юк. Тоткыннарны, ягъни этапны кабул итү бара. Озын кара шинельле, петлицалары икешәр кубиклы дежурный берәм-берәм чакырып, эчкә кертә тора. Ул да шактый озакка сузылды. Дежурныйдан үз фамилиясен ишеткән тоткын, таза баганалы биек капкадан кереп китүгә, күз алдыннан гына түгел, бу фани дөньядан бөтенләй үк юкка чыккандай тоела.

Якын-тирә өйләрнең капка төбенә чыгучылар, урамнан үтеп баручы ачык авызлар — болар соңгы тапкыр күргән иркле кешеләр, гадәти кешеләр. Эчкә керсәң, бетте андыйлар...

— Нәбиуллин!

Мотаһир сискәнеп китте. Ул иң соңгы кеше булып калган. Аңа дәшәләр микәнни?

— Нәрсә карап каттың? Сиңа әйтәм түгелме?!

Мотаһир, бөтен сабырлыгын, ихтыяр көчен җыеп:

— Мин Нәбиуллин түгел,— диде.— Мин — Фарукшин.

Дежурный аптырап, санкцияне карады. Кисәк иелүдән СССР гербы беркетелгән бәрән бүреге селкенеп куйды. Ул янә башын күтәреп, кызгылт-таза йөзен Мотаһирга төбәде.

— Как так?

— Точно так. Я не знаю кто такой Нәбиуллин.

Дежурный, кашларын җыерып, янында торган конвойчыга җикеренде:

— Мә санкцияне, мә үзеңнең Фарукшиныңны! Алып кит! Нигә карамадың?..

Тегесе аклана башлады, әлегешеп алдылар. Конвой башлыгы, озын кунычлы итекләре белән олы-олы атлап кузгалып киткән дежурный артыннан эчкә үтте. Калган өч конвойчы да капка артында юк булдылар. Мотаһир урамда, бизәкле зур капка янында, берүзе торып калды. Кинәт гәүдәсе-тәне җиңеләеп киткәндәй булды. Бергә килгән иптәшләре дә, сак та юк. Ул — берүзе. Кая юл тотарга? Нишләргә? Китеп барыргамы? Көтәргәме? Аңа бер кәлимә сүз әйтүче булмады. Менә хәзер китеп барса да... Баш исән дә җан исән... Хәер, китеп кая барасың? Чит-ят шәһәрдә ул нишләп йөрсен,

кая барып сугылсын? Кемгә сыенсын? Димәк, файдасыз. Икенчедән, бу ниндидер аңлашылмаучылык кынадыр. Аны барыбер эзләп табарлар. Ул җир читенә китеп олага алмый бит, китсә дә, килгән юлына кире төшәр — өенә кайтыр. «Тагын борчу, тагын шул ук каталажка, этап... Монысыннан да яманрак булыр. Чоры нинди бит. Юк инде, язмыштан узмыш юк, ни күрсәм да районлашлар-якташлар белән күрермен...»

Ул кисәк кенә башын күтәрде. Почмактагы каланчада ак тунлы, озын мылтыклы часовой тора бит. Вакыт-вакыт койма артыннан эт өргән тавыш та ишетелә. Моны ничек исеннән чыгарган? Димәк... һәм ул сабыр гына көтә бирде.

Мотаһир бераздан төрмәгә арты белән борылды һәм алда чиркәү дисәң — тәбәнәк, часовнямы шунда, кыскасы, түбәсе манара сыманрак итеп очлаеп эшләнгән ниндидер бина күрде. Очлы шпиле дә бар, хәтта икәү дә әле. Ләкин тәресе юк. Бу ни булыр икән, дип аптырап торганда, әлеге корылма янына агач мичкә утыртылган бер чана килеп туктады. Атлы чана китеп тә өлгермәде, көянтә-чиләкле бер хатын килде. Шуннан Мотаһир моның су ала торган колонка икәнен аңлады. Ләкин хәзергә ул әле бу колонканың тоткыннар тормышында нинди әһәмияткә ия булуын белми иде.

Бераздан кар явудан туктады, болытлар таралды, кояш чыкты. Әмма һава салкынча иде. Тәненә суык үтә башлагач, Мотаһир койма буйлап китте. Уңда бер катлы агач өйләр тезелеп киткән, каршыда кайсыдыр сәүдәгәрдән калган складлар булса кирәк — кызыл кирпечтән салынган озын биналар, алардан уңдарак ике катлы йорт түбәсен калкыткан. Ә алар артында, еракта, зур кыңгыраулы биек каланча. Аннан да ары чиркәү, ә сулдарак һәм бик еракта тагын ике чиркәүнең гөмбәзләре күренә иде.

Мотаһир урам чатында тора. Ул сирәк-мирәк узгалаган, билле тун кигән, шакмаклы шәл бәйләгән яисә озын колаклары күкрәгенә төшеп торган йонлач бүрек кигән, кулларын муфта эченә тыккан марҗа хатыннарына карап кала. Каракүл якалы пәлтә кигән, сакаллы бер агай да үтеп китте. Мотаһир тирә-юньне бик игътибар белән, җентекләп күзәтә гүя үзенә әйтергә курыкса да, ирекле тормышы белән хушлаша... Чаттан өченче йорт каршында агач көрәк белән кар көрәүче янына барып килмәкче иде, сул яктагы часовойның үзенә карап торуын күргәч, бу уеннан кайтты. Ул, тыңмас өчен, төрмә каршында әрле-бирле йөренә башлады. Капка төбеннән урам чатына хәтле бара да кире китә. Туктап тора, тагын китә... Ашыйсы-эчәсе килсә дә, түнса да түзде Мотаһир, читкә китмәде. Ул кешеләр белән дә сөйләшмәде. Шулай да аңа сүз катучылар булды. Күрәсең, болар төрмәдәге туганнары янына килүчеләр иде. Берсе яшь, икенчесе олырак ике хатын аның янында туктады.

Яшьрәге, пышылдап кына:

— Абый, сезнеке ничәнче камерада утыра? — дип сорады.

Ләкин Мотаһир аңа ни дип әйтергә дә белмәде.

— Юк шул, үскәнем, мин кеше янына килмәдем, — диде.

...Конвойчылар район белән элемтәгә кергәннән соң, көчкә-көчкә мәсьәлә ачыкланды: дүрт-биш сәгать үткәч, караңгы төшкәндә, Мотаһирны кабул иттеләр.

Кичкә таба дежурный, төрмә капкасын ачып Мотаһирга кычкырды:

— Әй, Нәбиуллин, кер!

Мотаһир койма буйлап әкрен генә килде дә, әле нәрсәгәдер өмет тотып, суыктан карлыккан тавышы белән, тагын баягы сүзен кабатлады.

— Мин Нәбиуллин түгел, мин — Фарукшин.

Ләкин бу юлы аның сүзләре дежурныйга элеккечә тәэсир итмәде, киресенчә, ачуын гына чыгарды.

— Булмасаң — булырсың! — диде ул һәм, җиде катлы итеп сүгенеп алгач, Мотаһирны капкадан эчкә таба этеп үк җибәрде. — Марш! Синең белән күпме чиләнергә була, зараза?!

Дежурка бер катлы аерым бүлмәдә икән. Мотаһирны анда озак тотмадылар. Бераздан, яшел гимнастеркалы ике надзиратель ишегалдынаияр-

теп чыктылар һәм өч катлы төрмә бинасына алып керделәр. Тар, караңгырак, түшәме гөмбәзле коридор. Таш идәндә дагалы күн итек тавышлары яңгырап тора. Уртада надзиратель йөри. Ике якта да камералар тезелеп киткән.

Коридорга аяк басуга:

— Сулга борыл!— диде аны озата баручыларның арттагысы.

Таш баскычтан өченче катка күтәрелделәр.

Надзирательләрнең дагалы итек авазы баскычта да яңгырап чыга, ә Мотаһирның аяк тавышы бөтенләй ишетелми иде. Аның тыны кысылды, ул үз сулышын үзе тоймас булды.

...Калын стеналы таш бинаның өченче катындагы кечкенә камера. Тыштан келәле һәм йозаклы тимер ишек. Камераның түшәме тигез, биек. Аңа төрле киемдәге һәм кыяфәттәге егермеләп кеше шыплап тутырылган. Стена буйлап ике катлы нарлар тезелеп киткән. Камерада берөзлексез шау-шу, кычкырып сөйләшкән авазлар өзелми, тыгыз, тынчу һава, сөрсегән ис, ишек төбендә — параша. Рәшәткәле озын тар тәрәзә.

Җитмәсә, кешелеген бетереп дигәндәй, мыскыллап, Мотаһирның чалбарындагы төймәләренә хәтле кисеп алдылар.

— Энә тапсак — карцер,— дип кисәтте петлицасына ике өчпочмак беркетелгән явыз надзиратель.

Мотаһир әле карцерның ни икәнен анык белмәсә дә, армиядагы гауптвахта сыманрак урындыр, дип уйлады.

Кәгазь-каләм, чәч алу, кырыну да юк икән.

Мотаһир кешеләр белән тиз аралашучан иде. Шуңа күрә камерадагылар белән танышып та чыкты. Берничә кеше — үзе белән килгәннәр, районндашлары иде. Хәер, калганнары да шушы төбәктән чүпләнгән агай-энеләр.

Мотаһир, гәптәшләреннән аерылып, рәшәткәле тәрәзә янына килде, урамга күз салды. Каршыда ул күзәтеп торган матур өйле су колонкасы, арттарак чиркәү манарасы. Ә сулда бер катлы бихисап агач йортлар һәм... шуның белән аның дөньясы чикләнде. «Кояшсыз якка да эләккәнмен икән»,— дип куйды ул үз-үзенә. Аннары төрмә тирәсенә, аска карады:. Төрмә ике катлы койма белән әйләндереп алынган икән. Ә алар арасында эт йөри. «Моннан тоткын түгел, кош та очып чыга алмас», диде Мотаһир үзүзенә күңелсез генә.

Ә камера гөж килеп тора. Ул ятарга әмер булганчы шулай икән. Менә кич җитте. Параша янындагы сукыр ут та сүнде. Салам матрац, салам мендәр, бер кат юка одеал гына булса да, туңган-күшеккән, юл йөреп алҗыган кешегә ял итү өчен ярыйсы урын иде бу. Ләкин йокы алмый. Башта һаман уй: өйдәгеләр нишли икән?.. Күрәсең, бу уй беркайчан да, Мотаһир ирекккә чыкканчы, аны ташламастыр, җибәрмичә үзенә бәйләп тотардыр инде. Бәлки шушы уй аны чатнама суыкларда җылытып, өметсезлеккә бирелгән чакларда күңелен күтәреп, ач вакытларда җан азыгы булып торыр, гел озата йөрер. Бәлки Мотаһир бары шушы уйлары аркасында гына исән калыр — кирәк-кирәкмәс адым ясаудан тыелыр. Бик күп ялгышлар билгесезлектән, сине көтеп торучы, газиз кешеләрең юклыктан, синең кылган гамәлләреңне хөкем итеп торучы булмаудан ясала. Әгәр ата-ана, кардәшыру, авыл халкы алдында җаваплылык тою, бурычлы икәнеңне аңлау хисе булса, бик күп җинаятьләр эшләнми калыр иде. Кече яшьтән каныңа сеңгән тәүфикъ, әдәп кагыйдәләрен бозмаска тырышу — безнең халыкны һәркайда күркәм итеп күрсәтүче асыл сыйфатлар түгелме соң? Адәм баласы алдында һәрвакыт бер чик була. Шуны атлаганчы, ул уйлый. Әгәр уйларга өйрәткән булсалар, билгеле. Кеше өчен һәрчак бер-беренә капма-каршы булган ике очракның берсен сайлау мөмкинлеге була: эшләргәме бу эшне, юкмы? Ялгышлык-угрылык, азгынлык-явызлык — барысы да әнә шул дилемманы уңай якка хәл итә алмаудан килә. Ә бу исә — тәрбиягә бәйле. Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән керми, диләр бит. Мотаһир да, күп айлар, күп еллар буена шушы хакыйкатьне яхшы аңлап яшәде.

Ә шулай да бүген йокларга кирәк. Йокларга... Юк, күз йомылмый. Йомсаң да зиһен туктаусыз эшли. Башкалар да тыныч түгел, кайсыдыр борсалана, торып утыра, тагын ята, пышылдап кына сөйләшкән тавыш та ишетелеп куя, кемдер төшләнеп хатынына дәшә, берәүсе көлә, икенчесе елый...

Караңгы камера эченә тыштан ут яктысы төшә иде. Мотаһир, шыпырт кына торып, тәрәзәгә килде. Сул яктагы каланчадан якты бөркелә икән. Ерактагы караңгы бушлыкка беркавым карап торды да, ул янә килеп үз урынына ятты.

Коридорда әкрен генә йөргән надзирательнең аяк тавышы ишетелеп куйгалый. Ул озын коридор буйлап әрле-бирле йөренә. Кайвакыт адымнары тына. Күрәсең, берәр камераның «волчогыннан» эчкә күз саладыр. Аннары янә коридорны адымлый башлый...

Икенче көнне надзиратель камерага ят бер кешене алып керде. Күкрәктәй кара сакаллы, уртача буйлы бу кеше үзен бик иркен тотса да, ул да тоткын икән.

— Сезнең яшьрәкләрегез эшкә чыкмасмы?—диде ул ишек янында калып.

Аңа җавап кайтаручы булмады. Шуннан Мотаһир, як-ягына карап алды да, ятагыннан торып басты һәм тегеңә сорау бирде.

— Ничә кеше кирәк?

— Ничәү дә ярый.

Ятакларыннан торып, икенче каттагы нарлардан коелып, алар янына халык җыела башлады.

— Эше нинди?

— Кәрҗин үрәбез. Мин бригадир булам. Җәмүк атлы. Бондюг керәшене. Йә, кемнәр риза.

— Шарты нинди?

— Дүрт кәрҗин үрсәң, дүрт йөз грамм ипи, алтыны икән — алты йөз грамм.

— Ай-һай, алтыны булыр микән?—дип шик белдерде арадан берәү.

— Алты ишшу сиңа. Әле дүртесен диген...

Бригадир аңлатып бирүне кирәк тапты.

— Әйе, ул эш шактый четерекле. Болдырда айбагар чиртеп утыру түгел. Шулай да, теләсәгез — өйрәнерсез. Үзем күрсәтермен.

Тоткыннар үзара киңәш-табыш иттеләр, шаулашып алдылар. Кем шундук риза булды, кем бу эшкә шик белдерде, кем баш тартып ятагына атлады. Калганнары һаман гөман кылды.

— Монда сасыда утыру булмас.

— Тик торганчы, тун чабуын уа тор диген.

— Вакыт тизрәк үтәр ичмаса.

— Әз булса да теш арасына ризык керер.

Кич белән надзиратель һәм кара сакал яңадан керделәр дә эшләргә теләк белдергәннәрне алып чыгып киттеләр. Артта тимер ишек шартлап ябылды, ә алар ике ягында да камералар тезелеп киткән коридордан ары атладылар. Баскычтан икенче, аннары беренче катка төштеләр. Чөнки эш урыны төрмәдә үк, аскы катта гына икән.

Көймәле итеп өелгән, почмаклардан түгәрәкләнеп өскә менгән түшәмле, кешене изеп, басып торган шикелле калын диварлы бүлмәдән гыйбарәт иде бу камера. «Моны снаряд та, бомба да ала алмас», дип уйлап куйды Мотаһир. Яктыртылган зур камера ишегалды ягына караган. Бер почмакта көлтә-көлтә тал чыбыгы өелгән, икенче башта — әзер кәрзиннәр. Урындык-эскәмияләрдә берничә кеше бөкрәеп кәрзин үреп утыра.

Күрәк сакал, яңаларны буш урыннарга утыртты һәм озын-озакка сузмыйча өйрәтә дә башлады.

— Менә, карагыз, иң беренче нәүбәттә...

Авыл баласы кайда да югалып калмый, эшнең дә җаен тиз таба, күнегә. Мотаһир да тиз отып алды. Кулы ятып тора, эшен дә яратты. Нәзек чыбыклардан — су буенда үскән гап-гади таллардан — шундый да кәрзин үреп була

дип анын башына да кереп карамаган иде моңарчы. Гомумән, алар авылында кәрзин ише нәрсә үрү белән шөгыльләнүче юк иде. Каз ояларын, тизәк җыя торган чуманнарны каяндыр читтән, күрше район базарларыннан алып кайталар иде бугай. Бәлки аңа ярашлы таллар Мотаһирның туган авылы Түгәрәк Күлдә үсмәгәндер. Ә монда әнә күпме алар — теләгәнең сайлап ал. Һәм Мотаһир, шул нәзек тал-чыбыклардан үргән кәрзинне күтәреп, бөтереп-бөтереп карый, таш идәнгә куя, елмайгандай итә. Кемдер бу кәрзингә яшелчә-җимеш тутырып алып кайтыр, балаларын сөендерер... Әнә бит тоткасын ничек җайлы итәргә тырышты ул аның, хатын-кыз кулына эләгәсен белгәнгә ул аны шулай пөхтә итеп үрде. Билгеле, ул хатын моның кайда ясалуын, кем тарафыннан үрелүен белмәс тә, шулай да, миннән булсын яхшылык, дигәндәй, Мотаһир йөрәк җылысын салып эшләде. Эшләгәнең кеше өчен булса, өйрәнүең — үзең өчен, дияргә ярата иде атасы. Ә моның өчен тоткыннарга ипи, су да биреләчәк бит әле. Димәк, үзе өчен дә тырыша. Бүген төнлә бер кәрзин үрде — йөз грамм ипи биләләр. Кулы күнегә төшкәч, икене дә, өчне дә үрер.

Мотаһирның ябылуына бер атна тулганда, надзиратель алар камерасының тимер ишеген ачып:

— Нәбиуллин, чык! — дип кычкырды.

Камерада тынлык урнашты.

Мотаһир дәшмәгәч, надзиратель ачуланып, аңа карап җикерде.

— Сиңа әйтәм түгелме?!

— Мин Нәбиуллин түгел, — диде Мотаһир үҗәтләнеп. — Мин — Фарукшин!

— Не один ли хрен...

— Ә миңа барыбер түгел, — диде Мотаһир еларга житешеп. — Мин — Фарукшин!

— Сиңа килгәннәр иде. — Надзирательнең ирен читендә мыскыллы елмаю галәмәте чагылып үтте һәм шундук юкка чыкты. — Үзеңә үпкәлә. Кабат свиданка күрмәссең, контра недобитая!

Надзиратель авыр ишекне шартлатып япты һәм китеп тә барды.

Камера тын калды. Бераздан, Мотаһирның хәлен белгәнгә күрә, кайсыларыдыр аны хупплады, янәсе, дөрес иттең. Ә кемнәрдер, киресенчә, үгетләде, янәсе, аларга каршы торып булмый, чыгарга кирәк иде. Алар фикеренчә, язмыштан узмыш юк, теләсә теләмәсә дә бүгенге көне белән килешергә, аның янына ничәмә-ничә чакрымнар ерактан килеп, аны дүрт күз белән көткән якыннарының хәлен аңларга кирәк. Ә Мотаһирны хуплаучылар, кешенең кешелеген генә түгел, исем-фамилиясен дә юкка чыгарырга тырышалар икән, моның белән ризалашырга ярамый, әлбәттә, диделәр.

Ничек кенә булмасын, Мотаһир бу юлы чыкмады.

Ләкин көннәр, атналар узган саен ул үзенең көчсезлегенә, төрмә кануннарын төгәл үтәүче бу явыз бәндәләргә каршы тора алмаячагына инанды. Әгәр кабат дәшсәләр, килүченең каршысына йөгереп чыгачагын, язмышы белән килешәчәген, бу изү машинасына каршы торырлык көч тапмаячагын ул яхшы аңлады.

Тик көннәр, атналар гына түгел, айлар узды, ә аны очрашуга дәшүче булмады.

...Ул эшли, ашый, йоклый, тиешле күзәтү астында һава суларга чыга, үзенә йөкләтелгән бурыч-вазифаларны башкара. Менә шулай көн артыннан көн үтә. Үтүен үтә, әмма бик авыр үтә, бик озак үтә шул бу көннәр. Мотаһирны билгесезлек корты кимерә. Ул көн саен өеннән хәбәр көтә. Ә аңа бер хәбәр дә юк. «Авылдан килмиләр микәнни әллә? Килеп тә кертмиләр микән?..» Бу уйлар Мотаһирны һаман чыбыркылап-камчылап, йөрәген телеп, миен боргычлап тора.

Ә ул, мескен, авылдан берничә мәртәбә килүләрен, әмма аларга, биредә Фарукшин юк, дип җибәрүләрен каян белсен? Белмәде, билгеле.

Шулай итеп, фамилия буталу аркасында, Мотаһир аны күрергә килгән туган-тумача белән очрашу бәхетеннән дә мәхрүм калды. Милиционер акт төзегәндә аның фамилиясен, Мотаһир үзе әйткәнчә Фарукшин, дип язды бит. Сорау алганда да ул Фарукшин йөрде. Ә Алабугага озатканда исә аны Нәбиуллин дип язганнарын Мотаһир белми иде шул. Хөкем прокурор санкциясенә карап чыгарылган иде.

## VII

Мотаһир, йомшак табигатьле булгангамы (бәлки, монда аның медицина хезмәткәре булуы — теләсә кемгә, теләсә кайчан ярдәмгә килергә әзер торуы, гомумән, бер язмышка дучар ителгән кешеләрнең үзара бердәмлеккә омтылу теләге дә ярдәм иткәндер), кешеләр белән тиз уртак тел таба иде. Шуңа күрә аңа гел чит-ят кешеләр дә кайчагында ачылып китәләр, үзеннән олыраклары — киңәшләрен, үгет-нәсихәт бирәләр.

Тоткыннар арасында Тимершәех исемле, илленең аргы ягына чыккан гына булса да, чәче дә, сакалы да агарып беткән бер абзый бар иде. Дөньяны күп гизгән, утны-суны кичкән, беркемгә баш имәс, беркемнән курыкмас көчле-гайрәтле, Нократ елгасы буйларында туып үскән Мамадыш кешесе иде ул. Үзе ифрат нечкә күңелле — үлеп җыр ярата. Үзенең әллә ни тавышы булмаса да, гел җыр суза. Җырлары — тоткынлыкта узган гомер кебек озын, сагышлы була. Баш күтәрми кәрзин үргәндә төннәр буе көйләп чыга ул... Каян хәтерләп бетерә диген шулхәтле җырны.

Талдан тартма гына үрер идем,
Тал кабыгы гына суелса шул.
Туган анам кайтып күрер идем,
Җир астыннан гына юл булса...

Беркөнне, ялгыш пычак тиеп, Тимершәех абзыйның бармагы киселде. Туктаусыз кан агуын күреп алган Мотаһир шундук аның янына килде.

— Каяле, абзый кеше, күрсәт әле.

— Ярар ла,— дип кул селтәде теге.

Ләкин аның ничек тешен кысып түзүен һәм канның һаман агудан туктамавын күреп, Мотаһир, ай-ваена карамыйча, яраланган кулга үрелде. Җәрәхәте тирән, бармагы сөягенә хәтле киселгән иде.

Мотаһир башын күтәреп:

— Кая, берәрегездә кульъяулыгы юкмы?— дип тоткыннарга дәште.

Табылмады андый затлы нәрсә. Мотаһир тиз генә күлмәк итәген шытырдатып ертып алды да яраны бәйләде.

— Рәхмәт,— диде тоткын.

Шуннан бер-беренә сүз катып, якыннан танышып киттеләр. Абзый аңа гомер юлын, тәрҗемәи хәлен сөйләде. Тимершәех абзый бик тәфсилләп тасвирламаса да, аның язмышы кызыклы-мажаралы, гыйбрәтле икән, ул дөньяны шактый гизгән, аның килесендә шактый талкынган. Шуңа күрә, өлкән кеше сыйфатында, ул Мотаһирга киңәш-табыш итүне кирәк тапты.

— Энем,— диде ул җай гына сүз башлап,— өтермәнең үз законнары бар, беркемнән дә курыкма, беркемнән дә бернәрсә сорама, беркемгә дә ахыргача ышанма, дисәләр дә кеше үзе генә дә яши алмый. Үзең генә яшәү өчен җә бик гайрәтле, җә звир кебек усал булырга кирәк, ә син андый түгел. Шуңа күрә ялгыз гына берни кыра алмассың. Һәрчак таяныч кирәк адәм баласына, ныклы таяныч кирәк. Чын кешеләргә таян. Миннең төсен таныганчы, берәүнең атын бел, дигән борынгылар. Синең холкың әйбәт, ким-хур булмассың. Әйбәт дуслар табарсың. Ялгыз агачны җил сындыра...

Мотаһир, кәрзин үрүдән туктап, башын артка ташлап, сынын турайтты, кул аркасы белән билен ышкыды. Беравык дәшми торгач, боек кына әйтә куйды:

— Әй, Тимер агай, ялгыз нидә, күмәк ни — сындырдылар инде. Ничә атналар өйдән хәбәр алган юк, алар минем хәлне белми... Моннан чыгу да билгесез... Ни өчен утырганыңны белмә, имеш...

— Юк, егет,— диде Тимершәех абзый, башын селкеп.— Болай уйласаң, риза-бәхил түгел. Якасы юк тун булмас, закуны юк йорт булмас. Дөреслек табылыр... Бер килер хаклык. Ышанычыңны, өметеңне югалтма. Син яшь әле... Чирле кеше күбрәк чирдән түгел, рухы төшкәнгә үлә, диләр.

Мотаһир янындагы яшь бер егет аның сүзен бүлде.

— Яше нидә, карты ни, Тимершәех бабай, башка нужа төште инде.

— Кит сәнә,— диде Тимершәех абзый кулын селтәп һәм кинәт кет-келдәп көлеп җибәрде.— Һәй, егетләр, яшьлектәге нужа-нужамыни ул. Ул бит уйный-көлә дә уза.

— Узар сиңа,— диде егет моңсу гына.

— Уза, егет, уза. Ә менә безнеке... безнеке елый-сыктый теркелди.

Мотаһир надзиратель янына карап алды да, аннары, алдындагы кәрзинен үрә башлап:

— Барыбызныкы да бер инде,— диде.— Моннан иреккә чыккан кеше юк диләр. Тимершәех абзый, этап белән генә китәләр.

— Йә подвалда чәкиләр,— диде егет.

— Китсә сон, барыбер егет бул, энем,— диде Тимершәех абзый Мотаһирга.— Әле гомерең узганы, күлмәгең тузганы юк... Безнең шахтада унар ел утырып чыкканнар бар ие. Өйләнеп, йортлар салып, кешечә тормыш корып җибәрделәр. Алар әле ни явыз, ни өметсез бәндәләр ие. Барыбер игә килделәр. Яшәү яме бар бит, егетләр... Син бит угры түгел, бандит түгел... Мин үзем герман сугышында плен төшеп тә исән калдым...

Әйе, кайда да тормыш бара, тукталмый. Аерма шунда: төрле җирдә ул төрлечә агыла. Төрмәнең дә үз тормышы. Кеше дигәнең һәр нәрсәгә яраклаша, җаен эзли, хәйләсен таба. Кыскасы, яшәү өчен көрәш дәвам итә.

*

Бу төрмәдә суүткәргеч юк. Суны урамнан, каршыдагы колонкадан (ә, аңа үз агымы белән чишмәдән килә), җәй көне булса — арбага, кышын чанага җигелеп, алты кеше мичкә белән ташый. Суга чыгу өчен һәркем атлыгып тора: аз гына булса да ирек һавасы сулап керәсең. Өстәвенә, таныш-белешеңне дә очратуың ихтимал. Чөнки алагаем дәү мичкә утыртылган чана капкада пәйда булуга, төрмә тәрәзәләренең берсе шар ачып куела һәм аннан җыр ишетелә.

Җәйгә чыксам арба ла,
Кышка керсәм чана ла.
Бирәсе язуың булса,
Сучыларны чамала.

Бу — шартлы сигнал. Моны якын туганы төрмәдә утыручы һәм аның янына килүче һәркем белә. Беренче мәртәбә килүчегә аңлатып-төшендереп бирәләр. Ә төрмә тирәсендә халык өзелми: ябылганнарның ата-анасы, хатыннары, туганнары, хәтта бала-чагасы да сәгатьләр буе таптанып, өметләнеп читтән карап тора. Шартлы билгене — җырны алар көтеп кенә тора.

Килгән кеше кош теле хәтле генә язу кисәген (конвойның күзенә чалынмаслык итеп) колонка кырына кыстырып куя. Бу юлы булмаса, икенче юлы алырлар, ди. Шулай итеп, ике арада хат-язу йөри.

Бервакыт Мотаһир язу алышуның икенче ысулына тап булды. Алар камерасындагы бер- токкын үзенең паегын — чирәк өч йөз грамм ипине — әвәләп, йон туп ясаган кебегрәк итте дә, җан көченә тәрәзәдән урамга атты.

Мотаһирның мондый хикмәтне беренче күрүе иде.

— Бәй, нишли ул? Нигә ризыкны исраф итә?—дип сорады күршесеннән.

— Шаулама,—диде иптәше камера ишегенә ымлап.—Эченә кәгазь тыкты ул аның. Тышта хатыны булырга тиеш.

Мотаһир бу хикмәтнең асылына төшенде. Чыннан да, урамда торкынның хатыны бар икән. Ул, узып баручы бер хатынның баласын сорап торган, баланы юрган белән күтәргән, юлдагы ипигә җиткәч кенә юрганны төшереп җибәрә. Бала, билгеле, кулында кала. Иелеп юрганны алганда ипине дә эләктерә...

Мотаһир сөйләшү-аңлашуның да әмәлен күрде. Монысы аңа могҗиза булып тоелды. Алар камерасында баштанаяк кара киемле, буй-буй зәңгәр тельняшкалы матрос бар иде. Беркөнне Мотаһир, аны күреп, хәйран калды: теге бер яшел, бер кызыл чүпрәк кисәге тапкан да, кечкенә таякларга саплаган. Шуннан ул берәүне ишеккә арты белән бастырды, андагы күз—«волчок»ны каплады. Ә үзе тәрәзәне ачып куйды һәм, тәрәзә каршына басып, таяклы кулларын әле күтәреп төшереп як-якка җәеп, төрле мәзәк хәрәкәтләр ясый башлады. Соңрак моның да серенә төшенде Мотаһир: морякның хатыны килгән икән дә, каршыда, юлдан читкә басып, карап тора икән. Күрәсең, ул да серле хәрәкәтләрнең мәгънәсен аңлый булса кирәк, һәм алар, икесе ике корабның капитан күперчегендә баскан сигналчылар кебек, бер-бере белән сөйләшәләр. Хәер, сөйләшү бер яклы гына бара.

Менә шулай көн арты көн уза. Монда Мотаһирдан сорау алучы да, артык борчучы да булмады. Эшләгәннәр әлегә кала бирә, эшләмәгәннәрне этап белән җибәрә торалар. Мотаһир үзенең авылдашларыннан да бер-ике кешенең элегрәк моннан китүен белде. Районадашлары да аз калды. Киткәннәр урынына яңалар өстәлеп тора: соңгы көннәрдә зуррак түрәләр—олы урында эшләүче җитәкче работниклар килеп каба башлады. Яңа килгәннәрне, әгәр шулай әйтергә яраса, көтеп алалар. Чөнки иректән нинди дә булса хәбәр керә. Тамак хакына эшләп, кояш батканнан таң атканчыга бил бөкрәйтеп, күз чекрәйтеп кәрзин үреп утырган тоткыннар өчен яңалык ишетү—зур бер бәхет.

Бәхет дигәнең кайчак искәрмәстән дә килеп чыга. Мотаһирның ятак буенча күршесе, районадашы Әсхәдулла, беркөн тәрәзә янында торганда, кинәт, сабый баладай шатланып, кычкырып җибәрде:

— Әби!

Аның янына тоткыннар, шул исәптән, Мотаһир да килеп җитте.

— Әнә, урамда минем әби—хатынның анасы,—диде Әсхәдулла куанычыннан нишләргә белмичә өтәләнеп һәм, тәрәзәне ачып урамга кычкырды:

— Әби-и!

Мотаһир, өмет тулы күзләрен текәп, ашыгып, аннан сорады.

— Сиңа свиданка буламы?

— Юк, диде теге урамнан күзен алмыйча күңелсез генә.

Шуннан Мотаһир аның янына басты да, бар көченә кычкырып җибәрде.

— Тути-и, монда Түгәрәк Күлдән дә кеше бар! Түгәрәк Күл авылыннан!

Карчык ишетте, ахры, башы беленер-беленмәс кенә селкенгәндәй булды. Үзе һаман бу тарафка карап торды.

Әсхәдулла өзгәләнде, бәргәләнде, яшьле күзләрен урамнан алмады. Ул тәрәзә янында күпме торган булыр иде, билгесез, ишек шалтырап ачылуга, ялт кына урынына килеп сеңде.

Надзиратель кереп:

— Чего разорались?—дип бугаз киерде.—У-у, твари!

Аңа дәшүче булмады.

Шушы вакыйга Мотаһир өчен әйтеп бетергесез шатлык алып килде. Чөнки беркөнне, надзиратель кереп, аңа:

— Набиуллин, на выход!— дип кычкырды, аннары: — На свидание,— дип өстәде.

Мотаһир бер мәлгә каушап, телдән язды. Аяк буыннары йомшады, хәле китте. Үзендә, мин Нәбиуллин түгел, мин — Фарукшин, дип каршы торырлык көч таба алмады, күрешүгә чыгарга булды. Ничәмә айлар бер якыннан күрмичә, хат-хәбәрсез яшәгән кешенең хәлен аңлавы кыен түгелдер, шәт. Ул, исен җыеп, ашыга-кабалана ишеккә таба атлады. Артта аны нужадашлары өчен сөенгән сагышлы күзләр озата калды.

Аскы катка төшеп, төрмә бинасыннан ук чыктылар. Капка яныннан, эчтән үтеп, лапас шикелле корылма-конторга керделәр. Мотаһирдан соң ук тагын бер тоткын килде. Бераз ара калдырып, икесен дә идәннән түшәмгә кадәр сузылган тимер челтәргә йөз белән бастырдылар. Каршыда, ике метр чамасы ераклык тагын карават сетка кебек вак челтәр тартылган. Аның артында ике хатын басып тора. Берсе — аның Мөсәмирәсе! Ятьмәгә эләккән балык кебек бәргәләнеп, тилмереп, челтәр аша гына булса да кадерле йөзне күрү — нинди бәхет! Ул килгән, аның хатыны, Мөсәмирәсе килгән! Аны эзләп, сагынып килгән.

Ул җыйнакланып калган шикелле, каратут йөзе сулган, агарган, элеккегә караганда озынчарак сыман. Әмма күзләре... күзләре элеккечә аңа яратып, үз итеп, сөеп карыйлар. Бәлки Мотаһирның үзгә кыяфәтен күреп бераз куркыгандыр, ләкин ул халәт тиз үтте шикелле. Шул ук кара, сызылып киткән кашлар, шәлъяулык астыннан чак кына күренеп торучы чем кара чәчләр. Никадәр якын барысы да, нихәтле газиз! Йә, хода, ничек сагынылган бу кадерле җан! Атна-айлар гына түгел, дистә еллар күрми торган шикелле... Карап күзләр туймас, сөйләп сүзләр бетмәс...

Иң кирәклесен, иң мөһимен әйтеп өлгерергә кирәк тә бит, биш минут эчендә ничек исеңне җыясы, ничек барысын да хәтереңдә тотасы... Ә телгә юк-бар сүзләр генә килә.

— Ничек таптың?

— Ничә килсәм дә, юк, юк, диләр.

— Бу юлы?

— Район базарында Якты Таудан бер карчык безнең авылдан кемнәр ябылуын сораштырып йөргән. Аңа әйткәннәр син икәнне. Шуннан, миңа кайтып хәбәр иттеләр.

Мотаһир тел очындагы соравын, ниһаять, сак кына бирде. Чөнки аның курыкканы, бар шикләнгәне — начар хәбәр ишетү иде. Мөсәмирә өчен бу инде узылган чор, бәлки шуңа да ул аңа әһәмият бирмәгәндер, үзе башлап әйтмәгәндер. Ә Мотаһир... моны уйлап күпме йокысыз төннәр үткәрде бит.

— Исән-имин котылдыңмы?

— Ие. Малай.

Менә ул бәхет, менә ул сөенеч! Моны инде бернинди төрмәләр дә, тимер рәшәткәләр дә кыса, тыеп тора алмый. Аның икенче малае бар!

— Менә рәхмәт, менә рәхмәт...

Ул әле һаман авызын җыя алмый, шатлык яшьләрен йотып җибәрә алмый.

— Исемен ничек куштың соң?

— Син әйткәнне инде.

— Әсләфме?

— Ие.

Мотаһирның күзләре дымланды, хатынының, шулкадәр якынының кулын сыйпыйсы, олы рәхмәтен белдерәсе килде. Ләкин ара ерак... Хәер, ул бик якын да, тик... ерак та. Арада тимер рәшәткә, берәү генә дә түгел... Шатлыктан зиһене томаланып, исен җыя алмыйча, сүз дәшәрлек хәле булмады. Бераздан, үзен кулга алып, беренче тәэсирләрдән айнып, кавышу-күрешүнең бары биш минут кына икәнен искәреп:

— Әгъдәс улым ниш̧ләп йөри?— дип сорады.

— Исән-сау. Сине бик сагына.

— Энесен карыймы соң?

— Карый, бик ярата. Мин бәбәйләгән көнне, минем энем бар, дип урамнан үткән һәр кешегә мактанып йөргән.

— Сабый, бигрәк сөенгән икән.

Аннары Мотаһир әти-әнисе, туганнары хакында сораштырды. Әмма хатыны җиткергән бәхетле яңалыктан соң башка сүзләр ничектер кирәк тә түгел шикелле иде. Икесенең дә күңелләрен биләп алган куанычтан соң сүзсез генә аңлашу кирәк иде: янәшә утырып, иңне иңгә терәп, бер-береңә сыенып, алга өметләр баглап... Ләкин... вакыт кыса, сәгать бара...

Әнә ике арадагы надзиратель сәгатенә карап-карап ала.

— Тагын кайчан килим?— диде Мөсәмирә, иреннән күзен алмыйча.— Абыйлар да белеп кайтырга кушты.

— Үзем ничек тә хәбәр бирермен әле.

— Ни алып килим?

— Борчылма, берни дә кирәк түгел. Тамак тук. Эшлим бит.

— Кием-салым?

— Хафаланма, яме, берүк борчылмаска тырыш. Сиңа болай да авыр бит. Әтиләрне...

Шулчак надзирательнең зәһәр тавышы яңгырады:

— Очрашу тәмам!

Бер-беренә омтылган карашлар, тән-гәүдәләр, кара-каршы йөгереп барырга, атлап кына китәргә әзер аяклар барын белми микәнни бу бәндә?! Тагын бер генә, ярты гына минут...

— Мотаһир...

— Мөсәмирә... Хуш, сөеклем! Сау бул. Бетеренмә. Мин кайтырмын...

Өмет тулы карашлар! Наз тулы күзләр! Сез аерылыр өчен, сагыш өчен яратылганмыни?! Сез бит бер-берегезне иркәләр өчен яратылган. Нигә сезне — бер җан, бер тән булып өлгергән һәм инде ике сабыйга тормыш бүләк иткән, әле тагын да ничә гомерләргә дөньяда яшәү рәхәте бирәсе кешеләрне — аерырга? Ни өчен сезгә бер түбә астында пар күгәрченнәрдәй гөрләшеп яшәргә (кызыл туйда шундый теләк теләгәннәр иде бит!) мөмкинлек бирмиләр? Нигә аларның нарасыйларын ярым үксез итәләр? Нигә? Йә, кемгә кирәк булды сезне аеру, икегезне ике ярга кагу? Какты, нык какты аларны тормыш дулкыны. Талкыды. һай талкыды аларны рәхимсез ачы җилләр! Әгәр алар икәве бергә яшәсә, игелекле эшләре белән ил-көнгә файда китерсә, кемгә ни зыян иде? Ике баланы ничек баксын бәләкәй генә шушы хатын? Ничек тормыш алып барсын? Балалар авызыннан өзеп алып килгән ризыклар ничек Мотаһирның тамагыннан үтсен? Их син, язмыш...

Мотаһир, надзиратель тарафыннан урталай ярып тикшерелгән ике түгәрәк ипине кулына тотып, авыр адымнар белән бер тарафка юл ала, ә хатыны икенче якка...

Мотаһир сак астында үз камерасына үтте. Ул кергәч, тимер ишек шартлап ябылды, бикләнде.

Мотаһир тәрәзәгә капланды. Йөрәге ашкынудан атылып чыгардай булып тибә, ярсый... Әнә, әнә аның бәгырь кисәге урамга чыккан. Капка каршында аптырап басып тора. Күрәсең, ничәмә-ничә көннәр, атналар, айлар көтеп алган очрашуның болай тиз бетүенә, тагын аерылышуларына ул әле ышанып җитмидер, исен җыя алмыйдыр. Иренең, газиз балаларының аталарының тагын таш капчыкта — биек койма, чәнечкеле тимер чыбык артында зинданда калуына, читлектәге кош кебек ирексез булуына ул әле һаман ышанып җитмидер...

Мотаһир аңа кул изи, янәсе, бар инде. Хатыны, аңладым, дигәнне белдереп, баш селки. Ә үзенең аяклары атламый, гүя ләпеккә ябышкан. Ул аларны мәҗбүри рәвештә диярлек хәрәкәткә китерә, кузгала, ян белән бара. Никадәр авырдыр газиз иреннән аерылып китүче хатынга... Дошман булган бәндәләргә дә күрсәтмәсен мондый язмышны!.. Отыры ерагая Мөсәмирә, отыры кечерәя бара...

...Мотаһир йөзтүбән капланды. Кемгә дә булса сиздермәскә тырышып, ике бала атасы үксеп елый иде. Аның йодрыклары йомарланган, дерелди, ә

гәүдәсе калтырана... Нишләп бу минутларда аңа кушылып бөтен төрмә бинасы калтыранмый икән? Нигә аның калын диварлары чатнап-ярылып ишелеп төшми дә, андагы барча хокуксызлар ирекә чыкмый икән? Ни өчен караңгы Себер урманнарын, Төньякның салкын тундраларын чорнап алган төрмә-лагерьлар тоткыннарның ачы каһәре белән җир йөзеннән себереп түгелми икән? Әгәр алар очлы тешләрен ырҗайтып, туймас тамаклы авызларын ачып тормаса, Мотаһир үз авылына, гаиләсе, ике йөрәк парәсе, үзен тапкан, багып үстергән газиз анасы янына кайтыр иде. И-и, ходаем, нинди каргышлар төште икән аның башына? «И ходаем, сабырлыклар бир,— дип пышылдый Мотаһир һәм, әнисеннән ишеткәннәр күңеленә килеп, шуларны кабатлый.— Адәм алларында рисвайлар итмә. И ходаем...» Аның мие кайный, тамагы кибә, теле чатный...

Шулчак камерада кемдер җыр суза!

> Әнкәй мине тапкачтын ла
> Ак биләүгә биләгән.
> Ак биләүләргә биләгән,—
> Бәхете булсын димәгән.

Мотаһир, шашынып, сикереп торды, тавыш килгән якка атылды. Шыңшып утырган яшь бер егетне изүеннән эләктереп алды.

— Син нәрсә анаңны каргап утырасың, ә? Нигә аны каргыйсың? Кайсы ана үз баласына бәхет теләми? Әйт, синекеме, минекеме? Әнә аларныкымы? Әйт!

— Җибәр.

— Юк андый ана җир йөзендә, юк!

— Кем соң минем бәхетемә балта чапкан? Кем? Кем? Әйт белсәң, әүлия? Кем мине болай каһәрләгән?

Егет тә, нәкъ бая Мотаһир кебек, йөзен каплап, илереп нарга ауды.

Мотаһир, айнygандай, үз-үзен болай тотышына аптырап китте. Нервылар какшый башлаган түгелме? Аның ни хакы бар кешегә болай каты бәрелергә? Җыр бит ул. Мескен, аптыраганнан җырлыйдыр. Ул да тоткын бит, аның да җаны уйныйдыр. Ул да читлектәге кош...

Бу хәлне читтән генә күзәткән Тимершаех абзый, Мотаһир янына килеп:

— Син, энем, яңадан тора салып кешенең якасына ябышма,— диде.— Ярамый алай, ярамый, энем.

— Аңладым, абый, хата эшләгәнемне үзем дә аңладым.

Мотаһир, кабат теге егет янына барып, җилкәсенә кагылды.

— Рәнҗемә, яме. Үзем дә сизми калдым нишләгәнемне.

Егет дәшмәде, килешкәндәй, кул аркасы белән күз яшен сөртте.

Бераздан Мотаһир, ипиләрен сындырып, ятагына тезеп куйды, тоткыннарга дәште.

— Килегез, егетләр, житешегез. Барыгыз да килегез, гафил булып калмагыз.

Берәм-берәм аның янына җыелдылар.

Бер абзый, элекке мулла, үгет-нәсихәт бирә:

— Бисмиллагызны әйтеп ашагыз, оланнар.

— И, ашы күп булса, бисмилласыз да үтә ул.

Карт бирешми.

— Кит, имансыз. Әстәгъфирулла диген.

— Ярар, шаярттым гына.

Берәү дә өлешсез калмады. Күңеле канәгать Мотаһир үзе дә авыз тутырып «куян калачы»н ашарга кереште.

— Ярый әле сез бар, егетләр, кайгы-хәсрәтне бүлешергә,— диде ул.

Әмма май аенда Мотаһирга Алабуга белән дә, мондагы танышлары белән дә саубуллашырга туры килде. Язмыш аны өеннән, туган җиреннән һаман саен ераккарак тибәрергә, җир читенә олактырырга уйлый иде ахрысы.

Урамнар кибеп, кыш көне шыксыз күренгән бакчалар яшеллеккә төренеп, алмагачлар, чияләр шау чәчәккә күмелгән бер мәлдә байтак тоткыннарга, шул исәптән Мотаһирга да әмер килде: җыенырга! Менә шунда тәүге кат аңа чын-дөреслекне, ачы хакыйкатьне ачып салдылар һәм беренче тапкыр бөтен фаҗигасе белән ул үзенең хәлен аңлады.

— НКВД «өчлеге»нең 1937 ел, 31 декабрь карары белән сез 58 статья буенча хөкем ителгәнсез. Сезгә — ун ел ирегегездән мәхрүм итү җәзасы...

Мотаһирның өстенә гүя бер чиләк бозлы су тондырдылар!

— ...билгеләнгән. Шуны аңлаганыңа кул куй.

Аның күз аллары караңгыланды, башы әйләнеп китте. Әйтерсең, урамнан, койма буеннан барганда, искәрмәстән башына күсәк белән ордылар. Ул күрсәтелгән урынны кармалап, хәлсез бармаклары белән имзасын салды. Бермәлгә бөтен барлыгын битарафлык чорнап алды. Ләкин тора-бара зиһене ачылды һәм йөрәге сулкылдап тибә башлады. Ун ел... ун ел... дөп-дөп... әйтерсең колак төбендә трактор дөпелдәп эшләп утыра... ун ел... дөп-дөп... Әнә, аңа эндәшәләр түгелме?

— Кузгал!

Әйе, аңа икән шул. Димәк, китәргә кирәк.

— Следующий!

Димәк, үзе шикелле тагын бер бәхетсезенә, аны да кара кайгыга батыру өчен, юл сабарга кирәк. Кешеләрне изәргә, сытарга көйләнгән коточкыч машинаның, берөзлексез әйләнеп торган алагаем зур, авыр тимер тәгәрмәченең тешләренә корбан кирәк.

Исерек кешедәй алпан-тилпән атлап, Мотаһир бүлмәдән чыкты. Калганы томан эчендә, аңсыз рәвештә эшләнде: саубуллашу, изге теләкләр, кайгы уртаклашу.

Тимершәех абзый:

— Ярый, ныный, исән йөреп, илеңә сау кайт, — диде.

— Сиңа да шундый ук изге теләкләр юлдаш булсын, Тимер агай. Бәлки әле җибәрмәсләр дә...

— Әй, ныный, тәтемәс инде безгә андый бәхет. Аерырлар туган илкәйдән... китәр башлар...

Һәркемдә бер кайгы: илдән аерылу. Әйе, илдән аерылу. Бу төшенчәгә бик күп нәрсә сыя, барысы да шул бер сүзгә төйнәлгән. Читен, бик читен кешегә туган-үскән туфрагыннан аерылу. Әмма башны ташка орып булмый, «китәргә булгач китәргә, китми ни хәл итәргә». Исән кеше барыбер яшәүгә йөз тота, иртәгесе көннең бүгенгедән яктырак булуына өметләнә, гәрчә, ул өмет ерактагы йолдыз кебек беленер-беленмәс кенә булса да, юлыңны яктыртмаса да, тәнеңне җылытмаса да... Әйе, өмете өзелмәгәннәрнең җаны суынмый, рухы сынмый.

Сафка тезелгән кырык кеше, сак астында Алабуга урамыннан атлый. Ничә айлар тынчу, сасы төрмәдә ябылуда ятканнан соң урам һавасын сулап, чит-ят урыннарга багып баруы, хәлләре ничек кенә мөшкел булмасын, ярыйсы иде. Әнә, Тойма елгасында көймәләр йөзә, яшьләр чыр-чу килә. Ак таш түшәлгән, ике якта да сай гына канаулы киң, үзәк урамга чыккач, үзгәрешләр ныграк сизелә башлады. Монда йортлар да икешәр-өчәр катлы, кибетләр, парикмахерский һәм башка нәрсәләр күзгә ташлана, сирәк кенә тарантас җилдерүче, арба тартып баручы атлар, агач әрҗәле «полуторка» машиналары очрый. Урамның ике ягында да өрәңге, юкә агачлары утыртылган, тәрәзә йөзлекләре, кыеклары бизәкләп эшләнгән зур, якты тәрәзәле өйләр язгы кояшка елмаеп тора. Тыз-быз халык йөри. Күтәрелеп карасаң, чалкан авып китәрсең — чиркәү манаралары шулхәтле биек. «Юк, безнең мәчет манаралары болай ук биек түгел иде», — дип куйды Мотаһир. Челтәрле тимер рәшәткәләр, биек таш коймалар, бизәкле авыр капкалар — барысы да монда эшлекле һәм мул тормышлы сәүдәгәрләр рәхәт чиккәнен әйтеп тора.

Алда, сул якта, киңлек ачылды: анда Тойма белән Кама кушылган, су җәелеп шәһәргә якын ук килгән. Ә каршыда, ерактагы текә тау башында, Шайтан шәһәрчегенең ак гөмбәзе пәйда булды. Әби патша юлы дип йөртелгән, ике ягына да тупыллар утыртылган киң таш юлдан кичүгә киттеләр.

Ярты ел төрмәдә утыру дәверендә Мотаһир шактый нык үзгәрде. Ул ябыкты, йөзе агарды, гәүдәсе хәлсезләнде. Киеме дә үзгә аның: гимнастерка өстеннән пинжәк кигән, галифе бриджи чалбар һәм кирзә итек. Биштәр капчыгында киндер кожан бар. Йөрүдән бизгән аяклары тиз арыды. Ләкин пристаньга күп калмаган иде инде. Шушы авылны гына узасы.

Подмонастырская авылының йортлары, дамбаның сул ягындагылары, су уртасында утыралар. Тәрәзәне ач та суга сикер. Ә арырак баржалар тора. Су шулкадәр күп, мул, тагын әз генә күтәрелсә, дамба өстенә үк менәр төсле. Кичүгә барып җиткәнче Мотаһир берничә мәртәбә артына борылып карады. Гомеренең күпмедер өлеше өзелеп калган шәһәрдә чиркәүләр һәм педучилищеның кызыл бинасы гына аермачык күренә иде.

Кичү тирәсендә халык чуар: ир-ат, хатын-кыз, бала-чага, яше-карты, татары-урысы... Ләкин ник кенә бер таныш йөз очрасын. Мотаһир шулай дип уйлап бетерүгә, кемдер аның исемен әйтте түгелме соң?

— Мотаһир!

Ул ялт борылып карады. И, нинди шатлык, нинди сөенеч: ике авылдашы! Алар, сак астындагы кешеләргә якын килергә базмыйча, читтәрәк басып торалар иде.

— Авылдашлар, исәнлекме? Сәхау, ни хәл? Нургата, сау гынамы?

— Аллага шөкер,— диде Мотаһир белән бер урамда уйнап үскән какча йөзле, тәбәнәк буйлы Сәхау.

Аның йөзендә куаныч та, авылдашын бу хәлдә күрүдән туган кызгану хисе дә һәм ни белән дә ярдәм итә алмавыннан гаҗизләнү дә чагылган иде. Ләкин, ни генә булмасын, авылдашын исән-имин күрү аңа да, Нургатага да күңелле иде.

Озын буйлы Нургата, батыраеп, тоткыннар сафына якын ук килде.

— Әй, Мотаһир, сез китәсезмени инде?— диде ул уфтанып.

Шунда ук конвойчыларның берсе килеп җитте.

— Кая? Ну-ка читкәрәк! Кемгә әйтәләр?!

Нургата бер-ике адым гына артка чикте, ерак китмәде. Моннан файдаланып, Мотаһир авылдашларының кая юл тотулары, өйдән кайчан чыгулары хакында сорашты. Әмма болар гомерләрен зимагурлыкта дигәндәй, читтә эшләп уздыручы егетләр булганга, авылдагы хәлләрдән бихәбәр иделәр. Әле дә шахтадан кайтып килүләре икән. Казаннан Пермьгә менүче пароходтан төшкәннәр. Мотаһир, өзгәләнеп, үзенең хәлен бер-ике сүз белән генә аңлатты. Ун ел дигән сүзне ишеткәч, авылдашлары икесе берьюлы аһ иттеләр.

— Бигрәк күп икән шул,— диде Сәхау башын чайкап.

Тирегә сеңгән шахта тузаныннан битендә вак кына зәңгәр төрткеләр беленеп торган Нургата да:

— Ай-яй!— дип куйды.

— Мөсәмирәгә кереп әйт, күрше, ямe,— диде Мотаһир Сәхауга.— Аны бер генә күреп калдым, хәбәр итә алмадым...

Ул арада «Москва» пароходы икенче гудогын кычкыртты. Яр буендагы базардан ризык алырга төшкән пассажирларын чакыра башлады.

Сәхау кабаланып, куен кесәсенә тыгылды да аннан акча чыгарды.

— Мотаһир, мә ал әле моны, кирәге чыгар.

Моны күреп торган конвойчы, зәңгәр түбәле фуражкасын кыңгыр салган яшь егет, аларга якын ук килеп, кырыс кына:

— Акча бирәсегез булса, миңа тапшырыгыз,— диде.

Тегеләр карышып тормадылар, икесе дә (Нургата да бумажнигын чыгарган икән) кулларын аңа суздылар. Конвойчы егет акчаларны алып, әйләндереп карады да:

— Ярар, үзем тапшырырмын,— дип кулын кесәсенә шудырды.

— Рәхмәт, энем,— диде Нургата һәм Мотаһирга дәште.— Сау бул, авылдаш.

Сәхау да хушлашты һәм алар пароходка таба йөгерделәр.

Алар утырганы китүгә, икенче бер иске пароход, шапыр-шопыр көпчәген әйләндереп, бер катлы, такта түбәле пристаньга килеп сарылды. Бераздан тоткыннар аның койрыгына кереп урнаштылар.

...Шап-шоп, шап-шоп... Әйләнә дә әйләнә көпчәк һәм һәр әйләнеш Мотаһирны биек, текә ярлы пристаньнан отыры ерагайта. Кичү кечерәйгәннән-кечерәя бара. Өстеңә ишелергә торган текә яр да, киң ябалдашлы наратлар да читкәрәк чүгә һәм пароход Кама уртасына чыга.

Талгын гына аккан киң елга, чинап-чыелдап очкан акчарлаклар, зәп-зәңгәр күк йөзе... Бу хәтле хозурлык бүтән чакта исертер дәрәҗәдә бөтен барлыгын биләп ала иде Мотаһирның. Бу манзара һәрвакыт тыелгысыз бер рәхәтлек кичертә иде бит. Ә бүген күңеле төшенке. Ниемә шатланасың? Ни куанычың бар? Юк бит, юк. Тагын юлга... Тагын ачлы-туклы тормыш вәгъдә итүче ерак сәфәр. Алда ни күрәселәре бардыр? Аның уйларын белгәндәй, кемдер ишетелер-ишетелмәс кенә шыңшый:

Безнең дә лә авыл — әй зур авыл,
Кыйблалардан килә жил-давыл;
Соңрак та ла бәхеткәйләр булыр,
Әле бүгенгесе бик авыр.

Әйе, авыр. Мотаһирга да авыр. Бик авыр. Авыр... авыр... авыр... Суга карап тәкрарлап бара торгач, кылт итеп исенә төште Мотаһирның: авылда кисәткәннәр иде бит аны...

...Җәй көне. Мотаһир капка төбендә утыра. Аның аягына уралып диярлек эт белән мәче мәш килә. Шулчак аның янына озын гәүдәле, таза тәнле яшьтәше Зәһлүл килде. Хром итектән, күлмәк җиңен сызганып куйган, башта — артка тибәргән кепка.

— Исәнме, Мотаһир.

— Исәнгереп утырам, яшьти,— диде Мотаһир көлеп.— Кая барыш?

— Синең янга килеш.

— Утыр алайса. Ни хәлләр бар?

— Хәлләр дип... ашауга карап инде,— диде Зәһлүл һәм тигез тешләрен күрсәтеп елмайды.— Үзең беләсең...

Бик әйбәт белә Мотаһир Зәһлүл яшьтәшен: ашауга да, эшкә дә батыр, авыл мәйданында да, район җыенында да теләсә кемгә бил бирә торганнардан түгел.

Зәһлүл, чигүле янчык чыгарып, тәмәке көйрәтеп җибәрде. Бераз вакыт тегесен-монысын сөйләшеп утырдылар. Шуннан Мотаһир:

— Берәр йомышың бар идеме әллә?— дип сорады.

— Әйе,— диде Зәһлүл җитди итеп һәм тәмәке төпчеген сүндерде дә, җиргә ташлап, аңа күн итеге белән басты.— Бая син минем хәлне сораштың. Минем ярыйсы да...

— Нәрсә бар?— диде Мотаһир аңа карады, сагая калды. Чөнки Зәһлүл шактый дөнья гизгән, шомарган егет, юкка-барга гына кайгырмас. Димәк, эш җитди. Шулай булып чыкты да.

— Мотаһир, синең турыда идарәдә сүз йөри.

— Нинди сүз?

— Мин дежур торганда авыл советы рәисе, район вәкиле, колхоз председателе, завхоз һәм бригадир сөйләшеп тордылар. Синең ревкомиссия председателе икәнеңне, күп нәрсәгә тыкшынуыңны әйттеләр. Син, Мотаһир, яхшы чакта чыгып сыз.

— Кая?

— Кая дип... беткәнмени? Шахтага ычкын. Адрес бирәм.

— Болай тора салып кына...

— Чынлап әйтәм. Алар әшәке сөйләшә. Тай моннан. Замана тыныч түгел.

— Анысын беләм дә... Соң минем бит гаилә бар. Аннан килеп, паспорт та юк. Ансыз...

— Минем икс паспорт. Берсен бирәм.

Мотаһир аптырашта калды. Беравык тын торды. Ә дусты аңа караган, чын йөрәктән теләктәшлек белдерә. Мотаһир, төпле бер карарга килеп:

— Әй, алла язмаган эш булмас,— диде.— Китмим.

...Пароход артында агарып, бытырдап күбекләнгән су эзенә текәлгән Мотаһир фикер йөртте: «Әгәр Зәһлүл сүзен тыңлап, читкә киткән булсам?... Кем белә инде аны. Хәзер үкенеп ни файда?»

Мотаһирның уйлары чияләнгән, очына чыгарлык кына түгел. Иртәгә ни язган!.. Өендә ни уйлыйлар икән инде? Сәхау кереп әйтер, билгеле. Шуннан барысы да ачыкланыр. Өйне кайгы басар...

Мотаһирның уйларына Сәхау килеп кергәч, йөрәген нидер тырнап үткәндәй булды. Сәхау — аның күршесе, яшьтәше генә түгел, заманында көндәше дә иде бит. Әйе, Сәхау Мөсәмирәне озаткалап йөрде. Ләкин аларга кавышу насыйп булмады. Ул, гадәтенчә, янә шахтага киткәч, Мотаһир аулак өйдә Мөсәмирәгә сүз катты һәм бераздан алар туй иттеләр. Кайткач дәгъвалап та йөрде Сәхау. Шуннан аның белән аралар суынып, юллар аерылган иде. Тагын очраштылар. Тагын аерылыштылар. Ләкин бу юлы Мотаһир ун елга төрмәгә китә, ә Сәхау — туган авылына. Анда аның әти-әнисе, туганнары һәм Мөсәмирә. Мотаһир үз-үзен тиргәп, мондый көнчел, ямьсез уйларны куып җибәрергә теләп, күзләрен йомды. Бераздан ул сискәнеп китте. Аңа дәшәләр икән.

— Әллә мәрткә киттеңме?

— Уйга талганмын.

— Булыр,— диде тоткын.— Шулай да күп уйлама. Уй кешене бетерә...

— Нәрсә бар?— диде Мотаһир өнәмичә генә.

— Мотаһир, сиңа бая пристаньда акча бирделәр...

— Әйе. Конвойда ул.

— Бар, сора. Аннары... син аны саклама.

— Нигә?

— Белгән кешеләр әйтә: Казанда тиененә хәтле алып бетерәләр икән.

— Нишләтим соң? Ашауга тотыймы?

— Шулай ит. Теге охран егетнең үзенә дә өлеш чыгарырбыз. Теләгән әйберсеңне алып килер.

Беркатлы Мотаһир, тоткыннарны аралап, фуражкасын кыңгыр салган конвойчыга табарак күченде.

— Гражданин начальник, акча...— дип авыз ачуы булды, тегенең күзләре шарланды.

— Нинди акча?

— Бая миңа авылдашлар биргән иде...

— Минем ни эшем бар синең акчаңда? Биргәннәр икән, кесәңдәдер!

— Юк, ул сездә бит.

— Син нәрсә, падла?! Кайчан миңа акча бирдең? Ә? Кайчан? Кем күрде? Юк! Пошел вон! Контра недобитая!

## IX

Казан Татар халкының, кайда гына яшәсә дә, олысы-кечесенең карашы төбәлгән, мәдәният учагы булган мәркәз, изге, нурлы йорт. Әле узган җәй генә, июнь-август айларында Мотаһир анда хәрби осталыгын, белемен арттыруда булган иде. Аларга күп нәрсәләр өйрәттеләр, күрсәттеләр, сөйләделәр. Арада хәтергә иң нык уелып калганы — Тухачевский, Якир, Гамарниклар турында, аларны «халык дошманы» дип атаулары. Төрлесе төрле төбәктән җыелган кече командирлар, тын да алмыйча, өлкәннәр сүзен

тыңлап, алар сөйләгәнне хуплап тордылар... Менә хәзер ул да халык дошманы. Кем уйлаган? Кем уйлаган...

Узган җәй Мотаһир Казанга «Красная звезда»да килгән иде. Зур, иркен пароходта кешечә ял итеп. Монысы да ике палубалы, юан торбалы, иске булса да чиста үзе. Тик... ирек кенә юк.

Язлыкта җәелгән су Бишбалта урамының кырый йортына хәтле килеп җитә иде, шунлыктан пристаньне Якын Тамакка куялар. Ә су чиккәч, ул Ерак Тамакка күчерелә.

Мотаһир утырган «Вера Засулич» пароходы, Маркиз утравы яныннан үткәч, тизлеген киметте һәм әле генә кузгалып киткән «Короленко» урынына, дебаркадерга килеп терәлде. Өстән командалар яңгырады һәм тельняшкалы, кара бушлатлы житез матрослар аны арканлап та куйдылар.

Түбәсе калай белән ябулы, ике катлы такта дебаркадер буш, бер генә кеше дә юк иде. Чөнки тоткыннарны яр буенда көтеп торган конвойчылар, этләрен ияртеп, пристаньга ук кереп басканнар, барча халыкны куып чыгарганнар.

Менә тоткыннар агыла башлады. Тиз-тиз яр буенда сафка тезелделәр. Кабат санап чыккач, аларга кузгалырга әмер булды.

— Шагом-марш!

Уңда бер, ике катлы агач йортлар, мәчет һәм чиркәү манаралары белән Бишбалта бистәсе татлы йокыдан уянып җитә алмыйча ята иде.

Пристань тирәсендә, иртә булуга карамастан, кер ат җиккән арбада аякларын салындырып утыручы түбәтәйле йөкчеләр, хәрбиләр, елга хезмәткәрләре күренә: чабаталы авыл агайлары, күн итек яки туфли кигән шәһәр кешеләре — юлаучылар күзгә чалына.

Ипи, сыра, аракы лареклары, кибет һәм ашханәләр яныннан үттеләр. Мотаһир, моннан ерак түгел, лареклар артында базар барын да яхшы хәтерли. Ләкин җәелеп уйланырга, алан-йолан каранырга түгел, тын алырга да ирек бирмиләр — гел ашыктыралар. Әмма күзе бар кеше бернәрсәгә дә битараф түгел, ул барын да хәтеренә салып бара.

Әнә, йортның капка төбенә ак күлмәкле, ияк астына китереп бәйләгән, бөтен аркасын каплап торган ак яулыклы бер карчык чыгып килә. Этләр, коралы сакчылар белән уратылган тоткыннар сафын күргәч, авыз эченнән генә ходай тәгаләне искә төшереп, тизрәк кире чигенде. Ә кыска чәчле, чуар ситсы күлмәкле, аягына ак оекбаш һәм калын киндер өсте гадәттә теш порошогы белән агартыла торган барретка кигән бер кыз эшкә ашыга иде, күрәсең, Мотаһирлар ягына бер генә карап алды да, юлын дәвам итте. Мондый хәлләр аңа күптән таныштыр, мөгаен.

Каршыда аркылы чыгу урыны, стрелочник өе һәм күтәрмә киртә. Сулда Казан-су елгасы ага, су Иван Грозный баскыннары истәлегенә корылган һәйкәл артыннан борылып Бишбалтага, биек күпер астына кереп югала. Ә һәйкәл артында, еракта, чал Кремль, очлы башын күккә төбәгән мәһабәт Сөембикә манарасы әле генә таралган томан эченнән калкып чыга. Уңда болын-күлләр җәелеп ята.

Дамба буйлап биек тупыл һәм юкә агачлары тезелешеп киткән. Дамбадан байтак баргач, дүрт тәрәзәле кирпеч йортка тап булдылар.

Колонна тирәсендә иртәнге тынлыкны яңгыратып овчаркалар һаулап ала, әледән-әле кискен команда авазлары ишетелә:

— Сөйләшмәскә!

— Артка калма!

— Җыела төш!

— Җәһәтрәк! Ананны...

Авызга алмаслык әшәке сүз белән аслы-өсле сүгенү, тоткыннарга карата рәхимсезлек, төрмәгә якынлашкан саен бермә-бер артты. «Эт оясында көчле шул», — дип уйлап куйды Мотаһир.

Дивар артында берни, аларны тыярдай беркем күренми. Әнә алда, стенага терәп үк салынган калай түбәле тәбәнәк, тәрәзәсез бина. Әллә шулмы? Юк, бу бик бәләкәй икән, койма-фәләне дә юк. Ә сулда иске шәһәрнең та-

гын бер өлеше — чиркәүләре, төрле-төрле йортлары, агачлары-бакчалары белән тау битендә яткан өлеше. Тоткыннар юлы стена буйлап янә уңга шуыша. Йөрәккә дә шом, зәһәр елан кебек шуышып керә, тәндә акрынлап кан туктый сыман. Хәлсез тоткыннар мышный-мышный, уңга таба калкулыкка күтәрелделәр.

Кремль стенасына сыенып ук утырган таш бина һәр яктан дүрт-биш метрлы ике катлы биек койма, чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган, почмакларда — каланча, ә аларда солдатлар.

Тоткыннарны проходной аркылы үткәрделәр. Ишегалдында бер як коймадан икенчесенә тимерчыбык сузылган, аңа бүре кадәр эт бәйләнгән.

Алты ай Алабуга зинданында яткан Мотаһир өчен болар ят түгел инде. Ике катлы, ә йорт астына эшләнгән капка турысында өч катлы төрмә бинасы кукыраеп калкып торса да, Кремль стенасыннан тәбәнәк, аңа терәп тә салынмаган икән. Беренче катның арт стенасы яртылаш җиргә күмелгән, ахры.

Йорт астындагы авыр капка шыгырдап ачылды, өсте гөмбәзле коридордан тугыз-ун адым баргач, тоткыннар калын тактадан эшләнгән тагын бер капканы үттеләр дә, төрмәнең бәләкәй генә, озынча тар ишегалдына керделәр. Төрмә бинасы дүрт почмаклы итеп эшләнгән икән. Тагын алар өчен кояш сүнде (гәрчә май кояшы һәр тарафка нурын тигез сипсә дә), әле генә иркен, хозур дөнья таш дивարлар белән кысылды, төрмә кануннарына буйсынды.

— Тукта!

Төрмә ишегалдында тавыш яңгырап, бермә-бер катырак булып ишетелде.

— Напра-во!

Мотаһир шаккатты: дүрт якта да, ике рәт булып шакмаклы, кечкенә тәрәзәләр тезелеп киткән, алар алдына козырек шикелле итеп такта куелган. Бу — тоткыннар ишегалдындагы кешене, ишегалдына кергәне, аларны күрә алмасын өчен шулай эшләнгән. Камерага яктылык өстән генә төшә икән. «И мескеннәр, ни гонаһлары бар икән аларның? Барысы да минем шикелле гаепсез микән? Кемнәр икән анда?..» Әмма озак уйланырга ирек куймадылар — кабул итү, камерага ябар алдыннан тентү-тикшерү башланды.

Бирелә Мотаһирны иң нык кимсеткәне, җанын кыерлаганы тентү булды. Кулга алынганнан бирле ул бу хәлгә бер генә юлыкмады, күнегелгән дип әйтергә мөмкин. Ләкин мондагысы...

— Төшер чалбарыңны!

Ике түш кесәле гимнастеркасын киң каеш белән буып, сул иңеннән портупея аскан сержант Мотаһир каршына баскан. Зур козыреклы, кызыл билле зәңгәр фуражкасын батырып кигән һәм зәһәр күзләрен тоткынга төбәгән.

— Нәрсә бәбәгеңне терәдең? Ишетмәдеңмени?

Гимнастерка якасында петлицасы да күзләре төсендә — зәңгәр икән. Мотаһир, мәрхәмәт көткәндәй, шул күзләргә төбәлде.

— Ишеттем дә...

Сержантның йөзе петлицадагы алсу сызык кебек кызарып чыкты. Уң кулы наган кобурасына үрелде.

— Ну!

Мотаһир тартынып кына чалбарын төшерде.

Тагын да шәфкатьсезрәк команда яңгырады.

— Иел!

Моның берничә кабат төргә дә сыймый торган, кешене түбәнсетә, рәнҗетә, хурландыра торган команда иде. Ләкин... Мотаһир аңа да буйсынды. Күе зәңгәр төстәге галифе чалбар, озын кунычлы күн итекләр Мотаһир янәшәсеннән үтеп, артына чыкты.

— ...тишегеңне ачып күрсәт!

«Ходаваңдә!» — дип кенә әйтә алды һушы-акылы киткән Мотаһир.

— Тизрәк бул, сволочь! Нәрсә кызлар кебек ялындырасың? Ике кулың белән...

Кайчандыр Екатерина Икенче указы белән, стена эченә беләк юанлыгы тимер рәшәткә тыгып калдырып махсус төзелгән бу төрмәнең кысан камерасында ач килеш, мыжгып торган халык, бет арасында бер төн кунуы — гомеренә онытылмаслык булып хәтеренә сеңеп, йөрәгенә җәрәхәт ясап калдырды Мотаһирның. Андагы гаделсезлек, андагы пычраклык — кеше әйтеп кеше ышанмас. Даһи юлбашчының, төрмә — төрмә булырга тиеш, дигән сүзләренең асылына ул шунда төшенде. Ярый әле бу мәшхәрдә озак ятарга туры килмәде аңарга. Уголовниклар белән дә бутамадылар. Чөнки, «илле сигезләр» үзләре күп, камерада, нар өстендә нар булган кебек, кеше өстендә кеше иде. Шулай булса да, уголовникларның ниләр кыланганын ишетеп чәчләре үрә торгач, аерым ябылуга барысы да сөенде.

Икенче көнне, кичке күлемдә, төрмә ишегалдына сафларга тезеп, барлап, аларны тагын алып киттеләр. Биек тимер капка ачылуга Мотаһир җиңел сулап куйды. «Иншалла, моннан котылам икән».

Төрмәнең бу як капкасы төбендә дә, нәкъ кичәге кебек, туганнары, таныш-белешләре янына килүчеләр тилмереп тора. Күзләрендә сагыш, сорау, өмет, хәсрәт, билгесезлектән гаҗизләнү... Аларга берничек тә булыша алмый шул Мотаһир. Хәлләрен җиңеләйтә алмый. Якыннарының кайдалыгын әйтә алмый...

Кремль стенасы буйлап өскә күтәрелделәр. Спасс башнясы яныннан үтеп, таш җәйгән юлдан түбән төштеләр. Казанның тыкрык-урамнарыннан лаштыр-лоштыр аякларын сөйрәп, бертуктаусыз атладылар. Тагын аларны зәңгәр фуражка, яшел гимнастерка, киң каеш буган, урам ташына шык-шык дагалары тиеп китүче кирза итекле, кораллы конвойчылар озата барды. Алар урам иңләп баручы тоткыннарны этләр белән уратып алганнар, берсен дә күздән ычкындырмыйлар. Колоннага портупеялы көяз һәм усал НКВД «егетләре» җитәкчелек итә иде. Трамвайлар, сирәк-мирәк узган йөк һәм җиңел машиналар шау-шуы астында, урамда тыз-быз йөргән халыкның сагаюлы күз карашын тоеп, алар баралар да баралар. Кая баралар, кайчанга чаклы — моны аңлатып-төшендереп бирүче юк.

Бу юлы этапны, кичәгедән берничә мәртәбә артыграк тоткыннарны, тимер юл вокзалының озын кызыл бинасы янына китереп туктаттылар, чүгәләттеләр һәм, озак та үтми, санап-барлап, товар вагоннарына төяделәр. Вагондагы кырык кешенең һәрберсенә коры паек биреп чыктылар: балык, ипи. Бөтен вагонга бер чиләк су кертеп утырттылар. Кем кая, ничек булдыра ала, шулай урнаштылар.

— Иншалла, мәхшәрдән котылдык бугай,— диде Мотаһир янындагы берәү сузылып ятып.— Монда хет интектерүче булмас.

Төнлә состав кузгалды.

Билгесезлектән гаҗиз булган борчулы, кыбырсык сораулар яуды, гоман кылу башланды. Күбесендә бер сорау:

— Кая барабыз икән?

Бер белдеклесе әйтеп куя:

— Төньякка, мөгаен.

Икенчесе шиген белдерә:

— Каян беләсең? Бәлки, Себергәдер?

Мотаһир һәм аның ише сала мужиклары дәшми. Чөнки монда шәһәр агайлары бар. Алар алданрак күрә, акыл белән эш итә, дөресрәк фараз кыла. Мутлыкка да алар остарак. Әнә берәү төне буе пычак (каян юнәткән диген!) очы белән вагон тактасын тишеп азапланды.

Иртәнчәк ул:

— Без Кировка таба барабыз,— диде.

Сакчылар, тоткыннарны төягәнче, вагонның һәр төшен карап-тикшереп чыкканнар иде. Вагонга кереп утыручы булмады. Кырык кеше арасында бер генә уголовный җинаятьче дә юк, барысы да илле сигезенче статьялар. Монысына Мотаһир янә сөенде. Чөнки Казан төрмәсендә бер төн куну, алар

турында ишетү — тегеләрнең кем икәнен бөтен вәхшилеге белән ачып салган иде. Шулай да Мотаһир өчен тагын бер борчулы ягы бар иде бу китүнең: чөнки райондашларыннан түгел, хәтта Алабугада бергә утырганнардан да таныш-белешләре юк иде.

...Поезд көн вә төн бара. Станцияләрдә шалтырап-дөбердәп туктап та ала. Иртәнчәк сасы, тынчу вагон ишеге чак кына ачылуга, тоткыннар штыклы мылтык аскан, эт җитәкләгән сакчыларга ялвара башлыйлар.

— Су бирегез! Су бирегез! Су...

Конвойчы миһырбаны килсә, чиләк белән су китерә, коры паек өләшә, ипи һәм кипкән балык...

Бер чиләк су күз ачып йомганчы юкка чыкты. Мотаһир, буш кружкасын тоткан хәлдә, аптырап, нәүмиз булып калган берничә тоткынга карады.

— Нәрсә тукталдың? — диде аңа берсе.

— Бетте бит.

— Тагын сорарга кирәк.

Мотаһир китеп баручы солдатка эндәште.

— Иптәш!

Солдат борылып карады:

— Брянск урманнарындагы соры бүре сиңа иптәш.

— Гафу итегез, гражданин начальник, су кирәк ие.

— Кемгә?

— Миңа һәм тагын өч кешегә.

— Җитмәдемени?

— Әйе.

— Прокурор өстәр, көт, — дип шаркылдап көлде солдат һәм китеп барды.

Берничә тоткын өлешсез калганнар белән үз суын бүлеште.

Тозлы балык ашаганнан соң эчәсе килүнең чиге-чамасы юк: Мотаһирның күзләре начар күрә башлады, колагы саңгырауланды, теле аңкавына ябышып, сүз әйтә алмас хәлгә җитте...

...Тагын ишекләр томалана. Бераздан вагон тартылып куя да тәгәрмәчләр шык-шык рельсларга бәрелә, вагонның тынчу һавасы җилләнә. Кемдер гырлап йоклый, кемдер төшләнеп саташа, кемдер биштәр капчыгын актарып, калдык-постык сохариен чыгара, кемдер шатыр-шотыр кашына... Гаиләсеннән, яраткан эшеннән аерылган бәхетсез җаннар — товар вагонының пычрак идәнендә ауный... Сугымга алып баручы маллар кебек.

Мотаһирның кисәк кенә исенә төшә: авылда, берәрсе кемгә дә булса бик нык ачуланса, әй дошман, дип әйтә торган гадәт бар. Менә хәзер ул да дошман. Ләкин, авылда әйтелгәнчә, юрамалый гына түгел. Шулай итеп, бу яман кушамат аңа гомергә тагылыр микәнни? Һәм ул, беренче мәртәбә үз язмышының гына түгел, ә гаиләсенең дә, туганнарының да никадәр аянычлы хәлгә дучар булуын аңлады. Шушы яман кушаматка дәлилләп каршы тора алмаудан, үзенең көчсезлегеннән кимсенеп яшәргә мәҗбүр ителү һәм шуның аркасында йөрәге талану — менә аңа гомер буена җитәрлек хафа салган нәрсә... Вагон тәгәрмәченең рельска шык-шык бәрелүе дә хәзер аңа «дош-ман, дош-ман» булып ишетелә. Колагыңны томаласаң да бер үк сүзләр кабатлана: дош-ман, дош-ман... һәм Мотаһир шуңа ялгап җибәрә: «Кем-гә дош-ман?»

Кировка җиткәнче дә, аннан соң да, Мотаһир, күпләр сыман, «тәрәзә»гә үрелмәде. Юк, кемдер аңа ирек бирмәүдән түгел. Ул яктан мондагы халык — тоткыннар — бер-беренә миһырбанлы. Нәрсәсен карыйсың? Табигатенме? Кайтыр юлыңны билгеләп барасыңмы? Әле беркем белми кая барасын. Беркем белми кайчан кайтасын. Һәм, гомумән, кем — кайта, кем — юк. Бәлки... Ул турыда уйлыйсы килми. Өметне өзәсе килми. Алабугада Тимершәех абзый әйткәннәр искә төшә: «Ышанычыңны, өметеңне югалтма. Син яшь әле...»

Әйе, аңа нибары утыз ике яшь. Әле яшисе дә яшисе, балалар үстерәсе... Кая баруын белмәсә дә, кайтуына өмет баглап яшәргә кирәк.

Берзаман, состав туктагач, тишектән карап баручы егет:
— Киров дип язылган,— диде.
Димәк, кая баруы да ачыкланды. Кировта озак юанмыйча, состав кузгалып та китте. Әлеге дә баягы, «тәрәзәгә» кунаклаган егет, ни сөенмичә, ни көенмичә, әйтеп куйды:
— Котласка барабыз икән.
Сорашу-белешү китте.
— Ул нинди җир тагын?
— Себер ягымы?
— Безне кая олактыралар икән?
Боларның борчулы сорауларына бер хәрби кеше җавап бирде:
— Төньякка. Димәк, йә шахтага, йә урман кисәргә.
— Алай икән,— дип куйды бер татар агай.— Шахтасын күргән бар-барын. Урманы ниндидер, анысын әйтә алмыйм.
Шуннан сүз иярә сүз китә, тоткыннар сабыр гына гәп коралар. Бик күп хәлләр, вакыйгалар телгә алына, истәлекләр, мәзәкләр сөйләнә, хәтта вагон селкетерлек булып шаркылдап көлгән авазлар да яңгырый. Кая барса да, нинди хәлгә тарыса да адәм баласы күңел кояшын сакларга тырыша.
Сакчы да уяу: тоткыннар артык шаулаша башласа, мылтык түтәсе белән вагон тактасын төяргә тотына. Янә авазлар тына, колаклар сагая, чама хисен саклау зарурлыгы бердән исләренә төшә.

## X

Аларның составы станциягә барып җиткәнче үк туктады, вагон ишекләре ачылды. Саф, салкынча һава керде. Саран гына булса да кояш яктырта, карасу болытлар түбәнтен генә йөзә. Тоткыннар бер-бер артлы сикереп төшә дә сафка баса. Тирә-якны кораллы солдатлар һәм усал этләр урап алган.
Солдатлар ашыктыра:
— Давай быстрее! Давай!
Чөнки аларның тоткыннарны тизрәк кулдан-кулга тапшырасылары килә. Конвойчыларның өлкәне, санап-барлап чыккач:
— Бер адым янга, бер адым артка атлау — качарга маташу!— диде.— Кисәтеп-нитеп тормыйча атачакбыз! Ишетсен колагыгыз!
Алда, еракта, шәһәр күренә, артта һәм уңда — урман, сул якта — бихисап күп палаткалар. Бераздан тоткыннарны шунда — пересыльный пунктка китерделәр. Ул Кече Двина елгасы буена урнашкан иде. Елганың үзен Мотаһир күрмәде. Чөнки бирге яр биек, текә. Әргы яр сөзәк һәм таллар-агачлар белән капланган. Күз күреме җитәрлек арада ике-өч авыл шәйләнә. Якындагысының чиркәү гөмбәзе кояшта ялтырый.
Пересыльный пункт белән янәшә озын-озын агач складлар тезелеп киткән. Ә алар артында, шактый еракта, чиркәүләре һәм бер-ике катлы агач йортлары белән Котлас шәһәре күренә иде.
Пересыльный пункт үзе исә бер-бер артлы һәм рәт-рәт тезелеп киткән палаткалары белән шәһәр урамнарын хәтерләтә. Тик аерма шунда: чәнечкеле тимер чыбык — палатка — чәнечкеле тимер чыбык — кораллы сакчы — чәнечкеле тимер чыбык — палатка... Һәрберсенә йөзәр кеше сыешлы, ике катлы, ягъни җылытылган палаткалар урам-урам тезелеп киткән...
— Кемнәр генә юктыр монда, нинди генә бичаралар үз язмышының кай якка юл аласын көтеп ятмыйдыр?— диде Мотаһир белән янәшә атлаган бер агай төшенке күңел белән.
— Әйе,— дип аңа җавап кайтарды икенчесе алга таба күз салып.
Мотаһир да, бирегә килеп төшкәч (әллә элегрәк тә микән?), үзенең язмыш колы икәнен яхшы аңлады. Кая алып китәрләр, нинди җиргә килеп эләгерләр? Һәркемне шул сорау борчый иде.

...Тоткыннарны күп төрле сораулар борчыса да, пересыльный пунктта аларның үзләрен борчучы булмады. Көненә ике мәртәбә зур калай бачок белән аш кертәләр. Калай котелогы яки башка савыты булганнар шунда ук бүлеп ала, ашый, ә савытсызлар тегеләрдән бушаганын көтеп тора... Аннары палаткада ауныйлар. Чыгып йөрергә рөхсәт юк.

Ниһаять, егерме дүрт көннән соң, аларга да чират житте. Тагын этап әзерләү ыгы-зыгысы башланды. Исемлек буенча тикшереп, унар кешене бер рәткә, алга таба каратып, утырттылар-чүгәләттеләр. Командалар яңгырады:

— Кычкырып сөйләшмәскә! Кузгалмаска!

«Ни-нәрсә сөйләшәсең инде,— дип куйды Мотаһир үзалдына, чөнки якын-тирәдә бер генә таныш чырай да юк иде.— Кузгалып кая барасың?»

Әйе, беркая һәм берничек тә китә алмыйсың: ике якта да этләр, коралллы солдатлар, читтәрәк пулемет көпшәләре сафка төбәлгән. Мең кешегә якын тоткын алар алдында тез чүккән.

Шулай көтеп утырганда, ике офицер ияртеп, юан гәүдәле олы чинлы бер хәрби кеше — начальник пәйда булды. Петлицасында дүрт ромба. «Дивизия командирына тиң икән бу»,— дип уйлады Мотаһир.

Һәр яңалык күпмедер вакытка игътибарны ала, үз кайгыларыңны, язмышыңны оныттыра. Шунлыктан тоткын бер генә яңа кешегә дә, бер генә вакыйгага да битараф калмый, эчке бер тоемлау белән моңа үзенең дә катнашы булачагын теге яки бу якка хәле үзгәрәчәген сиземли. Әкренләп Мотаһир да шуңа өйрәнә башлады. Әгәр лагерьга, төрмәгә яки камерага берәр яңа кеше, чит кеше килеп керә икән, синең язмышың да аңа бәйләнгән булуы мөмкин. Тоткын фараз кыла башлый: бу бәндәдән миңа файда булырмы, әллә зыян килерме? Күпчелек вакыт бу күрәзәчелек дөрескә чыга.

Әлеге хәрби кеше дә «ярты гәүдәле» сафлар каршындагы үзеннән түбән чиннарның бер-икесен ияртеп, вахта-проходнойга кереп китте. Монда ыгы-зыгы, хәрәкәт тукталды. Бераздан алар чыктылар. Сафлар җанланып алды: кыска гәүдәләр селкенде, башлар боргаланды, күзләр сөйләште. Мотаһирның фараз кылуы дөрескә чыкты: биш йөзләп кешене кире алдылар — икенче якка таба каратып утырттылар.

Соңыннан, бик күп айлар, еллар узгач та, Мотаһир язмышының шушы кешегә бәйле булуы, исән калу-калмавы да шушы кешенең бер сүзеннән торуы хакында уйланды: хәер, язмышында андый борылышлар бер генә булмады бит. Кыскасы, сафларның алгы өлеше бер якка, икенчесе — бүтән тарафка барырга тиеш булып чыкты.

Ахырда беленде: Мотаһирлар төркеме Кулойлагка караган Мокеев утравына, тегеләр — Ухта-Печорлаг карамагына китәргә тиеш икән.

Узмыйча интектергән озын көннең (чөнки ак төннәр башланган иде) ахырында, кичке уннар тирәсендә, аларны алып киттеләр. Ач, хәлсез тоткыннар лаштыр-лоштыр тузанлы юлдан атлый. Сул якта тимер юл ияреп бара. Яр буйлап тезелгән зур-зур, озын-озын он складлары да, эскерт-эскерт бүрәнә-агач өемнәре — Болтинская лесобаза биләмәләре дә әкрен-әкрен артка чүкте. Бераздан Котлас шәһәренә килеп керделәр.

Бер-ике катлы зур агач өйләр, юл кырында такта тротуарлар, биек манара очында алтын тәресе ялтырап торган чиркәү, салмак кына атлатып яки тузан туздырып, юыртып үтүче атлылар, тоткыннарга кайсыдыр шикләнеп, беришле жәлләп караучы кешеләр — барысы да кала. Монда халык та үзенчәрәк икән: хатын-кызлар күбесе сары чәчле, зәңгәр күзле, уртача буйлы, тулы гәүдәле, ирләр нык бәдәнле, сары яки бакыр чәчле, җирән сакаллы, муеннарына тәре такканнар.

Озак та үтмәде, уң якта ике катлы озын бина — тимер юл вокзалы һәм аның артында уфылдап үтеп баручы паровоз күренде. Ләкин тоткыннар сулга борылды. Ниһаять, су буена, пристаньга килеп җиттеләр. Әмер бирелде:

— Тукта!

Аста, су буенда, бер катлы такта пристань. Янында берничә такта сарай. Берсенә аркаларына махсус җайланма аскан йөк бушатучылар баржадан капчык ташый. «Алабугада да шулай иде»,— дип куйды Мотаһир. Баржадан

яр буена сузылган киң такталар таза егетләр узганда сыгылып-сыгылып кала.

Пристаньнан сул якта, бер читтә, ярга елышкан сал җәйрәп ята. Су өстендә коңгырт вак дулкыннар хасил була: бата-калка бер агачмы яисә бүрәнә башымы ага.

Менә нинди икән ул Төньяк Двина елгасы! Хәер, монысы әле аның Кече Двина дип атала. Котластан түбән Вычегда елгасы белән кушылгач кына ул Төньяк Двинага әйләнә. Ләкин тоткыннар аны белми. Алар өчен ул — Төньяк Двина. Ә ул ашыга-ашыга төньякка ага. Мул сулы, шактый киң елга. Ичмаса, туйганчы иркен һавасын сулап калырга кирәк.

— Әнә, ике башында будкалы баржа тора, мөгаен, безнең өчендер,— дип әйтә куйды янәшәдә баскан тоткын.

— Шундыйга охшаган,— диде Мотаһир аның белән килешеп.

Дөресен генә әйткәндә, аның әллә ни сөйләшәсе дә килми. Елга да нигәдер моңсу. Су өсте каралып тора — талларның күләгәсе төшә. Елганың бу ягы һәм урта өлеше якты, аксыл. Дулкын булмаса да, су өсте җанлы — берөзлексез селкенеп, уйнаклап тора — тоткыннар җаны кебек...

Нишләптер тоткыннарны әле һаман кузгатмыйлар. Ниндидер тоткарлык чыкты, ахрысы. Әллә иртә килгәннәр. Ничә көннәр беркая чыкмыйча ябылуда, тынчу палаткада яткан Мотаһир монда, яр буенда озак торуга уфтанмады. Ни дисәң дә, чагыштырмача иркендә торасың бит. Тик басып тор кугып кергәнче. Кара, күзәт, хәтереңә сеңдер дөнья киңлеген...

Күк йөзе сыек зәңгәр, сулда карасу болытлар куерып килә, кояш турында, өстәрәк, аксыллары да күп. «Болары — өмет чаткылары кебек»,— дип уйлый Мотаһир.

Яр өстендә, уң якка таба, бер-ике катлы агач йортлар тезелеп киткән. Артта, тимер юл вокзалы ягыннан, әледән-әле паровоз тавышлары ишетелә. Якында гына тоткыннарны озата килүче этләр өргәли, конвойчыларның кискен команда тавышлары яңгырый.

Елга өстендә, теге як ярда, балыкчы көймәләре күренә. Елга уртасында ак маяк — ак җилкән кебек. Әмма ул көймә кебек йөзеп бармый, тукталган. «Без дә шушында туктасак?— дип уйлап алды Мотаһир.— Юк, китәбез шул».

Аның янындагы бер тоткын, Мотаһирның уйларын белгәндәй, тел шартлатып, әйтеп куйды:

— Кара, нинди матур җир!

— Әйе,— диде Мотаһир һәм, уфтанып, өстәде.— Иректәге кешеләргә рәхәтләнеп яшәргә була. Ризык та җитәрлектер монда...

Бу як ярда, еракта, бер балыкчы кармак салып утыра, вакыт-вакыт кармак сабын күтәреп ала да, тагын суга ташлый. Әйләнә-тирә тын. Түгәрәк яшел яфраклы әрекмән, сарут, кара әрем (барсы да таныш!) исе килә, талгын җил белән су дымы борынга бәрелә.

Ниһаять, кояш таллар артына төшеп поскан, әмма кызгылт-шәмәхә шәүләсе әле бетмәгән һәм караңгы да иңмәгән бер мәлдә тоткыннарга кузгалырга команда булды.

— Аска, баржага, шагом-арш!

Агач баскычтан түбән төшә башладылар. Ар яктагы таллар артында әле генә күренеп торган авыллар да, таулар да юкка чыкты. Дөнья тарайды...

Мул, коңгырт-карасу төстәрәк сулы елга өстендә аларны баржа көтеп тора. Янына аннан дүрт-биш мәртәбә кечерәк буксир сыенган. Биек, текә ярлар каршында адәм балалары гына түгел, баржа-пароходлар да кечерәеп калгандай тоела. «Язмыш алдында без дә шулай...» Салдан аерылган ялгыз агач-бүрәнәләрне караңгы чырайлы елга, тоткыннарны йөрткән язмыш кебек, теләсә кая алып китә. Алар күндәм генә ага бирәләр. «Мин дә ялгыз, син дә ялгыз,— дип уйлап куйды Мотаһир сыңар бүрәнәгә карап.— Син дә кая барып бәреләсеңне, кай як ярга килеп төртеләсеңне белмисең. Мин дә белмим: уңгамы, сулгамы, әллә диңгезгә үк чыгабызмы? Бу озын көннәрне ничек уздырырсың? Гадәтләнмәгән поляр көннәр миңа алда ни әзерли? Иле

башка, җире бүтән... Монда сулар да үргә — төньякка ага бит. Алар салкын, төсләре кара. Алар да салкын якка теләмичә агадыр, шуңа йөзләре караңгы, суы җанны куыра торган... Иле ямьсез, суы тәмсез, өйгә кайтасым килә...»

Тар басмадан бая Мотаһир фараз кылган баржага күтәрелделәр. Люк-тан-баскычтан трюмга төштеләр. Трюмның тәлинкә хәтле генә түгәрәк тәрәзәләре бар. Ләкин алар өстә, буй җитәрлек, үрелеп карарлык түгел. Алар бая судан да шактый биектә иде. Әмма тоткыннар кереп тулгач, тәрәзәләр суга җитәр-җитмәс калды.

Сакчылар ике люкны да шартлатып ябып, бикләп куйдылар. Тоткыннар идәнгә чүгәләде: ни утырырга, ни ятарга җай юк иде. Шыплап тутырылган трюмның һавасы шундук бозылды — тынчу, арык күкрәкләр кысыла башлады.

## XI

Бер тәүлек узды. Әмма люклар ачылмады, тоткыннарга эндәшүче булмады. Кайберәүләр ачлыктан, һава җитмәүдән аңын югалта башлады — башлары салынып төште.

Моны күреп, Мотаһир торып басты да калын тавыш белән сөрән салды:

— Нишләп безгә ашарга-эчәргә бирмиләр? Бу ни эш?

Һәм ул гайрәтләнеп, тоткыннарның аякларына баса-баса ерып килде дә, текә баскычтан бер-ике басма күтәрелеп, башын артка ташлап, зур йодрыгы белән люк капкачын төяргә тотынды.

Күтәреп кенә люк ачылды. Сакчы, сул кулы белән фуражкасын тотып, иелә төште.

— Нәрсә бар? — дип сорады ул. — Нигә дөбердәтәсең?

— Ашарга бирегез! — диде ачуы басылмаган Мотаһир: — Су өстендә барабыз, ә эчәргә су юк.

Шулвакыт баскыч тирәсендәге берничә тоткын да астан аваз салды:

— Су! Ипи!

— Шулаймы? Су кирәкме? — диде сакчы Мотаһирга һәм янына килеп баскан икенчесенә күз кысты: — Бирикме?

Моңарчы күренмәгән икенче сакчы тоткынга чыгарга ым какты.

— Мен!

Тоткынның башы люктан күренүгә, сакчы дагалы күн итеге белән тибеп җибәрде. Икенче мәртәбәсенә өлгерә алмый калды: Мотаһир тимер баскычтан дөбердәп аска тәгәрәгән иде.

Кабат ризасызлык белдерүче булмады. Куна-төнә, отыры салкынаая барган су өстеннән, иртә-кич төшкән томан эченнән, көндезен саран нурлы кояш астыннан, күрер күзгә үк сөзәкләнә барган чит ярлар, кыргый урманнар буйлап озын юл үткәч, бервакыт баржа сулга борыла башлады һәм, әйләнеп, агымга каршы, дебаркадерга килеп терәлде. Берөзлексез агылган болытлар һавада асылынып калды, кырыс Двина бермәлгә агуыннан туктагандай булды. Тоткыннар тагын бер билгесезлек капкасына килеп бәрелделәр. Йөрәкләре бер мизгелгә туктап торгандай булды. Хәлсез аяклар хәлсез гәүдәләрне кыймылдатырга ымсынып карады. Ләкин кешеләрнең аңнары гына түгел, аларның саннары да фәрманга өйрәнә башлаган иде инде. Ниһаять, люк ачылды, тагын команда яңгырады.

— Баржадан чыгарга!

— Тезелергә!

Кемнеңдер аяклары бу боерыкка буйсынмый — аңа күршесе ярдәм кулын суза. Бер кул гына торгыза алмаса, икенче якта да миһырбанлысы табыла.

Чыгуын чыгарга да, ә кай төш соң бу? Кем белә? Көн якты булса да, әле аңышып җитмиләр. Кая килеп тап булуларын белмиләр иде. Тоткыннар арасында, әле берсенә, әле икенчесенә кагылып үтә-үтә, сораулар йөри:

— Бу кайсы төш?

— Безне кая китерделәр?
— Озакка тукталабызмы?
Һәм бераздан барысы да ачыкланды: алар килеп туктаган җир елга яры түгел икән, ә Мокеев утравы — иңе бер чакрым, буе — өч. Чәнечкеле тимер чыбык булмаса да, билгеле бер ара калдырып, каланчалар кукыраеп утыра.
Көне-төне чайкалып килгән башларны сафландырырга, оешкан аякларны, катыда корышкан гәүдәләрне язып алырга мөмкинлек тууына барысы да риза-шат иде. Корыган ботаклар җыеп, берничә урында учак ягып җибәрделәр. Өстән тиз генә киемнәрен салып аттылар, ут кабудан да курыкмыйча аларны ялкын өстендә селкергә тотындылар. Иске-москы сәләмәләрнең җөенә яшеренгән вак җанварлар шатыр-шотыр килә башлады...
Ул арада тоткыннарны бригадаларга беркетеп, коры паек өләштеләр: йөз грамм ипи һәм кипкән тәрәч балыгы. Су буенда юынып алырга да рөхсәт иттеләр.
— Суга кермәскә! — дип кисәтте конвой башлыгы.
Мотаһир, салкынча җил исеп торган яр кырыена килеп, шакыраеп каткан балыгын Двина суына манчып, ашыкмыйча гына, ипи белән аралаштырып, чәйнәп утырганда, янәшәдә генә ике кеше тел чарлый башлады.
— Тешең барда таш чәйнә, көчең барда көл чәйнә.
— Икмәк белән су — егетләр ашы.
Мотаһир аларның әңгәмәсенә тыкшынмады.
Чыннан да, чыбык-чабык түшәп, учак янына бер-беренә сыенып ятказ, тоткыннар җир дымын да, якындагы су салкынын да әллә ни тоймадылар. Чөнки киеме коры, хәшәрәтләре ут өстендә кимегән, тамак та ялганган, дөресрәге, корсак та алданган иде.
Иртән Мотаһир уянганда күрше-тирә кайсы гырлап, кайсы мышнап, йоклый иде әле. Ул күзләрен ачып, чалкан ятты. Берөзлексез салкынча җил исеп тора. Күк йөзенең буеннан-буена әллә нинди галәмәт дәү аждаһа сыман болытлар сузылган. Ул гыйфритнең койрыгы җир өстенә төшә, ә башы артка таба киткән. Бераздан, йокысы тәмам ачылгач, Мотаһирның колагына берөзлексез сайраган кошлар җыры килеп кагылды, баш өстеннән чыелдап акчарлаклар очып үтте. Ниндидер машинамы, тракторамы тыкылдый иде. Мотаһир, калкынып, терсәгенә таянды. Сал тартып баручы буксир тавышы икән ул.
Мотаһир торып басты. Шунда ук каланчадагы сакчының усал тавышы ишетелде:
— Кая җыендың?
— Йомыш белән, — диде Мотаһир кысталганын белдереп.
— Бар.
Мотаһир яр буена китте.
Монда агачтан күп нәрсә юк икән. Яр буенда анда-санда агачлар аунап ята. Ә артта, утрауның теге ягында, елга яры белән ике арага тау-тау булып агач өелгән иде. Аның очы-кырые, саны-исәбе юк шикелле тоелды Мотаһирга. Тоткыннарга монда эш җитәрлек...
Мотаһир туңа башлады. Шулай да су буеннан китәсе килми иде. Ул үзүзе белән генә сөйләшсә дә, һәрчак янында кемдер бар сыман. Хәер, соңгы вакытта ул үзенең бу халәтенә, үз кабыгына бикләнеп яшәүгә күнегә башлады. Чөнки кем беләндер ачылып сөйләшеп китеп булмый. Белмәгән-күрмәгән кеше — шикле кеше. Аның үзе белән дә иркенләп, җәелеп китеп сөйләшүче юк бит.
Әнә, бер акчарлак йөзеп бара, битен юа. Аңа карап, Мотаһир да, иелеп, кушучлап су алды, битен чылатты. Җиңел булып китте, тик эч өзелә. Ашыйсы килә... Әкрен генә кояш күтәрелә, җылысы да төшә, бөтен әтраф нурга чума. Тик... ашыйсы килү генә үзәкне өзә, җелеккә төшә. Су эчсә, басылмасмы...
Мотаһир, чистарак җирдән алу нияте белән, су эченәрәк керде. Кушучлап су алды да, аны йотлыгып эчә башлады. Ул бу эш белән мавыгып, яны-

на сакчы килгәнен дә сизми калган: икенче талкыр иелгәндә артына дагалы күн итек белән типкәнгә, суга барып төште.

— Син кая? Стой!

Шул минутта ук гөрселдәп мылтык аткан тавыш ишетелде. Мотаһир сикереп торды һәм кулларын күтәрде.

— Мин бит...

— Качаргамы? Сволочь! А-ну чык судан! Юкса атып үтерәм!

Ул арада икенче сакчы килеп җитте..

— Ни булды?

— Әнә, качмакчы иде...

Мотаһир куркудан һәм суга чыланудан дер калтырап:

— Гражданин начальник, мин су гына эчтем,— диде.

— Алдалый ул,— диде атканы.

— Бәхетең, мин булмадым, юкса, атып үтергән булыр идем. Бар урыныңа!

Ул арада тоткыннар баш калкыткан, кайберәүләр торып ук баскан иде.

Тиздән палатка әзерләү хәстәренә керештеләр, бакларда җылытып, кайнатып су эчтеләр; үз араларыннан парикмахер да табылды — аңа озын чират тезелде...

Менә шулай вак-төяк мәшәкатьләр белән ике көн узып китте. Әлбәттә, барысы да үзләренең монда ни өчен китерелүен чамалый иде. Көндез кояшта кызынып, кичен учак янында җылынып, якты төндә күктәге йолдызларга караган хәлдә юк-бар сөйләшеп палаткада ятар өчен китерелмәгән иде бу эш атлары. Әйе, аларны монда эш көтә. Авыр эш. Ирекле көннән бу нужа арбасына җигелергә теләүчеләр булмаганлыктан, мондый эшкә ихтыярый-мәҗбүри кушалар. Андый эшкә гомер-гомергә хокуксызларны кушканнар: каторжаннарны, җинаять кылганнарны. Ә болар исә икеләтә «җинаятьчеләр» — халык дошманнары. Һәм башланды...

— Урман кисәргә — беренче, икенче, өченче бригадалар... Елга аръягына барасыз... Десятникка...

— Утын хәстәрләргә — дүртенче, бишенче бригадалар. Балта, пычкы...

Бераздан эш бүлүче янына бер тоткын килде.

— Гражданин начальник, мин чулак бит,— дип гарип кулына күрсәтте ул.

— Тешең белән тартырсың!

Эшкә билгеләү дәвам итте.

Мотаһир сал ясаучылар бригадасына эләкте. Өйрәтеп торырга десятник бар, сакларга — конвой. Утыз-утыз биш кеше бер бригаданы тәшкил итә. Алар участогында эш шуннан гыйбарәт: егерме-утыз метрлы дүрт агачны тал чыбыгы белән беркетәләр һәм шуның өстендә йөри-йөри сал әзерлиләр — узган ел кисеп, яр белән утрау арасына тау-тау чыршы-наратларны суга төшерәләр. Сал әзер булгач, аны агым уңаена Архангельскига таба агызып җибәрәләр.

Шунда, гомерендә беренче мәртәбә, Мотаһир сал агызуның ни-нәрсә икәнен аңлады. Молевой сплав — агачларны берәм-берәм агым уңаена, сал итеп бәйләмичә агызу икән. Ручная сплотка — унар агачны, икешәр рәт итеп, тал чыбыгы белән беркетеп җыю. Машинная сплотка — егерме биш агачны тимер чыбык белән машинадан бәйләтү. Колагына ят сүзләр еш ишетелә: бортовой шлаг, средний шлаг... Әзер салны алып китүләрен дә күрде: башы һәм койрыгы очлы итеп җыелган салны ике буксир елга буйлап алып та китте, берсе алдан тарта, икенчесе койрыкка тагылган, боргаланырга ирек бирми. «Кайларга барып җитә икән бу саллар?» — дип уйлый Мотаһир. Салларга гына булса да утырып агар иде... Хәер, андый уйлы кешеләр бер ул гына түгел икән.

Мотаһирның кулдашы Порфирьев фамилияле чуваш егете булып чыкты. Киңчә кызгылт битле, кысыграк күзле, каты коңгырт чәчле Арсентий үтә сабыр холыклы, көчле кеше иде. Ул ике-өч кеше кузгата алмастай агачларны эһ тә итмичә тәгәрәтә. Ләкин ачлы-туклы яшәү, көне буена — уникe

сәгатькә сузылган, женеңне өзәрдәй гаять авыр эш ике атна дигәндә аны аяктан екты. Аның яңак сөякләре тагын да чыгыбрак тора башлады, йөзе агарды. Гайрәтләнеп тотынган бу эшнең ахыры кабер белән бетәчәген ул да яхшы аңлады.

Шуны чамалап, беркөнне, икесе дә хәлдән таеп, агач тәгәрәтә торган күсәкләрен ташлап, бүрәнә өстенә килеп утыргач, Мотаһир сүз башлады.

— Арсентий, хәлләр мөшкел.

Икесе дә берьюлы конвойчыга күз ташладылар.

— Әйтмә дә...

Мотаһир аның сука арасыннан чыккан ат кебек еш-еш сулавын, күкрәгенең гармун күреге сыман бер күтәрелеп, бер төшеп торуын күреп, хәйран калды. Болай тиз бирешер дип уйламаган иде.

Ул фуфайка изүен чишкән, гимнастеркасының да өске сәдәфләрен ычкындырган. Кара чалбар эчендә хәлсез аяклары дерелди.

— Син бераз саграк кылан.

— Үземне җәлли белмим шул,— диде Порфирьев, тупас ботинкасын салып, чолгавын кабат урый-урый.— Крестьян баласы бит.

Әйе, авылда туып-үскән бу егеткә дә ун ел чәпегәннәр. Язмышлары уртак. Шуңа күрә Мотаһир аңардан шикләнмәде.

— Монда исән калу шикле.

— Әйе. Пожалый...

Шушы кыска гына вакыт эчендә яңа килгәннәрдән ике кешенең суга батып үлүе моның ачык дәлиле һәм бу фаҗига барысының да җанын тетрәткән иде. Нишләргә? Бу афәттән ничек котылырга? Күрәсең, икесен дә бер үк сорау борчый иде.

Мотаһир утрауны күздән кичерде. Аның иңен-буен үлчәгәндәй итте. Моннан чыгу юлын чамалады. Әйе, мөмкин шикелле. Утрауның бер ягыннан пароходлар йөзә. Ә икенче ягында сал белән килгән бүрәнәләр тау-тау булып өелгән. Шуннан кача-поса шылсаң... Ләкин... ни ашарсың? Кемгә барып сүз катарсың? Кемгә сыенырсың? Юлын ничек табарсың? Диңгезгә төшкәч, еланга сарылу булмасмы бу? Димәк, барысын да төптән уйлап хәл итәргә кирәк. Тәвәккәлләсәләр, ризык юнәтеп, ипи киптереп әзерләргә кирәк.

Мотаһир битлеген күтәреп, чүпрәк кисәге белән тирләгән маңгаен сөртте, селтәнеп, черкиләрне куып таратты.

— Әгәр Двина буенча китсәк, Котласка барып чыксак...

Порфирьевның зәңгәр күзләренә нур иңде, җанланып китте. Кисәк кенә Мотаһирның беләгенә ябышты.

— Ничек тә рәт чыгарырбыз бит, ә? Нужәли...

— Әкрен...

— Син миннән шикләнмисеңме?

— Арсентий, син ни сөйлисең...

— Үпкәләмә. Дөньясы — эт оясы. Туганыңнан да шикләнә башларсың. Без...

Шулчак икесен дә бердән сискәндереп җибәргән аваз яңгырады:

— Әй, нәрсә җәелеп утырасыз?

Торып, эшкә керештеләр. Ләкин кул күндәм булса да, баш әсәрләнгән, күңел җилкенгән иде инде. Баягы уй аларның йөрәген ашкындырып җибәрде.

Мотаһир еш кына тирә-якны күзәтә, ярга карый торган булып китте. Әнә бер урында төбе-тамыры белән чыршы агачы ярдан каерылып төшкән. Әмма ул үсүдән туктамаган, һаман матур, мәһабәт килеш, очлы башын горур тотып, ямь-яшел булып утыра. «Мотаһир, син дә илеңнән аерылдың. Тик башыңны салындырма, сыгылып төшмә. Җебемә. Нык бул. Язмышың үз кулыңда...» Мотаһир шулай уйлый, үз-үзен юата, җанына көч-гайрәт өстәргә тырыша.

Ләкин моңарчы күз күрмәгән, кешеләре чит-ят булган җирдә андый хәтәр эшкә тәвәккәлләргә үзләре генә батырчылык итмәделәр. Киңәш-табыш итәрдәй кеше — җирле халык вәкиле кирәк иде. Андыйлар монда

бар — ялланып эшләүче ирекleләр. Шуларның берсенә, өлкән бер рус агаена Мотаһир серен чиште. Әлбәттә, ул аңа тиктомалдан, без менә шулай-шулай итәргә уйлыйбыз, төпле кинәшеңне бирсәнә дип ярып салмады. Ул кадәр тинтәк булырга — башына тай типмәгән. Әтисенең кайчандыр, армиягә киткәндә бугай, әйткән сүзләрен хәтерендә нык тотты: «Улым, алтмыш адым атлаганчы, алты тапкыр артыңа бак». Бер-ике көн күзәткәннән, аны-моны сөйләшкәндә сүз арасында качып китүчеләр булу-булмавы хакында белешкәннән соң гына, җаен китереп, авыз ачты.

— Ай-яй, сезнең монда урманнар! — диде Мотаһир тел шартлатып. — Боларның очы-кырые юктыр...

— Әйе, урман җитәрлек, — диде агай тыйнак кына һәм тәмәке янчыгы чыгарып башта Мотаһирга тәкъдим итте. — Тартып җибәр.

— Юк. Рәхмәт.

Агай аптырап калды: моңарчы тәмәкедән баш тарткан тоткынны күргәне юк иде. Күбесе үзләре сорап йөдәтәләр.

— Тартмыйсыңмыни?

— Әйе. Безнең нәселдә тартучы юк.

— Нишләп алай? — диде агай тәмәке төреп.

— Дин кушмый.

— Ә, ә, аңлашылды. Коран кушмый. Мусульманин.

— Әйе.

— Ярар, тартмавың хәерле. Болай да сезнең братның хәле мөшкел. Ә мин өйрәнгән инде.

Агай, бер-ике суыргач, корык-корык йөткереп алды.

Мотаһир, аңа сынап карап, янә җай гына сүз башлады.

— Монда якын-тирәдә авыллар бармы соң? Бер дә күренми.

— Бар. Күбесе су буенда. Теге якта — Кальп, аста — Подсосанье, Почтовая, өстәрәк — Лесопункт.

— Алай икән, — диде Мотаһир сузып кына.

Агай сүзен дәвам итте:

— Юмата елгасы тирәләрендә Родионовская, Уйта, ә Ваенга елгасы тамагында Усть-Ваенга авылы бар.

Мотаһир баш какты.

— Бик күп икән.

Агай үзе дә сорауга күчте.

— Бирегә Котластан килдегезме?

— Әйе.

— Узмадыгызмыни?

— Без бит баржада, трюмда килдек.

— Шулайдыр.

Мотаһир әңгәмәне тагын баягы эзгә төшерде.

— Урманда сазлык-күлләрме?

— Сазлыгы да җитәрлек, күле дә. Әнә тегендә, — дип агай төньякка, Двина аръягына күрсәтте. — Ковозеро күле. Вак-төяге — санап бетергесез.

Сөйләшкәндә агай да салынып төшкән сары кашлары астыннан Мотаһирга сынаулы карашын төбәде. Каяндыр килгән, чит милләттән, чит диннән булса да, бу кеше аңарда шик-шөбһә уятмады. Агай акыллы кеше иде, егетнең тел төбен шундук чамалады. Ул яловый күннән тегелгән, бот төбенә җитешле озын кунычлы бахилла кигән аякларын аерыбрак басты, бераз тын торды. Мотаһирга янә сынап карады. Конвой тарафына да күз төшерде. Фуражкасына кулын тидереп, аны күтәребрәк куйды, телогрейка изүен эләктерде. Шуннан соң гына үз сүзен әйтте:

— Монда кеше үтмәслек урман, — диде ул җирән сакалын сыпыргалап. — Ялгышасыз, егетләр. Ачыгырсыз, авылларга чыгарсыз. Урларсыз. Эләгерсез. Үзегезгә үк начар булыр.

Мотаһир бу сөйләшүне Порфирьевка җиткерде. Инде ниндидер өмет белән яши башлаган Арсентий кара көйде. Ул әле һаман үзенең көч-гайрәтенә таянырга исәп тота иде булса кирәк.

— Юк, мин — качам! — диде ул үҗәтләнеп. — Син, Мотаһир, үзең кара. Мин барыбер качам!

— Кая барасың? Күз караган яккамы?

— Су үз юлын тапкан кебек, миңа да җай чыгар әле.

— Кемгә сыгынырсың?

— Төнге юлның тармаклары күп. Яхшы кешеләргә юлыксам...

— Хәзер һичкемгә ышанып булмый.

— Менә без бер-беребезгә ышанабыз бит.

— Тотсалар?

— Тота пычагым. Бер юлдан киткән качкынны эзләргә йөз юл кирәк. Булышырлар әле, дөньяда яхшы кешеләр бетмәс.

Беркөнне, төштән соң, күк йөзе куера башлады. Бөтен яктан кара болытлар уратып алды. Кайдадыр дөбердәп күк күкрәде, тузан чыкты. Давыл купты. Күз ачкысыз ком бураны... Кошлар түбәнтен оча... Яшен яшьнәп, өстән аска таба бөтен күк йөзен ярып төшә, шуннан озак та үтми, күк күкри. Менә коеп яңгыр яварга тотынды. Тоткыннар, эш коралларын ташлап, кайсы-кая ышыкландылар. Ә яңгыр шаулап, тәтенләп ява, бөтен тирәюнь томан эчендә. Караңгыланды. Елгадагы буксир-пароходлар утларын кабызды, гудок авазлары ишетелде.

Шактый озак яугач, яңгыр туктады. Һава сафланды. Ерганаклар ясап, су акты. Үләннәрдә, агач яфракларында яңгыр тамчылары җемелдәде...

Тоткыннар тагын эшкә кереште. Ләкин Мотаһир озак маташа алмады, бермәлне, бүрәнә өстеннән барганда, аның аягы таеп китте һәм ул егылды. Торып басмакчы булды.

— Арсентий...

Порфирьев артына борылып карады.

— Нәрсә булды?

Ул йөгереп килде дә, култык астыннан тотып, Мотаһирга торырга ярдәм итте.

— Аякны авырттырдым, — диде Мотаһир йөзен чытып.

— Ныкмы?

— Белмим.

— Сынмаганмы?

— Юк шикелле, — диде Мотаһир аягын капшаштырып. — Тамыры сузылды, ахры.

Шулай булса да ул эшен ташламады. Каймыккан аягын ике-өч көн көчхәл белән сөйрәп йөргәч, аны утын кисүчеләр бригадасына күчерделәр.

Бәхетенә, ул ике татар кешесенә юлыкты.

Сафуан исемлесе Актаныш ягыннан, колхоз председателе булып эшләгән, унбиш ел биргәннәр. Ә икенчесе — Алимҗан — колхоз кладовщигы. Чүпрәле ягыннан, аның срогы Мотаһирныкына тиң — ун ел икән.

Эшләре чагыштырмача җиңел тоелса да, көнлек норма күп: унбиш погонный метр озынлыкта, бер метр биеклектә. Пароход миченә китәргә тиешле бу утынның озынлыгы җитмеш дүрт сантиметр: артык та түгел, ким дә түгел. Һәр бүкәнне үлчәп кисәргә кирәк. Кичке якта эшне кабул итүче килә, кулларына кәгазь бирә, ә сакчы — бер адым да китми.

Әйе, монда бригада булса да, өч кеше эшләсә дә, хәтта бер генә кеше дә — һәрчак сак астында. Беркая, бер адым да китә алмыйсың, сакчылар күздән җуймый. Ләкин чая башлар юлын-хәйләсен таба: соңгы вакытта өч тоткын юкка чыкты. Шуларның берсе Мотаһирның ярсу йөрәкле дусты Арсентий иде. Мотаһир аны әрләмәде, бу тәвәккәл адымы өчен орышмады, бары аңа хәерле юл гына теләде. Бу дөньяда һәркем бер генә тапкыр яши. Шуңа күрә, нинди генә хәлләргә юлыкса да, күпчелек очракта тормыш юлын ул үзе сайларга тырыша, үзе өчен бары үзе генә кылган гамәлләренә җавап бирә. Мотаһир намуслы, эш сөючән крестьян баласын кайчак сагынып исенә дә төшергәли иде. Ләкин кабат беркайчан да якын кардәшенең язмышы хакында ишетмәде...

Авыл кешесенең тормышы, бер уйлаганда, үтә ялыктыргыч кебек тоелырга мөмкин. Чөнки көн дә бер үк шөгыль: җир эше, мал-туар карау, кошкорт үрчетү, кыш чыгарлык ягулык әзерләү... Ләкин крестьян эше һәр сәгать, һәр көн үзгәреп тә тора. Бәлки шуңа күрәдер авыл кешесе табигате белән тыныч-сабыр була. Чөнки эш аны ялыктырмый, ул аның ихтыяҗына әверелә, хезмәт итәргә кирәклеге канына сеңгән була. Ул һәрнәрсәне үз белдеге белән башкара. Ә монда... хәл бөтәнчә. Эшкә дә сак астында барасың, якында гына урнашкан булса да, ашханәгә дә — күзәтү астында... Бер минут, бер секунд сине күздән яздырмыйлар. Эшләгәндә дә шул ук. Көнозын пычкы тартасың: алга-артка, алга-артка... Пычкы чүбе берөзлексез аяк астына коела, чаж-чож иткән тавыш колак төбеннән китми, уч төпләре кызарып чыга, кабарып тишелә дә чиләнеп тора. Ачлыктан кулыңның хәле китә, эчең арканга ябыша, анда бүреләр улый, ә туктарга ярамый — әле уң, әле сул кул белән тартасың... Күз аллары караңгыланганчы. Туктап ял итәр идең — норма тутырырга кирәк, ипи ашыйсы килә. Менә шундый хәлгә юлыккан крестьян баласы авылын, өен сагына. Киң кырларга күнеккән күзләре очлы ылыслы нарат-чыршыга килеп төртелгәндә дә, арыш-бодай дулкынлануын тойган һәм аларның талгын шавын тыңларга гадәтләнгән колакларына һәрдаим кыргый кара урманның куркыныч, шомлы авазы яңгырап торганда да ул туган җирен сагына. Талпынып-талпынып сиңа дәрт бирүче сабан тургайлары җыры, иртә таңнардагы сандугачлар моңы, бәрәңге бакчалары өстеннән, зәңгәр күкне иңләп, тезелешеп очкан торналар авазы — барысы да сагындыра. Шул сагыну, йөрәк ярсуына чыдый алмагач, эчке моң тышка бәреп чыга да, адәм баласы җыр суза:

Агыйделләр аша уклар аттым
Таш пулаткай башы тимергә.
Ходай да безгә язган микән
Туган илне кайтып күрергә?

Таш бәгырьләр дә эрер иде бу моңга. Әнә сакчы да, бер бүкән өстенә утырып, мылтык түтәсен җиргә терәп, уйга калган. Бәлки, ул да үз язмышын каргыйдыр? Бәлки, ул да гади бер керәстиян баласыдыр? Үзе кебек үк кешеләрне, гәрчә аларны аңа, дошман, халык дошманы, дип сакларга тапшырган, өркетеп куйган булсалар да, кызганадыр. Тоткын язмышы ни дә, конвой язмышы ни... барыбер түгелмени? Ач-ялангач кешеләргә карап тору аңа да җиңел түгелдер. Ул үзе дә ирексез ләбаса. Гәрчә сүзләренә төшенмәсә дә моңын тоя чит милләттән булган сакчы. Үзе дә илен-җирен, газиз анасын сагынып, онытылып куя. Ә җыр агач ботакларына урала-урала, наратның бөдрә ябалдашларына, чыршының очлы сөңгеләренә бәргәләнә-бәргәләнә оча:

Агыйделне иңләп-буйлап
Йөзәрсең үрдәккәем шул.
Бардыр хәсрәт күргәннәрең—
Түзәрсең йөрәккәем...

Түзми ни хәл итәсең? Кая барасың? Тирә-юнең ерып чыгалмаслык чытырманнар, үтә алмаслык сазлыклар. Түзәсең. Түзә адәм баласы, түзә. Урман киссә дә, таш ватса да түзә. Ул сабырлыкка өйрәнгән, ул өмет белән яши. Җиде-ят җирләрдә, җиде кат җир астында булса да, һәр мизгел агач астында калу, таш басу куркынычы янап торса да — өметен җуймый ул. Аның бар уй-хыялы туган җиренә, сөйгәненә барып тоташа.

Шахтер егет күмер чаба,
Кемнәр ала исәбен шул.
Гомер булып, таш басмаса,
Ташламам, җанкисәгем.

Әйе, ташламас ул сине! Көт син аны, сөйгән яры, хәләл җефете! Әлегә авыр җан дустының хәлләре, ай-һай, авыр! Таш кисүдән дә авыр аның хәлләре. Тоткынның пароход миченә ягыласы утын кисүе иректәге егетләрнең җиде кат җир астында күмер чабуыннан мең кат авыр. Кимсетелгән, рәнҗетелгән йөрәкнең сагышы ирекле зимагур хәсрәтеннән мең өлеш моңлырак.

Урман! Ишетәсеңме, урман! Агач кәүсәләренә, җәпләкә ботакларга кагылып узган моңны, җилләргә кушып, озат син ерак-еракларга, бу егетләрнең туган якларына, киткән юлларыннан күз алмаучы газиз ата-аналарына, тилмереп көтүче балаларына, наз күрмичә гомерләре заяга узучы сөйгән ярларына! Бу бахырларның сәламен ирештер. Аларны хәвеф-хәтәрдән сакла, урман! Олуг урман тамыры тоташкан изге Җир-ана! Ишетәсеңме хаксызга рәнҗетелгән җаннарның сыкравын? Ишетәсеңме әзмәвердәй егетләрнең давылда шартлап сынган агач кебек сыгылып төшеп зар җылавын?! Әйе, урман ишетәдер. Юкса, буыннар авыруы әләктергән кул-аяк сөякләре шыгырдаган кебек айкала-чайкала җәберләнмәс, өзгәләнмәс, сызланмас иде кәүсәләр-бәгырьләр...

...Кап-кара чәчле, кушылып диярлек үскән чем кара кашлы Суфиян. Андый кешене бәхетле була, диләр. Бәхетлеме Суфиян? Их, нинди бәхет турында сүз булуы мөмкин... Унбиш елга ирегеннән мәхрүм ител дә... Ә Алимҗан бәхетлеме? Их, нинди бәхет тәтесен ун елга зинданга эләккән кешегә? Ә Мотаһир? Ул да бәхетсез. Йорт-җирсез, туган илсез, гаиләсез калган сукбайлар язмышы хәзер аларның хәле. Тик адәм баласы уйлау, фикер йөртү, сөйләшү сәләтеннән мәхрүм түгел. Димәк, чыкмаган җанда өмет бар. Өмет, өмет, өмет... Өмет бар, ә ирек — юк. Кисәк кенә Мотаһирның күз алдындагы томан тарала. Чөнки Агыйдел баласы Суфиян җырлый:

**Тальянский гармуннарда**
**Уйный биш бармак кына.**
**Көзге яфраклар шикелле**
**Саргаям салмак кына.**

Әнә саргайган яфрак әкрен генә түбән төшә. Юк, агач яфраклары түгел, Мотаһирның күз яшьләре коела... Табигать һәм кеше бербөтенгә әверелә... «Мин дә шушы яфраклар кебек бер кирәксезгә әйләндем. Гомер агачыннан өзелеп төштем. Уза бит елларым-көннәрем! Ниләр кылыйм?! Йөрәккаемнән каннар сава бит! Ун ел гомерем заяларга уза бит! Кемнәргә сөйлим бетмәс зарымны? Кемнәр юатыр китек күңелемне? Бу узмас көннәр, караңгы төннәр, атмас таңнар кайчан бетәр? Кайда соң дөреслек? Кайда соң гаделлек? Ни гөнаһым бар минем?! И ходаем, үзең сабырлыклар бир... Бәлки, берәр хәл булып, азат та итәрләр әле... Амнистия булмасмы? Октябрь бәйрәме җитә бит... Кайтыр идем туган якларыма, су буендагы талларны, урамдагы тупылларны кочаклап елар идем; көзге сары яфракларны битләремә каплап, тирем түгелгән җирләргә ятып, кара туфрагына башкаемны салып шатлыктан елар идем. Кайчан гына кайтырмын туган илләремә?! Газиз балаларым, сөекле хатыным, изге атам-анам! Кайчан гына сезне күрергә насыйп булыр икән?»

...Уйларына бирелеп, бүкән өстендә утырган Мотаһир, зәһәр тавышка кисәк дерт итеп китте.

— Син, мать твою за ногу, контра, нишләп утырасың? Саботажник! Тор, сволочь!..

Ялтырап торган күн итек, каеш буган кыска шинель хуҗасы — каршына килеп баскан лагерь коменданты җикеренүенә Мотаһир сикереп торды. Бөтен тәне дерелди, аяк буыннарының хәле киткән, йөзе ап-ак булган иде.

— Хәзер, гражданин начальник...

Йолдызлы фуражкасын батырып кигән комендант, аңа, ашардай булып, бәбәген терәгән. Тук, кызгылт йөзен, ачулы күзләрен кан баскан. Колак төбендә һаман сүгенү, янау... Мотаһир аларны ишетми дә диярлек. Ул бик озак тормыш чынбарлыгына кайта алмыйча, хыялыннан айный алмыйча

җәфаланды. Югыйсә, үзе тагын пычкы тарта иде. Чаж-чож: алга-артка, алга-артка... Кинәт пычкы авазы бөтенләй икенче төрле ишетелә башлый: зиндан, зин-дан, төр-мә, төр-мә, ла-герь, ла-герь... Каһәр төшкән пычкының да теле гүя шуның белән ачылган... Ничек алай булды соң әле? Ничек шулхәтле җәелеп утырдылар икән? Әнә конвойчыга да эләгә... Алар ягына карамаска тырышып, Мотаһир пычкы тарта: чаж-чож, чаж-чож... «Чәнчелгере, тагын шул зиндан... узмас көннәр, караңгы төннәр...» дигән уйдан башы шаулый, мие туңа.

...Дөресен генә әйткәндә, тоткында да этлек җитәрлек. Кеше кыса-рам эчендә озаграк торган саен шомара төшә, һәр минут уяу булырга өйрәнә, кем әйтмешли, тапкырлыгы арта. Аның һәр күзәнәге сизгер, тоючан: ул арт чүмече белән дә кем килгән-киткәнне күрә ала, алдан ук куркыныч буласын да сизә, үзенә файдасы тиярдәй нәрсәләрне дә әллә каян чамалый.

Утын кисүчеләр дә, комендант күзенә тап булып, бер тотылгач, икенче эләкмәскә тырыштылар. Мотаһирның күзе конвойда булса, Суфиян — уңны сулны, Алимҗан алны-артны күзәтә. Үзләре ач, хәлсез булсалар да, сөйләшү теләге беркайчан да бетми. Хәер, сөйләшү дә күбрәк ашау-эчү тирәсендә була. Алар моның үз-үзләрен котырту икәнен ачык белсәләр дә, теләмәсәләр дә, ирексездән сүз ризык тирәсендә бөтерелә. Чөнки ризык та бит туган як, якыннар, өй-гаилә белән бәйләнгән. Шуннан хатирәләр дәрьясына агып китәсең.

Бу юлы Суфиян тиктомалдан әйтеп куйды:

— Һаман шул балык башыннан шулпа...

Эш дәвам итә: икәү кисә, берәү яра, конвойчы карап тора.

Алимҗан Суфиянга каршы килеп маташа:

— Балык ашаган тук булыр.

Суфиянга җитә кала:

— Тез буыны гына сыек булыр. Балык белән ерак китә алмассың. Бу балтаны күтәрергә... Аннан, безнең корсакка бик килешми дә әле ул.

Мотаһир аптырап сорый:

— Бәй, Агыйдел буенда үсеп...

— Безнең авыл Агыйделгә утыз чакрым.

Алимҗан дәртләнеп китә:

— Һәй, агайне, безнең халыкка ит булсын инде.

Мотаһир рәхәтләнеп ялгап җибәрә:

— Шулай инде. Ат ите диген. Кыш көне чүлмәк белән мичкә тыгасың... Ә безнең казылык өзелми торган ие. Келәткә чыксаң, тезелешеп асылынып торалар инде, мин сиңа әйтим... Ата каз муены кебек юан үзләре...

Суфиян иреннәрен ялап куя.

— Хәзер бер калҗа булса икән ул...

Алимҗан көрсенә.

— Каян аласың аны? Ит дисең... әле башка нәрсә булса да ярап торыр иде. Билбау асты бигрәк тиз бушый.

Мотаһир көлгәндәй итә.

— Майласаң, иске чабата да үтә дисеңме? Берәр әмәлен табып булмый микән соң?

Суфиян бик елгыр, җәптәш кешегә охшый, рәис тә булып эшләгән. Ләкин бу очракта ул да, кулын җәеп, уфтанудан ары китә алмый.

— Белмәем. Ә ничек?

Алимҗан йодрыкларын йомарлап, бармак сөякләрен шыгырдата.

— Их, ирек юклыклары... Без мондый егетләр идекмени?!

Алимҗанны аңлавы читен түгел: буе уртача гына булса да, чандыр сыман күренсә дә, тыгыз тәнле ул, унҗиде-унсигез яшеннән мәйдан тоткан сабантуй батыры. Тәрбия җитсә, әле дә көч-егәре ташып торыр иде. Ләкин... үлән ашап, кара җиләк ише вак-төяк чемченеп кенә тәнгә ит кунмый шул.

Бераздан, соңгы бүкәннәрне кузладан алып, җиргә ташладылар. Чираттагы агачны көч-хәл белән күтәреп, кузлага салдылар. Тагын чаж-чож пыч-

кы авазы тирә-юньгә үз зарын сөйли башлады. Каяндыр чыккан җил, пычкы чүбен бөтереп алып, ачу белән чырайга, күзләргә бәрә, мескен тоткыннарны кыерлый иде. Хәлсез кулларга эләккән балта, гайрәтле ирләр бер генә бәреп урталай ярасы бүкәнне, кырыйлап та кыя алмыйча азаплана.

Беразга тынып торган сүз тагын җай гына дәвам итте. Ләкин тема үзгәргән. Шулай булса да өй, гаилә, якыннар тирәсеннән ерак китмәгән икән.

Суфиян, уфтанып, әйтеп куйды:

— Хатынны сагынам. Нәкъ менә уналты яшьлек гашыйк егет сыман, гел күрәсем генә килеп тора.

Мотаһир:

— Бик чибәр идемени соң?— дип сорады.

— И, агайне, чибәрлектәмени хикмәт?!— диде Суфиян.— Чибәрлектән чиркәү салмыйлар. Аның яхшылыгы... Их, бер генә күнгә, бер генә сәгатькә кайтасы иде янына! Күрәсе иде нурлы күзләрен — үлсәм дә үкенмәс идем!

Алимҗан, Суфиянны юатып:

— Кайтырсың әле,— диде.— Өметсез шайтан гына диләр.

— Юк инде, булмас, агайне. Күңелем сизә: бу хәлләргә түзә алмам мин. Ярсу йөрәгем харап итәр мине...

Суфиянның сизенүе дөрескә чыкты. Бер ай чамасы үткәч, югарыдан килгән комиссиягә зарланганы өчен, лагерь администрациясе аны каядыр тагын да ары — Соловки утрауларына җибәрде. Шулай итеп, кеше эзсез югалды.

## XIII

Мотаһир, якташларының киңәшен тотып, икенче көнне санчастька юл алды. Ул анда Буров фамилияле табиб эшләвен, аның Ленинградтан икәнен ишетеп белә иде инде. Барын да тигез күрә торган, олы җанлы бер кеше, дигән сүзләр йөри иде лагерьда аның турында.

Мотаһир бусагадан кыяр-кыймас кына атлап палаткага керде.

— Исәнмесез...

— Исәнмесез, узыгыз.

— Рәхмәт.

Бу — амбулатор кабул итү үткәрә торган урын. Буров үзе генә түгел, санитар белән икәү утыралар иде. Палатканың җиһазы бик ярлы — өстәл, медикаментлар, тартмалар, инструментлар куелган шкаф, берничә урындык. Буровның өстендә ак халат, яланбаш, лагерьдагы барча тоткыннныкы кебек, аның да чәче кыркылган, сакал-мыегы да юк.

— Н-ни йомыш? Авырыйсызмы әллә?

— Анысы да бар,— диде Мотаһир һәм Буров күрсәткән урындыкка утырды.— Шартлар начар, ашау-эчү такы-токы. Эш тә авыр.

— Әйе,— диде табиб килешеп.— Аң-ладым.

Мотаһир аның тотлыгып сөйләшүенә игътибар итте.

Буров бүлмәдә дәшмичә боегыбрак утыра иде. Кеше керүенә шатланды. Ләкин Мотаһир керә-керешкә аңа гәптәш була алмады. Чөнки килүенең төп сәбәбен әйтергә кыймыйчарак, беравык бүлмәне караштырыбрак утырды ул. Дөресрәге, күптән онытылган дару исләреннән борыны кытыкланып, башы әйләнеп киткәндәй булды. Күңеле тулды, күптән узган хәлләр шикелле кайдадыр еракта калган ул эшләгән медпункт та, авыл да... томанлы хатирәләр генә исендә калган.

Бүлмә бик фәкыйрь булган кебек, дару шкафы да буш диярлек. Хәер, артыгын кем бирсен. Монда бит чирләшкәләр түгел, эш атлары кирәгрәк. Димәк, арып егылганчы эшлә дә эшлә! Инде хәлең бетсә — урын табылыр. Мотаһир да әнә шул хәле бетү алдында булганга, авыр эш җелегенә

үткәнгә, көч-җегәрен суырганга күрә монда килде дә ич. Һәм ул, бөтен кыюлыгын җигеп, тартыну-читенсенүен бер кырыйда калдырып, әйтеп салды:

— Мин — медицина хезмәткәре.

Буров аның кан басымын үлчәргә дип, приборын җайлап, кулына урелмәкче иде, тукталып калды, санитарына күз ташлады. Ул хәтта шатлыктан кычкырып ук җибәрде:

— О-о, монда без көтеп кенә торабыз! Югыйсә, беркем дә юк: ни ялланып эшләүчеләрдән, ни тоткыннар арасында. Ягез, әзрәк үзегез белән таныштырыгыз: кем сез, кайда укыдыгыз, кайда эшләдегез?

Илле яшьләр тирәсендәге доктор Буров, озын буйлы кешеләргә хас булганча, бераз бөкрерәк иде, йөзе ябык, күзләренә моң-сагыш тулган — үзе елмайганда да яктырып өлгермиләр; озынча, очлы борын яфраклары сөйләшкәндә киңәеп-киңәеп китә, куллары озын, бармаклары сөякчел, кул аркалары гына түгел, бармак сыртлары да төкле.

— Мин 1928 елда Кызыл Армиягә алындым,— дип башлады Мотаһир сүзен.

— Гафу итегез,— диде Буров аны бүлдереп.— Кайсы яктан? Милләтегез? Фамилиягез?

Мотаһир, мөмкин кадәр кыска тотырга тырышып, үзенең тәрҗемәи хәле белән таныштырды.

— Смоленскида санинструкторлыкка укыдым. Полоцк шәһәрендә бер ел да ике ай санчастьта хезмәт иттем. 1931 елда армиядан кайттым.

Күрәсең, ул Буровка торган саен ошый бара: чөнки табиб үзе дә сизмәстән, «син»гә күчте.

— Аннары кайда эшләдең?

— 1931—34 елларда колхозда эшләдем.

— Ә нигә больницада түгел?

— Авылда хәтта медпункт та юк иде.

— Шуннан?— дип сорады табиб җанланып.

— 1934 елны Минзәләгә трахматозный пунктка укырга җибәрделәр.

— Аңлашыла: трахома дәваларга.

— Әйе.

Санитар урыныннан торды һәм Буров янына килеп, иелеп, колагына нидер әйтте. Буров баш какты:

— Әйе. Әлегә кирәгең юк. Бар. Тик озак йөрмә.

— Ярар,— диде санитар һәм чыгып китте.

Өзелеп торган әңгәмә кабат ялганды.

— М-минзәлә... кайда ул?— дип сорады Буров.

— Бездә, элекке өяз шәһәре. Сезнең белмәвегез гаҗәп түгел. Үзебезгә калса, якын-тирәдә зур шәһәр инде. Анда, безнең программаны үткәнсең, дип, мине, кәгазь биреп, кире җибәрделәр. Райздравка кайтып әйттем. Ул мине күрше авылга участок больницасына җибәрде. «Трахматоз пунктында эшли ала»,— дип, теге Минзәлә кәгазенә резолюция дә салды. Аннары, кабат райздравка барган идем, үзебезнең авылда пункт ачарга куштылар, эшкә алдылар ягъни.

— А-аңлашыла,— диде Буров тотлыгып.

Тәбәнәк юка гәүдәле, зур такыр башлы, игътибар белән тыңлый һәм кирәк кадәресен ачык итеп сөйли ала торган Мотаһир абы, чыннан да, ошады. Ул Мотаһирның ничә яшьтә булуы, гаиләсе, бала-чагасы, ата-анасы белән дә кызыксынды. Ни өчен утыруын төпченеп тормады. Илле сигезенче статья булгач, сүзсез дә аңлашыла. Чөнки үзе дә шул статья белән хөкемгә тартылган иде.

Әңгәмә күпме дәвам иткән булыр иде, билгесез, бермәлне ишек ачылды һәм авызын тоткан берәү сызланып килеп керде.

— Доктор, доктор,— диде тоткын ялварып.— Мин Виноградов булам, бүген дүртенче көн инде...

Буров торып басты, аның кулын төшертеп, авызын ачтырды, сызлаган тешен карады. Аннары ул Мотаһирга мөрәҗәгать итте:

— Сез медицина хезмәткәре бит. Теш алалмассызмы?

— Инструмент бармы?—дип сорады Мотаһир батыраеп, чөнки монда табиб белән сөйләшеп утыру, санитар бүлмә аңа көч-куәт керткән, үз-үзенә ышаныч биргән иде.

— Бар,—диде Буров һәм шкафны ачып күрсәтте.

— Суырып карыйк алайса. Туры килгәләгән иде.

Мотаһир Буровның кулына да игътибар итеп өлгерде: теле тотлыгуы өстенә, терсәктән түбән кулы да калтырый икән мескеннең. Ул, коллегасын тикшерүдән бигрәк, үзенең кулы калтырауга читенсенеп һәм алыштырырга кеше булуына сөенеп, бу эшне Мотаһирга тапшыргандыр да әле.

Мотаһир таякчыкка мамык урады, йода сөртте. Кыскычны өскә каратып, йодалы таякчыкны өстәлнең икенче кырыена куйды.

Авыруны сөйләштерә башлады.

— Сез каян?

— Калугадан.

— Кемнәрең бар?

— Ха...

Мотаһир авыруның башын култык астына кыстырды. Чөнки бүтән мөмкинлек юк иде. Кыскыч белән тешне тартып та чыгарды.

— Менә,—дип Мотаһир авыруга «артык» тешен күрсәтте һәм, мамык алып, пинцет белән бушап калган урынга тампон утыртты.

Авыру:

— Китимме?—дип сорады.

— Юк әле.

Биш минут утыртты аны Мотаһир, тампонны алып, икенчесен куйды.

— Хәзер китәргә була.

— Рәхмәт,—диде авыру һәм Буровка да баш иеп, кулы белән авызын тотып, чыгып китте.

Авыруны озатканнан соң Мотаһир үзе дә озак юанмады, коралларын юып-чистартып урынына куйды да, Буров белән хушлашты.

Бу вакыйга эзсез югалмады, аның дәвамы икенче көнгәчә һәм хәтта айлар-елларгача сузылды.

Авыру палаткасына кайткан да нарга сузылып яткан. Дүрт тәүлек йокы әсәре күрмәгән бичара, башы ятакка тию белән йокыга да киткән. Гөнаһ шомлыгына каршы, килеп кергән комендант. Ни күрсен — дневальный юк. Шуннан ул эндәшә.

— Дневальный?! Виноградов?—Тегене ятагына барып уята.—Виноградов, бу ни хәл? Нигә җыештырылмаган? Нишләп йоклап ятасың? Эшчеләр кайтырга тиеш. Мич ягылмаган.

Виноградов сикереп тора, күзләрен уып, үрә ката.

— Гражданин начальник, дүрт көн буена тешем сызлады. Санчастька барган идем — суырып алдылар. Таянып кына торган идем, йокыга киткәнмен. Кичерегез, гражданин начальник, хәзер...

Иелгән башны кылыч кисми.

— Җитәр! Ә кем алды? Буровмы?

— Юк.

— Кем соң?

— Менә... бер бәләкәй татар бар бит әле, бонда, сплоткада да эшләде, аннан утын әзерләүдә...

— Нәбиуллинмы әллә?

— Әйе, әйе.

Комендантның җыерылган кашлары языла төште.

— Яхшы. Эшеңә кереш. Тәртип булсын!

— Есть, гражданин начальник!

Икенче көнне әле берни белмәгән Мотаһирны комендантка чакырттылар. Башыннан салкын су койган кебек булды аның. Бик борчылып, курка-оркә генә (чөнки түрәләр каршына бару бер дә хәерлегә булмый) ишек шакыды Мотаһир...

— Гражданин начальник, сезнең чакыруыгыз буенча килдем.
— Фамилиягез ничек?
— Нәбиуллин.
Комендант урыныннан кузгалмады. Бераз көттереп, кырыс кына:
— Виноградовның тешен син алдыңмы?—дип сорады.
— Әйе.
Мотаһирның йөрәге жу итте: «Мөгаен, берәр хәл булгандыр. Югыйсә, бөтен шартын китереп, чиста итеп алган идем бит. Әллә үзе пычрак кулы белән кагылды микән? Утын гына кискән булсамчы... Менә җәфа. Нишләтерләр икән инде?»
Комендант алдында, өстәлдә, катыргы кәгазь папка — Мотаһирның «дело»сы. Моны да күргәч, бичара тоткын шыр җибәрде. Өр-яңа гимнастеркасын аркылы-торкылы каешлар белән буган, сап-сары чәчле комендант игътибар белән, бик җентекләп аның эше белән янә бер тапкыр танышып чыкты, ахры. Озак кына утыргач (гүя ул кан калтырап торган тоткынның монда икәнен дә, аны ни өчен чакыруын да онытткан), комендант папканы япты. Сынын катырып басып торган Мотаһирга сөзеп карады, үткер карашы белән өтеп алды. Буй-кыяфәтен, килеш-килбәтен генә түгел, гүя аның бөтен эч серләрен, уй-фикерләрен дә анык белергә, аны үтәли күрергә теләгән иде. Һәм ул теләгенә ирешә дә кебек. Көттереп кенә:
— Яхшы,—диде һәм йөзенә чыккан канәгатьләнү билгесен яшерергә теләмәде ул.—Без сезне амбулаториягә күчерәбез.
Мотаһир, иңеннән бозлы бүрәнә төшкәндәй, җиңел сулап куйды. Беренче мәртәбә комендантның йөзенә күзен тутырып карады. Рәхмәт хисләре аның чыраенда гына түгел, бөтен торышында чагыла иде.
Комендант коры гына:
— Китәргә мөмкин,—диде.
Мотаһир чын күңеленнән илтифат күрсәтеп:
— Рәхмәт, гражданин начальник,—диде.
— Барыгыз.
Мотаһир, ишек артындагы сакчыга да баш кагып, елмаеп, бу бинадан чыгып китте.
Ул бары соңыннан гына, бу вакыйганы әнәсеннән җебенә хәтле дигәндәй, хәтеренә төшергәч, күп нәрсәгә игътибар итте. Комендант башта аннан: «Виноградовның тешен син алдыңмы?»—дип сорады. Ә ахырда, аның «дело»сын карап чыккач һәм төпле бер фикергә килгәч: «Без сезне амбулаториягә күчерәбез»,—диде. Менә шушы ике сүз, ягъни син һәм сез дип эндәшү, күп нәрсәне аңлата иде. Димәк, комендант аны шундый җаваплы эшкә куярга (әлбәттә, ул Буров белән киңәшеп эшләнгән эштер инде) лаек кеше дип саный, сез дип эндәшергә дә гарьләнми. Ләкин Мотаһир моның беркайчан да үзенә ташлама ясарга мөмкинлек бирмәячәген яхшы аңлый иде. Ни генә булмасын, аңа ничек кенә дәшмәсеннәр, ул монда — тоткын. Аны теләсә кая җибәрә һәм теләсә нинди эшкә куя алалар. Ул фәкать эш белән генә, намусына, медицина хезмәткәре дигән олуг исемгә тап төшермичә генә шушы ышанычны аклап, язмыш дәрьясында очраган саламга ябышып тора алачак. Монда тоткыннар гына түгел, үз ирке белән эшләүчеләр һәм хәтта сакчылар, олы начальниклар да һәрчак шик астында, һәрчак тәбе тирәсендә. Моның шулай икәненә аңа ике-өч айдан соң янә бер инанырга туры килде.

## XIV

Буров беренче көнне үк Мотаһирны кисәтеп куйды.
— Син кешенең тышкы ягын гына кара. Бер күз ташлау белән аның хәлен чамалап була. Утраксасын кара, ите булмаса, эшкә җибәрмә. Безнең бит әйбер юк.
Әйе, Мотаһир дарулар юклыгын да, тоткыннарны савыктыру өчен мөмкинлекләре бик чикле икәнен дә тиз аңлады. Шулай да ул хәленнән

килгәннең барын да эшләргә тырыша иде. Шуңадыр, аны тоткыннар да үз итеп өлгерде.

Амбулаториядә өч ай эшләгәч, Мотаһирны лагерь начальнигына чакырттылар. «Әйбәт кенә эшләп ятканда... тагын ни булды икән? Нигә чакыра икән?» Башта мең төрле уй, сорау. Ләкин авыз тутырып берсен дә, беркемгә дә бирә алмыйсың. Монда бары үз кабыгыңа бикләнеп кенә яшәргә кала. Чөнки ялгыш сүз ычкындырдыңмы, лагерь администрациясенә яки башка түрәләргә тел тидердеңме, нидән булса да зарландыңмы — аның ниндидер юллар белән тиешле җиренә, кешесенә барып ирешәсен көт тә тор. Дөрес, илле сигезенче статьялар үзара дус, тату яшәргә тырыша, ярдәмләшә. Әмма лагерь администрациясе алар арасындагы бу бердәмлекне җимерүне, аларның ни-нәрсә уйлап яшәгәнен белеп торуны максат итеп куйган, ахры. Шуңа күрә телеңне теш арасында тоту хәерлерәк. Дәшмәвең — алтын.

Шулай да Мотаһирның тыныч кына йөрүе, күбрәк кеше сүзенә колак салып, тыңлап утыруы берчакны илле сигезләр арасында шик тудыра. Аңа бу хакта доктор Буров әйтте.

— Нәбиуллин, синнән шикләнә башлаганнар бит әле,— диде ул беркөнне елмаеп.

— Кемнәр?

— Политиклар.

— Ни өчен?

— Чөнки син яшь. Шуңа аптырыйлар. Безнең бит күбебез өлкәннәр. Анары, син гел карап, тыңлап торасың, сүзгә катнашмыйсың икән.

— Мин бит авыл кешесе, доктор,— диде Мотаһир көрсенеп.— Ә алар...

— Анысы хак, әлбәттә,— дип килеште Буров уйчан гына.— Ләкин шикләнә башласалар... үзең аңлыйсың... Кичә берәү турыдан-туры, ул «бытовой» түгелме, дип сорады. Юк, мин әйтәм, ул да, мин дә бер статья — илле сигез дә ун. Делосын карый аласың.

— Билгеле,— диде Мотаһир җанланып.

— Ярар, курыкма, мин аларны ышандырдым шикелле. Тик үзең дә гел авыз йомып утырма, сүзгә катнаш. Русча да өйрәнерсең.

...Лагерь башлыгының кабинеты — тактадан корылган бүлмә. Өстәл, урындыклар — һәммәсе монда вакытлыча гына яшәү өчен әмәлләнгән. Хәрби киемле, таза гәүдәле начальник эшне тиз тотты.

— Син икенче участокка барырсың, Карговинога.

Мотаһир, каршы дәшә дип уйламасын өчен, мөмкин кадәр саграк, йомшаграк итеп, үзенең фикерен белдерүне кирәк тапты. Чөнки бер ияләшкән җирдән, ягъни, әгәр шулай әйтергә яраса, рәхәттән рәхәт эзләмиләр. Ә тегендә... алла белсен, ни язган.

— Гражданин начальник, мин Буров белән эшли идем...

Лагерь начальнигы, кәефе яхшы идеме, әллә Мотаһирның эшеннән канәгать булгангамы, каты бәрелмәде, орышмады. Көрәктәй кулының көчле, таза бармаклары белән өстәлдәге кәгазьгә ике тапкыр җиңелчә генә шапылдатып суккалап, тоткынның күзләренә туры карады, җиту чәчле зур башын чайкап алды.

— Анда да әйбәт булыр.

Ләкин сүзләрен, икеле-микеле аңлауга юл калдырмас өчен, аермачык итеп, тавышын күтәрә төшеп әйтте. Димәк, бу сүзләр Мотаһир өчен закон төсен ала.

Ул башкача сүз озайтып тормады, саубуллашып, кырт борылды да чыгып китте. Әзрәк баргач, үзенең баштагы курку-өркүен исенә төшерде. Димәк, аның эшендә гаеп-кыек юк икән әле. Бары аны икенче урынга гына күчерәләр. Һәр минут, һәр сәгать үзенең хокуксызлыгын тоеп, ут йотып яшәгән кеше өчен лагерь башлыгы бүлмәсеннән исән чыгу — ул зур бәхет.

Мотаһир Каргавинода стационар барын, анда да Ленинградтан килгән врач эшләвен, аның Киров эше буенча гаепләнүен белә иде. Буров әйткән

иде. Әмма ни өчен ул врачны эшеннән алганнар? Моны, әлбәттә, Мотаһир белми иде.

Буров янына кереп, ул үзен лагерь башлыгы чакыртуын һәм икенче участокка җибәрелүен әйтте.

— Беләм,— диде Буров күңелсез генә.

Моның шулай буласын Мотаһир үзе дә чамалаган иде. Чөнки аның турыдан-туры башлыгы Буров бит. Аның белән киңәшмичә эшләнмәгәндер бу эш. Күрәсең, шулай да Буров моңа риза түгел. Билгеле, кул астында шундый күндәм, ике әйткәнне көтми торган кеше булу — аның өчен хәзинә иде. Ләкин ул да тоткын, ул да башлыкларга каршы сүз әйтә алмый, аяк терәп каршы торырга кодрәте җитми. Шуңа күрә чыраеның төкселегe Мотаһирга ачудан түгел, ә бу ипле-тыйнак кешене үз янында калдыра алмау гаҗизләгеннән, үзенең көчсезлегеннән иде. Ирекле булса, ул кем белән эшләүне, кул астындагы медицина хезмәткәрләрен кемне кая урнаштыру-җибәрүне үзе хәл итәр иде. Ә монда...

Ниһаять, ул торып басты, бераз бөкрәя төшеп, ишекле-түрле йөренде. Мотаһирга утырырга кушты.

— Андагы врач — Кочетов — өеннән хат алган,— диде ул йөрүеннән туктап.— Хатыны үзенең икенче берәүгә тормышка чыгуы хакында язган. Билгеле, шундый хәбәр — кемгә шатлык? Кул астында спирт та бар. Ачуын, рәнҗүен, кайгысын, ничек телисең шулай аңла, басарга тырышып, Кочетов спирт эчкән. Ач кешегә күпме кирәк — спирт бик тиз башына киткән. Моны сизгәннәр һәм подвалга ябып куйганнар. Соңыннан, аның валерьянка һәм эфир да эчкән булуы ачыкланды. Менә шул. Эче януга түзә алмыйча, бераздан бу су сорый. Ләкин сакчы бирмәгән. Икенче көнне Кочетов җан тәслим кыла.

Буров, авыр сулап, янә кузгалды, ишекле-түрле йөренде. Тагын Мотаһир каршында тукталды. Аның эчкерсез күзләренә, тыныч һәм сагышлы йөзенә текәлде. Берсенә бу фаҗигане сөйләү, икенчесенә тыңлау җиңелдән түгел иде. Ни әйтсәң дә, алар Кочетов белән коллегалар, ягъни бер һөнәр ияләре бит.

— Мин моны ни өчен сөйләгәнне, шәт, аңлыйсыңдыр?

— Төшенәм, төшенәм.

Дулкынланудан врач гадәттәгегә караганда ныграк тотлыга башлады. Шулай да әйтергә теләгән фикерен ярты юлда калдырмады.

— Т-тормышыңда ни генә булса да, к-кем генә синнән килеп сораса да, хәтта таләп итсә дә — медицина кирәк-яраклары исән калырга тиеш, алар — изге. Аларга нәфесеңне сузма.

— Беләм, иптәш Буров.

Доктор кисәк, коры гына саубуллашкандай итте.

— Йә, уңышлар юлдаш булсын сиңа,— диде ул һәм урынына барып утырды.

Мотаһир үзенең вак-төяк әйберләрен җыештырды да хушлашып китеп барды.

Каргавинога алар дүрт кеше киттеләр. Икәве — сакчы, ә дүртенче кеше — Анохин фамилияле нәрәд бирүче. Элек ул полк командиры булган. Ә хәзер — кешеләрне эшкә бүлеп чыгару, ягъни бригаданы кая куу һәм башка вазифаларны башкара.

Каргавино — электән калган сал агызу участогы икән. Монда кыш көне агач кисәләр, язга чыккач сал агызу белән шөгыльләнәләр. Алты йөздән артык тоткын — күбесе шушы тирә кешеләре, әмма аралаш, ягъни сәяси дә, «бытовой» статьялар да бар — агач баракларда яшиләр. Мунча да бар.

Хәер, монда мунча гына түгел, больница да бар. Ә лагерьдан читтә — эшчеләр поселогы. Поселок дип йөртелсә дә, чынында исә ул авыл. Анда десятниклар, прорабалар тора. Алар яңа килгәннәрне эшкә өйрәтәләр.

Мотаһир бирелә мөстәкыйль рәвештә эшли башлады. Аның эш урыны — аерым барак. Стационарда туберкулез белән авыручы уникe кеше ята.

Амбулатор кабул итүне дә шунда үткәрә Мотаһир. Санитар хезмәтен үтәүче ярдәмчесе дә бар.

Әйләнә-тирә урман, сазлык, елгалар. Монда килүче-китүче юк диярлек. Өч айга бер килгән хат кына аның бертөрле тормышына әзрәк үзгәреш кертә.

Табигате җәен дә, кышын да матур. Җәй томанлырак та, су буенда салкынча һәм җиллерәк тә. Туган ягы белән чагыштырганда үзгәрәк. Ә черки... җәй көне ул мыжгып тора! Умартачы битлеге кебек нәрсә генә коткара, югыйсә...

Монда урман кисү, сал агызудан тыш, җимеш һәм сагыз җыюга да задание бар. Эше төрле булса да, тоткыннарның яшәү шартлары һәркайдагыча — шул ук рәттән тезелеп киткән баганалар, аларга сузылган чәнечкеле тимерчыбык, почмаклардагы каланчалар билгеләнгән һәм төгәл үтәлергә тиешле көн тәртибе, әлеге тәртипне саклаучы каты куллы һәм усал телле бәндәләр.

Көн артыннан көн, төн арты төн узып, ару гына эшләп ятканда, бу участок бетерелде һәм Мотаһирны Хетово дигән җиргә күчерделәр.

Аны Хетовога буксирга утыртып, су юлы белән илттеләр. Су уртасында кызыл маяк юл күрсәтеп калды. «Александр Пушкин» атлы бер пароход һәм җир тырмашып дигәндәй сал тартучы буксир очрады. Яр буенда балыкчылар күренә, учак төтенли. Сул як яр ишелә икән, таллары, чирәмнәре суга иелеп төшкән. Башларын суга салган таллар кебек, Мотаһирның да өметләре җимерелә.

Борыны белән су ертып, әкрен генә барган буксир яр буена килеп туктауга, Мотаһирга төшәргә әмер бирелде.

Монда тормыш су өстендә — баржада булды. Беренче карашка яшәү җиңел булыр шикелле иде. Мотаһирның беренче көне урнашу, танышу белән узды. Икенче көнне ул таң белән диярлек уянды. Бераз уяу яткач, палубага чыкты.

Кичә кич коеп яуган яңгырдан соң җир тулышып ята, дымсу. Су буенда салкынча. Үләннәр, агачлар куе яшел, сусыл. Тымызык кына җил исә. Күк йөзе аяз. Анда-санда гына юка, сирәк болытлар күренгәли. Кояш чыккан. Артта, үндарак, ул бөтен күк йөзен яктырткан. Аның нурлары әле су өстенә төшмәгән. Елга тыныч, өсте тип-тигез — алагаем зур көзге кебек. Теге як яр тирәсендә яшькелт таллар суда чагыла. Уң як ярда, комда, акчарлаклар ял итә. Бүген алар әле нишләптер очмый. Әмма табигать уянган, барча кошлар уянган: һәр тарафтан кош сайраулары ишетелә. Кошлар сайравы — үз авылының болыннарын, күл буен, әрәмәләрен хәтерләтә.

Мотаһирның да беразга гына булса да күңеле уяна, йөрәге җилкенә. Аның бар куанычы — шушы табигатьтә бит. Әнә шул гөнаһсыз кошларда. Аларга карагач, ничектер җанга җиңел булып китә. Юксынуы, кимсенүе, язмышына булган рәнҗүе басыла төшә. Үзен азга гына булса да кеше итеп тоя башлый. Күрәсең, авыл табигатендә, кош-корт һәм мал-туар арасында әвәрә килеп үскән кешегә болар тансыктыр.

Мотаһир суыктан калтыранса да әле һаман баржада басып тора, култыксага таянып, иртәнге табигатькә соклана. Әнә аның игътибарын су буенда йөргән ике акчарлак җәлеп итте. Чөнки алар янына әкрен генә бер мәче якынлаша. Акчарлакларның берсе аваз сала, ләкин чыелдап түгел, ә кыйкылдаган сыман итеп. Песи таш артына кача. Ул кузгалса, тегеләр янә күрә, ары китәләр. Бераздан алар очып ук киттеләр. Очканда канатлары белән һаваны ерган тавышка хәтле ишетелә.

Теге вакытта бу хәлләргә тарыйсын белсә, Мотаһир да шулай «очып» котылган булыр иде. Хәер, ул җиңел канатлы акчарлак түгел шул. Аны бәйләп тотучы җеп-баулар күп: гаиләсе, иле-җире... Кошлар кебек, кая теләсә шунда юл тота алмый. Аны әзәрлекләүчеләр дә, болары очса, икенчеләре килер әле, дип кул селтәп китүче гамьсез песи генә түгел шул. Шушы иртәнге хозурлыкка шактый озак карап торганнан соң, Мотаһир өмет белән: «Монда бик каты булмас, ахры, иншалла»,— дип куйды.

Әмма ул ялгышты.

Мотаһир бирелә ярты ел эшләде. Ләкин бу алты ай — алты елга торырлык иде, җелегенә үтте. Чөнки лагерь начальнигы — агылҗым күзле Семенов — бик әшәке кеше булып чыкты. Тиктомалга бәйләнә, кемгә генә дәшсә дә, авызында эт җыймас әшәке сүз иде бу конарсызның.

— Фәлән эшләмисез, төгән эшләмисез... Мин сезне ачка үтертәм...

Мескен тоткынның паегы болай да ташкаулчим — иртән ике йөз грамм ипи, балык ашы, бер кашык тары боткасы, кичен тагын шул ук ризык. Кайчагында ботка урынына бер кисәк балык эләгә. Ә эчәргә су бирмиләр. Семенов, ачка үтерермен әле, димәсә дә, аяк сузарга гына торалар, тоткыннарның эче эчкә ябышкан.

Дөрес, монда аерым бригадалар — стахановчылар бар. Алар тоткалы, тар гына фин пычкысы «лучковка» белән эшлиләр, көненә алты-җиде кубометр утын кисәләр. Аларга ашарга да күп бирелә, киез итек тә эләгә. Әмма алар илле сигезләр түгел, ә уголовный җинаятьчеләр. Уголовный димәктән, аларның да суына күрә — балыгы, авылына күрә — халыгы дигәндәй, араларында төрлесе бар: блатнойлар, шулерлар һәм, әлбәттә, «пахан» — лагерьдагы бөтен үз ишләрен кулында тотучы. Алар «очко»га кәрт тә уйныйлар, «чифир» да эчәләр. «Бугор»ларны, ягъни бригадирны санламыйча эшкә бармаган рецидивистлар теләсә ничек йөри: кыйный, талый, урлый... Иң кызыкканнары — ипи.

Дөрес, эшкә йөрүчеләре дә чиктән ашкан чая халык, тәкәллефләнеп тормыйлар. Илле сигезенче статья белән эләккәннәргә «болтун» дип кенә җибәрәләр. Янәсе, советка каршы коткы таратучылар.

Әйе, болар чын мәгънәсендә башкисәрләр: бернинди, беркемнән курыкмыйлар, теләсә нәрсә юнәтә алалар. Кыш көне итек кунычына энә, лезвие дә тыгып керәләр. Күрәсең, җирле халык, якын-тирә кешеләре белән дә элемтәләре әйбәт — «чифирга» гына канәгать булмыйча, кайчагында катырагын да «йотып» кайталар иде. Билгеле, лагерь начальнигы моны белә һәм эштән кайтучыларны үзе каршылап-барлап тора.

Бүген дә ул проходнойда иде. Ни өчендер Мотаһирны да үз янына чакыртты. Бәлки, якын көннәрдә тикшерү-фәлән белән киләселәрдер. Кыскасы, Мотаһир аның янында басып торырга мәҗбүр иде.

Семеновны берсе дә өнәми. Ул проходнойга килеп бастымы, кемнеңдер кыен ашыйсын көт тә тор. Бернинди гаебе булмаса да, Мотаһирга да җылы караш тәтеми иде.

Менә лагерь башлыгы, ябык колгасар адәм, исне яхшы сизүче овчарка кебек, алан-йолан карана торгач, корбанын тапты: берәүне сафтан чакырып чыгарды.

— Караваев, кил бире!

Таза гына гәүдәле, сары кашлары астыннан усал күзләре елтырап торган тоткын, эленке-салынкы кыяфәт белән аның каршына килеп басты, ләммим сүз дәшмәде. Әмма моны Мотаһир да сизде — ул салмыш иде.

— Син нәрсә, Караваев, исерекме?

Тоткын каш астыннан гына хуҗага карап алды. Мөгаен, ул үзенең ни хәлдә икәнен начальник сизмәс дип уйлагандыр. Сизде. Димәк, яшереп торудан, качышлы уйнаудан файда юк. Караваев кисәк кенә башын күтәреп, сул кулы белән бөеренә таянды да, аякларын аерыбрак басты. Тавышы көр чыкты:

— Ә нигә, гражданин начальник, эчмәскә? Бүген — бәйрәм!

Лагерь начальнигы мондый борылыш көтмәгән иде, ахры. Бер мәлгә аптырап калды. Тавышы йомшарды, ачуы басыла төшкән кебек булды.

— Нинди бәйрәм?

Ул хәтта тиз генә хәтер сандыгын барлап, бу көннәрдә нинди революцион һәм тарихи бәйрәмнәр барын исенә төшерергә тырышты. Әллә берәрсенең туган көне?.. Бәлки, даһи юлбашчыныңдыр?.. Юк, узган елның декабрендә иде бит алтмышы тулган көне... Күпме генә азапланмасын, бүген нинди бәйрәм көн икәнен белә алмады начальник, шыр җибәрә язды.

— Нинди бәйрәм соң бүген?— дип кабатлап сорады ул.

Шулчак Караваев аның башына күсәк белән органдай итте:

— Ниндиме? Сине дөмеккән диделәр!

Начальник, үз-үзен белештермичә, яшелле-мөшелле тавыш белән акырып җибәрде:

— Сволочь! Утыз тәүлек карцер сиңа!

Аның авызыннан чәчрәп чыккан төкерекләр тоткынның йөзенә кадәр сибелде. Ә Караваев, бер тотынгач, тыела алмыйча каһкаһәле көлә һәм аны мыскыл итә иде.

— Ну, начальник, әйбәт тә кеше инде син. Кызганыч, аллаһе тәгалә әҗәл генә бирми үзеңә.

— Молчать!

— Үзеңне мактыйм бит. Начальник, өстә тагын бераз.

— Молчи, сволочь!

— Нигә утыз гына? Иллене бирмисеңме? Илле әйбәтрәк бит...

Семенов, үз янында торган сакчыга борылып, җикерде:

— Алыгыз шуны!

## XV

Эшләр бер көйсезләнсә, аның гел шулай итәсен көт тә тор икән.

Алты айдан соң Мотаһирны янә икенче урынга күчерделәр. Бу лагерьның начальнигы Маместов та Семенов белән бер калыптан сугылган булып чыкты.

Алар үзәк участоктан биш чакрымда яшиләр иде. Ике йөзләп кеше, конвойсыз, барысы да — көнкүреш статьясындагы тоткын. Беркөнне Мотаһирга берьюлы җиде чирле тоткын килде.

— Яле, күлмәгеңне сал,— диде Мотаһир кабул итү бүлмәсенә иң беренче кергән, күзләре эчкә баткан, яңак сөякләре чыгып торган авыруга.

Тоткынның кабыргалары гармун күрүге сыман беленеп тора, муены нәзек, озын куллары да коры сөяк, тәнендә чыпчык чукырлык та ите юк.

— Борыл. Чалбарыңны ычкындыр.

Мотаһир аның утраксасын тотып карады. Утыру урынында ите юк. Димәк, моның эшләргә хәле дә юк. Авитаминоз. Ашау начарга күрә ябык. «Әй, бичара,— дип уфтанып куйды Мотаһир,— үз-үзен йөртергә дә хәле булмасын инде кешенең».

— Ярар, киен.

Тоткын чалбарын төймәләде, күлмәген киде. Мотаһир:

— Мин сине үзәккә, больницага җибәрәм,— диде.

Монысы артыннан тагын алты тоткын әпен-төпен атлап керде. Аларның дә хәле нәкъ беренче кергәннеке кебек аяныч — как сөяккә калганнар иде. Шулай итеп, Мотаһир бер көнне җиде кешене эштән азат итте. Чөнки алар тәмам өшәнгән, йончыган, чыкмаган җаннары гына калган иде.

— Рәхмәт,— диешеп, баракта калдылар.

Моның нәтиҗәсе үзен озак көттермәде.

Мотаһир ике-өч сәгатьтән вахтага кергән иде, дежурный аңа кырын гына карап:

— Сиңа Маместов өч тәүлек арест бирә,— диде.

Мотаһир аптырап китте. Башта, әллә шаяртамы, дип уйлады. Юк, йөзе җитди. «Бәй, ничек алай арест... Бер дә гаеп-кыегым юк иде шикелле».

— Ни өчен?— дип сорады ул.

— Теге җиде кешене эштән азат иткәнең өчен.

— Алар, чыннан да, авыру бит.

Дежурный моңа исе китмәде, билгеле.

— Син аны миңа түгел, Маместовның үзенә кереп әйт.

Монда сүз көрәштереп торуның файдасыз икәнен Мотаһир аңлый иде. Шунлыктан Маместовка керде.

Мотаһир, дөресен әйтергә кирәк, күпшек куллы бу кешене беренче күрүдә үк өнәмәде. Маместов тәбәнәк юантык гәүдәле, арт саны хатынкызныкыдай җәенке, ә үзенең борын астында мыегы бар. Дөньясы утка көйсен, миңа җылысы тисен, дип яшәүче адәм. Кичә генә ашханәдә пешекче: «Йомырка порошогы пешергәнне әллә каян сизә, имансыз, керә дә бер калаен үзенә илтергә куша».— дип зар елап торды. Менә шундыйрак кеше иде лагерь начальнигы Маместов. Ләкин нишләмәк кирәк, телисеңметеләмисеңме, кереп баш иярга, сәлам бирергә тиешсең.

— Исәнмесез, гражданин начальник.

Маместов кабинетында нидер язып утыра иде. Ул урыныннан кымшанмады гына түгел, хәтта Мотаһирның сәламен дә алмады. Төсен бозып, таларга торган этәч шикелле, эре генә әйтә куйды:

— Нишләп сез бүген җиде кешене эштән азат иттегез?

Мотаһир мөмкин кадәр итагатьле булырга тырышты, йомшак кына үз фикерен әйтте:

— Гражданин начальник, авырулар бик күп.

— Шуннан?

— Мин аларны күрәләтә эшкә җибәрә алмыйм. Аларның кеше булырлыгы калмаган. Алар...

Маместов тоткынның сүзен кырт кисте:

— Алайса синең үзеңә ял итәргә туры килер... изоляторда. Аңладыңмы?

Мотаһир, начальниктан ир затына хас булмаган тир исе килүен сизеп, борынын жыерды. Маместовның сүзен колагына элмичә, үз туксанын тәкрарлады. Чөнки икесе дә бу җәзаның ни өчен бирелүен беләләр бит.

— Аларны үзәк участокка илтергә кирәк.

— Ат юк,— дип кырт кисте Маместов.

Бәхәс куертып тору файдасыз иде. Шулай да Мотаһир, тәвәккәлләп һәм үз сүзен аяк астына салып таптамас өчен, үзәккә барып кайтырга рөхсәт сорады.

— Мин үзәк больницага барам. Пропуск бирегез.

— Бар соң, бар...— диде.

Гәрчә җирәнгеч шикелле әйтелсә дә, шул сүзне ишетү белән Мотаһир, пропуск алып, кабинеттан чыгып китте. Үзе эчтән генә, нәҗес, дип Маместовны сүкте.

Үзәк больницага барса, доктор Золотилов белән ничек тә бер әмәлен табарга өметләнә иде ул. Ә врач — исеме җисеменә туры килерлек алтын кеше иде. Буров кебек, ул да Мотаһирга хәерхаһ, аның эшеннән разый иде...

Биш чакрым ара ерак җир түгел.

Билгеле, ирektәге, ашау-эчүе рәтле булган кешегә ул бер сәгатьлек юл. Ә Мотаһирның үзенең дә теге авырулардан әллә ни артык җире юк, хәлсез, ач, җитмәсә, Маместов җәберләп, теңкәсенә тиеп тора — биш чакрымга ике сәгатькә якын вакыт сарыф итте. Хәер, ул бик ашыкмады да.

Март ае — туган җиреңдә яз ае инде ул. Мартта кояш мәрхәмәтле карый башлый: кар өстен юкарта, тамчылар тамдыра, чыпчык эчәрдәй сулар хасил итә, барча тереклек иянәренә җан кертә, дәрт-дәрман бирә. Дөрес, әле төнлә салкынча, иртән — томан төшә, бураннар да еш кабатлана, юеш кар да мул ява. Ә шулай да барыбер язны һәр тарафтан тоемлый аласың. Илеңдә шулай.

Ә монда язның исе дә юк. Бездәге кыш уртасы кебек. Их, бигрәкләр дә сагындыра шул туган җир?! Бигрәкләр дә телгәләнә икән шул бәгырь, йөрәкләргә кан сава икән.

Күңелендә туган сагыну хисләре үкенү-әрнү белән алмашына. Ни өчен монда, җәһәннәмдә җәфа чигә ул? Кем аркасында? Кемнәр ашады аның башын? Кемнәр? Нигә аны чит җирләргә олактырдылар? Газиз башын тәмугларга илтеп тыктылар?!

Мотаһирның хәтеренә утыз җиденче елның козендә булган бер вакыйга килде. Аңа эшкә, ашлык сугарга әйткәннәр иде. Барды. Ашлык сугу маши-

насы янында халык мәш килә. Читтәрәк трактор дөпелдәп эшләп утыра. Авыл өчен гадәти, күңелле бер манзара. Ләкин батырып эшләргә дә кирәк.

Өлкәнрәк бер абзый аңа әйтте:

— Син, Мотаһир, барабанга биреп торырсың.

— Ярар,— диде Мотаһир карусыз гына.

Эшкә тотындылар. Ут өертәләр. Берзаман, тарантаска утырып, ике рәис — авыл советы һәм колхоз рәисе килеп чыкты. Колхозныкы тарантастан төште дә, әлеге өлкән абзыйны дәшеп, Мотаһир янында туктады, сорау бирде:

— Нигә моны барабанга куйдың?

— Нигә?— дип сорады абзый үз чиратында.

— Ватса?

— Китсәнә, сөйләмә юкны,— диде абзый ошатмыйча һәм кул селтәп китмәкче үк булды.

Әмма рәис барыбер үзенекен итте: Мотаһирны аннан алып, салам өюгә куйдыртты.

Зәһлүл кисәтүе дә булды. Шулардан нәтиҗә ясарга, ни дә булса кылырга тиеш иде бит Мотаһир. Ә нишләргә тиеш иде соң ул? Нишләргә? Әйе, белде, сизде. Ә ни мәгънә?

Мотаһир атлавын дәвам итә. Уйлары чуала. Авылы әйбәт яклары белән дә, начар яклары (юк, алай әйтергә теле әйләнми) белән дә гел истә. Аптыраганнан, авыз эченнән җыр да көйли кайчак. Әллә җыр да түгел инде. Уйлы-саташулы халәттә ул. Каяндыр укыганмы, ишеткәнме сүзләр хәтеренә килә. Юк, бу — кешенеке түгел, үзе чыгарган, үз башыннан кичкән хәсрәте шигырь булып чыга, мөнәҗәт булып чыга ахры.

Күрелгән төш кеби үткән
Гомерләрне сагынамын,
Яныт хәсрәт уты белән
Күздән яшьләр агызамын.
Усал язмыш килеп башка
Авырлыклар өеләдер.
Бичара, кызганыч ул, дип
Дус-ишләрем көенәдер.
Туган илне, газиз җирне
Эзләсәң дә табып булмый.
Хәләл ашны авыр хәсрәт,
Ачы яшьсез кабып булмый.

Әйе, булмый... Атлап та булмый... Ул туктап ук кала. Ә атларга кирәк. Алга барырга кирәк. Кирәк, кирәк!

Үзәккә якынлашкан саен Мотаһирның уйлары доктор Золотилов тирәсендә чуала башлады. Ул — Мотаһир өчен башлык кына түгел, ә олы кеше, дөньяны күбрәк аңлый торган иптәш буларак та кадерле иде. Аның киңәшләрен, үгет-нәсихәтен Мотаһир үлгәндә дә онытасы түгел. Беренче көнне үк ул Мотаһирга төшендерде:

— Кеше арасында сак бул. Беркайчан да чит адәмнәрнең адресын алма. Үзеңнекен дә аларга бирмә. Хатларыңны да саклама. Алла сакланганны сакларм ын, дигән.

Моны Мотаһир үзе дә чамалый: чөнки тентү кайчан туры килсә, шунда була. Аннары, кайчандыр әтисе әйткән сүзләр дә гел хәтерендә: «Юлга чыксаң, кая барганыңны, динеңне һәм кесәңдә күпме акчаң барын башкаларга әйтмә».

Монда нәкъ шул рәвешле яшәлә дә инде. Тоткында артык әйбер юк. Дуслык та юк. Кешеләрне белмисең, синең өчен беркем янмый да, көйми дә. Ә алып китүләре мөмкин, анысы — теләсә кайчан була.

Золотилов кат-кат әйтте Мотаһирга:

— Кешеләргә ягымлы бул. Ләкин әйбер алма. Пускай булсын кызыл җиңле күлмәгең, кызыл җиңле бушлатың, ләкин түз. Ни дә булса сатып та алма.

Золотилов бу хакта юкка гына кисәтми.

Чөнки монда — лагерьда да үзенә күрә базар бар, акча да йөри. Алты йөз грамм ипине, мәсәлән, утыз сумга сатып була.

Мотаһир Золотилов янына керде. Юка гәүдәле, озынча буйлы доктор урыныннан торып, бераз иелә төшеп, Мотаһирга кулын суздьı, урын күрсәтте.

— Йә, хәлләр ничек? Сөйләп җибәр.

— Шәптән түгел, доктор. Эшләр көйсез әле.

— Ни булды?

— Миңа Мамесгов өч тәүлек арест бирде.

— Ни өчен?

— Җиде кешене эштән азат иткән идем.

— Әт икән,— диде Золотилов ачу белән һәм, мәсьәләне мизгел эчендә хәл итеп, әйтте:— Син болай ит. Үзең шифаханәгә кереп ят.

— Ничек? Мин бит сәламәт әлегә.

— Курыкма,— диде Золотилов Мотаһирны юатып,— үз өстемә алам.

— Шулай да...

Золотилов аның кыяфәтеннән ризасызлык белдерде, җәллөп әйтте:

— Хаста түгел, имеш. Коры сөяк инде...

Монысын гына Мотаһир үзе дә белә. Авыр эш эшләмәгәнгә генә үзүзен сөйрәп йөртә бит. Аннары... Нишләсен, икенең берсен сайларга кирәк: йә үзенә авырулар янына кереп ятарга, йә Мамесгов биргән өч тәүлекне изоляторда уздырырга, җәбер-золымына түзеп торырга... Ә стационардан чыккач, тагын аның каршына барасы була. «Алай да безгә нужа, болай да безгә нужа...» Мотаһир ике юлның беренчесен сайлады. Ничек тә җан асрарга кирәк иде.

Золотилов аның урынына яңа кеше табып куйды. Әмма атна үтүгә үк Мамесгов тагын пырдымсызлана, аңа да өч тәүлек чәпи һәм изоляторга ябып куя. Ләкин вакыйгалар шул хәтле тиз куера, Мамесгов моның ахыры ни белән бетәсен уйлап-аңышып өлгерә алмый.

Икенче көнне Архангельскидан лагерьлар идарәсенең санитария бүлеге начальнигы Воробей килеп төште. Золотилов белән бергә ул стационарны карап йөрде. Койкаларның берсендә Мотаһирны күреп (әледән-әле килеп йөргәнлектән, ул аны таный иде), аптырап, сорау бирде:

— Нәрсә, Нәбиуллин, авырдыкмыни? Катымы?

— Алай куркыныч түгел.

Золотилов та сүзгә кушылды:

— Ул арган. Мамесгов белән дә килешә алмаганнар.

— Ни өчен?— дип Воробей Мотаһирга таба борылды.— Эш нидә?

— Мин җиде кешене эштән азат иткән идем. Мамесгов ат бирмәде. Ә аларны шифаханәгә салырга кирәк иде. Икесе үлгән дә инде.

— Ничек?— диде Воробей һәм карашын Золотиловка юнәлтте.

— Менә шулай.

— Нәбиуллинның моңарчы кисәтү-мазар алганын хәтерләмим,— диде Воробей чыгып барышлый. Золотилов аның сүзен җөпләде:

— Мин аның эшеннән канәгать.

— Киттек Мамесговка.

Олы начальник эшне тиз тотты: ярты сәгатьтән Мамесгов участогына килеп төштеләр.

Проходнойда Воробей:

— Мамесгов үзендәме?— дип сорады.

— Юк.

— Ә Попов үзендәме?— дип сорады Золотилов Мотаһир урынына куйган медицина хезмәткәрен истә тотып.

— Юк,— диде дежурный.

Воробей инде тузына ук башлады. Ләкин дежурный аның сүзен бүлдерде.

— Попов изоляторда утыра.

— Ничек?—Золотиловның күзлеге маңгаена менде.—Ни өчен?
— Белмибез.
— Чыгарыгыз!—диде Воробей ярсып.—Хәзер үк.
Золотилов аларга Воробейның кем икәнен аңлатып тормады, чөнки тегеләр үзләре дә сукыр түгел, таныйлар. Ләкин Маместов җаннарын ашаганга күрә Поповны чыгарырга да шөллиләр. Ахырда, Воробейның Архангельскидан ук килгән кеше булуы һәм фәрман тонында әйтелгән сүз үзенекен итте: Поповны чыгардылар.
Золотилов берочтан Мотаһир эштән азат иткән җиде тоткынның язмышы белән кызыксынды.
Попов көрсенеп куйды:
— Аларның икесе үлде инде,—диде, бая Мотаһир әйткәнне раслап.
Воробей белән Золотилов кире үзәк участокка кайтып киттеләр һәм мондагы хәлләрне төкми-чәчми лагерь начальнигына җиткерделәр.
Кеше үлү—һәр җирдә вакыйга. Кем генә булмасын, ул адәм баласы. Лагерьда да, гәрчә бернинди хокуклары булмаса да, аларны баш саны белән генә, дело номерлары белән генә исәпләп йөртсәләр дә, һәр тоткын өчен кемдер җавап бирә. Эшче куллар кирәк. Лагерь начальнигы исә барысы өчен дә җаваплы.
— Нинди хәл ул?—диде үз кул астындагы Маместовның кыланышларына ышанырга да, ышанмаска да белмичә аптырап, лагерь начальнигы.—Мин аның белән үзем сөйләшермен!..

*Ахыры киләсе санда*

*Киләсе санда:*

**Мирсәет Солтангалиев**

## МИН ЯЛГЫШТЫММЫ?

...Моңа бәйле рәвештә төркиләр проблемасы тагын да кискенләшә һәм кискенләшәчәк тә. Шуңа күрә совет власте һәм партия бу юнәлештә максатчан эш җәелдерер һәм төрки халыкларны ыру-кабиләләренә карап вак-вак өлешләргә бүлү сәясәтенә чик куелыр, дип өметләндем. Ә болай эшләмәгәндә, реакция килгән очракта, вак «мөстәкыйль» төрки дәүләтләрне берәм-берәм кабып йоту һич тә кыен булмаячак... Менә шушы өч нәрсәдән чыгып... Советлар Союзы составына кергән, дәүләт капитализмына нигезләнгән халык-демократик республикасы рәвешендәге Туран дәүләтен төзү фикерен алга сөрдем... Эшләр болайга борылганда, планым буенча, кораллы күтәрелеш оештыру һәм шушы максатларда мөстәкыйль Туран республикасы өндәмәсен күтәрү, үзен ничек дип атаса да, капиталистик юлдан киткән хакимияткә каршы юнәлдерелер һәм анда Россиядән тулысынча мөстәкыйль дәүләт булып аерылып чыгу таләбе куелыр иде...

# ШИГЪРИЯТ

## Зиннур Мансуров

### Соңгы сәхнәгә бару

*1954 ел, май*

Каеннарны ләйсән коендырган,
калмагандыр җирдә кер-кинә!..
Җәяүлисе иткән җилкәнмени —
Сәйдәш бара Арча кырына.

Күренмидер хәтта күләгәсе,
аксөяктәй актан киенгән.
Күңелкәе генә көйләнә —
көтмәгәндә көзчә көй иңгән.

Күпмеләре, кәгазь күрмиенчә,
күңеленә кире күмелгән...
Сәйдәшемне соңгы сәхнәсенә
алып бара язмыш кем белән?!.

Көязләнгән язны көнләштереп,
Көлбикәдәй кыз да ияргән...
Салаватын әйтеп сәламләшә
кырмыскага башын ияр җан.

Кочаклашкан саен кәчтүменең
иңбашында аз-маз тап кала.
Урамнарны урап буранлаган
чия чәчәкләре... таптала!..

Ышандырмый: шушы кешеләрдән
Сәйдәш дусты күргән күп әләк?!.
Кәпрәймичә бара композитор,
якасында... кара күбәләк.

Кочегарга кадәр кочак җәя
кардәшләрчә ихлас үз күреп.

---

Зиннур МАНСУРОВ (1949) — *шагыйрь. «Кул бирәм», «Йөз суы», «Юлын белгән арымас» һ. б. татар һәм рус телләрендә нәшер ителгән шигырь вә публицистика китаплары авторы. Казанда яши.*

Сыланучан салкын сәламнәрне
нигә җибәрмәскә уздырып?!

Исемлесе, исәр, исереге
исәнләшеп китә көр генә.
Җәяүлисе иткән җилкәнмени —
Сәйдәш бара Арча кырына.

Саладагы сыман сәламләшә
Бәгырь белән бөтен башкала.
Кочаклашкан саен кәчтүменең
иңбашында аз-маз тап кала.

Фаразлыймын: ап-ак фәрештәнең
канатына кемдер... кул сөртә.
«Череккүл»нең кара чорларында
сөттә коенганнар куркыта...

Күбәләккә ашкан күңелдәше
күтәрмәгән нинди кер генә!..
Белми кызый, Бәгырь, болай озак
баруыңны Арча кырына.

Керләнмәгән соңгы пәйгамбәрдәй,
килә Сәйдәш кара еллардан.
Чайкалдыра чак-чак, чайкалдыра
байтак чаяларны егар дан...

Сәйранлыкка чыккан «сыйлаучылар»
сәламләшеп китә чатларда.
Кочаклашкан саен кәчтүменең
иңбашында арта таплар да.

Чәчәкләрен койган чиялекнең
итәгендә әллә кар ята?!.
Самимилек халык сөеклесен
сөя-сөя шулай каралта.

...Каберстанның кара каргалары
каркылдашып куя көр генә.
Җәяүлисе иткән җилкәнмени —
Сәйдәш бара Арча кырына...

## Халык санын алган чакта

Күкрәүләргә күнгән күңелемне
айкалдырдың әле, Ай кызы!..
Милләтеңне гүзәл мөлкәтеннән
«тарлык-татарлык»мы аерды?

Нәфесләнеп нәсел-нәсәбеңнең
бергә туплар чакта бар көчен,
сөелүдән сөргән сантыйларча
Мәрьям анабызның варисын.

...Шушы төндә, ахры, үги ана
яфрагына иртә кар яуган...
Таралгандыр тату татарыбыз
үзен-үзе шулай каргаудан.

«Татарва»ны төрле тарафларда
Сак-Сок сагынуы саргайта.
Йөрәккәең өшер ераклыкка
сөрелгәнсең, сеңлем, син хәтта.

Барлanганда милләт балалары,
тагын алынмыйсың исәпкә!
Түгәрәкләү өчен түгелгәнне,
җитми бирәү — булмый нишләп тә.

Бәгырьдәге бәйдә бәргәләнгән
балаларың җитми, Ай кызы!
Мәхрүмият сиңа мәхәббәттән
табышмыйча «Талак!» әйттерде.

Киленлеккә сине килешкәндә,
түләр иде татар ун калым.
Сөрелмәгән булса Сөембикә,
чукындыртмый калса угланын?!.

Болгарымның кызы булмагандыр
кемнең генә «асыл ярты»сы.
Тәгәрәмәс өчен түшәгеннән,
өммәтсезләр сине «яр» итте.

Кызларыңны кяфер... кәнизәккә
әйләндергән — яңа түл кирәк...
Барланганда милләт балалары,
булса икән дөньяң түгәрәк.

Оланкайлар кая олагышкан —
көтелгәннән күпкә ким чыга.
Хиссезләнеп беткән хисапчылар
санамаган сине кешегә.

Мәэюсләнгән күзен мөлдерәтеп,
сиңа бага, сеңлем, чал кавем.
Күрәләтә нәсел корыганда,
нигә кирәк гыйффәт саклавың?!

Көтмәгәндә кызып китүемә
ачуланма инде, Ай кызы!
Барланганда милләт балалары,
күңелемне кайгы айкады.

Сөембикә, юньләп сөелмичә,
балитәген эттән ашатты...
Җитеп торыр, җаным, җитеп торыр —
тансыклатып тагын таң атты.

## Хуҗасына охшаш бакча карачкысы

Күрмәгәнмен шундый карачкыны,
киенүе милли — бак кына!
Курыкмаган үзе каргалудан —
чалма урап куйган башына...

Җилкәсеннән җилме җилтерәтте,
шаяннарча ихлас үз күреп.
Каршымдагы милли карачкыдан
агач... тәре калды утырып.

## Чиге күренмәгән юану

. . . . . . . . . . . . . . .

Ачлык... Түзәрбез —
ил белән бергә.
Изү... Түзәрбез —
ил белән бергә.
Кырыш... Түзәрбез —
ил белән бергә.
Сугыш... Түзәрбез —
ил белән бергә.
Юклык... Түзәрбез —
ил белән бергә.
Тетрәү... Түзәрбез —
ил белән бергә,
ил белән бергә —
шулай... гомергә?!.

## Сатыш кызы Инҗилә

Төшләремне искә төшергәлим:
күрше йортка ак бәз, җеп керттем...
Уйламаган чакта Айбулатның
җирләп куйдык хәләл җефетен.

Хәтерлимен тере хәсрәтләрне —
игез бала калды биләүдә.
Иртәгесен ятим эргәдәшкә
сөтсез кермәгәндер берәү дә.

Нурсызланып калды нарасыйлар —
җанга ятып бетми ят кадер.
...Каенсарда ана күкрәгенең
сөте һаман саркып ятадыр...

Айбулатның җаны айкалгандыр —
тинтерәтте тәкъдир тол башын.

Хатыннарның аһы хәтеремдә:
«Димлик мәллә... шәфкать туташын?!»

Табышмактай авыл табибәсе,
шундый садә, шундый яшь иде!..
Ятсындырмый гына, ятимлекне
шул кыз... йөрәгенә яшерде.

Инҗиләбез күктән иңмәгәндер,
килгән иде бугай Сатыштан.
Сөйләделәр иртән сөенешеп:
«Кызның күкрәгенә... сөт төшкән!
Сөт төшкән!!.»

Гаҗәпләнде хәтта гайбәтчеләр:
«Сөбханалла, нинди могҗиза!»
Үксезләрең, дөнья, үкерешеп,
елагандыр шулчак мең өйдә...

...«Кызык хәл»не сөйлим кыз-кыркынга,
кулын гына селти: «Әй ялган...»
Хәятемнең сәер хатирәсе
әллә... әкияткә әйләнгән?!

## Ишек тоткасы

*Р. Ш.га — дусларча*

Күләгәдәй кермим күңеленә,
кыяфәтең белән җыйнак син.
Гадәтеңнән генә газапланам:
ишек тоткалары җыясың...

Гыйбрәтләрдән торган гомеремдә
эчтән әйттем күпме төртмә сүз.
Эшмәкәрдәй ачар ишекләрнең
нихәтлесе булды тоткасыз.

Дәрәҗәле генә дәрелфөнүн
ишекләрен кагар булсам да,
тоткаларын алып, тоткарладың:
буталмасын, диеп, бу бәндә.

Рәсәйдәге татар ристанына
ишек бавы кыйммәт болай да.
(Тоткарларга Аксак Тимерләрне
синдәй бирәү булса Болгарда!..)

Залимано зәһәр заманнарда
мәсҗет ишегенә тартылдым.
Каракларча капылт каерылган
тотка тишегенә тап булдым.

Каршылаучы, тыштан караганда,
дәшеп тора төсле: «Мәрхәбә!»
Эш-йомышым төшкән ишекләрдән
сөрдең мине ничә мәртәбә.

Арттырмыйча әйтәм: артишекккә
барсам — тагын миңа киртә син.
Тотлыктыргыч затлы тоткаларны
күпкә алдан каерып китәсең.

Ышкынмыймын бәхет ишегенә —
минем өчен ул да тоткасыз.
Заманында солдат зинданына
кереп чыктым, шөкер, тоткарсыз.

Кардәшедәй күреп каршыламый
дөнья йортындагы ишекләр.
Тәрәзәдән йөрмим тәреләнеп,
(үҗәтләргә андый тишек бар).

Шагыйрьлектән килер шөгыләндә,
ай-һай, туган, төштең төпкә син.
Ышанырмын: оҗмах ишегенең
йолкып кайтсаң сигез тоткасын.

## Тәрәзә «осталары»

Яурупага тәрәзәбез
калды Петр остадин.
Өлгеләрен тимер илә
челтәрләде Сталин.
«Демократ»ым! Инде шуны
капкачларга син алын...

## Тагын «урысныкы» турында

*«...Само слово «секс» имеет*
*чисто русское происхождение!»*

М. Мишин

Урысныкы иде урманыбыз,
кыш, чәй, мунча — бар да аныкы.
Гайрәтлеләр хәтта гаурәтеңне
кисеп алыр... Максат аныкмы?

Йомгаклыйлар күз дә йоммыенча:
«Безнең милләт сүзе... чип-чиста!»
Аракысы булгач урысныкы,
алардандыр, бәлки, «секс» та?!

Раслагандыр азгын Распутины
гомер буе... зөфаф кичендә.
Кыз-хатынга, бахыр, кызганмаган
тәнендәге соңгы көчен дә...

Ышанмыймын «секс эше»гезгә,
китер дәлилләрнең мең төрен.
Гыйш-гашрәттә йөзгән гыйззәтлегез —
Әби патша басса мөһерен,
бәлки...

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

## Гәрәй Рәхим

# ҖӘГҮР ДӘДӘЙ ДӘМӘКЛӘРЕ

Бу дәмәкләр ничек туды?

*Безнең авылның рәсми исеме Федотовка[1] булса да, халык телендә аны Аланлык дип йөртәләр. Саф керәшен авылы буларак, бездә чит телләрдән кергән алынма сүзләр фонетик яктан бик нык татарчалаштырыла, дөресрәге, төркиләштерелә. Әйтик, татар теленә ислам дине белән килеп кергән ф, в, х, һ авазлары безнең авыл телендә бөтенләй юк. Гаеп итмәгәз, без «файда» сүзен «пайда», «хәбәр»не «кабәр», «Фатыйма»ны «Патима», «Фатыйх»ны «Патик», «Христос»ны «Кристус», «хач»ны «кач», «колхоз»ны «калкуз», «һава»ны «ауа», «хәл»не «әл», «дәфтәр»не «дәптәр» дип сөйләшәбез. Ни өчен «гаеп итмәгез» дим, чөнки без башкача сөйләшә белмибез. Шулай ук төрки телләргә хас булганча, бездә сүз «р» авазыннан яки «ст» дип башланып китә алмый. Бездә «рәсем» — «эрәсем», «рәхәт» — «ыракать», «Родион» — «Ырадибан» яки «Ырайман», «рама» — «ырам», «стакан» — «ыстакан», «Степан» — «Ычтапан».*

*Мондый төркиләштерүләр кеше исемнәрен әйткәндә аеруча нык сизелә. Билгеле булганча, христианлаштырылган татарлар, ягъни керәшеннәр, рәсми төстә урыстан кергән исемнәр йөртәләр. Безнең авыл кешеләре арасында үз исемнәрен түбәндәге үзгәртелмешләрдә генә куллану инде тәмам ныгып өлгергән: без «Гурьян»га «Гурҗән», «Прокопий»га «Купей», «Ульяна»га «Үлук», «Арина»га «Үркәй», «Кристина»га «Керечтей», «Корнелий»га «Курый», «Антон»га «Унтый», «Татьяна»га «Татук», «Ефим»га «Җәпей», «Лев»ка «Элуп», «Терентей»га «Терәнтей», «Кирилл»га «Киркук» яки «Кируш», «Дарья»га «Дарҗа», «Мария»гә «Марҗа» дип дәшәбез.*

*Гадәттә, һәр авылда бер үк исемдә ике яки берничә кеше була. Бу бездә дә шулай. Әмма безнең авылда аларны тәгаен аерып йөртү һәм мөрәҗәгать иткәндә бер-берсен бутамау өчен игезәк исемлеләрнең һәркайсына аерым-аерым исем әйтелеше тагалар. Әйтик, авылдагы ике «Кузьма»ның берсен «Көҗмә» дип, икенчесен «Көҗей» дип йөртәләр. «Афанасий»ларның берсе «Апанас», берсе «Әппин» була, «Константин»нар — «Кечтәнтей» һәм «Кучтә», «Анастасия»ләр — «Нача» белән «Начтук» дип аерып йөртелә.*

---

Гәрәй РӘХИМ (1941) — *шагыйрь, прозаик, драматург; татар һәм рус телләрендәге утызга якын китап авторы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты.*

[1] Татарстан ССРның Лениногорск районы.

Бер ук исем өч һәм аннан да кубрәк кешегә бирелсә дә, аптырап калмый безнекеләр, һәрберсен аерып булырлык, бер-берсе белән бутамаслык исемнәр табалар. Элегрәк авылда «Александра» дигән хатын-кыз исеме аеруча куп иде. Бер ук чорда бишәр Александра булуын хәтерлим мин. Әмма авыл кешеләре аларны биш төрле исем белән йөртә: «Әләксандыра», «Сандыра», «Сандырый», «Санук», «Әләч». Дурт «Григорий»ны «Гөргөри», «Гурей», «Герук», «Гөрей» дип аерып йөртәләр.

Беренче ишетүче кешегә безнең авыл кешеләренең әнә шулай сөйләшүен тыңлап тору үзенә бер мәзәк булып тоелыр. Әмма мин авылыбыз телен татар халкының борынгы төркилек сыйфаты иң нык сакланып калган бер кыйпылчыгы дип карар идем.

Һәркайдагыча, безнең авылда да үзенчәлекле кешеләр, җор телле картлар бар. Хәер, Татарстанның безнең авыл урнашкан Кама арты төбәгендә барлыкка килгән гаять зур промышленность комплексының КамАЗлары, АлАЗлары, АЭСлары, нефть һәм нефтехимия предприятиеләре тирә-як авыллар һәм районнардагы балигъ булган һәр яшь кешене үз цехларына һәм «бөтен уңайлыклары да булган» шәһәр фатирларына йота барган бу заманда, безнең авылда да әнә шул карт-корылар гына калып бара бугай инде. Кем әйтмешли, кызганыч, әмма факт. Әнә шундый «соңгы данә» картларның берсе минем бу дәмәкләрем туууга төп сәбәпче булды. Ул кеше — Кузьмин Егор Григорьевич. Авылдашлар аны, үз итеп, якын итеп Җәгүр дәдәй яки Үркәй Җәгүре (әнисе Арина — Үркәй булганга) дип йөртәләр. Җәгүр дәдәй авылда иң карт кешеләрнең берсе, әмма әле һаман үз һөнәрендә булган бөтен эшне эшләп бара. Тирә-як авылларда дан казанган оста тегүче, умартачы, мич чыгаручы, балта остасы ул. Әле хәзер дә моннан 50 — 60 еллар элек Германия эшләп чыгарган «Зингер» тегү машинасының күп детален үз кулы белән ясап төзәтә. Кул машиналарын аяк машинасы итеп үзе үзгәртә ала, аяк белән эшли торган механизмнарын үзе ясый. Бу эшләрнең берсендә дә ул станок-фәлән кебек бүгенге заманның катлаулы машиналарын кулланмый, ә электән килгән гап-гади кул кораллары — чукеч, игәү, каргаборын, пычкы һәм үзе уйлап тапкан гап-гади, ләкин хикмәтле җайланмалардан гына файдалана.

Җәгүр дәдәй күп еллар колхозның умартачылар бригадиры булып эшләде. Ул әле хәзер дә ун баштан артык умарта тота.

Егор Григорьевич Бөек Ватан сугышында дәһшәтле хәрби операцияләрдә катнаша, фронтта күрсәткән батырлыклары өчен күп кенә медальләр һәм Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Җәгүр дәдәй безнең авылның бик оста җырчысы да. Ул әле хәзер дә бик борынгы, озын-озын керәшен көйләрен җырлап бирә ала. Аңа хатыны Үлүк җиңги һәм сеңлесе Супый түти бик җайлы кушылып җырлыйлар. Безнең авылдан башка беркая да ишетелмәгән озын көйле керәшен җырларын еш башкаралар. Миндә бу кечкенә «хор» башкаруын язып алган магнитофон тасмалары да саклана.

Бер ук вакытта Җәгүр дәдәй бик шаян, мәзәккә хирес кеше. Җае туры килгәндә ул үзебезнең авылда һәм тирә-як күршеләрдә туган кызык-кызык гыйбрәтле хәлләр, мәзәкләр сөйләп җибәрә. Безнең авылда кызыклы яки гыйбрәтле хәлләр турындагы сөйләкләрне, хикәятләрне, мәзәкләрне дәмәк диләр.

«Кичә концертка барган идем, бик дәмәк булды...» «Бер дәмәк сөйләп җиппәрим әле...» — диләр безнең авылда.

Журналның бу санында мин Җәгүр дәдәйдән ишеткән берничә дәмәк тәкъдим итәм. Аларны бер дә үзгәртмичә диярлек Җәгүр дәдәй авызыннан язып алдым. Әлбәттә, сүзләр язылышын Җәгүр дәдәйчә, ягъни безнең авылдагы төрки авызлы керәшеннәрчә үк итеп түгел, ә әдәби тел нормалары белән бирергә һәм урыны-урыны белән үземнең язучылык фантазиясен кушып җибәрергә туры килде.

Аңлашыла ки, дәмәкләр — керәшен авылы тормышыннан.

# Икона

Безнең авылда төзелгән беренче комсомол ячейкасы секретаре Үкчей Бәчкәсе (Аксинья улы Василий була инде) иде.

Алар бик тә ярлы тордылар. Дүртәүләшеп — Бәчкә үзе, хатыны Пикыла (Фекла), әниләре Үкчей һәм Бәчкәнең дәдәсе Гөргөри 9 кв. метрлы мунча кадәр генә өйдә яшәүләре турындагы документ Бәчкәнең уртанчы улында әле бүген дә саклана. Документ 1929 елгы. Һәр кешегә яшәү өчен 2,25 кв.м. мәйдан туры килә — минем исәп белән аркылысы бер адым, буе ике ярым адымнан да азрак. Әле бит шул өйдә зур мич, сәке, өстәл бар иде. Бу дүрт кеше шушы өйдә ничек сыеп яшәделәр икән дип бүген дә аптырап куям. Хәзерге аерым балконлы, кухнялы, прихожийлы фатирларда яшәүче шәһәр кешеләренең: «Кухнябыз бәләкәй...», «Залыбызга кунаклар сыймый...», «Прихожий тар...», «Өйгә гарнитур сыйдыра алмыйбыз...» — дип зарлануларын ишетсәм, гел шул Үкчей Бәчкәләренең урам чатындагы, әйттем исә кайттым, әберәкәй чаклы гына бәләкәй өйләре күз алдыма килә.

Бәчкә минем сеңлем Пикылага өйләнде, ә менә дәдәсе Гөргөринең башлы-күзле булганын бер дә хәтерләмим. Әмма аның авылда бик оста гармунчы икәне истә калган. Ул сугышка да гармунын алып киткән. Китеп озак та үтмичә, солдат киеме киенеп, гармунын тотып төшкән бер рәсеме дә килде диделәр. Гөргөри сугышта батырларча һәлак булган. Сугыш бетеп байтак еллар үткәч, Украинадагы бер авылдан пионерлар аның батырлыклары турында авылга хат яздылар, каберен бик карап, хөрмәтләп тоталар икән.

Әле илдә комсомол хәрәкәтләре чыкканчы, буйдак чагында Бәчкә тамак ялына күрше Сарабиккол авылында көтү көтә иде. Илдә яңа, советчыл хәрәкәтләр башлангач, авылга кайтты да өч кешелек кенә комсомол ячейкасы оештырып җибәрде. Бәхеткә каршы, әле бит ул чакта авылда коммунист ук булырлык кешеләр юк иде. Бездә дә башта комсомол оешты, алар авылдагы бөтен эшне, бөтен дилбегәне үз кулларына алдылар. Безнең авылның комсомол ячейкасы шактый көчле булган, күрәсең, утызынчы елларда аның турында «Кызыл Татарстан» гәҗитендә кечкенә генә бер мәкалә дә чыкты, анда Бәчкәнең дә исеме бар иде.

Бәчкә безнең Пикылага өйләнгәч, теге «әберәкәй»дә яшәү бик нык кыенлашкан булса кирәк, авыл Советы аларга яшәп торырга кулаклардан бушаган бер өй бирде. Бәчкә монда яшәргә бик кыенсынды. «Үзем раскулачивать итәм, үзем алардан бушаган өйгә керәм, минем турыда авылдашлар ни уйлар», — дия иде. Ләкин бер чара да юк. Пикыланың инде беренче балага корсагы борынына тигән, әлбәттә, бәләкәй генә йортка бишенче кеше сыймаячак та сыймаячак. Бәчкә сугышка кадәр тәки Совет биргән шул йортта торды, яңа йорт җиткерергә вакыты да, җае да булмагандыр инде, ә сугыш башлангач, Пикыла өч бала белән кулак йортында торып калды. Бәчкә сугышка чыгып китте. Шулай итеп, Бәчкәгә — ярты Европага телефон чыбыгы сузып (ул элемтә частьларында хезмәт итте), бу зур сугышта җиңүче булып, бик зур бер атака алдыннан башка солдатларга кушылып партийный ук булган Василий Семеновичка — тагын шул кулак өенә кайтып керергә туры килде.

Безнең авылда Совет чыкканнан соң ике зур оешма төзелде — берсе колхоз, икенчесе промартель. Безнеңчә әйтсәк, әртил була инде. Әртилдә төрле мебель ясыйлар, тугым бөгәләр, каен тузыннан дегет кайнаталар, аркан ишәләр, чыпта сугалар, юкә кабыгын буаларга батырып мунчала эшлиләр һәм шул заман өчен бик тә әһәмиятле булган башка төр «промышленность товарлары» җитештерәләр иде. Бу әртил хуҗалыгы бер заман бик нык көчәеп тә алды, ул хәтта колхозны да узып китте, авылда беренчелекне үз

кулында тотты, аерым кибет ачып җибәрде. Әртилгә үзәктән дә бик нык ярдәм итәләр, чөнки ул чыгарган товар илгә бик тә кирәк иде.

Элек тә активлыгы билгеле булгач, инде сугыштан партиягә дә кереп кайткач, Бәчкәне шушы әртил хуҗалыгына персидәтел итеп куйдылар. Менә шул чакта көчәйде дә инде әртил, илгә мул итеп төрле товар тапшыра башлады. Безнең авыл халкы эшкә оста да, батыр да — һәрберсенең кулында корал уйнап кына тора! Үз чиратында дәүләт тә әртил кибетенә авыл кибетләрендә булмый торган төрле-төрле товар кайтара башлады. Мунчала эшләгәндә артып кала торган юкә кабыгын Бәчкә авыл халкына таратты иде. Бу киң, озын кабык өй түбәсен ябу өчен шиферыңнан бер дә ким түгел. Кабыкны өй кыегына атландырып берничә кат тезеп чыгалар да, очларын озын киртәләр белән бастырып куялар. Кабык түбә матур да, юка да, нык та була, янгын куркынычы да салам кебек үк түгел.

Шулай итеп, безнең авылда сугыштан соңгы елларда ук салам түбәләр кими барып, кабык түбәләр үрчи башлады. Ниһаять, Бәчкәнең үзенә дә кулак йортыннан арынырга мөмкинлек чыкты: 1948 елда иске йортны сүтеп, бик үк зур булмаган алты почмаклы өй салып керде. Шуннан алар дүрт баласы, бер класс та укымаган, ШКМ*да йөреп кенә аз-маз латин хәрефләренә өйрәнгән минем сеңел Пикыла белән матур гына итеп яшәп китте. Бу вакытта инде әртилнең элеккеге даны төшә башлады — беренчедән, ул эшләгән товарны житештерү илдә промышленность нигезләренә салынды, икенчедән, колхозларны текә күтәрү башланды. Һәрхәлдә, безнең авылда төп һәм житәкче оешма булып колхоз калды, тора-бара ул әртилне дә үзенә йотып бетерде. Шул елларны булдыклы җитәкче дип Бәчкәне колхоз персидәтеле итеп сайладылар. Инде аның бөтен эше райком, район житәкчеләре белән бәйле иде, тарантасын җигеп көн дә район үзәге булган Шөгергә чаба бу.

Бәчкә белән Пикыланың тормышлары болай тыштан караганда шулай көйләнеп киткән кебек булса да, өй эчендә, боларның икесенең арасында гел бер каршылык килеп чыга икән. Эш шунда ки, керәшен авылы буларак, бездә бөтен кеше дә икона тота. Кайсы гына йортка барып керсәң дә, өйнең кояш чыгышы ягындагы почмагына икона куелган булыр. Юк, безнең авыл халкы бик диндар икән, дингә мөкиббән икән дип уйларга ашыкмагыз. Бездә иконаны дин әсбабы булудан бигрәк, өйнең аерылмас бер җиһазы, өй бизәү әйберсе итеп тоталар. Керәшен кешесе өчен икона почмагын бизәү — кул эше осталыгын күрсәтүче кечкенә генә бер күргәзмә кебек. Әйтик, ир кеше такталарга матур сырлар, бизәкләр уеп рам ясый. Хатын кеше исә ул рамга үзе чиккән пәрдәләр, үзе бәйләгән челтәрләр элә. Бу чиста, пөхтә, ап-ак итеп юылган челтәрләр, пәрдәләр зур, матур итеп эшләнгән рамнар артындагы икона исә күп йортта уч төбе кебек кенә бер рәсем инде шунда. Ә менә икона почмагы үзенең чигүләре, челтәрләре, нәкышләре белән балкып, бөтен өйгә ямь биреп тора. Җитмәсә, бәйрәм көннәрендә аны төрле матур, ачык төсләргә манылган кәгазьләрдән кисеп ясалган чәчәкләр, букетлар белән бизәп тә җибәрәләр. Шунысы кызык, дини бәйрәмнәрдә генә түгел, совет бәйрәмнәрендә дә өйне бөтенләй юып, түшәмнәрне кырып, иконаларны бизәп куя авыл халкы.

Менә шушы икона мәсьәләсендә чыга икән Пикыла белән Бәчкә арасында низаг. Бәчкә, авылның беренче комсомолы, алласызлар җәмгыятенең иң актив члены, чын дәһри буларак, теге чакта кулак өенә килеп урнашуга ук иконаны рамы-ние белән кубарып аткан була. Монсына әле Пикыла түзә, үз өең булмагач, берни дә эшләп булмый. Ә инде менә яңа өйгә, үз куллары белән төзешкән өенә икона куйдырырга исәбе Пикыланың. Аңа икона кирәк, ә кирәкнең төп сәбәбе шунда — авылдашлардан яхшы түгел. Авылдагы бөтен кешедә икона булганда, син генә кылтаеп, өйнең кояш чыгышы

---

* ШКМ — Школа колхозной молодежи. Колхозлар төзелә башлагач оештырылган, яше укудан узган, ләкин укый-яза белмәгән авыл кешеләрен укырга-язарга өйрәтүче мәктәп (Искәрмәләр авторныкы).

ягындагы почмагын шыр ялангач итеп тоту бер дә килешә торган эш түгел. Җитмәсә әле карчык-корчык, иконасыз өйне яшен суга, анда яшәүчеләрне мур кыра, анда төрле җен-пәриләр, убырлар ияләшә, иконасыз өйдән өй иясе чыгып кача, дип куркыталар. Ә бит өй иясе өйдәгеләрне чир-чордан саклый, өйнең иминлеге өй иясеннән тора. Һәм, гомумән, Пикыла алла булып алланы ук хөрмәт итмәүне һич кенә дә башына сыйдыра алмый иде. Пикыла белән Бәчкә балаларны чумылдыру мәсьәләсендә дә килешә алмадылар. Попның крестить итүен керәшеннәр башка татарлар кебек «чукындыру» димиләр, «чумылдыру» дип матур итеп әйтәләр. Чукындыру дигән сүз ул ямьсезләп, мыскыл итеп әйтү сүзе.

Чумылдыру мәсьәләсен Пикыла үзенчә чиште. Бәчкә Казанга авыл хуҗалыгы алдынгылары җыелышына киткән вакытта авылга яшеренеп кенә нindidер законсыз поп килгән булган. Поп нәкъ Бәчкә Казанга киткәч килгән, ул каядыр чыгып китмәсә, авылга андый-мондый кешеләр керергә куркалар иде. Пикыла, Бәчкәсе белән киңәшми-нитми, дүрт баланың икесен әнә шул попка алып барган да чумылдырып кайткан. Казаннан кайтып төшкән Бәчкә ике баласының муенында асылынып торганkачларны күреп тәмам чыгырыннан чыккан. (Безнең авылда чумылдырылган кешенең муенына асыла торган крестны «тәре» дип әйтмиләр, ә «кач» диләр. «Тәре» дисәң ул ямьсез була). «Чукынсагыз чукынгансыз инде, ичмасам шушы кургашны тагып йөрмәгез»,— дип ачуланган Бәчкә. Андый качларны әлеге поплар махсус формаларга кургаш эретеп кулдан коялар да, керәшен һәм урыс авылларында сатып йөриләр иде.

Пикылага бик каты эләккән Бәчкәдән. Әмма тегесенең алдан ук җавабы бар икән. «Мин икебезгә дә тигез итеп эшләдем,— дигән Пикыла,— икебезгә дүрт бала бар, мин үз өлешемне чумылдырдым, синең өлешеңә тимәдем, әнә икесе чумылдырмаган».

Эш үткәч, инде нишләсәң дә юк. Бәчкә бер-ике көн чәпчегән дә тынган.

Инде менә Пикыла икона мәсьәләсендә көн дә ирен талый. «Алып кайт инде шул иконаны, рамын әнә Җәгүрдән ясатам»,— ди ул. Бәчкә хатынының бу таләбенә якын да килми, партионный башым белән өйгә икона кертергә син мине кем дип белдең, дип кенә җибәрә. Пикыла: «Үзең борылып та карамассың, балалар белән минем өчен, өйгә кергән күрше-күлән сүз әйтмәсенгә генә куйыйк»,— дип тә карый. Ә тегесе хатынының сүзен җитди итеп кабул итми, аның җыен ырым-шырымга, хорафатларга ышануыннан көлә генә. Безнең Пикыла ул, чыннан да, яшь чагыннан ук гайре табигый булган нәрсәләргә игътибар итәргә ярата иде. Имеш, борын очы кычытса, кеше үлә икән, колак тишеге кычытса, буран чыгарга була икән, уч төбе кычытса — акча керә икән. Ә Бәчкәгә, дөньяга бөтенләй яңача караучы кешегә, көләргә шул гына кирәк тә. «Әй, синең танавың кычыткан саен кеше үлсә, инде авылда бер кеше дә калмаган булыр иде, колагың кычыткан саен буран чыга торган булса, бөтен дөньяны көрт баскан булыр иде, ә кычытмас өчен колак тишеген юып йөрергә кирәк. Инде синең уч төбең кычыткан саен акча керсә, без үзебез генә түгел, колхозны да күптән миллионер ясаган булыр идек»— ди ул мыскыллап.

Әмма Пикыла бик тешләк хатын, көн дә икона сорап Бәчкәне игәүли. Көннәрдән бер көнне, Бәчкә район үзәгенә барырга җыенып йөргәндә, Пикыла тагын шул сүзне башлый бит. Алып кайт булгач, алып кайт, Шөгердән ерак түгел чиркәүле авыл бар, шунда икона саталар икән, имеш. Бәчкә ни әйтергә дә аптырый, чөнки инде бу мәсьәләдә Пикылага әйтәсе сүз бар да әйтелеп беткән. Шуннан аптырап тора-тора да Бәчкә, нindidер бер карарга килгәндәй, кул селтәп әйтә:

— Ярар алайса, Пикыла, әйдә, синеңчә булсын, кичкә көт, алып кайтам икона,— ди.

Пикыла шатлыгыннан нишләргә белми. Бәчкәсе чыгып китүгә күршеләргә кереп мактана, бүген ирем икона алып кайта, без яңа өйгә яңа икона куябыз, янәсе. Шуннан миңа да йөгереп килеп җиткән: «Җәгүр,— ди,—

бөтен эшеңне ташлап миңа бик матур гына бер рам ясап бир әле. Бүген Бәчкә икона алырга китте»,— ди. Мин инде ышанырга да, ышанмаска да белмим, шулай да риза булдым, ни дисәң дә сеңел гозере бит. «Ярар,— мәйтәм,— иртәгеләргә эшли башлармын».

Пикыла көне буе ирен көткән, яңа өйне өр-яңадан җыештырып, юып чыгарган. Тәрәзәләргә яңа пәрдәләр элгән, балаларына чиста күлмәк-ыштан кидергән, кичкә табык суйдырып токмачлы аш белән ирен көткән.

Ниһаять, кичкырын Бәчкә кайтып төшкән. Чыннан да, култык астында кәгазьгә төргән дүрт почмаклы рамсыман әйбер дә бар. «Иконасы зур да булган икән, күрше-күләннеке кебек уч төбе кадәр генә түгел»,— дип куана икән Пикыла. Бәчкәнең дә шатлыктан йөзе балкыган, гел елмаеп кына тора.

Өйгә кереп төргәкне чишә башлыйлар. Эчтән, чыннан да, алтын төсле сап-сары рамлы рәсем килеп чыга. Пикыла әйбәтләбрәк караса, ни күзләре белән күрсен: рам эчендә бик матур майлы буяулар белән ясалган Сталин портреты тора.

— Менә синең аллаң, шуңа карап кына чукын, шуңа гына табын, дога кыл!— ди дә Бәчкә, портретны өр-яңа өйнең ике тәрәзә арасына, иң якты һәм күренеп тора торган урынына элеп куя.

Әйе, үзе ышанган нәрсәләргә бик тә турылыклы кеше иде ул Үкчей Бәчкәсе.

## Икенче дәмәк

## Бер арба утын

Колхоз председателе буларак, Бәчкә сугыштан соңгы авыр елларда авылның һәр кешесенә ярдәм итә иде. Шуңа күрә ул һәр колхозчы белән дус яшәде. Авыл советы рәисе белән дуслыклары аеруча якын булды. Берсенең әйткән сүзен икенчесе беркайчан да юкка чыгармады. Хәтта бер-берсенең ялгышканын белгән очракта да кеше алдында берсен-берсе рисвай кылмыйлар, оятка калдырмыйлар иде.

Ул елларда колхозчыга утын әзерләү мәсьәләсе шактый кыен булды. Эстерлүк (безнең авылда урман каравылчысын шулай дип йөртәләр. Электән килгән сүз, русча «стрелок»тан үзгәргән) рөхсәтеннән башка урмандагы корып беткән бер агачны киссәң дә каты чара күрәләр иде.

Әмма бу мәсьәләдә безнең авылның бер җайлырак ягы да бар, колхозыбыз кырларының иң түрендә, Колмаксар дигән урындагы урман кырыйларында дәүләт фондына керми торган уйдык-уйдык туйралыклар үсә. Аларга дәүләт урманчылыгы оешмалары түгел, ә безнең авыл, безнең колхоз хуҗа. Димәк ки, эстерлүкнең бу туйрада катнашы юк.

Башлыча ботак-чатаклы, кәкре-бөкре булып беткән имәннәр үсә торган бу туйралыклардан колхоз да, авыл советы да үз кирәгенә файдалангалый. Бик сирәк кенә авыл кешеләренә дә, корыган агачларны сайлап, берәр ат арбасы утын әзерләргә рөхсәт ителә. Ләкин бары тик Үкчей Бәчкәсе яки авыл советы рәисенең шәхси рөхсәте белән генә. Ул чакта әле колхозда накладной, рөхсәт кәгазе кебек әйберләр бик үк модага кереп бетмәгән иде. Колхоз яки авыл советы рәисенең телдән әйткән рөхсәте закон, аны беркем дә бозарга батырчылык итми.

Бер елны бит минем кышка әзерләнгән утын җәйгә хәтле җитми калды, яз азагына хатын соңгы пүләнне якты. Өйдә дүрт бала, сыерын-сарыгын, казын-үрдәген асрыйбыз, ашарга-эчәргә пешерергә, суын җылытырга, мунчасын ягарга кирәк. Ишегалдында сыер мөгри, өйдә балалар чыркылдый, ә иң яманы — хатын игәүли: кеше ирләре ирләр кебек, берьюлы ике кышка җитәрлек утын әзерләгәннәр, ә синеке җәйгә дә җитмәде, янәсе. Мин дә үземне акларга теләп кенә хатынга бәйләнгән булам, мичне таманлап яга

белмисең, утынны күп яндырасың, безнеке дә кешеләрнекеннән ким түгел иде, дигән булам. Үзем белеп торам, гаепне бер-береңә сылтап кына өйгә утын кайтмый, бер-бер чарасын күрергә кирәк. Колмаксар туйрасыннан утын кисәргә рөхсәт һәм ат сорап Үкчей Бәчкәсенә барып карыйм, ул әйтә, бер-ике ай түз, Җәгүр ди, колхозда уттай эш өсте, бераз җиңеләйгәч барырсың, ди. Белеп торам инде, ат кызгана Бәчкә, чөнки атны колхоз эшеннән төнлә генә аерып була, көне буе эшләгән арык колхоз атын төнгелеккә миңа бирсә, ул ат икенче көнне бөтенләй эшкә ярамаячак. Җитмәсә, мин дә утын кытлыгының иң соң чиккә җитүен әйтергә оялам. Бәчкәнең нәкъ минем хатын шикелле үк, булдыксызлыкта гаепләве бар. Персидәтел булмәсеннән дәшми генә чыгып китәм дә, хәйләгә керешергә карар итәм. Шул көнне үк колхоз эшенә Колмаксар кырына барам, юл уңаенда билемә балта да кыстырам. Эш көне бетеп, кешеләр авылга кайтып киткәч, эңгер-меңгердә туйралыкка кереп балта белән коры агачлар әзерли башлыйм. Минем бәхеткә, ялтырап ай чыга. Минем балтаның үткерлеген беләсез инде, төн урталары да җитми, мин бер арбалык утынны әзерләп, төяп китәргә җайлы гына булырлык бер урынга өеп тә куям. Таң атуга җәяүләп кенә авылга кайтам, йоклап-нитеп тормыйм, иртән бригадирдан бүген мине ат җигеп эшләргә Колмаксарга билгеләвен сорыйм. Бригадир үз кеше, рөхсәт бирә. Мин бригада утарына төшеп ат җигеп менәм дә, өйдә сыерга дигән бәрәңге кабыкларын, аш калдыкларын атка ашатам. Кичтән колхоз эше беткәч, бер-бер хәйлә белән колхозчылардан артка калып, беркемгә дә сиздермичә генә теге утынны төяп кайту инде минем исәп. Шулай итеп, берьюлы ат та, утын да урларга әзерләнәм. Көне буе колхоз эшендә дә эшләп, тугыз чакрымнан минем утынны да сөйрәп кайткан ат бөтенләй өзлекмәсен өчен аны алдан ук ашата торырга кирәк. Колмаксар кырында эшләгәндә дә, җае чыккан саен үлән йолкып ямсә аз гына буш вакыт булуга аркалыкны бушатып, үзен утларга җибәрәм.

Эш бетеп, кайтыр вакыт җиткәч, гомергә чишелмәслек итеп бәйләнгән камыт бавы төенен бушатып куям да, бөтен кеше алдында кинәт минем ат тугарылып китә. Шуннан мин камыт бавын карыйм да: «Җәмәгать, монда минем камыт бавының рәте киткән, ярты сәгатьсез рәтләп булмас, сез кайта торыгыз, мин сезне куып җитәрмен».— дигән булам. Колхозчылар башка атларга төялеп авылга кайтып китәләр. Алар тау артына күмелүгә, камыт бавын тыгызлап бәйләп куям да кичә әзерләнгән утыннар янына сыптырам. Якты күздә урманны чыгып өлгерим дип, тиз-тиз утынны төйим, арбаны арканлап боргычлыйм да олы юлга чыгам.

Менә сиңа бәхетсезне: олы юлга чыгып бер җир буе да барырга өлгермим, каршыга тарантасы белән челтер-челтер килеп Бәчкә үзе, ягъни колхоз персидәтеле килеп чыкмасынмы! Колмаксар кырындагы эшләрнең торышын карарга килеше икән. Эшнең нәрсәдә икәнен белеп, мине сразы туктатты бу.

— Мин бит сиңа бер-ике айдан алырсың дидем, нигә рөхсәтсез ташыйсың урманны, Кузьмин?!— ди бу усал итеп. Башка чакта миңа һәрвакыт Җәгүр дип эндәшкән Бәчкә, җитмәсә әле кияү кеше, миңа монда, ялан кыр уртасында фамилиям белән эндәшеп тора. Бик нык рәсмилеген күрсәтә, янәсе. Мин инде аптырадым да калдым, ни әйтергә дә юк. Шунда кинәт минемә башкиткеч кыю бер уй килеп төшмәсенме.

— Рөхсәтсез түгел, иптәш персидәтел, рөхсәт белән алып кайтам,— дип ярып салдым мин, күземне дә йоммыйча. Бәчкә аптырабрак калды. Әле моннан бер көн элек кенә миңа рөхсәт бирмичә чыгарганын хәтерли ич инде ул.

— Как так рөхсәт белән?! Кем рөхсәт итте?— диде ул йомшара төшеп.

— Кем булсын, авыл советы рәисе. Мин аңа өйдә бер ярка утын да калмаганын әйткән идем, ул үзе туйрадан бер олау утын алып кайтырга кушты.

Шуннан Бәчкәнең йөзе яктырып китте, кара айгырына бер чөңгереп алды да киткәндә артымнан кычкырып калды:

— Кара аны, атны бөтенләй өшәндерәсе булма.

— Борчылма, өйдә бәрәңге кабыгы ашаттым мин аңа, иптәш персидәтел,— дип кычкырдым, Бәчкә артыннан.

Алдавын алдадым да, кайта-кайта миңа пошаман төште бит. Иртәгә бу турыда авыл советы рәисеннән сорап, хәйләм ачылса, нишләтерләр болар мине? Ләкин минем башка чарам да юк иде. Миңа бүген бер олау утынны ишегалдына кайтарып аудару кыйммәт. Иртәгә, хәйләм ачылган очракта да, бер арба утынны ишегалдыннан алып чыгып китәргә үк җөрьәт итә алмаслар ич инде алар. Ә хәйлә өчен гафу үтенермен, башымны иярмен. Иелгән башны кылыч кисми.

Шундый борчулы уйлар белән авылга кайтып җиттем. Минем бәхеткә, тәмам караңгы төшеп җитте, көн болытлы, караңгы иде, мин чит-ят күзләргә күренми генә авыл буйлап үттем дә, үзебезнең тыкрыкка борылдым. Борылуым булды, арттан карлыккан таныш тавыш ишетелде:

— Кузьмин, тукта әле.

Бетте баш! Минем бөтен тәнем жу-у итеп китте, чөнки бу авыл советы рәисенең тавышы иде. Атымны туктаттым.

— Кузьмин, кем рөхсәте белән урман ташыйсың?—дип сорады персидәтел кырыс-коры тавыш белән.

Мин, инде беткән баш беткән дидем дә, ярып та салдым:

— Колхоз персидәтеле рөхсәте белән!

Авыл советы рәисе беразга тынып калды. Караңгыда миңа аның йөзе күренми иде. Рәис бер-ике минут тын гына торгач, шул ук карлыккан, ләкин шактый йомшак тавыш белән:

— Ы-ы-ы... Алайса ярар, бар, кайт,—диде дә үз юлына китеп барды...

Әйтәм бит—безнең персидәтелләр бер-берсен хөрмәт итәләр. Бер-берсенә, шул ук вакытта беркайчан да алдап-йолдап яшәргә өйрәнмәгән миңа да нык ышану аркасында алар икенче көнне дә, башка чакта да минем бер арба утын турында бер-берсеннән сорашып тормаганнар, бер-берсенең миңа рөхсәт бирүенә нык ышанганнар.

Шулай итеп, мин ике персидәтелнең әфтәритите белән файдаланып бик ансат кына бер арба утын алып кайттым, гаиләне коткардым.

Ул көннәрдән соң күп еллар үткәч, мин аларның икесенә дә бу хәл турында сөйләгән идем, рәхәтләнеп шырык-шырык көлделәр.

## Өченче дәмәк

# Пожарга ут капкан

Янгын, ут-күз чыгу адәм баласына һәрвакыт бәла-каза китергән. Элек авыл кешесенең йорт-җире янып китү гаиләнең зур фаҗигасенә әйләнә, кешеләрне яңадан мантып китә алмаслык фәкыйрьлеккә җиткерә иде. Йорт-җире, мөлкәте янып юкка чыккан кешегә мир белән ярдәм итү гадәте бездә элек-электән үк килә. Мәгәр, элек авыл кешесенең күбесе үзе бик ярлы иде, аларның хәер итеп кияргә биргән алам-саламы, ашарга биргән каты-котысы белән генә дистәләгән балалы ишле гаиләләр тернәкләнеп тә китә алмыйлар. Мондый гаиләне бигрәк тә торак мәсьәләсе интектерә. Элек безнең авылда алты почмаклы өй аз, күп кешедә дүрт почмаклы, ягъни бер бүлмәле генә өй. Гадәттә, гаиләләр ишле, аерым өй салу гаять кыйммәтле, күп чыгым сорый торган эш булганга, инде олыгаеп, үзенең биш-алты баласы булган ир туганнар да башка чыга алмыйлар, икешәр, өчәр, кайчакта хәтта дүртәр гаилә бергә әнә шул уртача зурлыктагы дүрт почмаклы өйдә яшиләр. Әлбәттә, мондый өйләргә йорт-җире янып, бала-чагасы белән урамда торып калган чит-ят гаиләләр сыя алмый инде.

Җәй көне ярый, куышта да торып була, ә менә яз-көз, кыш айларында интегәләр иде янгыннан бәла-каза күрүчеләр. Алар берәр кешенең бушаган мал абзарын аннан-моннан җайлаштырып, кара мич корып яисә авылдашларның берәрсенең мунчасында кыш чыгалар иде. Торагы торак, ә бит әле

бер көтү баланы кыш буе ашатып та чыгасы бар. Монысы инде чын мәгънәсендә фаҗигагә әйләнә. Шундый чакларда аягында йөри ала торган олырак балалар хәер сорашырга күрше-тирә авылларга чыгып китәләр, юллары уңса, кече туганнарына да каты-коты, туңган бәрәңге ише нәрсә алып кайталар. Кайсыбер балалар шул киткән җирләреннән югалып, гаип булып та калалар иде. Ул чакларда буран күмеп киткән, кырда яки урманда катып үлгән хәерче балалар турындагы хәбәрләр һаман саен ишетелгәләп тора иде. Чарасыз фаҗигагә дучар булган гаиләләрнең аякланмаган яшь балалары йә гомергә чирләшкә булып кала, йә ачлыктан гөбедәй шешенеп үлә. Шулай итеп, гаилә таркала, нәсел җебе өзелә, аның киләчәге сүнә.

Шуңа күрә дә элек авылда янгын чыгу бик зур вакыйга булып китә. ачудан, көнләшүдән, үч алу яки башка максатлар белән махсус ут-төртүчеләргә рәхимсез рәвештә самосуд була торган иде. Әгәренки янгын дөрләп торган чакта ут төртүченең кем икәне беленсә, авыл халкы аны шунда ук кул-аякларыннан тотып ала да, акыртып-бакыртып утның иң котырган ноктасына ыргытып бәрә. Бу мизгелдә, ут төртүче кем генә булуга карамастан, аңа бернинди ташлама да юк. Мондый самосудның тәэсир көче гаять зур, шуңа күрә авылда махсус ут төртеп чыккан янгыннар бик сирәк була иде.

Шулай да элек янгыннар хәзергегә караганда ешрак була иде шикелле. Өй яктырту өчен чыра яндыру, төнлә ишегалдына, абзар-курага шул ук чыра кабызып чыгу, җәй көннәрендә күкерт кебек кабынып китәргә генә торучы салам түбә, җәйге челләдә бөтен олы кешенең кыр эшендә булып, авылда вак бала-чаганың күзәтүчесез калуы — болар барысы да янгыннарның еш булуына сәбәп булгандыр. Аз-маз күзәткәләп яшәсәң, хәзер шифер түбәләр, менә дигән изоляцияле электр чыбыклары белән бүген бөтенләй дә янгын чыгармыйча яшәргә мөмкин дә бит, тормыш яхшырган саен адәм баласының ваемсызлыгы арта бара, күрәмсең — бит һаман янгалап торабыз. Әле күптән түгел генә авылда миңа яшьти тиешле берәү игътибарсызлыгы аркасында үзе дә янып үлә язды. Югыйсә олы яшьтәге кеше бит инде, бергә уйнап үстек. Ә янгыны аның дуңгыз суюю мәшәкатьләре аркасында килеп чыга язган.

Эш шунда ки, көз көне, җир туңдырып җибәргәч, әле кар төшмәс борын, безнең авылда дуңгыз суюю өмәләре китә. Шәхси хуҗалыкта ашатып, симереп, тазарып җиткән дуңгыз зур була, көчле була. Аны тотып суюның, суйгач өтүнең, аннары итен-иткә, салосын-салога тумыруның җаен, әмәлен белергә кирәк. Шуңа күрә авылда дуңгыз суюю осталары берничә генә, алар көз көне йорт борынча чакырылып, авылның бөтен дуңгызын суеп бирәләр. Дуңгыз өмәләре җиткәч, миңа үземә дә атналар буе диярлек өйгә кайтып керергә туры килми. Туган-тумача, күрше-күлән, яшьлек дуслары чакыра.

Чулак Питей гомере буе дуңгыз суйды һәм бер генә дуңгызны да рәтләп суя белмәде. Җитмәсә, ул малны сул кулы белән чала. Ә малны сулагай суюны борынгылар яратмаган.

Чулак Питей суйган көнне ачы итеп дуңгыз чинаган тавыштан бөтен авылның колагы тонып бетә. Дуңгыз чинавы хәтта күрше Сарабиккол авылына да ишетелә икән, дип сөйлиләр иде. Сарабикколлылар бит алар мөселман татарлары, дуңгызны яратмыйлар, хәтта аннан җирәнәләр, чирканалар. Үзара сөйләшкәндә алар дуңгызны «дуңгыз» дип тә атамыйлар. «чучка», «сосна», «мыркылдык», «кәкре койрык», «кәкре танау», «салпы колак» дип кенә йөртәләр. Әмма безнең авыл сарабикколлылар белән бик дус яшәде. Минем үземнең дә анда дусларым күп. Шунсы кызык, безнең авыл кешеләре белән аралашканда, алар, безне үпкәләтмәс өчен, дуңгызларыбыз турында үзара сөйләшкәндәге кебек мыскыллап сөйләшмиләр. Бервакыт Сарабикколдагы Бүре Хатип дигән аучы дустым урман-кырларда арып-талып ауда йөргән дә, юл уңаеннан чәй эчеп чыгарга дип, миңа кергән. Кунак та, дус та буларак бик әдәпле генә итеп сөйләшеп утыра инде бу, бала-чага, хуҗалык турында сораша.

Шунда, ишегалдында, без чәй эчеп утыра торган өстәл турындагы тәрәзә каршына минем симертергә куйган дуңгыз килеп чыкты. Шуны күрде дә Бүре Хатип: «Керәшен сарыгың күр генә икән».— дигән була. «Керәшен сарыгы» дип әдәпле итеп әйтә инде, янәсе, «чучка» яки «дуңгыз» дисә, тупас булып, миңе үпкәләтүдән саклана. Мин бит инде сизеп торам, дуңгызны күргә, аның тамагыннан аш үтми башлады, ясаган чәен эчеп бетермичә, караңгыга калганчы кайтып җитим, дигән булып өйдән чыгып тайды.

Инде әлеге шул Чулак Питейгә килсәк, ул дуңгыз суйган көнне безнең авыл ягыннан чинау тавышы ишеткән Сарабиккол кешеләре: «Керәшендә дуңгыз өмәләре башланган, әнә Чулак Питей чучка чала, кәкре танауны нишек разбой салдыра, әстәгъфирулла, ходаем, үзең сакла»,— дип укыналар икән, имеш, дип сөйлиләр иде.

Дуңгыз өмәсе борынгы бабайлар тарафыннан ук килгән аерым бер тәртип, хәзергечә әйтсәк, сценарий белән бара. Эш иртән иртүк, көн яктыруга башлана. Мин нәкъ шул вакытка хуҗаның өенә киләм дә. Хуҗа миңа ярдәмгә тагын өч-дүрт ир һәм ике-өч хатын кыз чакырган була. Дуңгыз суйганда аларның барысына да эш чыга. Беренче эш итеп, хуҗа өмәчеләргә җиңелчә генә чәй эчертә. Аннары бөтен өмәчеләр дә җыелышып ишегалдына чыгалар. Мин, гадәттә, башка өмәчеләрне өйалдында яки баскыч башында калырга, шунда тыныч кына көтеп торырга кушам да, ишегалдына, дуңгыз янына үзем белән хуҗаны гына алып чыгам. Чөнки бер көтү кеше шау-гөр килеп ишегалдына чыкса, дуңгыз курка, тынычсызлана башлый. Дуңгыз бит ул бик тә сизгер хайван, хәвефне алдан тоеп алса, кешене үзенә якын да китерми, тоттырмый...

...Хуҗалар тумырылган итләрне мунчала баулар белән чоланга асып куйганнан соң, дуңгыз өмәсенең эш өлеше тәмам була. Эш бетүгә бөтен өмәчеләр дә өйләренә кайтып китә. Кичтән алар билгеләнгән сәгатькә, бәйрәм киемнәрен киенеп, бизәнгән-ясанган хатыннарын ияртеп, дуңгыз өмәсенең мәҗлес өлешенә киләләр. Монда аларны хуҗабикә мул итеп яңа иттән пешкән төрле-төрле аш белән сыйлый. Бу мәҗлес олы бәйрәмнәрдәгечә бик зурлап уздырыла, бию, җыр, уен-көлке мул була. Әлбәттә инде, дуңгызны чалучы буларак, өмә мәҗлесенең иң түрендә иң хөрмәтле кеше булып Җәгүр дәдәң утыра. Сине хөрмәтлиләр, сине мактыйлар, сиңа багышлап моңлы-сагышлы керәшен җырулары әйтәләр.

Әмма дә ләкин болар барысы да элегрәк шулай иде. Хәзер дуңгыз суйганда мондый зур өмәләр ясап, мәҗлесләр үткәреп тормыйлар. Хәзер бит андый олы мәҗлесләр үткәрү өчен дуңгыздан башка да сылтаулар күп — һәркем туган көн үткәрә (безнең заманда аның кайчан икәнен дә белүче юк иде), бала тугач, туй кадәр итеп әллә ничәшәр мәҗлес үткәрәләр — тудыру йортыннан хәбәр алгач, аннан өйгә алып кайткач, исем кушкан көнне, туу таныклыгы алган көнне, балага бер ай булгач, ярты ел тулгач, бер яшь җиткәч, тагын әллә нинди, әллә нинди уңайлар белән байбай мәҗлесләр үткәрелә. Кая монда сиңа дуңгыз кайгысы! Хәер, хәзерге яшьләрнең нибары бер бөртек баласы булсын да, шуны да кадерләмәсеннәр, имеш. Безнең заманда гына ул гаилә саен ким дигәндә бишәр-алтышар, күп дигәндә унар-уникешәр бала була, аларның ашарларына азык, киярләренә кием бөтәйтеп булмый, инде кешедән оялып яшьләре җитеп узгач та күтләре ыштан күрә алмый йөриләр иде. Хәерчене бала баса, дип дөрес әйткәннәр шул борынгылар. Әнә, хәзерге яшьләр баедылар, бала тапмыйлар, үзләре күрәләр дөнья рәхәтен. Әмма дә ләкин шунсын да әйтергә кирәк, без,— картлар,— бер генә тамчы да кызыкмыйбыз аларның мондый баласыз тормышларына. Дөньяларның яхшырып китүенә, яшьләрнең мул тормышка тиенүләренә кызыгабыз, ә баласызлыкка — юк, кызыкмыйбыз. Үзара җыелышкан чакта без, картлар, бер-беребезгә сөйләнәбез: «Эх,— дибез,— без яшь чакта мондый тормыш булган булса, баланы тудырып та күрсәткән булыр идек,— дибез,— каз бәбкәләре кебек бер-бер артлы тупырдап кына торырлар иде»,— дибез. Тик нишлисең, балаларны, яшь буынны әле нинди дә булса эшкә, тәҗрибәңдә булган осталыкка, һөнәргә, әйтик, дуңгыз суярга

өйрәтеп була. Ә бит бала тудыру, бала табу кебек четерекле мәсьәлә ата-ана өйрәтә торган эш түгел.

Хәер, дуңгыз суюны да безнеңчә эшләргә теләмиләр, әйтик, дуңгызны хәзер бензин ягыла торган паяльни лампа белән генә өтәләр. Янәсе, уңайлы, тиз эшләнә. Әмма дә ләкин паяльни лампа белән өткән дуңгыз салосыннан трактор исә килә.

Ул инде малны кояш чыгышына каратып сую, канны җиргә түкмәү, түшкәгә беренче мәртәбә пычак белән сызган урынга тоз сибү кебек йолалар бөтенләй онытылды. Дуңгызны кайда туры килсә, шунда тотып алалар, шунда егып суялар.

Әлеге минем, янып үлә язган яшьти дә шушы дуңгыз мәшәкатьләре белән йөргәндә тарый бу бәлагә. Һаман да шул хәзерге заман шаукымы — паяльни лампа гаепле. Яшьтинең дуңгыз суяр вакыты җиткәч, күрше тирәдәге тракторчы егетләр моңа тиз генә дуңгыз суеп бирергә булалар. «Иртәгә иртәнгә бөтен әйберең әзер булсын, колхоздан бер чиләк бензин алып кайтып куй, паяльни лампа белән генә өтәрбез».— диләр. Карт кешегә нәрсә, ярдәм итәргә йөрүчесе булганда шатлана гына инде. Колхоз базасыннан бер чиләк бензин алып кайта да, өйалдына, гадәттә сулы чиләкләр тора торган урынга куя. Кичке якта моның карчыгы, аш пешерергә дип, казан астын тутырып яга да, үзе ниндидер йомыш белән күршегә кереп китә. Хатын-кыз күршегә нинди генә тәҗел йомыш белән керсә дә, хуҗа хатын белән сөйләшә-сөйләшә, күп чакта йомышын да, доньясын да тәмам оныта. Моның белән дә шулай була. Ә минем яшьти бу вакытта ишегалдында иртәгә дуңгыз суярга кирәкле нәрсәләрне әзерләп йөри икән. Шуннан, ишегалдында шактый вакыт юангач, нәрсәдер эзләп өйгә керә бу. Керсә, ни күрсен, казан астына яккан утыннар түрдә янып беткәннәр, ә учактан чыгып калганнары утлы кисәүләре белән чөймәлеп идәнгә төшкәннәр, идән өстен шәл урыны кадәр зурлыкта ялкын ялап алган, ут дөрләп янып ята. Менә-менә пәрдәләргә, чаршауларга кабынып китәчәк тә, бөтен өй ялкын белән тулачак. Яшьти инде көтелмәгән бу хәлдән куркып, тәмам каушап кала, ни эшләргә дә белми, зиһене тәмам чуала. Шуннан ул үз-үзен белештермичә өйалдына йөгереп чыга да гадәттә су чиләкләре тора торган урыннан бер тулы чиләкне эләктереп ала һәм шуны өйгә алып кереп ялкынга бөрки. Кинәт бөтен өйгә гөлт итеп ут кабына, тәрәзә пыялалары чылтырап коела, яшьтинең чәчләре, кашлары, керфекләре көеп чыга, бите пешә, үзен бәрмә дулкын өй ишеге аша өйалдына атып бәрә. Мондый аңлашылмаучылык яшьтинең тәмам котын ала, хәтта «Пажар!» — дип кычкырып ярдәм сорарга да хәле калмый. Ярый әле кинәт тәрәзәләрдән бензин ялкыны бөркеп чыкканны күрүче күрше-күлән, узгынчылар йөгереп кереп янгынны сүндерәләр. Өй эченә алай зур зыян килми кала. Шушы вакыйгадан соң яшьти миңа әйтте: «Гомерем булса, моннан соң бер генә дуңгызымны да яңача суйдырмам, гел искечә, үзебезчә генә суйдырырмын».— диде.

Ә менә Учтим Бәчүгенең (Устимов Василий) өе бөтенләй янып бетте. Төнлә булды бу хәл. Гадәттә, янгын төнлә өйалдында, чоланда, келәттә яки абзар эчендә башланса, баштан аны беркем дә абайлый алмый, янгын тәмам көчәеп, котырып киткән була. Ялкын тышка бәреп чыкканда инде эчтәге утны сүндерү бик тә кыенлаша. Бәчүкнең өендә ут каядыр чолан яки өйалды тирәсендә кабынган. Төнлә бит ялкын тышка бәреп чыккач та тиз генә кеше җыелып бетә алмый. Ә пожарниклар гадәттә янгын сүндерелеп яки бина янып беткәч кенә аһ-уһ итеп килеп җитәләр дә: «Мишәйт итмәгез әле».— дигән булып халыкны янгын булган урыннан читкә куалар һәм бик эшлекле кыяфәттә бармак башы кадәр күмерләрне сүндереп, инде халык әллә кайчан су сеңдереп бетергән урыннарга шапыр-шопыр су сиптереп йөриләр.

Бәчүкнең өен халык саклап кала алмады, янгын бик нык котырып өлгергән иде, сулы чиләк белән якын килерлек тә түгел. Хәер, чиләк белән генә сипкән су моның кадәр ялкынга аз гына да тәэсир итми иде. Аннан соң өй түбәсенә ябылган шиферның шартлавы да халыкны бик куркытты. Нәкъ

менә сугыш вакытындагы шрапнель шартлавын искә төшерде инде. Хатын-кызларның коты очып, янгынны бик ерактан гына күзәтеп тордылар. Шулай да авылның ир-егетләре зур батырлык күрсәтте ул көнне. Безнең авылда йортлар бер-берсенә бик якын китереп салынган. Бәчүкләр урамы бигрәк тә тыгыз утырган. Янгын вакытында шифер шартлап үзе белән әллә никадәр ут көлтәсен, ябып торган кисәү һәм күмер кисәкләрен дистәләгән метр читкә алып ата. Ә бит тирә-якта күршеләрнең өйләре, каралты-курасы. Янгын сүндерергә килгән ир-атлар әнә шул өй, каралты-кура түбәләренә менделәр дә, янгынның гаять кайнар ялкыннары астында ук диярлек, түбәләргә килеп төшкән ут көлтәләрен, кисәүләр һәм күмерләрне сүндереп яки куркынычсыз урыннарга алып ыргытып тордылар, янгынга таралырга ирек бирмәделәр, күпме авылдашның йорт-җирен саклап калдылар.

Ә Бәчүкнең бөтен йорт-җире, каралты-курасы, өй эчендәге бөтен мөлкәте янып бетте, әйберләрне алып чыгарга да өлгерә алмадылар. Әйтеп бетергесез зур фаҗига иде бу Бәчүк өчен.

Карт әнисе Думна (Домна) карчыкның елый-елый күзләре бетте. Болай да алар гомер буе бик бөтенлектә яшәмәделәр. Әмма Бәчүкнең бик нык тырышлыгы аркасында соңгы елларда муллыкта яши башлаганнар иде. Әйе, элекке заман булса, бәлки Бәчүк бу казадан тернәкләнеп тә китә алмаган булыр иде. Әмма да ләкин бу янгын турында болай җентекләп сөйләвемнең сәбәбе дә шунда: хәзер заман бүтән, заман әйбәт. Янганның икенче көнне үк бөтен авыл Бәчүккә ярдәм итә башлады. Кием-салым, ашау-эчү белән генә түгел, ә яңа йорт салырга акчалата да җыйды халык. Төрле оешмалар да нык ярдәм иттеләр. Бәчүк үзе бик уңган кеше — озак та үтмәде, теге янгын күмерләрен нигезеннән кырып ташлады да, менә дигән итеп, гүрничә кебек кирпеч йорт салып куйды.

Әле ул гына да түгел, хәзер мин сезгә шаккаткыч бер хәл сөйләп җиппәрим. Безнең якларда нефть чыгаруның гөжләп алга барган, бөтен дөньяда дан казанган елларында булды бу хәл. Бездән унбиш-егерме чакрымнар ераклыктагы Суркино дигән чуваш авылы бар. Билгеле булганча, чувашлар ике төрле — мәҗүси чувашлар бар һәм безнең кебек чукындырылган, христиан чувашлар бар. Әнә безнең авылга терәлеп диярлек торучы Кужминкә авылында чукынган чувашлар яши. Ә Суркино тулысы белән мәҗүси чуваш авылы, анда барлыгы 300 ләп йорт бар. Болар табигатьтәге төрле күренешләргә, әйберләргә табыналар. Утка, суга, агачка, айга, кояшка, ташка һәм башкаларга. Әмма алар боларның бөтенесенә берьюлы табынмыйлар, аларның үзләре генә белгән ниндидер еллар тәртибе, календарьлары бар. Шул тәртип буенча аларның аллалары ел саен үзгәреп тора. Бер елны аларның алласы таш, бер елны су, бер елны агач, бер елны нинди дә булса бер терлек яки җанвар һәм башкалар була. Агымдагы елда шушы әйберләрнең кайсы алла булса, мәҗүси чувашлар шуңа табыналар, шуны гына иң изге әйбер итеп кабул итәләр. Мәсәлән, теге яки бу әйбер алла булган елны аңа тияргә, аны борчырга ярамый. Таш алла булган елны аны бәреп ватарга, урыныннан кузгатырга, алып ыргытырга ярамый. Юл өстендә ятса да, әйләнеп узарга. Чөнки аллага шулай җайлы икән, ул шунда гына ятарга тиеш. Аны үзе теләгән урыннан алып ыргытсаң, алла ачуланып авылга бәла-каза китерергә мөмкин. Билгеле, бер төр агач алла булган елны ул агачны кисмиләр, сындырмыйлар. Су алла булган елны гөрләвекләр, ерганаклар, чишмәләр каян гына акса да, аны икенче якка ерып җибәрмиләр. Ә инде авылның зур буалары ерылса, шатланалар гына, янәсе моңарчы алланы тыеп, буып яткырганнар, ә хәзер ул әнә ничек рәхәтләнеп ага. Алла инде үзен буып тоткан өчен авыл халкына ачуланып бәла-каза китермәячәк. Ут алла булган елны, мәсәлән, мичкә, казан астына яккан утны яки кырда янган учакны көчләп сүндерергә ярамый, алар бары тик утыннары янып бетеп, үзләре генә сүнәргә тиеш. Әлеге гаҗәеп хәл дә шушы ут алла булган елда, ягъни ут елында була. Суркино элек-электән ярлы авыл иде. Тирә-як авыллар бөтәйгәндә дә Суркино авылы өйләре әле һаман шул салам түбәле бөкре ызбалар белән тулы булды. Әле мин олыгаеп беткәч тә хәтерлим,

Суркинода жир идәнле, морҗасыз, ягъни түтене төнлектән генә чыга торган мичле өйләр бар иде. Шул кыяфәте әлеге вакыйгага кадәр сакланды Суркиноның.

Бу эш урак өстендә, эссе чиллә вакытында була. Балалар шырпы белән уйнапмы, ни сәбәптәндер, авылның бер башында янгын чыга. Җитмәсә җил дә шушыннан авылга таба исә икән. Йорт-җир, каралты-кура түбәсе шыр салам, янгын эһ дигәнче үрләп тә китә. Яшь-җилкенчәк аһ-уһ килеп чиләкләр белән янгын сүндерә генә башлыйлар, аларны картлар туктата: «Аллага тимәгез, алла белеп эшли, алла үзе ала, үзе бирә ул»,—диләр. Телефоннан районга, күрше авылларга да шалтыратмыйлар. Бары тик өйләрдән мөлкәтне алып чыгарга гына рөхсәт итеlә. Шулай итеп, халык авылны соңгы мунчасына кадәр карап торып яндырып бетерә. Елның эссе вакытында зур янгын төтенсез яна бит ул, җитмәсә Суркино авылы тирән чокырга урнашкан — янгынны күрше авыллар да күрми кала. Нәтиҗәдә өч йөз йортлы авылның каралты-курасы көлгә әйләнә, халкы түшәк-ястыгын тотып шыр ачык һавада кала. Бу хәл икенче көнне үк район җитәкчеләренә барып ишетелә инде. Әлбәттә, район җитәкчеләре тулы бер авыл халкының ачык һавада яшәве белән килешеп тора алмыйлар, кичектергесез чара күрергә керешәләр. Әйткәнемчә, бу вакытта безнең якларда нефть оешмаларының бик көчле, шәп чаклары иде. Суркинода янгын булганның икенче көнне үк нефть предприятиеләренең, райондагы башка оешмаларның бөтен җитәкчеләрен, колхоз председательләрен райком бюросына җыялар да, оешмалар һәм колхозларның зурлыгына, материаль мөмкинлекләренә карап Суркино авылында кайсына биш, кайсына өч, кайсына бер йорт салырга йөкләмә бирәләр. Әй, шуннан китте минсиңайтим безнең районның нефть предприятиеләре, оешмалары һәм колхозлары арасында йорт салу буенча ярыш, һәркем бер-берсен уздырырга, йортларны бөтенесенекеннән дә матуррак итеп салырга тырыша. Ике-өч ай да үтмәде, күзгә кергәндә инде Суркино авылында менә дигән шыңгырдап торган нарат бүрәнәдән яки кызыллы-аклы кирпечләрдән бизәп төзелгән, һәркайсы өр-яңа шифер яки калай белән ябылган өч йөз йорт көлеп тора иде. Инде Суркино авылы халкы шатланганын, район җитәкчеләренә, нефтьчеләргә һәм тирә-күрше колхозлардагы райондашларына күрсәткән рәхмәт хисләрен күрсәң, олы бер бәйрәм диярсең. Әмма, кешеләр әйтүенә караганда, Суркинолылар соңыннан: «Менә күрдегезме, әйттек бит без сезгә, алла үзе ала, үзе бирә дип, әнә безнең иинди начар өйләрне алды да, гүрничә кебек пулатлар бирде алла!» — дип сөйләп йөргәннәр икән.

Менә шулай, дөнья булгач пожарлар да төрле нәтиҗәләр белән төгәлләнә икән ул. Мисалга ерак барасы юк, үзебезнең пожар өе белән булды шундый хәл. Әллә кайчан, сугышка кадәр үк ашык-пошык салынган ферма, амбар биналары бетте хәзер колхозларда, бар да бетоннан да таштан, түбәләре шифер белән ябылган. Ул культура йортларының эчке ягы да, тышкы ягы да гөлт итеп тора, җиһазга бай. Колхозның машина, трактор, комбайн ремонтлый торган мастерскойларына гына кара. Берсе-берсе завод кадәр бит алар. Хуҗалык йортлары, мәктәпләр, колхоз идарәсе, авыл советы, медпункт, почта биналары, кибетләр—бар да өр-яңадан салынды. Әмма бөтен авылларда да диярлек бер генә нәрсә һаман элеккечә, искечә, җәбәхәер булып калды — ул да булса пожар каравыллары, пожарный өйләре. Шуларны яңартырга, өр-яңадан үзгәртеп салырга куллары җитми әле авылларның. Бу хәл безнең авылда да нәкъ шулай иде. Безнең пожар каравылы әлеге дә баягы шул чиркәү тау итәгенә урнашкан. Чөнки моннан бөтен авыл уч төбендәгедәй күренеп тора. Шуңа күрә безнең авылның пожар каравылында гомер-гомергә биек күзәтү каланчасы булмады. Тау битенә тавык кетәге кадәр бәләкәй генә пожар өе салып куелган, аның өч ягында өч тәрәзә, шулардан бөтен авылны күзәтеп була. Пожар өенә үк терәп салынган лапас кебек бер нәрсәдә ике арба тора. Аның берсендә коргаксып беткән, бер тамчы су да тотмый торган бик зур агач мичкә, икенчесенә кул белән эшләтелә торган таганлы насос беркетелгән. Мин сиксән

яшемә җиткәндә дә ул насосның янгын вакытында адәм рәтле итеп эшләгәнен күргәнем булмады диярлек. Югыйсә инде аны янгын каравылчылары буш вакытта төзәтеп, рәтләп, су сиптерерлек хәлгә китереп тә куялар, пожар өе янында узып баручы ирләрне туктатып эшләттереп тә карыйлар иде. Ул насос үзе болай зур гына, ике тәбәлдерегенә икешәр ир тотынып суыртканда суны шактый гына еракка сиптерә дә. Аңлашыла ки, янгын каравылчылары насосны көн дә болай карап тормыйлар, киресенчә, елга бер, күп булса ике мәртәбә генә була бу эшләтеп карау. Әмма бит әле ул янгын дигән нәрсә синең насосны тикшергән, рәтләп куйган көнеңне тәгаен генә көтеп тормый, истә-оста булмаган бер вакытта кабына да куя. Кыш көннәрен әйтеп тә торасы юк инде, кышын ул насос янгын булган җиргә гомумән дә килеп җитә алмый. Чөнки ул дүрт тәгәрмәчле арбага беркетелгән, кышын чанага күчерелми. Янгын башлангач, ат җигелгән пожар арбасы чиркәү тавын төшеп авыл урамына керүгә дүрт тәгәрмәче белән дә көртка кереп бата да, атың түгел, тракторың да тартып алмалы булмый. Җитмәсә насос эчендә көзен калган сулар боз булып каткан була, насос тәбәлдереген дүрт түгел, кырык ир дә кузгата алмый. Әмма ләкин җәен дә эшләми насос — күрәсең, тикшереп караганда яки чираттагы бер янгын вакытында аның эчендә су калган була да, насоç детальләрен күтәртә. Әле тәбәлдерекләрне атындыра-атындыра насосны рәткә китергәнче әллә ни гомер вакыт уза, аңынчы инде бала-чага, хатын-кыз чиләк белән сибеп янгынны сүндерәләр, яки янгын бик котырып китеп каралты тәмам көл була. Күп вакытта янгын янына бу насосны алып килү эшкә зыян гына китерә. Ни өчен дигәндә, насос килеп җитүгә янгын сүндерүче ирләр барысы да аны эшләтү, насос рәтләү белән мавыгып китәләр. Китә тегеләй, болай итәргә, теге җирен борырга, бу җирен бушатырга дигән тәкъдимнәр, китә бәхәс — азмы-күпме рәтле, тазалыгы булган бөтен ир-ат янгынның бар икәнен дә онытып, насос тирәсендә кайнашалар. Кайчакта карт-коры, бала-чага, хатын-кыз инде янгынны сүндереп таралышып беткән була, ә таза-таза ирләр әле һаман бәхәсләшә-бәхәсләшә насос төзәтәләр.

Шушы насос һәм әлеге буш мичкә тора торган лапастан бераз гына читтә пожар атларын аерып торган бәләкәй генә абзар. Анда гомер буена начар гына ике ат асралды.

Гадәттә, пожар каравылчысы булып карт-коры эшли. Җәен-кышын пожар өе тирәсендә үткән-сүткән, эштән иртәрәк кайтып яки эшкә бөтенләй бармаган биләмче ир-ат җыелып ята. Алар тәмәке тарталар, җыен юк-барны лыгырдыйлар, ирләр гайбәте саталар. Бу бөтен авыл пожарныенда да шулай. Ахыр килеп, пожар каравылчысы булып эшләү авылда бик үк мактаулы эшләрдән дә саналмый. Шуңа күрә кайбер елларда авылда пожар каравылчысы итеп куярлык кеше дә табып булмый. Әмма пожар өен каравылчысыз калдырырга ярамый, каядыр янгын чыкканны күрүгә чаң кагарга булса да кеше кирәк бит. Әнә шундый юньле каравылчы булмаган чакларда пожарныйда авыл кешеләре йорт борынча чиратлап дежур торалар. Дежур көнне каравыл өендә ике кеше куну мәҗбүри. Әле моннан ике ел элек кенә авылда әнә шулай чиратлап дежур оештырылды, һәм шул елны пожар өебез үзе үк янып та китте.

Көзге яңгырлы, лычма пычрак вакыт иде бу. Көн дә яңгыр ява, ә авыл халкы әле һаман бакчаларыннан бәрәңге алып бетермәгән. Бу көнне пожарныйда ике күрше хатын дежур торып кунарга тиеш икән. Болар көне буе бакчаларында яңгырда чыланып бәрәңге алганнар да, барыбер топ буе эш юк, пожар өенең мичен ягып киемнәребезне киптерербез әле дип, каравыл өенә менеп киткәннәр. Өсләренә алмашырга җылы күлмәкләр һәм каравыл өендә киеп йөрергә коры оеклар гына алган болар. Шулай итеп, сөйләшә-сөйләшә каравыл өенең бәләкәй генә мичен күп итеп ягып җибәргәннәр, мичнең төрле урынына юеш киемнәрен салып элгәннәр, аякларына йон оекларын, өсләренә күлмәкләрен киеп, сөйләшә-сөйләшә чәй эчкәннәр. Әмма бит көзге төн бик озын ул, сөйләшеп сүзләре беткән, бик мул итеп ягылган мичтән өйгә тәннәрне оеткыч җылы да төшкән, бер мәлне йокылары килеп

иснәнә башлаган болар. Мичкә эленгән кием-салым әле кибеп, мич эчендәге күмерләр сүрелеп тә бетмәгән, түр сәкедәге салам түшәктә бөгәрләнеп татлы йокыга да талган ике дежур хатын. Көне буе юеш җир казый-казый арыган тәннәре тәмам эреп кенә киткән инде боларның. Каравыл өенең мичендә ярыклар булган икән, күмер кызуы шул ярыклардан чыгып, тәмам кибеп, кызып беткән киемнәргә ут капкан. Күрәсең, ут мич артындагы киемнәргә кабынып киткәндер, чөнки болар йоклаганда вак бүрәнәләрдән генә буралган каравыл өенең ул почмагы бөтенләй янып беткән, ут әлеге буш мичкә белән насос торган лапаска капкан. Шунда гына утны авыл кешеләре күреп алганнар. Алар җыелгалап житкәнче, инде лапас кебек нәрсә ишелеп төшеп мичкәләре, насос арбалары-ние белән янып беткән, ут атлар абзарына да үрли башлаган. Ә бу ике хатын каравыл өенең янмый калган почмагында айны-вайны белмичә йокы симертәләр икән. Өйнең инде ишек як стенасын да ут ялмаган булган. Теге ике «пожарник» хатын авыл ирләре килеп җитеп, җитмеш җиде катлы итеп сүгенә-сүгенә, күсәк белән бәреп тәрәзәне ваткач кына уянып киткәннәр дә тәрәзәдән урамга сикергәннәр. Ярый әле чыгып өлгергәннәр, югыйсә үзләре дә янып үләселәр икән. Бу хәл иртәнге сәгать бишләр тирәсендә булган. Ирләр утны ат абзарына кадәр үрләтмәгәннәр, сүндергәннәр.

Әмма дә ләкин теге ике хатын бик нык курыкканнар. Куркудан, каушаудан һәм авылдашлары алдында шушы кадәр адәм мәсхәрәсенә калудан аларның телләре тотлыккан, юньләп сүз әйтә алмас хәлгә килгәннәр. Җитмәсә, авылның бригадиры да җикеренә икән боларга: «Мин сезнең өчен җавап бирмим, барыгыз, колхоз персидәтеленә үзегез өчен үзегез җавап бирегез»,— ди икән. Безнең колхоз персидәтеле көн дә иртәнге сәгать биштә идарәдә була. Шуннан бу хатыннар оектан гына чапыр-чопыр көзге пычрак ерып төшеп китәләр инде колхоз идарәсенә. Җавап тотасы бар бит, никадәр җәмәгать милкәте янып харап булды, түләтә башласалар, ничек түләп бетерерсең. Шуннан тасырдап килеп керәләр болар персидәтел бүлмәсенә. Теге әле бу хәлләрдән хәбәрдар түгел икән. Каушаудан хатыннарның икесенең берсе хәлне аңлатып бирә алмый.

— Нәрсә бар, ни йомыш?— дип сорый персидәтәл.

— Пожарга... пожарга... ут капты... пожарга ут капты...—дип буталалар икән теге ләр. Персидәтел аңлый алмый гына бит боларның сүзен.

— Ни сөйлисез сез, пожарга ничек ут капсын, пожар үзе ут ич инде ул,—дип аптырый ул. Аннары боларның кыяфәтенә, үз-үзләрен тотышларына яхшылабрак карый да, шикләнеп куя.

— Әллә бер-бер янгын чыктымы?

— Әйе...—диләр теге ләр икесе берьюлы,—янды... бетте... бөтенесе дә янып бетте...

— Нәрсә, әллә фермаларга ут каптымы?—дип сикереп тора персидәтел.

— Юк... юк... фермага түгел... пожарга... пожарга ут капты...—диләр теге ләр һаман исләренә килә алмыйча.

— Нинди пожарга? Аңлатыбрак сөйләгез!—дип, бар көченә кычкырып җибәрә персидәтел, ниндидер хәвеф барын сизенеп.

— Пожарга... пожарныйга ут капты... Пожар өе дә, лапасы да, насосы да, мичкәсе дә янып бетте, атлар абзары гына калды,—дип аңлатып бирәләр теге ләр, ниһаять. Шуннан персидәтел боларны шаккаттырып кычкырып көлеп җибәрә һәм:

— Вәт шәп булган,—ди,—инде бөтен авылны менә дигән итеп төзеп бетереп, шул пожарныйга гына һаман кул җитми иде, хәзер инде өр-яңасын төзергә мәҗбүр булачакбыз. Шул тавык кетәген яндырмасагыз, әле яңа пожарный төзүне һаман сузып йөргән булыр идек. Әшне кызуландырдыгыз, рәхмәт сезгә, түтәйләр, —дип коты очкан ике хатынны тәмам тынычландырып чыгарып җибәрә. Теге ләр инде идарәдән, безне персидәтел мактады дип күкрәкләрен киереп, йон оеклары белән урам пычрагына горурлык белән чәпелдәтеп баса-баса кайтып китәләр. Үзләренең нинди дәмәк хәлдә калганнарын уйлап та бирмиләр теге ләр... Чыннан да, персидәтел әйткән

сүзендә торды, янгын куркынычсызлыгы тәртипләренең бөтен шартын туры китереп яңа пожарный төзетте, аның гаражына кып-кызыл янгын сүндерү машинасы кайтартты. Бу инде сиңа теге тәбәлдерекле насос кына түгел, суны авылның бер ягыннан икенче ягына ук аттыра. Әмма ләкин пожарныйда бер нәрсә үзгәрешсез калды — ул да булса каравылчы булып эшләргә хеше юк. Һаман да шул миннән аз гына яшьрәк булган ике карт эшли анда. Әле күптән түгел генә узышлый кереп чыккан идем үзләре янына. Якты, җылы, иркен каравыл өе. Мин яңа пожарныйны мактагач:

— Әй, Җәгүр кордаш, бар да әйбәт, ләкин бер нәрсәгә аптыраган — инде бер ел буена авылда янгын чыкканы юк. Үзебез үлгәнче шушы пожар автомобилен сынап карыйсы килгән иде,— диләр тегеләр. Үзләре тешсез авызларын ерып көләләр. Шаярталар, әлбәттә, тел тегермәне тарталар. Ел буена бот күтәреп ятып, нишләсеннәр соң ул картлар шаяртмыйча. Кайтсалар — өйләре, монда килсәләр — пожарныйлары җылы, мондагы жалунҗалары өстенә ай саен пенсияләре килеп тора.

## Дүртенче дәмәк

### Алтын кач

Безнең авылның чиркәве дә бар иде. Хәзер юк инде. Моннан бернича ел элек аның жилдә селкенеп торган соңгы диварларын да бульдозер белән эттереп ташладылар. Хәзер безнең авылда «чиркәү» дигән исем дә, авылны икегә ярып, үзәк урамнарга ук килеп кергән текә тауда гына сакланып калды. Аны авыл халкы әле һаман «чиркәү тавы» дип йөртә. Шул тауның нәкъ маңгаена, бик мәһабәт урынга, авылның, тирә-як кырларның бөтен җиреннән күренеп торган урынга салынган иде ул чиркәү. Хәзер ул тауның итәгенә, бик матур, күркәле урынга Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларга зур һәйкәл салып куйдык. Анда кулына автомат тоткан совет солдаты басып тора, шунда ук сугышта ятып калган авылдашларның исемлеге дә бар.

Әлбәттә, мин чиркәүнең салынган вакытын хәтерләмим. Читтән китерелгән балта осталары салдылар, дип сөйлиләр иде мин яшь чакта картлар. Нигезе шикәр кебек ап-ак, юкә тактасы кебек тип-тигез итеп шомартылган зур-зур дүртпочмаклы ташлардан салынган иде. Бу ташлар — атаклы Чупай ташлары нәселеннән. Әлмәтнең хәзерге үзәк өлеше, тулы бер шәһәр әнә шул Чупай ташыннан төзелде бит. Ә Чупай кырлары белән безнең авыл кырлары ызандаш. Чупай тавының безнең авыл җирләренә кадәр үк сузылып киткән итәкләрендә, Чупайдагы кебек үк мул булмаса да, бик әйбәт ак таш ятмалары бар. Авылыбыздан өч-дүрт кенә чакрым ераклыктагы Таштау дигән урында бу таш аеруча мул. Безнең чиркәүгә нигез өчен ташны әнә шунда, Таштауда ук кисеп, шомартып алып кайтканнар, дип сөйли иде өлылар.

Тагын авылда, имеш, чиркәүне салганда аны Алла мәңгегә сакласын, ул изге урын булсын өчен, нигезенә алтын кач (тәре) салып калдырганнар икән, дигән сүз дә йөри иде. Монысын халык урамда авыз күтәреп түгел, ә бер-берсенә пышын-пышын гына сөйли. Ә үзегез беләсез инде, авылда пышын-пышын сөйләнгән сүз трибунага менеп мең мәртәбә кычкырганнан да тизрәк тарала һәм тәэсирлерәк була.

Чиркәүнең үзе бик шәп нарат бүрәнәләрдән бурап ясалган, тышы киң нарат такталар белән тышланган иде. Безнең авыл халкы гадәтләнгән биналардан аермалы буларак, чиркәүнең бер гаҗәп ягы бар иде: агач булуга карамастан, идәнгә такта түгел, ә нигез белән берочтан әнә шул ап-ак таш җәелгән иде. Чиркәүнең өч ягында өч бик зур тимер ишек булып, авылга карап торган зур челтәрле ишек иң олы бәйрәмнәрдә генә ачыла иде. Ул

чиркәү эчендәге затлы җиһаз, бизәк-мазар, шәмдәлләр, буяулы рәсемнәр, иконалар, алтын йөгертелгән агач ишекләр, алтарь бизәкләренең иге-чиге юк иде. Безнең гомергә ярлы, хәерче, надан булган, салам түбәле, чабаталы керәшен авылы уртасында бу чиркәү чын мәгънәсендә бер могҗиза булып утыра иде. Утызынчы еллардан соңгы яшьләр инде чиркәүнең мондый чагын күрмәделәр, әлеге дингә каршы көрәшүче оешмалар аякланып киткәч, чиркәүгә карата чын мәгънәсендә сугыш игълан ителде. Сүз дә юк, коммунистлар чиркәүнең диненә, янәсе, халыкны алдаган ышандыруларына, алар әйткәнчә, «алдашып баеп ятучы сорыкорт» побына, чиркәү законнарының «халыкны тыеп, изеп, караңгылыкта яшәтүенә», гомумән, кылган гамәленә каршы сугыш ачтылар. Революция халыкның аңын дини яктан түгел, белем ягыннан ачачак, диделәр алар. Ярар, монысына мин бик үк тыгыла да алмыйм, тик чиркәүнең бинасы, төзелеше, аның эчендәге матур бизәкләр, нәкышлар, шәмдәлләр, кыңгыраулар, картиналар, буяулар, музыка инструментлары, җиһазлар белән сугышырга кирәкми иде. Моны өстәгерәк түрәләребез дә шулайрак кушканнардыр дип аңлыйм мин. Чөнки бит чиркәүне поп салмаган, авыл картлары әйтүенә караганда, аны нәкъ безнең авыл кешеләре кебек үк гап-гади балта осталары килеп салган. Аннан соң мин, бөтен попларны да бер чыбыктан куалап, барысын да халыкның сыртын игәүләп яшәүче зобаныйлар дип, кырт кисеп әйтмәс идем. Бигрәк тә халыкны караңгылыкта, наданлыкта тотуда бөтен поплар да бердәй үк гаепле түгел. Ни дисәң дә, безнең чиркәү янындагы бәләкәй генә мәктәптә авыл побы инде революциягә кадәр үк бала-чагага азмы-күпме хәреф таныта башлаган. Ә инде укытучы попка килсәк, шунсын да онытмаска кирәк, хәзерге мәктәпләрдә бик яхшы укытучылар белән бергә бик начар укытучылар да булган кебек, попларның да балалар укыту эшенә төрлечә караучылары булган, бик начарлары булса, әйбәтләре дә булмый калмаган. Әнә бит, татар халкының күренекле шагыйре Яков Емельянов үзе дә авыл чиркәвендә дьякон булып эшләгән. Әйтәсе килгәнем шул — һәр эштә дә бодайны кибәктән аера белергә кирәк. Кыскасы, революциядән соңгы елларда чиркәүгә каршы сугыш ачылган очракта да, ул сугыш аның бинасы һәм җиһазына каршы юнәлдерелергә тиеш түгел иде.

Әмма безнең авылда моның киресе килеп чыкты. Авылда активлар арасында диннең чын зыянын ачып салырлык итеп лекция-фәлән сөйләүче, агитация-мазар ясый алырлык башлы, белемле, грамытлы кеше юк иде. Монысы өчен аларга үпкәләп тә булмый. Шулай итеп, чиркәүне рухи яктан туздырып ташларлык кеше табылмады. (Бәлки аны туздырып булмый да торгандыр?!) Ә менә аның бинасын һәм җиһазларын бик шәп туздырдылар. Иң беренче чиратта юкә агачыннан бик тә матур итеп юнып чәчәк, яфрак рәсемнәре ясалган һәм тулаемы белән елкылдап торган алтын төсенә буялган алтарьның бөтен җиһазларын чиркәү тавы итәгендәге пожар буасына ыргыттылар. Гомумән, пожар буасына бик күп чиркәү җиһазы очты ул көннәрдә. Киң-киң такталарны бер-берсенә ябыштырып ясалган, зур-зур өстәл өсте кадәр иконаларны урамга алып чыгып, пычракка ыргытып, чабаталы аяклары белән таптаучылар да булды. Ул иконаларга төрле-төрле дини изгеләр рәсемнәре төшерелгән иде. Җиргә ташланган иконаларны өйләренә алып кайтып, такталарыннан өстәл, урындык, эскәмия һәм башка нәрсәләр ясаучылар да булды. Шундый бер өстәлне әле мин соңгы елларда гына да Пидура исемле бер карчыкның өендә күрдем. Авылда Пидураны (Федора) үз исеме белән атап йөртмиләр, ә Гөри Питер хатыны дип кенә йөртәләр. Аның ире Гөри Питере яшьтән үк авылда бик хөрмәтле, ипле, оста кеше иде, гомере генә озын булмады үзенең. Күрәсең, яшь чакта күп кызлар Гөри Питеренең хатыны булу турында хыяллангандыр. Ә бу бәхет Пидурага гына эләккән. Әмма Пидура булу әллә ни зур мәртәбә түгел, Пидура исемле хатын-кыз авылда күп, ә менә Гөри Питеренең хатыны булу инде бик зур дан. Пидуралар күп, ә Гөри Питер хатыны бер генә!

Менә шул Гөри Питер хатынының өендә күрдем мин ул иконаларның берсен. Безнең авылда зур бәйрәмнәр алдыннан өйне кырып чистарту

гадәте бар. Өй кыру өмә итеп эшләнә. Өй кырырга биш-алты хатын чакырыла, алар көн дәвамында үткен кыргычлар белән өйнең түшәмен һәм дивар бүрәнәләрен ап-ак итеп кырып, юып куялар. Өмәгә шушы хатыннар янына бер оста ир дә чакырыла. Ул хатыннарның коры бүрәнә һәм такталарны кыра-кыра бик тиз үтмәсләнә торган кыргычларын үткенли. Бер көнне бөтен бала-чагасы да инде күптән шәһәрләргә таралып бетеп, ун еллар буе япа-ялгыз яшәгән Гөри Питер хатыны өй кырырга уйлаган бит. Кыргычлар үткенләргә мине чакырды. Килдем, хатыннар җыелган, эшли башладык. Гадәттә, хатыннар түшәмне кырганда өстәл өстенә басып эшлиләр. Безнең авылда өстәлгә аерата бер хөрмәт бар — беркайчан да аның өске ягына аяк белән басарга рөхсәт ителми, бу бездә электән килгән бик катгый йола. Теге яки бу эш эшләү өчен өстәлгә аяк белән басарга туры килә икән, өстәлнең өстен аска әйләндереп куялар да, өстәл тактасының аскы ягына басалар. Гөри Питер хатынында да, эш түшәмгә җиткәч, өй кыручы хатыннар өстәл өстен әйләндерергә тотындылар. Ул да булмады, Пидура карчык өстәлгә чат ябышты: «Әйләндермичә генә басыгыз, өстенә генә басып кырыгыз, әйләндерергә ярамый»,— ди бу. Без барыбыз да аптырап калдык. Мин өстәл өстенең бер кырыеннан күтәреп аскы ягына карасам, ни күрим — анда инде буяулары купшыра башлаган икона. Рәсемнән ниндидер бер изге карт туп-туры минем күзләремә карап тора. Шуннан инде хатыннарга, беренче мәртәбә авыл йоласын бозып, өстәлнең өске ягына басып (дөрес, Гөри Питер хатыны аңа иске ашъяулык капларга өлгерде) түшәм кырырга туры килде. Кайчандыр урамга ыргытылып, пычрак чабаталар белән тапталган апостолның чыраена инде сиксәненче елларның чытлык хатыннары аяк белән басарга кыймадылар.

Ә теге чакта чиркәү җиһазлары белән ни генә кыланмадылар?! Безнең Көҗмәндрич исемле ызбач бар иде. Әйткәнемчә, безнең авылда беркем дә бер-берсенә русчалатып этисенең исеме белән дәшми. Ә Көҗмәндрич — актив, ул культуралы булырга тырыша һәм һәркемнән үзенә Кузьма Андреевич дип мөрәҗәгать итүне таләп итә. Әмма безнең төрки авызлы керәшеннәрнең болай ук әйтергә теле әйләнми. Шуннан авылдашлар аны үзләренчә гап-гади генә итеп Көҗмәндрич дип йөртә башладылар. Үзе таләп иткәнчә дә әйтеләә, үзебезнең авыл теленә дә ятышлы. Тора-бара теге үзе дә моңа тәмам күнегеп китте. Һәм Көҗмәндрич дигән исем моңа гомерлеккә ябышып калды... Гражданнар сугышы елларында безнең якларда чуалышлар аңлап бетереп булмыслык дәрәҗәдә катлауланып китте. Бу табигый да — бер якта Европадан Себергә алып бара торган тимер юлның төп станцияләреннән булган Бөгелмә, бер якта Келәүле станциясе, икенче якта Идел-Кама су юлының әһәмиятле пристаньнарыннан Чаллы белән Чистай. Ә без шуларның нәкъ уртасында утырабыз. Аклар бу бик әһәмиятле нокталарны бирмәскә чирәшеп ята, ә безнең кызыллар өчен боларны алу революция язмышы белән бәйләнгән. Ул чакта бит әле аклар белән кызылларны киемнәреннән, атлар-сбруйларыннан, коралларыннан гына аерып бетерү дә кыен иде. Алары бит аның барысы да бер төрле, үзебезнеке, Россиянеке. Җитмәсә безнең якларда кызылларга бөтенләй капма-каршы булган, шул ук вакытта аклар да булып җитмәгән «сәнәкчеләр» дигәннәре дә күтәрелеп чыкты.

Менә шулай, килеп керә авылга атлы, коралы отряд, кемнәр икәнен белми аптырыйсың. Туктатып сораша башласалар, ничек сөйләшергә белеп булмый. Кызыллар булса, ансы ничек сөйләшергә икәнен беләбез, ә менә аклар яки сәнәкчеләр булса, бик чамалап сөйләшергә туры килә. Кызыллар ягына салам кыстырыбрак сөйләшкәнеңне сизсәләр, баскан урыныңда ук атып егалар. Бервакыт авылга килеп кергән аклар безнең өч ирне атып үтерделәр. Ә бит аклар үзләрен дин яклы итеп күрсәтәләр иде, шулай да теге өч крестьянны бер гаепсезгә чиркәү нигезенә терәп үк диярлек аттылар, алладан да курыкмадылар.

Көрәшләр бик авыр, сугышлар бик каты булган, күрәсең, кызылларның да тәмам ачуы чыгып җиткән иде, үзләренә аз гына каршылык күрсәтүгә дә

каты чаралар күрәләр. Җитмәсә, кызыллар куркынычсыз походлар һәм тәгаен җиңгән бәрелешләрдә генә ал байраклар күтәрәләр, җиңнәренә һәм бүрекләренә кызыл тасмалар тагалар. Көндәлек тормышта, авылдан-авылга күчү белән бәйле яки дошманның каян килеп чыгасы билгесез булган сугыш операцияләре вакытында кызыллар, тактика дигән булып, ул нәрсәләрен яшереп куялар. Гадәттә, авылга килеп кергәндә, аларның тәмам ачуы чыккан була, үзләре дә акларның кайсы якта, бу авылның нинди авыл, акларны эзәрлекләп яки алардан качып авылның кайсы ягынарак чыгып китәргә икәнен белмиләр, акларның әле алларына, әле артларына төшеп, ориентирны югалтып, адашып беткән булалар. Менә шундый чакта аларга очрама гына инде. Хәтта сез кызылларны, акларны дип сорау да сәяси хатага санала һәм моның өчен туры мәгънәсендә башың белән җавап бирергә дә мөмкин. Кызылларны аклардан аера алмый торган деклассированный элемент булып исәпләнәсең, ә моның нәтиҗәләре шактый фаҗигале булып тәгалләнәчәк. Шундый кызган бер мәлдә кызыллар да безнең авылның берничә ирен атып киттеләр.

Менә шундый чуалчык, мәтәвекле вакытта Көҗмәндрич ызбач булып эшли иде. Аның хәзерге авыл клублары вазыйфаларын үтәүче уку ызбасы совет лозунглары белән бизәлгән. Өстәлдә большевиклар чыгарган берничә брошюра да бар. Ул чактагы гадәт буенча ызба кыегында кызыл әләм җилферди.

Авылга таныш булмаган отряд якынлашуын малай-шалай алдан ук күреп, бар халыкка хәбәр сала торган иде. Яки берәр чит авылдан кайтучы безнең авылга отряд килергә җыенганлыгын әйтә. Көҗмәндричнең бар кайгысы отрядның кемнәр икәнен тәгаен белүдә — акларны, кызылларны? Аклар килә икән дип ишетсә, ул тиз генә ызба түбәсенә менеп кызыл әләмне алып төшә, ызба диварыннан бөтен лозунгларны кубарып ала, брошюраларны җыеп куя. Янәсе, аклар килсә, күрәләр, монда бернинди кызыл пропаганда юк, һәм Көҗмәндрич исән кала. Ә инде кызыллар килә икән дисәләр, Көҗмәндрич тиз генә әләмне менгереп кадый, лозунгларны диварга ябыштырып куя, брошюраларны өстәлгә тезә, чистарынып-төзәтенеп, киң елмаеп баскыч башына чыгып баса.

Бервакытны авылга бер отряд кереп килүен хәбәр итәләр, әмма тәгаен генә кемнәр икәнен белүче юк. Көҗмәндрич лозунгларын, брошюраларын тоткан килеш нишләргә белмичә бер урамга йөгереп чыга, бер ызбасына керә, очраган бер кешедән отрядның кемнәр икәнен сорый. Инде отряд килеп җитте дигәндә генә аклар икәнен белеп ала да, бөтен кызыл коткы әсбабын тиз генә ызба базына тондыра. Шулай итеп исән кала Көҗмәндрич.

Ә икенче бер вакытта аңа кызыллардан бик каты эләгә дә. Бу көнне авылга аклар отряды килә икән, инде Чыршылы авылыннан чыкканнар, безгә килеп җитәләр, дигән хәбәр тарала. Көҗмәндрич тиз генә уку ызбасына барып кызыл коткы әсбапларын базга ыргыта. Ызба кыегында әләм дә юк, диварлар да шып-шыр, өстәлендә дә ник бер сыңар гәзит булсын. Әмма аклар дигәнебез кызыллар отряды булып чыга. Алар авылга керүгә уку ызбасын сорыйлар, карасалар — ызба шып-шыр. Бер солдат ызба базын ачып караса, анда кызыл әләм, лозунглар һәм большевик брошюралары ята. Шуннан командир ызбач Көҗмәндричне чакыртып китерә дә тетмәсен тетә тегенең, син совет пропагандасын базда ябып саклаучы аклар себеркесеме әллә? Кызыл пропагандага мондый саботаж ясавың өчен революцион трибунал сине аяп тормас иде, ярый әле кесәңдәге комсомол билетың коткара, ди. Шуннан соң ул Көҗмәндричкә шушы ызба базында өч көнлек арест бирә. Көҗмәндричне базга ябып, баз капкачына коралды солдат бастыралар. Ләкин шул ук көнне отряд чапкыннары командирга ниндидер яңа хәбәрләр китерәләр, отряд тиз-тиз җыенып авылдан чыгып китә. Бу ыгы-зыгыда инде, әлбәттә, аларның кайгылары Көҗмәндричтә булмый — аны шул килеш калдырып китәләр. Отряд китүгә, авылдашлар Көҗмәндричне баздан чыгаралар.

Менә шушы ызбач Көҗмәндрич чиркәү җиһазларын пыран-заран китерүче активларның берсе иде. Бер көнне ул чиркәүне ничек туздыралар

икән дип күрергә җыелган халык алдында, урамга яки пожар буасына чыгарып ташлау өчен дип чиркәү диварларыннан алынган һәм чиркәүнең бер почмагына өеп куелган иконаларның берсен алган да, анда төшерелгән изге карт рәсемен эт итеп сүгә икән: «Син, сволочь, хәзерге көнгә кадәр халыкны алдап караңгылыкта, наданлыкта тоттың, менә хәзер безнең дә синнән үч алыр вакытыбыз җитте!...» Аннары ул: «У-у-х, мин сине чәйнәп ташлар идем»,—дип рәсемдәге изге картның борыннарын, колакларын, битләрен тешләгәндәй итә башлый...

Көҗмәндрич бик картаеп үлде. Гомеренең икенче яртысында ул бик озак еллар балалар укытты, авылның беренче укытучысы булды, эшен бик тырышып эшләде, авылда зур хөрмәт казанды. Гомеренең соңгы елларында аны паралич сукты, шуның нәтиҗәсендә авызының бер ягы кыегаеп калды. Шуңа нигезләнеп авылдагы кайбер усал телләр: «Теге елларда иконаны тешләгән өчен Алла Көҗмәндричнең авызын кыегайткан»,—дип авыз да чайкадылар.

Чиркәү җиһазларын туздырганда иконаларны мыскыллау шул дәрәҗәгә барып җиткән ки, кайбер оятсыз ирләр хәтта аларга пес тә иткәннәр, дип сөйләделәр. Монсын мин үзем күрмәдем, тәгаен генә әйтә алмыйм, әмма авылда бу сүз бик нык таралды. Шуны эшләгән ирләрнең исемнәрен әйтеп сөйлиләр иде. Инде ул вакыйгалардан соң бик күп еллар үткәч, сугыштан соңгы тыныч елларда авылыбызның бер тол хатыны андый ирләрнең берсе турында миңа үзе сөйләде. Туган-тумачаларын оялтмас өчен ирнең дә, аны сөйләгән хатынының да исемнәрен әйтеп тормыйм. Теге хатын гомергә кияүгә чыкмады, шулай да аның балалары күп булды. Үзе болай чибәр, таза, матур, эшчән генә хатын иде, кияүгә чыга алмады. Ник дисән, бик чая иде. Яшьли чая булды һәм яшьли уйнаштан бала тапты. Беренче баладан соң оялып-нитеп тормады, җиде-сигез ел дигәндә тагын дүрт бала тапты. Болай ачыктан-ачык азып-тузып та йөрмәде, балаларын да бик тырышып тәрбияләде, берсен дә балалар йортына бирмәде. Чаялыгы, чибәрлеге, уңганлыгы, бигрәк тә шаянлыгы гомере буена сузылды, авылның бөтен хатыны аннан көнләшүдән шартлардай булып яшәде. Аның һәрбер баласын авылның һәрбер хатыны үз иреннән дип исәпли иде. Шулай итеп, бу ятим балаларның, фараз иткәндә, әллә ничәшәр этиләре бар иде. Җитмәсә, авыл ирләре хатыннары белән сүзгә килсәләр, тегеләрнең көнләшүдән болай да дөрләп янган йөрәкләренә бензин сипкәндәй, чибәрлек, уңганлык үрнәге итеп теге хатынның исемен әйтәләр иде. Ә теге хатын гайбәтләргә төкереп тә бирми, колхоз эшендә каерып эшли, теләсә кем алдында үзен лаеклы тота, телен бик озайткан гайбәтче хатыннардан үчне дә үзәккә үткәрерлек итеп ала — тегенең ирен бәрәр төнгә үз янында кунарга калдыра. Ә сез, үзегез беләсез инде, безнең ир-ат халкы бу мәсьәләдә йомшак халык, бигрәк тә мондый отчаяный хатын янында...

Менә шул хатын сөйләде миңа иконаны алда әйткән юл белән мыскыл итүче бер оятсыз ир турында. Миң үзем дә ул ирне әйбәт хәтерлим. Тазалыкка таза, әмма да ләкин бик тупас, хатын-кыз мәсьәләсендә тотнаксыз, авызы тулы пычрак, оятсыз сүз иде. Авылда байтак хатын-кыз зарланды аның тупас рәвештә оятсызлануыннан. Әлеге миңа сөйләгән хатын әйтә:

«Мин үз күзләрем белән күрдем аның иконага пес иткәнен,—ди.— Иконага күкрәген ачып бала имезеп торучы, ялварулы күзләре белән күккә караган яшь ана рәсеме төшерелгән иде. Теге оятсыз: «Менә сиңа, менә сиңа...»—дип сөйләнә-сөйләнә, хахылдап көлә-көлә, яшь ананың битенә, күкрәгенә, ими капкан сабый балага чаптырды. Минем әле анда беренче балам гына туган чак иде. Моны күргәч мин кинәт имәнеп киттем, бугазыма каты төер тыгылды. Чөнки бит мин эчтән генә бу егетне яратып, аның баһадир гәүдәсенә сокланып йөри идем. Минем эчке яратуым белән, әле генә күргән вәхши бу хәл күкрәгемдә берләшеп, мине тәмам дивана хәленә китерде. Мин кешеләргә сиздермичә генә чиркәүдән йөгереп чыктым да, өйгә кайтып, сабыемны кочаклап, өч сәгать буе еладым. Шунда минем дөньядагы бөтен ирләргә карата нәфрәтем кузгалды. Ул чакта әле теге ир

өйләнмәгән егет кеше иде. Бер мәлне бу килгән миңа, балаң белән алам, чык миңа кияүгә, ди. Мин әйтәм, гомеремдә бер гарип ир күрмәсәм дә синә кияүгә чыкмыйм, дим. Оятсызлыкның чиге юк бит аның, бу миңа әйтә, әйдә алайса, болай гына, өйләнешмичә генә, ди. Минем кичтән ипи пешерергә дип яккан мичне тартып маташуым иде, шул сүзне ишетүгә, кайнар кисәү агачы белән куып чыгардым тегене. Юньлерәк ир-ат белән алай тупас кыланмыйм мин, Җәгүр дәдәй. Аннан соң теге өйләнеп җибәрде, сугышка кадәр үк ике баласы да туды.

Әлеге вакыйгадан соң тагын бер икәүдән-икәү генә очрашырга туры килде миңа моның белән. Монысы инде озак еллар үткәч, сугыштан соң булды. Үзең дә беләсең инде, Җәгүр дәдәй, ул ир сугыштан зур батырлыклар күрсәтеп, йолдызлы погоннар тагып кайтты. Үзең дә сугышта булган кеше, сугыш вакыты кешене анда гына түгел, монда, тылда да тегеләй дә, болай да талкыды. Менә дигән актив дип йөргән кешеләрдән сатлык җаннар да килеп чыкты, әлеге ир кебек әшәкеләрдән батыр, әйбәт кешеләр дә әвәләде сугыш. Сугыштан соң, үзең беләсең, Җәгүр дәдәй, барыбыз да берберебезгә якынайдык. Чөнки сугыш елларында бер-беребезгә сыенышып, бер-беребезне ач үлемнән, дөмә ятимлектән саклый-саклый, фронттагылар авылдагыларны, авылдагылар фронттагыларны сагына-сагына яшәдек. Теге эшләргә инде байтак еллар да үткән, сугыштан яхшырып кайткан теге иргә күңелем йомшады минем. Аннан соң ул, сугыштан батыр булып кайтуга карамастан, нииндидер боек, күңеле китек кеше кебек йөри иде. Мин моны тоеп, эчтән генә ничектер кызганып та йөри башладым. Тегенең хатыны, ике баласы бар бит инде, сугыш алдыннан ук туган балалар. Бердән-бер көнне безгә, теге ир белән икебезгә бер ат җигеп, икебез бер арбага утырып Колмаксардагы ашлык сугучылар янына барырга туры килде. Юлда, урман аланына кереп, арба төбенә салу өчен печән чабып чыкмакчы булды бу. Бик матур җәйге вакыт, урман эче саф, салкынча, рәхәт. Урак өсте бит, күптән инде болай урман эчләренә кереп, хушланып йөргән юк иде, минем кәеф бик күтәрелде. Теге хуш исле печән чабып арбага түшәде дә, кинәт миңа карап туктап калды. Минем дә бит инде тел тик тормый, чытлыклана, үзем дә сизмәстән:

— Нәрсә, әллә теге елларда үкенечкә калганны исеңә төшердеңме?— дип әйтеп ташладым.

— Юк,— ди бу,— миндә хәзер андый уйлар юк инде, мәнә синең чибәрлегеңә генә сокланып торам,— ди.

— Нишләп юк әле андый уйлар, теге чакта бик әтәчләнгән идең бит.

Кинәт аның йөзе караңгыланып китте. Йодрыгын йомарлап, һәр сүзен теш арасыннан гына сөзеп: «Сволочь фашист пулясы шунда тиде»— диде дә арба үрәчәсенә бала башы кебек йодрыгы белән китереп орды, хәтта ат куркуыннан кинәт тартылып куйды.

Менә, Җәгүр дәдәй, Алланы юк, дибез дә, теге эшләре өчен Алла каргаган аны, икмәктер, кояштыр менә»

Мин бу шаян, чая хатын сүзләреннән көлеп куйдым. Әнә бит халыкның хыялый, иҗади фикерләве нинди киң, шундый четерекле нәрсәләрне дә тәмам ышандырырлык итеп сөйли белә.

Инде әлеге дә баягы чиркәүгә килсәк, аның эчке стеналарын шып-шыр калдырып, җиһазларын кайсын кая таратып бетерделәр. Гөмбәзендәге зур кыңгырауны алып төшеп, пожар каланчасына асып куйдылар. Тавышы бик яңгыравык, янгын-фәлән чыкса, чаң кагарга бик шәп иде. Ул кыңгырау әле менә соңгы елларга кадәр пожарный каланчасында эленеп торды да кинәт әллә кая юкка чыкты. Югыйсә бит инде ничәмә-ничә потлы җиз кыңгырауны беркем дә күтәреп китә алмый. Хәзер зуррак шәһәрләрдә аерым кешеләр борынгы, иске-москы әйберләрдән нииндидер коллекцияләр җыялар икән дип ишетәбез. Иске сәгатьләр, самавырлар, иконалар, кыңгыраулар һәм башкалардан. Бәлки шундыйлардан берәрсе безнең кыңгырауны күреп кызыгып калгандыр да төнлә машина белән килеп урлап киткәндер. Бер дә белеп бетереп булмый. Ә чиркәүнең тагын бер кыңгыравы, бәләкәй генә

жиз кыңгыравы әле хәзер дә исән һәм бөтен авыл халкына хезмәт итә. Ул — мәктәбебезнең дәрескә һәм тәнәфескә чакырып чылтырата торган кыңгыравы. Утызынчы елларда ук безнең авылга бүрәнәдән ике катлы итеп унъеллык мәктәп салып куйдылар (кызганычка каршы, моннан берничә ел элек ул сигезьеллыкка гына калды — авылда балалар аз туа). Бу кечкенә генә сап-сары жиз кыңгырау шул еллардан бирле чылтырый инде мәктәбебездә. Ничәмә-ничә буын авыл халкын үзенең яңгыравык, моңлы, жиз тавышы белән чылтырап зур, олы тормышка озатты ул кыңгырау. Инде мәктәбебез бик искерде, күп катлы агач йортлар, гомумән, түземсез булалар. Инде тимер-бетонлап, кирпечтән яңа мәктәп салгач та, узганнар традициясен дәвам итеп, яңа мәктәпкә дә күчсен иде ул жиз кыңгырау. Илебездә зур-зур эшләр майтарган күпме авылдашның күңел түрендә мәктәп еллары, яшьлек чорлары истәлеге булып яңадан-яңа зур эшләргә дәшеп һаман чылтырый бит әле ул нәни генә жиз кыңгырау.

Совет властеның беренче елларында совет бәйрәмнәре, сайлау вакытларында бөтен авылны бәйрәмчә бизәү гадәте бар иде. Ул чактагы сайлау көннәренең олы бәйрәм булып үтүләре әле хәзер дә күз алдында. Сайлау буласы көнне иртән караңгылы-яктыда ук яшь киленнәрнең чиккән сөлгеләре, кызыл кәшимир яулыклар, төрле төстәге тасмалар, тукымалар, ирләр эзәрләре* белән бизәп жигелгән, дугаларына кыңгыраулар тагылган атлар авыл буйлап кәтәлчә** чаба башлыйлар. Ул жиз кыңгырауларның авылның теге башыннан ук челдер-челдер килеп болай табан якынлашуы бала-чаганы, яшь-жилкенчәкне дәртләндереп йокыдан уята, алар тиз-тиз генә бәйрәм киемнәрен киенеп урамга ашыгалар. Бу көнне олырак кешеләр сайлаута жәяү бармыйлар. Аларны клубка әнә шундый бизәкле, кыңгыраулы экипажлар илтә. Авылда чат саен гармун чыңы, чат саен жыелышып биләр, жырлыйлар. Клуб, авыл советы, мәктәп, кибет һәм башка биналарда кызыл әләмнәр, кызыл такталарга ак буяу белән язылган лозунглар. Авыл активлары кызыл флагларны еракта ук күренеп торсын өчен авылның иң биек биналарына кадарга тырышалар иде. Әлеге дә баягы, безнең авылның беренче комсомол ячейкасы секретаре булган Үкчей Бәчкәсе шуның аркасында газиз башын да югалта язды. Әйткәнемчә, безнең чиркәү авылның иң биек урынына урнашкан. Үкчей Бәчкәсе өеннән хатынының кешелеккә генә бәйләргә дип тоткан кызыл кәшимир яулыгын, бер таяк һәм бау кисәге алган да, шулардан флаг ясап, чиркәү гөмбәзе өстендәге качка (тәрегә) бәйләп куярга булган. Менә, янәсе, безнең авылдагы совет властеның тантанасы әллә кайлардан ук балкып күренеп тора. Ул анда кадәр ничек менеп житкәндер, шайтан белсен, чөнки әле чиркәү эшләгән чакта да ул кач янына махсус жайланмалар белән генә менәләр иде. Бәчкә качка менеп, аңа кызыл кәшимир яулыкны бәйләп ятканда, авыл кешеләре күреп кала инде моны. Авыл диндарларының моңа бик нык ачулары чыга. «Чиркәүне тәмам пыран-заран китерделәр, ярый, анысына түздек. Инде хәзер изге кач булып качка кызыл әләм бәйли башладылар, монысына түзәр хәлебез юк, атып төшерәбез Үкчей Бәчкәсен».— дип, кемнәндер ау мылтыгы табып алалар да, чиркәү тавына табан йөгерәләр. Үкчей Бәчкәсенә бит тегеннән, өстән бөтен нәрсә уч төбендәге кебек күренеп тора. Мылтык тоткан бер төркем ирнең ах-вах килеп чиркәү тавына менеп килгәнен күргәч, эшнең нәрсәдә икәнен сизеп ала да бу, тиз-тиз генә әләмне качка ныгытып бәйләп, гөмбәз эченә кереп шыла. Тегеләр тауга менеп житкәндә инде ул гөмбәз эченнән түбән таба төшә башлый. Диндарлардан берничә көчле ир, барыбер үтерәбез дип, чиркәү эчендәге үлчәүдән герләр алалар да (ул вакытта инде чиркәү колхоз амбары хезмәтен үти башлаган иде), төрлесе-төрле яктан гөмбәзгә менеп китәләр. Шуннан Бәчкәгә нишләргә инде? Гөмбәзнең эчендә, диварлар нык-лыгы өчен аркылы-торкылы бүрәнәләп ясалган терәү араталары сузылган. Чиркәү төзүче балта осталары аларны юкартып, түгәрәкләп шомартып куй-

---

* Эзәр — керәшен ирләре бәйли торган билбау.

** Кәтәлчә — русча «кататься»дан.

ганнар. Гер белән бәреп үтерергә ашкынып каршысына килгән таза ирләргә тоттырмас өчен Үкчей Бәчкәсенә чиркәү идәненнән кимендә 30—40 метр биеклектәге шушы тар, түгәрәк араталардан йөгереп үтәргә, яки шушы арата уртасына кереп басып тегеләрнең киткәнен көтеп торырга туры килгән. Ә тегеләр арataларга кермиләр, егылып төшәрбез дип куркалар. Озакламый чиркәүдәге хәлне белеп, авыл активлары килеп җитә һәм Үкчей Бәчкәсен бәладән коткаралар. Әмма безнең Пикыланың кәшимир яулыгы тәки шул качка бәйләнгән килеш калды. Әләмне алу өчен качка кадәр үк менәргә беркемнең дә кыюлыгы җитмәде. Бәйрәм үткәч, Бәчкәнең үзенә әйтеп карадылар, үзең менгереп бәйләдең, үзең алып төш, диделәр. «Мин ул чиркәү качына менү түгел, печән төялгән олау өстендә торырга да куркам хәзер»,— диде ул. Теге чакта диндарлар тәмам котын алганнар икән Бәчкәнең. Соңыннан Пикыла гына: «Бәйрәмгә генә бәйли торган өр-яңа кәшимир яулыгымны әрәм итте»,— дип, Бәчкәдән зарланып йөрде.

Ә кәшимир яулык чиркәү өстендә берничә ай буена җилфердәп торды да, уңа башлады. Тагын бер-ике атнадан инде әле кайчан гына кып-кызыл булып янып торган кәшимир яулыгыбыз чиркәү өстендә ап-ак флаг булып җилферди иде. Моны күреп, авыл активлары тагын пошаманга төштеләр. «Кара син моны, аклар флагына әйләнә бит бу шайтан алгырысы, үзәктән килеп күрсәләр, ни әйтербез»,— дип борчылдылар. Бәхеткә, кәшимир яулык җилферди-җилферди тузды булса кирәк, җилле-давыллы бер төндә ул юкка чыккан иде.

Билгеле булганча, чиркәү эшләгән чакта авылның бөтен эш кәгазе, документы шул чиркәү кулында иде. Кешенең туган елы, көне, әти-әнисенең исеме һәм үзенә исем бирелү, чумылдырган елы, чумылдырганнан соң булган урсатасының һәм урсанасының* исемнәре язылган кәгазьләр, өйләнешкәндә чиркәүдә ясалган кәбен кою (никахлашу) документлары, кешенең үлү, күмү кәгазьләре һәм төрле дини эш кәгазьләре, метрика кенәгәләре — барысы да чиркәү тавының итәгенә урнашкан бер контора кебек бинадагы зур сандыкта саклана иде. Революциягә кадәр бит авыл кешесенә кәгазь-мазар, документ ише әйбернең гомумән кирәге булмаган. Чөнки аның хезмәт хакы яки хезмәт көне эшлисе юк — ул үз хуҗалыгы, үз кереме белән яши. Ул чактагы авыл кешесенә паспорт-мазар да кирәкми. Авыл кешесенә хәтта туган көнен белү, хезмәт стажын санауның да хаҗәте юк, аңа барыбер беркем дә пенсия түләми ич. Шулай итеп, революциягә кадәр баш санын исәпкә алу шул берничә дистә елга бер була торган халык санын алу вакытларында гына булса булгандыр. Ә менә мал санын һәм күпме мәйдан җир тотуны ел да исәпләгәннәр. Чөнки боларыннан патша хөкүмәтенә налог кирә.

Авылда совет власте урнашкач кына адәм баласына кәгазь кирәк була башлый. Кая гына барсаң да, кем син, дип документ сорыйлар, чыгышыңны тогәл генә расларга туры килә һәм башкалар. Ә инде хәзер кәгазь-документсыз авылның тышында түгел, эчендә дә бер адым да атлап булмый. Гомерең буе бер ызаннан атлап йөреп, көннең көнендә биләмгә, кунакка, ашка йөрешкән күршеңе дә, әгәр ул пенсия билгеләүче булса, мин фәлән елны шунда эшләдем, фәлән елны монда эшләдем, дип, телдән генә ышандырып булмый. «Синең кайларда эшләгәнеңне мин синең үзеңнән дә яхшырак беләм, тик син миңа документ, кәгазь китер»,— ди ул.

Ә теге елларны кәгазь-мазарның беркемгә дә кирәге юк иде. Олылар чиркәүне туздырып ташлагач, авылның малай-шалае әлеге контораны туздыра башлады. Алар олыларга ияреп, дини китаплар долой дип, борынгыдан туу-үлү, исем кушу, кәбен кою мәгълүматлары, димәк ки, әллә кайсы заманнарда ук яшәгән авылдашларның исемлекләре язылган кенәгәләрне, хәзергечә әйтсәк, архивны урамга алып чыгып, битен-биткә ертып авыл буйлап

* Урсата, урсана — баланы чумылдырганнан соң билгеләнә торган крестный әти һәм крестный әни. Керәшеннәр аларны үз телләренә җайлаштырып урыс атасы, урыс анасы дигәннәр. Халыкта кыскартып урсата, урсана дип йөртелә.

очыртып йөрделәр. Кайберәүләр бу кенәгәләрне авыл советы архивына куярга кирәк дип карасалар да, активлар: «Юк, юк, чиркәү кәгазьләрен авыл советының изге бинасына кертер хәлебез юк»,— дип каршы төштеләр.

Ә менә авыл советы әйбәтләп эшли башлагач, архив документлары бик кирәк була башлады, әмма инде бу вакытта чиркәү конторындагы сандыкның үзеннән үк җилләр искән иде. Шуңа күрә безнең авылда миңа чордаш кешеләрнең күбесе үз бабасы белән әбисенең исемнәрен, атасы, анасы, туган-тумачаларының туган елларын белми. Менә мин үзем дә әнкәй карчыкны моннан ун еллар элек кенә җирләдем. Урыны очтомакта* булсын, ул бик озын гомер яшәп, картаеп үлде. Тик аның туган елын үзе дә, без, балалары да, гомумән, авылда беркем дә белми иде. Аның үзенә туган елы кайчан икәнен белү беркайчан да кирәкмәгән, яшьтәш авылдашлары күптән үлеп беткән, ә метрика кенәгәләре берсе дә сакланмаган. Исән чакта аннан: «Әни, кайчанрак тугансың соң син, исеңә төшереп кара әле?» — дип сорасаң: «Әни мине тары урганда таптым, ди, торган иде, чутлап карагыз инде үзегез шуннан»,— дип җавап бирә иде.

Чиркәүнең җиһазлары, китаплары, архивы белән эшне бетергәч, авыл халкы беразга тынып калды. Тик бу тынлык озакка бармады. Бер мәлне кемдер, мөселман авылларында мәчет манараларын кисәләр, дигән хәбәр алып кайтты. Берничә көннән инде күрше-тирәдәге мөселман авылларында, чыннан да, мәчет манараларын кисеп аудару турында билгеле булды. Безнең авылның бер активы хәтта махсус рәвештә Сарабиккол мәчете манарасын кискәнне карарга барган. Укымышлылар сөйләвенчә, болгар-татар шагыйре Кол Гали язган «Йосыф кыйссасы» дигән китапның (Утыз Имәни тарафыннан фәнни эшкәртелгән атаклы нөсхә! Автор.) кульъязмасы нәкъ әнә шул мәчет чормасыннан табылган бит. Миңа калса, ул кульъязма китапны Сарабиккол кешеләре нәкъ әнә шул манара кискән вакытларда, дин сабагы дип мыскыллап, мәчетнең башка кәгазьләре белән чормага атып бәргәннәрдер. Ярый әле Сарабикколлылар архивны чормага, җил-яңгыр тими торган җиргә ташлаганнар, безнең авыллар кебек бала-чагадан туздырткан булсалар, ничәмә-ничә төрки халык гаҗәеп кыйммәтле нәрсәдән мәхрүм булган булыр иде.

Теге безнең авыл кешесе сөйләве буенча, мәчет манарасын кисеп аудару алай бик үк кыен эш тә түгел икән. Берничә дилбегә ялгап ясалган озын бауны манараның аена бәйлиләр дә, берничә таза ир бауны манара авачак яктан тартып торалар. Ә тагын берничә ир манараның төбен, ягъни мәчет кыегыннан чыгып киткән урынын пычкы яки балта белән кисәләр. «Аз-маз кисүгә, манара, теге таза ирләр аркан белән тартуга түзә алмыйча, шатыр-шотыр килеп сынды, мәчет түбәсен сыта-сыта, дөбер-шатыр килеп, мәчетнең ничәмә йөз еллык тузан болытын кузгатып, ирләр һәм бала-чага акырган-бакырган, сызгырган тавышлар астында прәме арканчы ирләрнең аяк астына ук килеп төште»,— дип сөйләде безнең теге авылдаш шаһит.

Мәчет манаралары кисү хәрәкәтенә без белгән тирә-як авыллар бар да кушылып бетте, бөтен төбәккә бер булып, безнең чиркәү гөмбәзе генә күккә сузаеп тора иде. Бу хәл безнең авыл активлары арасында ниндидер шом, шик кузгатты. «Әнә хәзер бөтен мәчетләр манарасыз, безнең чиркәү генә исән-имин басып тора, үзәктән килгән вәкилләр безнең турыда ни уйларлар?» — дип аптырыйлар иде алар. Шуннан берсе тота да: «Давай, без дә гөмбәзне мәчет манарасын аударган кебек аударабыз»,— дип тәкъдим ясый. Бу тәкъдимне дәррәү яклыйлар һәм, мәсьәләне озынга сузмас өчен, эшне шул көнне ук башлыйлар. Бөтен авылдан дилбегә җыеп килеп, ялгыйлар, гөмбәз эченә махсус баскычлар ясап менеп, бауның бер очын әле кайчан гына Үкчей Бәчкәсе кызыл кәшимир яулык бәйләгән качка бәйлиләр. Инде эш гөмбәзнең төбенә, чиркәү кыегыннан чыгып киткән урынына җиткәч, бар да аптырап кала. Чиркәү гөмбәзенең төбен мәчет манарасы кискән кебек балта яки пычкы белән генә кисеп булмый икән бит. Чөнки

* Очтомак — «оҗмах» сүзенең керәшенчә әйтелеше.

гөмбәз ул — чиркәү түбәсенә зур түгәрәк итеп буралган махсус корылма. Бурап кына куелган булгач, бәлки тартып кына аударырбыз дип, әллә күпме таза ир җыелып, качка бәйләнгән арканга тагын дилбегәләр ялгап, «айт-два»ны әйтеп тә тартып карадылар. Гөмбәз селкенергә уйламый да, ә менә, арыслан кебек ирләр тартуга түзә алмыйча, дилбегәләрнең берсе шартлап өзелә һәм аркан тартучы ирләр хут белән чүт кенә чиркәү тавы астына очмыйлар. Шулай да, егылып кайсының бите сыдырыла, кайсының бармагы тая. Болай эш барып чыкмагач, гөмбәзнең бүрәнәләрен берәмтекләп сүтәргә булалар. Ул да булмый, шалтыр-шолтыр китереп, гөмбәзне каплаган түбә калайларын каерып ташлыйлар, ниндидер әмәл табып, авыр тимер качны шаңгырдатып төшерәләр һәм тотыналар гөмбәзне бүрәнәләп сүтәргә. Шунда гына барысы да аркан белән тартканда ни өчен гөмбәзнең селкенеп тә карамаганын аңлый. Чиркәүне төзүче осталар гөмбәз бүрәнәләренең очларын бер-берсенә беркеткәндә безнең авылда өй салгандагы шикелле киртләп кенә калмаганнар, ә әллә ниткән уемнар, чыгынтылар белән йозаклап беркеткәннәр икән. Шуңа күрә һәр бүрәнәне аерым-аерым, рәте белән генә күтәреп алмасаң, кырыйдан төртеп яки тартып-сугып бер генә бүрәнәне дә кузгата алмыйсың. Менә нинди оста куллар эшләгән бит чиркәүне. Ә бүрәнәләренең ныклыгы, тазалыгы! Алар ничәмә еллар кояшта кайнарланып яткан калай астында тәмам кибеп, җип-җиңел булып калганнар. Бер-бер бүрәнәсен бер үзең кул очына күтәреп була. Әнә шул бүрәнәгә бер чиертеп җибәрсәң, аннан зең-ң-ң итеп матур бер тавыш чыга. Бу бүрәнәләрдән тот та скрипка ясa, әллә ниткән моңлы авазлар белән уйнаячак.

Гөмбәзен сүтеп ташлагач, безнең чиркәү чыннан да мөселман авылларындагы манарасы киселгән мәчетләргә охшап моңаеп калды.

Гөмбәздән төшкән бик шәп коры бүрәнәләрне авыл халкы кызыгып өйләренә ташый башлаганнар иде, бер җитәкче, бүрәнәләр шәхси милек түгел, коллектив милке дип, бу эшне шундук тыйды һәм гөмбәзнең бөтен әйберсен авыл советы янына өеп куярга кушты. Күпмедер вакыт үткәч, гөмбәзне колхозның Әчелек чүннигенә* илтеп яңадан җыйдылар. Шулай итеп, Әчелек урманы эчендә җирдән күтәрелгән шактый иркен генә түм-түгәрәк, шлем кебек очлы бер бина хасыйл булды. Аны Әчелек чүннигенә омшанник итеп төзегәннәр икән. Чиркәү гөмбәзе омшанник өчен гаять тә әйбәт, җайлы, җылы бина булып чыкты. Ул әле менә соңгы елларга кадәр колхозга омшанник булып хезмәт итте. Дөрес, инде аны сипләштереп, түбәсен үзгәрткәләп тә бетерделәр. Шулай да, бүген барып карасагыз да, әле аның кайчандыр түм-түгәрәк чиркәү гөмбәзе булганлыгын ачык шәйләргә була. Бүрәнәләренең дә әле барысы да череп бетмәгән. Шулай итеп, безнең чиркәү бинасының язмышы кызык кына булды — аның нигезе һәм диварлары инде әллә кайчан юкка чыкты, ә гөмбәзе әле һаман исән.

Гөмбәзне сүтеп ташлаганнан соң, инде җәмәгать оешмаларының чиркәүгә һөҗүме тукталды. Чиркәү түбәсендә гөмбәз сүтелгән урыннан соң зур тишек калган иде. Аны аннан-моннан гына, шул ук гөмбәз калайлары белән каплаштырып куйдылар. Чөнки бит чиркәү эчендә амбар, анда онфәлән, авылга кайткан төрле товар саклана.

Әмма әле җәмәгать оешмалары чиркәүне тыныч калдыруга карап кына, авыл халкының чиркәүгә карата булган кызыксынуы кимемәде. Халык инде чиркәүнең нинди дә булса бер хуҗасы юклыгын белде, чөнки поп әллә кайчан авылдан куылды, совет органнары чиркәүне дәүләттән аердылар, соңгы еллардагы вакыйгалар халыкка Алладан курыкмаска мөмкин икәнлекне күргәзмә рәвештә аңлаттылар. Шулай булгач, чиркәүне теләсә нәрсә эшләтергә мөмкин иде. Амбар булу аркасында чиркәүнең эченә керергә ярамый, монысы бөтен кешегә дә аңлашыла, ә менә аның тышкы ягында эш эшләп була иде. Мәгәр чиркәүнең тышкы ягында да авыл халкына эш күп иде. Мәсьәлә шунда ки, чиркәү төзелгән елларда ук чышын-пышын гына

* Чүнник — умарталык.

сөйләнә торган «чиркәү нигезенә алтын кач салып калдырганнар икән» дигән сүз, чиркәү бөтенләй хуҗасыз калгач, авыл халкы арасында кинәт бик нык куерып, һәркемне ярсытырлык, зур бер кисәк алтын табуга дәртләндерерлек хәбәр булып таралып китте. Инде чиркәү нигезенең әле бер, әле икенче җирендә әчкә табан казып керелгән кечкенә чокырлар да күренә башлады. Ләкин бу чокырларны кем, кайчан казыганын беркем дә күрми, белми. Чөнки ул чокырлар төнлә генә казылалар иде. Әмма алтын эзләүчеләрне бер дә бушка җир казып интегү канәгатьләндермәде булса кирәк, бер мәлне, абзар-кура, мунча-фәлән нигезенә салырга дип, чиркәү нигезендәге әлеге шоп-шома, шикәр кебек ак ташларны каерып алып өйләренә ташый башладылар. Өйгә менә дигән әзер төзү материалы кайта, әле күңелдә, чиркәү нигезенә куеп калдырылган алтын качка тап булуым бар бит, дигән бик татлы, ымсындыргыч өмет тә сүнми. Әмма шунысы бар, бу ташларны бер-берсеннән кубарып алу да бик үк җиңелдән түгел. Чөнки алар бер-берсенә махсус измә белән бик тә нык итеп ябыштырылганнар икән. Картлар сөйләвенчә, чиркәү төзүче осталар ул измәгә шикәр һәм чи йомырка куша торган булганнар. Йомыркасы ярар инде, ә менә ул заманда балчык измәсенә шул кадәр дә сирәк, затлы азык булган шикәр кушу безнең авыл халкының тәмам исен китәрә иде.

Чиркәүнең нигезе биек, мәйданы зур, димәк, ташы күп — нигез ташы каеру соңгы елларга кадәр дәвам итте. Шулай да һаман әле беркем дә алтын качка юлыкмады, беркем дә аны табу бәхетенә ирешә алмады. Дөрес, сугыш һәм аннан соңгы ун еллар дәвамында чиркәүгә беркем дә кагылмады. Бу елларда авылда төзелеш бөтенләй тукталды диярлек, халык бары тик фронт һәм илне торгызу өчен генә эшләде, һәм, әлбәттә, бу чорда халыкта алтын кач кайгысы онытылып торды.

Соңгы елларда чиркәү нигезендәге соңгы ташларны да алып бетерделәр. Шулай итеп, чиркәүнең нигезе тәмам бетте, әмма әле үзе һаман карачкы кебек караеп утырып тора иде. Инде болай да төрле җиреннән су үтеп череп барган чиркәү бинасы чын мәгънәсендә куркыныч бер корылмага әверелде. Чөнки ул, үзен тотып торган нигезе булмау сәбәпле, җилдә селкенеп, атынып тора башлады. Түбәсе череп ишелеп төшә башлагач, тизрәк аннан колхоз амбарын да алдылар. Инде бердән-бер көнне диварлары ишелеп китеп якындагы берәр кешене яки малны басып үтерү куркынычы туды. Шуннан соң авыл советы рәисе Унтый Микайласы (Антонов Михаил) үз җитәкчелеге астында чиркәүне бульдозер белән эшерттереп ташлады. Шушы көнне үк нигезгә куеп калдырылган алтын кач мәсьәләсе дә хәл ителде.

Чиркәүнең нигезен, бульдозер көрәге белән эшертеп, җир белән тигезләделәр. Элек алтарь торган урынны казытканда җир астыннан бик үк зур булмаган металл кач килеп чыкты. Бу эшне тамаша кылып торучылар барысы да аһ итеп качка ташланды! Качны алып, туфрактан арындырып, күгәрекләрен чистартып карасалар, аның гап-гади тимердән ясалганлыгы билгеле булды.

Чиркәүне бульдозер белән аударып, нигезен җир белән тигезләп куйгач, безнең авыл нәкъ моннан бик борынгы заманнардагыча, ягъни бабаларыбызның бабалары шушы Аланлык чокырына килеп утырган чактагы кебек булып калды — анда ни чиркәве, ни мәчете дигәндәй, берсе дә юк...

Әнә шулай күп хәлләрнең шаһиты булдым мин, җәмәгать.

Миргазиян Юныс

# ШӘФКАТЬ КЫЙБЛАСЫ

*Кешеләрнең сиңа күрсәткән этлеген,*
*үзеңнең башкаларга эшләгән игелекләреңне*
*шундук онытырга өйрәнмәсәң,*
*бәхеткә мәңге ирешеп булмый...*

КОНФУЦИЙ

Күрше ике милләт. Хәтта күрше генә дә түгел. Татарларның дүрттән өч өлеше — урыс арасында. Шуңа карамастан, без, язучылар, шушы көнгә кадәр шуны ике милләт арасындагы мөнәсәбәтләрне дөрес итеп күрсәтергә куркып яшәдек. Күрсәткән очракта, башлап, Сталин авызыннан чыккан «мәңгелек дуслык», «өлкән абый» шикелле сүзләрне алга сөрдек.

Ниһаять, хәбәрдарлык чоры килде. Соңгы вакытта галимнәребез шактый кызыклы һәм кирәкле тикшеренүләр алып бара башладылар. Татарстанның Югары Советы трибунасыннан да акыллы фикерләр ишетелә. Марат Мөлеков күбек депутатларны без ихтирам белән тыңлыйбыз. Шуңа карамастан, бу темага язылган публицистик әсәрләр чиктән тыш аз, фундаменталь фәнни тикшеренүләр бөтенләй юк.

Татар-монгол золымы, татарларның кыргый, кара халык булуы турында язылган китаплар миллионлаган тираж белән таралып тора. Шуна күрә, Советлар Союзында яшәүче халыкларның туксан тугыз проценты безне Чыңгыз ханга ияреп килеп, урыс җиренә утырган килмешәккә саный. Милли конфликтлар кан коюга барып җиткәч, карагруһ галимнәр саграк кылана башладылар. Аның каравы, телевидение, газета-журнал битләрендә татарларның суверенитет игълан итүен мыскыллау, сезнең азатлык кан коюа, ачлык белән бетәчәк дип, гади халыкны куркыту дәвам итә. «Литгазета»ның 1990 елгы 44нче саны. Жан Миндубаевның «С кем вы, татарстанцы?» дип аталган мәкаләсе үзе генә ни тора?! Имеш, без кая китә алабыз? Без кемнәр белән чиктәш? Безне чүл бүреләре, арыслан-киекләр, крокодиллар урап алганмыни? Бу фикерне әйтүчеләр туган республикабыз әйләнәсендә яшәүче халыкларга яла ява, аларны ерткыч итеп күрсәтә. Без шуны кабул итәбезме?

Менә шушындый пыскып яткан милли учакларга ягулык ташлаучы карагруһларга трибуна бирү — искиткеч зур җинаять. Икенче бер җинаять — безнең сукырлык, чукраклык һәм телсезлек. Без, милли гауга калкып чыга башлаганын күрү белән, тәвә кошы шикелле, башыбызны ком астына тыгып, афәт үткәнне көтеп ятабыз. Ул арада мәсьәлә катлауланa, үсә, киңәя, көчәя, аны бары тик ике төрле корал белән генә җиңеп була. Ул коралларның исеме: х а к ы й к а т ь һәм ш ә ф к а т ь.

Хәтәрле торгансыздыр. Америкада әле күптән түгел генә өсләренә ак җөббә кигән ку-клукс-клан вәкилләре негрларны җәзалап йөри иде. Америка галимнәре бу мәсьәләне кырык ел буе өйрәнделәр һәм этник стереотиплар картасын төзеделәр. Бу эшкә күренекле рус галиме Георгий Гачев та катнашты. Безгә дә, социология, тарих, социаль психология, этнография, фәлсәфә, мәдәният, демография фәннәре казанышларына таянып, нәкъ

шундый карта төзергә кирәк. Этник стереотипларны тирәнтен өйрәнгән очракта без урыс белән татар арасындагы «мәңгелек дуслык» киләчәктә безгә нинди уңышлар китерүен алдан әйтербез. Безнең өчен иң мөһиме — татар белән урыс арасындагы мөнәсәбәтләрне тәшкил иткән бәяләмәләр.

Утыз елга якын күзәтү дәверендә мин үзем өчен бер ачыш ясадым. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң җир шарында яшәүче халыклар арасында ике төрле милли мөнәсәбәт барлыкка килде: тарих шаукымында, тарихи сәясәттә яшәүчеләр һәм экономика чолганышында яшәүчеләр. Дөнья базары, трансконтиненталь корпорацияләр, төрле милләт вәкилләреннән оешкан үзара предприятиеләр халыкларда интернациональлек мөнәсәбәтләре тәрбияләде.

Безне исә дөнья революциясенә, череп таркалырга торган капитализмны тар-мар итәргә әзерләделәр.

Мин дингезчелектә хезмәт иткәндә җир шарының кайсы төбәкләренә генә корал ташымадым?! Планетаның кайсы гына почмагында сугыш кабынып китмәсен, солдатларның кулларында — «Калашников автоматы», командирларның путасында — «Макаров пистолеты» булды. Һәм безне рәсми патриот итеп тәрбияләделәр. Рәсми патриотлык белән шовинистлык арасындагы чикне кем күрсәтә ала? Соңга табарак конкрет рәвештә көньяк кореяләргә, көньяк вьетнамлыларга, әфганлыларның өчтән ике өлешенә, Никарагуа контрасларына, Сальвадор халкының күпчелегенә каршы әчебезгә шовинистик нәфрәт җыя тордык. АКШ, Федератив Алмания (Германия), һәм башка капиталистик илләр турында әйтеп тә торасы юк. Безне рәсми пропаганда, башта Сталин үзе, аннан соң аның шәкертләре — «соры кардинал» Сусловлар, соңрак Зимяниннар һәм башка казарма милләтчелеге остазлары тәрбияли тордылар. Нәтиҗәсен күрәсез.

Милитаристлык шартларында интернациональ тәрбиягә урын калмый. «Өлкән абыебыз»ның тарихына күз салып алыйк.

1721 елның 30 октябре. Озакка сузылган Төньяк сугышының Ништадт солыхы белән тәмамлануы уңаеннан урыс патшасы рәсми рәвештә Бөтенроссия Императоры итеп игълан ителә. Империянең дәүләт чикләре Алтын Урданыкы белән тәңгәл диярлек, халыклары да, тулысынча диярлек — Җусый улысында яшәгән халыклар. Шуңа карамастан, үрнәк итеп, Чыңгыз дәүләте түгел, Бөек Рим империясе алына. Империянең гербы — ике башлы бөркет, башкаласы — Санкт-Петербург. Петр Беренче колониаль яулап алуны ачыктан-ачык дәүләт сәясәте һәм максаты дип игълан итә. Идарә өчен абсолютизм, тоталитар режим сайлап алына, крепостной строй, илдәге һәр завод-фабрика, артель, һәр хуҗалык армияне тәэмин итү өчен эшли. Империя — тоташ хезмәт армиясе. Урыс дәүләте башта дала халыклары, аннан соң Казан, Хаҗитархан, Кырым ханлыклары белән сугышу, шул халыкларның җирләрен колонизацияләү дәверендә барлыкка килде.

Петр Беренче хәтта чиркәүне дә хәрбиләр сафына бастыра. Ул чыгарган карарларның сиксән процентлабы — әле дә хәрәкәттә. Йодрыклап эшләтү, хезмәт иясләрен җан асрарлык итеп кенә тукландыру, казармага охшаш торак һәм хәрбиләрнекенә охшаш кием-салым... Рәсәй халкы әле һаман шушы шартларда яши...

Яңа буын императорлар Петр Беренче игълан иткән Рәсәй империясен камилләштерәләр генә. Экспансия юнәлеше төньяктан көньяк-көнбатышка таба борылгач, Рәсәй-Византиянең дәвамы дип белдерелә һәм аның төп вазифасы Византияне һәм христиан халкын «басурманнар золымыннан» коткаруга күчә. Шведлар, поляклар, литвалылар белән сугышкан чорда татарларга караш, алар урыслар белән янәшә сугышып йөргәнлектән, бераз йомшарып тора. Яулап алулар төрек һәм фарсы юнәлешенә борылгач, безне тагын да аяусызрак җәберли башлыйлар.

Шушы чорда яңа риваятьләр туа, яңа символлар барлыкка килә. Шуларның берсе — Юнан императоры Костантин Багрянородный бүрегенең Владимир Монамахка тапшырылуы. Бу хәл властьның мирас рәвешендә күчүен аңлатып тора. Ул бүрек «Оружейная палата»да саклана һәм аның Алтын Урда ханыныкы икәнлеген исбатлау өчен кием тарихы белгече булу да кирәкми.

Мәкаләнең максаты татар һәм урыс тарихын сурәтләү түгел иде. Бу — ифрат авыр, катлаулы эш. Шулай да, бер тотынгач, дәвам итим әле. Империяне нинди дә булса бер милләт исеменнән төзиләр. Бөек Бабил (Вавилон), Борынгы Мисыр, Борынгы грек, Госман, Бөек Британия империяләре... Хәзерге көндә кая алар? Күбесенең халкы калмады инде. Бөек Мисыр империясе хөкем иткән җирдә — гарәпләр; заманында бөтен халыкларны дер калтыратып торган Искәндәр Зөлкарнәй империясе урынын-

да — бәләкәй генә, тыйнак һәм эшчән греклар яши. Госман империясе дә, яулап алган җирләреннән баш тартып, колонияләреннән китеп, мул һәм тыныч яшәүче төрек иленә әйләнде. Инглизләр дә колонияләреннән баш тартты. Бары Совет Рәсәе генә җир йөзендәге соңгы империя булып кала бирә. Хәзер көн тәртибенә аның язмышы килеп басты.

Тоталитар системаны саклап империя дилбегәсен кулларында тотучылар, гадәттә, гел халык исеменнән эш итәләр. «Халык» сүзен бик еш кулланып, халык мәнфәгатен «кайгыртучы» булып кыланган диктаторлар тарихта яхшы мәгълүм: Нерон, Явыз Иван, Гитлер, Сталин, Пол Пот... Безгә, Явыз Иван чорыннан башлап, күрше халыкларның җиренә басып керүне ватан иминлеген саклау өчен кирәк, дип аңлаталар. Карагруһ фәлсәфәчеләр экспансияне аклый, бәхилли торган кагыйдәне дә уйлап тапканнар. Имеш, урыс кешесе кысынкылыкта яши алмый, аңа киңлек, чиксезлек кирәк, аның җаны туктаусыз нindидер офыклар артындагы тылсымлы билгесезлеккә ашкына. Сүз дә юк: матур теория! Бусын инде мәгълүм шагыйрь әйткән: «Рәсәйне акыл белән аңлап, аршын белән үлчәп булмый. Аның токымы бөтенләй башка төрле. Рәсәйгә ышанырга гына кирәк». Ә кайсы халыкны салкын акыл белән аңлап була соң? Халыкларның кайсыларына ышанырга ярамый соң? Менә шушы сорауларга җавап эзләгән чакта төшенәсең: империя дәрәҗәсенә ирешкән этник берәмлек, үзенең башкаларга охшамаганлыгын дәлилләү өчен, үзенә генә хас сыйфатлар эзли башлый. Аларны табуы исә кыен түгел. Саны күпнең мөмкинлекләре дә зур, өстәвенә, башка халыклар да империягә хезмәт итә. Колониаль золым эшкә ашырылу дәверендә империя олтаны астында яшәүче халыкларның таланты идарә итүчеләр ягына тартыла башлый. Бу табигый хәл. Хакимлек итүчеләр ягында — талантка мөмкинлекләр зур, мәйдан киң, сәләтенә тияр бәһа югары. Карамзин, Караморза килеш татарча сөйләшеп, татар арасында гына яшәсә, шундый зур күләмле, киң колачлы тарихны яза алыр идеме?! Кантимер — Державинның дәрәҗәсе нинди булыр иде?! Челебей нәселен дәвам иттерүче бөек Лермонтов һәм бүгенге әдәбият сөючеләрнең алласы Владимир Набоков?!

Бәлки, кайбер шәхесләр бишектән үк үз милләтенең патриоты булып, татар җанлы булып сакланганнардыр? Мин үзем гөнаһлы. Их, ул яшьлегем — алсу-зәңгәр чоркайларым минем! Офицер идем. Һава патшасы! Сталин лачыны! Җилкәләремдә — ука белән чигелгән погон, маңгайларымда елкылдап торган җиз бизәкләр. Хром итек, атлаган саен, шыгыр-шыгыр килеп, йөрәкләрне җилкендерә. Галифе чалбар шундый матур! Кыскасы, бөтен урамның күзе синдә генә! Ашау да — оҗмах сые. Сары чәчле сылулар, анкетаңны актарып, милләтеңне тикшереп тормый. Алар белән үбешер алдыннан син инде Габдрахман түгел — Гена, Мөхәммәт түгел — Миша. Һәм... генерал буласы килү теләге шулкадәр көчле, бу максатка ирешү өчен, әйтик, Фәхрелисламгалиев дигән фамилияңне, ике дә уйламыйча, «Федотов»ка алыштырасың. Шундый мөмкинлеге барында ничә процент татар гөнаһтан куркыр иде икән?!

Дөрес, тимер юл ремонтлап яки төзелештә кирпеч ташып йөрүчегә татар фамилиясе бернинди авырлык та китерми. Әгәр сине язмыш әдәбият яки сәнгать дөньясына кертеп җибәргән булса?.. Камал театры сәхнәсендә Сергей Каюмович Шәкүров шушы дәрәҗәгә ирешә алыр идеме? Рифкат Маликов үзенең исемен һәм фамилиясен Михаил Львов дип үзгәртмәсә, «Новый мир» журналында баш редактор урынбасары булып утыра алыр идеме? Париждагы «Гран опера»ның баш балетмейстры, «Ковент гарден» исемендәге король операсында, АКШтагы «Метрополитен опера»да озак еллар җитәкчелек иткән Рудольф Нуриевны Уфа театры сәхнәсендә күз алдына китереп карыйк әле? Ә бөек вулканолог Һарун Таҗиев Татарстанда нишли алыр иде?!

Кешенең автоном республика шартларындагы иҗаты стаканга тутырып, өстенә таш бастырган үрмәкүчләр хәлен хәтерләтә. Стаканның стеналары калын, һава юк, урын тар, ә өстән сине басып торучы бюрократик аппарат шундый зур һәм шундый көчле. Шушы шартларда иҗат итүче интеллигенциягә шәфкатьлерәк булыйк һәм онытмыйк: җинаять тудырган ялгышлыклар, халтура, урта кул әсәрләр әзме-күпме бәхилгә лаек. Бу дөньяда бер адымга — әхлак хыянәтенә генә бәхилләү булмаска тиеш. Бер микъдар, бары тик бер генә микъдар хыянәт, иман сату, милләтеңне сатуга мәңге бәхиллек юк. Сатылу рухи атмосфераны агулап юкка чыгара.

Унтугызынчы гасырның ахыры, егерменче гасырның башында Рәсәйдә гигант көч белән Ренессанс чоры башлана. Һәр өлкәдә берничә гигант: Лев Толстой һәм Достоевский, Врубель, Марк Шагал һәм Филонов, Чайковский һәм Рахманинов, Владимир Соловьев һәм Николай Бердяев. Фән

һәм техникада — Менделеев һәм Павлов, Лобачевский, дөнья авиациясенең атасы һәм мие Юрий Сикорский, диңгезчелек тарихындагы иң зур, иң гүзәл һәм тиз йөрешле «Нормандия» лайнерын төзүче инженер Юркевич. Нигә соң шушы бөек яуланышлар үзе дә бинибая талантлы булган рус халкының культурасын бер генә миллиметрга да күтәртә алмаганнар? Ни сәбәп: Рәсәй кешесе коймa буенда, бәвеленә манчылып, аунап ята? Ни сәбәп: урыс вокзаллары пычрак, җәмәгать әбрәкәйләрендә тончыгып үләрлек, юллар юк, гөлбакчалар ватык шешә һәм консерв банкалары белән тулган? Третьяковка, Эрмитаж кебек мәшһүр күргәзмәләргә профсоюз тарафыннан куып кертелгән тамашачыларның, эч пошуын яшерә алмыйча, иснәп йөрүләре турында искә алырга да куркам мин.

Инде менә ничә еллар урыс интеллигентларына мин бер үк сорауны бирәм: «Рәсәйдәге бөек Ренессанс казанышлары ни сәбәп бөек культурага әйләнмәгән?» Күпчелек: «Безнең культура Европаныкыннан кимме-ни?» — дип, сорау белән үк җавап кайтара. Азчылыгы исә: «Әле бит вакыт әз үтте, әкренләп, һичшиксез, урыслар җир йөзендәге иң бөек культуралы халыкка әйләнәчәк», — дигән була. Соңгы вакытта: «Революция комачаулады, культура күн тужурка өстенә патронташ тасмасы ураган, маузерлы комиссарлар кулына эләкте», — диючеләр барлыкка килде. Ә, минемчә, сәбәп башкада — культура өлкәсендә эшләүче интеллигенция белән культурага мохтаҗ киң масса арасында таш стена булып бюрократик аппарат тора. М. С. Горбачев бу «стена»ның 18 миллионлы номенклатура икәнлеген игълан итте. Михаил Сергеевич әйткән санга бюрократик ысулда иҗат итүче язучыларны, сәнгать эшлеклеләрен, укытучыларны да өстәргә кирәк. Менә нигә империя шартларында Толстойларның һәм Рахманиновларның илаһи тәэсире халыкка үтеп керә алмый.

Шушындый тоткарлык ятмаса, патша заманында да, совет чорында да урыс әдәбиятын, сәнгатен һәм культурасын бөеклеккә күтәрүче әһелләр белән аралашу империя олтаны астында яшәүче халыкларның тәрәккый үсешен дә дөнья культурасына тиңләштерә алыр иде. Бөек Мәрҗанине Сергей һәм Владимир Соловьевлар, Павел Флоренский һәм Алексей Лосевлар белән тыгыз элемтәдә эшләгән итеп фаразлап карыйк. Дөрес, Казан университетының Шәрык бүлеге галимнәре Шиһабетдин хәзрәтнең энциклопедик белем-эрудициясеннән файдалана белгәннәр. Мин Казан чоры ориенталистларының фәнни эшләреннән Мәрҗанинең исемен эзләп карадым. Юк аның исеме. Патша заманында һәм совет чорында басылган бер генә энциклопедиядә дә, сүзлекләрдә дә һәм белешмәләрдә дә аның фәнни эшләре һәм исеме юк. Соңгы совет энциклопедиясенә футбол тибүче Бесков та, алдынгы тракторчы Паша Ангелина да кергән, Мәрҗанигә урын табылмаган. Шиһабетдин хәзрәтне Кэмбридж ориенталистлары белә, гарәп илләрендә, Төркиядә аны ихтирам итәләр. Шулай булгач, нишләп соң Казанда аның белеменнән файдаланган галимнәр аның исемен һәм фәнни хезмәтләрен популярлаштырырга тырышмаганнар?

Тоталитар дәүләттә фән дә, сәнгать тә, мәдәният тә — барысы да власть иясе кулында. Аларга исә колониаль режимда яшәүче халыктан чыккан галимнәрнең, тоталитар көчкә хезмәт итмәгән очракта, бөтенләй кирәге юк. Андыйларга киресенчә, үз халкына хыянәт итүчеләр, шымчылар, куштаннар кирәк. Бөек Мәрҗанинең шәкерте Хөсәен Фәезхановның фаҗигале тормышы шуңа мисал. Бу канун совет чорында да дәвам итә. Хәтта безнең чорда үз халкының мәнфәгатен сатучыларның коньюнктурасы күтәрелде дә әле. «Халыклар дуслыгы» дип игълан ителгән номенклатур элита сафына союздаш республикалардан бер-ике вәкил, автономияләрнең дә кайберләреннән берәр бәндәне кыстырып интернациональлек тамашасын уйнау, күз буяу дәвам итә. Дөрес, хезмәт ияләре, нинди генә милләттән булуга карамастан, үзара дошман яшәми. Завод цехларында, кыр-басуларда, Андрей Сахаров, Лев Гумилев һәм генерал Григоренко бөеклегенә ирешә алган интеллектуаллар арасында интернациональ туганлык яшәп килә.

Моннан дүрт-биш ел элек Е. П. Хабаровның Урал тавыннан көнчыгышта яткан «хуҗасыз», «кыргый» җирләрне үзләштерүгә турында «фәнни» фильм чыкты. Тамашачы, фильмны карагач, бу җирләрдә, урыслар килгәнче, беркем яшәмәгән, анда Себер ханлыгы да, төбәктә хуҗалык иткән себер халыклары да булмаган икән, дигән фикердә кала. Колонизаторлар, үзләренең канлы эшләрен аклар өчен, интернациональ кагыйдәгә таянып эш итәләр. Без аборигеннарга мәдәният алып килдек, без аларны хезмәткә, кешеләрчә яшәргә өйрәттек, диләр. Колонизаторлар көчләп таккан гореф-гадәтләр исә, алар нинди генә югары сыйфатлы булмасын, җирле халыкка ярдәм итә алмый. Киресенчә, катастрофа алып килә. Бу ка-

гыйдәгә читтән мисал эзләп йөрисе юк. Төньякта. Чукотка. Камчатка һәм Сахалин аборигеннарының юкка чыгып килүләре турында газета битләрендә һәм Югары советта чаң сугалар. Чират безгә дә житеп килә.

Кешелекле. гуманистик канун белән эш итүче колонизаторлар тарихта юк. Әмма берсе дә — колонияче инглиз солдатлары да. Канар атауларының аборигеннарын юкка чыгарган португал дингезчеләре дә. хәтта һиндләрне резервацияләргә бикләп тамырларын корыткан янкилар да. Хабаровка багышланган фильмдагы шикелле. без килгәндә бу жирләрдә берниндн кеше заты да юк иде дип. оятсыз ялганга таянып эш итми.

Рәсәйгә генә хас бер сыйфат бар: бу империядә изге хакыйкать белән бөек ялган бер-берсен юкка чыгармыйча. янәшә яшәп киләләр. Бу сыйфат бөек Достоевскийны — кеше психологиясен. бигрәк тә урыс милләте психологиясен искиткеч тирән һәм дөрес аңлаучы корифейны да хәйран калдырган. Достоевский болай ачына: урыс ул һәрдаим игелек күрсәтергә омтылып яши һәм шуның белән бергә. үзе дә сизмәстән. шундый әшәкелек күрсәтеп ташлый, аның бу кабахәтлеген мәңге оныта алмыйсың.

Гасырлар буена сузылган басып алу. күрше халыкларны буйсындыру юлында кан коюлар. җәберләр. кыямәт көненә тиң гарасатлар беркайчан да тукталып тормаган. Колониаль сәясәтне оештыручылар шушы җинаятьне табигый санаганнар. чөнки бу процесс аларга иксез-чиксез байлык. дәрәҗә китереп торган. Урысның яулап алулары гади халыкка байлык та. бәхетле тормыш та бирә алмаган. Ул һаман ярлы. һаман солдат шартларында яши килә. Шушы шартларда урыс халкына хас этник психология туа. Бу психология бик катлаулы. киң диапазонлы һәм капмакаршылыклар белән сугарылган. Патша сарайларында. власть тотучылар арасында туган аяусыз. оятсыз ялган бу халыкта хакыйкатькә омтылу теләге. тормыштагы явызлыклар исә савап һәм игелек эшләүгә этәреш тудыра. Самодержавие оештырган халыклар төрмәсе шартларында рус милләте кешелеккә Чаадаев. Толстой. Достоевский шикелле шәхесләрне биргән. Тифлис. Баку. Ош гарасатлары вакытында мин «Хаҗи Морат»ны тагын бер кат укып чыктым. Бөек рус корифее азатлык өчен кан коючы халыкларга нинди изге ихтирам белән карый алган. «Хаҗи Морат»та сокландыргыч бер эпизод бар. Урыс гаскәрләре бер авылга һөҗүм итеп. халыкны аннан тауларга куып җибәрәләр. Гаскәрләр оборона линиясенә кире чигенгәч. авыл халкы үз җиренә әйләнеп кайта һәм күрә: солдатлар мәчеткә кереп тәрәт иткәннәр. чишмәне пычратып. суын эчмәслек хәлгә китергәннәр. унбиш яшьлек үсмернең аркасына сөнге кадап киткәннәр. Шушы каннибаллыкка карата бөек рус язучысының нәфрәт сүзләрен кабатлыйсым килми. Вакыт табып. сез аны үзегез укып карагыз! Ә бит фашистларча кыланган солдатларның берсе дә явыз. канга сусап йөргән вәхши түгел. Көндәлек тормышта алар — тыйнак. юаш һәм шәфкать күрсәтергә әзер торучы бәндәләр. Шушы алогизм фаҗигане йөз. мең кат көчәйтеп җибәрә.

Шушы каршылыклы күренешне аңларга теләп. Кавказны яулап алу чорындагы документларны укыйм. Генерал Ермолов. Кавказ халыкларын сугыш кырында җиңә алмагач. патшага яңа тактика куллану кирәклеге турында рапорт яза. Яңа тактиканы император хуплый. Шуннан соң Төньяк Кавказның искиткеч гүзәл урманнарын. кырда башак кысып утырган игеннәрен. авылларны яндыра башлыйлар. Мал-туарны кыралар. коеларны. чишмәләрне агулыйлар.

Корпус командиры полковник Грековның 1882 елның 6 июнендә язган донесеньесы: «...Хатын-кызлар. балалар елавы. паника тирә-якка таралды. Кичү тирәсендәге үзән. якын тирәдәге урманнар халык белән. йөк төялгән арбалар. мал-туар белән тулды. Калкулыктан без картечь. ядрә. мылтык уты белән «эшкәртергә» тотындык. Халык берьюлы суга ташланды: хатын-кызлар. балалар. маллар. җайдаклар...»

«Көлгә әйләндерелгән җир» тактикасының авторы. башкомандующий генерал Ермолов бу эшне менә ничек дәлилли: «Монда. кырыс һәм кыргый. яхшылыкның нәрсә икәнен аңламый торган халыкларга. закон урынына. бары тик көч куллану гына уңыш китерә. Урысларның кораллы көчләреннән куркып яшәү генә кавказлыларны буйсындырып тота ала...» Ермоловка Грозный каласының үзәк мәйданында чуеннан койган һәйкәл тора. Теге пуля белән «эшкәртелгән» кавказлыларның оныкларының оныклары шул һәйкәлгә чәчәк бәйләмнәре дә сала торганнардыр әле...

В. Пикульның «Битва железных канцлеров» исемле китабының герое. авторның кумиры вице-канцлер А. М. Горчаков. XIX гасырның икенче яртысында Урта Азияне колонизацияләү максатын болай аңлата: «Әгәр без. ул вәхшиләрне җәзалаганнан соң. кире китеп барсак. безнең турыда көчсезләр һәм куркаклар дип уйлаулары бар. Азиатлар бары тик кыргый

аяусызлыкны гына ихтирам итә. Әхлак кануннары, аң, белем, шәфкать аларга бернинди тәэсир ясый алмый...» Күрәсезме, колонизаторлар уртак бер канун тудырганнар: аборигеннарның барысы да кыргый, явыз, ялганчы һ. б. Ә менә шәрыктәге японнар, Сингапур кытайлары, Көньяк Корея һәм Гонконгта яшәүче азиатлар кыска вакыт эчендә шушы канунның көлен күккә очырдылар.

Явыз Иван чорыннан башланып киткән урыслаштыру XVIII—XIX гасырларда Рәсәй империясенең үзәк сәясәтенә әйләнә. Бу илдә инородец (дөньяга башкача килгән кеше) булып яшәү оят, хәтта җинаять санала башлый. Алар арасында иң әшәкесе—татарлар. Чөнки алар өч йөз елга якын урысларны үзләренә буйсындырып яшәгәннәр.

Власть ияләре халыкларны берләштерү, аларның көчен бер ноктага юнәлтү өчен һәрчак дошман символы уйлап тапкан. Совет чорын гына алыйк. Революция алдыннан—самодержавие, гражданнар сугышы вакытында—аклар, соңрак троцкийчылар, зиновьев-бухаринчылар, черек интеллигентлар, космополитлар, диссидентлар. «Татар-монгол» золымы исә универсаль символ урынына кулланышта һәрчак тотылган. Бу символ әле дә файдаланыла.

Рәсәй империясе белән Госман империясенең чиге, заманында, Кременчуг (Кирмәнчек), Никополь тирәсеннән үткән. Әби патша чорында, «Византиянең изге васыятен үтәп, Константинополь мирасын, хәләл җиребезне кире кайтару» дигән чакыру ташлап, Босфор һәм Дарданелл бугазларына табан һөҗүм башлана. Төрек сугышына әзерләнер алдыннан татарларны чукындыру, аларны туган туфракларыннан куып, мөһаҗирлеккә дучар итү көчәеп китә. Төрки халыкларның берләшүләреннән куркып, алдан профилактик чаралар күрелә. Төрек сугышы башланыр алдыннан шовинистик хәрәкәт—панславизм көчәя. Петр Беренче заманында Рәсәйне яңа Рим империясе итү күздә тотылса, әби патша, Төркиядән тартып алган җирләрне бергә туплап, экспансияне Борынгы грек дәүләтен торгызу байрагы астында алып бара. Кырымда ял итүчеләргә экскурсоводлар грекча атамаларны борынгы греклар яшәгән чорныкы дип аңлаталар. Дөресе исә—Кырымдагы калаларга грек исемнәрен басып алганнан соң кушканнар. Акмәчет—Симферопольга, Акъяр—Севастопольга, Кафа—Феодосиягә әйләнгән. 1944 елдагы геноцидка кадәр Кырымда авыллар, ваграк калалар, тау, күл, елга исемнәренең күпчелеге татарча иде: Курман-Кимелче, Таракташ, Карасубазар һ. б. Андыйларны ашыгыч рәвештә алыштырырга тотындылар. Мин хезмәт иткән авиаполк Мелитопольда тора иде. Очучы кулындагы карталарда—татар исемнәре, хәрби округтан исә яңа исемнәр белән боерык килә. Округтан килгән исемнәр картада юк. Шуның аркасында һавада адашып йөрүләр, башка аэродромга утыру очраклары булып бетте.

Исем алыштыру—татар милләтен бетерү сәясәтенең бер өлеше ул. Безнең бабаларыбыз исемгә тап төшерүне зур фаҗигага, абруй югалтуга санаганнар. Исем—рухи эчтәлекнең тышкы күренеше.

Узган көзне мин Төркиядә йөрдем. Яңа шәһәргә барасыны алдан белгертәләр. Мин әле ул шәһәрне күрмәгән, аның нинди булуы, тарихы, утырган урыны турында берни белмим, ләкин исемен ишетү белән төсмерли башлыйм һәм күп очракта шул исем уяткан күзаллау дөрес булып чыга. Төркиядә мин тагын бер ачыш ясадым. Алфавитны алыштыру, гарәп графикасыннан кириллицага күчү дә халык аңына, аның рухи көнкүрешенә кереп урнашкан бик күп символларны, шул, символларга бәйләнешле мәдәни байлыкларыбызны исраф иткән. Борынгы татар архитектурасын, нәкыш сәнгатен, шамаилләрне, көнкүрештәге бизәкләрне һәм бабаларыбызның шул мирасларын буыннан-буынга тапшырып килгән изге хәреф-символларны юкка чыгару безнең манкортка әйләнүебезгә сәбәп булган.

Динебездән, гореф-гадәтләрдән, ата-баба мирасыннан яздыру, рухсызландыру—туган туфрагыбызны экологик талауга, катастрофага дучар итү. Бу җинаятьләр псевдоинтернациональлек байрагы астында урыслаштыру юнәлешендә эшләнеп килде. «Урыслаштыру» термины фаҗигане төгәл аңлата алмый, чөнки империя сәясәте урысларның үзен дә интектерә. Татарларга карата кулланылган сәясәтне манкортлаштыру, кешелектән яздыру дип атау дөресрәк булыр иде.

Моңа кадәр без манкортлаштыруны империя тарихы юнәлешендә тикшерергә тырыштык. Шушы процесска татар тарихы, татар халкының фаҗигале язмышы аша караганданиләр күрә алабыз? Сталинның тугрылыклы булышчысы А. Громыко, кырым татарлары турында сүз чыккач, СССРның Югары Советы Президиумы исеменнән болай диде: «Алар бит Кырымда яшәүче башка халыклар арасында бары тик унтугыз процент кына булганнар»... Унтугыз процент! Шул кечкенә генә ярыматауда яшәгән

«19 %лы» халыкның гаскәре. Казан һәм Әстерхан Явыз Иван коллыгына эләккәннән соң, Рәсәйнең башкаласы Мәскәүне алуын. Явыз Иванның: «Казан ханлыгыннан, Әстерханнан гаскәрләремне алам.» — дип ант иткәнлеген фән докторы Громыко белергә тиеш иде бит. Бу очракта без Рональд Рейганның «явызлык империясе» дип атаган феноменының хәрәкәткә килүен күрәбез. Татарга карата итәк астыннан ут йөртү, шалшак гаделсезлек — бу алымнарның берсе дә гөнаһ саналмаган. Британ империясе кулланган «бүлгәлә һәм идарә ит» кагыйдәсе Рәсәй империясе шартларында: «Туракла, тар-мар ит, милләтләрне маңгайга-маңгай чәкештер, сулыш алырга мөмкинлек калдырма», — рәвешендә тормышка ашырыла.

Аксак Тимер, Алтын Урданы җимереп, Мәскәү кнәзьлеге өчен мөмкинлекләр ачып китә. Ул чорда әле Казан, Әстерхан, Нугай, Кырым, Себер ханлыклары һәрберсе, мөстәкыйль рәвештә, Мәскәү кнәзьлегенә каршы тора алырлык булсалар да, Алтын Урда мирасы, шуның урынына утырыр өчен үзара туктаусыз ызгышып тору аларны көчсезләндерә. Мәскәү кнәзьлеге шушы низаг утын гел көчәйтеп, аларны үзара чәкештереп тора, һәм әкренләп, ханлыкларны берәмләп, яулап ала башлый. Казан ханлыгы коллыкка эләккәннән соң да, бердәм эш иткән очракта, азатлыкка ирешү мөмкинлекләре була. Бүленү, тураклану һаман дәвам итә. Башта опричнина кырып ташлаган урыс боярларының җирләренә Казан ханлыгының югары катлам аристократларын күчереп утырталар. Аннан соң, чукындырулар башлангач, татарларны мөселманга һәм керәшенгә бүлеп, үзара берләшү мөмкинлегеннән мәхрүм итәләр. Казан ханлыгындагы әйбәтрәк җирләрне самодержавиегә хезмәт иткән урысларга биреп, җирле халыкны туган туфрагыннан куу башлана. Бу сәясәт әле дә дәвам итә. Татарларны бүлү, милләткә хыянәт итәргә мәҗбүрләү өчен гасырлар буе тагын бер уңышлы алым кулланыла: татарны түрә итү. Татар түрәсе урыс түрәсеннән аяусызрак, кансызрак.

Татарны бүлгәләү дәвам итә. Әһәмият биреп укыдыгызмы икән: Ж. Миндубаев «Литературка»ның 44нче санында (1990 ел) болай яза: «И вот уже поговаривают в интернациональных (!) Набережных Челнах, в Нижнекамске о создании некоей «закамской республики» и о выделении оной из суверенного Татарстана». Шул сүзләрне укыгач, Шекспирның «Венициан сәүдәгәре» дигән трагедиясендәге Шейлок монологы искә төшә: «Бер кадак ит әҗәте өчен мин аның йөрәген кисеп алам...»

Армиягә китәр алдыннан мин Чаллы төбәгенә ашлык ташыдым. Тоташ татарлар яши иде ул тирәдә. Шайтан таягына охшаш тамырсыз токым баскан икән хәзер...

Бүленүдән соң барлыкка килгән кисәкләрнең күләме һаман кечерәя. Соңгы вакытта безне иң якын, тугандаш һәм уртак язмышлы башкортлар белән чәкештерергә тырышалар. Татарны болгарга, мишәргә, типтәргә, нижгәргә һ. б. бүлү дә уңышлы бара. Милли бердәмлекне таркатуда тагын бер чара уңышлы башкарылып килә. Яңартып кору, хәбәрдарлык игълан ителгәч, мәскәү татарлары «Туган тел» оешмасы төзегәннәр иде. Матур гына кичәләр, күренекле фән, сәнгать, әдәбият әһелләре белән очрашулар уздырыла башлады. Асадуллаев йортын (татарлар үз акчаларына салган сарай) бирәбез дип, МГКның беренче секретаре Прокофьев телечыгышында безгә вәгъдә бирде. Киләчәк матур һәм өметле күренде. Нәкъ шул чакта Гарипов дигән чиктән тыш актив һәм эшчән оештыручы каяндыр яңа бер кешене җитәкчелеккә алып килде. Без Гариповка ышандык һәм шул яңа кешене җитәкче иттек. Мәдәни кичәләр, очрашулар, нәтиҗәле эш урынына кәгазь язу, аны раслау, тагын яңаны язу, яңадан раслаулар башланды. Асадуллаев йорты кулдан ычкынды, ниндидер вак низаглар, власть бүлү башланды. Мондый алымны нинди ведомство кулланганын аңлатып торасы юктыр дип уйлыйм. Таныш алым.

Милли яңару, азатлык өчен көрәш юлындагы киртәләрне санап бетерерлек тә түгел. Шуларның иң көчлесе — татарның психологиясенә кереп оялаган таркаулык, уртак тел таба белмәү, хәлиткеч мизгелдә, бәхәсләшүгә күчеп, мөмкинлекне кулдан ычкындыру. Империя түрәләре гасырлар буе безне бер-беребезгә дошман итеп тәрбияләргә тырышканнар һәм максатларына ирешә килгәннәр. Милләтне шул авыр хастадан тергезү өчен күпме көч, күпме түземлек һәм фидакярлек кирәк?!

Бәлки, безгә милләтне торгызу кирәк тә түгелдер? Безне хәзер, базар икътисадына күчкәндә, милли көрәш сәясәтеннән баш тартып, байлык өчен көрәшкә чакыралар. Безне милли программадан ваз кичәргә өндәүчеләр мисалга Европа икътисади берлеген китерәләр. Әмма бу юлдагы зарури бер этапны яшерәләр. Европа илләренең бүгенге көндәге берләшүе — тигез милләтләр, азат илләр берлеге ул. Империя сәясәтчеләре барлык

милләтләргә азатлык бирсәләр. Европа ысулындагы берләшү безгә дә киләчәк. Без шуны онытмаска тиешбез. Татар азатлыгы башкортка, әрмән азатлыгы әзербайҗанлыга, урыс азатлыгы Балтыйк буе халыкларына коллык газабы китерергә тиеш түгел.

Татар булып яшәү минем халкыма күпме авырлык, аһ-зар, канлы күз яшьләре, күпме үлем, бәхетсезлек китерде. Бәлки, безгә, үзара килешеп, Брежнев игълан иткәнчә, «совет халкы» булып, мәшәкатьсез тынычлыкта яшәргә генә кирәктер?

Белмим, табигатьме, әллә Аллаһе Тәгалә үземе, кешелек сыйфатларына ирешү юлында өч баскыч яулап алуны зарур итеп куйган. Бәндәлектән шәхеслеккә күтәрелүне, сукбайлыктан гаиләле булуны һәм аерым бер милләт вәкиле дәрәҗәсенә ирешүне. Адәм балалары шушы омтылышларда яши. Шәхеслеккә ирешү адәм баласын кешелекнең күркәм сыйфатлары белән бүләкли. Гаилә нәсел дәвамы, тәрбия җимешләре, җан җылылыгы һәм башка күп төрле гуманистик куанычлар, чын бәхет бирә. Милли горурлык хисе безне халык дигән бөек, илаһи көч белән тоташтыра һәм аңа лаек булу омтылышын тудыра. Ирекле милләт үз балаларының иминлеген кайгырта, аларга бәхеткә илтүче юлларны күрсәтә.

Совет чорында «вак халык» дигән сүз барлыкка килде. Шушы сүзне ишетү белән тәннәрем чымырдап китә. Халык дигән бөек исемгә ирешкән этник берәмлек бәләкәй була аламыни?!

Бу темага кагылышлы фикерләрнең иге-чиге юк. Гасырлар буе тупланып килгән катлаулы мәсьәләләрне чишәргә кирәштек. Юл авыр, катлаулы. Милли азатлык көрәшенә чыккан тугандашларыма мөрәҗәгать итеп, менә нәрсә сорар идем мин. Иң беренче, урыс халкына тел тидермәскә. Икенчедән, Михаил Георгиевич Худяков, Лев Николаевич Гумилев, Андрей Дмитриевич Сахаров шикелле, безнең иминлек өчен көрәшкән бөек шәхесләрне ихтирам итәргә, андыйларның хезмәтләрен таратырга, өйрәнергә! Милли азатлыкның төп дошманнары — бюрократия, шовинистлар, карагруһлар. Алар арасында татарлар да җитәрлек. Милли мәнфәгатькә хыянәт итүчеләргә мул түлиләр, шуңа күрә милли хәрәкәтне җиңеп тә була. Эпиграф итеп мин Конфуций фикерен куйдым. Кабат әйтәм, без тарихтагы җәберләрне, гаделсезлекләрне онытырга әзер, тик газета-журнал битләреннән, телеэкраннан тоташ ачылып торган мыскыллау, куркытырга тырышып янаулар, кимсетү сүзләре тукталырга тиеш. Безнең таләп шул.

Флора Әхмәтова

# КАМИЛЛЕККӘ ОМТЫЛУ

Америка Кушма Штатларының Висконсин штаты Мэдисон шәһәре университеты каршындагы Үзәк Азия Ассоциациясе тарафыннан уздырыла торган IV халыкара конференциядә катнашканнан соң, анда алган тәэсирләрне журнал укучылар белән дә уртаклашасы килү теләге кулга каләм алыга мәҗбүр итте. Ә сөйләр, уртаклашыр нәрсәләр күп!

Конференциянең беренче көнендә ук безне горурландырырдай нәрсәләрдән аны оештыручылар Мэдисон университеты профессорлары әлеге Ассоциация президенты Кемаль әфәнде Карпат һәм былтыр Казанга килеп Алтын Урда турында лекция сөйләп киткән яшь галим Юлай әфәнде Шамил угылы, Лос-Анжелес университеты профессоры, «Идел буе татарлары» китабы авторы Гайшә ханым Рорлих булганын һәм беренче докладның татар телендә Казан университеты проректоры, профессор М. Госманов сөйләвендә яңгыравын әйтергә мөмкин. Шулай ук кич концертта якташыбыз, бөтен дөньяда алдынгы композиторларның берсе Софья Гобәйдуллина әсәрләре башкарылуын һәм Сан-Францискодан Мэдисонга конференция тыңларга татар галимнәре белән күрешергә, дип милләттәшләребез Шәмсия ханым һәм Салих әфәнде Апакайлар, Нәрмин туташ Диюш махсус килүләрен әйтер идем. Калифорния, Канзас штатларыннан да танышлар шылтыратып, көн саен сөйләшеп тордылар. Минем Мэдисонга совет делегациясе белән Нью-Йорк аша тугел, Вашингтон аша очасын белгәч, һәммәсе Карпат әфәндегә шылтыратып, телекс, факслар җибәреп, хәбәр итеп торганнар.

Конференция, нигездә, төрки-мөселман халыклар тарихы, теле, иҗаты, милли, сәяси проблемаларына багышланган иде. Кемаль әфәнде Карпатның конференцияне ачу доклады «Үзгәртеп кору һәм хәбәрдарлык шартларында Америкада Үзәк Азияне өйрәнү мәсьәләләре» дип куелды. Чыгышларының берсендә ул кунакларны, «Союзда уналтынчы республика» дип, Татарстан игълан ителүе белән котлады. Әле аэропорттан кайтышлый ук ул шундый фикер әйтеп барган иде: «Татарлар эшчән, акыллы халык. Әмма фәндә күбрәк техник фәннәргә йөз тоталар (К. Вәлиев, Р. Сәгъдиев, Р. Тәбиләрне атады). Ә халыкның, милләтнең йөзен ачу, аны дөньяга таныту өчен тарих, тел, сәнгатьне күрсәтергә кирәк». Үзенең шәкерт һәм коллегаларына ул Добруджа татары керәшеннәре (Париж галиме А. Кефели-Елэй), Идел һәм Себер татарлары дини карашлары (А. Франк, Индиана), Кырымда «Яшь татарлар» хәрәкәте (Х. Кырымлы, Мэдисон), Алтын Урда һәм нугай турында (проф. Ю. Шамил угылы, Мэдисон) һ. б. докладлар биргән. Профессор Гайшә ханым Рорлих (Лос-Анжелес), Кемаль әфәндегә туган тиеш, җәен Казанда, Алма-Атада, Фрунзеда булып киткән иде. Ул СССР мөселман республикаларында экологик кризис һәм хатын-кызлар хәле турында сөйләде. Конференцияне оештыручылардан берсе буларак, хатын-кызларны ул чакырттырган булса кирәк. (Кыргыздан рәссам Д. Чочунбаева, әзербайҗаннан композитор Ф. Ализадә, татар, казах, таҗик галимнәре). Күкрәккә исем-фамилияне тагып әлгәч, «Идегәй»не Сез әзерләдегезме?» — дип, берничә галим килеп сораштылар. «Алпамыш»ның Ә. Диваев вариантын төрки американ һ. Паксой әйбәт чыгарып китерган. Американ фольклорчысы Д. Бэйли рус былиналарының инглизчәгә тәрҗемәләрен бүләк итте. Татарлар дусты, М. Солтангалиев турында китап язган А. Бенигсен кызы Фанни ханым күп китаплар бүләк итте. Күтәрә алганча алып барган китапларыбызны без дә галимнәргә һәм Мэдисон университеты китапханәсенә бүләк итеп калдырдык. Анда татар китаплары бик аз икән.

Барлыгы 45—50 доклад ике аудиториядә инглизчә сөйләнде. Берничәсен русчадан, татарчадан, үзбәкчәдән, әзербайҗанчадан, төрекчәдән инглизчәгә тәрҗемә итеп бардылар. М. Госманов һәм Р. Фәхретдинов татарча сөйләделәр. Темалары татар халкының килеп чыгышы, аның XV-XVIII гасыр тарихи чыганакларындагы урынына кагылышлы иде.Төрек-татарча да яхшы белгән берничә рус һәм яһүд галиме никтер залны ташлап чыга башлады. Бу хәл әзрәк эчне пошырды. Мирфатих ага һәм Али Чиченов (Мәскәүдән, ул да башта балкар телендә сөйләмәкче иде) Болгар-Хазар һәм Биармия турындагы

докладларын русча сөйлисе иттеләр. Юлай әфәнде алар сөйләгәнне инглизчәгә тәрҗемә кылды.

Минем доклад конференциянең өченче көнендә булырга тиеш һәм ул бик үзенчәлекле иде: «Идегәй» дастанында сүз белән сурәт ясау». Әйтик, «картайгач», дими, «Утыз тешем беткәндә, йөз сиксәнгә җиткәндә»,— ди. «Кашларына карасам, каләмнән пәйда булгандай. Күзләренә карасам, күгәннән пәйда булгандай» дигәндә каләме билгеле сурәт булса, күгәне — күк йөзе зәңгәрлегеннәнме, әллә күгән дигән зәңгәр җимештәнме (Себер) яисә күгәндеш дигәндәге зәңгәр чәчәктәнме һ. б. тикшерү, шулай ук дастанның авыз иҗаты булудан бигрәк язма чичәнлеккә каравын, 50 ел зинданда ятуын һ. б. сөйләргә тиеш идем. Әмма карыйм: залда «Идегәй»не түгел, татарның үзен дә белмәгән кешеләр бар кебек. Кермәгәннәр кермәс тыңларга, кергәннәре ташлап чыкмаслык итүне уйларга кирәк иде. Мәкаләне шул көе калдырып, докладны бөтенләй башкача сөйләргә уйладым, аеруча русча белүчеләр өчен инде.

Илһам Шакиров башкаруында «Карурман»ны яңгыратып башларга телим. Әле Шәмсия ханымнар килмәгән иде. Аларның татарча җыр язмалары инде ярты меңгә җитә торгандыр. «Карурман», «Казан сөлгесе»н ала килүләрен үтенәм. Алар: «Илһам аккомпанементсыз җырлый бит. Ансамбль башкаруында кәккүкләр, сандугачлар да ишетелә. Бу очракта Шамил Әхмәтҗанов яңгыраса, әйбәт булыр»,— дип, шул язманы алып киләләр. Мин инде докладымны «Камиллеккә омтылу» дип үзгәртүемне аңлаттым да, «Карурман»ны тыңлатып, менә бу җыр авторы Иделдә, Уралда, Себердә, Кырымда мең еллардан артык яши, дип, бер сүз белән тарих, географияне атыйм. Антропологиясенә килсәк, менә Р. Фәхретдинов докладында әйтелгәнчә, 85 % ны европеоид, 15 % ы минем шикелле монголоид, дим. Этнографиясендә малчылык һәм игенчелек, мал тиресен шул дәрәҗәдә камил эшкәртеп, дөньяга «болгари» һәм «сафьян» дигән күн бүләк итәләр. Үрнәге моннан 2500 еллар элек Алтайда Пазырык курганнарында табылган күн аппликациясен ефәк белән чигеп, татарлар шундый камиллеккә ирешәләр, дим һәм чиккән читекне күрсәтәм (дөресе, Равил күрсәтеп утыра). Рус фольклорында «Привези мне из Торжка два сафьянных сапожка»,— дип, шулар җырланган, патшалар шуларны кигән, Эрмитаж саклагычларында менә шундый читекләр ята. Кәҗә мамыгыннан эрләп шәл бәйлиләр икән, аның бәяләмә-үлчәме шул: шәл йөзек аша үтәрлек булсын. Бодай онынннан токмач киссәләр, камырны кәгазьдән юка җәеп, кылдан нечкә кисәргә тиешләр — шундый эстетика. Шул ук бодай оны, йомырка, сары май һәм балдан менә нинди деликатес әзерләнә, дип, чәк-чәк белән сыйлыйбыз.

Инде кайбер дошманнар, татарларда пакьлек, арулык җитми, дип сөйләнәләр. Менә бу Казан сөлгесе — сынлы сәнгатьтә үрнәк, җырда ләззәт, сәхнә сәнгатендә классика, чөнки татар халкының пакьлек символы булып, туганыннан алып гүргә иңдерелгәнче доминанта хәлендә яши. Авыл хатыны менә бу чиккән ак яулыкны башына көнгә ике тапкыр бәйләми — арулык кульпы татарда. Менә шул халыкның төп эпик китабы — «Кыйссаи Йосыф», инде 800 ел телдән һәм китап кишстәләреннән төшми. Ул сүз сәнгате генә түгел, көй белән дә укыла, дип, магнитофоннан Саратов, Пенза якларындагы популяр көен тыңлатам. Ул «Игорь полкы турында сүз» белән бер заманнарда иҗат ителгән, дип санала, әмма аларның халык телендә һәм күнелендәге урыннары чагыштыргысыз. «Йосыф» китабыннан 300 еллап соңрак иҗат ителә башлаган «Идегәй» дастанында музыка юк, сүз сурәте гаҗәеп көчле. Татар халкы гади хат язуын да энҗеләр тезү белән чагыштырып җырласа, бу дастандагы сурәтләр һәммәсе энҗе бөртеге, асылташлар кебек ялтырый, дигән төп өлешне киләчәктә мәкаләдә укырга тәкъдим итеп, сүземне тәмамлыйм.

Соңыннан тюрколог руслар А. М. Щербак, И. Н. Кормушин һ. б. ның «иң яхшы доклад» дигәннәрен магнитофонга язып алдым. Докладны үзгәртүем Кемаль әфәнде Карпат сүзләрен тотып та эшләнгән иде, әмма ул мин сөйләгәндә залда күренмәде бугай. Шулай да Нью-Йоркка Рифат әфәнде Тәбигә дә кемдер: «Әйбәт доклад ясады Әхмәтова»,— дигән. Югары стильгә күчсәк, тәшәккердән гаҗизмен, мәмнүн улдыгымны изһар итмәктәмен.

Ә менә соңгы көн сәяси мәсьәләләргә багышланды. «Колониализм нәрсә ул?» дигән сөальгә җавабында мөхтәрәм профессорыбыз Раиль әфәнде Кузеев (Уфа) терминология аңлату беләнрәк чикләнде булса кирәк. Лингвист И. Кормушин (Мәскәү), басып: «Дәүләт нәрсәнедер алып, бернәрсә дә бирмәсә, шул була колониализм»,— дип төгәлләгәч, үзбәк мамыгын, кыргыз алтынын, якут алмазын су урынына агызу, «Невада» хәрәкәте, совет төрки ханымнарын күп бала тудыруда гаепләүләр һ. б. сүзләр буаны ачкандай агыла башлады. Ә Татарстан нефтен 2,5 млрд тонна агызып, бер тиен бирмичә, шушында-

гы көтепханә кебек үк байлыкны башка хәрефкә күчерү алымы белән юкка чыгару, татар мәктәпләре булмавын башка, кечерәк аудиторияләрдә һәм кулуарларда сөйләсәм, тыңлаучыларым башта аңлый алмый торалар. Һәрхәлдә: «Казанга киләсе килә, чакыртмассызмы?» — дип сөйләшеп йөргән Агнес, Алан кебек яшьләр күзендә кызгану, өмет киселү күргәндәй булдым. Килегезсәнә, дусларым! Мең кат ишеткәнче, бер кат күрү артык. Ачтан үлмәссез. Аның каруы, яшьләребез белән аралашып, бай тарихлы, мул табигатьле Татарстаныбызны сезнең ил ирешкән муллык, арулык, кешелеккә кайтарышырга ярдәм дә итәрсез, бәлки.

Безнең ашау-эчү, отельдә тору, ил эчендә самолет юллары Ассоциация тарафыннан түләнгәнлектән һәм үзебездә сыңар бер тиен акча алмаштырылмаганга, без хуҗалар өчен күпмегә төшкәнебезне белә алмадык. Шулай да үзебез теләгән җирдә ашарга дип унар доллар бирделәр. Бер кечне студентларның кул буенда урнашкан матур, чиста, шактый очсыз ашханәләрендә ашап чыгармын, дисәм, шул акчаның бер ашауга җитәр-җитмәсен белдем.

Мэдисон — күз яшедәй саф сулы, матур күлләр буенда урнашкан, 400 мең халкы, 45 мең студенты булган, яшел газоннар, парклар, стадионнар каласы. Завод-фәләннәр күрмәдек. Театр да юк. Һәммә тамашалар университет концерт залында бара. Һавасы чиста. Шәһәр тыныч. Яшьләр төне буе урамнарда хәрәкәттә, җырлыйлар, бииләр, ат арбасына да утырып йөриләр, нәрсәләрдер саталар, ниндидер үләннәр көйрәтәләр. Әмма ул-бу ишетелми. Бер ял көнне зур митинг булды, марихуана сатуны легальләштерү икән таләпләре. Берәр сәгать сөйләшеп таралыштылар.

Бер зур матур өйдә төрек яшьләре клубы урнашкан. Анда очрашуга баргач, мин яшьләрне Бакый ага иҗаты белән таныштырдым. Альбомын, слайдларын алып барган идем. Кызганычка каршы, Тукайны да, Урманчены да, Кайсын Кулиевне дә белүче юк. Шулай ук безнең дә Н. Хикмәт һәм А. Несиннән башканы белмәвебездән кычкырып көлделәр.

Юлай һәм Винсент әфәнделәр — өйләрендә, Кемаль әфәнде — төрек, Джеймс әфәнде итальян рестораннарында кунак иттеләр. Өйләрдә һәм төрек яшьләре клубында бездәге һәм рестораннардагы шикелле өстәл тирәли утырып, аңгәмә кору юк. Аля фурше: һәркем үзенә кирәк хәтле салат, ит, җимеш, туңдырма кебекләрне кәгазь тәлинкәгә җыеп ашау, сулар, шәраблар эчеп, ике-өчәр кеше сөйләшкәләп йөриләр. Аш алды, аш арты ашлары, кайнар көе бирү өчен борчылу кебек мәшәкатьләр юк. Ашау-эчү, кием-салым табу бездәгечә проблема булмагангадыр инде, әз ашыйлар, гади киенәләр кебек тоелды.

Нью-Йорк дәү микән? Җылымы, матур микән? Безнең белән бер көнне үк килеп төшеп, кунарга урын, түләргә акчалары булмаган рус коллегаларыбыз күзенә ни җемелдәгән Бродвейлар, ни күккә ашкан ташпулатлар, ни шәһәрне әкияти чолгап яткан океан матур булып күренә алмагандыр, мөгаен. Шул көнне үк алар, Ленинград рейсына эләгеп булса да, Мәскәүгә кайту ягын караганнар. Ә безнең затлы һәм газиз, кунакчыл һәм киң күңелле милләттәшләребез кайсыдыр штатта фәнни конференциядә катнашкан галимнәрен күрми кала алмаганнар, алдан ук бүлешеп куйганнар, очрашу мәҗлесе оештырып, кунакка чакырып, бүләкләр биреп, зур хөрмәт итеп калырга уйлаганнар. Мең рәхмәт аларга!

8 миллионлы Нью-Йоркта йөзләп кенә татар гаиләсе яши, диләр. Һәрхәлдә, үзара аралашып яшәүчеләре шул чама. Шәһәр уртасында үзләре генә җыелып, бәйрәмнәр, төрле очрашулар уздырыр өчен, балаларга татар теле һәм музыкасы, дин сабаклары өйрәтү өчен махсус бина сатып алганнар.

Асия ханым Аги үзенчәлекле бер җыр җырлаганны бездән алдагы конференциядә булган профессор Я. Абдуллин әйткәч, мин ул җырны алдыру әшенә керешкән идем. Шәмсия ханым аның ике язмасын миңа тапшырды. Мин аны Татарстан радиосыннан ишеттерү нияте белән Р. Ильясовка тыңлаткан идем, әллә ни реакция сизелмәде. Мин, Асия ханымда тагы үзенчәлекле җырлар булырга тиешлеген абайлап, бу турыда газетада да язып чыктым. Шуннан соң Р. Яхинның «Керим әле урманнарга» дигән җырын янә берничә җырны бер ир кеше белән матур җырлаган тасмасы кулга керде. Үзен күрмәгәч, мин Асия ханымны олыгаеп, моңаеп утыра торган ханымдыр, дип күз алдына китерә идем, бигрәк тә «Салкын чишмә»не пианинода ничектер элеккечә уйнавын ишеткәч. Ул аны остазы М. Солтановадан откан булган. Үзе әле яшь, дәртле, музыка укытучысы икән, Харбинда консерватория тәмамлаган. 22 яшьлек скульптор улы Әдип белән бергә җырлаганын да яздым. «Таулар» дигән җыр һәм мәүлет бәетләрен язып алдым. Зәйтүнә ханым Тәби, Нәркиз ханым һәм Илдар әфәнде Агишлар башкаруында Харбин «Тәфтиләү»ен, «Сак-Сок» бәетен һәм бер сугыш бәетен язып алдым. Фаизә

ханым Сәләк, Нәфисә ханым Алмакай, аның кызлары Мөнирә һәм Нурия ханымнардан мәүлет, тәрәвих һ.б. язмалар керде.

Рөкыя ханым Вафалы да күп бәетләр, мөнәҗәтләр белергә тиеш. Ул Нью-Йорктан читтәрәк яши икән. Кичәдә генә аннан күп нәрсә язып өлгерә алмадым. «Азатлык»та да эшләгән. Үзе дә, ире Габдулла әфәнде дә — җаннары-тәннәре белән сәнгатебезне, халкыбызны яратучы затлар.

Нинди көенечле очраша алмаулар була бит ул! Әле Рифат әфәнде Тәбине быел үзебез Казанда бер-ике көн көтеп утырган идек. Әмма нишлисең! Кызганычка, күрешә алмаган идек.

Мена мине Тәбиләрнең олы ир туганы Әнвәр әфәнде һәм Ләйлә ханымнар гаиләсенә урнаштырдылар. Рифат әфәнде гаиләсендә профессорлар М. Зәкиев һәм М. Госманов торды. Илдар әфәнде Агиш Р. Фәхретдинов, Р. Кузеевларны алып кайткан.

Ни гүзәл кешеләр булгандыр Тәбиләрнең гаилә башлыгы Шакир ага һәм аның күптән түгел генә дөнья куйган хәләл җефете! Өч уллары: Әнвәр, Ирфан, Рифат, дүрт кызлары Рәфика, Шәфика, Диляра, Рәхилә белән алар бу сугыш алдыннан гына Ак Мәчеттән (Симферополь) Алманиягә, аннан Төркиягә, аннан инде Америкага килеп дөнья куялар. Токымнары чибәр, таза, акыллы — төптә Әҗем авылы җәмәгате. Әнвәр әфәнде — Төркиядә Касыйм татарларыннан (Шакуловлар нәселе үк түгелме әле) Ләйлә ханымны, Ирфан әфәнде Оренбург ягыннан Зәйтүнә ханымны тапканнар, һәммәсе әйбәт гаилә корган. Бер тирәдәрәк урнашып, җәен океан буендагы дачаларында, балаларны җыеп чын татарча яшәп яталар. Шаһидә ханымны Касыйм ягына гына хас олылау белән «кода әннәкечкенәм», «әбкәм» дип хөрмәт итәләр. Үзе туктаусыз эштә. Пилмән, пәрәмәч, сөзмә-катыклар гел татарча булса да, төрек кухнясын үз итә төшкәннәр инде. Илдән киткәннәренә илле елга якын, әмма безнең тормышны бөтен нечкәлекләре белән аңлап торалар. Шул ук вакытта безнең иң борынгыдан калган асыл хасиятләрне саклап кала алганнар: ярдәмчеллек, илнең моггәбәр кешеләрен тану, аларны үстерү өчен кулдан килгәнне эшләү... Авылларда берәрсенә кунак килсә, туганнарны җыю, аннан соң аларны кунакка алу гадәте кайбер районнарда әле дә саклана бездә. Океан артында аларны безнең Аги, Агишлар, Тәби, Диюшлар, Сәләх, Мәҗитләр, Вафалы, Килкилар, Апакай, Алмакайлар саклый икән.

Татар җәмгыяте белән очрашуда безгә Гаяз Исхакыйның дүртәр китабын бүләк итеп бирделәр. «Җан Баевич» дигән әсәре Харбинда куелу уңае белән төшкән фотода чәчәкләр тотып утырган автор, баш рольне башкарган язучы Хөсәен Абдюш, башка чибәр-чибәр һәвәскәр артистлар. Болары — шуларның токымнары инде, димәк, без күргән татарлар. Хәзер шул эмигрантларнымы, әллә безнеме тикшерәсе: акмы, кызылмы, фашистмы, коммунистмы, империалистмы, капиталистмы, дип.

Мена Нью-Йорк татар җәмгыяте башлыгы Илдар әфәнде Агиш. 30-35 яшьләрендә. Моннан ике ел элек биш иптәше белән, фин яшьләренә кушылып, безнең илгә дә килеп киткән иде. Сабыр-салмак, акыллы һәм ачык булуына һәркем яратып калган иде үзен. Кыска вакытлы күрешүдән ике сүз истә калган. Мәчет агайларының: «Миллионерларыгыз бармы? Айзек Азимов татармы?» — дигән белдекле сорауларына: «Азимовның үзен татарлардан саныганын белмим. Кемнең кесәсендә күпме миллион бардыр, аннан да хәбәрем юк. Үземдә миллион юк. Шулай да кирәгемә, сезне килеп күрү мөмкинлегенә акча җиткердем», — диде. Күрешкәндә дә: «Океанның теге ягында булырмы ул очрашулар, бу ягындамы — була торсын!» — дип киткән иде. Һич уйламаганда, менә теге якта һәм беренче көнне үк үз өендә мәҗлестә очраштык. Әлбәттә, мин киләсен дә, Бакый ага вафатын да белмәгәннәр, тәгъзия белдерделәр. Әти-әнисе Фатыйма ханым һәм Габдрахман әфәнде шундый яшь күренәләр. «Ничек шундый акыллы, чибәр уллар үстерә алдыгыз?» — дип сорайсы килә һаман. Хатыны Нәркиз ханым, әти-әнисе Маһинур ханым һәм Габдулла әфәнде Агиларга да, аларның киленнәре Асия ханым Агига да шул сорауны бирәсе килгән иде, бер биш яшьлек бала күзендә күрдем мин аңа җавапны.

Нәркиз ханым, өч баласы белән күбрәк өйдә булыр өчен, иртәнге дүрттә эшкә китә. Унберләрдә өйдә була. Балаларны мәктәпкә әтиләре озата, әниләре каршы ала. Җәен дуслары белән йә яхтада, йә кечерәк корабта Төркиягә, башка илләргә барырга яраталар икән.

Илдар әфәнде кунакларга җимеш таратып йөргәндә балалар йокларга китте. Кече кыз Әлфия төнгә ак күлмәген кигән, әтисенә кунаклар артыннан гына кул изәп тора. Йә, ничек тасвирларга бу күз карашын? Анда сорау да, өндәү дә, чакыру да, олы мәхәббәт, бәхет, сәгадәт! Әтисе өчпочмаклап киселгән карбыз, дүртпочмаклап өелгән кавын, алар өстенә куелган җиләк, тагы нindидер экзотик җимеш өеме тулы подносын җәйләп кына куеп торды

да, сабыр адымнар белән кызы янына китте. Күтәреп алып, үбеп күрештеләр, кыз кул болгый-болгый йокы бүлмәсенә баскычтан менеп китте.

Олыларның да үзара «май кошым», «җаным», «абзый» дип мөгамәлә кылулары, елмаюлары җанны рәхәтләндерә; ниндидер төптән, күңел түреннән килгән, бөтен җанын ачып,күзенең иман нурын бөркеп, йөзен яктыртып җибәргән елмаю аларда.

Нурия ханым һәм Рөстәм әфәнде Борлуҗаларның ак пароходтай өендә түгәрәк өстәл тирәсендә Раил әфәнде Кузеевның расалар һәм милләтләр турындагы гыйлемен тыңлап утырабыз. Профессорны җөпләп, хуҗа ханымның апасы Мөнирә Коръәндәге «Сезне һәммәгезне тигез яраттым» дигән сүрәне искә төшерә. Әңгәмәне Нәркиз ханым дәвам итә — «Балалар курчаклары белән уйнаганда: «Банан апа!», «Шоколад абый!» дип сөйләшәләр», — ди. (Без, гомумән, раса дискриминациясе аларда түгел, бездә иканен күреп кайттык). Менә шулай иркен, табигый рәвештә динлелек, иманлылык бала туганнан бирле хөкем сөрә. Ортодоксаль диндарлык та түгел, денсезлек, тәрбиясезлек тә юк. Дини йолалар белән беррәттән, җырлар да бәйли араны. Халык җырлары, композиторларыбыз әсәрләрен илдән алдырып торалар, килүче-китүче бүләк итә икән. Ноталарга сусыйлар. Балалар музыка өйрәнәләр. Рөстәм Яхин әсәрләре анда бик популяр. Кызганыч, татар әдәбияты бүгенге хәрефләр аркасында укыла алмый. «Алманиягә күчеп — алманча, японда — японча, бередә инглизчә өйрәнергә мәҗбүр булдык. Инде моннан торып урыс алфавитын өйрәнгәнче, без көчебезне әти-әниләребез укыган гарәп графикасын өйрәнүгә сарыф кылабыз. Нигә соң латин алфавитына күчмисез? Бөтен дөньядагы татарлар үз әдәбиятларын укып рәхәтләнерләр, театрлар куяр идек», — диләр күз яшьләре белән.

«Илдә ниләр бар икән?» — дип кызыксынулары да шуннан аларның. Әдәбият, сәнгатебезне күрмиләр, ишетмиләр. Радио тавышы, телевидение тапшырулары җитми. Газета-журналлар юк. Кайберәүләр «Сөембикә»не ала. Анда да Бөгелмәдән берәүнең: «алар капиталистлар, безгә ярдәм итмәделәр,» — дигәне җаннарын өшеткән. Чит-ят илләрдә тырышып-тырышып, зур уңышлар белән көн күрү бәхетенә ирешкән милләттәшләрдән ил эчендә ятып ярдәм көтү — безнең әхлак дәрәҗәсе төшүне күрсәтә инде.

Бервакыт безгә килгән чит ил кунакларын озатып, машина көтеп торганда шундый хәл булып алган иде. Ишек алдында комда чыр-чу килеп, яман да кычкырышып, бер төркем бала-чага уйный. Күренә: бер олырак абзыйның җанына һич хуш килми бу тавышлар. «Уйныйлармы? Ызгышаларммы соң алар? Әти-әниләре кая?» — дигәндәй, шул якка борылып-борылып карый. Соңыннан ул безнең мәшһүр ТЭЦ төтеннәренә төртеп: «Балалар язмышы менә шул төтен кебек сездә», — дип, машинага утырып китте. Төрлечә уйлап йөрдем мин аның бу сүзләрен. Менә хәзер аңлагандай булам...

Илдар әфәнде, бер эш көнен сорап алып, безгә көне буе шәһәр күрсәтеп йөрде. Метрополитен-музеум, Карнеги-холларның яныннан узу да, кичке Бродвей, БМО бинаоары, 107 каттан шәһәрне карау, Чайна-Таунда сыйлау, фотога алуларны — һәммәсен алдан уйлап куйганнар. Шул машиналарны әйтүем әле, 107 каттан карап торганда алар коңгыз-кырмыска кебек кыймылдашалар. Утырып барганда исә майда йөзгәндәй тып-тыныч барасың — арбаларымы яхшы, йөртүчеләреме, юлларымы, әллә һәммәсеме?

Бу юлда миңа 7 тапкыр самолетка менәргә туры килде. Туктап кына үтүләрне санасаң, өч-дүрт дистәгә якын экипаж, стюардлар алмашынды. Америка эчендә кара һәм ак тәнле стюард егет-кызлар һәммәсе ягымлы, игътибарлы, һәр күз карашыңны тотып алырга әзер торалар. Үзара мөнәсәбәтләре дә сөйкемле, кыяфәтләре эшлекле. Тел белмәүчене, кызганып диярлек, тиешле урынга озатып куялар, каршы алучыны очратсалар, тәмам шатланып, саубуллашып китәләр.

«Шереметьево-2»дә исә безнең стюард егетнең «Хуш киләсез тәмәке тартучылар салонына!» — дигән сүзен ишетүгә, шаяртамы, дип туктабрак та калганмын. «Мин тартмау түгел, төтененә дә түзә алмыйм аның», — димәкче идем дә, игътибар җәлеп иттерү бәхетенә ирешә алмадым. Мондый үтәли багып та күрми торган, буш, тозсыз караш булдыру өчен нинди мәктәп узарга кирәк икән?!

Вашингтон, Детройт, Мәдисон аэропортларында тып-тын. Тышта бер күтәрелә, бер төшә торган очкычларның ник бер гөрелдәгән тавышы ишетелсен. Эчтә әкрен генә музыка уйнап тора. «Аккош күле» дә, Моцарт, Бетховенның иң популяр әсәрләре дә ишетелеп кала. Ә гомумән үзебездә туйдырган шакылдавык рок-шоклар, карлыккан тавыш белән чит телдә акыруларны бер тапкыр ни ТВ, ни урам музыкантларыннан ишетмәдем. Ниндидер моңлы, хәтта безнекенә якын американ музыкасын магнитофонга шактый язып алдым. Ишекләр кеше килүгә бер метр кала үзләре ачыла, үзләре ябы-

ла. Иданнәрдә — паласлар. Ни чират, ни бездәге кебек, автобусларга төялеп-ме, җәяүме аэродром аша самолетыңны эзләп йөрү юк. Ул аэропорт стенасына ук береге тора, пассажирларын алып, тавышсыз гына очып китә.

Мин самолетларны, гомумән, яратмыйм: дерелдәтә, һава чокырларына төшеп китәсең, колаклар тона. Монда болар кечкенә дигән очкычларда да берсе-бер юк, укып, йоклап, ашап-эчеп барасың. Хәтта Мәскәүдән иртәнге сигездә чыгып, Вашингтонда көндезге бергә килеп җиткәч, җиде сәгать артка «кайту» кыенлыгы да сизелмәде. Аның каравы ул ун сәгатьлек юл кайтышлый бер тәүлеккә әйләнде, Нью-Йорктан кич чыгып, икенче кич кенә Мәскәүдә булдык. Шул вакыт аермасына һич күнегә алмыйча, ике атна буе көнгә икешәр генә сәгать йоклап йөрдем. АКШта мин төнге сәгать өчтә уянып (бездәгечә иртәнге ун), телевизордан 7-8 программа карап чыга торган булдым. Бер каналда гел бөтендөнья рухани музыкасы уйнап тора, бик ошый ул миңа, кытайның да, финнның да, чиркәүнең дә, мәчетнең дә рухани көйләре күңелне тынычландыручан.

Бер төнне «Эмейзиң дискаверал» (кызыклы ачышлар) дигән тапшыруга юлыктым. Ир-ат пешекчеләр залдагы бер төркем хатын-кызга төрле ашамлыклар пешерергә өйрәтеп, ашатып, китапларын күрсәтеп, телефоннарын биреп, бәясен әйтеп торалар. Тутырган тавыгыбыз килеп чыкмасынмы?! Шешәгә охшаш тимер каркаска утыртып, тиресен җай гына ачып, ни дә булса тутыралар (бездәгечә йомырка гына түгел), берничә минутка компьютерлы мичләренә тыгып, өлгертеп алалар. Кызарган, күркәдәй зурайган матур тавыкны кискәләп татараталар. Ашап караучы ханымнар гаҗәпләнәләр, мактыйлар, сорашалар. Ул турыда язылган китаплар, каян алырга мөмкин булган урыннарның телефоннары, ахырдан: «Бары фәлән доллар гына!» — дигән язулар калка.

Шул компьютерлы мичкә тыгып, дүрт-биш минутта өчпочмак өлгерткәч, «Әллә безнең китаплардан алганнармы?» — дип тә уйлап куйдым. Мичкә куела торган таба дүрт кырлы һәм алты өчпочмакка бүленеп куелган. Шуларга сыек кына камыр коялар, эчлеген салалар, өстән тагы камыр. Пешеп чыккач күрәсең — чын өчпочмак!

Язмамны татар дөньясына хас бер хәл белән тәмамлыйм. Китәр алдыннан, бүләккә нәрсә алыйм, дип Казан кибетләренә сугылгалаганда, Арча читекләренең яңартылган һәм йөз сумга кыйммәтләнгән партиясенә очрадым. Бик уңайлы һәм милли дә булгач, үземә дә, бүләккә дә алдым. Үземнекен Мәскәү урамында ук бер пензалы татар хатыны очрап, инәлеп, сатуымны сорады. Салып калдырмаган идем, Мэдисонда кыргыз рәссамы Юинара югослав итегенә алыштырды һәм тагы табып җибәрүемне үтенде. Арча фабрикасы, минемчә, күптән ул заказларга күмелеп калгандыр. Әле бу сәнгать әсәре диярлек малыбызның дөнья базарын яулыйсы бар. Амин!

Мин шул читекләрне киеп Мэдисонга килеп төшкәч, каршы алучым аягыма төртеп күрсәтеп: «Сән Флорамы?» — дип сорап тора. «Әйе. Сез кем?» «Мин Кемаль Карпат». Татар кешесе икәнемне читектән тануыннан бигрәк, Ассоциация президенты үзе каршы алуына ничектер күңелләр дә тула язган иде. Соңыннан аңладым: ул нинди дә булса элитарлыкмы, миллилекме, туган-тумачалыкмы протоколын үтәү йөзеннән яисә билгеле бер галиҗәнаб әһелне озату-каршылау йолаларын башкару түгел. Бу — культура, кунакчыллык, инде бездә онытыла, юкка чыга башлаган шәфкатьлелек, җаваплылык, эшчәнлек һәм эшне оештыра белүнең чагылышы. Һәр эшне җиренә җиткереп, тәм табып, камил итеп эшләмәүне, ялкаулык дигән нәрсәне алар фәһем дә итә алмыйлар сыман. Һәрхәлдә, эшкә салкын караш — мөхаль-мөмкин булмаган нәрсә, зур бер язык, дип карау тумыштан сеңдерелә. Балалар мәктәптә яхшы укымауны, вузда укыганда кая да булса эшләмичә укуны башларына да китермәгән кебек үк, укып чыккач эшендә, кешеләр арасында якты мөгамәлә, иҗади хезмәт белән камиллеккә омтылып эшлиләр.

**Радик Сибәгат**

# БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ТЕЛЕ

I

«Башкортстан» газетасы күптән түгел үзенең укучылары алдына: «Ни өчен татар халкының кайсыбер вәкилләре башкорт теленә, язмасына каршы чыга?» — дигән сорау куйды.

«Татарларның каршы чыгуы» мәсьәләсе газетада беренче тапкыр гына кузгатылмый. Мондый «гаепләү материаллары» очрау белән, башка шундый уй килә: әгәр татарлар тарафыннан чыннан да хилафлык эшләнгән икән, безгә бик житди уйлашырга, сөйләшергә, нәтиҗәләр ясарга кирәк. Максат дуслык, туганлык мөнәсәбәтләрен киләчәктә дә саклаудан, яңартудан торырга тиеш.

Мәкалә авторлары «татар»ларның каршы чыгуын» ничек дәлилли соң? Р. Насыйров «Дусларыңның исемен әйт» дигән гомуми баш астында басылган берничә мәкаләсендә (1989, X, 13, 14, 15) үзара мөнәсәбәт мәсьәләсенең күптән килеп чыгуы турында яза. Ул аны 1918 елда Татар-Башкорт республикасы төзү белән бәйле вакыйгаларга хәлиткеч йогынты ясаган мәсьәлә итеп куя. Бер республика булып берләшү юлында булган төп каршылык татар эшлеклеләренең башкортларны аерым бер халык итеп танымауларына кайтарып калдырыла. Автор шушы каршылыклы көрәш тарафдарлары итеп Үзәк мөселман комиссариаты председателенең урынбасарлары — татар әдибе Галимҗан Ибраһимов белән башкорт эшлеклесе Шәриф Манатовны ала. Комиссариатның Татар-Башкорт республикасы төзү турындагы декретка кул куелганнан соң үткәрелгән бер утырышында Шәриф Манатов, үзенең элекке позициясен үзгәртеп, мондый республика төзүгә каршы чыга. Рәүф Насыйров менә шуның сәбәпләренә төшенергә тырыша һәм үзенчә бер «ачыш» та ясап куя. Утырышта катнашучыларның кайберләре: «Башкортлар — шул ук татарлар, тик телләрендә генә чак-чак аерма бар», — диләр. Монда ачыктан-ачык Галимҗан Ибраһимов күздә тотыла. Болай дип раслау өчен авторның фактлары юк (стенограмма файдаланылмый). Шулай да ул әлеге фикергә кат-кат әйләнеп кайта. Икенче урында, мәсәлән, буржуаз милләтчеләрнең татар теле белән башкорт теле арасындагы аерманы инкарь итүе тәнкыйтьләнә. Һәм, шуңа өстәп, газета: «Үкенечкә бу караштан Г. Ибраһимов та ерак тормый» — дип яза. Ары таба, ниһаять, газета үзенең гаепләү сүзләрен тәмам «көченә кертә»: «Татар-Башкорт республикасын төзергәме-юкмы дигән бәхәснең шаукымы озакка сузыла... Г. Ибраһимов белән Ш. Манатов та үзара дошманга әверелә. Монда төп сәбәп — беренчесенең «башкортлар — шул ук татарлар алар» дип исәпләвендә, аерым башкорт автономиясен булдыру бердәм төрек-татар милләте берләшмәсен төзүгә каршы килә дип уйлавында», — дип яза.

Шуның белән газетада «мәсьәлә» куелды булып чыга. Инде аны ныграк торып куерта башларга була. Һәм менә Салават Галин килеп чыккан мөмкинлекне кулдан ычкындырмаска тырыша. «Хакыйкатькә хыянәт итмик» дигән мәкаләсендә ул һичбер икеләнү әсәре күрсәтмичә: «Аерым татар эшлеклеләренең башкорт халкына, аның теленә каршы чыгыш ясавы совет властеның беренче көннәреннән үк килә», — дип язды («Башкортстан», 1990, X, 5).

Автор әзләнгән, ул мөселман комиссариатының башкорт шөгъбәсе мөдире Хәбибулла Габитовның архивта яткан хатын тапкан. Х. Габитов башкорт матбугатын оештыру өчен, В. И. Ленинга кереп, бер миллион сум акча соравы турында яза. Ленин мәсьәләне карауны Сталинга тапшыра.

---

Радик СИБӘГАТ (1934) — *филология фәннәре докторы, профессор, Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире. Уфада яши.*

Комиссариат утырышы җыела. Утырышта: башкорт теле татар теленнән аерыламы, башкортлар өчен аерым язма булдыру кирәкме, дигән мәсьәлә тикшерелә. Шәриф Манатов башкорт теленең үзаллы тел булуы турында сөйли. Мулланур Вахитов белән Галимҗан Ибраһимов, имештер, бу фикергә каршы чыгалар. (Хатның эчтәлеге өстәмә материаллар белән ныгытылмый, монда да стенограмма, беркетмә кебек документлар файдалану юк). Шушы хатка таянып, мәкалә авторы фараз итә: «Мулланур Вахитов белән Галимҗан Ибраһимов 1918 елда ук В. И. Ленин янына кереп: «Башкорт теленең татар теленнән аермасы юк, башкортлар татарча һәйбәт укый, телне яхшы аңлый, башкортлар өчен язма кирәкми»,— дип йөргәннәр».

Болар бары да бик җитди гаепләү сүзләре. Аларны, үз өстенә җаваплылык алып, газетада бастырып чыгару җиңел булмаска тиеш кебек. Ләкин «Башкортстан» авторлары «җиде үлчә, бер кис» кагыйдәсе буенча эш итми. Имеш, шулай булган икән, имеш, болай булган икән, дип хәбәр тараталар. Ярар, мәсьәләнең фактик ягын тарихчылар ачыклар. Без хәзергә Галимҗан Ибраһимовның гыйльми, публицистик хезмәтләренә таяна алабыз. Анда аның татар-башкорт мәсьәләсенә карашы шактый киң яктыртылган һәм кардәшлек мөнәсәбәтләре өстенә күләгә булып төшәрлек бернәрсә дә юк.

Галимҗан Ибраһимов БАССРны төзүгә ничек карый соң? Бу турыда аның «Зур Башкортстан» мәсьәләсе» дигән махсус мәкаләсе бар. Ул анда Татар-Башкорт республикасы идеясенең барып чыкмавын һич тә «тел бәхәсе» белән бәйләми. Бу идеяне тормышка ашыру өчен ул чакта шартлар җитмәве (гражданнар сугышы) белән аңлата. Инде башкортларның үзаллы автономия алуына килгәндә, ул аны тулысынча хуплый. Мәкаләдә болай диелә: «Татар җөмһүрияте аерым төзелде. Ул Агыйдел, Җәнүби Урал туфракларына чаклы җәелүне уйламый. Шулай ук Башкортстанны кайчан да булса көчләп үзенә кушу кебек ахмак хыяллардан татар эшче һәм крестиән гаммәсе бик ерак тора».

Г. Ибраһимов Башкортстанның башкаласын «сәнгатьнең, техниканың җиле-яңгыры ирешми торган» Темәс авылыннан Уфага, революцион көчләргә бай булган шәһәргә, тимер юл буена күчерүне ихлас тәбрикли. Ул Зәки Вәлидинең җөмһүрият мәркәзен «тау эчендә» урнаштыруын «борынгы төрек кабиләләренең теләсә кайда тирмә корып пайтәхет ясавы» сыман күрә. «Хәзерге вакытта, җөмһүриятнең чиген киңәйтеп, Уфага күчәргә омтылулары,— дип яза ул...— киң тормышка чыгарга теләүләре дигән сүздер. Буны шулай аңларга кирәк».

Галимҗан Ибраһимовның телләргә карашы үзенә бер теоретик тәгълимат хәлендә. Анда, әлбәттә, бөтен нәрсә дә хәзерге «стандартларга» туры килеп тормый. Шулай булуы гаҗәп тә түгел. Бу чорда әле төрки телләрне гыйльми эшкәртү башланып кына ята. Бигрәк тә үзара мөнәсәбәтләрне билгеләү мәсьәләсе катлаулы: телләр, диалектларны аеру авыр була. Гыйльми, публицистик иҗатының башлангыч чорында Г. Ибраһимов төркиләргә карата «халык», «милләт», «тел» төшенчәләре кулланмый диярлек. Аның хезмәтләрендә егерменче елларга чаклы «кабилә», «шивә» терминнары өстенлек ала. Ул төрле төрки төркемнәрнең бер дәүләт эчендә яшәү аркасында үзара якынаюларын, «матди тормышта да, идеологиядә дә бер җәмәгать, бер коллектив булып» оеша башлауларын күрә. «Мишәрләр, типтәрләр, касыйм татарлары, Себер төмәннәре, Уфа алатырлары, Әстерхан нугайлары менә шушы җәмәгатьнең әгъзалары иде»,— дип яза галим. Ул моңа: «Бу алтыга, җиденче буларак, башкортлар да керәләр иде»,— дип өсти. Казан татарлары (сигезенче төркем) башкаларны үз тирәсенә җыючы, берләштерүче үзәк ролен уйный. Язма тел, әдәбият, мәдәният җәһәтеннән моны инкарь итеп булмый. Бу — тарихи чынбарлык.

Шулай итеп, 1917 елгача Идел буе, Урал, Көнбатыш Себер төркиләренең бербөтен әдәби-мәдәни хәрәкәте, уртак әдәби теле яшәп килә. Башкортлар да, башкалар белән бергә, шушы хәрәкәткә хезмәт итәләр, уртак әдәби телдән файдаланалар. Андый тел хезмәтен башта Идел-Урал төркие, соңрак иске татар әдәби теле үти. Бу беркемгә дә көчләп тагылган нәрсә түгел. Галимҗан Ибраһимовның язуынча, «бөтен хәят боларны шуңа әзерләгән». «Бу табигый хәрәкәт иде»,— ди ул.

Революциядән соң, автономиячелек хәрәкәте белән бәйләнештә башкорт әдәби телен булдыру мәсьәләсе кузгатыла. Г. Ибраһимов 1923 елда «Әдәби тел мәсьәләсе яңадан күтәрелә» дигән мәкаләсендә болай яза: «Әдәби телебез эчендә сигез кабилә саный идек. Башкорт бу сигез эчендә иң кадерлесе иде. Чөнки без, язучылар, аның музыкасыннан, җырыннан, саф шивәсендән бик күп хәзинә, илһам ала идек. Башкортның аерылып чыгуы безнең телнең, әдәбиятның бик зур чишмәләрендән берсен икенче якка борып җибәрәчәк. Бу безнең әдәбиятка югалту булачак. Шуңа күрә

бу — безгә, татар әдипләренә, бик авыр бер мәсьәлә. Ләкин, егетләр, ничаклы авыр булса да, ничаклы ачы булса да, без моңа игътираз кылырга һичбер төрле хаклы түгелбез. Теләсә матбугат аркылы, теләсә аппарат аркылы һичбер кемнең, һичбер мишәрнең, татар яки типтәрнең моңа каршы төшүе мөмкин түгел». Бу фикерне ул кат-кат әйтә: «Безгә башкортларның бу хәрәкәтенә — аерым тел-әдәбият тудыру дәртенә каршы төшү фикереннән ваз кичү лазем».

Мәсьәләне болай куюя өчен сәбәп бар. Г. Ибраһимов татарның «Милли идарә» тирәсенә җыелган «ахмак сәясиләре», алар артыннан барган милләтче зыялылары арасында башкорт телен гамәлгә куюга каршылык булуын белә, шуңа борчыла: «татар тарафыннан аз гына каршы тору сизелсә, башкортларда милли фанатизм көчәячәк, алар йөрәкләрендә дошманлык асраячаклар»,— дип искәртә.

Шул ук елны И. Биишев һаман да әле аңлашмау барлыгы турында язып чыккач, Г. Ибраһимов мәсьәләгә яңадан әйләнеп кайта. «Мәсьәләне өзәргә вакыт» дигән мәкаләсендә: башкорт язмасы, башкорт әдәби теле булдыруга «каршы тормау гына түгел, моңа ярдәм итәргә кирәк», ди.

Инде Г. Ибраһимовның тел турындагы гыйльми карашларына килгәндә, шуны әйтергә була. Аның тел белән шивә мөнәсәбәтен үзенчә аңлавы, бүгенге карашка, сәер. Башкорт телен «шивә» дип атавы тагын да сәеррәк. Тик моны һич кенә дә башкорт телен бәяләп җиткермәү, аңа тискәре мөнәсәбәт чагылышы итеп карарга ярамый. Галимҗан Ибраһимов хезмәтләрендә, әлеге тәгъбир белән бергә, «әзәрбайҗан шивәсе», «казакъ шивәсе» тәгъбирләре дә очрый. Моның чыганагын да ерак эзлисе түгел.

Галимҗан Ибраһимовка Россия империясе Фәннәр академиясе дәрәҗәсендә рәсмиләшкән төшенчәләрнең йогынты ясавын тоярга була. Рус ориенталистлары лингвистик, этнографик хезмәтләрендә төрки халыкларны һәм аларның телләрен үзләренчә төркемлиләр. Еш кына шулай килеп чыга: татарлар — бербөтен халык, ә башка төркиләр — татарның бер өлеше, тармагы. Татар сүзе монда хәзерге мәгънәсендә түгел, ә «барлык төркиләр» мәгънәсендә аңлашыла. Шул ук вакытта татар теленә карата тел, ә башка төрки телләргә карата шивә атамасы кулланыла. Бу күзлектән казан татарлары теле дә «тел» түгел, шивә. (Г. Ибраһимовта «татар шивәсе» дигән тәгъбир шулай ук очрый). Шулай итеп, Рәсәй дәүләтенең рәсми фәнендә «татар теленең башкорт шивәсе» кебек атамалар гадәттәге бер хәл була.

Тарихтан мәгълүм, төрки халыкларның телләрен азмы-күпме эзлекле өйрәнү Екатерина II заманында башлана. Аның әмере белән академик П. С. Паллас телләрнең һәм шивәләрнең чагыштырма сүзлеген төзергә керешә. Аның беренче кисәкләре (Европа һәм Азия телләре) 1787—1789 елларда дөнья күрә, башкорт теле буенча материалны Иоган Готлиб Георги әзерли. Монда «башкорт кабиләсенең татар теленнән» 285 сүз кертелә. Сүзлекне төзүче, башкорт теленә бәя биреп, «шул ук татар шивәсе», ләкин «Казан татарларыныкына бер дә охшамаган», ди Академик В. В. Радлов «Төньяк төрки телләрнең фонетикасы» дигән хезмәтендә (1883), башкорт теленә дә беркадәр тукталып, аны «татар теленең бер диалекты яки сөйләше» дип атый. Ә башкортларның үзләрен «рус татарлары» дигән төркемгә кертә. Алай гына да түгел, башкортларның үз араларыннан чыккан Мирсалих Бикчурин да гарәп, фарсы, татар телләрен өйрәнүчеләр өчен чыгарган кулланмасында (1869) «башкорт шивәсе»нә бер бүлек бирә, шушы «шивәдән» кечкенәрәк сүзлек китерә. Башкорт телен шивә, диалект дип карау рус ориенталистикасында гына түгел, Идел буе, Урал матбугатында, хәтта башкорт тел белемендә Г. Ибраһимов заманына кадәр урын алып килә. Менә 1924, 1926 елларда «Белем», «Башкорт аймагы» журналларында басылган мәкаләләр: «Башкорт шивәсендә язу, сөйләшү өчен белергә тиешле булган төп кагыйдәләр», «Башкорт шивәсенең фонетикасы тәнгәлендә тезислар». Боларның авторы — башкорт теленең беренче дәреслекләрен язган Габделәхәт Вилданов.

Күренүенчә, Г. Ибраһимов «татар һәм башкорт телләре» мәсьәләсен үзенчә генә хәл итми. Монда, һичшиксез, үз заманының рәсми фәненә, иҗтимагый фикер юнәлешенә иярү бар.

Бу турыда чаң сукмыйча, тавыш күтәрмичә, бик тыныч сөйләшергә кирәк. «Башкортстан» газетасында мәкалә бастырган авторлар — гыйлем иясе кешеләр. Аларга мәгълүм булырга тиеш: үткән заман шәхесләрен тарихи шартлардан аерып карарга ярамый.

Бу чорда татар теле — борын заманнан язмасы, күп гасырлык әдәби традицияләре булган тел. Татар әдәби телен башка төрки телләрдән аера торган төп тексик, фонетик грамматик нормалар XVI гасырда — Казан хан-

лыгы чорында ук барлыкка килә. Башкорт теле үзе турында бик күпкә соңлабрак белдерә башлый. Бу телнең әдәби формасы XX гасырның 30 елларына кадәр бердәм нормага салынып җитә алмый. Ул татар әдәби теле йогынтысында кала. Монда шунысы бигрәк тә игътибарга лаек: башкорт теленең академик грамматикасында (Мәскәү, 1981) әйтелгәнчә, татар йогынтысы шулкадәр тирән һәм көчле була ки, башкорт зыялылары тиз генә читләшүне дә мөмкин эш дип исәпләми. Г. Ибраһимовның ике туган-даш халык, ике кардәш тел арасындагы мөнәсәбәтләргә кагылышлы сүзләре менә шундый шартларда әйтелгән.

Без Галимҗан Ибраһимовны башкорт әдәбияты, башкорт әдәби теле турында ихлас хәстәрлек күргән эшлеклеләрнең берсе дип беләбез. Менә Шәехзадә Бабич турындагы мәкаләсеннән өзекләр: «Ченәкәй иптәш Бабичның кадерле мирасларын җыярга тотынган... 1921 елның җәендә мәрхүм шагыйрьнең моңарчы җыела алган һәммә нәрсәсен Башкортстан хөкүмәте миңа җибәрткән иде... Хәзер менә «Бабич шигырьләре» мәҗмугасыннан беренче китапны дәүләт нәшриятына тапшырам».

Инде Г. Ибраһимовның Бабич иҗаты турындагы фикерләре: «Иң күп, иң кыйммәтле әсәрләрен саф әдәби татарчаның матуры вә садәсе белән язды... Бу мәҗмугадагы барча кыска шигырьләре һәм «Газазил», «Китабеннас», «Исемнәр бакчасы» моңа мисал булалар. Кызу революция дулкыннары вакытында Җәнүби Уралда, Сакмар, Җаек, Ашказар буйларында эшләгәнгә күрә, ...шулар язмышын уртаклашкан көннәрендә язылганнары тау эче башкортларының иң садә һәм саф эслүбе белән чыктылар. Бу мәҗмугада «Без ник кызылларга кушылдык?» дигән хитабы, ...без шигыре һәм әле басылмаган, кулга кермәгән байтак нәрсәләре менә шул җөмләдән».

Шагыйрьнең болай ике телдә язуына Г. Ибраһимов ничек карый соң? Ш. Бабич өчен монда бернинди проблема булмаган кебек, Г. Ибраһимов өчен дә кыенлык юк. Ул моны табигый бер нәрсә итеп кабул итә. «Шагыйрь өчен боларның һичбере,— дип яза ул,— ясалмадан, үзен көчләүдән туган хәлләр түгел, бәлки тарихның зур вакыйгалары вакытында кайсы халыкның җәмгыяте эчендә булса, кайсы кабиләнең язмышына тәэсир итәргә теләсә, ...шул кабиләгә (татарга, башкортка) мәшәкатьсез аңланачак телне үзенең уйларын, тойгыларын аңлатырга корал итте».

Менә шундый заман, шундый гамәлләр, шундый бәяләр.

Ниһаять, Г. Ибраһимовның «төрек-татар берләшмәсенә» карашы турында. «Башкортстан» газетасында шундыйрак сүзләр дә бар. Ул заманда, чыннан да, төрле төрки халыкларны «бер тел, бер әдәбият астына җыяргамы, яки һәр җирнең үзенә бер әдәбияты булу мәҗбүриятен икърар итәргәме» дигән мәсьәлә кызу тикшерелә. Исмәгыйль Гаспринский «бер лисанда» язылган гомуми бер әдәбият булдыруны яклый. Г. Ибраһимовның бу мәсьәләгә ап-ачык һәм реаль карашы революциягә кадәр үк формалашып җиткән була. 1916 елда язган бер мәкаләсендә ул әлеге уртак тел, уртак әдәбият идеясен буш хыял итеп карый. «Хәят бу халыклар яшәгән туфракта биш яки алты төрле әдәбият тудыру белән җавап бирде»,— ди Г. Ибраһимов. Үз заманында инде госманлы төрек, әзәрбайҗан, татар, казакъ һәм башка кайбер халыкларның аерым әдәби тел, аерым әдәбият булдырулары раслый.

«Башкортстан» газетасындагы мәкаләләрне укыгач, миндә шундый икеләнү торып калды: нәрсә бу, сенсация эзләүме, юкны бар итеп, «Менә без нинди ачыш ясадык!» — дип шапырынырга тырышумы? Әллә монда башка берәр нәрсә бармы?

Бүрәнә аша бүре күрү — үткән заман чире. Безгә аңардан арынырга вакыт.

## II

Безнең туган телебез — татар телеме, әллә башкорт теленең көнбатыш шивәсеме? Беренче карашка, сәер сорау бу. Кеше үзенең нинди телдә сөйләшкәнен белмимени. Шулай да республиканың көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш районнарында яшәүче халык, бигрәк тә интеллигенция, аптырап калган. Башкортча матбугат, радио, телевидение аларга: «Сезнең телегез — башкорт теленең бер диалекты»,— дип кабатлап тора. Бу якларга һәртөрле гыйлем ияләренең вәкилләре чыгып йөри. Алар да шул ук сүзләрне сөйли. Боларга кушылып китүчеләр дә юк түгел. Ләкин халыкның зур күпчелеге: «Юк, безнең туган телебез — татар теле. Без үзебез дә татар»,— ди.

Шулай итеп, фикерләр аерыла. Хәзерге хәлдән башкорт туганнар да, безнең татарлар да канәгать түгел. Ары таба безгә ничектер аңлашырга, бер уртак фикергә килергә кирәклеге көн кебек ачык. Монда иң мөһиме — бер-береңнең дәлилләренә мөмкин кадәр игътибарлы булу.

«Башкортстанның төньяк-көнбатышында башкорт балаларына туган тел өйрәтү проблемалары» (1990) дигән җыентыкта республика күләмендә үткәрелгән фәнни-практик конференция материаллары тупланган. Андагы кайбер чыгышларның эчтәлеге белән танышыйк.

Тарихчы Әнвәр Әсфәндияров: XVIII—XIX йөзләрдә булган ревизия материалларына караганда, Агыйдел, Ык буйлары башкорт биләмәләре булган. (Бәләбәй, Бөре, Минзәлә, Бөгелмә өязләре күздә тотыла). Бу якка татарлар Иван Грозный Казанны алганнан соң күченә башлаган. Тоташ башкорт авыллары белән бергә, катнаш авыллар барлыкка килгән. Кайбер урыннарда татарлар күпчелек ала башлаган. Этник ассимиляция өчен шартлар туган.

Тарихчы Марат Колшәрипов: Башкортстанның төньяк-көнбатышында башкортларның татарлашуы диния нәзарәте эшчәнлеге белән дә бәйләнгән. Патша хөкүмәте мөфтиләрне аңлы рәвештә татарлардан куйган. Муллалар татар булган. Мәдрәсәләрдә укыту татарча алып барылган. Шуның аркасында халык, башкорт телен ташлап, татар теленә күчә башлаган.

Тел галиме Нәҗибә Максютова: Революциядән соң, 20 нче елларда, Төньяк-Көнбатыш Башкортстанда укыту телен билгеләгәндә зур гаделсезлек җибәрелгән. Махсус гыйльми экспедиция: мондагы башкорт сөйләшләре татар әдәби теленә якынрак, дигән нәтиҗә ясаган. Укыту татар телендә оештырылган. Бу хәл башкортларның татарлашуын көчәйткән.

Конференциядә чыгып сөйләүчеләр: төньяк-көнбатыш башкортларын ассимиляцияләү дәвам итә, дигән караш белдерделәр. Моны «күрелмәгән экспанция политикасы» дип бәяләделәр. «Без бу халыкның милли үзаңын саклап кала алабызмы-юкмы?» — дигән сорау бирделәр. Таләпләре исә тагын да катгыйрак иде.

Зур бер регионда башкортлар татарлашкан икән, димәк, аларга үз милләтенә кире кайту өчен шартлар тудырылырга тиеш, диләр алар. Ягъни татар мәктәпләрен яңадан башкортча укытуга күчерү мәсьәләсен күтәреп чыгалар. Тел галиме Сәрия Миржанова Төньяк-Көнбатыш Башкортстанга башкорт телен ике юл белән кертеп була дип исәпли:

«Беренче юл. Башкорт әдәби телен кертү. Моның өчен без республика (Югары совет) җитәкчеләрен ничек булса да күндерергә тиешбез. Һәрхәлдә, район җитәкчеләре безгә йөз белән торырга тиеш, ярдәм итәргә тиеш. Шунсыз бу политиканы үткәреп булмый.

Икенче юл. Төньяк-Көнбатыш башкорт әдәби телен ясау... Бу башкорт әдәби телендә тик ч һәм һ авазлары гына булмаячак. Фонетика, грамматикасын бик нык уйлап, кайсыбер диалект формаларын алып эшкәртергә мөмкин булыр иде. Шулай эшләсәк, башкорт теле отар иде».

Укыту методикасы белгече Мөсәлия Хәйруллина, асылда, шушы икенче юлны яклый. Аның фикеренчә, Төньяк-Көнбатыш Башкортстан мәктәпләре өчен Казан дәреслекләре ярамый. Уфада махсус дәреслекләр бастырып чыгарырга кирәк. Бу грамматика дәреслеге түгел, «актив коммуникация» (чынында: җирле сөйләм, диалект) дәреслеге булырга тиеш!

Татар ягы үзенең фикерен ничек нигезли? Монда шуны әйтергә кирәк: Татарстан галимнәре заманында бу як сөйләшләрен татар теленең урта диалектына кертә. Ләкин хәзерге ыгы-зыгыдан читтәрәк торалар, бәхәскә катнашмыйлар. Уфада эшләүче татар филологлары да битарафлык саклый. Моның сәбәбен төрлечә аңлатырга була. Берәүләр, күрәсең, бәхәсне көчәйтергә теләми, ыгы-зыгы булыр да бетәр, тормыш үз юлы белән барыр дип уйлый. Ә икенчеләр, гомумән, монда җитди фәнни-теоретик дискуссия өчен предмет юк дип исәпли булса кирәк. Һәрхәлдә, хәзергә оппонентлар булып «Кызыл таң»ның укучылары — ата-аналар, ветераннар, мәдәният хезмәткәрләре, укытучылар чыгыш ясый. Бер-ике мисал да китерик («Кызыл таң», 1989.V.28)

Илеш районыннан Роберт Харисов: «Гаиләдә дүрт бала идек. Икебез үзебезне татар, икебез башкорт дип йөри. Чөнки паспорт биргәндә шулай дип язганнар, сорап та тормаганнар».

Краснокама районыннан Мөхәммәт Шакирҗанов: «Без башкорт булырга тырышып карадык. Үзем дә башкорт булырга өндәдем. Тик ни башкорт булып булмады, ни туган телебезне камиллектә белмәдек».

Октябрьский шәһәреннән Фәхирә Заһидуллина: «Туган тел урынына башкорт теле өйрәнелергә тиеш дигән сүз кайда язылган? Безнең балалар-

ның татар телен — үз туган телен өйрәнергә хакы юкмыни? Бу хәлне ничек аңларга? Милли мәсьәләне дөрес хәл итү шулай буламы?..»

Күрәсез, мәсьәлә кискен тора. Ул үзенең асылы белән башкорт теленең көнбатыш диалекты дигән теоретик концепцияне тану-танымауга кайтып кала. Башкорт галимнәре үз сүзләрен сүз итәргә тырыша, ә җирле халык алар белән килешми. Бу инде теория авыр хәлдә дигән сүз. Монда, димәк, нидер җитми, нәрсәдер үз урынында түгел. Мондый чакта фәнни теорияне яңабаштан карап чыгалар. Мин бу эшне тулысынча башкарып чыга алырмын дип уйламыйм. Шулай да кайбер анализ белән шөгыльләнәсе килә.

Башкорт теле диалектлары турындагы беренче фикерләр революциягә кадәр үк әйтелгән. Башкорт ягына килеп йөргән рус ориенталистлары монда ике диалект бар дип исәпләгән. Академик В. В. Радлов белән лингвист, этнограф А. Г. Бессонов аларның берсен Кувакан сөйләше, ә икенчесе Юрматы сөйләше дип атаганнар. Хәзер боларны көнчыгыш (тау ягы) диалекты һәм көньяк (дала ягы) диалекты дип йөртәләр. Мондый бүленеш безнең чорга — 40 нчы елларга кадәр үзгәрешсез кала. Шушы вакыттан алып кайбер дәреслекләрдә (авторлары Т. Г. Баишев, К. З. Әхмәров, Ә. И. Харисов) өченче диалект турында сүз кузгатыла башлый. Моңа Көнбатыш һәм Төньяк-Көнбатыш Башкортстан сөйләшләре кертелә. Ниһаять, 1955 елда Т. Г. Баишев Мәскәүдә рус телендә чыккан монографиясендә көнбатыш диалектка карый торган тел үзенчәлекләрен дә үзенчә җентекле генә итеп тасвирлап бирә. Әлеге диалект турындагы төшенчәнең фәнгә керү тарихы менә шундый.

Т. Г. Баишев алдына моңа кадәр «татарча сөйләшәбез» дип йөргән халыкның телен башкорт диалекты дип исбатлау бурычын куйган. Бу диалектта ул тапкан үзенчәлекләр:

Күплек кушымчасы лар-ләр борын тартыкларыннан соң нар-нәр рәвешендә әйтелә (Урамнар, көннәр). Исем, сыйфат, фигыль ясый торган лык-лек, лы-ле, ла-ле кушымчалары да шулай үзгәрә (Л авазы Н гә күчә).

Иялек килеше кушымчасы ның-нең, төшем килеше кушымчасы ны-не фонетик шартларга (нинди аваздан соң килүенә) карап үзгәрми, һәрвакыт шулай Н белән әйтелә, мәсәлән: ташның, тауның, көннең: атны, малны, кемне.

Чыгыш килеше кушымчасы берничә вариантта йөри: сузыклардан һәм яңгырау тартыклардан соң дан-дән, саңгырау тартыклардан соң тан-тән, борын авазларыннан соң нан-нән, мәсәлән: авылдан, баштан, таңнан.

Башка барлык кушымчалар ике төрле әйтелә: сузыклардан һәм яңгырау тартыклардан соң яңгыраулаша, мәсәлән, юлда, таудай, янды; саңгырау тартыклардан соң саңгыраулаша, мәсәлән: якташ, таштай, кайтты.

Ярдәмлек сүзләр дә шулай охшашлана, мәсәлән, мал да тук, үзем дә тук, ат та чаба, эт тә чаба.

Т. Г. Баишевның фикеренчә, көнбатыш диалектның үзенчәлекләре шулардан тора. Нәрсә килеп чыга соң? Шундый үзенчәлекләр нигезендә башкорт теленең үзенә башка (өченче) диалекты бар дип әйтеп буламы? Болар бит, туганнар,— татар теле үзенчәлекләре! Алар бөтенесе дә хәзерге әдәби телебездә норма санала.

Башкорт диалектларын татар теленнән аера торган үзенчәлекләр бөтенләй башка. Без аларны Кувакан (көнчыгыш) һәм Юрматы (көньяк) диалектларында күрәбез. Шуннан алар башкортларның әдәби теленә дә кергән. Карап үтик.

Күплек кушымчалары: *ат-тар, таң-дар, яз-зар.*
Иялек килеше кушымчалары: *таш-тың, таң-зың, һың-зың.*
Төшем килеше кушымчалары: *ат-ты, мал-ды, без-зе.*
Чыгыш килеше кушымчалары: *баш-тан, кем-дән, өй-зән, һауа-нан.*
Башка төр кушымчалар һәм ярдәмлек сүзләр: *машина-лай, әнә-ләй, яма-ны, ире-не, ас-та ла, өстә лә.*

Көнбатыш, төньяк-көнбатыш Башкортстанда боларның берсе дә юк.

Т.Г. Баишиев башкорт теленең өченче диалекты бар дип игълан итә. Ә үзе аны татар теленнән аера (башкорт теленә карата) торган үзенчәлекләрне таба алмый. Моңа нибары бер-ике ишарә бар. Бу диалектта урыны белән ашай, эшләй, бармай, килмәй, инәй, бәбәй дип сөйлиләр (ягъни татар телендәге ый-и кушымчасы урынына ай-әй кушымчасы кулланалар), диелә. Аннары бу як телендә тешара З авазы бар дип раслана.

Шушы ике фонетик күренеш тә башкорт теленең көнбатыш диалекты дигән лингвистик концепцияне «күтәреп торырлык» түгел. Ай-әй кушымчасы тик башкорт теленә хас билге дип карарга һичбер нигез юк. Ул бөтен

төрки дөньы буйлап «сикереп йөри»: әле бер сөйләштә, әле икенчесендә килеп очрый. З авазына килгәндә, шуны әйтергә була: беренчедән, ул бөтенләй үк башкортча яңгырамый, катырак, икенчедән, сүздәге урыны белән башкорт телендәге З авазына туры килми, күбрәк Н, Л авазларына алмаш булыһ йөри. Чагыштырыйк: башкорт телендә — ашаны, эшләне, каланан, кала; көнбатыш сөйләшләрдә — ашазы, эшләзе, калазан, калаза. Монда З татар теленең Д авазын алмаштыра, яңгырашы да шуңа бик якын. Өченчедән, бу авазны чыгышы белән борынгы кыпчак теленнән килә дигән караш бар. Димәк, аны тик башкорт теленең үзе дип түгел, ә төрки бабалар мирасы дип карау дөрес. Аннары, бу аваз бөтен Көнбатыш, Төньяк-Көнбатыш Башкортстанга таралмаган, аерым төбәкләрдә генә ишетелеп кала.

Кыскасы, башкорт теленең көнбатыш диалекты турындагы концепция фәнни тәнкыйтьне күтәрми. Лингвистик планда ул нигезсез. Заманында аны башкорт телчеләре үзләре дә шулай кабул итте. Башкорт тел белеменең аксакалы, филология фәннәре докторы, профессор Ж. Г. Киекбаев бу мәсьәләгә үзенең берничә житди теоретик хезмәтендә тукталды. Ул ачыктан-ачык итеп: «Көнбатыштагы башкортларның сөйләү телен башкорт диалекты дип атаучылар фикерен без уртаклашмыйбыз», — дип язды. («Башкортстан укытыусыһы» 1975. № 7) Ж. Г. Киекбаев үзенең позициясен болай аңлата: «Башкортстанның көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш өлешендә яшәүчеләр татар телендә (татар теленең урта диалектында) сөйләшәләр», «татар телен үзләренең ана теле дип таныйлар», аларның «сөйләү теле күптән инде татарлашкан». Икенче урында: «Башкорт АССРның көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш өлешендә яшәүче башкортларның телен, ягъни сөйләшен, башкорт сөйләше дип карау тарихи яктан да, юридик яктан да (мәсәлән, официаль документларда татар телен ана теле дип танулары) һәм сөйләшнең фактик торышы ягыннан да акланмый».

Якташыбыз — СССР Фәннәр академиясенең Тел белеме институтындагы төрки телләр секторының өлкән гыйльми хезмәткәре, филология фәннәре докторы Ә. Ә. Юлдашевның да карашы шундый иде. Ул үзе Туймазы ягыннан. Башкорт теленең беренче академик грамматикасын чыгаруны оештырган кеше. Аның, мәсәлән, Туймазы башкортлары теленә багышланган мәкаләсе бар. Ул анда: бу як башкортларының сөйләмә теле татар әдәби теленә, татар теленең теләсә кайсы сөйләшенә караганда да, якынрак дип язды. Ә. Ә. Юлдашев, гомумән, Көнбатыш һәм Төньяк-Көнбатыш Башкортстан халкының жирле сөйләшләре «башкорт теле системасына керә алмый» дип исәпли. Башкорт теле өлкәсендә эшләүче башка күп кенә галимнәрнең дә фикере шундый.

Шулай булгач, «көнбатыш диалект» төшенчәсе нишләп һаман фәнни әйләнештә кала? Моның өчен нинди нигез бар? Бу катлаулы мәсьәлә. Аңлатырга тырышыйм. Тел белеме диалектларны тел үзенчәлекләренә карап бүлә. Бу төп принцип. Шуның белән бергә телдән читтә торган (экстралингвистик) факторлар да күпмедер исәпкә алына. Моңа халыкның чыгышы, этник составы, тарихы керә. Күргәнебезчә, көнбатыш диалект лингвистик принцип буенча билгеләнә алмый. Монда фәкать экстралингвистик факторлар таянычка әйләнә.

Көнбатыш һәм Төньяк-Көнбатыш Башкортстанда халыкның бер өлеше чыннан да үзен башкорт дип атый. 1989 елгы исәп буенча аларның саны күпме икәне хәзергә аерым игълан ителмәде. Якынча исәпләп чыгарырга мөмкин. Башкортларның 183,2 меңе татар телен туган теле дип яздырган. Бу халыкның төп өлеше көнбатышта һәм төньяк-көнбатышта яши дип уйларга кирәк. Татарча сөйләшүче башкортлар, соңгы исәп буенча, бигрәк тә Балтач, Бүздәк, Дүртөйле, Илеш, Краснокама, Тәтешле, Туймазы, Яңавыл районнарында күп (бөтен халыкның 20 процентыннан алып 50 процентына кадәр). Авыргазы, Бакалы, Бишбүләк, Благовар, Федоровка, Чишмә, Шаран, Ярмәкәй районнарында 5—10 процент чамасы.

Бу башкортларның килеп чыгышын фәндә ике төрле аңлаталар. Бер төркем галимнәр аларны борынгы башкорт кабиләләренең токымы итеп карый. Икенче төркем бу якта «башкорт» сүзе — этник термин (жир мәйданы) белән башкортларга тигезләшкән татарларның элекке юридик атамасы дип раслый. Беренче караш Башкортстан матбугатында, икенчесе Татарстанда яклана. Кайсы якка кушылырга? Минемчә, аларның берсе дә искәрмәсез, төзәтүсез кабул итәрлек түгел. Көнбатыш башкортлары — үтә катлаулы тарихи күренеш. Аны ниндидер вакытлы максатларга яраклаштырып, гадиләштереп аңлатырга ярамый. Бу турыда шактый тарихи тикшеренүләр бар. Арада, безнең карашка, Р. Г. Кузеев хезмәтләре аеруча игътибарга лаек.

XVI гасырда хәзерге Башкортстан чикләрендә төрле төрки кабиләләрнең консолидациясе тәмамлана. Алар, төрлесе төрле исем белән йөргән кабиләләр, шул чордан үзләрен башкорт дип атый башлаган булырга тиеш. Әмма халык бер төрле булмаган. Кабилә чикләре озак сакланып калган: Көнбатыш Башкортстанда—XVIII гасырга, көнчыгышта—XIX гасырга кадәр. Ике төбәкне кабилә составы ягыннан чагыштырганда, алар һичбер туры килми. Көнбатышта бер төрлерәк, ә көнчыгышта икенче төрлерәк этнос формалашырга тиешлеге күренеп тора. Фикерне дәлиллик. Көнбатышта болгар өлеше зур. Биш кабилә телгә алына. Аларның исемнәре дә билгеле: бүләр, юрми, янәй, гайнә, танып. Көнчыгышта болгар өлеше азрак. Бер юрматы кабиләсе атап әйтелә. Кыпчаклар көнбатышта да, көнчыгышта да бар. Ләкин көнбатышта шулай ук күбрәк килеп чыга. Гәрә, елан, казанчы, кайпан, елдәк, канлы, кыргыз, каршен—сигез кабилә, ыру. Моннан тыш кыпчаклашып киткән балыкчы, дуван, уран, таз, ирәкте кабиләләре бар. Көнчыгышта кыпчаклар болай атап саналмый диярлек. Башкорт этносының төп өлеше: бөрҗән, үсәргән, тәңгәвер, тамьян, табын, катай кабиләләре—барысы да көнчыгышта тупланган. Көнбатыш аларның вакытлыча яшәп киткән жире дип кенә исәпләнә.

Ниһаять, шуны әйтәсе килә: көнбатышта берләштерүче көч ролен кыпчак кабиләләренең үтәве таныла. Ә көнчыгышта бу хезмәтне чыгышы белән борынгы төрки-бәҗәнәкләр арасыннан булган кабиләләр (бөрҗән, үсәргән, тәңгәвер һ. б.) башкарган.

Кабиләләр составының ике төбәктә ике төрле булуы көнбатыш башкортлары белән көнчыгыш башкортлары арасында аерма китереп чыгармый булмый. Көнбатыш үзенең этник составы белән Идел буе Болгар дәүләтенә; Казан ханлыгына якын, көнчыгыш Үзәк Азия, Алтай ягына тарта. Шуны да әйтик: көнбатыш башкортлар составына кереп киткән бүләр (биләр) кабиләсе татарлар белән уртак. Булган тарихи материаллар өстендә уйлану шундый нәтиҗәгә китерә: көнбатыш башкортлары баштан ук татарларга якын булган, һәм, әлбәттә, алар көнчыгыш башкортларның татарлашуы турында сөйләгәндә, хәзерге башкортны (көнчыгыш башкортын) күз алдында тоту дөрес булмас.

Аннары, монда ассимиляция мәсьәләсе бик житди тора. Күп гасырларга сузылган демографик процесслар халыкның тарихи-этник йөзен тагын да үзгәртә. XVIII гасыр уртасында Башкортстанда халык саны 412 мең исәпләнә, шуларның 200 меңен күчеп килүчеләр тәшкил итә. XVIII гасыр азагына бөтен халык саны 740 мең, күчеп килүчеләр 470 мең була. Шулай итеп, чит халык башкортлар саныннан артып китә.

Күчеп килүчеләрнең составы чуар. Анда урыслар, угро-финнар, төрки халыклар бар. Арада татарлар күпчелек урын ала.

Татарларның башкорт жирләренә килеп урнашуы Казан ханлыгы дәвереннән үк башлана һәм Башкортстан урыс дәүләте составына кушылганнан соң аеруча көчәеп китә. XVIII гасыр урталарына кадәр төгәл саннар юк. Шуннан соң булган агымны ачык итеп күз алдына китерергә була.

Башкорт жирендә яши башлаган татарларны патша чиновниклары өч төркемгә бүлеп санаганнар: типтәрләр, мишәрләр һәм Казан татарлары. Типтәрләр белән мишәрләрнең исәбе XVIII гасыр урталарыннан ук алына барылган. Типтәрләр 1747 елда—57500, 1850 елда—261824, 1913 елда 305124 кеше була. (Хәзерге фәндә танылуынча, типтәрләрнең кимендә 90 проценты татарлар, ә калган өлеше башка халыклар дип карала). Мишәрләр турында мәгълүмат бик бай. Алар 1747 елда—10100, 1782 елда— 28772, 1795 елда—46300, 1833 елда—73615, 1856 елда—110595, 1879 елда—138900, 1913 елда 150879 була. Казан татарлары исәп кенәгәләрендә XIX гасыр урталарыннан гына аерым бирелә башлый. Аларның 1865 елда—89733, 1870 елда—101231, 1879 елда—107300, 1913 елда 210333 булганлыгы мәгълүм. Революция алдыннан Башкортстанда татарлар бөтенесе 650 меңнән артып китә.

Бу чорда Көнбатыш һәм Төньяк-Көнбатыш Башкортстанда яшәгән татарлар белән башкортлар санын чагыштырасы килә. Ләкин мондый чагыштыру белән шөгыльләнү жиңел түгел. Фәндә кабул ителгән саннар белән эш иткәндә, реаль нәтиҗә килеп чыкмый. Татарлар саны (650 мең тирәсе) чынбарлыкка туры килә дип карарга мөмкин. Ә менә көнбатыш башкортларының саны бәхәсле. 1920 елда, мәсәлән, алар 524 меңнән артык булган, диелә. Бу чорда Көнбатыш һәм Төньяк-Көнбатыш Башкортстанда татарларның башкортлардан күбрәк булганлыгы күренә. Ләкин күпмегә икәнен гади исәп белән китереп чыгарып булмый. Чөнки башкорт исәбенә йөргән халыкның да бер өлеше чынында татарлардан тора. Аларның башкортка күчүе күп төрле рәсми документлар белән расланган факт. (Бу ту-

рыда татар телчесе Д. Б. Рамазанованың махсус хезмәтләрен укырга мөмкин.) Боларны тарихта «яңа башкортлар» яки, Зәки Вәлиди әйткәнчә, «ак башкортлар» дип йөрткәннәр. Халык арасында кайвакыт һаман да: «Без әтәмбәй башкортлар гына, җир өчен башкорт булып киткәнбез»,— диләр. Монда, димәк, «башкорт» сүзе үзенең туры мәгънәсендә (этник термин буларак) алынмый. Ул үзенең социаль хәле (җир майданы, ясак шарты) белән башкортларга тиңләштерелгән татарларны атау өчен кулланылган.

Мондый халык, («яңа башкортлар») көнбатыш башкортлары арасында күпме урын алган? Р. Г. Кузеев Көнбатыш Башкортстанда башкортлар саны үсешен тикшереп, шундый бер хәлгә игътибар итә. XVIII гасыр башыннан алып XIX гасыр азакларына кадәр бу территориядә башкорт дип йөртелгән халык һәр илле ел саен 2,5—3 тапкырга арткан. Моны табигый үсеш нәтиҗәсе дип карарга нигез юк. Еллык табигый үсешнең 1,4—1,6 процент икәнлеге билгеле. Мондый темп белән 50 ел эчендә нибары 70—80 процентка артырга мөмкин. Ә монда 2,5—3 тапкыр!

Үсешнең көнчыгыш башкортлары исәбенә барганлыгы да расланмый. Бу чорда инде көнчыгыштан көнбатышка күпләп күченүләр күзәтелми. Бердәнбер аңлатма реаль булып кала: табигый булмаган үсеш башка төркиләрнең (барыннан да элек, татарларның) башкорт сословиесенә күчүе юлы белән барган. Шулай итеп, башкорт булып йөрүче татарлар, гомумән, бик зур саннар белән исәпләнергә тиеш була. Шуннан инде Көнбатыш Башкортстанда татарлар белән башкортлар арасында сан ягыннан булган арманың чынында зуррак булуы аңлашыла. Монда татарларның күпчелек алуы да үткән гасыр урталарыннан гына түгел, ераграк заманнардан килә дип уйларга кирәк.

Димәк, экстралингвистик факторлар да көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш халкының сөйләм телен башкорт диалекты дип раслау өчен ышанычлы җирлек була алмый.

Татар филологлары өчен бу — күптән хәл ителгән мәсьәлә. Әлеге төбәкләргә татар диалектологларының дистәләрчә экспедицияләре оештырылды. Җитди фәнни тикшеренүләр үткәрелде. Диссертацияләр язып якланды. Галимнәребез беравыздан: бу — татар сөйләше, диләр. Аны татар әдәби теленә нигез булган урта диалектка кертәләр.

## III

Шундый бер мәсьәлә бар — Башкортстан татарларының мәдәнияттә тоткан урыны мәсьәләсе.

Мин үзебезнең яктан чыккан әдипләр язмышы турында уйланам. Һәм, беләсезме, аларны бер дә көтелмәгән сурәттә күз алдына китерәм... Башкортстан белән Татарстан чигендә. Ык буенда, яр астына аяк салындырып утыралар... Берәүләре — бу якта, икенчеләре — теге якта. Бу яктагылар Татарстан турында хыяллана, ә теге яктагылар Башкортстанны юксына. Ләкин күперләр сүтелгән. Такыр юллар юк. Теләсәң, киемең-ниең белән суга ташлан. Йөзеп чыксаң, бәлки, күңел ярсуларың басылыр...

Татарча сөйләшүче Көнбатыш һәм Төньяк-Көнбатыш Башкортстан халкының рухи дөньясы икегә аерылган. Җире монда, җыры тегендә дигәндәй. Үзе Башкортстанда яши, мәдәнияте Татарстанда иҗат ителә. Берсен икенчесе белән ялгый алмый азаплана кешеләр.

Мине кайвакыт Казанга я берәр фәнни конференциягә, я кемнеңдер диссертациясенә оппонент итеп чакырып алалар. Барган саен Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында булам. Якташым—филология фәннәре докторы Фуат Ганиев җитәкчелек иткән бүлеккә керәм. Аның янында тагын институтның өлкән гыйльми хезмәткәрләре, филология фәннәре кандидатлары Хәлиф Курбатов белән Рифгать Әхмәтҗановны очратам. Үзебезнең яктан барып укып яткан аспирантлар килеп кушыла. Һәм без нәрсә турында сөйләшәбез, дип уйлыйсыз? Юк, фәнни бәхәсләр алып бармыйбыз. Алары — конференция өчен. Без Башкортстан турында сөйләшәбез. Ганиев кебек Курбатов белән Әхмәтҗанов та безнең яктан, Башкортстаннан. Инде күптән Казанда урнашкан кешеләр. Татарстанның күренекле галимнәре булып киткәннәр. Ләкин һәркайсы Башкортстан баласы булып калган. Аларны туган як һаман тарта. Ганиевның, мәсәлән, бер генә ай булса да Уфада, университетта, лекция укыйсы килә. Без аны үзебезнең татар бүлегенә махсус курс үткәрергә чакыру турында килешәбез.

Әйтәсе килгән сүз бер: безнең якташлар өчен Татарстанда иҗат мәйданы киң; туган тел, әдәбият, мәдәният дәрьясында колачлап йөзәргә була.

Ләкин жирсәү бетми, әлбәттә. Жирсәү—сагыну гына түгел. Үз туфрагыннан аерылу тойгысы ул. Иҗат кешесе үз табигый мохитеннән читтә тамырлары киселгәндәй буладыр кебек. Көнбатыш Башкортстан—татарлар төяге. Монда алар—өйдә. Ләкин милли мәдәният өлкәсендә эшләү мөмкинлеге чикләнгән. Китәләр...

Җирсәү дигәннән... Элекке Татарстан АССР Югары Советы Президиумы Председателе С. Батыев белән аның эш бүлмәсендә сөйләшеп утырырга туры килде. Минем белән «Кызыл таң»ның мөхәррир урынбасары Расих Ханнанов һәм мәрхүм Хәсән Сарьян бар иде. Батыев үзе Чакмагыш районыннан. Якташлар очрушуы сыман бер нәрсә килеп чыкты. «Җирсәү» сүзен мин беренче тапкыр шунда Батыевтан ишеттем. Без аңарда: «Туган якка кайтып йөрисезме соң!»—дип сорадык. Ул безгә: «Кайтам, мөмкинлек булган саен кайтам. Авылыбыз янында чыккан чишмә буенда утырып килсәм, җирсәвем басылып торгандай була»,—диде.

Рухи комфорт җитмәү—бер нәсрә. Безнең татарларга Башкортстанда иҗат итү өчен бер телдән икенче телгә күчәргә кирәк. Икенче милли мохиттә үзләшергә кирәк. Кемгәдер бу җиңел бирелә, ә кемдер булдыра алмый. Үз җирендә үзенә урын тапмый кеше. Шушы сәбәп белән республика (димәк, аның халкы) күп нәрсә югалта: менә дигән талантлар читкә китә. Менә шунысы аеруча мөһим монда. Бу турыда иң әүвәл татар җанлы кеше түгел, ә эш өчен җаваплы вазифа иясе уйларга тиеш кебек.

Шундый бер исәпләү белән шөгыльләнеп утырдым. Татарча сөйләшүче Көнбатыш һәм Төньяк-Көнбатыш Башкортстаннан бөтенесе 110 язучы чыккан. (Мин монда танылып өлгергәннәрен, һәртөрле белешмәләргә кертелгәннәрен генә алам.) Шуларның алтмышы республикада торып калган, хәзерге вакытта башкорт язучысы булып йөри. Ә илле кеше Татарстанга барып урнашкан, татар язучысы исәпләнә.

Мондый мәгълүматларны театр сәнгате, эстрада, музыка һәм мәдәниятнең башка тармакларыннан да китереп булыр иде.

Болар барысы да игътибарга лаеклы хәлләр. Татарча сөйләшүче Көнбатыш Башкортстан мәдәният җәһәтеннән икегә өзелгән: бер өлеше—Казан, икенче өлеше Уфа ягында.

Бу хәл, үз чиратында, бөтен Башкортстан мәдәниятенә үзенчәлекле бер төс бирә. Анда, без гадәттә бербөтен итеп карарга тырышкан башкорт иseme белән атап йөрткән мәдәнияттә, чынында ачык аерылып торган ике катлам бар: башкорт катламы һәм татар катламы. Бу, аңлашылуынча, тарихи шартлар белән бәйле рәвештә, ирексездән килеп туган хәл. Аны күрмәмешкә салышырга һәм хәзерге заманда ачыктан-ачык сөйләшүдән качарга ярамый. Бу мәсьәлә башкорт эшлекләләрен күптән борчый. Алар «Мондый хәлдә мәдәниятебезнең үз йөзен, милли колоритын саклап кала алырбызмы икән?»—диләр. Бик җитди һәм аңлашылырлык сорау. Әлеге шул бербөтен мәдәнияткә хезмәт иткән татар ягы да уйланмый түгел. Аның хәле, минемчә, тагын да катлаулырак. Милли мәдәнияттә ныклы урын алу өчен шул милләтнең тормыш рәвешен, гореф-гадәтләрен, психологиясен һәм, ниһаять, үзенчәлекле телен төптән белергә кирәк. Юк, белергә генә түгел, канына сеңдергән булырга кирәк. Моңа ирешү җиңел түгел. Бу юлдагы тырышлык кайвакыт яраклашу белән тәмамланырга мөмкин. Үзара мөнәсәбәттә, күренүенчә, проблемалар тулып ята. Моңа кадәр бербөтен мәдәният сакланып килгән икән, моны, барыннан да элек, административ-команда системасының каты куллылыгы белән бәйләп аңлатырга була. Соңгы чорда, демократия шартларында, Башкортстан мәдәниятенең ике тармак булып үсеп китү ихтималы арттаннан-арта бара. (Моның аерым билгеләре электән үк бар). Яхшымы бу, әллә начармы? Бер төрле генә җавап бирергә ашыкмыйк. Ике реаль кисәкне бербөтен мәдәнияткә берләштерү милләтләрнең һәм телләрнең кушылуы концепциясе күзлегеннән, әлбәттә, яхшы иде. Ләкин концепция үзенең тормышчан булмавын күрсәтте. Яңа политик ситуациядә аерымланырга, үзаллы үсеш юлына төшәргә тырышу табигый хәл. Тик монда басым ясап әйтергә кирәк: сүз хәзергә реаль процесс турында түгел, ә идея юнәлешләре, формалашып килгән иҗтимагый хәрәкәтләр турында бара. Ул хәрәкәтләрнең башында татар һәм башкорт иҗтимагый үзәкләре тора.

Гамәлдә нәрсә килеп чыга соң? Ике якның да хәле шәптән түгел. Ике як өчен ике төрле проблема туа. Милли мәдәният традицион юнәлешен (гомуми характерын) үзгәртү белән, аның йогынты, хәрәкәт мәйданы тараеп кала. Көнчыгышка һәм көньякка гына йөз тоту, үз чиратында, көнбатыштан (татарча сөйләшүчеләрдән) читләшү дигән сүз булачак: укучылар, тамашачылар, тыңлаучылар кимеп кала. Базар экономикасы шартларында мәдәнияткә финанс табу мәсьәләсе катлаулана. Ә көнбатыш, (татар ягы) аерым-

лану нәтиҗәсендә, бөтенесеннән бигрәк, мона кадәрге оешу формаларыннан мәхрүм була. Аларны яңабаштан төзү зарурлыгы алдында торып кала. Янадан башлау җиңел түгел. Монда власть кыяләренең хәлне аңлавы һәм ихлас ярдәм итүе кирәк. Ә ярдәм булыры хәзергә ачык күренеп тормый.

Ике як та үз хәленнән канәгать түгел. Үзара мөнәсәбәтләр шактый киеренкеләнә бара. Безгә бу хәлдән ничек котылу турында уйларга кирәк. Мондый чакта гадәттә: кирегә юл юк, искене үзгәртеп кору өстендә эшләргә кирәк, диләр.

Мин монда бик нечкә нәрсәләргә кагылам шикелле. Сүз чынында мәдәният мәсьәләләре турында гына түгел, шуңа хезмәт иткән кешеләр язмышы, дәрәҗәсе, аларның бүгенге һәм киләчәк статусы турында бара. Мондый мәсьәлә кузгатырга минем хакым бармы, дигән сорау туарга мөмкин. Бар дип уйлыйм. Мин татарча сөйләшүче Башкортстан вәкиле. Гомерем буе югары интеллигенция арасында яшим. Татарлар белән дә, башкортлар белән дә иркен аралашам. Хәл белән танышмын дип исәплим. Аннары, мин бернәрсәне дә уйлап чыгармыйм, бары тик булган әйберләрне исемнәре белән атыйм. Моңа кадәр «качыш уйнау» аркасында хәлне кискәнләштердек түгелме? Ярар, болар — лирик чигенү.

Ә чынбарлык шундый: республика мәдәнияте тармаклану алдында тора. Бүген иң катлаулысы — менә шуңа мөнәсәбәт мәсьәләсе. Инерция көчле. Туган анам теле — татар теле, ләкин башкорт теле — кәсебем теле генә түгел, язмышым, тормышым теле, дигән позиция бар. Аңлашыла торган, тирән ихтирамга лаеклы позиция. Ләкин плюрализм заманында без фикерләр бердәмлеген югалттык. Әлеге позицияне күпләр уртаклашмый.

Хәзерге дөньяда каршылыкларны хәл итү өчен бердәнбер юл — демократия. Минемчә, тел, әдәбият, сәнгать өлкәсендә көчләү, диктат — иң яманы. Бу юл белән мәсьәлә беркайчан да хәл ителмәгән һәм киләчәктә дә шулай булыр дип уйлыйм.

Мин республиканың бердәм мәдәнияте эчендә татар тармагын үстерү өчен мөмкинлекләр ачу ягында торам. Мондый сүз кузгалу белән, шундый рәсми билгеләмәгә тотыналар: безнең илдә алтмыш миллион кеше үз милләтеннән читтә яши. Алар өчен һәр урында үзенә башка әдәбият, сәнгать булдырып булмый, моның өчен экономик мөмкинлекләр җитми, диләр. Аларның мәдәни ихтыяҗларын милләтнең төп өлеше яшәгән республика белән аралашу, үзешчән сәнгатьне үстерү исәбенә канәгатьләндерү максатка ярашлы дип карала. Күп милләтләрнең читтә яшәүче өлешләре өчен кабул итәрлек билгеләмә бу. Ләкин Башкортстанда татар телен үзенең туган теле итеп танучыларны бу рәткә куеп санарга ярамый. Алар монда җирле халык: шушында формалашкан үзенә бер этник төркем. Сан ягыннан башкортлардан байтакка күп. Аларны башкортлар белән дә, Казан татарлары белән дә тиңләп карау (бутау) дөрес түгел. Башкортлар белән тиңләү аларның үз йөзе барлыгын инкарь итүгә әйләнә. Ә Казан татарлары белән тиңләү аларны килмешәк хәленә куя.

Минемчә, бу халыкның үзаллы мәдәният булдырырга хакы бар. Һәрхәлдә, мәсьәлә кузгалган икән, андый мөмкинлекне бирергә кирәк.

Татар иҗтимагый үзәге Башкортстанда татар теленә дәүләт теле статусы бирүне юллый. Үзаллы мәдәният булдыру өчен, бу, әлбәттә, беренче шарт. Рәсми танылган тел булмыйча, аерым мәдәни юнәлеш тә була алмый. Башкортстан мәдәнияте эчендә татар тармагының булуы мөмкин дип карала икән, татар теле дә рәсми хәлгә куелырга тиеш. Татар теле республикада рәсми телләрнең берсе итеп танылса, Көнбатыш һәм Төньяк-Көнбатыш Башкортстанда яшәүче үзенчәлекле этник төркемнең мәдәнияте дә юл алып китәчәк. Монда бер нәрсә икенчесе белән аерылгысыз бәйләнгән. Берсен инкарь итү яки аңа каршы чыгу икенчесен кире кагуга китерә.

Республиканың татар җәмәгатьчелеге урынлы таләпләр куя. Татарча язучы әдипләргә үзләренең оешмасын булдырырга мөмкинлек бирү, татар телендә журнал, яшьләр газетасы чыгару, Башкортстан китап нәшриятында татар бүлеге оештыру, радио, телевидениедә татар редакцияләре булдыру, Уфада татар театры төзү, яшь тамашачылар театры янында татар труппасы җыю, Уфада татар балалары өчен интернат-мәктәп ачу, республиканың югары уку йортларында татар мәктәпләре һәм балалар учреждениеләре өчен белгечләр чыгаруны арттыру — болар барысы да өлгереп җиткән мәсьәләләр. Аларның күбесе зур акча тотуны да сорамый.

Республиканың мәдәният тормышында килеп туган хәл, гомумән, җаваплылык белән хәл итүне көтә. Көнбатыш һәм Төньяк-Көнбатыш Башкортстан халкының мәдәниятка булган ихтыяҗы турында сүз чыккан саен, Казан ягына төртеп күрсәтү бар. Бердән, Казан ул ихтыяҗны

канәгатьләндерә алмый. Аның да экономик мөмкинлекләре чикле. Икенчедән, татарча сөйләшүче ярты Башкортстан халкын мәдәниятне бары тик кулланучылар хәленә куймакчылар. Ә халыкның, үзенчәлекле тарихы, этник йөзе булган халыкның, үз мәдәниятен үзе иҗат итәсе килә. Менә бит мәсьәлә ничек тора. Бу омтылышны исәпкә алмау, минемчә, заманча эш түгел. Ул җитди каршылыклар китереп чыгарачак. Хәзер үк инде Көнбатыш һәм Төньяк-Көнбатыш Башкортстанның суверенлыгы мәсьәләсе кузгатыла башлады. Моның нәрсәгә китеререн беркем дә әйтә алмый. Җәмәгатьчелек фикере хәзергә утырып җитмәгән. Шулай да элекке Уфа губернасын, халык фикерен сорамыйча, Башкортстан составына кушып куюны күпләр тәнкыйть итә. Хәзер ситуация тиз үзгәрә. Бу мәсьәлә кичә генә «кара урман» иде. Кая кереп адашырыңны да белми идең. Бүген карасаң, РСФСРның яңа Конституциясе проектында ап-ачык итеп: бер милли республиканың аерым бер өлеше халкы яңа республика төзи ала, дип язылган. Ике республика чигендә яшәүче халыкларга да, теләсәләр, берләшү хокукы бирү күздә тотыла. Хокуклар гарантияләнә икән, калганы — көндәлек эш. Ләкин максат — аерылышу, бүленү түгел, бергә килешеп яшәү юлын табу.

---

*Безнең календарь*

## Еллар һәм җырлар

20 гыйнварьда шагыйрь Галимҗан Латыйпның тууына 80 ел тулды.

Ул 1912 елда Башкортстанның Чакмагыш районы, Яңа Дөмәй авылында туа. Башлангыч белемне дә шунда ала. Революциянең шау-шулы шаукымына ияргән яшь егет башта үз авылында мәдәният эшләренә чума: кызыл почмак мөдире, китапханәче булып эшли. Бәләбәй шәһәрендә укытучылар әзерләү мәктәбен тәмамлагач, башлангыч мәктәптә балалар укыта. Соңыннан ул Казанга килеп, урман техникасы институты рабфагында, Казан финанс-экономика институтында укый. Ватан сугышы башланыр алдыннан Совет хәрби диңгез флотында хезмәт итә. Илленче елларга кадәр финанс эшләрендә эшләп, калган бөтен гомерен әдәбиятка багышлый.

Шагыйрьнең «Юл буйлап» дигән беренче китабы 1939 елда студент чагында ук Казанда дөнья күрә. Шул көннәрдән алып аның иҗаты төрле жанрларда тармаклана<br>нып үсә башлый: шигырьләр, җырлар, поэмалар, балалар өчен әсәрләр, урыс һәм дөнья классиклары иҗатыннан татар теленә тәрҗемәләр. Шулар өстенә җәмәгать эшләрендә, әдәбиятны халыкка җиткерүдә актив катнаша.

Г. Латыйпның озак еллар дәвам иткән иҗатын тулы килеш күзаллап шуны әйтергә мөмкин: җирдәге матурлыкны яклап көрәшүче иҗат ул. Күп кенә лирик шигырьләре, дистә еллар буена җырчылар җырлап килгән җырлары, балалар дөньясына ямь булырдай әсәрләре күп аның. Шагыйрь иҗаты халык күңелендә дәвам итә.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Мансур Хәсәнов,**

филология фәннәре докторы

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮНЕҢ КАЙБЕР МЕТОДОЛОГИК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Җәмгыятебез үсешендә яңа этап башланганга менә инде җиде елга якын вакыт үтеп тә китте.

Үзгәртеп кору фикерләве һәм практикасы тормышның барлык өлкәләренә үтеп керде, тирән үзгәрешләр тудырды һәм һаман да тудыра килә. Без бик катлаулы, каршылыклы һәм җаваплы бер чорда яшибез. Матди тормышта, экономикада, сәясәттә, рухи сферада, кешеләрнең аңында, психологиясендә бик зур үзгәрешләр бара. Электән килгән караш-принциплар җимерелә, гасырларда яшәр сыман булып лозунгка әверелгән купшы вәгъдә-ышандырулар сына, ватыла, ишелә. Илдә иман яңарту процессы бара. Кайберәүләр хәтта дистәләрчә еллар табынып килгән идеалларыннан баш тарталар, рухи ориентирларны тәнкыйть итәләр, шик астына куялар.

Үзгәртеп кору методологиясе рухи тормышка тирән үтеп керде, анда җитди үзгәрешләр тудырды. Үткәннәргә яңача караш, рухи байлыкларны яңадан бәяләү һ. б. процесслар бара. Эстетиканың һәм мәдәният теориясенең бик мөһим, фундаменталь положенияләре, милли культураның, әдәбият һәм сәнгатьнең тормыштагы, халыкның язмышындагы роле, миллилек һәм интернациональлек төшенчәләренең мәдәнияттә, сәнгатьтә, гомумән рухи тормышта үзара мөнәсәбәте мәсьәләләре яңадан карала, тарих фактларына, мәдәният күренешләренә, милли мираска бәя биргәндә ясалган хаталар, гаделсезлекләр төзәтелә, тарихи шәхесләрнең, язучыларның, сәнгать ияләренең, аерым талантларның урыны һәм роле ачыклана һ. б. Кыскасы, әдәбият, мәдәният үсешенең объектив панорамасы бөтен катлаулылыгы һәм каршылыклары белән торгызыла, бәян ителә. Янә, аеруча мөһиме шунда ки, бу процесста, әдәби-мәдәни хәрәкәттә рухи байлыкларга бәя биргәндә, тар сыйнфый карашлардан, фирка мәнфәгатьләреннән чыгып түгел, ә гомум кешелек кыйммәте югарылыгыннан торып эш ителә.

Табигый, бу процесстан, гомуми хәрәкәттән иҗтимагый һәм гуманитар фәннәр дә читтә кала алмыйлар. Алар бу үзгәрешләрнең эчендә, үзәгендә кайныйлар. Шунысын таныйк: үзгәртеп кору, бүгенге көн таләпләре югарылыгыннан чыгып караганда, Татарстанда иҗтимагый һәм гуманитар фәннәрнең хәле, торышы канәгатьләнерлек, дип раслап булмый. Бу фәннәрдә аеруча элекке фикри торгынлыктан, искергән калыплардан арынып, яңа заман таләпләре һәм ихтыяҗлары биеклегенә күтәрелергә, шул рухта эш итәргә кирәк.

Мондый үзгәреш-яңарышның зарурлыгы әдәбият фәне өлкәсендә дә үзен нык сизderә. Шуңа басым ясап әйтергә тиешбез: җәмгыятьтә барган яңару хәрәкәте, иң әүвәл нәкъ менә фикер-карашлар өлкәсендә, кеше психологиясендә бөреләнде, һәм, димәк, төп өйрәнү объекты образ-характерлар булган әдәбиятта аеруча калку гәүдәләнеш алды.

Гәрчә, татар әдәбиятының күпгасырлык тарихын өйрәнү өлкәсендә (әдәби мирасны барлау, туплау, бастырып чыгару; текстология өлкәсендә: К. Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабыннан башлап, Утыз Имәни, Кандалый, Мәрҗани, Акмулла әсәрләрен халыкка кайтару, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һәм башка классикларның күп томлык әсәрләрен дөньяга чыгару; татар әдәбияты тарихының 6 томлыгын эшләү, классик әдипләрнең иҗатына, әдәби хәрәкәтнең аерым дәверләренә, яки жанрлар үсешенә багышланган монографик хезмәтләр һ. б.) бик зур фәнни эш башкарылган булса да, алда тора торган бурычлар тагы да күп әле. Хәзер безгә күп нәрсәгә яңадан әйләнеп кайтып, күп нәрсәне яңача, чын фәнни нигездә өйрәнергә һәм бәяләргә кирәк булачак. Беренче

нәүбәттә фәнни тикшеренүнең методологиясен ачыклау мәсьәләсе күтәрелә. Моңа кадәр без инанган һәм таянган методология күп җәһәттән хәзерге таләпләргә һәм үзгәртеп кору фикерләвенә җавап бирә алмый. Чөнки бу методология еш кына мәгълүм бер идеологиянең фәлсәфи категорияләрен, принципларын турыдан-туры әдәбиятка һәм сәнгатькә күчерүгә корылган, соңгыларының асыл үзенчәлекләрен искә алып бетерми иде.

Бүген әдәбият фәне алдында торган бурычлар, хәл итәсе мөһим мәсьәләләр нидән гыйбарәт соң?

Иң зур проблемаларның берсе: әдәбият белеменең, гомумән, татар әдәбияты белеменең хосусан үз методологиясен булдыру зарур. Аның төп принцибы — фәлсәфи категорияләрне турыдан-туры, механик рәвештә әдәбиятка күчерүдә түгел, ә әдәбиятның, сәнгатьнең, кеше рухи эшчәнлегенең мөстәкыйль өлкәсе икәнлеген тануга нигезләнгән, корылган булырга тиеш. Әдәбият сәясәткә, идеологик күренешләргә өстәмә, иллюстрация рәвешендә түгел, дөньяны һәм кешене образлы танып белү объекты буларак өйрәнелергә тиеш. Биредә В. Г. Белинскийның әдәбият хакындагы, аның фәнни аермасы турындагы, мәгълүм формуласын искә төшерү урынлы булыр. Әдәбият-сәнгать дөньяның, яшәешнең, кешенең сәясәт тә, фәлсәфә дә, фән дә (тарих, экономика, социология, юриспруденция һ. б. гуманитар фәннәр) ачып бирә алмаган хасиятләрен иңләп анализлый ала. Ф. Шопен музыкасы, мәсьәлән, поляк халкының милли рухын һичбер сүз, идеология, политик трактатлар үтеп керә алмаган асыл үзенчәлегендә күрсәтергә сәләтле, шуның белән ул кешене тетрәтә дә. Алыйк үзебезнең Дәрдемәнд шигырьләрен. Ул татар рухының, тарихи язмышының һичбер философ, тарихчы, социологик трактат ачып бирә алмаган серләрен татар күңеленә җиткерә. Әдәбият тарихы политик, идея-эстетик схемаларга буйсындырылган ясалма тарих итеп түгел, ә әдәбиятның эчке үсеш тарихы буларак өйрәнелергә, ачып бирелергә тиеш.

Әдәбият фәне методологиясен яңартуны әдәбиятны милли үзенчәлекле, хасиятьле сәнгать итеп караудан һәм «милли әдәбият» төшенчәсенә ачыклык кертүдән башлау хак булыр. Гомумән, социологиядәге кебек үк, әдәбият белемендә дә озак еллар Сталинның «формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик» дигән схоластик формуласы хакимлек итеп килде. Әдәбиятның миллилеген бары тик формага гына кайтарып калдыру аны сәнгать буларак җансызландыру, иллюстрациягә кайтарып калдыру булыр иде. Бу тере кешенең җанын алып, тәнен генә калдыру белән бер тигез. Әлеге зарарлы фәлсәфәнең турыдан-туры йогынтысы аркасында татар әдәбиятында җансыз, төссез образлар галереясы пәйда булды. Бу һәрберебезгә дә мәгълүм нәрсә һәм ул әдәби процессның үсешенә зур зыян китерде. Әдәбиятның миллилеге беренче нәүбәттә аның эчтәлегендә гәүдәләнә, югыйсә, милли әдәбият мөстәкыйль сәнгать өлкәсе булудан туктый. Әгәр дә без татар әдәбиятын милли әдәбият буларак өйрәнергә телибез икән (һәм без аны нәкъ менә шулай өйрәнергә тиеш тә!), алгы планга миллилек һәм тарихилык принципларын куярга тиеш булабыз. Әдәбиятны тарихи-милли яссылыкта өйрәнү аның сәнгатьчә асылын һәм хасиятен дөресрәк, тирәнрәк ачарга ярдәм итәчәк.

Әдәбиятны сәяси, идеологик күренешләргә иллюстрация буларак өйрәнүдән баш тарту әле һич тә әдәбият, сәнгать белән политика, сәяси тормыш арасындагы мөнәсәбәтләрне танымау, инкарь итү, дигән сүз түгел. Ул мөнәсәбәтләр, һичшиксез, бар гына түгел, зарурый да. Әмма алар бик тирән, гаять катлаулы һәм каршылыклы, күпләр фараз кылганча, өстә генә, күзгә күренгән җирдә генә ятмый. Аларны таба, ачып бирә белергә кирәк. Моңа кадәр татар әдәбият белеме генә түгел, гомумән совет әдәбияты фәне ул мөнәсәбәтләрне бөтен тирәнлеге, катлаулылыгы һәм каршылыклары белән ача алмады. Мәгълүм идеологик положение — карарларның боерулы таләпләре нигезендә катгый, кысан калыпларга куып кертелгән, зәгыйфьләндерелгән фикерләү дәрәҗәсе моңа әзер түгел иде. Һәм моның өчен шартлар да юк иде. Бу бик җитди, аерым сөйләшү-фикер алышуны таләп итә торган мәсьәлә. Биредә өстәп шуны гына әйтергә кирәк: әдәбият фәне алдына заман үзе куя торган мөһим методологик таләпләрнең берсе — ул әдәби процессны, аның тенденцияләрен һәм күренешләрен реаль тормыш белән бәйләп өйрәнү, бәяләү. Әдәбиятны реаль чынбарлык белән тыгыз бәйләнештә өйрәнүдә әдәбиятчы галимнәр иҗтимагый һәм гуманитар фәннәрнең башка тармаклары, бигрәк тә тарихчылар, философлар, һәм социологлар ярдәменә мохтаҗ.

Бүгенге көндә аеруча әһәмиятле методологик принцип булып әдәбият тарихын өйрәнгәндә әдәби чыганакларның фактик базасын киңәйтү һәм тирәнәйтү мәсьәләсе тора. Гыйльми тикшеренүләрне чын фәнни нигезгә кору галимнәрдән әдәби чыганакларны, өйрәнү предметының фактурасын төгәл, тулы белүне таләп итә. Хәлбуки, моңа кадәр бездә әдәби әсәрләр еш кына билгеле сыйнфый мәнфәгатьләрдән яки сәяси күрсәтмәләрдән чыгып, теге яисә бу схемаларга туры китерелеп, ә инде аңа сыеп бетмәгән фактларны төшереп калдырып өйрәнелделәр һәм шул рәвешчә дөньяга да чыгардылар. Ә кайбер язучылар, аерым әсәрләр хәтта әдәбият тарихыннан бөтенләй сызып ташландылар. Табигый, мондый фәнни булмаган, волюнтаристик методология әдәбият тарихына багышланган күп кенә хезмәтләрнең фәннилегенә зур зыян китерде, аларның тарихи-эстетик әһәмиятен киметте. Ә хакыйкый үткәнне бөтен тулылыгында күз алдына китерми, әдәби мирасны бөтен рәвештә өйрәнми торып, ничек чын тарих

турында сүз барырга мөмкин инде? Үзгәртеп кору чорында әдәбият, мәдәният тарихы хуҗалыгына күп кенә әдәби җәүһәрләребез яңадан әйләнеп кайтты. Болар — Р. Фәхретдинов, Ф. Кәрими, С. Максуди, Г. Исхакый һ. б. иҗатлары. Бу мирас, бердән, бастырып чыгарылырга, халыкка җиткерелергә, һәм, икенчедән, боларның һәркайсы үз чорының әдәби, мәдәни, рухи хәрәкәтендә лаеклы урын алырга тиеш. Бу исә, әдәби процесстагы аерым шәхесләр роле мәсьәләсендәге элекке карашларның, бәяләрнең шактый үзгәртелүен таләп итәчәк. Кыскасы, тарихи дөреслек торгызылырга тиеш. Бу — татар әдәбият белеме һәм тәнкыйте алдында торган мөһим бурычларның берсе. Бу юнәлештә фәнни-теоретик тикшеренүләрне текстологик эш белән тыгыз бәйләп алып барырга кирәклеге ап-ачык дәлилләнеп тора.

Тарихи процесслар, мирас хакында сүз барганда татар әдәбияты белән ислам дине арасындагы мөнәсәбәт мәсьәләсенә дә туктамый булмый. Мәгълүм ки, татар әдәбияты, иҗтимагый фикер үсешенең мең еллык тарихы ислам белән тыгыз бәйләнгән. Үзгәртеп кору карашына һәм практикасына кадәр без бу бәйләнешне бер яклы, тискәре мөнәсәбәт, дип аңлатып килдек. Кызганычка каршы, совет идеологиясе бу проблемага карашта дөньядагы зур-зур галимнәрнең, философ һәм политикларның фикерләрен кабул итә, файдалана алмады.

Бу мәсьәләгә яңача карашны мин моннан ике ел диярлек элек, татарларның (Идел буе болгарларының) ислам динен кабул итүләренә 1100 ел тулу уңае белән Казанда үткәрелгән зур җыелыштагы чыгышымда куйган идем. Ислам диненең татар әдәбияты, мәдәнияты үсешендәге уңай йогынтысына багышланган иде ул. Минем әлеге чыгыш Мәскәү журналларының берсендә басылып та чыкты. Биредә сүзне озын-озакка сузмыйча, шуны гына ассызыклыйсы килә: әдәбият тарихын, бигрәк тә революциягә кадәрге чорны өйрәнгәндә бу бәйләнеш мөһим бер методологик принцип буларак кулланылырга тиеш.

Әдәбият тарихын өйрәнгәндә безгә андагы төрле чорлар, дәверләр арасындагы бәйләнеш һәм күчемлелек (преемственность) мәсьәләләренә игътибарны арттыру кирәк. Моңа кадәр бу тарихның аерым дәверләре ничектер үзаллынарак өйрәнелеп килендә, бүтән дәверләр белән күчемле бәйләнештә карауга дикъкать җитмәде. Бу тенденция аеруча совет чоры әдәбиятын өйрәнүгә хас иде. Ул гадәттә үткәндәге күп гасырлык әдәби тәҗрибәдән һәм традицияләрдән аерыбрак, әйтергә кирәк, хәтта каршы куебрак тикшерелде. Үткәндәге мираска мөнәсәбәттә аны бары тик караңгылык, наданлык, дин белән агуланган зәгыйфь чаралар итеп караган һәм, Октябрьдән соң гына сәламәт үсешкә ия булган диган фикерне куәтләүче совет тәнкыйте әдәби этапларның, буыннарның тыгыз бәйләнешен өзгәләүдә зур роль уйнады. Бу хәл ахыр чиктә әдәбиятыбызның милли йөзен объектив бәяләүгә гаять нык комачаулады. Гомумән, Октябрьдән соңгы әдәбиятыбыз тарихын чын фәнни нигездә өйрәнү хәзер әдәбият фәненең иң мөһим бурычларыннан берсе булып тора. Чөнки соңгы вакытларга кадәр нәкъ менә шушы дәверне өйрәнүдә фәннилек аеруча җитмәде, аны мәгълүм идеологик схемалар һәм күрсәтмәләрдән генә чыгып бәяләү өстенлек итте. Ә уйдырма принципларга буйсындырылган әдәбият исә бер ничек тә җимешле була алмый.

Әдәбият тарихын тикшерүдә төп юнәлешне, төп игътибарны әдәбиятның, сәнгать буларак, төрле коньюнктуралар белән бәйләнмәгән, социаль-политик алмашынулар нәтиҗәсендә үзгәрми торган мәңгелек проблемаларына юнәлтү дөрес булыр. Шундый мәсьәләләрнең берсе — әхлак проблемасы.

Татар әдәбиятының мең еллык тарихында бу проблема Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ыннан алып, Казан ханлыгы чоры Мөхәммәдьяр, аннан соңгы дәверләрдә Утыз Имәни, Кандалый, Акмулла иҗатларында, Г. Тукай, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, һ. Такташ, Г. Кутуй, Х. Туфан һ. б. әсәрләрендә кызыл җеп булып сузылган. Ул бигрәк тә бүгенге шагыйрьләр, язучылар иҗатында тирән чагылыш һәм яңгыраш таба. Чөнки әхлакый чаралар кешедә сәламәт рух, саф акыл тәрбияләүдә төп принцип булып торалар. Ә камил шәхес — ул сәламәт милләт дигән сүз.

Без милли әдәбиятта, күчемлелек, традицияләр хакында сүз алып барабыз икән, алар беренче нәүбәттә нәкъ әнә шундый барлык халыклар, барлык әдәбиятлар өчен дә уртак булган мәңгелек темаларны кую һәм образлы хәл итүдә гәүдәләнә дә инде.

Сыйнфый, идеологик көрәш, партия аерымланулары һәм башкалар — болар һәммәсе әдәбиятта әлбәттә бар, булган, тарихта мәгълүм мөһим мәсьәләләр. Әмма алар аерым бер чор, дәвер проблемалары. Һәм аларны һич тә абсолютлаштырырга ярамый, ул мәсьәләләрнең урыны фәнни яктан дөрес билгеләнергә тиеш.

Татар әдәбияты, гомумән иҗтимагый фикер үсеше тарихы читләтеп үтә алмый торган мөһим бурычларның берсе — җәдитчелеккә караш, җәдитчелек вә мәгърифәтчелекнең үзара мөнәсәбәте мәсьәләсе. Озак еллар дәверендә җәдитчелекне бер идеологик, политик күренеш итеп карау — әдәбият, иҗтимагый фикер үсеше тарихына, кирәксә-кирәкмәсә дә, сыйнфыйлык принцибын көчләп тагарга тырышудан башка нәрсә түгел иде.

Мәгърифәтчелекне җәдитчелеккә каршы куеп тикшерү, аларның беренчесен — халык массалары идеологиясен, мәнфәгатьләрен, ә икенчесен — татар буржуазия идеологиясен чагылдырган дип бәяләү назари яктан да дөрес түгел иде. 20 еллар әдәбият беле-

ме һәм тарих фәнендә мондый капма-каршылы бүленеш юк, аларның икесе дә бер итеп карала. (Мисал өчен Г. Ибраһимовның 1925 елда басылган «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» дигән китабына мөрәҗәгать итәргә мөмкин). Әмма ВКП(б) Татарстан өлкә комитеты бюросы тарафыннан 1951 елда кабул ителгән татар мәктәпләренең 8-классы өчен әдәбият дәреслеге турындагы карарыннан соң җәдитчелеккә караш бөтенләй үзгәрә, тискәре төс ала. Бу, әлбәттә, татар әдәбияты тарихын тикшерүгә зур зыян китерде, рухи-мәдәни мирасыбызга карата кимсетүле, гарип карашларның яшәвенә этәргеч бирде. Бердән, бу әдәбият һәм тарихны өйрәнүдә зур буталчыклар китереп чыгарса, ясалма киртәләр, аңлашылмаучылыклар тудырса, икенчедән, татар мәдрәсәләренә мөнәсәбәттә, бигрәк тә аның алдынгы-җәдит ысулындагыларына карата ясалма кыенлыклар тудырды. Ә бит татарның октябрьгә кадәр «Мөхәммәдия», «Галия», «Хөсәения», Иж-Бубый мәдрәсәләре кебек нинди мәшһүр мәгърифәт учаклары булган! Заманында җәдит мәдрәсәләрендә белем-тәрбия алган, соңыннан күренекле мәдәният, фән, җәмәгать эшлеклеләре булып җитешкән кешеләрнең кайберләре, мәсьәлән, Галә Ходаяров, җәдитчелеккә ябыштырылган мондый ясалма, ялган идеологик мөһерне үзгәртүне таләп итеп күпме көч, энергия түксә дә, никадәр вакыт сарыф итсә дә, нәтиҗәсе күренмәде. Чөнки бу торгынлык чорындагы рәсми пропаганда күрсәтмәләренең конкрет бер чагылышы булып, аны үзгәртү чорга каршы баруга тиң кабул ителә иде. Үзгәртеп кору фикерләве ниһаять бу өлкәдә дә әдәбият, иҗтимагый фикер үсеше, татар мәгарифе тарихын тикшерүчеләр алдында фәнни дөреслекне торгызу өчен зур мөмкинлекләр ача дип ышанырга кирәк.

Хәзерге заман әдәбият белеме революциягә кадәрге чор иҗатында, иҗтимагый фикер үсешендә, гомумән тарихта милли азатлык һәм сыйнфый көрәш мәсьәләләренең чагылышын, аларның үзара мөнәсәбәтен өйрәнүне дә бурыч итеп куя. Кызганыч ки, 70 ел буена диярлек безнең тарих, шулай ук әдәбият тарихы фәннәрендә боларның урыны, роле үзгәртелеп, сыйнфый көрәшнеке арттырылып, милли азатлык хәрәкәтенеке — татар милләтенең киләчәге, язмышы һ. б. өчен көрәшнең әһәмияте киметелеп күрсәтелде. Бу мәсьәләдә дә тарихи дөреслек торгызылырга тиеш.

Шул нисбәттән, татар әдәбиятының күпмилләтле совет әдәбияты, гомумән дөнья әдәбияты тарихында тоткан урыны хакында да җитди уйланырга вакыт җитте. Моңа кадәр совет әдәбият белемендә милли әдәбиятлар ранжирланган принцип белән өйрәнелеп килде. Мәскәүдә М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты чыгарган күпмилләтле совет әдәбияты тарихын (6 томлык) алыйк. Анда татар әдәбиятына барлык 15 союздаш республика әдәбиятларын тикшереп чыкканнан соң гына урын бирелә. Революциягә кадәрге үсешендә халык авыз иҗаты этабыннан үтмәгән кайбер союздаш республика әдәбиятларына (казах, кыргыз, төрекмән) әдәби мәктәп саналган. Тукайлары, Әмирханнары, Ибраһимовлары, милли романнары ул халыклар өчен остаз булган татар әдәбияты (1916 елда Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә казах әдәбиятының милли әдәбият булу-булмавы турындагы бәхәсне, анда Г. Ибраһимовның позициясен хәтергә төшерегез!) ранжирлау принцибы белән кимендә 16 нчы урынга төшеп утыра иде.

Моннан ун еллар элек шәхсән бу хакта СССР Фәннәр Академиясе член-корреспонденты Г. И. Ломидзе белән бик нык лап сөйләшкән-бәхәсләшкән идем. Мин аңа турыдан-туры: Сез нигә Татарстанга — автономияле республикага карата булган политик административ карашны, механик рәвештә татар әдәбиятына күчерәсез, дигән идем. Сез нигә СССР да милли әдәбиятларны тикшергәндә аларның эчке үсеш дәрәҗәсеннән, тарихыннан, традицияләреннән, потенциаль мөмкинлекләреннән чыгып түгел, ә халкының нинди республика статусына ия булуыннан чыгып эш итәсез, дигән законлы сорау-таләпне куйган идем. Бу бит фәнни караш түгел, ә административ мөнәсәбәт, дидем. Аргументлар китердем, милли әдәбиятларны чагыштырдым. Татар әдәбиятының 1917 елга кадәр үк нык үскән булуын, украин, белорус, әзербайҗан, грузин, әрмән әдәбиятлары белән бер дәрәҗәдә тора торган әдәбият икәнлеген күрсәттем, дәлилләр китердем. Ул минем фикерләү, исбатлаулар белән килешергә мәҗбүр булды. Ләкин моңа карап бер нәрсә дә үзгәрмәде. Әдәбиятларны ранжирлап өйрәнү дәвам итте. Күрәсең, республикаларны, милләтләрне сортларга аерып кую сәясәтен тамырдан үзгәртми торып, моңа ирешү мөмкин түгел иде.

Шундый факт китерим. Татар әдәбиятына мондый ранжирлау принцибыннан чыгып карау мисалын мин үземнең практикамда, бик тупас рәвештә, 1972 елны Ашхабадта очраттым.

Төрекмән поэзиясенең классигы Кәминәнең 200 еллык юбилее бара торган көннәр. Бәйрәмгә хөкүмәтнең рәсми чакыруы буенча шагыйрь Әхмәт Исхак белән килдек. Баруга республика Үзәк Комитетының беренче секретаре Мөхәммәтназар Гафуров янында булдым. Бик җылы кабул итте. 30 нчы елларда төрекмәннәрнең мәгарифе, мәдәнияте ни хәлдә булуын искә төшерде, татарлар безнең укытучыларыбыз, мәгърифәтчеләребез, остазларыбыз, дип сөйләде, зур рәхмәтләр әйтте. Ә мин Кәминәнең шигырьләре беренче мәртәбә Казан типографиясендә басылганын сөйләдем, татар-төрекмән әдәби элемтәләрен искә төшердем, юбилей кичәсендә этрафлы чыгыш ясаячагым хакында әйттем. Бик хуплап, бик шатланып риза булды. Бу очрашудан мин бик канәгать калдым, үзем уйлыйм: әйбәт чыгыш ясарга кирәк, сүзне докладтан соң беренче

булмаса да (гадәттә рус, украин делегатлары беренче нәүбәттә сүз алалар), өченче-дүртенче итеп бирерләр, дип план корам. Беренче секретарь белән дә сүз булгач, бу ышанычым яңа ныгый төшә.

Ниһаять, юбилей тантанасы ачылды, төп доклад ясалды. Кунакларның чыгышлары башланды... Миңа чиратта уналтынчы итеп, бөтен союздаш республикалардан соң, хәтта төрекмән әдәбиятына, Каминәгә тарих, тел ягыннан һичбер мөнәсәбәте булмаган Балтыйк буе республикаларын үткәреп җибәргәннең ахырында гына сүз бирделәр. Мин шул вакытта аңладым: кабинетта үзара дустанә, туганнарча сөйләшү-аңлашу — бер нәрсә, ә рәсми сәясәт — икенче нәрсә икән. Шулай да күңелне күтәргән бер вакыйга булды: иртәгесен кунакханәгә Барды Кербабаев килде, татар әдәбиятына, үз осталарына ихтирамын белдереп, китапларын бүләк итте.

Алга таба Мәскәүдә үткәрелгән административ, политик рәсми җыелыш-киңәшмәләрдә миңа Татарстанга мондый мөнәсәбәтне күп мәртәбәләр татырга, кичерергә туры килде.

Республикабызның суверенлыгы халыкларны сортларга бүлү сәясәтен тамырдан җимереп, әдәби-мәдәни байлыгыбызны өйрәнүдә, бар куәтенә күрсәтә алуда яңа мөмкинлекләр ача.

Бу җәһәттән, әдәбият белеме, әдәбият тарихы фәнендәге дәвамчылык мәсьәләсенең дә үзгә, яңа сыйфатлар белән тулыланачагы ачык күренеп тора.

Гомумән, совет чоры тормышындагы кебек үк, бездә гуманитар фәннәр үсеше дә берьяклылык белән барды. Һәрдаим кире кагу, инкарь итү, каршы кую принцибы өстенлек итте. Бу өлкәдә без зур «уңышларга» ирештек.

Егерменче еллар башында революциягә кадәрге иҗатка «буржуаз әдәбият» ярлыгы тагып, аннан баш тарттык, иң әүвәл пролетариат әдәбиятын, соңрак совет әдәбиятын, каршы куйдык. Ә утызынчы еллар бу яңа әдәбиятны төзүчеләрнең иң атаклыларын кырып бетерде. Мәһабәт агачлары киселгән урманны куаклык баса. Чын талантларны иҗаттан аергач, мәйданга башкалар — «лилипут» әдипләр калкып чыкты. Тамырларына балта чабылган, тоталитар режимның идеологиясе белән сугарылган татар әдәбияты очсыз, «кызыл» әсәрләр белән тулды һәм, шуның нәтиҗәсендә күзгә күренеп вакланды, кечерәйде, фәкыйрьләнде.

Үткәнне инкарь итү, ул мирастан баш тарту әдәбият үсешенә гаять зур зыян китерде. Әлеге чорның идеологиясенә без бүгенге көн күзлегеннән карап бәя бирергә тиешбез. Шулай ук әдәбият фәнендә кызу бәхәсләрне дә яңадан карау таләп итела. Биредә 1922 елны матбугатта Г. Ибраһимов белән Җ. Вәлиди арасындагы бәхәсне искә төшерү дә җитә.

Егерменче елларда мәйданга килгән пролетариат әдәбияты революциягә кадәрге чор иҗатының күренекле вәкилләре булган Р. Фәхретдинов, Ф. Кәрими, Җ. Вәлиди, Г. Гобәйдуллин, Г. Кәрам хезмәтләрен инкарь итте, ул әсәрләрне яңа дәвер өчен бөтенләй кирәксез, дип игълан ясады, шул рәвешле, бөртекләп җыелган искиткеч бай әдәби-мәдәни-фикри хәзинә файдаланылмады. Нәтиҗәдә традицияләр дәвамчылыгы тупас бозылды.

Татар җирлегендә Көнбатыш Европа эстетик принципларын урнаштырабыз, дип, Көнчыгыш, төрки халыклар, гарәп һәм фарсы әдәбиятлары белән булган тарихи-әдәби бәйланышларга зур зыян ясалды. Бу бәйләнешләрнең гасырларга сузылган тарихы бар, аларны өзгәләү, яисә инде бөтенләй инкарь итү әдәби процессны гаять фәкыйрьләндерүгә китерер иде. Һәм, кызганычка каршы, 20—30 еллар әдәбияты моңа гыйбрәт — ул шулай булды да. Ә бит шушы шифалы бергәлекнең нәтиҗәсе буларак татар әдәбиятларында никадәр дастан, кыйсса, поэмалар иҗат ителде! Кол Гали, Котб, Сайади, Курмаши иҗатлары моңа дәлил. Инде яңа гасырга килсәк, Г. Ибраһимов, С. Җәлал, Г. Монасыйпов роман-повестьларында да классик әдәбиятның мотив-сюжетларын күрергә мөмкин. Гарәп-фарсы һәм төрки-татар әдәбиятлары бәйланышы зур, катлаулы проблема булып безнең фәндә тиешенчә яктыртылыш ала алмады әле. Ул гына да түгел, догматик фикерләүләр, вульгар социологизмның ярлыкларын бүген дә әдәби тарихыбызның дәверләрен күзаллаганда һәрвакыт комачаулык итеп килә.

Әдәбият белеме алдына бу традицияләрне яңадан тергезү, ләкин механик рәвештә күчерү юлы белән түгел (югыйсә, без тагын икенче чиккә ташланачакбыз, ә моның ачы гыйбрәт белән сугарылган нәтиҗәләре тарихыбызда җитәрлек булды), бәлки яңа югарылыкта, яңа әйләнеш-кабатланышта торгызу бурычы тора.

Татар матбугатында әле революциягә кадәр үк әдәби үсеш перспективасына кагылышлы «шәрыкме, гәрепме?» дигән кызу бәхәсләр барган. Хәзерге чорда мәсьәлә башкача «шәрык тә, гәреп тә» дип куелырга тиеш. Бу очракта «мир един и неделим» дигән катгый канунны онытмау зарур.

Яңача фикерләү таләбе әдәбиятчылар алдына тагын бер мәсьәлә куя: ул да булса, иске, догматик карашлардан баш тарту, котыла белү. Әлеге таләп өлкән буын әдәбият белгечләренең барысына да карый. Монда беркемгә дә чыгарма ясап булмый дип уйлыйм. Бу авыр процесс, мәшәкатьле, борчулы, хәтта гаугалы эш. Биредә кемнеңдер кәефе дә кырылырга мөмкин, ачуланып кукрәк кагучылар да булырдыр. Әмма хакыйкать никадәр ачы булса да, иң әүвәл аны танырга кирәк. Үткән идеологиянең ялган бал-

лылыгыннан, черек күл җылысына тиң алдавыч рәхәтлегеннән арынырга бик вакыт. Хаталарны күрә, ялгышларны төзәтә белү үзгәреш җилләре юнәлеш күрсәткән кыйбланы табуда, аны югалтмауда иң көчле чараларның берсе һәм әле бәлки беренчеседер дә.

Аң булыйк, бу хәрәкәт әдәбият белеме, иҗтимагый фикер, тарих фәне үсешенә теге яки бу өлеш керткән галимнәрне, аларның хезмәтләрендәге элекке карашлары өчен кыйнау, кимсетү юлы белән түгел, ә конструктив юнәлештә барырга тиеш. Онытмыйк: догматик схемалар өчен әдәбият белгечләре, тарихчылардан бигрәк, рәсми политик, идеологик принциплар гаепле. Без бүгенге көн таләбеннән торып элекке карашлары тәнкыйтьләнә торган теләсә кемнең — тарихчымы ул, әдәбиятчымы — эзәрлекләнүен, аннан үч алуны катгый рәвештә инкарь итәбез. Бу сәяси афәтне инде күп кичердек, аның авыр фаҗигале, канлы нәтиҗәләре һәрберебезнең күз алдында.

Кабатлап әйтәм, татар әдәбият белеме алдында зур үзгәрешләр тора. Әмма бу үзгәртеп коруга 1937 елларындагы кебек тулы бер буын кадрларын физик яктан юк итү, торгынлык елларындагы шикелле мораль яктан кысу, рәнҗетү, рәсми идеологик тышауларда тоту рәвешендә түгел, демократия, фикер иреге, фәнни караш хокукы, үзара бәхәсләшү, аңлашу, уртак фикергә килү юлы белән барырга кирәк.

Ниһаять, ахырдан тагын бер мәсьәләгә тукталып үтәргә тиеш саныйм. Югарыда бәян кылган фикерләремнән соң сорау туарга мөмкин.

Ә боларны эшләү, башкарып чыгу өчен бездә җитәрлек гыйльми куәт бармы, кадрлар белән тәэмин ителү ни хәлдә?

Бу табигый, законлы сорау.

Җавап кыска булыр: әлбәттә, җитәрлек түгел, мәсьәлә бик, бик кыен тора. Бездә моңа кадәр дә бердәнбер фәнни гуманитар институт башка союздаш республикаларда берничә институт башкарган эшне эшләп килде.

Татарстан Фәннәр Академиясен төзү беренче нәүбәттә гуманитар фән оешмаларын арттыруны, 4—5 яңа институт ачуны күздә тота. Һичшиксез, әдәбият институты булырга тиеш. Кайберәүләр фикеренчә, бәлки ул әдәбият-сәнгать институты булып формалашыр. Ул институтта җитәрлек санда хәзерлекле кадрлар — фән докторлары һәм кандидатлары булырга тиеш. Бу җәһәттән, татар әдәбияты буенча докторлык диссертациясе яклау советын гамәлгә кую гыйльми көчләргә булган ихтыяҗны канәгатьләндерүдә зур роль уйнаячак.

Алда безне зур перспективалар һәм шуңа мөнәсәбәттә зур эшләр көтә. Әдәбият фәне өлкәсенә килгән һәм киләчәк яшь көчләр кыю фикерләре, намуслы, әхлаклы максатлары белән яңа гыйльми үрләр яуларлар дип ышанырга тулы нигез бар. Республикабызның фәнни потенциаль мөмкинлеге моңа ачык дәлил.

## Нажар Нәҗми

# ГОМЕРНЕҢ ДӘВАМЫ

### Гүзәл гамь

Мәшһүр шагыйрь Хәсән Туфан вафатыннан соң ун ел үткәч чыккан, моңарчы басылмаган шигырьләр китабы «Гүзәл гамь» дип исемләнгән... Бу исемне күргәч тә мәшһүр халык җырының «Исеме матур, кемнәр куйган...» дигән сүзләре искә төшә.

Әйе, моңача басылмаган шигырьләр... Элек чыккан китапларда, бигрәк тә сайланмаларында шагыйрьнең шигырьләре кулъязмалардан, чыккан китаплардан сайланып төзелгән — сөзеп алынган дигән сүз. Ә бу китаптагы шигырьләре исә сайланганнан калганнары, ягъни сөзелгәннән соң калганнары дигән фикергә килергә мөмкин. Ләкин «Гүзәл гамь»дәге шигырьләрне укыгач, сөзелгәннән соң түгел, ә киресенчә, каймак шигырьләр генә торып калган шикелле тоела. Бу инде, гадиләштереп әйткәндә, чын шагыйрьнең шигырьләрен төрле сортларга аерып булмый дигән сүз.

«Гүзәл гамь»не укып чыккач, күңелдә калган төп тойгы шул: монда шагыйрь үзенең рухы белән, йөрәге һәм уйлары белән, хәтта көндәлек тормышы белән, шигъри халәте белән, бу халәттәге мөнәсәбәтләре белән бөек классиклар белән аваздаш, аларның иҗади йөзен, рухын хәтерләтә. Монда йөздә, рухта да ниндидер илаһи гармония, бердәмлек бар. Шушы юл, шушы алым — әчкерсезлек, хәйләсезлек, ачык күңел, ачык йөз, укучың алдында бер нәрсә дә яшермәү — кеше йөрәгенә иң изге һәм туры юлдыр. Безнең бөек классикларыбыз Пушкин, Лермонтов, Есенин, Тукай да үз укучыларыннан үзләренең иң мөкатдәс тойгыларын яшермәгәннәр. Без аларның кемнәрне сөйгәнлеген, яратканлыгын, кемнәргә карата нәфрәт йөрткәнлеген беләбез. Шул ук Пушкинның Жуковскийга, Чаадаевка, Дельвигка, Анна Кернга багышлап язылган шигырьләре шедеврлар исәбенә керә түгелме соң? Булгарин, Воронцов кебекләргә карата язылган полемик һәм сатирик шигырьләрендәге үткер акыллылык Пушкинны бит икенче яктан да ача, аның тормыш офыкларын киңәйтү белән бергә, иҗатның кара-каршы көрәш икәнен дә, шул ук вакытта иҗади шәхеснең кирәк чагында рәхимсезлеге хакында да сөйли. Бер сүз белән әйткәндә, чын иҗатның кермәгән, күрмәгән, белмәгән урыны юк, һәр нәрсәгә «кысылырга» хакы бар, һәр нәрсәдә эше бар.

Ә Тукай? «Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай — өч йолдыз ул» дигән ялкынлы һәм гадел сүзләрнең аерым шәхескә җавап рәвешендә әйтелгәнен беләбез бит!

Әйе, шигърият күгендә үзеңне йолдыз итеп тоймый торып, Хәсән Туфан кебекләргә «Мәрәкәйләр, әрсез Әпкәләйләр»гә каршы баш күтәрү дә мөмкин түгелдер. Мондый баш күтәрүгә хокук та кирәк, ә ул хокукка ия булуны шигъриятне иман итеп, бөтен тормышың, булмышың, табигатең белән, ягъни җаның-тәнең белән раслау, исбат итү мотлак. Хәсән Туфан менә шуларның барсын да үз иҗаты белән исбат иткән шагыйрь, шәхес. Ул — Пушкиннар, Лермонтовлар, Есениннар, Тукайлар кебек шигъририяттән тукылган җанлы материя. Аның өчен, алда әйткәнемчә, шигърият эн дә өстен иман юк. Аерым кешеләргә төбәлгән шигъри сүзләре дә үз иманы ноктасыннан, кимәленнән барсы да хакыйкать дип раслау да дөрес булмас иде. Шагыйрь буларак та, кеше буларак та, ул ничек кенә әчкерсез, ихлас булмасын, ул — кеше бит әле, әүлия түгел. Мәсәлән, татар шагыйрьләре арасында аның яратмаган, хәтта җене сөймәгәннәре дә бар иде. Алар хакында миңа ачыктан-ачык сөйләгән чаклары булды. Ләкин ул иҗатчыларны мин бөтенләй үк талантсызлар дип исәпләмәс идем һәм шуны тойдым: ул шагыйрьләр үзләрендә шигъри көч барлыгын тоеп, олкән шагыйрьгә кинә кумадылар. Шуның белән алар, мәсәлән, үз исемнәренә тап төшермәделәр, үзләрен кимсетмәделәр, киресенчә, әхлакый югарылыкта калдылар. Ә бит күсәк күтәрү, йә булмаса уч алыр өчен төрле сәбәпне теләсәң ничек, теләсәң нинди кешедән дә табарга мөмкин.

Әмма ләкин Туфанның шигъриятәге югарылыгын берничек тә инкарь итү мөмкин түгел. Әгәр дә ул:

*Тукайлар, Бабичлар, Такташлар, Мусалар,*
*Кутуйлар, Бурнашлар, Камаллар, йортына*
*Әрсезләр, гарьсезләр, дөм-сукыр тычканнар,*

*Бөҗәкләр ябырыла, абына-сөртенә.*
*Галимҗан абыйлар, Әмирхан өенә*
*Намуссыз, битсезләр өелә,*

— ди икән. «Бу дөрес түгел!» — дип кире кагып кара! Уйлап карасаң, хакыйкать Туфан ягында бит: татар шигъриятендә генә түгел, урыста да, башкортта да шулай. Чүп үләннәрен чәчеп үстергән шикелле хәзер. Алай гынамы, җырдагы «Ат тугарып җигә белми, кызлар сайлаган була» дигән кебек, шигърияттәге сәләтләре бик чамалы икәнен танымый, төшенмичә, үзләрен камил шагыйрь итеп санап, шигырь осталары булып танылганнарны да шигырь язарга, хәтта поэма язарга «өйрәтәләр» һәм үз иҗатларының киләчәктә фаҗигале бетәчәген күз алларына да китермиләр, аңламыйлар. Ә аңлатып кара! Аларга башкасы бирелмәсә дә сөмсезлек ходай тарафыннан чиксез күп бирелгән. Андыйлар хәзер буа буарлык. Алар бер-берсен яклыйлар, аларны бер Туфан гына түгел, хәтта ун Туфан җиңә алмаячак! Ләкин Хәсән Туфан мондый хәлләргә авыз йомып кала алмаган, тыныч калса, ул Туфан да булмас иде.

Туфанчалык — ул чын шигърилек, саф күңеллелек, кешелеклелек, табигыйлек дигән сүз. Әгәр дә ул бер шигырен: «Туктат әле, Нажар, айгырыңны» (икенче бер вариантта «машинаңны»), — дип башлап китә икән, — болар барсы да тормышта булган вакыйга. Мондый самимилек — аның бар шигырьләренә дип әйтерлек хас.

Китапта, чыннан да, конкрет исемнәр бик күп. Әнә шуларның булуы (макталып та, тәнкыйтьләнеп тә искә алынуларына карамастан) шигырьләрне кешелекле, җанлы итә дә инде. Анда татар шагыйрьләренең дә, башкорт шагыйрьләренең дә исемен бик күп табарга мөмкин.

Хәсән Туфанның шигърияттәге иҗади процессны бик тә җентекләп күзәтеп барганлыгы күренә. Мондый үзенчәлек, мондый хәстәрлек, мондый йөрәк белән яну һәркемгә бирелмәгән. Тормышта сирәк очрый торган бер генә мисал: җыентыкка минем «Иртә төшкән кар» дигән шигырем Хәсән Туфанныкы булып кереп киткән. Моның сәбәбен төшендерү авыр түгел. 1960 ел башларында, шул шигырь матбугатта чыккан вакытларда, мәрхүм Гайнан Әмири Казаннан кайткач: «Туфан абыйга синең бер шигырең бик ошаган. Шуны җентекләп анализлап утырды», — дип сөйләгән иде. Бу җыентыкны төзүчеләрнең сүзләренә караганда, шигырьләрне аның архивыннан үз кулы белән язган кульязмалардан сайлап туплаганнар (алар әйтүенчә, кульязмалар берничә папка). Күренә ки, вакытында Туфан агай минем шигырьне башкортчадан татарчага күчереп алгандыр да, соңыннан үз шигырьләре белән буталып, кульязмалары арасына кереп киткәндер. Төзүчеләр минем алда гафу үтенделәр, ә мин әллә ничек бер горурлык хисе кичердем — минем шигырь Туфан хәтле Туфанның шигырьләре арасында, китабында булсын әле!

Бу китап — шагыйрьнең чираттагы китабы да, соңгы китабы да түгел. Аерым кешеләргә турыдан-туры багышланган шигырьләр белән генә аның йөрәккә керә алуы турында сүз алып барсак, ул берьяклы гына булыр иде. Китапта гражданлык тойгылары белән, ягъни ил, халык, дөнья язмышы хакында уйланган, янган шигырьләре дә күп. Гражданлык тойгысы дигәндә Хәким Гыйләҗевның: «Кеше һәм аның шәхси тойгылары турында җырлау гражданлык тойгысыннан читтәмени? Төрле темага язылган шигырьләр — бөтенесе бер йөрәктән чыга бит», — дигәнрәк фикере йөрәккә сеңеп калган. Хәсән Туфанда исә, зур шагыйрь буларак, шәхси яки шәхси түгел дигән төшенчәләрне аерым карау мөмкин түгел. Шәхсилек һәм гражданлык бербөтен булып, бер-берсенә бөтерелеп, тукылып килә.

Менә Тукайга карата язылган дүртьюллык, унбиш сүздән генә торган (юри санадым) шигырь:

*Яшь иде: утыз җиденче*
*Елларда әле бары*
*Илле бер яшьтә генә ил*
*Каршылар иде аны...*

Нәрсә бу? Өстән караганда, еллар һәм кеше яшенең исәбе генә бит! Ә төптә, тирәндә күпме ассоциацияләр — Тукай һәм 1937 ел... Ныграк уйласаң, тәннәрең эсселе-суыклы булып китә. Дүрт юллык шигырь үзе бер роман түгелме соң?

Мондый мисалларны китаптан күпләп китерергә була, әмма аны эшләве мөмкин түгел, шигырьләрнең үзләрен укырга кирәк. Илдар Юзеевка, Роберт Миңнуллинга кушылып: «Туфанны укыгыз. Авыр чакларда да, бәйрәмнәр килсә дә Туфанны укыгыз!» — дип әйтәсе килә.

Шулай да тагын бер шигырьне искә алмый китә алмыйм.

*Әгәр берәр шваль расист*
*Сине эткә саный икән,*
*Я ул синең милли хисненң*
*Яңагына ямый икән —*

*Аның әле бу «холкына»*
*Беразгача түзеп була.*
*Ә ул менә*
*Кайчак синең*
*Ил исменә телен суза...*
*А-а, безнең кан ничек кыза! —*
*Куллар гына түгел, хәтта*
*Нервалар да йомарлана...*
*Дүрт йөз еллык иске гадәт*
*Тешне кысып, җылап димли:*
*— Чыда, чыда,*
*Тагын чыда!*

Соңгы сүзләрне мин: «Чыдар хәл калмады! Чыдау мөмкин түгел!»—дип аңлыйм. «Милли хисләрең сүнмәсен өчен дә, җир-суың, халкың, телеңә булган мәхәббәт янарсын өчен дә Туфанны укы! Укымаганнарны укыттыр!»—дип тагын кабатлыйсы килә.

«Гүзәл гамь» дүрт юллык шигырь белән очлана. Ул 1981 елда язылган. Бу — Хәсән Туфанның иң соңгы шигыре икәнлеген төшенү авыр түгел.

*Тәрәзәдән палатага кереп,*
*Кояш мине тышка чакыра.*
*Бик чыгасы иде дә бит, кояш,*
*Хәл җыясы бар шул чак кына.*

Кызганычка каршы, хәл җыеп палатадан чыга алмады. Китте... Әмма Хәсән Туфанның якты һәм нурлы иҗаты үзе һәрвакыт кояш чыкканны хәтерләтә.

## Шагыйрь сабагы

Хәсән агай Туфанның «Гүзәл гамь» дигән китабында минем исем кертелгән һәм миңа бәйле булган биш шигырь бар: «Миңа инде дөнья үз хикмәтен...», «Ул да яшь иде», «Өч күңел, өч сәлам канатында», «Юл авыр булган саен» һәм «Тик сәлам бу». Шул кадәрле үк игътибарга мин ничек лаек булганмындыр — анысы билгеле түгел. Бу очракта Гомәр ага Бәшировның 1986 елны миңа язган хатындагы юллар, бәлки, моңа ачыклык кертәдер: «Дуслар сайлауда Хәсән мәрхүм һич тә ялгышмый иде, ул исә сине бик якын итте».

Әйе, биш шигырь... Шуларның тәүге өчесендә минем исем искә алынган, ә соңгы икесендә — юк. Шул сәбәпле бу ике шигырь, үзләренең фикере ифрат тирән булуларына карамастан, һавада эленеп кала шикелле. Мисалга «Юл авыр булган саен» дигән шигырьне алыйк.

*Татарча әйтсәң гендер*
*Чамалап була аны:*
*Сездә дә бардыр гомернең*
*Җиде төн урталары.*
*Болытсыз төннәр түрендә*
*Сез — Тимерказык сыман!*
*Мин сезгә багып-чамалап*
*Азимут язып куям.*
*Уятып, уйландырып сез*
*Кәрванны, туганнарым,*
*Яктырак яна барасыз,*
*Юл авыр булган саен!*

«Сез» кемнәр алар? Бу шигырь, миңа алтмыш яшь тулган көннәрдә «Кызыл таң» газетасы редакциясенә фототелеграмма аша җибәрелгән иде. Телеграмма соңга калып килү сәбәпле, газетада урын ала алмагач, редакциядә эшләүчеләр аны, истәлек итеп, миңа биргәннәр иде. Телеграммада шундый кереш сүз бар: «Башкортстан һәм Татарстан әдәбиятында балкып яшәгән энеләрем, сеңелләрем бар. Алар — Бәшир, Сибгат, Мостай һәм син, Нәҗар. Бусы менә Бәйрәмең көннәрендә синең янына юнәлә».

Күрәсез ки, телеграммадагы шигырьнең беренче строфасындагы «шигырьләп» дигән сүзе «татарча»га, «синең дә бардыр иҗатта» дигән юл «сездә дә бардыр гомернең» дип алмаштырылган. Фикер һәм образ тирәнәйгән — бу инде Хәсән ага Туфан-

ның шигырь өстендә ничек эшләгәнен, һәрбер сүзнең образлы салмаклыгын үтә тирән тоеп эш иткәнен күрсәтә.

Хәсән Туфанның шушы иҗади үзенчәлеген, шагыйрь хезмәтенең ниндидер бер серле процесс икәнлеген аерым бер үрнәктә — «Тик сәлам бу» дигән шигырь мисалында җентекләп күрсәтеп китмәкче булам. Башта ул исемсез булып, миңа телеграмма аша килде. Менә ул.

*Кадерле Нажар!*
*Тарихтагы кашка тауларның*
*Түбәсендә — ташсыз каберләр.*
*Безгәчә дә килеп киткәннәр,*
*Бездән соң да килер дәверләр.*
*Ияргәнне түгел, әле дә*
*Ияртkәнне хәтерли заман.*
*Арка куеп түгел давылга,*
*Күкрәп керү хәерле һаман.*
*«Кабы чего...» дия белмисең,*
*Каналсаң да көбә кимисең.*
*Ил бәгъренең ораны булып*
*Гамьсезләргә тынгы бирмисең.*
*Сәлам генә әле бу синең*
*Кылганыңа, кылачагыңа,*
*Нафталинсыз хиснең, фикернең,*
*Яшен булып яшьнәп яшәүнең*
*Нәкъ Тукае булган чагыңа.*

*Өчегезгә дә бәйрәм сәламе белән — Хәсән*
*05. II. 73 Казан.*

Яшерен-батырын түгел, мондый мактау сүзләре минем күңелемнең йомшак урыннарына кагылып, йөрәккә рәхәт булып калса да, ниндидер икеләнү тойгылары кичердем. Һаман да кичерәм, чөнки, чын күңелдән әйтәм, мондый ук мактау сүзләрен күтәрү миңа авыр. Теге чакта да: «Хәсән агай Туфан минем хакта арттырып җибәрмиме?» — дип уйлап куйдым. Һаман да шулай уйлыйм. Бәлки, бу бергә кайнашып яшәмичә, еш күрешмичә, иҗат белән генә очрашып яшәүдән дә (белмим, нәрсәдәндер инде) килгәндер. Мине фәкать шул тынычландыра: мин боларның берсен дә сорап алмаганмын, шулай итәргә аңа, кайберәүләр шикелле, «тишмәгәнмен». Бу аның фәкать үз җанының авазы, үз ихтыярының җимеше.

Кабатлыйм, бу шигырьне фәкать шигъри әсәр ничек эшләнгәнен, шигырьне камилләү сабаклары ничек, ни рәвешле булганын күрсәтү өчен генә мисалга алам. Хәзер инде шигырь эшләнеше ачыктан-ачык күренеп торсын өчен аның икенче (шартлы рәвештә) вариантын, китапта басылып чыкканын, чагыштырып карау өчен, тулы килеш монда күчерәм.

## Тик сәлам бу

*Тарихтагы канлы тауларның*
*Түбәсендә ядкарь каберләр.*
*Өсләрендә — гамьсез әремнәр...*
*Монарчы да килеп киткәннәр,*
*Моннан соң да килер дәверләр.*
*Ияргәнне түгел, әле дә*
*Ияртkәнне хәтерли заман.*
*Артка куеп түгел, давылга*
*Күкрәп керү хәерле һаман.*
*Ексалар да, тора да баса,*
*Турая да чәчәк ата бит.*
*Лев Толстой агабызны да*
*Сокландырган чая татарник!*
*Җан — яланбаш, рухың — ап-ачык*
*Кыйналсаң да, көбә кимисең.*
*«Кабы чего...» дия белмисең,*
*Ил бәгъренең ораны булып,*
*Гамьсезлеккә тынгы бирмисең.*
*Сәлам генә әле бу синең*
*Көчле, дәртле, моңлы җаныңа;*
*Нафталинсыз хиснең, фикернең,*
*Яшен кебек яшьнәп яшәүнең*
*Тукайчысы булуларыңа.*
*Тарихтагы юллар буенда*
*Таш билгеләр — ядкарь каберләр,*
*Безгәчә дә килеп-киткәннәр,*
*Бездән соң да килер дәверләр.*

Бер карауга, беренче вариант белән икенче вариант арасында аерма бик күп тә түгел шикелле, әмма күләм ягыннан гына караганда да 17 юллык шигырь 27 юллыга әйләнгән. Хәсән Туфан кебек шагыйрьгә ун юл өстәүнең нидер торганы ап-ачык.

Хәзер инде ике вариантның да беренче строфаларын алып карыйк. Беренче вариантта:

*Тарихтагы к а ш к а тауларның*
*Түбәсендә — т а ш с ы з каберләр.*
*Безгәчә дә килеп киткәннәр,*
*Бездән соң да килер дәверләр.*

Икенче вариантта:

*Тарихтагы к а н л ы тауларның*
*Төбәсендә — я д к а р ь каберләр.*
*Өсләрендә — гамьсез әремнәр,*
*Моңарчы да килеп киткәннәр.*
*Моннан соң да килер дәверләр.*

Күрәсез: дүрт юллык строфа биш юллык булган — «Өсләрендә гамьсез әремнәр» өстәлгән һәм ул үзе никадәр күзгә ташланып торган, тирән мәгънәле образ. «Кашка таулар» — «канлы таулар»га, каберләр исә «ташсыз» дан «ядкарь»гә әйләнгәннәр. «Безгәчә дә», «бездән соң да» дип әйтүләр «моңарчы да», «моннан соң да» белән алмаштырылган. Шулай ук «Ексалар да, тора да баса» дигән юллар белән башланып киткән строфа өстәлгән. Бу строфада нинди фикер ятканын, шигырьнең төрле яклап тирәнәя төшкәнен әйтеп торасы да юк.

Тәүге варианттагы өченче строфага: «Җан-яланбаш, рухың ап-ачык!» дигән юллар өстәлгән һәм үз нәүбәтендә беренче һәм икенче шигъри юллар урыннарын алмаштырганнар. Нигә? Анысы инде шигъри сизгерлектән, шагыйрь осталыгыннан килә.

Шулай ук соңгы строфаның «кылганыңа, кылачагыңа» дигән икенче юлын «көчле, дәртле, моңлы җаныңа» дип һәм соңгы юлындагы «Нәкъ Тукае булган чагыңа» дигәне «Тукайчысы булуларыңа» белән алмаштырыла. «Кылганың», «кылачагың», күрәсең, остага бик гомуми күренгәндер, ә сәламне «Көчле, дәртле, моңлы җанга» җибәрү күпме ачыклык, конкретлык өсти. Шулай ук «Тукае булу» белән «Тукайчысы булу»да күпме аерма!

Хәзер инде бу шигырьнең өченче варианты турында сүз алып барырга тиешмен. Аның иң соңгысы булуында шик юк. Хәсән агай аны папкасыннан алып, миңа бүләк итте. Димәк бу вариант аның үзендә калмаган, дип тә әйтергә мөмкин. Аны ул миңа Уфада, «Россия» кунакханәсендә бүләк иткән иде кебек, шул хакта истәлекләремдә дә язып чыктым. Әмма кульязма битенең почмагына: «Хәсән абый бүләге. Казан. 14. 1. 77» дип язып куйганмын. Истәлек язган чагымда бу кульязманы алып карамаганмындыр, күрәсең. Менә ул вариант:

## Тик сәлам бу

Н. Нәҗмигә

*Яктырак йолдыз янадыр.*
Г. Тукай.

*Тарихтагы кашка тауларда*
*Уйчан, сабыр, ялгыз каберлар.*
*Өсләрендә — гамьсез әремнәр...*
*Безгәчә дә килеп киткәннәр.*
*Бездән соң да килер дәверләр.*
*Ияргәнне түгел, әле дә*
*Ияртмәнне кадерли Заман —*
*Арка куеп түгел Давылга*
*Күкрәп керү хәерле һаман.*

*Ексалар да тора да баса.*
*Турая да чәчәк ата бит.*
*Лев Толстой агабызны да*
*Сокландырган чая татарник!*

*Җан — яланбаш, рухың ап-ачык!*
*Каналсаң да — көбә кимисең*
*Ораны син шигырь бәгъренең:*
*Гамьсезлеккә тынгы бирмисең.*

*Тик сәлам бу — бездән, Казаннан*
*Көчле, дәртле, моңлы җаныңа.*
*Йолдыз булып янып яшәүнең*
*Тукайчысы булуларыңа.*
*Тарихтагы юллар буенда*
*Таш билгеләр, ядкарь каберләр.*
*Безгәчә дә килеп киткәннәр,*
*Бездән соң да килер дәверләр.*
*1973.*

Бу вариантның тышкы яктан күзгә чагылганы шул: шигырь 27 юллыдан 25 юллыга калган, адресаты ачык һәм Тукайдан эпиграф та алынган.

Шигырьнең эченә кереп китсәк, икенче вариант белән моның арасында да байтак аерма күрәбез. Сүзне тагын беренче строфадан башлыйк һәм аны тулысынча алыйк. Китапта басылган вариантта:

*Тарихтагы канлы тауларның*
*Төбәсендә — ядкарь каберләр.*
*Өсләрендә — гамьсез әремнәр...*
*Моңарчы да килеп киткәннәр,*
*Моннан соң да килер дәверләр.*

Соңгы вариантта:

*Тарихтагы кашка тауларда*
*Уйчан, сабыр, ялгыз каберләр.*
*Өсләрендә — гамьсез әремнәр...*
*Безгәчә дә килеп киткәннәр,*
*Бездән соң да килер дәверләр.*

Игътибар итегез: икенче варианттагы «канлы тау» «кашка тау»га әйләнгән, шагыйрь иң беренче вариантына кире кайта, ә кайбер сүзләр исә строфаның икенче юлында «уйчан, сабыр, ялгыз»га әйләнәләр. Каберләргә кешегә хас сыйфатлар бирелә: монда халыкның үткәне, холкы, үзчәнлеге чагыла — бу могҗиза түгелме соң?

Бүгенге көндә исән булса: «Хәсән абый, «ялгыз каберләр» — не «канлы каберләр» дип алмаштырып булмасмы? «Тау» алдыннан «кан»ны алып ташлагансың бит»,— дип сорар идем. Кем белә, бәлки килешкән дә булыр иде. Ә үз вакытында шундый сүз алып барырга күп нәрсә җитмәгәндер шул инде.

Строфаның дүртенче һәм бишенче юлларында шагыйрь иң беренче вариантына кайта: «моңарчы да»ны «безгәчә дә» ди. Монда кешенең, шәхеснең роле күтәрелә, аның югарылыгы сызык өстенә алына — бу классик алымнарның өлгесе.

Күренүенчә, «Иярганне түгел, әле дә» дип башланган икенче строфа бөтен вариантларда да үзгәртелми килә дип әйтерлек, чөнки бу — шагыйрьнең кредосы. Әмма ләкин соңгы вариантта шулай да бер сүз — «хәтерле» сүзе «кадерле» белән алмаштырыла. Кадерле заман! Бер сүз, бары бер сүз, ә нинди тирән мәгънәлелеккә, иҗтимагый яңгырашка алып килә! Сүзне таба белү, аны үз урынына куя белү тылсымы — шагыйрьне шагыйрь итүнең бер сереДер. Шагыйрь үз-үзенә шундый таләпчән ки, тора-бара:

*«Как бы чего» дия белмисең*
*Ил бәгъренеңораны булып*

— дигән юлларны алып ташлап, аларны:

*Ораны син — шигырь бәгъренең*

— дигән бер юл белән алмаштыра һәм «шигырь бәгъре», «шигырь җаны» дигән бер ачышны күз алдына бастыра.

Аннары соңгы вариантның беренче строфасына игътибар итик. Монда да:

*Нафталинсыз хиснең, фикернең,*
*Яшен кебек яшьнәп яшәүнең,*

— дигән ике юл алып ташлаган да, алар:

*Йолдыз кебек янып яшәүнең,*

— дигән бер юл белән алыштырылган. Монда Тукайның «Яктырак йолдыз янадыр» дигән сүзләре ярдәм иткәндерме, әллә «йолдыз кебек янып яшәүнең» дигән фикер Тукай шигыреннән эпиграф алырга өндәгәнме — икесе дә булуы мөмкин. Әмма бөтен мәсьәлә шунда: шул уйланулардан, эзләнүләрдән соң шигырь ни эшли? Әйтик, шул ук строфаның беренче юлындагы «сәлам генә әле бу синең» дигән сүзләр урынына «тик сәлам бу бездән, Казаннан» дип әйтү шигъри юлларны ничек тыгызлый, конкретлаштыра.

Хәсән ага Туфан, өстә әйткәнемчә, бу шигырьне 1977 елда бүләк иткән, ә шигырьнең тәүге язылу вакыты 1973 ел. Дүрт ел ара. Димәк, шагыйрь әнә шул дүрт елның кайсыдыр айларында, көннәрендә, минутларында шул шигырьгә әйләнеп-әйләнеп кайткан — эшләгән, уйланган.

Шигырь язуның ачысын-төчесен татымаган кешеләр өчен Хәсән Туфанның шигырь өстендә эшли-эшли шулкадәр интегүе (бу сүзне кулланудан һич тә тартынмыйм, чөнки шигырь язу чын мәгънәсендә интегү — тик бу интегүдә көчәнү генә сизелмәсен — иҗади бәхеткә, шатлыкка ирешү өчен бәхетле, шатлыклы интегү) ул бераз ят та тоелыр, әмма ул интегү шундый табигый! Димәк, шагыйрь гомере гел шулай, гел шундый — эзләнү халәтендә.

Иҗатка, шигырьгә таләпчәнлегендә шагыйрь яшьлектә дә, картлыкта да бер булгандыр дип уйлыйм. Бу таләпчәнлек күпләребезгә зур сабак.

# БОЛГАНЧЫК ЕЛЛАР АВАЗЫ

## I

Мисыр мөселман яңарышын рухландыручы Мөхәммәт Габдуһ (1849—1905) бер вакыт болай дигән: «Сәясәт катышкан нәрсә исән калмый» («Шура», 1915, № 23, 732 бит).

Әйе, әдәбиятка сәясәт катыштымы, ул — исән калмый. Безнең гасырның утызынчы еллар татар әдәбиятының да хәленә җитүенә сәбәп әнә шул: менә нәкъ шул елларда әдәбият, әдәби процесс белән ВКП(б) Өлкә Комитеты командалык итә башлый.

Сталин идарәгә килүнең беренче елларында ук ВКП(б) җитәкчелеге язылыларны боеру вазифаларыннан мөмкин кадәр читләштерергә, ә ахырда физик яктан кырырга, бетерергә тотынды. ВКП(б) Үзәк Комитетының бюро составын, дәүләт җитәкчелеген карасаң, анда ярым-йорты белемле кешеләр халык алдында идеологик эш алып бара. Сталин, Калинин, Ворошилов һ. б. Болар ике-өч класс белемнәре генә барлыгын «онытып», язучыларны ничек язарга, композиторларны ничек көй иҗат итәргә өйрәтә башлый. Зыялылардан Сталин чорында гына түгел, Хрущев заманында да курыктылар.

Коммунистлар партиясенең бөтен сәясәтен коррупциягә әйләндергән Брежнев та зыялылардан курка иде. Хәтерлисезме? 70 елларда партиягә кабул итүнең нормаларын билгеләделәр: тугыз эшчене алгач кына райкомнар бик сыкранып партия сафына уныньчы кеше — укымышлыны алалар иде. Партия сафларына — эшчеләрне! Лозунг шул иде. Ә эшченең станок янында басып торасы, машина йөртәсе, урман кисәсе, күмер чабасы бар. Идеологиягә катнашырга аның вакыты калмый — җитәкчелек өчен нәкъ менә шул кирәк тә...

## II

«Әдәбиятта, язучы кадрлар арасында эшчеләр катламын көчәйтергә!» Утызынчы елларда ВКП(б) Үзәк Комитеты әнә шундый юл күрсәтте. Татарстан Өлкә Комитеты җитәкчеләре исә бу көрәшкә җиң сызганып ташланды.

Шул максаттан чыгып, 1930 елда «Атака» журналы чыгарыла башлады. Татар телендә чыккан бөтен газета-журналларда матур әдәбиятка һөҗүм көчәйтелде. Бу өлкәдә бигрәк тә «Чаян» журналы дәртен күрсәтте. Партия Өлкә Комитетының беренче секретаре Разумов матбугатта, пленум-конференцияләрдә даими рәвештә татар әдәбияты мәсьәләләрен кузгатып торды. Аның чыгышларында төп ике тезис ярылып ята иде: 1. Үткәндәге әдәби мирасны (Тукай, Дәрдемәнд һ. б.) бастырып чыгарганда марксистик күзлектән чыгып эш итәргә. 2. Татар язучылары арасында эшче-крестьян катлавыннан чыккан кешеләр санын күбәйтергә.

Һәр ике тезистан бик күп нәрсә ачылмаган кое кала иде: Тукай, Дәрдемәнд әсәрләрен бастырганда марксистик күзлектән карау хосусан нәрсә ул? Әдәбиятка эшчеләр, крестьяннар түгел, бары тик иҗат итәргә сәләте булган талантлы кешеләр генә килергә тиеш бит инде. «Әдәбиятка — эшчеләр» лозунгысы матбугат битләрендә үзен тиз сиздерә. Дәрдемәнд, Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ф. Кәрими, Г. Исхакыйлар тудырган нәфис әдәбият урынына тупаслык, гайбәт, сүгенү, аламалык, шапшаклык керен тула. Шул атмосферада татар язучылары арасында идән асты контрреволюцион «Җидегән» оешмасы турында хәбәр тарала. Һәм шуннан соң әдәбият бетеп, аның урынын әләкләр, бер-береңне сатып, үзең исән калу турында кайгыртулар, җыелышлар, чистартулар кебек җәзалар комплексы хутка җибәрелә.

«Җидегән» оешмасы турындагы беренче сигнал Ф. Мөбәрнең «Кызыл Татарстан» газетасында (1930, 19 август саны) басылган мәкаләсе аша була. Автор анда шагыйрь Т. Ченәкәйнең һәм Г. Карнайның редакциягә килгән хатларын урнаштыра. Т. Ченәкәй әлеге хатында элек «Җидегән» дә торганлыгын икърар итә һәм тәүбәгә килгәнлеген әйтә. Гали Карнай исә Кутуйга адреслаган хатында болай ди: «Ченәкәйне ул оешмага алганчы башта үземә әйткән булсагыз, мондый хурлыкка калмаган булыр идек».

Мәкалә авторы Ф. Мөбәр боларның икесен дә гаепли: берсен тәүбә иткәне, икенчесен бу оешмага керәсе килеп калганы өчен... Һәм нәтиҗә ясый: «Тиздән бу оешманың төбен — тамырын актарырга кирәк».

«Кызыл Татарстан»ның 27 август санында инде татар язучыларының «Җидегәнче»ләргә протесты басыла. Протестка Ф. Мөсагыйть, Мөбәр, Һ. Такташ, М. Әмир, Ф. Кәрим, И. Гази, Х. Туфан, Л. Гыйльми, Г. Иделле, Н. Баян, И. Хәйруллин, С. Каратай, Р. Ишморат, Т. Госман кул куялар.

«Җидегән» исеме, имеш, аның составында җиде язучы булганга күрә бирелгән. Ләкин канга сусаган журналистлар, партия эшлеклеләре, «без — эшчедән чыккан» дип күкрәк киереп шигырь, роман язган булып йөргән талантсызлар җиде белән генә канәгатьләнергә теләмиләр. «Без — пырлитар язучылары»,— дип күкрәк сугып йөргән урта кул язучы Л. Гыйльми, мәсәлән, аларның санын тугызга җиткерә: Гали Рәхим, Н. Исәнбәт, Төхфәт Ченәкәй (псевдонимы — Сәмави), Мәхмүт Бөдәйли, Ф. Бурнаш, С. Кудаш, Н. Гальгаф, Г. Минский, С. Агиш («Кызыл яшьләр» журналы, 1931, № 2). Кайбер өлкәләрдә бу исемлеккә журналист Закир Галине дә кертәләр.

1930 елның 31 августында ТАПП (Пролетар язучыларының Татарстан ассоциациясе)ның гомуми җыелышы булып, анда бик иркенләп «җидегәнчелек» мәсьәләсе тикшерелә һәм «тиешле» карар кабул ителә. Төп докладчы Гомәр Гали була. Җыелышта Т. Ченәкәйнең «Башкортстан», Ф. Мөбәрнең «Кызыл Татарстан» газеталарындагы мәкаләләре, Г. Кутуйларның аңлатма язулары тикшерелә. Җыелыш мондый резолюция кабул итә (кыскартып бирәбез — авторлар):

1. Идән асты әдәби оешмасы булган «Җидегән», чыннан да, 1929 елның җәендә Өфедә оешкан һәм үзенең тәэсирен Казанга да тарата башлаган. «Җидегән»нең инициаторлары Ченәкәй, Н. Исәнбәт, Г. Кутуйлар булган.

2. Фаш ителгән «Җидегән» үзенең формасы һәм алдына куелган бурычлары буенча матур әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә турыдан-туры партия сәясәтенә каршы юнәлтелгән, пролетариат әдәбиятына ачыктан-ачык дошман оешма булып тора.

ТАПП һәм пролетар җәмәгатьчелек «Җидегән»гә рәхимсез, хәлиткеч отпор бирергә, бу оешма һәм аның әгъзаларының чын сәяси физиономияләрен бөтен совет җәмәгатьчелеге алдында фаш итәргә тиешләр.

3. «Җидегән»нең эшчәнлегендә сәяси төс булуны Кутуй һәм Минский инкяр итсәләр дә, ТАПП боларның «Җидегән»дә эшләүләрен, бу мәсьәләдә Кутуйның сәяси икейөзлелеген аерым билгеләп үтә.

ТАППның гомуми җыелышы Кутуй һәм Минскийны татар пролетар язучыларының ассоциациясеннән чыгарырга кирәк дип таба.

4. ...ТАППның гомуми җыелышы эштә соңгы вакытта байтак зур кимчелекләр булганын билгели. Бу бигрәк тә түбәндәгеләрдә күренә:

а) Матур әдәбиятта «Җидегән» йогынтысына каршы эшнең йомшак булуы;

б) ТАППның төп составын яңа кадрлар, эшче яшьләр арасыннан выдвиженецлар белән көчәйтү буенча җитәрлек эшләмәү;

в) Сугышчан пролетариат әдәбияты рухында эшче язучы яшьләрне тәрбияләүгә игътибарның җитәрлек булмавы;

г) ТАПП җитәкчелегенең татар язучыларының төп массасыннан аерылуы һәм үз эченә бикләнгәнлеге:

Гомуми җыелыш ТАППта партия җитәкчелеген көчәйтү кирәклеген билгели.

5. Җыелыш ТАПП составына предприятиеләрдән күбрәк эшче-яшьләрне тартырга, эшчеләр массалары арасында «Җидегән» турында докладлар укырга, ТАПП сафлары арасында чистарту уздырырга, «Җидегән» турында татар һәм рус матбугатында материаллар бастырырга кирәк дип таба.

6. Н. Исәнбәтнең БАПП та исәптә торганлыгы турында әйтеп язган гаризасын искә алып, гомуми җыелыш бу турыда Башкорт пролетар язучыларының ассоциациясенә җиткерергә кирәк дип таба. (Татарстан партия архивы, 292 фонд, 1 тасвирлама, 1009 төпләм, 53 бит. Әлеге хезмәтебездә бары тик шушы архив материаллары гына файдаланганлыктан, алга таба бу чыганакның исемен кыскартып бирербез — авторлар).

Җыелышта, Г. Минскийның хаты нигезендә, Сафа Борһанның да «Җидегән»гә мөнәсәбәте барлыгы ачыла. Җыелыш С. Борһанның бу эшен киләчәктә тикшерергә, ТАПП идарәсендә пассив эшләвен исәпкә алып, аны идарә әгъзасыннан чыгарырга дип карар кабул итә. (Шунда ук, 50 бит).

## III

Нинди нәрсә ул Г. Минский хаты? Нигә бик еш телгә алына ул? Бу хат «җидегәнчелек эше»нә байтак ачыклык һәм шуның кадәр үк буталчыклык та кертә. «Җидегәнчелек»кә кагылышлы документлар арасында бу хат иң озыны, шуңа күрә без аны бераз кыскартып бирергә мәҗбүрбез. Ул «Кызыл Татарстан» газетасының редакторы исеменә 1930 елның 20 августында язылган.

*«1928 елда мин Г. Кутуй белән әдәби сәяхәт ясап, Уфага барып кайттык. Уфада кичә уздырылды. Уфаның әдәби көчләре белән аерым иптәшләр, очрашу тәртибендә булган сөйләшү-фикер алышуларда сизелерлек булып сызылган бу фикер куәтләнде: ул да булса, без язучыларның оешып җитә алмавыбыз, бер-беребез хәбәрләшеп тора алмаучылык кеби зарлар нәтиҗәсендә бу фикер үзенә күрә бер «приключенческий» төс алып, «Җидегән» дигән бер төркем төзүгә кадәр килеп җитте. Бигрәк тә бу эшкә шагыйрь Ченәкәй аерым бер дәрт, теләк белән зәвыксенде, һичшиксез, бу — «Җидегән»нең кирәклеген көчәйтте.*

*Әнә шуннан башлап «Җидегән» төзелде. «Җидегән»гә мин белгән биш иптәш керде (Ченәкәй, Кутуй, Н. Исәнбәт, Г. Минский, Сәйфи Кудаш). Калган икесе турында, шуңар лаеклы булган «Җидегән»гә ярарлык кешене табу дигән фикер кузгалды. Бу фикер буенча Уфа шагыйре С. Агишнең кандидатурасы күрсәтелүен дә хәтерлим. С. Агишнең «Җидегән»гә керүе, эшләве турында моңар кадәр бернәрсә дә белмим. ...Оештыру эше тәмамланды, без кире Казанга кайттык. Мәсьәләнең тарихи ягын чуалтмас өчен, Уфада уздырылган киңәшмәдә Мәскәү язучысы Г. Ильяс катнашуын әйтеп китәргә кирәк. Ләкин Г. Ильясның «Җидегән»гә һичбер төрле дә катнашы булмады һәм ул аның турында белә дә алмады».*

Бу — ачыш! Без, 1957 елдан бирле, С. Батыевның Татарстан урта мәктәпләрендә тарих фәне укытучыларның семинарында ясаган чыгышына ышанып яши идек. Ул анда болай дип әйткән иде: «Без тикшереп карадык, бернинди «Җидегән» булмаган, бу — уйдырма, бу — язучыларны кырыр өчен генә уйлап табылган бер легенда...»

Г. Минскийның хаты исә моны — С. Батыев фикерен инкяр итә, утызынчы елгы версияне раслый. Бу безне, тикшеренүчеләрне, бик кыен хәлгә куя. Г. Минский теге чорда «Кызыл яшьләр», «Авыл яшьләре» журналларында эшли. Бу журналларда Кутуй, Исәнбәт, Кудаш шигырьләре басыла. Боларны басу, ди Г. Минский, «Җидегән» принцибында түгел, «бәлки, басарга яраклы шигырьләр булулары өчен басылган шигырьләр. Ләкин, шулай да булса, моның нигезендә пассив хәлдә булса да, «җидегәнчелек» энергиясе булуын бу урында яшереп булмас».

Г. Минский, ахыр нәтиҗәсен һич тә күз алдына китермичә, «Җидегән»нең ф а к т т а б у л у ы н раслый. Ә җәзага сусаган Сталин бөркетләренә шул гына кирәк: «оешманың» де-юре һәм де-факто яшәвен тану. Дөрес, тәҗрибәсез Минский әйтергә теләми: монда бернинди «анти» юк, бу — болай гына... Ләкин утызынчы елларда акны кара итеп күрсәтү караны ак итеп күрсәтүгә караганда җиңелрәк иде. Г. Минский хаты нәтиҗәсендә әнә шундый сәяси платформасы бөтенләй булмаган, рәсми яктан да формалашмаган, ләкин инде матбугатта сәяси төс алган бу оешма турында сүз китә. «Караңгы төн уртасында караңгы бүлмәдә кара мәчене, бигрәк тә ул анда булмаса, тоту бик кыен». Кайсыдыр халыкта, гарәпләрдәме икән, шундый әйтем бар.

Ләкин, шулай да... «Җидегән»нең бөтен трагедиясе Г. Минский хаты аркасында дип уйларга тулы нигез бар. Ул болай яза:

*«Җидегән» оешмасы о е ш т ы р ы л с а д а (курсив безнеке — авторлар), ул мине үзенә якынлаштыра алмады. Киресенчә, мин ул вакыттагы яшьләр матбугатында күренә башлаган сәламәт булмаган күренешләрдән качарга һәм сыйнфый тәрбия ала алмаганда богемачылык күренешләренә кереп буталуларга да мөмкинлекләр бар иде. Шуңар күрә дә мин Кызыл гаскәр сафына китәргә ашыктым һәм шул ук елны өч айдан соң ук Кызыл гаскәр сафына алындым. Шуннан соң «Җидегән» төсендә моңар кадәр бернәрсә дә белми идем, хәтта, онытkан да идем, чөнки, «Җидегән» ул үз әсасында (нигезендә) сәяси бер зур төс бирү аркасында түгел, бәлки, җ и ң е л ч ә г е н ә әдәбият мәйданында була торган каләмдәшлек, дуслык г р у п п а ч ы л ы г ы тәртибендә оештырылган иде» (ассызык безнеке — авторлар).*

Рәхмәт төшсен атабыз Сталинга, «җидегәнче»ләрне аттырып бетермәгән өчен. Әлбәттә, шунысы кызык: бу исемлеккә кергән язучыларның кайберләре төрмә күрми. Тырышып-тырышып бу исемлектән чыккан С. Борһан һәлак була. Хәер, «Җидегәнче»ләр исемлеге — әдәбият тарихындагы иң төгәлсез исемлек.

*«Минем бер гаебем бар,— дип дәвам итә Г. Минский.— Ул да булса, «Җидегән» турында матбугатта аның й ө з е н а ч ы п (димәк, идеологик диверсия булган? Курсив безнеке — авторлар) ташламау. Бу урында укучылар бәлки гаҗәпләнерләр дә... Ни өчен соң «Җидегән» соңгы вакытта зур төс алды? Ул миңа болай: Ченәкәй совет язучыларының оешмасында член иде. Чистарту вакытында Ченәкәйне чыгардылар. Ни өчендер (бәлки Ченәкәй матбугатта әйтер) Ченәкәй ул вакытта ук Кутуй белән ераклашкан иде һәм аерым бер дошманлык сакларга тырышкан кебек сизеләдер иде. Кутуйның ТАПП члены булуы турында дәгъва күптән башланган иде. Ченәкәй дә әнә шул дәгъвага кушылып, Кутуйга каршы барырга башлады. Моның өчен ул «Җидегән»нең оешмасын казып чыгарып, аңа зур төс бирергә тырышып Уфада матбугатка хат белән чыкты. Бу — Ченәкәйнең үзенә күрә бер тактикасы иде. Хат белән чыгуга кадәр Ченәкәй Уфада «Җидегән»нең яшәве турында татар пролетариат язучыларының берсенә сөйләгән...*

*«Җидегән»гә бүген ничек карарга кирәк?*

*Бу мәсьәлә бик мөһим һәм мәсьүл мәсьәлә. Әгәр дә без «Җидегән» турында аңар бөтенләй юк дәрәҗәсендә бәя биреп, йә аны «балалык» дип атасак, бу — сәяси хата. Без моның белән фәкать совет дөреслегеннән күз йому, партиянең сыйнфый көрәштәге юлын йомшарту... буржуазия тегермәненә су түгү булып чыгар иде. Шуңар күрә дә бу урында «пролетариат диктатурасы дошманнары гына ачыктан-ачык советларга каршы барырга мөмкинлек булмаган-*

*да ғына яшерен рәвештә эшләргә керешәләр» (Ф. Мөбәр мәкаләсеннән — авторлар), дигән аргумент бик дөрес һәм мәсьәләгә большевикларча карау тәртибендә әйтелгән бер сүз дип табып, «Җидегән»нең хөкеменә булачак приговорның беренче нигез сүзе шул булырга тиеш, дибез. Хәзерге көндә «Җидегән» мәсьәләсе кузгалу уңае белән аңар төс бирмәскә, аны бөтенләй йомшартырга теләүче иптәшләрнең барлыгы сизелә».*

Кыскасы, Г. Минский җиде-сигез язучының муенын бүкәнгә салырга чакыра. Хатта алга таба Татар театрындагы зарарлы идеология турында сөйләнә, театрның тотнаксыз әсәр «Пикүләй Шәрәфи»не куюы (Н. Исәнбәт) гаепләнә. «Бу әсәрне репертуарга алуда Кутуйның катнашы булды». Алга таба Р. Ишморатның «Данлы чор» әсәрен сәхнәгә кую, аның тирәсендәге ыгы-зыгы, шул әсәргә Кутуйның тискәре мөнәсәбәте һ. б. театр интригалары турында языла. Кутуй өстенә байтак гаеп ташлана.

Хатта чираттагы корбан — «Кызыл Татарстан»ның редакторы С. Борһан.

*«Сафа Борһан иптәш «Кызыл Татарстан»да редактор булып эшләгән вакыт иде. Бу вакытларда мин яшьләр мәсьәләсендәге булган күренешләрне безнең матбугат башындагы җитәкче иптәшләребезнең әһәмият бирмәүләреннән, шул ук вакытта матбугатта күренә башлаган куңелсез фактлар турында Сафа Борһан иптәшкә махсус бер хат язган идем. Ни өчендер, ул башта минем хатны газетада басарга җыенган булган, басмыйча калдырып, язу машинкасы аркылы күбәйтеп шуларга («Җидегән»челәргә?— Авторлар) таратканы турында ишеттем... Логика турыдан-туры Сафа Борһанның «Җидегән»гә якын торуын дөресли. «Җидегән» ачылды.*

*Ләкин бу юлы ныклы көрәш кирәк. Бу көрәш тар бер рамка эчендә булмыйча, моңар кадәрге начар фактларның барысын тикшереп законлату тәртибендә барырга тиеш...*

*Бүгенге сыйнфый көрәш дәверендә пролетариат җәмәгатьчелегенең социализм фронтында катнашы ускән бер вакытта бөтен булган яшеренлек, группачылык... рәхимсез корытылырга тиеш... Мин бу көрәштә катнашачак иптәшләргә үземнең бар булган мәгълүматым белән ярдәм итешергә һәм кирәк булган тәртиптә матбугатта да, ТАПП каршында да җавапка чыгарга хәзерлегемне белдерәм. Г. Минский, 30 август»* (Партархив, шул ук төпләмә, 27—30 битләр).

## IV

Инде матбугат органнарына күз салыйк. Кайда, кем, нәрсә яза? Әмма өлгерлек: август ахырында ТАППта мәсьәлә тикшерелә, «Чаян»ның август-сентябрь ахырында инде «җидегәнче»ләргә коточкыч сатира. Дөресрәге, сатира түгел, ә шәхесне мәсхәрә итү. Язучыларны. Бу — бары тик сталинизм системасында гына булуы мөмкин хәл. «Чаян»ның тышлыгында күсе рәсеме. Аның авызында «Җидегән» уставы. Шунда ук шигырь сыман бер тезмә:

*Җиде күсе идән астында оя корганнар,*
*Күп еллар урлап совет икмәген ашап торганнар.*

*Тел очларында чума микробы барын белгәннәр,*
*Сөтләргә тыгылып шушы микробны ташып йөргәннәр.*

*Нәсел-нәсәбле, һәйбәт токымлы*
*Бу җиде күсе хәзер тотылды.*

Журналның эчендә «Астрономнар фикере» (янәсе, Җидегән йолдыз турында) дигән баш астында Г. Иделле, М. Гали, Ф. Мөсәгыйть, «астроном профессор» Такташ фикерләре. Сүбәтәй псевдонимлы берәү «Җидегән» бәетен бирә. «Астроном-шагыйрь» Туфан фикере.

*Демокритлар фәнне «алдадылар»*
*«Бер атом да бетми» диделәр.*
*Бу дөньяда нәсле бетә торган*
*Материядән икән «Җидегән».*

Мөсәгыйть бу уңайдан үз телендә булган бөтен шапшак сүзләрне файдалана: *«Җидегәнчелек» — дип яза ул,— Гаяз Исхаковларның пролетариат әдәбиятын сасытыр өчен тукмиенчә, үзләре эмиграциягә качканда совет өенең бер почмагына яшереп калдырган тәрәт чүлмәге. Ә «җидегәнче»ләр шуның эчендә үсеп җитешкән хәшәрәтләр» («Чаян», 1930, № 8—9). Шул ук көннәрдә аның «Кызыл яшьләр»дә «Гегемонлык өчен көрәштә җимерелгән «Җидегән» исемле зур*

*мәкаләсе чыга. Ул әлеге төркемнең исемлеген бирә. «Боларның бер-икесе партия члены, комсомол булса да, калганнары ачыктан-ачык вак буржуа вәкилләре»,— дип тамга суга ул. Болар, ди ул, «ничек итеп тирес башыннан, завод корымы эченнән күтәрелгән малайларга иректе рәвештә матур әдәбиятта юл бирсен! Нәкый Исәнбәт, Кутуйлар менә шулай уйлыйлар, менә шуңа күрә дә «Җидегән» оештыралар. ...Бу бәндәләрнең оешуына тагын бер сәбәп — аяклары астыннан зәминнең китә, шуа баруын сизенүләре. Пролетариат кадрлар үскән саен бу бәндәләр эри, югала баралар. Шәһрәт чәчәкләре сула, корый башлый... Кутуйлар матур әдәбиятны үз кулларына алмакчылар, үзләре генә яшәмәкчеләр. Пролетариат әдәбияты фронтында үсеп килгән яшь каләмнәргә астыртын ут төрттәләр... «Җидегән»нең эчтәлеге пролетариат әдәбиятына каршы көрәш, пролетариат идеологиясенә каршы буржуа идеологиясен кую, кыскасы, матур әдәбият фронтында пролетариат диктатурасына каршы бардан тора».*

«Җидегән»не ТАППтан куу гына Ф. Мөсәгыйтьне канәгатьләндерми. Аларның, ди ул, ВАПП составында торганнары да бар, аларын да куарга кирәк (1930, IX, 2).

Әйе, «пролетариат»ка монда кизәнергә мөмкинлекләр зур. Кем ул Н. Исәнбәт? Мулла малае, мәдрәсә шәкерте. Җитмәсә, сатирик. Кем ул Гадел Кутуй? Аңа тамга бер генә, имеш, фабрикант малае. Дөрес инде, фабрикант ук булмаса да, кулында эш биеткән кешенең малае. Кем ул Ченәкәй? Аның бит псевдонимы да «пролетарча» түгел — Сәмави. Ягъни, күккә ашкан. Ул бит чүкеч, домна турында язмый. Әнә аның «Күзсенмәсен бу бала» шигыре. Ирек турында.

*Әлли-бәлли итеп ул уйнаса,*
*Изге фәрештәләр ярала,*
*Тел тибрәтсә, мең-мең серләр ача,*
*Сер чишмәсе инде бу бала.*

*«Ирек» дигән исем бирик аңа,*
*«Ирек» атлы булсын бу бала;*
*Кул күтәрик, йөгез, без боңарга,*
*Мәңге яши курсен бу бала,*
*Кул күтәрик изге бер догага,*
*Җир йөзендә калсын бу бала.*
*«Кызыл шәрекъ», 1921, № 7—8.*

Пролетариат мондый шигырьне ничек гафу итсен?

Менә пролетариат шагыйре бичара Крыймов Мансур. Донбасс шахталарына барган да, яхшук төшереп алгач, койма буенда төн кичкән. Шул ук «Чаян» моны эләктергән: «Шагыйрьнең аяклары ревматизмлы» дип, ул аңа сатира биргән (1931, № 1). «Ударниклар» журналы да бик усал. М. Крыймовның бер «шигырь»еннән өзек китерә, дөрес, мактап түгел:

*Шагыйрьләрне*
*Зурлык санаучылар*
*Борнын күтәрсеннәр йолдызга;*
*Үсу юлыбызга*
*Файда бирсә —*
*Безнең өчен иптәш дуңгыз да...*

«Пролетариат әдәбияты» менә шулай ул. М. Крыймов «җидегәнче»ләргә карата да бик принципиаль. Гадел Кутуйга ул мондый «шигырь» белән бәрә:

*Син сволочь!*
*ВУЗлар үтеп*
*Кеше булдың безнең җилкәдә.*
*«Эшче», 1930, № 102.*

Ә Ченәкәйне үтерергә кирәк! Кутуйны бетерергә кирәк! Ф. Бурнашны әдәбияттан алып ташларга кирәк! Йә әле, Мансур Крыймов, пролетариат шагыйре, бу юнәлештә ниләр эшли аласың?

«Ударниклар» (Мәскәүдә чыга) журналы, 1930 ел, 4—5 саннар. Шигырь. Авторы — М. Крыймов. Шигырьнең исеме — «Атака». Кыскартып бирәбез.

*Төннәр саен*
*Хан сараен*
*Кемнәр сагына?*
*Кем чылатып*
*Кузен ата*
*Төннәр ягына?*
*Фәтхи Бурнаш,*
*Катгый боргач*

*Артка кеймәсен,*
*Тыгылмасын,*
*Легендасын*
*Атка сөйләсен.*

*Кемнең анда*
*Җыр язганда*
*Куллары тала?*
*Ярты юлда*
*Әрнеп җылап*
*Уе бутала?*

*Ул — Ченәкәй,*
*Кечкенә, кәй,*
*Адашып калган.*

*Юкны җырлап,*
*Чүпне зурлап,*
*Куллары талган.*

*Тынчып чыккан*
*Толчокчыга*
*Кем җанын сата?*[1]

*Бывший буржуй*
*Гадел Кутуй*
*Шулмы сыйныфташ?*
*Чит дөньядан*
*Безгә калган*
*Ярты сынык таш...*

Вульгар социологизмның иң актив лидерларыннан берсе С. Мортазин «Яңалиф» журналының 1931 елгы 1 санында зур мәкалә бастыра: «Диния нәзарәте, сырахана, лото, алимент һәм чүп-чарлар шагыйре Төхфәт Ченәкәй (Сәмави)». Ченәкәйгә яшәргә урын калдырмый Мортазин! Ченәкәйгә өмет белән караган тәнкыйтьче Г. Нигъмәтине дә бәреп ега ул әлеге мәкаләсендә.

Мөхәммәт Парсин (1899—1963) — журналист. Сталиннан ниләр күрәсен әле белми. Бичара! Менә болай яза: «Җидегән» — 1928 елда Уфада оешкан татар язучылары оешмасы. Оештыручылары: фабрикант улы Кутуй, сәүдәгәр улы Минский һәм динче-милләтче шагыйрь Ченәкәй. Бу оешмага член булып мулла малае Нәкый Исәнбәт һәм мәгълүм Зыя Камалиның кияве Сәйфи Кудаш керәләр. Агишев. Әлегә тикшерелмәгән хәбәрләргә караганда, бу оешмага Сафа Борһан да керә, имеш» («Ялчы» газетасы, 1930, IX. 6).

Г. Тләшев — шул еллардагы иң актив әдәбиятчы, журналист. Бу кеше бөтен жанрларда да эшли, бу үзен «пролетариат әдәбиятының» иң алдынгы вәкиле дип исәпли, ешкына башкаларны ярышка чакыра, ничек язарга өйрәтә (таланты булмаган «язучы», гадәттә, кеше өйрәтә). Г. Тләшев әле шәхес культы елларын кичеп исән калгач та (ул Чиләбе өлкәсе Копейск шәһәрендә яши иде) татар әдәбиятына кабат керергә омтылып карады, урындагы татар район газетасы типографиясендә ниндидер китапчык та чыгарып маташты. Ләкин татар әдәбияты томаналыктан айнып килә иде инде. Менә шул Тләшев «җидегәнче»ләр турында болай яза:

*«Оешма төзүдән максат югарыда фамилияләре күрсәтелгән бәндәләр әдәбият мәйданын уз монополияләренә алырга, социализм төзергә хезмәт итүдән тайпылдырып, шәхси интригаларга буйсындырырга тырышканнар, гәзит-журналларда фәкать уз әсәрләрен генә бастырырга булганнар. Пролетариат сафыннан чыккан яшь язучы кадрлардан көлеп, аларның җитешлекле әсәрләрен дә тәнкыйть итеп килгәннәр һәм бер-берсен вакытлы матбугатта мактарга булганнар. Бу бурычларны Уфада һәм Казанда практик эштә дә башкарганнар» («Кызыл Армеец», 1930, IX, 2).*

Мәкаләне Г. Тләш үзенең шигыре белән тәмамлый. Әйдәгез, карыйк әле, шәп шагыйрьме икән ул?

*Безнең кайгы — көрәш кайгысы,*
*Безнең тойгы — сыйныф тойгысы;*
*Бүгенгене һаман сөймәүче чит элемент*
*Бүре булып һаман боексын!*

Журналист Мирза Даутовның мәкаләсе дә канлы. «Милләтче кодалар һәм аларның партбилетлы кодагыйлары турында» дигән мәкаләсе «Ударниклар» журналының 1930 елгы 4—5 санында басылган. Мәкалә татар әдипләре дөньясын бик нык бутау максатында язылган. Монда байтак гайбәт тупланган. Әйтик, ул Г. Кутуйның әле дә булса туганнары белән яшерен рәвештә бәйләныш тотуын яза. Бу — зур гаеп икән. Әлегә ди ул, ике «җидегәнче» билгеле түгел. Әйттерергә кирәк, әйтмәсәләр, «әйттерә торган юллар бар». Әйе М. Даутов тәкъдим иткән методны без беләбез: репрессияләр вакытында Сталин ОГПУ-НКВД органнарына, сорау алганда әгәр гаепләрен танымасалар, «физик тәэсир ясау максатка ярашлы» дигән күрсәтмә бирә һәм үзебезнең фашистлар моны зур канәгатьлек хисе белән башкаралар: тоткыннарның ач күселәр тулы салкын подвалларга ябалар, бармакларын ишеккә кысалар, тешләрен сугып сындыралар... Моны соңрак М. Даутов, шәт, үзе дә татыгандыр. «Җидегәнче»ләр турында язганда Ф. Мөбәргә кадәр: «Алар — пролетариат диктатурасына каршы көрәш максатын куйма-

---

[1] Г. Кутуйның «Базарда жан сатам» дигән футуристик шигыренә төрттерә. — *Авторлар.*

ганнар».— дип әйтеп тора. М. Даутовка исә бу ошамый. «Моннан да сәяси сыгылма сыйраклыкны кайда күргәнегез бар?» — дип дулый. Г. Галигә дә өлеш чыга: ул «җидегәнче» Кутуйга тел тидермәскә чакыра икән. Тагын кемнең гайбәтен сатарга? Әһә, Ченәкәй бар бит әле. Әнә ул авырып ятканда ТАПП аңа йөзәрләп акча биргән, ә менә С. Баттал авырганда аңа бирмәгәннәр...

М. Даутов, бөтен төрле гайбәтне болгатып чыкканнан соң, ТАПП җитәкчелегендәге Г. Галигә катгый хөкем чыгара: ул, ди, милләтче кодаларның партбилетлы кодагыйлары...

1930 елның 2 сентябрендә «Красная Татария» газетасында берьюлы ике мәкалә басыла: «Политические уроки» «Джидегановшины»; «За большевистское руководство».

Беренче мәкаләнең авторы псевдоним белән имза куя: С. Ар. Мәкаләсендә 31 августта узган язучылар җыелышына, анда ӨКның культпроп мөдире Г. Касыймовның чыгышына туктала. «Җидегәнче»ләрдән Н. Исәнбәтне аерып ала: ул Г. Ибраһимовны классик дип танымый, ә менә ак эмигрант Г. Исхакыйны һәм гомеренең ахырына кадәр совет властенең дошманы булып калган Ф. Әмирханны классиклар дип исәпли.

*«Исәнбәтнең бөтен иҗатын анализлаганда аның иң явыз дошман, аның бөтен әсәрләре совет властена, пролетариат диктатурасына каршы икәнен, үзен совет әдибе дип атарга мөмкин булсын өчен аның кайвакытта формальсоветча әсәрләр белән чыкканын аңларга тиешбез. Исәнбәт әсәрләренә иң яхшы теләктән чыгып караганда да безнең төзелеш өчен аларда бернинди уңай сыйфатлар табып булмый. Исәнбәтнең пьесалары совет чынбарлыгыннан ачыктан-ачык көлү һәм тоташ мыскыл итүдән тора.*

*Бу пьесаларны берәр Берлин театрчыгында татар эмигрантлары рәхәтләнеп карарлар иде. Чөнки бу пьесаларда татар буржуаз милләтчеләрен тәнкыйть иткән бер генә фраза да юк. Исәнбәт идеологиясе ул үзенең тамырыннан ук Гаяз Исхакый һәм башка акгвардиячеләр өгренең тамырдан безгә дошман идеологиясе...»*

Г. Касыймов әйтә:

*«Уфадагы беренче утырышта беренче сүзне Кутуй нәкъ менә Исәнбәткә биргән. Ул болай дигән:*

*— Беренче почетлы сүзне бөтенебез тарафыннан ихтирам ителгән Исәнбәт агага бирәбез...*

*...Исәнбәт органик рәвештә партиянең теләсә нинди өлкәдә җитәкчелеге белән килешә алмый (һәм беркайчан да килешмәячәк тә)... Исәнбәт кискен моментларда коммунистларның эшне партиясезләр җилкәсенә салырга тырышуларын, кеше кулы белән утлы күмер чүпләргә яратуларын әйтеп, «Алласызлар Союзы»нда эшләүдән баш тартты... Кутуй аерым урын алып тора. Без аны бик озак вакытлар үз кешебез дип, безнең белән чын күңелдән бергә эшләргә теләүче, партиягә һәм совет властена ярдәм итәргә теләүче дип йөрдек... бу шәхестә без ачыктан-ачык сәяси хаинне, совет властена ябышкан оятсыз карьеристны күрәбез...»*

«За большевистское руководство» дигән мәкаләдә «җидегәнчелек» белән көрәш татар әдәбияты тарихына сыйнфый көрәшнең бер сәхифәсе булып, ләкин пролетариат әдәбиятының дошман тарафыннан тылдан әйләнеп үтелгән мизгеле булып кереп калыр, диелә. Мәкаләдә мондый тәкъдим кертелә: уң оппортунистик һәм буржуаз милләтче солтангалиевчелек тенденцияләре белән кискен көрәш башларга. Бу тайпылыш һәм агымнар белән килешүчәнлеккә шулай ук отпор бирергә.

Матбугат бу турыда әле бик озак шаулый. Белмиләр: Г. Касыймов та, язучылар да үзләренә-үзләре баз казыйлар. 1937 ел килгәч, бу базга бер-беренне төртеп төшерү иң ансат эш булачак. Ялгышалар: Кутуйның татар зыялылары арасында дингә каршы кампания алып баруы, мәчетләрне яптыру өчен татар укымышлылары арасында 90 имза җыюы да (фонд 291, 1-тасв., 1009 док., 9-бит), Ф. Бурнашның «Җидегән» өстеннән өлкә комитетына язган хаты да — берсе дә ярдәм итми: барысына да кара тамга сугыла һәм барысы да диярлек төрмәгә озатыла... Ф. Бурнаш хаты дигәннән...

## V

Бу — аерым мәсьәлә, һәм катлаулы, һәм аңлавы авыр булган мәсьәлә. Әллә моның нигезендә шәхси мөнәсәбәтләр генә ятамы? Театр бит авторларны сугыштыру, талаштыру өчен иң уңайлы мәйдан. Чөнки, әгәр репертуарда синең әсәрең барса — синең тамагың тук, өстең бөтен. Әгәр синеке барса, димәк, теге авторныкы бармый. Димәк, теге — ач, ялангач. Театр исә бөтен авторны да берьюлы туйдыра алмый, ул һәрвакыт бер йә ике автор белән генә эшли. Ул әле дә шулай. Әсәреңне сәхнәгә менгерү өчен көрәш сәнгать дөньясындагы иң рәхимсез, имансыз көрәшләрдән берсе. Бу көрәштә нык нервлы, планлы, рәхимсез авторлар гына җиңеп чыга. Җиңелгән автор алга таба инде беркайчан да беренче планга чыга алмый. Язгы «гон» вакытында ата пошилар арасында «кәләш» өчен котчыккыч бер сугыш булып ала икән. Шунда җиңелгән поши,

имеш, ялгызлыкка дучар ителә, бер җиңелгәнне икенче язны күрәшкә дә кертмиләр, имеш.

Гаҗәп, «Җидегән»не сәяси яктан иң нык гаепләп чыккан кеше — Ф. Бурнаш. Партархивта аның бу турыда хатлары саклана. «Җидегәнчелек»не ул Украинада, Белоруссиядә, Казагыстанда «табылган» милләтчелек хәрәкәтләре белән бер бәйләнештә бәяли. Бурнаш нәкъ Сталинча яза. Аның фикерләре түбәндәгеләргә кайтып кала: капитализмның тамырларын актару, кулакларны сыйныф буларак бетерү барышында социалистик һөҗүмнең уңышлары сыйнфый көрәшнең кискенләшүенә китерә. «Җидегәнчелек» хәрәкәтенең иң характерлы сыйфатларыннан берсе шунда ки, аның кайбер вәкилләре үзләренең чын йөзләрен революцион гыйбарәләр белән каплау хәйләсенә ирештеләр. РАПП оешмасы язучылар арасында оппортунизм урнаштырды.

«Җидегән» — безнең партиябез уздырган әдәби сәясәт кысаларына сыя алмаган татар язучыларының оешмасы. Бу оешма әгъзаларының кайберләре Кутуй, Кудаш (ул ВКП(б) әгъзасы), Минский (комсомолец) алсу төскә буянып эш иттеләр, шуның белән пролетариат әдәбияты өчен бу оешманың хәвефе тагы да артты. Бу оешманың илдә һөҗүмчән социализм нигезендә сыйнфый бәрелешүләрнең кискенләшкән, партиядә уң оппортунистик тенденцияләр көчәйгән, милли окраиналарда (Солтангалиевчелек, Сәгъде Ваккасчылык һ. б.) милләтче-шовинистик хәрәкәте көчәйгән чорда барлыкка килүе игътибарны җәлеп итә.

«Җидегән» ул — китеп баручы капиталистлар сыйныфы оешмасы».

И Бурнаш, и Бурнаш! Алда ниләр көткәнен белсәң иде син...

Ләкин хатны укыйк әле:

*«Җидегән» әдәбиятта гына түгел, үзен театрда да күрсәтте.*

*Г. Кутуй, Г. Минский театрның репертуарын, актерлар составын, режиссерларны билгелиләр иде. Алар кулы белән театрдан Б. Тарханов, С. Байкина, Р. Кушловская, Ф. Ильская, К. Шамиль читләштерелделәр. Алар инициативасы белән театрга Тинчуринның сәнгатьчә җитәкчелеге урнаштырылды. Тинчурин — буржуаз рухи бозыклык, милли көнкүреш тарлыгының вәкиле.*

*Рецензияләр һәм контроль тулысынча Кутуй карамагында иде. Театр һәм сәнгать турында «Кызыл Татарстан», «Безнең юл» битләрендә Кутуйдан узып беркем дә берни дә бастыра алмый иде.*

*ТАПП һәм аның җитәкчелеге Кутуй йогынтысы астында, ә Гомәр Гали, Сафа Борһан кебекләр аны бернигә дә карамастан яклыйлар иде. Кутуй ТАПП-та череп таркалган буржуаз язучылар — Такташ, Минский кебекләрдән үзенә «ядро» төзегән иде.*

*«Җидегән»гә кемнәр ярдәм итте?*

*Аларны ачыктан-ачык яклаучылар, һичшиксез, Сафа Борһан, Гомәр Гали, Газыйм Касыймов, Г. Касыймов үзенең чыгышында («Кызыл Татарстан», 1930, IX, 2) Кутуйны тел гә алмыйча, бөтен гаепне Исәнбәткә аударып калдыра».*

## VI

Партархивта Сафа Борһаннан кергән хат саклана.

*«ВКП(б)ның Татарстан Өлкә Комитетына ВКП(б) члены Сафа Борһанның гаризасы.*

*ТАППның 29—31 сентябрьдәге (1930) киңәйтелгән утырышында кайбер иптәшләр минем исемне идән асты сәяси-әдәби «Җидегән» оешмасы белән бәйләргә тырыштылар. Моннан тыш, Казан, Уфа һәм Мәскәүдәге кайбер иптәшләр пролетариат әдәбиятына дошман булган бу оешма белән бәйләнешем турында бик тырышып хәбәр таратканнары миңа мәгълүм.*

*Мондый җавапсыз җирәнгеч гайбәт иҗтимагый журналист һәм партия әгъзасы буларак дәрәҗәмне төшерә.*

*Контроль Комиссиясеннән эшемне тикшерүне һәм реабилитация ясавын сорыйм.*

*Коммунистларча сәлам белән С. Борһан, 5. IX».*

*Минем исемемне телгә алган Минский (Казанда), Шамил Усманов (Мәскәүдә), Мөсәгыйтов (Казанда), Минский һәм Мөсәгыйтов комсомол газетасында эшлиләр.*

*Материалларны бирергә мөмкин кешеләр: Гомәр Галиев, Г. Кушай, Кави Нәҗми, Закир Гали, Газыйм Касыймов һ. б.*

*6.IX. С. Борһан.*

С. Борһан 1898 елда Уралдагы алтын приискларының берсендә шахтер гаиләсендә туган. Беренче белемне шундагы амбар сакчысы булып эшләүче татар картыннан алган. Алар анда барлыгы сигез малай грамотага өйрәнгәннәр. Сафа прииcкта ат әйдәүче булып эшләгән. Аннан металл заводында. Йөкче дә булып эшләргә туры килгән. 1916 елда аны Верхотурьега укытучылар курсына чакыралар. Курсны тәмамлап кайткач, ул

завод янында башлангыч мәктәп ачтыруга ирешә, шунда татар эшчеләренең балаларын укыта.

1919 елда аны «кызыллар»га хезмәт иткән дип гаепләп, аклар кулга ала. Егерменче елларда ул Башкортстан комсомолын оештыручылардан берсе була. Сафаны комсомол өлкә комитетының бюро әгъзасы итеп сайлыйлар. 1919—21 елларда партия өлкә комитетының Стәрлетамак шәһәрендә агитпроп мөдире булып эшли, аннан Мәскәүдә Шәрекъ хезмәт ияләре коммунистик университетында укый. 1923—26 елларда партиянең Башкортстан өлкә комитетында матбугат бүлеге мөдире булып эшли. 1926 елда партия аны Казанга күчерә.

Казанда ул «Кызыл Татарстан»ның баш редакторы, «Красная Татария»нең баш редактор урынбасары булып эшли. 1936 елда кулга алынганчы «Известия» газетасының Татарстан буенча махсус хәбәрчесе була. 1920 елдан бирле партия әгъзасы С. Борһан — бик күп китаплар авторы, 1936 елда кулга алына һәм 1937 елда һәлак була. 1957 елда реабилитацияләнә. Псевдонимнары: С. Танай, Т., С. Б., Лялин.

Менә шундый «кызыл киселгән» коммунистның исеменә Г. Минскийның хаты нигезендә тап төшә. Һәм Обкомда «Сафа Борһан эше» барлыкка килә.

Өлкә Комитетының яшерен бюро утырышында «Җидегән» мәсьәләсе карала. Көн тәртибе буенча докладны өлком секретары Б. Абдуллин ясый.

Абдуллин. Партия оешмасы бу төркемне үз мөнәсәбәтләрендә берсен-берсе яклап пролетариат тәнкыйтенә каршы оешкан антипролетар төркем дип бәяләргә тиеш.

Бaһавeтдинов Г. (1897—1938, юрист, галим, партия-совет эшлеклесе). Башында партияле һәм комсомолец торган бу оешманы партиягә каршы кешеләрне үзенә туплаган төркемчелек дип бәяләргә һәм аларны җәзага лаек дип исәпләргә.

Ип. Мөэминев. «Җидегән» кебек хәлләр бүтән кабатланмсын өчен ТАПП сафына түбәннән кешеләр алып, аның эшенә яңа агым бирдертергә кирәк. ТААПта партия җитәкчелеген көчәйтергә, анда квалификацияле җитәкчеләр идарә итәргә тиеш.

Ип. Разумов. Безгә сыланган Кутуй кебек карьеристларның шәхесен билгеләп шуны әйтергә кирәк: түбәндә торган эшлекле иптәшләрнең тәкъдимнәренә колак салырга. ТАППның эшчәнлеген моңа кадәргегә караганда югарырак дәрәҗәгә күтәрергә, партиясез язучылар арасында партия оешмасының җитәхчелеген көчәйтергә. Милли шартларда интеллигенция линиясе буенча партиялеләр һәм партиясезләр арасында тоташуга юл куймаска, чөнки алар арасында бу очракта аерма бетә (мисал — язучылар).

Ип. Азанова. ТАППның үз эченә бикләнгәнлеген (эшчеләрдән язучыларны үстерми) һәм ТАПП белән йомшак җитәкчелек иткәнен исәпкә алып, Культпроп ТАПП җитәкчесе ип. Галиевне алыштырса әйбәт булыр иде...

1930 елның 6 октябрендә өлкә комитетының бюро утырышында ТАПП мәсьәләсе тагын карала. Монда Разумов, Мөэминев, Галиев, Яһудин, Касыймов, Еникиев чыгыш ясыйлар. ТАПП сафларында 60 әгъза икәнлеге, шуның яртысы эшчеләрдән икәнлеге, басылып чыккан әдәбиятның 80 проценты тәнкыйтьтә чагылыш тапмавы әйтелә. Чыгыш ясаучылар ТАПП җитәкчелегендәге топ ике кимчелекне — эшчеләр массасы белән элемтәнең җитәрлек булмавын һәм эштә сизгерлек юклыгын күрсәтәләр.

Касыймов. Татар әдәбиятында соңгы вакытта торгынлык сизәбез. Бездә җитди әсәрләр юк... аларны тудыручыларны предприятиеләрдән эзләргә тиешбез.

Разумов (беркетмәдә аны «татарча белми һәм татарча укымый» дип күрсәткәннәр. Бу хәл безгә соңгы дәвергәчә татар әдәбияты буенча «җитәкче» фикер әйтеп утырган Табеев, Усманов, Вәлиев, Мусиннарны искә төшерде — Авторлар): Менә Галиев, соңгы вакытта татар әдәбиятының йөзе үзгәрде, дип әйтә. Ләкин хәл башкачарак. Кем дә кем хәзер колхоз һ. б. тема белән шөгыльләнә — болар юлаучылар, ягъни күтәрелеп чыгарга теләүчеләр. Колхоз турында иң әйбәт пьеса язган Бурнашев — уң оппортунист...»

Бюрода ТАППның эше канәгатьләнерлек түгел, дип табыла.

1930 елның 14 октябрендә Өлкә Контроль комиссиясе С. Борһанның контрреволюцион «Җидегән» оешмасында эшләү мәсьәләсен карый. Комиссиянең рәисе Г. Ходаяров, әгъзалар И. Еникиев, Сакаев түбәндәге документларны тикшерәләр:

1. Г. Минскийның хаты. Бу хатта, безгә мәгълүм булган хәбәрләрдән тыш, Г. Минский тагын бер факт китерә: С. Борһан, ди ул, татар буржуаз язучыларының (Дәрдемәнд) әсәрләрен бастырды. С. Борһанның «Җидегән»гә якын торганын логика үзе раслап тора, ди Минский.

2. М. Даутов мәкаләсеннән өзек: Казанда бу оешманың җиденче әгъзасы С. Борһан, дип сөйлиләр. Ә бит җиденченең кем икәне Казанда билгеле.

3. Ф. Бурнаш хаты. «Җидегәнчелек»не ачыктан-ачык яклаучы кешеләр Сафа Борган, Гомәр Гали һәм Газим Касыймовлар булды. Бу шәхесләр Кутуй һәм аның фикердәшләренең корткычлык эшләренә хәерхаһлык юлында еллар буе эш алып бардылар, аларның эш урыннары бу өлкәдә үзләренә ошаган бөтен нәрсәне дә алып барырга мөмкинлек бирә иде.

4. Г. Тлошев мәкаләсе («Җидегән»нең безгә мәгълүм исемлеген бирә).

5. М. Парсин мәкаләсе. (С. Борһанны шушы исемлеккә кертә).

6. Ф. Мөсәгыйть мәкаләсе (шулай ук).

Бу мәгълүматларны комиссия җитәрлек түгел дип таба һәм иптәшләрне аерым-аерым комиссиягә чакырта.

Г. Минский. Логика С. Борһанны шул оешмада торган дип расларга мөмкинлек бирә. Чөнки С. Борһан Г. Кутуйга бик нык ышаныч белән карый иде. С. Борһан бервакыт Г. Кутуйның мәкаләсен «укып тормастан да басарга мөмкин» диде. Редакция аппаратында Г. Кашшаф, Ә. Айдар кебек чит элементлар эшләде. С. Борһан Татиздат директоры булып эшләгәндә пролетар яшьләрнең әсәрләрен бастыруга зыян китереп, татар буржуаз классикларын бастырды.

Әңгәмәнең ахырында Г. Минский шулай да С. Борһанны «Җидегән»дә торган дип раслый алмавын әйтә.

Г. Тләшев түбәндәгеләрне сөйли: С. Борһанның бу оешмада торуын мин Г. Минскийга таянып әйттем. Шулай да, С. Борһан объектив рәвештә «Җидегән»гә ярдәм итте, дип исәплим. С. Борһан пролетар язучылары Г. Тләшкә, М. Сөндеклегә ярдәм һәм игътибар күрсәтмәде, редакциядә эшләү өчен Г. Кашшаф, Әхмәров, Айдар кебек чит элементларны җыйды.

Г. Гали — Г. Минский һәм Г. Тләш фикерен сүзгә-сүз кабатлый.

К. Нәҗми. «ТАПП фракциясенең комиссиясе «Җидегән» оешмасы әгъзаларының 51 хатын һәм бер телеграммасын өйрәнде. Бу язышулар арасында С. Борһанның әлеге оешмада катнашканлыгын расларлык әйбер табылмады. Ләкин С. Борһан Г. Кутуйга карата гадәттән тыш ышаныч белән каравы аркасында «Кызыл Татарстан»да пролетар язучыларының әсәрләрен пычрата торган («Данлы чор» — Р. Ишморат, «Ут» — Ш. Камал) рецензияләр бастырды, шуның белән «җидегәнчеләргә» һәм Кутуйга татар мәдәниятенә каршы көрәшергә ярдәм итте».

К. Нәҗми. «Кызыл Татарстан»да чит элементларны файдалану фактларын шулай ук раслый.

Кушаев. Кутуйның «Данлы чор»га рецензиясе редакциядән С. Борһан киткәч басылды.

С. Борһан. Кутуйга булган ышанычымны тулысынча раслыйм... Кутуйны коммунист язучылардан артык күргәнемне инкяр итәм.

## Нәтиҗә

Язылган мәкаләләр белән дә, телдән бирелгән күрсәтмәләр белән дә С. Борһанның контрреволюцион «Җидегән» оешмасында торганлыгы расланмады. Төп гаепләүче Г. Минский үзенең элеккеге күрсәтмәләреннән баш тартты һәм бөтен эшне «логик нәтиҗәгә» генә кайтарып калдырды. Башка барлык мәкаләләр, нигездә, Г. Минский күрсәтмәсе аркасында язылган булып чыкты... С. Борһанның Кутуйга артык ышаныч күрсәтүенең сәбәбе исә редакторның газетаны яхшырту максатында үткен репортажлар артыннан кууы булган. Шул ук вакытта газетада, штатта тормасалар да, чит элементлар файдаланылган.

Контроль комиссиясенә материал биргән һәм мәкалә язган язучылар арасында аерым иптәшләрдән (Г. Касыймов, Г. Гали, С. Борһаннан) шәхси үч алырга омтылу тенденциясе сизелде. Моның ачык мисалы — партиядән чыгарылган кара эчле солтангалиевче Фатхи Бурнаш хаты... Мондый хатлар Татреспубликада партия җитәкчеләрен дискредитацияләү максатында язылганнар (партархив, 292 фонд, 1 тасвирлама, 1009 төпләм, 10 документ).

## Резолюция *(кыскартып бирелә — авторлар)*

1. С. Борһанны «җидегәнчелек»тә гаепләргә нигез юк дип санарга.
2. Г. Кутуйга карата артык ышаныч күрсәтүен әйтеп үтәргә.
3. ВКП(б) әгъзасы Мирза Давыдовның (Даутовның) ишеткән сүзләргә нигезләнеп кенә «Эшче»дә республиканың партия оешмасын «Җидегән» әгъзаларын яшереп калдыруда берничә дәлилсез гаепләргә тырышуын күрсәтергә. Бу турыда тиешле оешмаларга җиткерергә (партархив, 292 фонд, 1 тасв. 1009 төпләм, 11 док).

ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты Секретариаты утырышы беркетмәсеннән (1930 ел, 27 ноябрь).

## ТАППны чистарту йомгаклары

Тыңланды 17. ТАППны чистарту йомгаклары турында.

Карар кабул ителде: 1. ТАППның эшен үзгәртеп кору һәм чистарту комиссиясенең нәтиҗәләре белән килешергә...

2. ТАППның җаваплы секретары итеп К. Нәҗмине расларга. Урынбасары итеп — Имамметдиновны (бу кеше әле үзен күрсәтәчәк — авторлар).

3. «Атака» журналының редколлегиясен К. Нәҗми, Толымбайский, Каратаевлар составында расларга (Партархив, 15 фонд, 2 тасвирлама, 788 төпләм, 137 док.).

## VII

Хуш, «җидегәнче»лек белән көрәшү татар әдәбиятына нинди файда китерде? Фабрикант, мулла малайлары Кутуйлар, Исәнбәтләрне сәхнәдән алып ташлагач, «түбәннән» күтәрелгән кешеләр ниләр яза башладылар соң? Татар әдәбияты пролетарлаштымы?

Әйе, пролетарлашты. Моңа ирешелде. Әйтик, пролетар язучы Г. Ильясның «Штык» повесте басылып чыкты. Әсәрдә вакыйга икмәк пешерә торган җирдә бара. Төп герое — Шәмгун. Ул тырыш егет. Аның (ипине мичкә тыкканда) тырышлыгын автор болай сурәтли:

«Тизрәк, тизрәк, тизрәк... Удар! Удар! Удар!» «Һәр ударникның эче — ягылган мич», «Һәр мичтә каен утыны — ялкын», «Һәр ударникның бите — икмәк бите, кәрәзләнеп аккан икмәк мае». «Һәр ударникның күзләре — кызыл бөре җыры», «Һәр ударникның ирене — шалтырап төшкән алсу каен күмере».

Беткәнче шулай. Бичара авторны талантсызлыкта гаеплисе урында аңа... сәяси ярлык тагалар. «Штык» — контрреволюцион әсәр икән. Матбугатта чиле-пешле бу әсәр турында зур сәяси кампания башлана. М. Җәлил, Г. Төхфәт, Алфади имзалары белән «Коммунист» газетасында өч санга сузылып «Матур әдәбиятта контрреволюцион троцкийчылыкка каршы» исемле зур мәкалә басыла. Тәнкыйть объекты — «Штык». Әсәрнең редакторы булган М. Максуд «артка таба хут» ясый. «Штык» китабы объектив алганда Кызыл Армиягә контрреволюцион троцкизмча пычрак яга торган әсәр дип бәя бирүгә мин тулысынча һәм бөтенләе белән кушылам,— дип белдерү ясый ул.— Әсәрне басарга яраклы табуым белән тирән сәяси хата эшләвемне бөтен кискенлеге белән икърар итәм» («Коммунист», 1932, 122 сан).

Бичара авторга шуннан соң ни кала?

«Минем «Штык» дигән әсәремдәге хаталар турында» дигән мәкалә белән матбугатка чыга ул. Кешеләр күрсәткән бөтен хаталарны таныйм, ди ул, ләкин болар аңлы рәвештә түгел, аңламыйча шулай эшләнгән. («Коммунист», 1932, № 259).

Әдәбият кая таба бара? Менә мондый әсәрләргә таба:

*Власть күчте хезмәт ияләренә,*
*Завод-фабрик җирне алдылар.*
*Заводлардан, киң-киң җирләрдән*
*Бай нэпманнар мәхрум калдылар.*

(Д. Фәтхи, «Ударниклар», 1931, № 11).

С. Латыйповның «Гөлкәйгә хат» хикәясе. Кызылармеец яза: «Үпкәләмә, бәгърем, кайвакытта синең шомырт күзләреңне дә айлар буенча онытырга туры килә. Чөнки винтовкама булган мәхәббәт синең мәхәббәтеңнән катырак» («Колхозчы», 1930, № 59).

Яки МАПП (пролетар язучыларының Мәскәү ассоциациясе) чыгарган «Көрәш еллары» җыентыгы. А. Таһировның «Беренче көннәр» хикәясендә «ананы...»; Г. Ильясның «Вахта» хикәясендә: шкивлар, «маңка тыгылган борын кебек лышкылдап эшлиләр». Шунда ук: «Анасын... дип ачы сүгенде». Хәтта ни әдәпле А. Шамов та «Лазаретта» дигән хикәясендә болай яза: «Кая керәсең, ананы...»

Ш. Шәһәретдиновның рецензиясе. Ә. Айдарның «Барабызлар турында» исемле шигырь җыентыгы турында. Тәнкыйтьче монда «зур хата» таба. Шигырьдә «кызны ак каен, ялгыз ай белән сөйләштерү ул табигатьтән тыш бер көч бар, дип ышандырырга тырышу була». Безнең кызлар «клуб, кызыл почмак, уку өйләрендә комсомол уставын өйрәнәләр, гәзит-журнал, китаплар укыйлар, социализм төзелеше мәсьәләләрен тикшерәләр» («Эшче», 1929, № 141).

«Революцион бәйрәмнәрне үткәрү кичәләрендә сөю-сөешү җырларын җырлау булгаладыᵦ,— дип яза С. Сәлманов дигән берәү («ТКУ» газетасы, 1929, № 3).

Такташка да бәйләнәләр: «Югалган матурлык» та, «Мәхәббәт тәүбәсе» дә ошамый формалистларга.

Такташ бу әсәрендә хатын-кызларга бәя бирүдә «Хатын-кызның бөтен матурлыгы ана булуда» дип, бөтенләй пролетариатка чит карашны җырлап чыкты,— дип яза Г. Толымбайский шагыйрьнең үзе төзегән беренче томына Г. Гали язган сүз башын тәнкыйтьләп.— Гомәр... шуңардан күзен йома. Такташ хатын-кыз образын бирде, бөтен специфик яклары белән бирде, нык уңышлы әсәр бирде, ди. Хатын-кыз мәсьәләсендә төп карашы ялгыш булгач, ничек инде ул хатын-кыз образын бөтен специфик яклары белән бирә, «нык уңышлы» итеп бирә?» («Коммунист», 1932, № 85).

Уралдан торып шагыйрьгә Г. Тләш һөҗүм итә. «Югалган матурлык» авторы Такташка» дип атаган ул үзенең эпиграммасын.

*Бик биек шул шөһрәт тавы, ай-йәй, биек,*
*Менеп булмый аллы-гөлле баскыч куеп.*
*Такташ абзаң, инде менеп җиттем, дигәч,*
*Саз эченә «лерт» иттереп төште килеп.*

(«Сабан һәм Чүкеч» газетасы, 1929 ел, 15 сан).

«Шүрәле», «Су анасы»н яңалифчә басып чыгару урынсызрак диясе килә,— дип яза С. Самадов дигән берәү,— китаплар балаларны эш белән, тормыш белән кызыксындырмыйлар». Автор фикеренчә, балаларга завод-фабрика, ясле турында язарга кирәк. («Эшче», 1930, № 33).

«Нинди дә булса бер сыйныфка хезмәт итмәгән әдәбият булырга тиеш түгел. Бездә ул пролетариат сыйнфы белән бер юлдан барырга тиеш». (М. Әмир. «Сыйнфый бурыч онытылырга тиеш түгел» («Авыл яшьләре», 1929 ел, 10 сан).

Утызынчы еллар башында татар әдәбиятын «большевиклаштыру» өчен аяусыз көрәш башлана. Әдәби әсәрдә төп герой булып ударник, пролетариат вәкиле, комсомол әгъзасы торырга тиеш, дип раслана. Бу тенденция Г. Абдуллинның «Литературная газета»да басылган «Татарстан матур әдәбиятын большевиклаштыру өчен» (1933 ел, 16 сан), М. Җәлилнең «Комсомольская правда» да басылган «Яшьләр әдәбиятын югары баскычка» (1931, 25 ноябрь саны) исемле мәкаләләрендә ярылып ята.

Авыр идеологик атмосферада бик күпләр сынала. Кимсетелгәннәр генә дәшми. Үзенә «җидегәнчелек» яки «солтангалиевчелек» янамаган язучылар иманнарын сата башлый. М. Максуд «Эшче» газетасында бик нык һөҗүмчән «Матур әдәбиятта эшчеләрдән кадрлар җитештерү турында» исемле мәкалә бастыра (1930, № 26). Ул анда «солтангалиевчеләр»нең исемлеген бирә. Болар: Ф. Бурнаш, М. Бөдәйли, Ф. Агиев, Г. Касыймов. Игътибар итик: болар барысы да Сталин корбаннары була. М. Максуд хәтта Ф. Әмирхан мирасына да кара буяу сала. Б. Мансуровның (1889—1942) Ф. Әмирхан иҗаты турында әйткән уңай фикеренә һөҗүм итеп, ул болай ди: «Шул ук Мансуровның Фатих Әмирхан кичәләре үткәреп милләтче шакертләрне күкләргә күтәрүе... солтангалиевчеләрнең матур әдәбият фронтына нык игътибар иткәнлекләрен күрсәтә» (Шунда ук).

Ә. Фәйзи дә фәрештә түгел: С. Сүнчәләйне ул «солтангалиевче» дип гаепләп матбугатта яза. Сүнчәләй 1919 елда «Интернационал»ны тәрҗемә иткәндә бик күп гарәп сүзләрен кулланган икән. М. Максуд хаклы:

*Бу булыр иң ахыргы, иң каты зур җиһад,*
*Булыр һәм бәйнәлмиләл бәни инсан азат!*

Ләкин бит моннан контрреволюция эзләргә ярамый. Мәкаләнең исеменә генә игътибар итик: «Мөселманнар», «шәһитләр» «бәйнәлмиләлеме», әллә пролетариат «интернационалымы?»

«Бу «тәрҗемә»не,— ди Ә. Фәйзи,— революциянең беренче елларында атаклы солтангалиевче Сәгыйть Сүнчәләй ясаган. Дөресрәк әйткәндә, ул аны «мөселманчылык» һәм милли «мохтариатчылык» кухнясында үз вирусына карап «пешереп» чыгарган... Ул «Интернационал»ны баштанаяк гарәпчелек белән сугарып, гарәпчелек астына гимнның революцион пафосын яшерергә тырышкан... Кыскасы: тәрҗемә бозык һәм кичекмәстән ул яңадан төзелергә тиеш». («Коммунист», 1932, № 149).

Онытмыйк, С. Сүнчәләй бераздан «халык дошманы» буларак төрмәдә атыла.

Утызынчы еллар татар әдәбияты тарихы бездә өр-яңадан эшләп чыгуны көтеп ята. Монда бернинди «культ»лар ясамыйча, бер талантка да табынмыйча, ничек булган, шуны күрсәтергә кирәк. Л. Гыйльми, М. Давыдов (Даутов), М. Крыймов, Г. Тләш, М. Максуд, Ф. Мөбәр, Ф. Мөсәгыйть, Г. Толымбайский, Г. Гали, Ф. С. Казанлы, З. Гали, С. Борһан кебек каләм әһелләренең «пролетариат әдәбияты» өчен көрәштә кайсының ялгышып, кайсының аңлы рәвештә корбаннар соравын, кан коярга чакыруын бүгенге буынга җиткерергә кирәк. Тарихны бүген без язмасак, киләчәк буыннар барыбер язар: газета-журнал тупламәләре, архивлар исән бит. Тик инде киләчәк буыннар бу тарихны язганда утызынчы ел әдипләреннән бигрәк, бүгенге әдәбият галимнәрен гаепләп язарлар. Кандидат та, доктор да булганнар, әмма татар халкыннан әдәбият тарихын яшереп яшәгәннәр, диячәкләр.

Бүген бик күп зыялы безне тарихта казынмаска чакыра. «Җитәр инде, кара таплар эзләмәгез, ник хәзер генә акыллы булып кыланасыз?» — диләр. Болай диючеләрне аңлап була: донослар, Өлком өчен язылган рецензияләр, үч алу өчен язылган кәгазьләр соңгы елларда теркәлгән архивларда да байтак. Аларны ача башласаң, кайбер иптәшләрнең урамга чыгып безнең арада йөрергә мөмкинлеге дә калмас иде.

Ә инде «ник элек дәшмәдегез?» дигәннәргә карата тарихи бер факт белән җавап биреп була. Н. С. Хрущев XX съездда шәхес культы турында докладын тәмамлагач, президиумга имзасыз бер сорау килә. Анда болай язылган була: «Сталинның бу хәлләрен белгәч, ник аны үз вакытында әйтмәдегез?». Хрущев сорауны укый да залга мөрәҗәгать итә:

— Моны кем язды?

Залда тынлык. Берәү дә «мин» дип әйтми. Һәм шуның белән сорауга җавап та бирелә.

Үткәндәге хаталар, ул хаталарны ясаган кешеләр турында бүген язу кирәкме, юкмы? Шул ук Хрущев СССР Язучыларының III съездында аерым шәхесләрнең үткәндәге хаталарына кагылып, аларга даими рәвештә бармак белән төртеп күрсәтмәскә, ләкин шулай ук, онытып бетерергә дә ярамас, дигән иде.

«Солтангалиевчелек», «Җидегән» эше, бераздан «Черек либерализмга каршы көрәш» — болар барысы да киләчәк трагедиянең генераль репетициясе булдылар. Бу елларда палачлар һәм булачак корбаннар ачыкланды, билгеләнде.

Алда канлы утыз җиденче ел тора иде. Татар әдәбияты, башка милли әдәбиятлар белән чагыштырганда, бу елда иң күп корбан биргән мәйдан булды.

«Җидегән» исемле спектакльнең генераль репетициясен партия өлкә комитеты һәм татар язучылары шундый «шәп» башкарганнар. Әйе, сәясәт катышкан әйбер исән калмый...

Рәмзи ВӘЛИЕВ,
тарих фәннәре докторы.
Мөхәммәт МӘҺДИЕВ.

# ЯШЕРЕН ВАСЫЯТЬ

«Урыс кышы», «урыс каены», «урыс чәе»... Кубада, Әфганстанда, Анголада урыс мәнфәгатьләре, шул мәнфәгатьләрне саклаучы совет танклары һәм ракеталары. Кайдан килә бу? Боларның чишмә башлары кемгә тоташкан?

Тарих китапларында һәрвакыт урыс халкының бөеклеге, күршеләренә аның дуслык һәм мәдәният кенә алып килүе хакында укыйсың. Казан ханлыгын да Иван патша үз дәүләтенә куша һәм «гаделлек» урнаштыра, янәсе. Петр патша Азов диңгезенә походлар ясап, Төркиянең «артык» биләмәләрен эләктерергә омтыла, анда эш барып чыкмагач, 21 ел буе Швеция белән сугышып, Балтыйк диңгезенә «тәрәзә ача». Аннары тагын көньякка юнәлә — Каспий диңгезе буена килеп, Иран белән «дуслыгын ныгыта», аның да бер «кыргый» өлешен үз «мәдәни» дәүләтенә кертеп, бәхетлә итә. Диңгезләргә гашыйк «тәрәзә ачу» остасы ничек инде мәмләкәте чигендә ике уем ясау белән канәгатьләнсен? Яңа диңгезләргә тәрәзә яки форточка ачар өчен аның оныклары ун мең чакрымдагы Камчаткага, хәтта аннан да ерактагы Аляскага да барып җитәләр, юл уңаенда тагын дистәләгән халыкларга ясак түләү бәхетен бүләк итәләр. Шуңа күрә мондый патшаларын урыс халкы «күренекле дәүләт эшлеклесе», «атаклы хәрби юлбашчы», «тиңдәшсез үзгәртеп коручы», «мәшһүр галим» дип мактап килә. Мәдәният алып килүе өчен бездән рәхмәт укуны көтә.

Әмма без генә түгел, барлык кыйтгаларның алдан бер өлешенә ия булган, тәрәзәне инде ундүрт диңгезгә «ачарга» өлгергән урыс халкы үзе дә бәхетсез бүген. Чөнки бәхетле булыр өчен җир киңлегеннән, диңгезләр күплегеннән бигрәк, матди муллык, рухи хөррият кирәгрәк. Соңгы казанышларга ирешү өчен исә диңгезләр һәм җирләр иркенлегенә ия булу һич тә мәҗбүри түгеллеген байтак алдынгы илләр, халыклар үсеше раслап килә. Моның өчен милләтләрнең әхлакый сәламәтлеге, сәләтен һәм көчен табигатьне саклауга, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә җигүе, мәдәни һәм фәнни кыйммәтләр иҗат итүгә юнәлтүе кирәк икән.

Русия-СССРның җире дә, суы да хисапсыз күп. Әмма бүген аның халкы ашарга ризык, киярге кием, торырга торак, суларга саф һава җитмәүдән интегә. Урманнары мәгънәсез әрәм-шәрәм ителә, кырлары-далалары уңдырышсыз тозлакка һәм чүлгә әвереләдерелә, чишмә-инешләре генә түгел, диңгезләре дә йә киптерелә, йә тереклеге үлгән шакшы сулыкка әйләндерелә. Халыкның тарихи үсеше исә аның юлбашчылары әхлагына, алар куйган максатларга һәм шул максатларга ирешү тырышлыкларына турыдан-туры бәйле. Юньле юлбашчылар халкының сыйфат ягыннан яхшыруына, аның югары казанышларга, җитеш һәм бәхетле тормышка ирешүенә сәбәпче булса, икенчеләрнең милләтен ялгыш юлга кертеп җибәрүе бик мөмкин. Әйтик, игенче белән илбасар икесе ике башлангычка нигез сала: игенче тырышлыгы яңадан-яңа байлыкны барлыкка китерә, илбасар исә инде барлыкка китерелгән хәзинәне аның иясеннән генә тартып ала. Беренчесенең тырышлыгы кешелекнең алга атлавына гел куәт кенә өстәсә, икенчесенең кәсебе киңәю сәламәт үсешне буа, паразитик фәлсәфә һәм гамәлләрне арттыра, шуның белән таланучыларның харап булуына яки аларның баш күтәрүенә китерә. Моннан инде гомум кешелек кризисына да ерак калмый.

Халыклар җәллады Явыз Иван (1530—1584), Европа жандармы Беренче Александр (1777—1825), алар арасында күпер булган «тиңдәшсез үзгәртеп коручы» Беренче Петр (1672—1725). Болай тезеп караганда, Беренче Петр әлгәрегесе һәм соңгысы арасында — иң гөнаһсыз хаким, иң мәдәни һәм кешелекле зат. Әмма аның «Васыяте» белән танышканда, бигрәк тә шундагы «кәсеп итеп, сез... бөтен дөньяга ия булырсыз», дигән соңгы юлларны укыганда, СССР дигән илнең бүгенге фаҗигасен, әле кичә генә җитәкчелектән киткән, ләкин тагын хакимлекне кулына эләктерергә ажгырып торган сәясәтчеләрнең сыек кына томан пәрдәсе белән капланган фикер сөрешендә, максатларында һәм гамәлләрендә тарихи нәфеснең, илбасарлык шаукымының, Беренче Петрның империячел ашкынулары дәвамын тоясың. Бу — СССРның азчылык милләтләренә генә түгел, урыс халкына да хәвефле, чөнки Беренче Петрның «кәсеп итү» төшенчәсе, «Васыять»тән күренгәнчә, миллионнарның күз яшен, кан дәрьясын агызуга кайтып кала, һичбер тартынусыз, үз ихтыяҗларын бүтәннәрне талау хисабына канәгатьләндерергә дәртләндерә. Ул инде менә ничә гасыр зур бер халыкның сәләтен, куәтен, тормыш эшчәнлеген, энергиясен башкаларның яшәү тирәлеген җимерүгә, матди байлыкларын талауга, яулап алуга юнәлдерде. Шушы басым

һәм һөҗүмнәрдән саклану өчен, күршеләрен чамасыз күп чыгымнар ясарга, бихисап корбаннар бирергә этәрде. Евразиянең балансланган тыныч-тату яшәешен инде ничә гасыр тетрәтеп, фаҗигаләр упкынына этәрде. «Урыс кышы» бәйрәмнәрен Әфганстан уйсулыкларына, тропик Ангола чүлләренә китереп җиткерү — бүген Беренче Петр васыятен утәү түгелдер, дип кем ышандыра ала?!

Беренче Петрның «Васыяте», ничек кенә яшерен сакланмасын, көндәш илләрнең тәхет ияләренә 1738 елда ук мәгълүм була, шул заманда ук Русия кысрыклавына каршы чаралар күрелә башлый. Дәверләр үзгәрде, хәзер инде кылыч түгел, атом бомбалары, ракеталар белән дә бүре законнарын гамәлгә кертү мөмкинлеге бик нык чикләнде. Әмма моңа карап, тарихи документларның әһәмияте кимеми. Русия империясе һәм СССР җитәкчеләренең (И. Сталинның 1945 елдан соң Төркиядән Босфор һәм Дарданел бугазларын бирүне таләп итүен генә искә төшерик!) халыкара сәясәтен, үткәндәге вакыйгаларны һәм бүгенге кайбер омтылышларны аңлауда бу «Васыять»нең роле әле дә зур. Шуңа күрә «TÜRK KÜLTÜRÜ» (Анкара) журналының 323 саныннан (1990 ел) алып тәрҗемә кылынган бу тарихи документ белән танышу укучыларыбызга шактый ук гыйбрәтле булыр, дип уйлыйм.

Чит илләрдә игътибар казанган (Akdes Nimet Kurat. Turkiyé ve Rusya. Ankara, 1990. B. H. Peter the Great and the ottoman Empere. Oxford, 1949) Беренче Петр «Васыяте» хакында әлегә тарихчы галимнәребезнең һичбер фикер әйткәннәре юк. Бәлки, шушы документның дөнья күрүе аларның да телен ачар, халкыбыз язмышына нинди-дер кагылышы булган бу яки бүтән чыганаклар, хезмәтләр турында сүз алып барырга этәргеч бирер? Хакыйкать тирәнрәк һәм киңрәк ачылса, без үз-үзебезне һәм тирәлегебезне яхшырак таныйп-белербез. Иртәгә дә яши алыр өчен безгә нәкъ менә шундый хәбәрдарлык кирәк.

**Тәуфикъ ӘЙДИ.**

## Беренче Петрның 1725 елда язган «Васыятнамәсе»

Бөтен нәсел-нәсәбебез, бер-берсенә ялганып, киләчәктә Европа илләрендә хаким булачактыр, чөнки Европаның барлык дәүләт төзелеше искергән һәм тузган. Фәкать Урыс патшалыгы гына үсештә, без бу үсешкә акылыбыз белән ирештек. Киләчәк нәселемә бер «тәгълимат» шикелле юл күрсәтсен дип, мин «Васыятнамәм»не түбәндәге теләк рәвешендә яздым:

1. Урыс дәүләте аңлы рәвештә сугыш кубу шартларын даими әзерли һәм бу әзерлеген Русиянең алга китешенә сәбәп булсын өчен алып бара.

2. Сугыш вакытларында Европадан мөмкин кадәр хәрби юлбашчыларны, тыныч заманда исә гыйлем ияләрен Русиягә җәлеп итә.

3. Европа илләре арасында ызгыш-талаш чыгару, араларына ут салу һәм, бәрелеш башлангач, алардан берсе белән дуслыкта булу кирәк. Бигрәк тә нимес халкы арасындагы болганыш һәм фетнәләрдә актив бер сәясәт тотарга. Чөнки алар безнең белән чиктәш — мәмләкәтебезгә орынып тора.

4. Польшада ыгы-зыгы чыгарырга, аннан хозурыңа килгәннәренә саранлык күрсәтүдән тыелып, ришвәт биреп, көчләрен таркатырга, дәүләт эшләренә зыян салырга. Мәскәүдән гаскәр китереп, анда урнаштырырга. Әгәр бүтән дәүләтләр безнең бу чарага каршы төшсәләр, «тавышлары тынсын» өчен, Польшаның бер өлешен аерып алып, аларга да бирергә. Эш тәмамланганнан соң, ул өлешне дә кире алырга, урыс патшалыгын көчәйтергә.

5. Швеция һәм Норвегия илләрен мөмкин кадәр бер таяныч тобәгенә әйләндерергә. Чөнки аларның идарәчеләре кулыбызда булса, Швеция һәм Норвегиянең Даниягә дошманлык орлыгы чәчүен тәэмин итү тагын да җиңеләячәк.

6. Русия аксөякләре Герман аксөякләреннән, хакимнәреннән, йогынтылы шәхесләреннән даими кыз алуны онытмасыннар. Чөнки аларның мондый кардәшлеге безгә һәрвакыт файда китерер.

7. Англия хөкүмәте белән берлектә булып, бәйләнешләрне ныгытыгыз. Чөнки сәүдәдә һәм дәүләт идарәсендә бу безгә зур файда бирер. Бөтен төзелеш өчен кирәкле барлык материалларны алардан алырга мөмкин. Бу бәйләныш һәм корал, һәм корабчылык өчен гаять файдалы.

8. Русия дәүләтенең чиге — Европаның төньягында Балтыйк диңгезенә, көньякта исә Кара диңгезгә кадәр. Бу биләмәне саклау һәм Русия чиген киңәйтү — нәселемнең бурычыдыр.

9. Русия дәүләтен дөнья мәмләкәтенә әйләндерер өчен, аның башкаласын Азия һәм Европа хәзинәләренең ачкычы булган Истанбулга күчерү шарт. Ки-

чекми һәм ялгышмый эш итеп, Истанбулның көнбатыш җирләренә ия булу кирәк. Шөбһәсез ки, Истанбулга ия булган патша дөньяда илаһи патша булачак. Бу максатына ирешү өчен Төркия белән Иран арасына дошманлык орлыкларын даими чәчеп торырга, ызгыш һәм сугыш чыгарырга кирәк. Бу эш өчен сөнни һәм шигый мәзһәпләре арасындагы каршылыклар — иң хәлиткеч корал һәм җиңелмәс гаскәрдер. Русиянең үтеп керүен Азиягә җәю өчен сөнни-шигый каршылыклары иң яхшы чара. Төркия белән Иран дәүләтләре арасындагы тотрыклы татулыкны шундый итеп бозу кирәк ки, алар бер-берсе белән һичберзаман аңлаша алмасыннар. Һәм Иран, һәм дә Төркиянең Европа халыклары белән бәйләнеш ясавына мөмкинлек бирмәскә кирәк. Әгәр бу илләрнең мөселманнары күзләрен ачып, хокук-бурычларын аңлап алса, ул безгә иң яман бәла булачактыр. Һәм Төркиянең, һәм дә Иранның дин эшлекләләрен кулда тоту, алар аша сөнни-шигый каршылыкларын көчәйтү кирәк. Ислам динен Азиядән ераклаштыру, христиан динен һәм мәдәниятен анда җисми бер рәвештә тарату һәм җәю зарурдыр.

## Яшерен тотылсын

Безнең галимнәребезнең бүгенгә кадәр дәүләт эшләренә катнашуы Русия мәмләкәтенең алга китешенә киртә булды. Мин үз сәләтемне һәм бәйсезлегемне файдаланып, аларны дәүләт эшләреннән ераклаштырдым. Руханиларның дәүләт эшләренә тыкшынуларын туктаттым, хәзер алар сафка тезелгән гаскәриләр кебек, куллары һәм аяклары бәйле калды. Мин моны гаять бөек бер тәвәккәллек белән гамәлгә ашырдым. Руханиларны дәүләт вә милләт эшләреннән читләштереп, вәкаләтләрен бары чиркәүләрдә дини вазифа үтәү белән чикләдем.

Боларга өстәп бүтән төрле чаралар да куллану кирәк ки, Иран иле узган һәр көн саен тагын да акчасызрак һәм сәүдәсезрәк калсын. Кыскасы, Русия дәүләте Иранны даими артка калдырсын, бәйле хәлдә тотсын, аны теләгән вакытта кыенлыксыз гына үтерүгә кодрәтле булсын. Әмма Төркия дәүләтен юк итүдән элек Иранның җанын алуны киңәш итмим.

Грузия иле Кавказ сызыгының, ягъни Иранның үзәк тамырыдыр. Әгәр Русиянең кодрәтле кулы ул тамырны барып киссә, мескен Иран йөрәгенең тереклек каны агып чыгачак һәм аны шундый хәлсезләндерәчәк ки, мең нәселе терелеп килсә дә, аны кире аякка бастыра алмаячак. Ул чакта Иран мәмләкәте Русия патшаларына дөя кеби тыңлаучан булачактыр һәм Төркиядән соң яшәү ялкыны да сүнәчәктер.

Матди ихтыяҗлар даирәсе булган Төркия эшен бетергәннән соң, Иранны читенлексез юк итү, аның башын кисү мөмкиндер. Моның өчен сез, вакытны югалтмастан, Грузия һәм Кавказияне буйсындырып, Иранның хаким шәхесләрен үзегезгә бәйле вә тыңлаучан итәчәксез. Аннан соң — Һиндстанга күз атарга. Ул мәмләкәт гаять бөек һәм киң бер сәүдә мәйданыдыр. Анда кул сузган тәкъдирдә, Һиндстаннан Англия кәсеп итеп тапкан ачка һәм керемнән дә күбрәк товарлар алыначактыр. Һиндстанның ачкычы — Төркиянең башкаласыдыр. Гизә алган кадәр кыргыз, Хива һәм Бохара сахралары тарафыннан юл сабу сезне максатка якынайтсын. Вакытны бушка әрәм итмәгез, әмма артык ашыгу һәм кабалanudan да сакланыгыз.

Австрия дәүләте белән тыштан дус булырга кирәк. Фәкать шундый бер чара күрү тиешле ки, Германия һәм Австрия әкренләп көчләрен җуйсыннар.

Төркияне Европадан аеру һәм бу гамәлдән Австриягә файда тәэмин итү хәерле. Бу эштә ике юл бар: берсе — Австрияне бүтән бер җирдә мәшгуль итү, икенчесе — Австриягә Төркия биләмәләреннән соңыннан аны кире кайтарып алу ансат булырлык бер өлеш кисеп бирү.

10. Грекларга тыныч һәм дусларча мөгамәләдә булыгыз. Сугыш вакытында алар сезгә ярдәм итәр, чөнки греклар Төркиядән даими зыян күрделәр.

11. Швеция, Норвегия, Төркия, Иран һәм Польшаны басып алганнан соң, Италия һәм Франция белән бердәмлек элемтәсе урнаштырыгыз. Әгәр алардан һичберсе дуслыгыбызны кабул итмәсә, ул чакта, форсаты чыккач, җирләрен басып алыгыз, дәүләтләрен юк итегез. Бу җирләрне кулга төшергәч, дөнья хакиме булырсыз.

12. Әгәр югарыда саналган илләрнең берәрсе сугышны кабул итмәсә, бу ике хөкүмәт (Италия һәм Франция) арасында ызгыш-талаш чыгару кирәк булыр. Бу сурәттә алардан берсе берзаман уртадан калкып чыгып харап булачак. Җиңелгән илләрне талап, кәсеп итеп, сез исә бөтен Европада хакимлек корырсыз. Тора-бара бүтән дәүләтләрнең һәммәсен үз мәмләкәтегезгә кушып, бөтен дөньяга ия булырсыз.

# ҮЗЕБЕЗНЕКЕ, ХАЛЫКНЫКЫ!

Безнең татар тамашачысы арасында артист Хәлим Җәләлов уенын яратмаган кеше бар микән? Шуның кадәр дә халыкчан, шундый да ягымлы һәм бер үк вакытта шаян-җор табигатьле, саф күңелле, эчкерсез җанлы артистны ничек итеп яратмаска, үз итмәскә мөмкин?!

Шуңа күрә дә тамашачы Хәлим Җәләлов уйнаган бер генә спектакльне дә калдырмаска тырыша, аның иҗади яшәвен инәсеннән җебенә кадәр күзәтеп барырга тели, артист хакында һаман күбрәк белергә омтыла.

Әнә шул теләк, әнә шундый омтылыш бик күпләрне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына йөртә, тынгысыз да һәм бер үк вакытта гүзәл дә булган сәнгать дөньясына алып керә.

Ә еллар әкрен-әкрен уза тора икән...

Әле дә хәтеремдә: 1965 елда Хәлим Җәләлов «Ата хакы — тәңре хакы» дигән спектакльдә үзенең беренче ролен уйнаган иде. Яшь егет Севка роле иде ул. Әнә шул елларда Хәлим Җәләлов турында матбугатта мин болай дип язган идем. «Бу рольне Х. Җәләлов зур осталык белән башкара. Ул сәхнәдә үзен иркен тота. Аның Севкасы гади дә, табигый дә. Шуңа бу актерның күп кенә күренешләрдә тамашачы игътибарын үзендә тотуы һич очраклы түгел. Академия театрының Х. Җәләловны үз труппасына алуын хупларга кирәк. Һәм без уңышлы дебют ялгыз калмас, Җәләловның актерлык язмышы бәхетле булыр дип ышанабыз».

Бу юллар язылганга инде 30 елга якын гомер үткән. Һәм мин, әлеге сүзләрнең авторы буларак, биредә кистереп әйтә алам: әйе, чынлап та, артистның язмышы бәхетле булды. Хәлим Җәләловның илле еллыгына багышланган кичәдә бу бигрәк тә ачык чагылды. Шагыйрь Зөлфәт үз чордашы Хәлим Җәләловка багышлап язган шигырендә болай ди:

*Халык җанын, халык ышанычын*
*Үз иңенә алган хәлендә,*
*Язмышларның якты сәхнәсенә*
*Күтәрелә яңа Хәлимнәр.*
*Күңелем булмас, мондый көнендә мин*
*«Бәхет телим, дускай!» димәсәм,*
*Иң зур бәхет — халык мәхәббәте —*
*Бәхетеңнән чынлап көнләшәм.*
*Ачылсыннар йозләр сине күреп!*
*Сәнгать шифасына керендер.*
*Ни кылансаң — шул килешә сиңа,*
*Елат, көлдер, сөйдер, сөендер!*

Шагыйрь дөрес әйтә: чыннан да, иң зур бәхет, ул — халык мәхәббәте. Артист Хәлим Җәләлов моны даими тоеп яши, иҗат итә.

Әйе, мондый мәхәббәтне тою — бик күңелледер, бик рәхәттер. Ләкин бит әле шунысы мөһим: бу хөрмәтле дәрәҗәгә, бу мәртәбәгә нинди юл белән ирешелгән? Билгеле булганча, халык хөрмәтенә ирешергә теләүчеләр бик күп, алар бихисап! Иҗат дөньясында бигрәк тә. Ә менә ни өчен сирәкләр генә чын мәгънәсендәге халык мәхәббәтен яулап ала? Моның сере нәрсәдә икән?

Минем уйлавымча, моның сере гади һәм бер үк вакытта тирән дә. Ләкин кыска гына итеп, бер сүз белән әйткәндә, бөтен хикмәт м и л л и җ а н л ы и җ а т ч ы булуга кайтып кала. Иң зур сер әнә шунда!

Ә монысына инде бөтен яшәвеңнең, гомер юлыңның, алай гына да түгел — әле сине дөньяга китерүчеләрнең дә сәнгатькә — ягъни милләт җанының иң нечкә кылларын зеңләп, җырлап торган дөньяга бәгъле булуы, күңелләре яткан булу сораладыр...

Хәлим Җәләловны алсак, 1940 елда дөньяга килә ул. Сәхнәдәш дусты Равил Шәрәфиев белән бер авылдан — Балык Бистәсеннән ерак түгел урнашкан Зур Солтан дигән авылдан.

Сугыш алды еллары... Татар авыллары өстеннән дә революция гарасаты узган... Иң эшчән кешеләр кулак итеп Себер сөрелгән, меңләгән еллык тәҗрибәне үзләштергән халыкны «яңача яшәргә» өйрәтү башланган «совет» дигән сүз телдән төшми... Ләкин шулай булса да, бу елларда әле авылның җаны тере, анда милли рух исән! Әле меңләгән еллар буе ныгытылган әхлакый җирлек, нигез какшап ук җитмәгән. Шытып чыккан һәр үсемлеккә әйләнә-тирәнең һава шарты тәэсир иткән шикелле, дөньяга килгән һәр балага авыл үзенең рухи тәҗрибәсен, акылын, фикерләү рәвешен, әхлак-әдәбен сеңдерә бара. Һәр сабый татар мөхитендә татар булып үсә, тәрбияләнә.

...Хәлим үзенең әтисен хәтерләми. Әтисе 1942 елда Ленинград янында һәлак булган аның... Зур Солтан кешеләре исә әтисенең бик тә җор табигатен, җыр-моңны яратуын яхшы хәтерли. Үзе ишеткән бәетләрне җыеп та барган Хәлимнең әтисе. Күп еллардан соң әтисенең әнә шул дәфтәре кулына килеп керә дә, Хәлим әллә нишләп китә... Әтисенең бөтен җанын, күңелен сөйли торган бер серле чишмәгә тап булгандай тоя ул үзен шулчак.

Ә бит бер карасаң, Хәлимнең әтисе гап-гади хисапчы гына булган. Әйе, әйе — хисапчы гына! Әмма кеше күңеле, кеше җаны һич тә һөнәргә генә бәйле түгел шул! Хисапчылар арасында да шагыйрь җанлылар күп, шагыйрь дип аталучылар даирәсендә дә хисапчылар байтак... Хәлим дә, күрәсең, әтисенә тарткан. Шагыйрь җанлы, шагыйрь табигатьле артист ул.

Тол калган әнисе җиде малай турында кайгырта. Ул көн буе колхоз эшендә, ә иртәкич абзар-кура тирәсендә мәш килә.

Кичләрен инде, тамак ялгап алгач, бәләкәй малайлар өчен сихри дөньяның ишекләре ачыла — «борын-борын заманда» дип, әниләре чираттагы әкиятен сөйли башлый. Кечкенә йөрәкләр гаделлек һәм явызлык көрәшен мавыгып тыңлый, үзләре дә шуңа кушыла. Әнә шулай итеп, аларга инде кечкенәдән үк милли рух сеңгән, татар җаны иңгән.

Менә хәзер Хәлим Җәләловның балачагы үткән елларны күзәллап утырам да, бүгенге авылны уйлап уфтанып куям. Чын милли иҗатчылар тудыручы мөхит хәзерге авылларыбызда сүнеп бара, ләбаса! Чаң сугарлык хәл бит бу — тормышның яме, гүзәллеге кимү ич бу!

Ә ул елларда, тормыш авыр булса да, авыл мәктәбендә төрле түгәрәкләр эшли. Хәлим аларның берсен дә диярлек калдырмый. Бигрәк тә шигърияткә тартыла, бик күп шигырьләрне ятлап ук ала, аларны сөйләп йөри. Хәлимнең шигърият белән мондый дуслыгы гомер буе дәвам итә. Ул 1972 елны хәтта шагыйрьләр секциясендә поэзия турында доклад та ясый. Аның чыгышын тыңлаганнан соң Хәсән Туфан болай ди: «Кара, бүгенге артистлар да шигырьне бик шәп тоя икән бит! Кариевлар, Мутиннар токымы болар... Егет икәнсең!»

Әйе, Хәсән аганың җылы сүзен ишетердәй, сәхнәдән уйнап халык мәхәббәтен казанырдай егет үзенең иҗат юлын мәктәптән үк башлый. Габделхәй абыйлары Яруллин оештырган үзешчән сәнгать түгәрәге аның күңеленә канат куя.

Ә аннары инде Казан... Юк, юк — театр училищесы түгел, ә авыл хуҗалыгы институты... 1961 нче елда исә Хәлим чирәм җирләр күтәрешә, комбайнер ярдәмчесе була. Казанга кайткач, укуын кич дәвам итәргә уйлап, җитен комбинатына эшкә керә. Шул ук вакытта М. Вахитов исемендәге клубтагы драма түгәрәгенә дә йөри башлый. Аны исә академия театры артисты Һ. Солтанов җитәкли.

Шул ук 1961 елның көзендә Казанда «театр училищесы ачыла икән» дигән хәбәр тарала. Хәлимнең күңеле алгысына: теләк тә бик көчле, ләкин курку да нык, һич җиңәрлек түгел. «Буй да бәләкәй,— дип уйлый Хәлим,— кыяфәт тә әлләни түгел...»

Тәвәккәл таш яра, дип бик дөрес әйткәннәр икән! Илтеп бирә Хәлим документларын училищега. Ә имтиханны татар театрының иң зур осталары ала: Хөсәен Уразиков, Ширъяздан Сарымсаков, Габдулла Шамуковлар! Исемнәре генә дә ни тора бу сәхнә осталарының! Имтихан бара торган бүлмә янында егетләр-кызлар мәш килә... Тез буыннары калтырауны көчкә тыя-тыя Хәлим дә эчкә үтә. Башта шигырь сөйли, аннары бер мәсәл... Ә икенче көнне этюд уйнап күрсәтә. Һәм аны, өченче турга калдырып та тормыйча, шундук училищега алынган дип исәплиләр! Егетнең башы түшәмгә тия, шатлыгының чиге-чамасы булмый! Ул бит хәзер артистлар дөньясында яшәячәк дигән сүз — күпме хыялланган, никадәр ашкынган сихри дөньяда!

Актерлык осталыгы дәресләрен Хәлим артист Рәфкать Бикчәнтәевтән ала. Олы талантка ия, сәхнәгә үлеп гашыйк җан була ул...

Училище укучыларын Камал театры спектакльләренә дә еш чакыралар. Күбрәк массовкага, әлбәттә. Чөнки биредә сәхнә сәнгатенең иң төп принциплары үзләштерелә, артист иң тәүге кат чарлана, сынала.

Хәлим баштан ук табигый һәм иркен уйнап китә. Ә диплом спектаклендә инде ул башкалардан нык кына аерылып та тора. «Карагыз, кеше ничек тиз үсә! Карагыз, ул Гомәр ролен ничек оста башкара!» — дип яза аның турында «Социалистик Татарстан» газетасы үзенең 1965 елгы 22 май санында.

Шулай итеп, яшь артист Хәлим Җәләловның язмышы хәл ителә. Наил Әюпов белән икесен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына алалар. Театрның үзенең

дә иҗади күтәрелеш кичерә башлаган чоры бу. Баш режиссер булып Марсель Сәлимҗанов эшкә тотынган чак. Артистлар составы да бик көчле. Ш. Биктимеров белән Н. Гәрәева иҗаты чәчәк ата башлаган еллар. Ф. Халитов, Г. Шамуков, Ш. Әсфәндиярова әле сәхнәдә уйнаган чор... Бу осталар белән бергә-бергә уйнау яшь артист өчен иң зур бәхет түгелмени!

Өлкән артист Габдулла Шамуков Хәлимне беренче айларда ук үз итә, якын күрә. Һәр сүзне кеше йөрәгенә барып җитәрлек дәрәҗәдә сихри тәэсирле итү осталыгына да ул өйрәтә. Аның сабакларын Хәлим әле дә күңел түрендә йөртә, кадерләп саклый.

Хәлим Җәләловның беренче уеннарыннан ук аңа тамашачылар да, театр тәнкыйтьчеләре дә игътибар бирә. Хәлим спектакльләрдә еш катнаша, беренче елны гына да М. Әмирнең «Тормыш җыры»нда Каюмны, Ә. Баяновның «Күзләре нинди иде?»сендә Рифкатьне, Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы»нда Әсгатьне уйный.

Икенче елда тагын шундый ук онытылмастай рольләр. Ч. Айтматовның «Гүзәлем Әсәл»ендәге Камал, Н. Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу»ндагы Гариф һәм Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ендәге Атамыш... Ягъни һәр ел саен артист өч яисә дүрт яңа роль иҗат итә.

«Татарстан яшьләре» газетасының 1968 елгы 23 апрель санында театр дөньясына гашыйк булган студент (Г. Камал театрының хәзерге директоры) Шамил Закиров болай дип яза: «Сәхнәдә аның үз-үзен иркен тотышына, яшьләргә хас булган темпераментына, геройларның эчке дөньясын оста итеп тотып ала белүенә гаҗәпкә каласың». Ә инде «Социалистик Татарстан»ның 1967 елгы 15 июнь санында Д. Гыймранова белән Р. Кәримов мондый сүзләр әйтә: «Шәрифҗан-Җәләлов бер ягы белән дә күзгә артык ташланмый торган гап-гади авыл малае. Күп нәрсә белә дә кебек, ләкин фикер мөстәкыйльлегенә ирешмәгән». Әлеге сүзләр А. Гыйләҗев әсәре буенча куелган «Җиргә тапшырылган серләр» спектакле турында. Чыннан да, бу образ яшь Хәлимнең үзенә дә бик туры килә. Чөнки икесе дә авылдан, икесе дә хыялыйлар... Тормыш тәҗрибәсе әле икесенә дә җитми, шуңа күрә төпле фикер йөртү дә юк дияргә була. Ләкин һәр икесендә олы тормыш көче, киләчәк бар!

Алтмышынчы еллар ахырында Г. Камал театры сәхнәсендә «Гүзәлем Әсәл» куелды. Аны күренекле үзбәк режиссеры Ташхуҗа Хуҗаев әзерләде. Бу спектакль — театрның истә калырдай эшләреннән берсе. Нәкъ әнә шул әсәр өстендә тир түккәч чакта атаклы үзбәк режиссеры Хәлим турында болай ди: «Театрыгызда шәп актер үсеп килә, тик масая гына күрмәсен». Хуҗаевка Хәлимнең сәхнәдәге ихласлыгы, табигыйлеге һәм тормыш чынлыгын бирә алуы бик ошый. Чөнки үзбәк театры үзе дә бит баштарак татардан, аннары урыстан нәкъ әнә шундый сыйфатларны алга сөргән спектакль үрнәкләре ала, шулар рухында тәрбияләнә. Ягъни бирелә психологик яктан да, режиссура буенча да уртак яклар байтак була. Шуңа күрә дә Хуҗаев, Казанга килгәч, татар артистлары белән бик тиз уртак тел таба, җиңел эшли.

Хәлим Җәләлов үзенең иҗат юлын массовкалардан алып китте, дигән идек. Кечкенә генә өзектә дә ул авыл яшьләренең шаянлыгын, уен-көлке яратуын, сүз уйнатуларын — кыскасы, яшьлек рухын бирә алды. Тора-бара аның образлары һаман истә кала торганрак була барды. Мисал өчен «Зәңгәр шәл»не генә алсак та, качкыннарның «Кара урман»ны җырлау күренеше никадәр тәэсирле икәнен күрербез. Ә бит биредә Хәлимнең өлеше бик зур! «Яшь йөрәкләр» белән «Казан сөлгесе»ндә дә шундый ук хәл. Ә инде «Сүнгән йолдызлар»да авыл егетләре башта уйнап көлсәләр, соңрак «Каз канаты» көенә ничек моңлы итеп, үзәкне өзәрдәй хисләнеп җырлыйлар. Әлеге спектакльләрдә Хәлим төп рольдә булмаса да, әсәрнең идея эчтәлеген ачуда аның гаять әһәмиятле иҗади көче салынган. «Моңлы бер җыр»да исә үлем җәзасы көтеп утыручы Җәлилчеләрдән берсе — Абдулла Баттал. Биредә дә дусларының күңелен күтәрергә теләү, уен-көлке сөйләү, яшәү дәрте... һәм инде бергәләп башкарылган тетрәндергеч җыр — «Сибелә чәчәк»... Геройларның да, тамашачының да күзләрендә яшь, ачы яшьләр...

Җитмешенче еллар башында Хәлим Җәләлов үзенең иҗади үсеше өчен бик тә мөһим булган ике образ тудырды. Берсе — «Диләфрүзгә дүрт кияү»дә Шәкүр, ә икенчесе «Агыйдел»дәге Ильяс. Соңгы образга килсәк, без хәзер сыйнфый көрәшкә бүтәнчәрәк карыйбыз. Ләкин, ул карашлар үзгәрсә дә, яшь кешенең һәр чорда дәртләнеп яшәргә һәм зур эшләргә алынырга тиешлеге бәхәссез хакыйкать булып кала бирә. Ягъни биредә энтузиазм, рухлану турында сүз бара.

Хәлимнең Ильясы нәкъ әнә шундый герой. Күренекле театр тәнкыйтьчесе Гази Кашшаф болай дип язды: «Көчле, эмоциональ нюансларга игътибар итеп, егерменче еллар авыл комсомолецының рухына кереп уйный». («Соц. Татарстан», 1974 ел, 20 й саны). Шул ук газетада Габдрахман Минский мондый фикер дә әйтә: «Х. Җәләлов Ильяс образында, иң әүвәле, бу образга хас булган балаларча гөнаһсызлыгы, егетләрчә кыюлыгы, әдәплелеге һәм, аеруча, дуска карата кристаллдай сафлыгы, тугрылыгы белән тамашачыны җәлеп итә». Баян Гыйззәт белән Рәшит Ягъфәров та яшьләр газетасында: «Хәлим Җәләлов — гаять үзенчәлекле, тормышны тирәнтен аңлый белүче артист. Аның геройлары һәрвакыт хәрәкәтчән, темпераментлы, шул ук вакытта шигъри күңелле, юморга бай, оптимистик рухта булалар» дип язды.



Сәхнә белгечләренең мондый бәһасенә лаек булу өчен, әлбәттә, артистның үзенең дә чын авыл егете булуы, кеше холкын тирән аңлый алуы һәм табигать тарафыннан бирелгән, зур тырышлык куеп үстерелгән сәләт кирәк иде. Ягъни һаман да шул формулага әйләнеп кайтабыз: талант һәм хезмәт, хезмәт, хезмәт!

Шәкүр исә бөтенләй башка тип герой. Биредә җиңел, уенчак характер, шук егет. Шунысын да әйтик: әлеге спектакль сәхнәдә 600 мәртәбәдән күбрәк уйналды инде. Диләфрүзнең бик күп «кияүләр»е алышынды, аларны башка артистлар уйный башлады, әмма Шәкүрне әле дә Хәлим башкара! Шушы хәл үзе генә дә артистка иң яхшы характеристика түгелмени?! Әйе, «Советская культура» газетасы 1975 елгы 25 июль санында бер дә юкка гына Хәлим Җәләлов уенына зур бәя бирмәде! Чыннан да, Диләфрүзнең иң әйбәт «кияве» иде ул!

Шул ук вакытта Хәлим Җәләлов башкарган рольләр икегә дә аерыла бардылар. Бер якта әнә шул Шәкүр кебек шук-шаян типлар булса, икенче якта инде драматик кичерешле, лирик-романтик затлар. Мондый персонажларны Хәлим Җәләлов тудырган образлар арасыннан күп табырга мөмкин. Мисал өчен Х. Вахитның «Ике килен-килендӑш»ендә Гыймран, Н. Исәнбәтнең «Зифа»сында Бикәмәт һәм шул ук Н. Исәнбәтнең «Качаклар»ында Хөләй бер якта торсалар, икенче якта инде Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми»еннән Шәвәли, А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»еннән Адашны күрәбез. Әлеге образларның бер ишләрендә кешелек кимчелекләреннән дусларча, йомшак итеп көлү, елмаю булса, икенчеләрендә инде мөнәсәбәт сатирага ук якынлаша. Андый очракта инде артист үзе тудырган типка карата нәфрәтен кызганмый, аның рухи мескенлеген, катып калганлыгын һәм тыштан гына ялтырарга тырышуын төп-төгәл итеп ача, безгә күрсәтә.

Г. Камал исемендәге театр күптән түгел Т. Миңнуллинның «Ат карагы»н куйды. Биредә Хәлим Җәләловка, мөгаен, үз гомерендә беренче мәртәбәдер, явыз кеше ролен уйнарга туры килде. Ул — Сәйхун. Усал, явыз тип, ләкин шул ук вакытта кыю да. Ләкин аның бу кыюлыгы яхшылыкка түгел, ә начарлыкка таба юнәлтелгән.

Бу образны ачуда Хәлим Җәләловның моңа кадәр туплаган тәҗрибәсе, осталыгы тулысынча диярлек күренде. Хәлим башкаруындагы Сәйхунда үзе турында гына кай-



*«Диләфрүзгә дүрт кияү» спектакленнән күренеш. Шәкүр ролендә — Х. Җәләлов.*

*«Агыйдел» спектакленнән күренеш. Ильяс ролендә — Х. Җәләлов. Мәһибикә ролендә — Ф. Хәйруллина.*

гыртып һәм шуның өчен теләсә нинди адымга әзер торган анархист гәүдәләнә. Үзенә каршы төшкән теләсә кемгә ул ерткычларча ташлана, аны өзгәләп атарга әзер. Күргәнегезчә, мондый образ Хәлимнең әлегә кадәр уйнаган геройларына бөтенләй дә охшамаган. Әмма спектакльдә артист тулы канлы һәм тамашачыны ышандыра алырдай персонаж тудыра.

Аның элеккеге остазы Рәфкать Бикчәнтәев белән Хәлим арасында мондый бер охшашлык бар. Алар икесе дә образ өстендә эшләүне геройның тышкы кыяфәтен ачыклаудан башлыйлар, иҗатка шуннан тотыналар. Ә аннары инде персонажның холык-характерын аңлау, яшәү логикасын, яшәү рәвешен ачыклау...

Бәлки нәкъ менә шуңа күрәдер дә Хәлим Җәләлов иҗат иткән образлар бер-берсеннән үтә нык аерылып торалар, ачык булып истә калалар. Әйтик, В. Шекспирның «Чамасына күрә чарасы»ндагы Помпей бер төрле булса, К. Гоццининың «Болан патша»сындагы Бригелла инде бөтенләй бүтән кеше. Шулай ук А. Гыйләҗев белән А. Яхиннның «Шамил Усманов»ындагы Сәхидән В. Шукшинның «Шома кешеләр»ендәге Почык борын да әллә каян аерылып тора. Ә инде Тяпа белән Сарбай турында сөйлисе дә юк. Болары М. Горький һәм Т. Миңнуллин әсәрләренең геройлары.

Хәлим Җәләлов бик күп укый, үзебезнең татар әдәбиятын да, дөнья халыклары тудырган җәүһәрләрне дә. Гомумән, әдәбиятта һәм тулаем мәдәни тормышта аны кызыксындырмаган бер генә тармак та юк дияргә була. Күрәсең, бусы да шагыйранә җанның гадәти чагылышыдыр. Шигъри күңел, мөгаен, шунсыз яши дә алмый торгандыр.

Урыс драматургы А. Вампилов пьесалары татарча Хәлим Җәләлов тәрҗемәсендә китап булып дөнья күрде. Хәзер ул белорус драматургы А. Дударов әсәрләрен тәрҗемә итә.

Әйе, тынгысыз зат ул Хәлим Җәләлов — беркайчан да эшсез, шөгыльсез яшәми. Радио һәм телевидение тапшыруларында да иң актив катнашучылардан ул. Бер тапшыруда шигырь укыса, икенчесендә инде спектакльдә катнаша, өченче көнне исә мавыгып-мавыгып хикәя укып утыра... Ә аннары радио тыңлаучылардан, телевизор караучылардан аңа күп санлы хатлар ява. Рәхмәт сүзләре ява...

Халкыңа, сөйгән милләтеңә шулай бирелеп хезмәт итү үзе зур бәхет түгелмени?! Әйе, Хәлим Җәләлов — бәхетле иҗатчы, бәхетле артист!

**Ильтани ИЛЯЛОВА**

Китап күзәтү

# БОРЫНГЫ ТАМЫРЛАР ЭЗЕННӘН

Милли хәятыбызның нинди генә әтрафы турында сүз чыкмасын, горурланып халкыбызның мең еллык бай үткәнен, мәдәниятен, мөстәкыйль дәүләтчелек тарихын искә алабыз. Чыннан да, ислам диненә нигезләнгән милли мәдәниятебезгә генә дә инде мең дә бер йөз ел булды бит!

Әйе, без «мең еллык тарихыбыз, мәдәниятебез бар» дибез. Әмма әлеге горур сүзләрдән соң бу «мең еллык» тарихка якынрак килергә, аның байлыгын, бөеклеген ачып күрсәтергә кирәк булса, кыенрак хәлдә калабыз. Чөнки киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итәрлек чын мәгънәсендәге фәнни хезмәтләребез аз. Яңа заман тарихыннан арырак, тирәнрәк атлаган саен, бүгенге буын караңгылыкка төшеп киткән кебек. Тарих тамырларына ныграк якынайган саен караңгылык арта бара. Ә бит бу мең еллык тарих, мәдәният — халыкның милли аңын, горурлыгын үстерүдә иң көчле чараларның берсе. Менә шуңа күрә рухи тарихыбызның борынгы, башлангыч чорларын яктырта торган хезмәтләр бүгенге көнне — милләттәшләребезнең, бигрәк тә яшь буынның, уянып, халкыбыз азатлыгын, мәдәниятен яклап мәйданнарга чыккан көннәрдә — аеруча мөһим. Бу җәһәттән мин Гамирҗан Дәүләтшиннең Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән (1990 ел) «Волжская Булгария: духовная культура» исемле китабын күздә тотам.

Бу китапта халкыбызның нәкъ менә 1000 ел элек булган тарихы хакында языла. Алай гына түгел, ул ерак бабаларыбызның иң аз өйрәнелгән, безнең өчен иң караңгы булган иҗтимагый тормышы — рухи мәдәниятенә багышланган. Дөрес, Идел буе болгарларының иҗтимагый тарихы, дәүләт тарихы, матди мәдәниятләре археологлар, тарихчылар, сәнгать белгечләре тарафыннан билгеле бер дәрәҗәдә өйрәнелгән. Әмма моны рухи мәдәниятkә карата әйтеп булмый. Бу мәсьәлә һәм дә аңа бәйләнешле борынгы болгарларның башлангыч белемнәре, халык иҗаты, фәнни казанышлары, дөньяга карашлары Г. Дәүләтшиннең хезмәтендә монографик планда беренче тапкыр тикшерелә.

Китапта яктыртыла торган X—XIII йөзләр башы татар халкының мәдәният тарихында әһәмиятле урын алып тора. Бу — мәдәниятебезнең чишмә башы. Бу чорны дөрес, тегәл күрсәтү, аңа дөрес бәя бирү алга таба мәдәният үсешен, аның төп сыйфатларын, юнәлешен дөрес билгеләүнең алшарты булып тора. Без монда, беренче чиратта, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларын күздә тотабыз. Бу чорларның Болгар дәүләте тудырган рухи мәдәният белән тыгыз, аерылгысыз бәйләнеше бар. Гомумән, безнең галимнәр алдында бик әһәмиятле бурыч тора. Бу — рухи мәдәниятебезнең төрле тармакларын, чорларын тикшереп «мең еллык тарихыбыз» дип йөртелгән гыйбарәне өзлексез, эзлекле рәвештә бөтен яктан ачып күрсәтү. Әлеге олуг максат ягыннан караганда, Г. Дәүләтшиннең хезмәте олы панораманың мөһим бер өлеше булып күз алдыбызга килеп баса.

Болгар чорына мөрәҗәгать иткән тикшеренүчене күп кыенлыклар көтә. Шулардан күзгә иң нык ташланганы, бәрелеп торганы — язма чыганакларның азлыгы, ярлылыгы, булганнарының да безнең көннәргә кадәр аерым кисәкләрдә генә килеп җитүе. Бу чыганаклардагы мәгълүматлар әле еш кына бер-берсенә каршы да киләләр. Әмма бу очракта да хәл өметсез үк түгел әле. Сайланган теманы мөмкин кадәр тулы тикшерү өчен бер юл кала — мөмкин булган барлык чыганакларны туплап, аларны үзара чагыштырып файдалану. Мондый ысул бик җентекләп эшләүне таләп итә. Әмма бу мөһим мәсьәлә Г. Дәүләтшин китабында уңышлы хәл ителгән һәм әһәмиятле нәтиҗәләргә китергән.

Автор чыганаклар мәсьәләсен комплекслы рәвештә хәл итә. Язма чыганаклардан тыш киң күләмдә археология, этнография, тел материалларын, халык иҗат үрнәкләрен эшкә җигә. Алар бер-берсен бик урынлы тулы-

ландырып, раслап хезмәттәге мәсьәләне ышанычлы хәл итүгә китерә. Рухи мәдәният — гаять киң дөнья. Китап авторы бу дөньяның бар ягын күзәтүне максат итеп куймаган. Хезмәттә күтәрелгән мәсьәләләр ике бүлектә бәян ителә. Беренче бүлек «Халык мәдәнияте», икенчесе «Профессиональ мәдәният» дип атала. Бу бүленеш очраклы түгел, әлбәттә. Ул авторга болгар бабаларыбызның рухи мирасын үсештә, эволюциядә карарга мөмкинлек биргән. Чыннан да, мондый төзелеш укучыга рухи мәдәниятнең төрле баскычларын, үсеш этапларын (башлангыч белемнәрнең фәнни өлкәләргә нигез булуын, халык авыз иҗатының язма әдәбиятның чишмә башы булуын, мәҗүсилек чоры белән бәйләнгән карашларның монотеистик ислам нигезендәге дөньяви карашларга үсүен һ. б.) ачыкларга булыша. Хронологик планда рухи мәдәниятнең үсешен болай ачык күрсәтеп булмас иде — бу чорда халык мәдәнияте профессиональ мәдәният белән бергә үрелеп бара.

Әлбәттә, Гамирҗан Дәүләтшиннең хезмәте буш урында барлыкка килмәгән. Автор моны үзе дә күләме зур булмаган, ләкин бай эчтәлекле историографик күзәтү бүлекчәсендә күрсәтә. Бу өлештән күренгәнчә, болгарларның рухи мәдәнияте тарихына теге яки бу чамадагы күзәтүләр, фаразлар рус, , татар, совет галимнәренең хезмәтләрендә шактый очрый. Әмма алар барсы диярлек үз фәнни өлкәләреннән чыгып, үз материалларына таянып кына фикер йөрткәннәр. Г. Дәүләтшин исә фәнни әдәбиятка да, чыганакларга таянган кебек үк, комплекслылык позициясеннән чыгып якын килә һәм файдалана. Әйтергә кирәк, автор, «комплекслы ысул» төшенчәсе астында төрле характердагы һәм төрле чордагы чыганакларны чагыштырып тикшерүдән тыш, төрле халыкларның, болгарлар белән якын мөнәсәбәттә булган дәүләтләрнең дә мәдәниятләрен чагыштырып күрсәтүне күздә тота. Һәм китапта нинди генә яктыртылган мәсьәләне алсак та, борынгы болгарларда календарьмы, саннар яки үлчәүләр системасымы, космогоник карашлармы — барысы да менә шул комплекслы ысул нигезендә җентекләп тикшерү, мәгълүматларны төрле чыганаклардан бөртекләп-бөртекләп җыю бәрабәренә күз алдыбызга бербөтен күренеш булып килеп баса.

Шул мәсьәләләр арасында, безнең карашыбызча, аеруча мөһимнәрдән — Идел буе Болгар дәүләтендә мәҗүсилек белән исламның үзара мөнәсәбәте. Җәмгыятьтә хөкем сөрә торган дин, дөньяга караш һәм идеология буларак, шул җәмгыятьнең дөньякүләм цивилизациядәге тарихи урынын, дәрәҗәсен, төзелешен, рухи тормышның нигезен билгели. Авторның хаклы язуынча, әгәр дә кайбер тикшеренүчеләргә ияреп, X—XIII йөзләрдә Идел буе болгарларында ислам дине киң таралмаган, мәҗүсилек өстенлек иткән дип бәян итсәк, без ярылып яткан бик күп фактларны инкарь итәргә мәҗбүр булыр идек. Бу Болгар җәмгыятенең ислам нигезендә корылган дәүләт төзелешенә, «югары язма профессиональ мәдәниятенә» (77 бит), гомумән, Идел буе болгарлары дәүләтенең үз заманы өчен алдынгы ислам дөньясының «төньяк форпосты» булуын күрмәмешкә салыну булыр иде. Г. Дәүләтшин, күп фактларга таянып (X йөз гарәп сәяхәтчеләренең язмаларыннан башлап археолог Е. А. Халикованың махсус тикшеренүенә кадәр) һәм аларга үзенең дәлилле материалларын өстәп, бу нигезсез фаразын кире кага. Чыннан да, Болгар дәүләте үзенең күп санлы шәһәрләре, үзәкләштерелгән хакимияте белән, чәчәк аткан фәне, мәдәнияте белән ислам цивилизациясенең җимеше булмаса, нинди цивилизациянең казанышы соң? Һәм бу мәҗүсилек нигезендәге цивилизация ни өчен болгарларга күрше булган халыкларда шундый казанышларга китермәгән соң? Бу сорауларга җавап кирәкми. Әгәр дә без инде мәдәниятнең аерым өлкәләрендә, әйтик, сынлы сәнгатьтә, йә булмаса Болгар дәүләтенә буйсынган, аның составына кергән аерым кабиләләрдә үткән мәҗүсилек чорының сизелерлек йогынтысы ислам дине киң таралгач та әле шактый дәвам иткән дисәк, бу башка мәсьәлә. Болгар дәүләтенең социаль-икътисади мөнәсәбәтләрендә, тормышында да хәл бер төсле булмаган. Ләкин сүз җәмгыятьнең, дәүләтнең төп сыйфатларын билгели торган факторлар турында бара. Әйтик, Радищевның «Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт»ендә күренгәнчә, Рәсәй империясенең Европага хас башкаласыннан йөз чакрым чыгып китмәс борын ук башка гасырга гына түгел, башка тарихи чорга диярлек эләгә. Бу бит X нчы йөз түгел, ә XVIII гасыр ахыры. Ләкин моңа карап без Рәсәй дәүләтен Европа дөньясыннан аерып карамыйбыз. Чөнки бу дәүләтнең төп сыйфатларын, цивилизация дәрәҗәсен Петербург белән Мәскәү билгели, ике арада вәхшиләрчә яшәүче авыллар түгел.

Бәяләнә торган хезмәтнең тагын бер уңышлы ягын билгеләп үтәсе килә. Хезмәтнең фактик материалга байлыгы, авторның үз алдына куйган төп мәсьәләләрне ачыклаудан тыш, тарихи фәннәр алдында киң планда торган

татар халкының этногенез мәсьәләсен, болгар-татар мәдәниятенең варисларын, борынгы бабаларыбызның башка илләр, халыклар белән бәйләнешләрен ачыклауда үз өлешен кертә. Аталган мәсьәләләр бүгенге көндә галимнәрне, зыялыларны гына түгел, киң җәмәгатьчелекне дә кызыксындыра.

Иҗтимагый фикер тарихы күзлегеннән караганда шуны да әйтергә кирәк: Г. Дәүләтшинның бу хезмәте болгар чорының социаль-фәлсәфи мирасы мәсьәләсен тикшерүдә дә зарури башлангыч эш һәм мөһим чыганак булып тора. Бу җәһәттән авторның үз хезмәтен болгар чорының фәлсәфи фикерен тикшерүдә төп чыганак булган Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ына карата күзәтүләр белән төгәлләве гыйбрәтле күренеш.

Гамәли куллану ягыннан караганда рухи мәдәниятебез тарихының аеруча актуальлеген, китапның уңышлы төзелешен, аңлаешлы һәм кызыклы эчтәлеген истә тотып, без аны хәзерге көннәрдә аякка бастырыла торган татар гимназияләре һәм мәктәпләренә дәреслек-кулланма итеп тәкъдим кылыр идек. Мондый хезмәтләр яшь буынны борынгы рухи мирасыбыз белән таныштыруда, аларда тарихыбызга кызыксыну уятуда бик кирәк. Бу очракта китапны, әлбәттә, татар теленә тәрҗемә итеп, уку курсына бераз яраклаштырырга кирәк булачак. Гомумән, китап инде тиз арада таралып бетте. Аны тагын да зур тираж белән киң халык катлавына җитәрлек тел һәм эчтәлек белән бастыру бик зарури. Шулай ук бу хезмәт нигезендә югары уку йортларының тиешле факультетларында махсус курс әзерләргә мөмкин булыр иде.

Хезмәтнең тагын бер уңай, аның фәнни әһәмиятен күтәрә торган ягы — китап ахырында бирелгән кушымталар-җәдвәлләр һәм рәсемнәр. Алардагы мәгълүматлар бер яктан хезмәтнең эчтәлеген баетса, икенче яктан материал үзләштерүне һәм аның белән файдалануны җиңеләйтә.

Хезмәт эчтәлегенә бер-ике искәрмә һәм тәкъдим дә әйтәсе килә. Киләчәктә китапның икенче бүлеген («Профессиональ мәдәният») билгеле чыганакларны тулырак ачып һәм яңа материалларны да ачыклап, баетасы бар. Беренче бүлек белән чагыштырганда, икенчесе ярлырак булып күренә. Урыны белән хезмәттә кечкенә генә фактлардан зур нәтиҗә ясау очраклары да юк түгел. Мәсәлән, әдәбият белгечләренә ияреп булса кирәк, автор, Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасыннан бер юл китереп (Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүенә бәйләнешле), Н. Коперникның 1515 елны эшләгән бөек, чын мәгънәсендә революцион фәнни ачышы ислам дөньясы өчен күптән билгеле нәрсә булганын исбатлый (152 бит). Сүз дә юк, китерелгән шигырь юлы бик кызык факт, ләкин бер факт мондый җаваплы нәтиҗә ясау өчен җитеп бетми. Һәрхәлдә, бүген фән тарихы раславынча, урта гасыр фикер ияләре өчен, шул исәптән, ислам дөньясының бөек математик һәм астрономнары өчен Аристотель-Птоломейның геоцентрик дөнья төзелеше шиксез фәнни теория буларак кабул ителә иде. Әлбәттә, фән тарихы, бигрәк тә Шәрык фәне тарихы әлегә кадәр күп серләр саклый, шуңа күрә бу өлкәдә алдынгылык, беренчелек мәсьәләсе яңа мәгълүматлар табылганчы ачык кала...

Кайсыбер очракта фәнни терминнарны куллануда да төгәллек җитеп бетми. Мәсәлән, монотеизм төшенчәсе турында фикер йөрткәндә, Гамирҗан Дәүләтшин «Мәҗүси монотеизм»га каршы ислам динен күздә тотып, «Сыйнфый монотеизм» төшенчәсен куллана (76 бит). Ләкин мәҗүсилек тә сыйнфый җәмгыятькә хас күренеш бит. Әйтик, колбиләүчелек җәмгыятенә. Димәк, ул да сыйнфый дин булып чыга. Безнең фикеребезчә, мәҗүсилек белән ислам арасында принципиаль аерма нәкъ менә шул «монотеизм» төшенчәсендә. Мәҗүсилек чын мәгънәсендә монотеистик дин түгел, ул еш кына бер алланы (Тәңре — төркиләрдә, Зевс — борынгы грекларда, Перун — борынгы славяннарда һ. б.) башкалардан өстен куйса да, башка илаһи көчләрнең, затларның булуын, аларга табынуны инкарь итми. Ислам дине, киресенчә, «лә илиәһү илля Аллаһ... (алладан башка алла юк)» дигән фундаменталь формасы белән принципиаль рәвештә башка илаһи көчләрне, затларны инкарь итә. Фәлсәфи тел белән әйткәндә, мәҗүсилек диненә һәм дөнья карашына плюрализм (бу очракта — күп аллалык) хас булса, ислам диненә һәм аңа нигезләнгән дөньяга карашка катгый, эзлекле монизм хас. Әлбәттә, бу авторның: «Баш алла — Тәңрегә табыну болгарларга ислам диненә күчүне җиңеләйткән»,— дигән тезисына каршы килми. Чыннан да, Тәңре культы борынгы төркиләрнең үз карашларында монотеистик дингә таба үсүләрен күрсәтә.

Безнең ныклы уебызча, Гамирҗан Дәүләтшинның хезмәте татар халкының рухи мирасын өйрәнүдә, болгар чорын өйрәнүдә яңа уңышлы адым булып саналырга лаек.

**Рашат ЭМИРХАН,**
философия фәннәре кандидаты.

**Риф Мөхәммәтҗанов,**
филология фәннәре кандидаты

# ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫНА БӘЙЛЕ ЙОЛАЛАР ҺӘМ ҖЫРЛАР

Халык сынамышлары һәм хуҗалык эшчәнлегенә бәйле йолалар әле мәҗүсилек чорында ук барлыкка килгән. Гарәп сәяхәтчесе Ибне Фазланның әйтүенә караганда, болгар чорында яшәгән татарлар, мәсәлән, 12 иягә табынган. Бигрәк тә җәнлек-җанвар, кош-кортка табыну көчле була. Күпчелек төрки кабиләләр шикелле үк, татарлар да, шул исәптән Ык буена урнашкан ыру-кабиләләр дә, элек заманнарда һәр елның «иясе» бар дип уйлаганнар. Соңыннан бу карашның нығып, халык календарена сынамышлар рәвешендә килеп керүен, йола иҗатына әверелүен күреп була. Бу караш буенча унике ел бер цикл (мөсәл) барлыкка китерә һәм алар түбәндәгечә: Тычкан, Сыер, Барыс, Куян, Ләү (балык, кәлтә), Елан, Елкы (ат), Куй (сарык), Мичин (маймыл), Тавык, Эт, Дуңгыз. Әлеге елларның һәрберсенең үз билгеләре нигезендә туган календарь сынамышлар хәзер дә бик күп очрый. Берничә мисал:

*Барыс елы — байлык,*
*Тычкан елы — баллык,*
*Сыер елы — туклык,*
*Куй елы — кытлык,*
*Куян елы — йотлык,*
*Елан елы — баллык,*
*Дуңгыз елы — байлык h. б.*

12 еллык мөсәл нигезендә тотемистик ышанулар ятса да, ахыр чиктә алар аграр характерлы һәм халыкның авыл хуҗалыгы, җир эшкәртү, малчылык өлкәсендәге меңәр еллык тәҗрибәсенә тоташалар.

Билгеле булганча, Россиядә Петр 1 тарафыннан кертелгән календарь системасы татарларда бары тик XIX йөз урталарында гына ныклап урнаша. Ә аңа кадәр Зодиак йолдызлыгына нигезләнгән язма календарь белән эш ителә. Аның шактый киң таралган булуын сөйләүче истәлекләр, күзәтүләр хәтсез табыла. Мәсәлән:

*Сөнбелә туса, суыныр;*
*Гакрәп башында кар яуса,*
*кырык көн ятар;*
*Сәвер килми яз булмый;*
*Хут керде — хатыннар артына ут керде;*
*Җәүза керми җәй булмый,*
*кавес керми кыш булмый h. б.*

Шунысы игътибарга лаеклы, бу сынамышларда китерелгән сөнбелә, гакрәп, сәвер, хут, җәүза, кавәс кебек Зодиак йолдызлыгы буенча алынган гарәпчә ай исемнәренең төрки халыкларда үз вариантлары яшәп килгән. Мәсәлән, сөнбелә — сөнбел чәчле кыз (август), гакрәп — чаян (октябрь), сәвәр — үгез (апрель), хут-балык (февраль), җәүза — игезәк (май), кавәс — җәя (ноябрь) һ. б.

Аларның һәммәсендә дә ел фасылларын сынау, табигать тормышына игътибар итү күзгә бәрелә һәм хуҗалык эшләренә илтеп бәйләү омтылы

шы төсмерләнә (хут керде — хатыннар артына ут керде, ягъни хут — февраль, искечә 7 мартта чыга). Бу айда хатын-кызлар киндер станнарына утыра — алар өчен кызу, ут көннәр башлана. Нәкый ага Исәнбәт, иранлылардан алынып, нәүрүз (март) ае белән башлана торган кояш системасы календаре булганлыгын да әйтә. Һәрхәлдә, бернәрсә бәхәссез — борынгы татар календаре аграр характерлы.

Иң башта шуны әйтик, бу язмада Башкортстанның Ык буенда яшәүче татарлары арасында таралган йолалар һәм җырлар гына күз уңында тотыла һәм алар ел фасылларына, хуҗалык эшләренә ярашлы рәвештә тикшерелә. Шул ук вакытта йола вакытында катнашкан башка иҗат төрләрен дә читләтергә ярамый. Чөнки ансыз теге, яки бу ритуал турында төгәл картина тудырып булмый.

Яңа елны каршылау йолаларыннан иң киң таралганы — Нардуган. Гадәттә ул декабрьнең соңгы көннәрендә һәм гыйнвар башларында уйналган. Дөрес, элегрәк ул Нәүрүз (март) аенда да үткәрелгән. Ягъни, бу йола заманга карап яраклаша бара. Асылы белән ул дөньядагы күпчелек халыкларга хас ритуалларны эченә ала һәм киләчәк уңыш, мал-туарның үрчүе, крестьян гаиләсенең иминлеге өчен борынгыларның хәстәрлек күрүен чагылдырган магик һәм көнкүреш йола хәрәкәтләреннән тора, күрәзәлек итүгә, табигать һәм тирәлекне аңларга тырышуга кайтып кала. Нардуган йолалары берничә көн дәвам иткән. Яңа елга каршы көндә махсус ашлар пешерелгән (нардуган һәм нәүрүз ашлары). Аларга муллык теләү мәгънәсе салынган.

Төрле уеннарга бай Нардуган йоласының эчтәлеге күпчелек халыклар өчен уртак — йөзек белән күрәзәлек итү (йөзек салыш). Благовор районы Каргалытамак авылында яшәүче Фатыйма әби Терегулова 1971 елда безгә, әтисеннән ишетеп калганнарны һәм кечкенәдән үзе күргәннәрне болай дип сөйләгән иде:

«Мәрхүм эткәй әйтә иде, нәүрүз әйтмәк фарыз, бабаларыбыз җоласы дип. Шәриктәшләр, җәнә сабакташлар берлән сөекле остазларымны чаналарга утыртып, урам буйлап, җорттан җортка җөреп, нәүрүз көйләп чыгу савап дип әйтә иде. Без яшь чакта да бар иде бу җола. Һәркем хәленчә, җоласы кушканча, күкәй, җарма, прәннек, күмәчләр бирә. Камзул, тастымал, бал, чәй, казылык, бөркәнчек ишеләр дә була инде. Бәгъзеләр үзләренә алып кереп сыйлап та чыгаралар. Нәүрүз шулай каршылана. Ашсу күп була. Аннары, кызлар, аулак өйләргә китә идек кич белән. Җөзек-балдакларны табак савытка сала идек тә (табакның өсте каплаулы, абруйлы абыстай биргәне сулы; ана яңа пешкән әпекәй ваклап та салына иде борынрак. Болай да гаеп түгел инде, салсаң җарай, салмасаң җарай). Шул. Берәү артка карый, берәү җыр башлый. Калганнар кушыла. Җыр бетүгә артка караган кыз әйләнеп, тиз генә сулы табактан берәр җөзек-балдак ала. Кем җөзеге булса — җыр шуңа хуш килә, шуңа кияүгә барасың. Аннары, кеше аягы басылгач, төнге берләрдә, чүп-чарны себереп урамга түккәннән соң, тышка чыгып тыңлана идек. Кайдан эт өрсә — шул җакка китәсең диләр иде. Тынга бару була иде. Ул болай. Җараткан җегете булган кыз ахирәтен ала да, шул җортның тәрәзә төбенә барып тын кәтә. Тыңлап тора: җегете әрме китәме, юкмы, әрмедә булса, кайтамы — юкмы, шуларны белә. «Китте», «кайтмады», «ашамас» кебек сүзләр ишетелсә,— җегет китә, «ашай», «кайтты» сүзләрен ишетсә — кире кайта. Уллары әрме китәсе кәтелгән хатыннар төшлек салдыр. Төшлек салу да хикмәтле. Улы әрме китәсе ана улының нинди булса да киеменә хәер төреп, иң фәкыйрь карчыкка төшлек салырга китерә. Төшлекче карчык шул киемне баш очына салып җата. Иртәгесен ниләр күрсә, шул төшне сөйләй».

Нәүрүз — фарсы сүзе, ел башы дигәнне аңлата. Фарсылар яңа елның беренче көне итеп, хәзерге календарь белән искечә 7 мартны саный. Төрки халыклар кулланып йөрткән Ай-Кояш календарында ай исемнәренең берсе шулай ук Нәүрүз дип атала. Бу атама фольклорда да чагыла. Борынгы болгар-татарларның бәет мирасында «Нәүрүз бәете» дигән әсәр билгеле.

Нардуган кичәләренең соңрак нәүрүз кичәләре дип тә аталуы мәгълүм. Нардуган йоласы, югарыда әйткәнчә, кич утырып, нардуган әйтү — күрәзәлек җырлары җырлауны аңлата. Фатыйма әби Терегулова сөйләгән нәүрүз кичәләре дә шул ук йоланы үз эченә ала.

Телгә алынган нардуган һәм нәүрүз традицияләрен күз алдына китерү өчен бер мисал алыйк:

*Нардуганым нарына,*
*Бакма кеше ярына.*

*Күрше авыл Аллайда,*
*Мулла көтә, картайган.*

Югарыда әйтелгәнчә, фал ачканда җырлана торган бу җыр балдак иясе булган кызга ишарә ясый. Шушы җыр тигән балдакның иясен, димәк, карт мулла алачак, имеш.

Инде берничә нәүрүз да китерик:

*Нәүрүз, нәүрүз,*
*Нәүрүз, хуҗалар,*
*Котлы, мөбарәк булсын,*
*Тормыш түгәрәк булсын,*
*Мал-туарыгыз артсын,*
*Колыннарыгыз чапсын,*
*Игеннәрегез бик уңсын,*
*Кукәй кебек тук булсын,*
*Нәүрүз, нәүрәз! һ. б.*

Язгы бәйрәмнәрнең берсе — Җимчәчәк тә йолага бай. Анда күмәк уеннар, әйлән-бәйләннәр дә башкарыла торган була. Җимчәчәк йоласы, исеме үк әйтеп тора, үсемлек культы белән бәйле булырга тиеш. Өстәвенә, ул язгы ташкыннар җиткән көннәрдә, беренче чәчәк-үсемлекләр (умырзая) кар астыннан күренә башлагач, уздырыла. Ык буе районнарында картлар бу бәйрәмнең атна-ун көн дәвам итүен һәм анда «Тары чәчтек», «Ак тирәк», «Шайкамыш», «Сайлаш» уеннарының башкарылуын телгә алалар.

Мондый уенлы-җырлы йолаларның аграр-календарьга бәйлелегенә ишарә ясаган күренешләрнең берсе итеп сөрән йоласын күрсәтергә мөмкин.

Сөрән сугу җырларында кызыклы гына үзенчәлекләр бар. Мәсәлән:

*— Әби-бабай, аманмысыз,*
*Аш-тәгамнар салганмысыз?*
*— Майашлар әзер, туганнар,*
*Утырыгыз, оланнар.*

Яки:

*— Алтын да гынай ишек, көмеш тупса,*
*Атлый да йөгереп без кердек.*
*Әби дә бабай — илнең солтаннары,*
*Табыннарыгызны хуп күрдек.*

*Аслары да йомырка, өсләре май,*
*Тәбәләре телең йотарлык.*
*Кибән-эскертләрегез ишәйсен,*
*Гомерегездә күрмәгез тарлык.*

Сөрән сугу җырларын җентекләбрәк тикшергәндә шул күзгә ташлана: аларның кайберләре турыдан-туры нәүрүз белән авазлашка әйләнә. Чагыштыру өчен сөрән сугу һәм нәүрүз әйтүне китереп үтик:

**Сөрән сугу:**

— Сөрән дә сөрән, дисез,
Кая киттегез?
— Киттек басу буйлап,
Хуҗалардан аш-су даулап.
— Сөрән дә сөрән дидегез,
Моңача кайда йөрдегез?
— Өйдән-өйгә йөрдек,
Инде сезгә килдек.

**Нәүрүз әйтү:**

— Нәүрүз, нәүрүз!
Кая киттең?
— Киттем авыл буйлап,
Он, йомырка, маен юллап.
— Нәүрүз, нәүрүз!
Моңача кайда идең?
— Ялан-кырда кундым.
Инде сезгә юлдым.

Һәр икесендә дә чакыру, каравыл кычкыру катнаша. Сөрән бәйрәмендә — язны көтү (югарыда җимчәчәк йоласына карагандыгын әйтеп киткән идек.) нәүрүздә дә кояшның кышны җиңеп, язга борылуын котлау ята. Һәр икесендә дә бүләк, аш-су таләп итела. Гадәттә һәр ике йола вакытында да традицион текстлар кереш өлештән, мактаудан, бүләк сораудан һәм бүләк биргән очракта әйбәт теләкләр әйтүдән, бүләк бирмәгәндә

янаулардан тора. Хәтта йолаларында уртак яклар бар: нәүрүз әйтүчеләр дә, сөрән сугучылар да йорт-җирне туздырып, идән-сәкеләрне куптарып та чыгып китә алалар.

Болар өстенә, кышкы-язгы күренешләргә бәйле тагын бер кызыклы йолага игътибар итми үтү мөмкин түгел. Ул — кышны озату, язны каршылау йоласы. Моның кайбер чаткылары Ык буе якларында чагылып кала. Мәсәлән, кайбер авылларда, элегрәк, боз кузгалган көндә, яр буенда зур салам карачкы эшләгәннәр һәм шуның әйләнәсендә атна буена һәркөн кич уеннар оештыра торган булганнар. Боз китеп беткән көнне бу карачкыга ут төртеп, таратып-сипкәләп яки соңгы бозга утыртып агызып җибәргәннәр. Шул рәвешчә, янәсе, кыш-суык озатылган.

Язгы-җәйге чордагы уенлы-җырлы йолалардан карга туе бик характерлы. Башкортстанның татарлар яшәгән күп кенә авылларында карга туе әле дә үткәрелә. Аучылык, балыкчылык йолалары онытылып бетеп бара, ә менә карга туе (Ык буенда карга боткасы дип атала) йолачылык элементларын күпләп саклый әле.

Карга туе, гадәттә, җирләр ачыла төшкәч, каргалар килгәч үткәрелә. Язгы бәйрәмнәрнең барсында булган кебек, бу көнне яшүсмерләр он, ярма, май, йомырка һ. б. шундый азыклар җыя. Карга туеның эчтәлеген түбәндәге мисаллар да ачык сөйли:

*Карга әйтә: карр, карр,*
*Туем җитте — барр, бар,*
*Ярма, кукәй алып бар,*
*Сот, маеңны тагын ал,*
*Әпәй, итең салып барр!*
*Барр! Барр! Барр!*

Шулай җырлап, авылны урап үткәннән соң, табигатьнең иң күркәм җиренә, калку чишмә буена юнәләләр. Зур-зур казаннарда аш, ботка пешә, йомыркалар буяла. Аш-суга оста карчыклар карга боткасын өлгерткәнче, төрле уеннар оештырыла, җыр өзелми. Ботка пешеп өлгергәч, иң башта ботканы барчасы учлап җиргә сибәләр, чишмә суына корбан итәләр (җир тук булсын, су иясе тотмасын, яңгыр бирсен).

Күренүенчә, карга туе нигездә халыкның ышануларын чагылдыра. Карга булып кылану, ботканы җиргә-суга сибү — болары барысы да алдагы уңышның мул булуын теләүгә кайтып кала.

Хәзер инде ел фасылларына караган иң олы милли йола — сабан туена тукталыйк. Башкортстанның Ык буе районнарында, атап әйткәндә, Шаран төбәкләрендә аны «сука бәйрәме», «сука җыены» дип әле XX йөзнең егерменче елларына кадәр йөртәләр һәм җирләрне беренче кат сөреп чыкканнан соң үткәрәләр. Һәрхәлдә, сабантуе — шул ук язгы кыр эшләренә бәйле йола бәйрәме.

Сабантуе ике моментны үз эченә ала (сүз революциягә кадәргесе турында бара): 1. Хәзерлек чоры. 2. Бәйрәм.

Хәзерлек чорының эчтәлеге хакында, мәсәлән, Ярмәкәй районы Усман Ташлы авылындагы Дәүләтгәрәй Гәрәев (1887 елгы) 1970 елда менә нәрсәләр сөйләде:

«Сабантуена әзерлек зур, җаваплы эш. Иң элек авыл әйләнәсен уратып сабан белән (тимер сука да ярый, бабайлар әйтә торган иде, тимердә куәт, җегәр ята, чир-коры, явыз көчләр шуннан өркә дип) сызып чыгалар. Сызучылар — кияүгә чыкмаган кызлар. Ирләрнең дә, өлкән хатын-кызларның да бу эшкә катнашырга хакы юк. Кызлар яланбаш, бәйрәм киемнәрендә була, яңа яулыклары белән билләрен буалар, чәчләрен тузгыталар, сабанга күмәкләп җигеләләр, кулларында чыбыркы яки камчы. Алларыннан бер карчык чәчләрен тузгытып, пумалага атланып бара. Икенче карчык сабан башына тотынып, дилбегә кагып, камчы белән куалап бара. Кыйнарга да тиешле. Кояш чыгыштан башлап кояш батышка табан зур түгәрәк ясыйлар. Бу вакытта авылга берәү дә керә алмый, чыгарга да тиеш түгел. Бик хәтәр бетү мөмкин. Якын килергә дә ярамый: үтергәнче тукмыйлар. Менә шулай сабан сызыла. Инде хәзер бәйрәм бүләкләре җыя башларга мөмкин. Чөнки авылда чир-чураман, явыз иyәләр калмады, үтеп тә керә алмый».

Сабан сызу йоласы фольклорчыларга таныш. К. Насыйри үзенең «Казан татарларының ышанулары һәм ырымнары» дигән мәкаләсендә «ваба» яки «үләт чире» булган очракта шуңа охшаш йолалар үткәрелүе турында яза һәм аның нигездә малларны саклау өчен кулланылганлыгын әйтә. Күрәсең, сабан сызу йоласының роле моның белән генә чикләнми. Игътибар итегез: кояш чыгыштан башлап кояш батышына табан түгәрәкләнеп,

авыл әйләнәсенә сабан сызыгы сызыла. Димәк, борынгы халык һәрнәрсәгә тереклек бирүче язгы кояшның хәрәкәтен кабатлый. Кояшка табыну йоласы исә күпчелек халыкларга хас. Идел-Кама болгарларында әле игенчелеккә кадәр, малчылык, аучылык белән шөгыльләнгән вакытларда ук, кояшка табыну йоласы булганлыгы билгеле. Археологик материаллардан күренгәнчә, болгарлар савыт-сабаларга кояш сурәтләре төшергәннәр, кояш хөрмәтенә ак мал (акбүз ат, ак елкы, куй һ. б.) корбан иткәннәр. Халык тәгъбирләре дә шуңа ишарә ясыйлар. Мәсәлән ант иткәндә, вәгъдәләшкәндә әле дә «Кояштыр менә, сүзем хак», диләр. Бу шул борынгыларның кояшка табынуыннан калган ерак чаткыларның берсе. Ягъни кешеләр һәр хәрәкәткә табына, магик мәгънә сала. Сабан сызу йоласында әнә шул борынгы мәҗүсилек эзләре ярылып ята. Сабантуена әзерлек инде шушы йоладан ныклап башлана. Беренче чиратта, бирнә җыючылар (үткер телле аксакал картлардан баш бирнәче сайлана) сабан сызучыларны алмаштыра. Йорттан-йортка кереп (сөлге, тастымал, кулъяулык, түбәтәй, такыя, яулык, күлмәк, акча, бияләй, йомырка һ. б.) сабантуе бүләкләре җыю башлана. Йомырканы нигездә бала-чага җыя. Бүләк әйберләрен исә аксакал көчле егетләрнең берсенә тапшыра. Озын колгадагы бөҗралы беркетмәгә бәйләп ул аларны күтәреп йөри. Борынгы магиячелекнең эзе колгага бөҗра беркетелүдә дә чагыла, монда да язгы кояшка табынуның чагылышын күрү авыр түгел.

Бирнәчеләр бүләк җыйган көннәрдә атларны, юрткаларны чабышка әзерләү кыза төшә. Үсмер малайларга атлар беркетелә. Сабантуена берике көн кала атларны сынап, чамалап карау билгеләнә. Аны ат тоягы кыздыру дип тә атыйлар.

Сабантуенда язгы йола-уен җырларның алда саналган барлык төрләре яңгыраган дип әйтеп була. Болар өстенә йөгерү (үзе бик күп төрле), көрәш, ат чабыштыру, сикерү, капчык белән сугышу, чүлмәк вату, өчаяк узышы, атаман куыш һәм башка дистәләгән милли уеннар, ярышлар башкарыла. Бала-чага аерым-аерым житезлектә ярыша, такмак-такмаза әйтешә, биек, шома колга башындагы бүләк өчен алыша (монысына зурлар да теләп катнаша) һ. б.

Сабантуе тантанасы хезмәт белән алышына. Сабаннан кайтучыларны чәчү беткән көнне басу капкасы янында көтеп торганнар һәм су белән коендырып үткәргәннәр. Бу да борынгыларның уңыш теләү йоласы — суга табыну, анда магик көч бар дип ышану. Беренче буразна ярганда йомыркалар чәчү, сабан суы сибү бүген дә аерым урыннарда саклана әле.

Чәчү тәмамланып, игеннәр шытып чыгуга җир-анага бүләк китерү, сүзтеләкләр белән мөрәҗәгать итү йоласы бар.

«Җир-ана» дип әйтүдән үк җиргә табыну, ана илаһи көч дип ышану чагылышын сизеп була. «Җир упсын», «җир йотсын» кебек тәгъбирләр шул мәҗүсилек заманнарыннан килеп житкән булырга тиеш.

*Җир атасы — җирән сакал,*
*Җир анасы—асыл бикә!*
*Түбәсенә туклыгын бир,*
*Тамырына ныклыгын бир,*
*Ил өстенә муллыгын бир,*
*Ил эчендә безгә дә бир!*
*Башлыйк теләкне,*
*Күтәрик беләкне!— дип,*

җиргә баш оралар. «Кояш, шаһит бул!» дип, кулларын күтәреп кояшка эндәшәләр. Кояшка багу, табыну — киң таралган йолаларның берсе. Борынгы кулъязмаларда бу хакта мәгълүматлар очраштыра. Кояшка йорт-кура түбәләреннән, тау башларыннан бакканнар, жыр-келәү әйткәннәр:

*Асыл кояш, кил бире,*
*Кил бире, китмә кире!*
*Кошлар да көтә сине:*
*Тавыклар да кыткылдый,*
*Чыпчыклар да чыркылдый,*
*Ак үрдәкләр бакылдый,*
*Ата казлар каңгылдый,*
*Каргалар да каркылдый.*
*Уңнан йөри кызыл туш,*
*Юлга чыккан сыерчык,*
*Бар да җара: кояш чык!*

Мондый келәү-теләкләр Башкортстанның Ык буенда һәр авылда диярлек таныш. Җентекләбрәк караган очракта, алар да турыдан-туры йолачылык белән бәйле мөрәҗәгатьләр дә күзгә ташлана. корбан ашлары вәгъдә ителгәнлеге аңлашыла:

*Асыл кояш, болай кил,*
*Эт кояшы, тегеләй кит,*
*Майлы кашык бирермен,*
*Кызыл үгез суярмын,*
*Майлы таба бирермен,*
*Итен сиңа куярмын,—*
*Кояш, чык, чык, чык!*

Алда китерелгән һәм әлеге юлларның табыну җыры икәнлеге бәхәссез булса кирәк. Борынгыларның ышануынча, чалт аязда туган кояш муллык, уңышлы ел вәгъдә иткән. Мондый ышану, һәм кояшка табыну күпчелек халыклар өчен уртак.

Сабан ае (май) тәгәлләнүгә, халык әдәбияты буенча җәй (июнь), чиллә (июль) айлары башлана. Язгы кыр эшләре үләннәрнең, чәчәкләрнең — кыскасы, яшеллекнең иң нык җанланган, тернәкләнгән бер чорында тәмамлана. Шул чакта җыеннар башланган. Дөрес, этнографлар татарларда җыен йолаларының борынгы ыручылык мөнәсәбәтләренә бәйләнештә туган булуына басым ясыйлар. Ләкин аларга да аграр-хуҗалык һәм ел фасылларына бәйле йолаларның йогынтысы баштан ук зур булган. Сүз дә юк, атна-ун көн буена дәвам итә торган бу җыеннарда кабиләчелек чорында ыру белән ыру белән аралашкан, ил белән ил йөрешкән, соңрак дәвердә исә авыл белән авыл, урам белән урам, оч белән оч йөрешә.

Башкортстанның Ык буе якларында (бигрәк тә Шаран районында) болардан тыш башка төр җыеннар булганлыгын да сөйлиләр. Мәсәлән, юа, җиләк, яшь бәрәңге, кузгалак җыеннары. Алар әле егерменче, хәтта утызынчы елларга кадәр үткәрелеп килә.

Күргәнебезчә, җыенның исеме үк табигатьтәге үзгәрешләргә бәйле булуына ишарәли, ягъни борынгыларның үсемлек культына барып тоташа. Соңгы вакытта аларны ел фасылы йола бәйрәмнәренә бәйләп аңлату да шуннан килә. Ягъни җыеннар ыручылык мөнәсәбәтләре йоласы буларак туып та, үз ролен югалтканнан соң, исемен үсемлек культы йолаларына тапшыра, шул рәвешле ел фасылларына караган йолаларның эчтәлеген үзләштерә, әмма аерым элементларын саклап кала. Мәсәлән, Башкортстанның Шаран районы Алпай авылы карты Якуп Игъдиев юа җыены турында шушындый мәгълүматлар бирә: «Җуа җыены май азаклары, июнь башларына табан оештырыла. Кыңгыраулы атларга төялеп (алдагыларында — кызлар, арттагыларында егетләр утыра, гармунчылар, җырчылар уртага баса) авыл урап алалар. Өч-дүрт көн алдан әзерлек бушка үтми: атлар чуклар һәм сөлге-яулыклар белән бизәүле, кызлар ал, яшел, зәңгәр, кызыл кулъяулыкларын куеннарына яшергән, җыенга теге яки бу сәбәп белән бара алмаганнар атларын, йөгәннәрен баручыларга бер көн кала тапшырып куйган, оста ашчылар казан асар өчен урын-җир тәгаенләп өлгергән. Аш-су әзерләү өчен бал, май, икмәк, чәк-чәк, йомырка арбаларга төялгән. Җуалыкка җиткәнче ничә авыл үтелсә, һәркайсысын җырлап урыйлар, мәйданнарда төшеп биилэр, җыенга өндиләр. Бергәләп кузгалалар. Җуалыкка килеп җитәләр. Җыен зур түгәрәк ясап баса. Кызлар урталыкта кулъяулыклар болгап баса, атлар (ат башын тотучылыр гармун уйнап) җыенны өч тапкыр әйләнеп чыга, аннан аларны махсус бер урынга куялар. Уен-бию башлана.

Шуннан соң җуа җыю буенча ярыш оештырыла. Ярышта җиңгәннәрнең җуасыннан оста пешекче (авылларда аш-су әзерләү буенча даны чыккан апа) һәм аның ярдәмчеләре җыен ашы өлгертә. Ул бик мул, һәркемгә житәрлек була. Җуалыкка рәхмәт йөзеннән аш-су җиргә дә сибелә, конфет-прәннекләр дә чәчелә. Өч-дүрт көн буена җуалык тынып тормый. Әлегрәк авыл белән авыл ызгышлары булгалый иде (ыру низаглары гадәттә кыз-кыркын өчен чыга.) Наҗар (җуа) җыены андыйларны килештерү өчен хезмәт итә иде. Аеруча катайлар:

*— Без үзебез шәрә Катай,*
*Киләбез дә китәбез.*
*Җыен шәрә җыелышып,*
*Бергә фарчит итәбез,— дип җырлыйлар иде.*

Җыен таралганда да тәртип саклана. Аксакал картлар алдан китә. Яшьләр генә алардан калып, уен-биюне дәвам итә: таганасты үткәрә. Кем нинди арбаларда килсә, шулай утырып кайта. Кыңгырау тавышлары яңгырый, авыл саен урап чыкканнан соң, тукталып җырлап-бию булып ала. Гаҗәеп күңелле кайтыла. Кайтканда ат ярышлары уздырыла. Бу — Нәҗар җыены. Чикә (җиләк) җыены беренче җиләкләр җиткәндә, июль башында, сакат җыены яшь бәрәнге өлгергәндә, август башында үткәрелә. Үткәрү тәртипләре бер төсле. Тик җиләк җыенында җиләк ашлары, яшь бәрәнге җыенында бәрәнге ашлары пешерелә, калганы үзгәрешсез».

Җыеннарның уздырылу тәртибе күп төрле, моның өстәвенә алар өч-дүрт көнгә сузыла: кайсы урыннарда (авыллар тыгызрак утырган урыннарда), атна-ун көн дәвам итә. Җыеннар да шул ук борынгыларның үсемлекләргә табынуыннан килеп чыккан, дип фараз итәргә урын бар, әлбәттә. Әмма җыеннарда борынгы ыручылык мөнәсәбәтләре ныграк саклана. Борынгарак киткән саен аларда ел фасылларына, хуҗалык эшләренә бәйлелек югала бара.

Үсемлек культы дөньядагы барлык халыкларда да бар. Алар хөрмәтенә махсус бәйрәмнәр үткәрү — җир-анага табыну, үсемлекләрне могҗизалы көчкә ия дип ышану мәҗүсилек заманнарыннан ук килә. Шунысын искәртик, ел фасылларына бәйле барлык йолаларда (нәүрүз, сөрән, сабантуе, җыен һ. б.) ут катнаша. Җыеннарда, мәсәлән, ут туйдыру йоласы очраштыра. Ул шуннан гыйбарәт: җыен ашы ашаганчы учакка ит-май кисәкләре юргыталар, аш сибәләр.

Җирле халыкларның сөйләвенә караганда, янә дә бу җыеннарда (бигрәк тә юа, кузгалак җыеннары көннәрендә) такыя үреп күрәзәлек итү йоласы булган. Анда бары тик кызлар катнашкан. Такыя үреп бетергәч кызлар, киләчәк язмышларын белергә теләп, такыяларын суга ташлаганнар. Әгәр такыя батса — такыя иясе үлә, яки сөйгән егете аны оныта, дип фараз иткәннәр; әгәр бер урында әйләнеп торса — ул кыз утырып кала, ярга килре кайтса—туган авылына кияүгә чыга; такыя кайсы якка йөзеп китсә — шул якка кияүгә чыга һ. б.

Шулай итеп, җыен йолалары уеннары һәм җырларының магик нигезе ике характерлы. Бер яклап — аграр магия (язгы-җәйге үсемлекләр: юа, кузгалак, җиләк, бәрәнге чәчәкләр — булачак мул уңышның гәүдәләнеше, юралышы), икенче яклап — ыручылык мөнәсәбәтләре, гаилә-никах мотивлары (әйләнә-бәйләнә уеннары, такыя белән күрәзәлек итүләр, кызларның фал ачулары һ. б.). Дөрес, бу уеннарның, җырларның күбесе йолалардан бөтенләй азат төсле кабул ителә, яки аларда борынгы табынуларның эзләре генә төсмерләнеп кала.

Ык буе төбәгендә борынгыларның табигать күренешләренә табынуларын чагылдырган тагын бер йола озак вакытлар сакланып килә. Ул — яңгыр боткасы яки яңгыр туе. Гадәттә ул җәен, игеннәр өлгерер алдыннан, яки уракка төшкәнче, корылык елларда үткәрелә. Үткәрү тәртибе өч өлештән тора: а) Авыл буйлап йөреп, яңгыр бәйрәме өчен азык җыю. Нигездә башлап карчыклар йөри, аларга бала-чага иярә. Йомырка, тоз, ит, май, сөт, ярма һ. б. җыела; б) Табыну өлеше. Су буенда үткәрелә. Кояшка, болытка, яңгырга эндәшеп, теләкләр теләнә, кием белән суга кереп, кычкырып арбау-такмаклар әйтелә. Аерым урыннарда ак үгез, ак сыер, ак тана корбан ителә, күл яки елга эченә капчык-капчык чуерташ кертеп салына; в) Яңгыр боткасы ашау һәм кайтканда да кем очраса, шуны йола суы белән коендыру. Болар өстенә басу капкасына, изгеләр зиратына сулар сибелә.

Ык буе районнарында яңгыр теләү туйлары утызынчы елларга кадәр яшәп килә. Соңга табарак корбан итеп эре мал түгел, каз, тавык, сарык һ. б. кулланыла. Яңгыр туйларында башкарыла торган җыр-такмакларны бүген дә табарга мөмкин.

*Яңгыркаем, яу, яу, яу!*
*Илгә ачлык килмәсен,*
*Ачтан халык үлмәсен,*
*Чума чире йөрмәсен.*
*Яңгыркаем, яу, яу, яу!*
*Иген-ашлык күп булсын,*
*Башаклары тук булсын,*
*Кибән-эскерт зур булсын,*
*Яңгыркаем, яу, яу, яу!*

*Кара сарык суярмын,*
*Ботын сиңа куярмын,*

*Майлы ботка казанда,*
*Сөтле сыер абзарда,*
*Бар да булыр яуганда,*
*Яңгыркаем, яу, яу, яу!!!*

Яңгыр теләү вакытында күлгә чуерташ батыру йоласының да үз мәгънәсе булырга тиеш. Аңлатманы халыкларның утка, суга, җиргә табыну чорларыннан эзләргә кирәк. Этнографлар халык ышануларының төрле жанрда төрлечә, аның юнәлешеннән, функциясеннән чыгып тормышта чагылуын билгелиләр. Шул ук су иясе дә әкиятләрдә үзенчә, им-томнарда үзенә башка, мәкаль-әйтемнәрдә шулай ук башкача күз алдына баса. Бу хәл инде барыннан да элек теге яки бу жанрның поэтик үзенчәлекләренә бәйле. Шул образга хас сыйфатлар генетик яктан бер нәрсәгә кайтып кала: аларда борынгыларның куәтле, ләкин явыз, усал су стихиясе һәм су ияләренең шуңа хуҗа була алуы (елга һәм күлләр белән идарә итү) турындагы карашлары гәүдәләнә. Капчыклап күл эченә таш ташлау—су ияләренә бирелгән корбан булырга тиеш. Мәҗүсилек заманнарында ташларга табыну билгеле нәрсә (кабер өсләренә таш утырту да шуннан килә).

Көзге эшләргә бәйле хуҗалык йолалары бу төбәктә ул кадәр үк бай түгел. Урып-җыюга бәйле бәйрәм йолалары аз сакланган. Керәшен татарларында (Бакалы районы) беренче көлтәнең орлыгын чәчүгә саклау гадәте бар. Урак беткәч соңгы көлтәне мал-туарга ашату йоласы яши. Уракчы хатын-кызларның урак тәмамлангач, җирдә тәгәрәп аунаулары, шул ук вакытта «җир, җир, көчем бир» дип кычкыру, оран салу, соңгы көлтәне бизәп-ясап курчак кебек киендереп-ясап, тантаналы рәвештә алып кайту (Ярмәкәй районы Тарказы авылы) һ. б.—болар һәммәсе аграр характерлы йолалар. Татар авылларында календарь йолаларның малчылыкка һәм көнкүрешкә бәйле төрләре исә ешрак очрый. Көзге сугым бәйрәмнәре (аеруча каз өмәләре һәм тула өмәләре) Ык буе якларына киң таралган. Болардан тыш, өмә ясап сүс туку, киндер сугу шулай ук көзге йолага керә.

Сугым бәйрәмнәрендә һәм каз өмәләрендә борынгы магиячелек эзләрен күпләп очратырга мөмкин. XX йөз башларында үткәрелгән каз өмәләреннән бер күренешне китерик. Шаран районы Күгәрчен Бүләк авылында яшәүче Фатыйма Садретдинова (1904 елгы) аны болай хәтерли:

«Кар явып, беренче салкыннар төшкәч, октябрь урталарында, ноябрь башларында авылларда каз өмәләре башлана. Аның үзенең йоласы, тәртибе бар. Өмә буласы көн алдыннан кичен хуҗа өмәчеләргә әйтеп чыга. Иртә таңнан кызлар җыела. Суючылар — оста ирләр. Беренче булып өмәгә килгән кызны түр башына мендәргә утырталар. Ул өмә башлыгы. Аның сүзен һәркем үтәргә тиеш. Өмә башлыгы булу бик җаваплы. Йола, гореф-гадәтләрне белгән кеше кирәк. Беренче казны ул әти-әниле яшь кыздан тоттыра. Моның мәгънәсе бар: казның нәсел-нәсәбе туктамасын, алдагы ел янә ишәеп китсен өчен эшлиләр. Казларны юарга алып бару өчен кыңгыраулар тагылган атларда егетләр килеп җитә. Әрҗә-әрҗә казларны чаналарга төйиләр. Чишмәләр якын булса, көянтәләргә асып, тезелешеп җәяү генә баралар. Атлар белән исә урам урап, гармун тартып, җырлап ераграк су буена китәләр. Кул арты җиңел дип исеме чыккан берәр кыз, я килен су буена җиткәнче каз каурыйларын сибеп, таратып бара. Алдагы елга, димәк, су буеннан алып хуҗа йортына җитәрлек булып казлар уңсын дигән сүз. Каз мае белән пешкән тәбикмәкләр өзелми. Кичен каз ите салып пешерелгән аш мәҗлесе оештырыла. Табын җыр, уенкөлке белән үтә. Кичкә кыңгыраулы атларда урам урап, өйләргә таралалар. Каз өмәләре йорттан йортка күчеп тора, ун-унбишәр көн дәвам итә».

Каз өмәләрендә җырланган җырларда турыдан-туры хуҗалык эшләренә бәйләнеш мотивлары күренми. Аларда нигездә сый-хөрмәт оештырганы өчен хуҗалар мактала, яхшы теләкләр әйтелә. Каз өмәсендә катнашучыларның махсус урыны булу, өмә башлыгы сайлану кебек ритуал элементларның очравы әлеге җырлар борынгылардан калган иҗат булырга тиеш дип әйтергә мөмкинлек бирә.

Көзге-кышкы хезмәткә бәйле йолаларның берсе—тула өмәсе. Алар егерменче елларга кадәр дәвам итәләр. Халыкта киң таралган «Тула көе» дә үткәндәге йолачылыктан аерылып чыккан. Тула өмәсен үткәрү тәртибе каз өмәләренекенә охшаш. Төшке ялга туктаганда тула басылган йортның тәрәзәсе янына егетләр җыела. Кызлар тәрәзә аша аларны коймак белән сыйлый. Шунда үзара җыр-әйтеш башлана. Тула басуы җиңел түгел, эссе су белән станок (агач җайланма) артында туктаусыз эш итәргә туры килә. Ял вакыты җитә башлауга ул тагын да кыза төшә, шуңа карап җырның да

тизлеге көчәя. Өстәвенә, тәрәзә төбендә утырган кызлар егетләр килә башлавын да күреп өлгерә.

Тәрәзә аша әйтешүләр тагы көчәя, җыр күмәк иҗатка әйләнеп китә:

*— Әй, тула, тула, тула,*
*Тулада кызлар була.*
*Кызлар белән уйнагачтын,*
*Безнең күңелләр була.*

*— Тәрәзәдән карама,*
*Бүрек тышың алама.*
*— Нигә булсын алама,*
*Кар сыргандыр аңарга.*
*— Була безнең тулабыз,*
*Тула безнең тулабыз.*
*Бу туланы булдыруга*
*Уйнатам, ди хуҗабыз — һ. б.*

Шулай итеп, тула өмәсе җырларында, сүз текстында табыну элементлары бөтенләй катнашмый. Бу аңлашыла да, магик йолачылык, хезмәт җырына үз урынын биреп, җуела, юкка чыга.

Ел фасылларына бәйле йолалар һәм җырлар кешенең яшәү идеалларын күзалларга, аның ни-нәрсәгә омтылуын, нәрсә теләвен һәм нәрсәне нәфислек, матурлык кануны итеп тануын аңларга мөмкинлек бирә. Игеннең муллыгы, мал-туарның ишлеге, гаилә иминлеге — йола җырларының барысында да болар бердәй катнаша һәм үзенчәлекле, эчке реализм барлыкка китерә.

Шул ук вакытта йола иҗатында халык хыялы, мәҗүсилек дәвереннән калган һәртөрле ышанулар, магик элементлар, табынулар һ. б. ш. борынгылык эзләре дә үзен сиздерә. Җыр-теләкләрдәге эндәшләр, кычкырулар, боерулар (нәүрүз, сөрән, карга боткасы, сабантуй һ. б. вакытында) календарь иҗатның эчтәлеген сугаралар. Шигъри яктан бу җырлар халыкның көн күрү, тормыш итү барышында туган уй-тойгысын, фикерен, кәефен чагылдыра, хезмәт аша якты хыялны тормышка ашырырга мөмкин дип ышанучыларның иҗат җимеше булып тора.

## Айдар Хәлимгә — 50 яшь



Айдар Хәлим (Хәлимов Борис Нәҗметдин улы) 1942 елның 1 гыйнварында Башкортстанның Миякә районы Бәләкәй Кәркәле авылында туа. Сугыш ятиме буларак, ул Олы Кәркәле балалар приютында тәрбияләнә. Урта мәктәптән соң Октябрьск шәһәрендә бораулаучылар училищесын тәмамлап, калмык далаларында нефть эзләүдә катнаша. Туймазы районының Балтай авылы мәктәбендә тәрбияче булып эшли, шуннан Совет Армиясенә хезмәткә чакырыла.

1964—68 елларда Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укый һәм, журналистлык дипломы алгач, үз теләге белән Түбән Кама нефть химиясе комбинаты төзелешенә китә. «Кама таңнары» иҗади берләшмәсен, беренче татар халык театры һәм үзешчән сәнгать түгәрәкләрен оештыруда күп көч куя (монда яшь шагыйрь үзенең «Беренчеләр», «Биктырыш», «Печән чапканда» поэмаларын иҗат итә). Татар халкының милли-сәяси хокукларын яклаганы, татар милли азатлык хәрәкәтен оештырудагы омтылышлары өчен ул административ-аппарат тарафыннан төрле кысымнарга дучар ителә. 1971 елны туган ягына — Уфага кайтып китә.

1971—76 елларда ул — «Совет Башкортстаны» газетасында журналист, 1976—82 елларда — Урал-Себер нефть үткәргечләре идарәсендә өлкән инженер, 1982—83 елларда — Башкорт дәүләт академия театрында әдәби бүлек мөдире. 1983—85 елларда СССР Язучылар Союзы каршындагы Югары Әдәби курсларда укый. 1988—89 елларда Бөре бораулау эшләре идарәсендә бораулаучы ярдәмчесе булып эшли.

Шигърият, балалар шигърияте, проза һәм публицистика өлкәләрендә аның Уфада башкорт һәм Мәскәүдә рус телендә егермегә якын китабы басылып чыкты. «Җанчишмә», «Пәри туе» исемле пьесалары Башкорт академия драма театры сәхнәсендә куелды. Ниһаять, туган телендә беренче шигырь китабы — «Йөрәк ташы» Казанда 1990 елда басып чыгарылды.

Айдар Хәлимнең байтак шигъри һәм публицистик әсәрләре ил-күләм матбугатта еш басылды. Татар халкының ачы язмышын сурәтләгән «Телем минем — дусым минем...» мәкаләсе («Дружба народов», 1988 ел, 6 сан) илебездә милләтара мөнәсәбәтләрне дөрес яктыртуда һәм милли хәрәкәтләргә этәргеч бирүдә аерым урын алып тора. Литваның «Моксрас» («Фән») нәшрияты аны аерым китап итеп тә басып чыгарды. Татар халкы, аның мең еллык тарихы, рус-татар мөнәсәбәтләре, Башкортстандагы татар халкының хәленә багышланган «Книга печали или Записки аборигена» («Хәсрәт дәрьясы») китабын шушы ук нәшрият 1991 елда аерым китап итеп тә нәшер итте.

Айдар Хәлим — җәмәгать эшлеклесе буларак та билгеле шәхес. Ул — Бөтенсоюз Татар иҗтимагый Үзәге идарәсе әгъзасы, Уфа татар мәдәният мәркәзе идарәсе рәисе. Бүгенге көндә Айдар Хәлим — Чаллыда яңа чыга башлаган «Аргамак» журналының баш мөхәррире.

***Татарстан Язучылар Берлеге идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны кайнар котлыйлар, аңа сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телиләр!***

## ТАТАРСТАННЫҢ ҮЗ ФЛАГЫ ҺӘМ ПРЕЗИДЕНТКА ӨСТӘМӘ ВӘКАЛӘТЛӘР...

29 ноябрьдә Казанда Татарстан Республикасы Югары Советының җиденче сессиясе үзенең эшен тәмамлады. Анда күп бәхәсләр аша җөмһүриятебезнең мөстәкыйльлеген нығыту юнәлешендә мөһим карарлар, законнар кабул ителде. Алар арасында «Куллану товарларына һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрнең үзгәрүен исәпкә алып, халыкның керемнәрен индексләштыру», «Халыкны эш белән тәэмин итү турында»гы законнар бар. «Татарстан Республикасыннан СССР Кораллы Көчләренең хәрби-төзү отрядларына хезмәт итәргә чакыруны кыскарту турында»гы карарда Югары Советның бер нәтиҗәле эше саналырга тиеш.

«Татарстан ССРда референдум турында»гы ТССР Законын тикшерүдә депутатлар аеруча активлык күрсәттеләр. Ул кызу бәхәсләр кузгатты. Нәтиҗәдә, әлеге Закон һәм аны гамәлгә кертү турында карар кабул ителде.

Бу сессия җөмһүриятебезнең үз флагын булдыру белән дә тарихка кереп калачак. Әйе, Татарстанның үз флагы, үз әләме бар хәзер! Ул яшел, ак, кызыл төсләрдән тора. Флагны сессия барган залга алып чыгуга, депутатлар аягүрә торып бастылар, зал көчле алкышларга күмелде. Тәнәфес вакытында бер төркем депутатлар дуслыкка, килешүгә чакырып торган яңа әләмебезне парламент эшләгән бина түбәсенә беркеттеләр.

Сессиядә җөмһүриятебезнең мөстәкыйльлеген тагын да нығыту максатыннан, ТССР Президенты М. Шәймиевкә өстәмә вәкаләтләр бирелде.

## МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИ МУЗЕЕ

Драматург Мирхәйдәр Фәйзинең тормышы, иҗаты Балтач районының Шода авылы белән тыгыз бәйләнгән. Әдип биредә еш булган, авыл халкы белән күп аралашкан. Атаклы «Галиябану» пьесасын да ул шунда язган. Әсәренә прототипларны да шунда тапкан.

Узган ел М. Фәйзинең тууына 100 ел тулды. Халкыбыз аны зурлап билгеләп үтте. Үзләренең яраткан әдипләрен Шода авылы кешеләре дә ихтирам белән хәтерләрендә саклыйлар икән. Аның исемен мәңгеләштерү буенча да зур эшләр башкарганнар. Күптән түгел авылның борынгыдан калган бер корылмасы — Фәйзулла мулла йорты бинасында ачылды.

Музей ачылган көн Шода халкы өчен зур бәйрәмгә әверелде. Әлеге тантанага Казаннан ТССР мәдәният министры урынбасары М. Низамиев, шагыйрьләр И. Юзеев, Р. Мингалим, артистлар Р. Мотыйгуллина, И. Әхмәтҗанов, И. һәм Р. Төхфәтуллиннар килгән иде. Сәхнәдә «Галиябану» спектакленнән өзекләр күрсәтелде.

Шода авылында драматург М. Фәйзи истәлегенә ачылган әлеге музей киләчәктә бу як кешеләрендә халкыбыз тарихына, аның күренекле улларына хөрмәт һәм ихтирам, горурлык хисләре тәрбияләргә ярдәм итәр.

## КОМПОЗИТОР УҢЫШЫ

Узган ел азагында Санкт-Петербург шәһәрендә яшь композиторларның II халыкара музыка фестивале үткәрелде. Илнең төрле төбәкләреннән килгән яшь талантлар белән бергә, концертларда АКШ, Германия, Ирландия, Корея, Голландиядән килгән композиторларның күпләгән әсәрләре башкарылды.

Анда безнең Татарстаннан ТССР Композиторлар берлеге идарәсе рәисе Рәшит Кәлимуллин дә катнашты. Фестивальне ачу тантанасына багышланган камера әсәрләре концертында Рәшитнең виолончель өчен язылган сонатасы башкарылды. Аны Казан дәүләт консерваториясенең икенче курс студенты Андрей Каминский башкарды. Композиторның әлеге әсәре фестивальдә югары бәя алды.

## РӘССАМНАР ҖЫЕНЫ

21—22 ноябрьдә Татар милли мәдәни үзәгендә Татарстан рәссамнарының VII корылтае булды. Анда ТССР Рәссамнар берлеге идарәсенең эше турында аның рәисе Ә. Мәҗитов, РСФСР рәссамнар фондының Татарстан бүлегенең производство комбинаты эше турында Р. Кильдебәков ревизия комиссиясе рәисе урынбасары Ф. Якупов отчетлары тыңланды. Аннары әлеге докладлар буенча фикер алышу булды.

Съезд ТССР рәссамнар берлеге рәисен, аның идарәсен һәм ревизия комиссиясен сайлады. Идарә рәисе итеп Н. Әлмиев сайланды.

## ТӨРЕК ИЛЧЕСЕ — КАЗАН КУНАГЫ

Төрек Республикасының Мәскәүдәге илчелеге беренче секретаре Реха әфәнде Кескинтепе Татарстанга рәсми визит белән килде. Ул Казанның истәлекле урыннарын карады, музейларда булды һәм Югары советның депутат комиссияләре белән танышты. Югары Совет Рәисе Ф. Мөхәммәтшин белән очрашу вакытында Р. Кескинтепе Төркиянең Татарстан белән ике арадагы элемтәләрен тагын да ныгытырга теләк белдерүен әйтте. Сөйләшүләр барышында икътисади һәм мәдәни хезмәттәшлекне киңәйтү йөзеннән гомуми парламент группасы оештырырга кирәк дигән нәтиҗә ясалды. Чит илләрнең мөстәкыйль Татарстан белән торган саен ешрак кызыксына баруын сөйләүче шатлыклы вакыйга бу.

## ЯҢА КОМИТЕТ ЯҢАЧА ЭШЛИ

Татар иҗтимагый үзәге каршында оештырылган «Мәгариф» комитетының чираттагы утырышында Гомумтатар мәгариф ассоциациясенең оештыру съездын 1992 елның январь аенда Г. Камал исемендәге театр бинасында уздырырга карар кылынды.

Утырышта шулай ук «Мәгариф» комитетының уставы каралды һәм гамәлгә кертелде, комитетның штаты расланды. Эш планлы рәвештә кадрлар, балалар бакчалары, мәктәпләр, югары уку йортлары һәм башка бүлекләр буенча алып барылачак.

«Мәгариф» комитетының үз исәп-хисабы булдырылды. Җәмәгатьчелек, мәктәпләр, хезмәт коллективлары спонсорлар була алалар. Матди ярдәмне түбәндәге адрес белән юлларга мөмкин. Расчетный счет: «1700315 в Московском отделении ТСБ г. Казани МФО 265179. Комитет «Мәгариф».

Яңа уку елыннан татар балаларын барлык мәктәпләрдә дә аерым туплап укыту-тәрбияләү эше башланачак.

## СИБГАТ ХӘКИМ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәким әдәбиятыбызны үстерүгә, яшь талантлар тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш керткән замандашыбыз иде. 1911 елның 4 декабрендә Арча районы, Күлле Киме авылында туып үскән әдип олы һәм мактаулы тормыш юлы узды. Бөек Ватан сугышында катнашкан фронтовик үз иҗатында Ватан азатлыгы өчен корәшкән яудашлары батырлыгына багышлап күп санлы шигырь, поэмалар иҗат итте. Г. Тукайның якташы буларак, аның үлемсез образын дөньяга шаулатты. Халкыбыз йөрәгенә кереп урнашкан «Фазыл чишмәсе», «Башка берни дә кирәкми», «Кайда да йөрәктә», «Өзелгәнсең сиреньнән» һ. б. бик күп җырларның сүзләрен дә Сибгат Хәким язган иде. Хөкүмәтебез аның иҗатын югары бәяләде. Ул ТССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт (1960 ел), РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт (1970 ел) бүләкләренә лаек булды.

29 ноябрь көнне Татар милли мәдәни үзәгендә шагыйрьнең тууына 80 ел тулуны җөмһүриятебез җәмәгатьчелеге киң билгеләп үтте.

Кичәне кереш сүз белән ТССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев ачты. «Шагыйрьнең әсәрләре бүген дә актуаль, алар киләчәктә дә халык күңелендә яшәячәк»,— диде ул. Кичәдә чыгыш ясаган Башкортстаннан килгән шагыйрь Нажар Нәҗми, Татарстан әдипләре — Равил Фәйзуллин, Гариф Ахунов, М. Хөсәен, Лена Шакирҗанова, Газинур Моратов, язучының тормыш иптәше Мәршидә ханым, улы Рафаэль олуг шагыйрь турындагы истәлекләре белән уртаклаштылар.

Кичәнең икенче өлешендә шагыйрь иҗат иткән җырлар яңгырады. Аларны җөмһүриятебезнең танылган җырчылары Вафирә Гыйззәтуллина, Э. Җәләлетдинов, Галина Казанцева, Георгий Ибушев һ. б. башкарды.

## СӘФӘРЛӘР, ОЧРАШУЛАР

Узган елның ноябрь аенда каләмдәшләребез иҗтимагый-сәяси тормышта шактый актив булдылар. ТССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, мәсәлән, Швейцариядә интеллектуаль милекне саклау буенча Бөтендөнья үзәгенең (ВОИС) чираттагы конгрессында булып кайтты. Р. Батулла исә Төркиядә төрки халыклары алфавитын камилләштерү мәсьәләләренә багышланган конгресста катнашты һәм чыгыш ясады.

Язучылар В. Нуруллин белән Р. Мингалим Пермьдә татар һәм башкорт әдәбияты көннәрендә булдылар. Драматурглар Т. Миңнуллин белән И. Юзеев Уфада Башкорт дәүләт театрының баш режиссеры Р. Исрафилов юбилее тантанасында катнаштылар.

## ИДАРӘНЕҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ

ТССР Язучылар берлеге идарәсе 27 ноябрь көнне уздырган утырышында күп кенә мәсьәләләр карады. Шуларның берсе әдәби ел йомгакларына әзерлек мәсьәләсе. Январь азаклары яисә февраль башларында узачак бу җыен башка еллардан аермалы булачак. Анда бары бер доклад тыңланачак, аны Рахмай

Хисмәтуллин ясаячак. Соңыннан фикер алышулар үткәреләчәк.

Идарә утырышында, шулай ук, «Казан утлары» журналының яңартылган редколлегиясе, язучыларның киләчәктә чыгачак «Әдәби җомга» газетасының исемен, әдипләребез Г. Исхакый, Н. Арслан, Ә. Исхак әдәби мирас туплау комиссиясе әгъзаларын раслау булды. Шушы ук утырышта идарә әгъзалары итеп язучылар Г. Ахунов, М. Мәһдиев расланды.

ТССР Язучылар берлегенең әлеге утырышында Ф. Рәсүлова, Б. Рәхимова, Ш. Җиһангирова, А. Литвин, П. Прихожан, Ә. Сәфиуллин Язучылар берлегенә кабул ителде.

## «ВАКЫТ»НЫҢ ДӘВАМЫ

1917 елга кадәр татар халкы яши торган төбәкләрдә күпләгән газета, журналлар нәшер ителүе мәгълүм хакыйкать. Шундый басмаларның берсе Оренбург каласында «Вакыт» исеме белән чыккан газета иде. «Вакыт» газетасының беренче саны 1906 елның 21 февралендә чыга. Г. Тукай, Дәрдемәнд, Ж. Вәлиди, Й. Акчура, Г. Ибраһимов, Ш. Камалларның иң затлы әсәрләрен үз битләрендә баскан, Фатих Кәриминең ялкынлы, акыллы публицистик язмаларын басып татар доньясын шаулаткан газета була «Вакыт».

1918 ел 26 гыйнварда Оренбур мөселман хәрби-революцион комитеты милләткә уникс ел хезмәт иткән газетаның кәгазен конфисковать итә, шул көннән башлап газета чыгудан туктый.

Бүгенге көнгә кадәр татарлар күп яши торган Оренбург өлкәсендә үзебезнең телдә газета чыкмады. Менә, ниһаять, 73 елдан соң бу гаделсезлек бетерелде. Оренбурда «Яңа вакыт» исеме белән атналык иҗтимагый газета чыга башлады. Аның беренче саны ук Оренбургта яшәүче якташларыбызның тормышын, халкыбызның ирек өчен көрәшен чагылдыруга багышланган. Газета әдәби әсәрләргә дә зур урын биргән. Язучы М. Мәһдиевның газетаны котлап, тарихыбызда зур эз калдырган «Вакыт» газетасына тәпле бәяне биреп язылган мәкаләсе дә урнаштырылган.

## СӘЙДӘШ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Бу гасырның соңгы ун елында халкыбызның мәшһүр композиторы Салих Сәйдәшев истәлеге зурлап билгеләп үтеләчәк. Мәдәниятыбызга караган оешмалар белән бергә, Татарстан мәдәният фонды шул хакта махсус чаралар билгеләп куйды. Эш башланды да инде.

Өченче декабрьдә җәмәгатьчелек Салих Сәйдәшев каберенә зиярәт кылды. Чәчәкләр салынды, аның турында истәлекләр сөйләнде. Биектау районының Өбрә авылы музеенда узган очрашу да истәлекле булды. Анда композиторлар, язучылар катнашты. 10 декабрьдә исә Татар мәдәният үзәгендә С. Сәйдәшев әсәрләреннән әзерләнгән зур концерт булды. Анда моңа кадәр яңгырамаган җырлар да башкарылды. Тамашада композиторның туганнары, язучы Гомәр Бәширов, артист Шириязданл Сарымсаков кебек замандашлары да катнашты.

# КИТАПЛАР ДӨНЬЯСЫНДА

Татарстан китап нәшрияте 1991 елда түбәндәге китапларны бастырып чыгарды:

Гамил **АФЗАЛ**. Сайланма әсәрләр. *Лирик һәм юмористик шигырьләр.* 400 бит, портрет белән. Б. 4 с. 20 т.

Гариф **АХУНОВ**. Гомер юлы. *Роман һәм повесть.* 288 бит. Б. 3 с.

Рина **АСЫЛБАЕВА**. Болытка хат. *Шигырьләр.* 16 бит, рәсемнәр белән. Б. 30 т.

Балалар календаре. 112 бит, рәсемнәр белән. Б. 1 с. 20 т.

Кол **ГАЛИ**. Кыйссаи Йосыф. *Дастан.* 224 бит, портрет белән. Б. 1 с. 50 т.

Әхмәт **ГАДЕЛ**. Серле күпер. *Шигырьләр, җырлар.* 112 бит. Б. 40 т.

Рәшит **ГӘРӘЙ**. Тургайлы тугайларым. *Шигырьләр.* 256 бит, портрет белән. Б. 2 с.

**ДАЛА ГӨЛЛӘРЕ**. *Казакъ повестьлары.* 434 бит. Б. 4 с. 60 т.

Җәүдәт **ДӘРЗАМАНОВ**. Айбулат. *Әкият-поэма.* 24 бит, рәсемнәр белән. Б. 1 с.

Әмирхан **ЕНИКИ**. Сайланма әсәрләр. Өч томлык. 2 том. Әйтелмәгән васыять. Без дә солдатлар идек. Гөләндәм туташ хатирәсе. 416 бит. Б. 3 с. 40 т. 3 том. *Хикәяләр.* 416 бит. Б. 3 с. 20 т.

Әнисә **ИБРАҺИМОВА**. Сары умырзаялар. *Повестьлар.* 208 бит. Б. 1 с. 50 т.

Әбрар **КӘРИМУЛЛИН**. Татарлар: исемебез һәм җисемебез. 160 бит. Б. 1 с. 40 т.

Мәгъсүм **ЛАТЫЙФУЛЛИН**. Сәйдәшнең балачагы. *Повесть.* 144 бит. Б. 30 т.

Фәнил **МАНСУРОВ**. Агыйделкәй алкын. *Повестьлар һәм хикәяләр.* 256 бит, портрет белән. Б. 2 с. 70 т.

Роза **МУЛЛАНУРОВА**. Чйшмә күзе. *Балалар өчен хикәяләр.* 96 бит, рәсемнәр белән. Б. 1 с.

Хуҗиәхмәт **МӘХМҮТОВ**. Ел тәүлеге — унике ай. *Халык календаре битләреннән.* 128 бит, рәсемнәр белән. Б. 70 т.

Илдар **НИЗАМОВ**. Өзелгән революция. *Тарихи повесть.* 128 бит, рәсемнәр белән. Б. 90 т.

Шамил **РӘКЫЙПОВ**. Кайдан син, Җан? *Повесть.* «Мәктәп китапханәсе» сериясеннән. 384 бит, портрет белән. Б. 1 с.

Мәрди **РӘФЫЙКОВ**. Сазлыктагы утлар. *Очерклар.* 128 бит. Б. 90 т.

Бикә **РӘХИМОВА**. Кырмыскалар өендә. *Шигырьләр.* 48 бит, рәсемнәр белән. Б. 10 т.

Габделхәй **САБИТОВ**. Урман кызы. *Хикәяләр һәм пьеса.* 208 бит. Б. 1 с. 20 т.

Әхмәт **РӘШИТОВ**. Давыллар кайтавазы. *Шигырьләр, поэма.* 80 бит. Б. 30 т.

Заһид **ФӘЙЗИ**. Язмыш бормалары. *Повесть.* 224 бит. Б. 1 с. 90 т.

Роза **ХАФИЗОВА**. Актәпи ник моңая? *Әкиятләр.* 222 бит. Б. 1 с. 10 т.

Ризван **ХӘМИДУЛЛИН**. Китәм инде. *Пьесалар.* 382 бит, портрет белән. Б. 3 с.

Гарәфи **ХӘСӘНОВ**. Елның дүрт фасылы. *Табигать турында хикәяләр.* «Мәктәп китапханәсе» сериясеннән. 320 бит. Б. 2 с. 40 т.

Нурислам **ХӘСӘНОВ**. Бәхилләрме йөрәк? *Повестьлар һәм хикәяләр.* 304 бит, фото белән. Б. 2 с. 60 т.

Мәгъсүм **ХУҖИН**. Юл өзеге. *Документаль повесть.* 96 бит. Б. 35 т.

Риза **ШӘФИ**. Җомак әйтәм — җавап көтәм. 16 бит, рәсемнәр белән. Б. 20 т.

**ӘДӘБИ МИРАС**. Беренче китап. 208 бит. Б. 2 с. 80 т.

Тәүфикъ **ӘЙДИ**. Безгә ни булды? *Эсселәр, мәкаләләр.* 184 бит. Б. 1 с. 40 т.

Тәүфикъ **ӘЙДИ**. Елан угы. *Роман.* 368, бит, портрет белән. Б. 4 с.

Габдрахман **ӘПСӘЛӘМОВ**. Ак чәчәкләр. *Роман.* 512 бит. Б. 2 с.

Рәшидә **ҖИҺАНШИНА**. Күңелем түреннән. *Истәлекләр.* 96 бит, рәсемнәр белән. Б. 90 т.

## Урыс телендә:

Абдрахман **АБСАЛЯМОВ**. Газинур. *Роман.* «Татар романы китапханәсе» сериясеннән. 384 бит. Б. 3 с. 60 т.

Флер **БАГАУТДИНОВ**. По закону 34-го года (1934 ел кануны буенча). 136 бит. Б. 20 т.

Фаниль **ГАЛИЕВ**. Рассказы следователя Сомова (Тикшерүче Сомов хикәяләре). 96 бит. Б. 60 т.

Мансур **ГИЛЯЗОВ**. Лунные врата (Айлы капкалар). *Пьесалар.* 189 бит. Б. 85 т.

Гамир **ДАВЛЕТШИН**. Духовная культура Волжской Булгарии домонгольского периода (Идел Болгарстанының монголларга кадәрге дәвере рухи мәдәнияте. X—XIII йөзләр). 192 бит, рәсемнәр белән. Б. 45 т.

Котдус **ДАВЛЕТШИН**. Из мудрости веков (Гасырлар зирәклегеннән). *Фольклорны тикшерү.* 125 бит. Б. 1 с.

Амирхан **ЕНИКИ**. Невысказанное завещание (Әйтелмәгән васыять). *Повестьлар һәм хикәяләр.* 480 бит. Б. 4 с. 50 т.

Марсель **ЗАРИПОВ**. Медовый край (Баллы як). *Повестьлар, хикәяләр, очерклар.* 464 бит, портрет белән. Б. 4 с. 50 т.

**ЗНАМЕНИТЫЕ ЛЮДИ О КАЗАНСКОМ КРАЕ** (Атаклы кешеләр Казан ягы турында). 224 бит. Б. 2 с. 40 т.

**ИДЕГӘЙ**. Татар халык дастаны. 256 бит. Б. 3 с.

**ИСТОРИЯ КАЗАНИ** (Казан тарихы). 2 китап. Совет дәвере. 382 бит. Б. 4 с. 30 т.

**КОРАН** (Коръән). Урысчага И. Ю. Крачковский тәрҗемәсе. 512 бит. Намазлыгы белән 55 с. 47 т.

Шайхи **МАННУР**. Глядя на текучие воды (Агымсуларга карап). *Повесть.* 352 бит. Б. 4 с. 80 т.

Рафаэль **МУСТАФИН**. Древняя и вечно молодая (Борынгы һәм мәңге яшь). *Татар шагыйрьләре әдәби портретлары.* 240 бит. Б. 2 с. 20 т.

Ибрагим **НУРУЛЛИН**. Прометей из Новотатарской слободы (Яна бистә Прометее). *Документаль повесть.* 270 бит. Б. 1 с. 70 т.

**РУССКО-ТАТАРСКИЙ СЛОВАРЬ** (Урысча-татарча сүзлек). 735 бит. Б. 15 с.

Рустем **САБИРОВ**. Прощание с ангелом (Фәрештә белән саубуллашу). *Хикәяләр.* 192 бит, портрет белән. Б. 1 с. 60 т.

Ибрагим **САЛАХОВ**. Черная колыма (Кара Колыма яки Тайгак кичү). *Роман.* 318 бит, портрет белән. Б. 4 с.

Флера **САФИУЛЛИНА**, **КАМИЛЬ ГАЛИУЛЛИН**. Русско-татарский разговорник (Урысча-татарча сөйләмлек). 2 басма. 320 бит. Б. 2 с. 70 т.

Михаил **ХУДЯКОВ**. Очерки по истории Казанского ханства (Казан ханлыгы буенча очерклар). 310 бит. Б. 15 с.

Якындагы кибеттә булмаса, бу китапларны почта аша сорап алдырырга мөмкин. Адреслар: 420057, Казан шәһәре, Октябрьская урамы, 18. «Китап-почта» кибете. 420084, Казан шәһәре, Бауман урамы, 19. 1—китап кибете, «Китап-почта» бүлеге.

# НАИЛ ЛОТФУЛЛА ӘСӘРЛӘРЕ

Быел журнал тышлыгында яңа серия ачып җибәрәбез. Үткән еллардан аермалы буларак, тышлыкта халык иҗаты җәүһәрләре түгел, ә профессиональ рәссамнарның иҗат җимешләре — безнең замандашларыбыз тудырган сәнгать әсәрләре булачак.

Әлбәттә, хәзерге рәссамнарның эшләре үткән чор әсәрләреннән шактый нык аерылып тора. Ләкин, шуңа да карамастан, без яңа серияне алып барганда бүгенге татар сәнгатенең торышын тулы чагылдырырга тырышачакбыз. Татарстанда гына түгел, ә аннан читтә яшәүче рәссамнарыбызның да хезмәтләре укучыга тәкъдим ителәчәк. 1991 елның маенда Ленинградта ачылган, ә аннары Казанда дәвам иткән «Татарт — 91» күргәзмәсе безнең бу серия өчен төп нигез булачак.

Беренче санда сезнең игътибарга талантлы рәссам Наил Лотфулла әсәрен чыгарабыз. Ул Уфа шәһәрендә яши. Андагы татар рәссамнарын «Чыңгыз хан» дип аталган берләшмәгә туплаучы һәм бу иҗади оешманың рухи җитәкчесе буларак, Наил Лотфулла соңгы елларда дан казанды. Оешмага тагын В. Ханнанов, Р. Харис, бертуган Әхмәтвәлиевлар, И. Бикбулатов һ. б. керә. «Чыңгыз хан»ның беренче зур күргәзмәсе 1990 елда Ленинградта узды һәм бик тиз арада тамашачыларның, сәнгать белгечләренең, шулай ук чит ил коллекционерларының игътибарын яулап алды. Хәтта без хәзер бу төркемне Башкортстанда яшәүче иң алдынгы сәнгатьчеләр дип тә әйтә алабыздыр. Һәрхәлдә, бүгенге татар рәсем сәнгатенең дөнья күләмендә игътибар казана алырлык дәрәҗәгә җитүен телибез икән, без бу оешманы читләтеп үтә алмаячакбыз. Наил Лотфулланың әсәрләре чит илләрдәге сәнгать белгечләре теленә керүе һәм аның ярты ел дәвамында АКШтагы Милли Мәдәни үзәктә эшләве, үз әсәрләрен андагы халыкка күрсәтүе дә безнең бу өметләрне ныгыта.

Наил Лотфулланың тормыш юлы Уфа шәһәре белән бик тыгыз бәйләнгән. Биредә ул урта мәктәптә укый, сәнгать училищесын тәмамлый, аннары Совет Армиясендә хезмәт итә, ә инде 1984 елдан башлап бөтен көчен сәнгатькә багышлый. 1900 елда аны СССР Рәссамнәр берлеге әгъзасы итеп алалар.

Бу рәссамның әсәрләре күп санлы күргәзмәләрдә урын алып килә. Аларның күбесе, әлбәттә, Башкортстанда уздырылган. Ләкин биредә бер нәрсәгә игътибар итү зарур: республикада яшәүче татар рәссамнары үзләре теләп төрле-төрле төркемнәргә берләшкәннәр. Алар биредә үз әсәрләрен иркенләп тикшерәләр, кызып-кызып бәхәсләшәләр, күргәзмәләр оештыралар — кыскасы, бик тә кызыклы иҗади тормыш белән яшиләр. «Чыңгыз хан» дигән исемне алулары да безнең милләтне монгол дәвамчылары дип санаганга түгел, ә татар тарихына тамашачы, халык игътибарын җәлеп итәргә теләүдән.

Наил Лотфулла әсәрләре бик тә үзенчәлекле булулары белән аерылып тора. Безнең тышлыкка чыгарылган «Философ» дигән әсәр дә әнә шуны раслый.

Биредә мәңгелек хакыйкать булып балкучы кояш та бар, үзгәреш һәм алышынулар символы булган болытлар да күренә, ә үзәктә ап-ак җиңле кул сурәтләнгән. Кулның бармаклары нәрсә белгерткәнен, әлбәттә, сез үзегез дә бик яхшы аңлыйсыз. Анда — безнең чор, хәзерге заман эчтәлеге дип әйтергә дә була. Кайбер идеяләрнең тирән кризисы да чагыла аңарда.

Менә шушы әсәрдә рәссамның иҗат үзенчәлеге дә бик ачык күренә. Ул бер үк вакытта реалист та һәм экспрессионист та. Аны хәтта авангардист дияргә дә мөмкин. Чөнки ул заман билгеләрен бик нечкә тоя.

Наил Лотфулла үз әсәрләрендә бик кырыс та була ала, кайчагында исә аның әсәрләре, киресенчә, төсләр, буяулар муллыгы белән гаҗәпләндерә, сокландыра. Аларда еш кына көнчыгыш әһәңнәре өстенлек итә.

Наил Лотфулла әсәрләрен башка бер генә рәссамныкы белән дә бутау мөмкин түгел. Бу рәссамның иҗаты да аның шәхесе кебек — кабатланмас һәм талантлы.

**Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА**,
сәнгать белгече.


Тышлыкның дүртенче битендә: күренекле язучы һәм тәнкыйтьче Р. Мостафин.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотолары.

Бәясе 1 сум 80 тиен

Аерым сатып алучылар өчен 3 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог